Галимҗан Гыйльманов

Оча торган кешеләр

*Роман, повестьлар, бәяннар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

2007

УДК 821.512.145-31

ББК 84 (2Рос=Тат)-44

Г92

**Гыйльманов Г.Х.**

Оча торган кешеләр: роман, повестьлар, бәяннар / Галимҗан Гыйльманов.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.— 463 б.— 3000 д.— ISBN 978-5-298-01498-4

Галимҗан Гыйльманов — бүгенге көн татар прозасында үз стилен, үз юлын, үз образлар дөньясын булдырган язучыларның берсе. Аның үтә дә мавыктыргыч геройлары хыял белән чынбарлык чигендә яшиләр, шул ук вакытта алар тетрәндергеч язмышлы, әмма үз идеалларына, рухи кыйблаларына тугры калалар. Язучының халыкчан, мәгънәле һәм иманлы иҗаты бүгенге татар укучысын битараф калдырмас дип ышанабыз.

ISBN 978-5-298-01498-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Гыйльманов Г.Х., 2007

# РОМАН

## *ОЧА ТОРГАН КЕШЕЛӘР, ЯКИ*

Иясез язмышлар хакында бәЯн

Кешенең иң бәхетле чагы — бала чагы.
Үлемнән иң ерак чагы бит аның…

*Әнкәй сүзләре*

### 1

Поезддан төшкән бу кешегә беркем дә игътибар итмәде. Гадәти юлчылардан берни белән дә аерылмый кебек иде ул: күп киелүдән күркәмлеген җуйган, төсе уңа башлаган яшел костюмнан, шакмаклы күлмәктән. Аның өстенә иске фасондагы галстук таккан. Кулында күп ышкылудан, бәрелүдән почмаклары кырыла башлаган кара чемодан… Шулай да нәрсәсе беләндер башкалардан нык аерылып та тора ул. Нәрсәсе белән аерыла соң? Ә! Аңлашылды… Үтә дә гамьле-борчулы, хәтта кайгылы иде аның йөзе. Юк–юк, бәла-каза яисә үлем-китем кайгысы түгел бу. Нindидер эчке моң, эчке гамь-сагыш бәреп чыккан иде аның йөзенә. Җыйнак кына мыек җибәргән, тыйнак кына, әмма ыспай итеп чәчен кистергән бу юлчыга кырык биш яшьләр чамасы булыр. Үзе укымышлы-зыялы кешегә охшый — ак, чиста йөзен бизәп торган яшькелт-зәңгәр күзләре читендәге берничә җыерчыктан кала картаю чалымы күренми. Бу күзләр җирән чәчләренә ай-һай килешеп тора тагы… Бераз сәеррәк йөри: берничә адым атлый да җилкәсен сикертеп куя, атлый да сикертеп куя. Әйтерсең аркасында авыр йөк бар, ул шул йөкне ара-тирә рәтләп, җайлап куя… Аның иңендә канатлар бар кебек, гүя ул бара-бара да шул канатларын барлап ала. Очар иде — очалмый, нидер аска, җиргә тартып, басып тора. Нindидер авырлык бар аның иңендә. Ә бәлки, күңелендәдер?

Бөтен, имин, әйбәт тормышта яшәгән булырга тиеш ул. Шулай да аның йөзенә чыккан теге моңсулык, сагыш-гамь күңелгә тынгылык бирми: нидер борчый бу кешене, нәрсәдер аның күңел тынычлыгын алган, шушы «нәрсәдер» җанын туктаусыз бимазалап, изалап тора, йөрәген әрнетә… Бәхет белән өмет — кардәшләр, әмма өмет белән сагыш та — туганнар. Шуларның өчесеннән язмыш туа. Бу кешенең язмышы да гади-гадәти түгел, ахры. Рухы арыган кешеләр белән гел шулай була — бөтен кыяфәтләре сәламәтлек, пөхтәлек бөркеп торса да, андыйлар башкалар күзенә бәхетсез булып күренәләр…

Әмма кеше үзе теләгән кадәр генә бәхетле була!

Бәхетнең кардәше — өмет.

Рух нык булганда гына кеше күңелендә өмет туа һәм яши ала. Өмет бар икән, әгәр дә чын икән, ихлас икән, ул бервакытта да кешене алдамый.

Авыл юлына төшкән бу бәхетсез Хода бәндәсенең һәр ым–хәрәкәтендә әнә шул чын, ихлас өмет нуры бөркелеп тора иде…

Бу юл аны кая алып бара? Бәхетенәме, бәхетсезлегенәме? Бәхеткәдер… Бәхеткә, бәхеткә! Бәхеткә алып баручы юл — үзе бәхет инде. Чынлыкта бәхет үзе юк, бәхеткә илтүче юл гына бар.

Әйе, бәхет эзләүче бәхетледән дә бәхетлерәк…

Ярар. Укучы ихтыярын башкача сынамыйм. Бу гамьле кешенең исеме — Сәүбән. Ул ерак каладан туган авылына кайтып бара. Унсигез ел кайтмаган ул туган нигезенә. Менә хәзер кайтып бара. Ял-

гызы гына кайта. Юк-юк, әллә ниләр уйламагыз. Гаиләсе бар аның: хатыны, үсеп җиткән малае бар. Бу хакта бер сөйләр әле ул сезгә. Ә хәзер аның вакыты юк. Ул борчылып уйлана. Шулай борчылып, тәүлек буе поездда кайтты, менә хәзер дә — авыл юлына төшкәч тә — күңелен җыеп ала алмый, уйлана да уйлана, сызлана да сызлана…

Уен эшмени — унсигез ел бит!.. Авылдан чыгып киткәндә үсмер бала гына иде әле ул. Борынына ис, күңеленә хис керә башлаган малай иде. Кайда калган ул чаклар — бала чаклар — бал чаклар?!

Кайсыдыр изге китапта әйтелгән бит: «Алла безгә биргән рухны нык сагына», — дигән. Әйбәт, изге җанлы, күркәм рухлы кешеләрнең Аллаһы Тәгалә катына бик иртә китеп баруы шуның белән аңлатыла булса кирәк. Яман ниятле явыз бәндәләрдә рух бик тиз тузып-таушалып бетә икән — ни гаҗәп! Андыйлар гайрәтне чигәрерлек дәрәҗәдә озак яшиләр. Туган җир белән дә шулай. Изге җанлы, саф рухлы балаларын Туган җир һәрвакыт сагынып яши, үзенә чакырып, ымсындырып тора. Кызык, балачак белән дә нәкъ шулай икән. Балачак та гел сагышта, гел гамьдә. Кеше алдагы тормышында ниләр генә эшләмәсен, аның бөтен ният-хыяллары, кылган эш-гамәлләре һәм, әлбәттә инде, эчке рухияте дә бала чагы ихтыярында кала. Ничәмә-ничә мәртәбәләр сыналган фал — кеше үзенең туган җирен, туган нигезен, бала чагын сагынмый башлый икән, дөресрәге, аны туган җире, туган нигезе, бала чагы сагындырмый башлый икән, димәк, аңа нидер булган, ул үзенең рухи орбитасыннан ычкынган, бала чагыннан ук килгән гомер юлыннан читкә тайпылган, кыйбласын югалткан, Иблис коткысына бирелгән…

Сәүбән белән дә шулай булды, ахры. Ул кайдадыр, кайчандыр ялгышты. Гомер юлының бик мөһим бер борылышында читкә каерылып кереп китте дә… юлдан язды, сукмагын югалтты… Бөтен көчен, сәләтен салып тырышса да, әллә ни кыра алмады: эше җиңел бирелсә дә, хезмәтендә зур уңышларга ирешмәде, гаилә тормышыннан канәгать булса да, бәхеткә бөтенәймәде. Менә хәзер ул, гаиләсен, яшәгән йортын һәм күпьеллык хезмәтен ташлап, авылына — туган йортына, газиз ялгыз әнкәсе янына кайтып бара.

Озак еллардан соң балачакка кайту рәхәт тә, кыен да икән. Хәтта… куркыныч та! Чөнки кеше бала чагына ике очракта гына кайта: нәрсәдәндер качканда яисә бик мөһим бер әйберен эзләгәндә… Сәүбән кистереп кенә әйтә алмый: качып кайтамы ул, әллә күңеле теләгәнне эзләп кайтамы? Бу, бәлки, ул чаклы мөһим дә түгелдер. Иң мөһиме — ул кайта. Кайтмаска ант итеп киткән җиренә кайта. Бәхиллек алмыйча киткән нигезенә кайта. Саубуллашмый-нитми киткән әнкәсе янына кайта… Ни өчен кайтамы? Моның сәбәбе бар. Ул авырды, үлемнең күзенә карады… Шул үлем әҗәле аңа туры карап әйтте: «Кайт бар, авылыңа кайт, гомер, нәсел йолдызыңны рәнҗетергә теләмәсәң, нәселеңне югалтасың килмәсә, кайт, кайт!» — диде.

Юк, башта ук үлемне искә алып, укучының нәзберек, нәзакәтле күңелен өркетмим әле. Сәүбәннең гомер таңында матуррак хатирәләр дә булган бит. Нигә шулар хакында сөйләмәскә?!

Әй ул чаклар! Әй ул тиле чаклар!.. Нәрсә генә булды соң әле ул вакытта? Хәзер инде хәтергә дә төшереп бетерә алмассың…

Артыграк яратты шул ул Сәвиясен. Баштарак бөтенесе дә әйбәт, матур иде. Төннәр буе озатышып йөрүләр дисеңме, татлы үбешүләр, онытылып сөешүләр дисеңме… Сөеп үбешкәндә җаннар алмашына, диләрме әле? Мәхәббәт мөнбәренә басып, алар бер мәртәбә генә «җан алмашмадылар». Җан белән бергә иң кадерле, иң газиз серләр дә, ант-вәгъдәләр дә алмашынды…

Ләкин болары кызык түгел әле. Болары — һәр гашыйк пар белән була торган хәлләр… Сәүбән белән Сәвия бер-берсенә тартылган көннән алып мавыктыргыч шөгыль уйлап таптылар: бер-берсе белән йолдызлар аша сөйләшә башладылар. Ничекме? Сарманай авылыннан бер чакрым ераклыкта Кала-тау бар. Ә-ә-әнә ул. Бу тау итәгендә юкәләр үсә. Шул юкәләрнең берсен сайлап алалар да, икесе ике ягына сөялеп басып, күктәге йолдызларга багып «сөйләшәләр»... Бигрәк тә Чулпан йолдыз аша тиз «аңлашалар»…

— Сәүбән, син кем булыр идең?

Сәүбән дәшми, бары тик йолдызга карап җавап уйлый.

Сәвия аның җавабын үзенчә юраган була:

— Очучы буласыңмы?

— Әйе! Белдең…

— Сәүбән, синең хыялың бармы?

Үзе тагын йолдызга карап юрый:

— Бар, бар синең хыялың!.. Синең хыялың… Синең хыялың… Җиргә, менә шушы Кала-тауга, өстән, күк катыннан карыйсың килә, шулаймы?

— Юк, белмәдең… Минем сине үбәсем килә!..

— Ә син хәрәмләшмә! Дөресен әйттемме, дөресме? Йә инде…

— Дөрес-дөрес, үпкәләмә яме, мин бит шаяртып кына…

— Сәүбән, ә син кемне яратасың?

Сәүбән дәшми. Сәвиянең карашлары төнге күктә. Ул килештереп уйланган була. Белмәгәнгә салыша. Аның юри белмәгәнен Сәүбән дә сизеп тора. Шуңа да юри ашыктыра:

—Йә инде, әйт инде.Чулпан йолдыз берни дә сөйләшмиме әллә?..

— Чулпан әйтә… Чулпан әйтә… Ул берни дә әйтми, Сәүбән…— Кинәт Сәвиянең тавышы каядыр убылып төшеп китә.

Сәүбән барыбер ышанмый. Көлә, шаяра. Ә Сәвия шаярудан узган. Аның йөзе инде көлми, күзләре дә көлми. Алар төнге күктә, шомланып карап торалар.

— Чулпан дәшми, Сәүбән…

Сәүбән Сәвиянең шаярмаганын аңлый, качып торган җиреннән чыга.

— Ничек инде — дәшми?..

— Дәшми…

— «Сәвия» дип тә әйтмиме?

— Әйтми…

Сәүбән аны үзенең киң кочагына ала, яңакларыннан, чәченнән назлап сөя, маңгаеннан үбеп ала.

— Ул бездән көнләшә, Сәвия. Безнең бәхетебездән көнләшә…

— Әйдә, кайтып китик, үпкәләмик без аңа. Янсын шунда ялгызы гына, шул кирәк аңа…

Инде кайту юлына төшкәч, Сәвия, Сәүбәннең каршына ук килеп, капыл сорап куя:

— Сәүбән, син мине яратасыңмы?

— Яратам, Сәвия…

— Чынлапмы?

— Чынлап… Миңа сине явату җиңел, чөнки син искиткеч чибәр, Сәвия!..

Ул төнне Чулпанның дәшмәве юкка булмаган икән.

Озакламый аларның тормышында бөтенесе дә буталды, өмет-хыяллары чәлпәрәмә килде, күңел савытлары томаланып, карашлары төссезләнеп, яшәүләренең яме, назларының тәме бетте… Сәүбәннең сөю-мәхәббәтеннән дә ачыну катыш әрнү генә, рәнҗү генә торып калды; ул гомер йомгагының очын, язмышының иясен югалтты…

Ул көнне Сәүбән кичке уенга соңрак чыкты. Авиация институтына барырга әзерләнә иде ул. Казанда яшәүче Хөрмәт абыйсы бик кирәкле китап табып җибәргән, шуның белән мавыгып, вакыт узганын сизми дә калган.

Сарманай авылы яшьләре иртә яздан башлап көз ахырына кадәр инеш буендагы Сабантуй яланына кичке уенга чыгалар. Элегрәк мондый уеннар һәр татар авылында булган. Ә менә сарманайлылар бу матур йоланы бүген дә онытмаганнар.

Яр буенда хәтфә кебек җәелеп яткан җете яшел чирәмлектә очып-очып биеп китәләр!.. Башта ялгызаклар чиратлашып бии, аннары парлы биюләр китә… Ахырдан уен күмәк биюләр белән тәмамлана…

Күмәк биюләрнең иң кызган вакытында төшеп җитте Сәүбән инеш буена. Төшүен төште, әмма Сәвиясен таба алмады. Ян-ягына каранып эзләнгән арада, Зәлифә исемле күрше кызы аны җилтерәтеп түгәрәк эченә алып кереп тә китте, ике кулыннан тотып, үз тирәсендә әйләндерергә кереште. Сәүбән каршы килмәде, көне буе өйдә утырып ойый башлаган аякларын үз иркенә җибәрде — бию дигән тылсым ихтыярына тапшырды…

Бөтерелеп, дәртләнеп күпме биегәннәрдер, кайсыдыр бер мизгелдә Сәүбән тагын Сәвиясен исенә төшерде. Ул инде түгәрәктән чыкмакчы да булган иде, әле ярый бию тукталып калды, яшьләр таралыша башладылар.

Сәүбән Сәвиянең юклыгын нәрсәгә юрарга да белмәде. Бу юлы да уйланып, аптырап озак торырга туры килмәде, Зәлифә аны тагын култыклап алды да сөйрәп диярлек авылга алып кайтып китте.

— Әйдә кайтабыз, булмаган Сәвияңне көтеп торма,— диде ул.

— Булдымы соң ул бүген?

— Анысын инде үзеннән сора, күршекәем…

Шулай икәүләшеп кайтып киттеләр. Зәлифә җәһәт кенә Сәүбәнне култыклап алды. Егет читкә тайпылып караган иде дә, кызый аның беләгенә тагын да ныграк ябышты. Дөресен генә әйткәндә, Сәүбәннең үзенә дә яшьлеге ташып торган, дәртле, чая күрше кызының кайнар беләген тоеп бару рәхәт иде…

Тел бистәсе буларак даны чыккан Зәлифә озак көттермәде:

— Борыныңа чиерттеме Сәвияң?!

— Нигә алай дисең?

— Кайда соң ул, йә әйт, кайда?

— Кайда булсын, кайтып киткәндер…

— Китте ди сиңа!

— Йә, башны тинтерәтмә әле, болай да көне буе формула ятлап чиләнгән баш ул.

— Чиләнәсе көннәрең алда әле…

— Әллә ничек сөйләшәсең син бүген, Зәлифә, ичмаса, син дә үртәмәле җанны…

— Йә, бетте-бетте. Мин бит шаяртып кына…

Бераз сөйләшмичә бардылар. Зәлифә башын Сәүбәннең кулбашына салды. Үзе астыртын елмая.

— Безнең болай барганны күреп калсалар, ә, Сәүбән?

— Чынлап та, Зәлифә, кыланма әле, җитте сиңа…

Сәүбән бу сүзләрне әйтүен әйтте, әмма Зәлифәнең башын читкә алып куймады. Аңа рәхәт иде. Сәвия андый түгел бит. Кайтканда якын да китерми үзенә, үзе дә якын килми. Юкә янында гына сөйдерә, үптерә… Кыргыйлык җитәрлек аңарда… Шушы ымсындыруы, үзенә тартып торуы белән, һаман саен янына якын җибәрмәве белән яраттырды да инде ул Сәүбәнне.

Төн пәрдәсен ертып бара торгач (бүген йолдызлар да аз, ә менә Чулпан үз урынында, тик бераз моңсурак кына), Зәлифәләрнең капка төбенә килеп җиттеләр. Әмма, алдан ук сүз куешкан шикелле, алар бу таныш зәңгәр капканы узып киттеләр. Сәүбәннәр турысында да сүз катучы булмады, ниндидер бер яшерен көч, тылсым-гипноз бу ике яшь йөрәкне алга — хәтәр билгесезлеккә әйдәп алып китте…

Чынлыкта алар арасында берни дә юк бит: уртак хис тә, уртак хыяллар да, вәгъдәләр дә… Кечкенәдән бергә тәгәрәшеп үскән ике яшүсмернең соңгы мәртәбә урам уравы, шул рәвешле матур итеп хушлашуы гына иде бу.

Их, алай гына булса!

Теге яшерен көч юкка алып бармаган икән аларны. Сәүбәннең матур яшьлегенә, ихлас мәхәббәтенә, саф хисләренә киртә кую өчен этеп-төртеп китергән икән аны монда дөм караңгы төннең кара рухы!

Инеш яры буенда бер-берсенә сыенышып утырган бу парны алар ерактан ук күреп килделәр. Зәлифә нәрсә уйлагандыр, Сәүбәннең күңеленә шунда ук сәер бер тойгы үрмәләп керде. Керде дә, иң нечкә бер урынны сайлап, кетер-кетер кимерә башлады.

Авызларына су кабып бара бирделәр. Сәүбән кире борылырга да уйлаган иде. Зәлифә көләр дип курыкты. Күрше кызы белән китеп барганнан ни була соң?! Сәвия генә күрмәсен, ул инде көлеп кенә калмас, әллә нәрсәләр уйлап, мәңге кичермәслек итеп үпкәләр.

Сәүбән тоеп, сизеп килде — нидер булыр кебек. Әнә бит йөрәге ничек тынгысызлана: әле кирәгеннән артык кага башлый, әле шып туктап кала.

Шомлануы юкка булмаган икән. Яр башында, тын гына агып яткан кичке инешкә карап, югары оч атаманы Рәмис янында аның Сәвиясе утыра иде!..

Шуннан соң нәрсә булганын Сәүбән ачык кына хәтерләми. Сәвия белән күзгә–күз карашып, берникадәр телсез калып торганын гына чамалый:

— Сәүбән?..

— Сәвия?..

Аннары ул үзеннән әллә никадәр көчлерәк, «төптән чыккан» Рәмискә барып ябышкан. Ул кичне алар кара канга батып сугышканнар. Елап шешенеп беткән Сәвияне Зәлифә алып кайтып киткән. Сәүбән һаман Рәмискә сикергән, тегесе аны тәпәләп торган. Авылны үз кулында тоткан Рәмиснең күзе чыга язган, кулы каймыккан, тавышка йөгереп килеп җиткән авыл егетләре Сәүбәннең кара янып беткән кул-аякларын бәйләп, өенә кайтарып ташлаганнар…

Сәүбән икенче көнне таң белән читкә абыйсы янына чыгып китте. Күгәргән, кара янган йөзен пинжәк якасына яшереп, авылдан чыгып барган Сәүбән артыннан көтүче Хәләф карт белән күршедәге Май әби генә сәерсенеп карап калдылар…

Сәүбән Сәвиянең сафлыгына ышанмыйча китте. Ә ышаныч булмаса… Ә бит ышаныч хисләр тибрәлешенә генә бәйләнгән булырга тиеш түгел. Ышанычның төп тамыры йөрәккә түгел, акылга барып тоташа. Бу вакыт Сәүбәннең акылы томаланган, йөрәге үпкә ташы белән басылган чак иде. Ул вакытта үз-үзе белән күп тарткалашты Сәүбән.

Бәхәс болайрак тәмамланды:

— Ә син беләсеңме, аң хакимлек итә, хис идарә итә…

— Ничек-ничек?

— Аң хакимлек итә, хис идарә итә.

— Шулай булып чыга икән…

Шул китүдән ул бүтән кайтмады, Казандагы Хәйдәр абыйсы янына барып сыенды. Теләгән урынына укырга керде. Аны тәмамлагач, авиация заводына эшкә урнашты.

Кеше ялгыз яшәрлек дәрәҗәдә көчле түгел. Сәүбән дә бөтен гомерен ялгызлыкта үткәрә алмый иде, әлбәттә. Шуңа күрә ул табигать биргән олы бүләкне кабул итте. Өйләнде. Малайлары туды. Фатир алды.

Юк шул, Сәвияне тиз генә оныта алмады ул. Дөресрәге, бер тамчы да оныта алмады. Кызык та, кызганыч та: бик озак эзләп, Сәвия исемле кызга өйләнде. Үз итеп, үзенчә яратып, күңеленә якын алып өйләнде. Хәләленең йөзе, күзләре, хәтта гәүдә-сыны да авылда калган Сәвиясен хәтерләтә. Тавышы да йомшак, бәрхет тавыш, элекке Сәвиясе белгән җырларны да яратып җырлый иде кәләш.

Тик... матур хисләр туса да, Ходай Тәгалә кавыштырган кешеләрдә генә була торган мәхәббәт бәйләнешы урнаша алмады алар арасында.

Эчтән иректе булмаган кеше тыштан иректе була алмый. Сәүбән дә эчтән кол булып яшәде. Сагышының, үпкә-рәнҗешләренең колы булып гомер кичерде. Шуңа күрә ул тормыш-яшәешендә дә ачылып, канат җәеп җибәрә алмады кебек...

Әнкәсе килгәләп, абыйсы кайткалап торса да, Сәүбән авылда калган Сәвиясе хакында бер кәлимә сүз сөйләшмәде, сорашмады. Бервакыт әнкәсе шул хакта сүз каткач:

— Әнкәй, җитте, Сәвия минем өчен юк инде. Мин дә аның өчен юк!— диде дә кырт кисте.

Шуннан соң бу хакта сүз булмады.

Сәүбән тиле түгел. Ул бик яхшы аңлап яшәде. Туган җирен яраткан кеше генә бөтен дөньяны ярата ала. (Ә аның кайтканы да юк.) Туган җир бер генә, чөнки гомер дә бер генә. (Ә ул әллә ничә гомергә ия кеше кебек яши.) Иң ярлы кеше — туган җирсез кеше. (Ул иң ярлы кеше булып чыга, чөнки ул туган җиреннән баш тартырга маташа.) Читтә йөргән кеше — бер җирдә дә яшәми. (Чөнки аның кайтыр урыны, димәк, яшәр җире юк.) Туган җирен яраткан кеше генә хатын-кызны чынчынлап сөя, ярата ала. (Димәк, ул чын сөюдән дә мәхрүм?) Ватан — мәхәббәт кенә түгел, Ватан ул — язмыш! Ә язмыш — җаваплылык дигән сүз! (Димәк, ул тормыш-яшәеш җаваплылыгыннан да баш тарткан булып чыга...) Туган җирнең чын улы булу өчен, соң дәрәҗәдә ихлас булу кирәк! (Димәк, ул ихлас тормыш белән дә яшәми?!) Иң мөһиме: Туган җирне онытып булмый, аны сагынып кына була! (Ә ул аны онытырга тырышты...)

Сәүбән туган җир белән бәйле бөтен төшенчәләрнең дә әхлакый категория булуын, вөҗдан, иман, хакыйкать, сафлык белән тугандаш булуын бик белә. Әле бит тагын да югарырак — милли, сәяси мәгънәләре дә бар бу төшенчәләрнең. Әйе-әйе, Ватанпәрвәр булу өчен башта Ватанлы булу кирәк!

Аннары... Туган җир төшенчәсе язмыш мәгънәсенә дә ия әле! Туган җирендә үткәнең дә, киләчәгең дә бар, ә чит-ят җирдә бүгенгедән, хәзергедән башка берни дә юк...

Сәүбән боларның барысын да аңлый, белә, тоя иде...

## 2

Түр басу очында авыл капкасы күренде. «Басу капкасы» дип тә йөртәләр аны. Һаман да шул икән. Җил-яңгырдан караеп беткән ике имән багана. Алар өстенә шундый ук имән киртә сузылган. Янәшәдә генә ялгыз тупыл агачы. Сәүбән чыгып киткәндә беләк калынлыгында калган бу агач хәзер әнә колачка сыярлык булып үскән. Шунда ук озын эскәмия. Элегрәк армиягә алынган егетләр, шушы эскәмиягә тезелешеп утырып, соңгы мәртәбә тәмәке көйрәтәләр, авыл белән хушлашалар иде. Хәзер ул буш, әлегә призыв юк... Ялгыша икән — кемдер бар анда, әнә бер малай утыра. Авыл малае. Ак күлмәктән, киң сатин ыштан-чалбардан, җирән-коңгырт чәчләре ерактан ук тырпаеп, балкып тора.

Сәүбән аның йөзен ачык кына күрә алмый әле. Тик сизенә: аз гына сипкеллерәк, бер кашында тар гына яра җөе бар. Кышын кәшәкә уйнарга яраткан малайларда була андый тамгалар. Сәүбәннең үзендә дә бар. Яшәгән еллар бу җөйне куе каш астына яшереп куйган куюын... Әмма уң каш астындагы буй сызыкны барыбер күрәләр, шул юк кына нәрсә хакында сорашып ялыктыралар...

Тагын шуны сизеп килә Сәүбән: кайдадыр күргән кебек ул бу малайны. Тик кайда? Таныш, әмма күргәне юк... Бәлки, күргәне дә бардыр? Юк ла... Унсигез ел кайтмый йөреп, каян күрсен ди... Тиле...

Малай-шалай дип тормаска, барып күрешергә кирәк. Ни дисәң дә, авылның беренче кешесе бит әле ул. Сарманай үзе менә шушы малай кыяфәтенә кереп каршы алырга чыккандыр, бәлки?

— Исәнме-саумы, энекәш?!

— Исән-сау әле... Үзең саумы?

— Аллага шөкер...

Малайга якынрак килгәч, сәерсенеп, хәтта дертләп үк китте Сәүбән. Чынлап та кайдадыр күргәне бар аның бу авыл баласын... Тик кайда, кайда? Кайчан? Кайда, кайчан күрә алсын?! Сәүбән авылдан чыгып киткәч туган сабый ласа ул. Сәер... Бик сәер!..

Күзләре! Күзләре тагын да сәеррәк. Чәчләре дә сәер. Җип-җирән! Сәүбәннеке кебек... Шулай да күзләре аеруча сәер! Әйе! Бу малайның күз карашлары аның яшенә, сабыйлыгына һич кенә дә туры килми иде! Олыларча, акыллы караш. Сәүбәннең бер танышы әйтергә ярата иде: «Мудрый караш». Озын-озак гомер яшәгән, күпне күргән, күпне татыган кеше генә шулай карый: гамьле, моңсу, шул

ук вакытта ышанычлы, төпле итеп... Иң мөһиме, сынап карау бар бу күзләрдә. Хәтта шикләнү, шомлану бар. Юк, шомлану ук түгел, сагаю бар...

Сәүбән тагын шуны тойды, бу күзләргә карау белән, җаныңны куеныңа кысып, әллә кая — уйлар-хатирәләр өермәсенә ияреп, күңелнең иң ерак төпкелләренә убылып төшеп китәсең... Төшкәндә яр-кыя читенә тотынып калырга телисең, тырмашасың, чәбәләнәсең, әмма барыбер төшәсең, төшәсең...

Сәүбән дә малай чагында шушы эскәмиядә утырырга ярата иде. Әткәсенең кайтуын көтте ул. Әнкәсе әйтә иде: «Әткәң бик еракта шул... Әйбәт булсаң, тәүфыйклы-тәртипле булсаң, әнкәңне, өлкәннәрне, укытучыларыңны тыңласаң, ялкау булмасаң, кайтыр ул, кайтыр...» Сәүбән ышанды. Тәртипле булырга, уңган булырга тырышты. Укуын болай да яхшы укыды. Бу яклап куркыныч юк иде.

Соңыннан гына белде: аның әткәсе шул ук авылда башка гаилә белән яши икән. Әмма моңа карап кына Сәүбән тәртипсезләнеп, әнкәсен санга сукмыйча йөрмәде, аның төп ярдәмчесе булып калды. Авылдан чыгып киткәнче өй-нигезне үз кулында тотты. Хәйдәр абыйсы, сигезенчене тәмамлау белән, төзелеш техникумына укырга китеп барган иде шул...

— Син кем малае?

— Рәмзиянеке.

— Әткәң кем?

— Әтием юк минем.

— Алай да буламыни?

— Булмый да соң... Безнең белән тормый ул. Самига апаларда яши... Яшәде...

— Нишләп — «яшәде»?

— Үлде ул.

— Шулаймыни?

Сәүбәннең дөм караңгы хәтер чоланында тагын челт итеп ут кабынды: тукта-тукта... аның әткәсе дә Самига апалар гаиләсендә бит! Ә?! Әнкәсе дә Рәмзия исемле... Нәрсә бу? Нинди хикмәтле малай? Нинди дөнья галәмәте?

— Кызы-ы-ык... Тагын туганнарың бармы соң синең?

— Хәйдәр абый бар. Бетте шуның белән...

— Ә?!

Шикле-шөбһәле уйларны тәртипкә салу өчен, таянычын-кыйбласын югалтып як-якка карана башлаган уй-зиһенне нindider кысага кертү өчен бер генә сорау бирәсе калды:

— Исемең ничек соң синең?

— Сәүбән.

Сәүбән аң-зиһенен күңел савытына, хәтер кысасына куып кертә алмый калды, көтелмәгән хәлләрдән башы әйләнеп, шып итеп теге малай янына эскәмиягә утырды.

— Бәй... Бәй, син бит... Син бит мин буласың...

— Әйе, син булам.

— Мин? Кит моннан! Юләр сатма! Син нәрсә, мине юләр дип белдеңме әллә? Йә, әйт хәзер үк — кем малае син? Әткәң-әнкәң кем? Беренче очраган кеше белән шулай шаярырга ярыймыни?! Бала чакта без дә шаярта идек, ну бу чаклы...

— Мин шаяртмыйм...

— Шаяртмыйсың? Шаяртмыйсың ди... Кара син аны, малай актыгын, каяндыр белеп алган да, юри шаярып утыра.

— Шаяртмыйм дидем бит инде. Ныклабрак кара. Менә — кара, кара! Син түгелмени? Бишенчедә районга сабантуйга баргач төшкән карточкаңны хәтерлисеңме? Шул вакыттагы син инде мин!..

Сәүбән шаклар катты: шул? Нишләргә дә белмичә, торып китте, арлы-бирле йөренде, ара-тирә, теге малай каршында тукталып, сынап карап торды, тагын йөренде... Үзе, тиле бәндә кебек, мәгънәсез, бәйләнешсез сүзләр сөйләнде:

— Бишенчедә дисеңме? Әйе шул, бишенчедә чыгып киткән идем... Аннары... Аннары институт... Әнкәй, Сәвия, Хәйдәр... Ә-ә!.. Ул сабантуйда Хәләф абый аты җиңде... Аннары Рәмис батыр калды... Сәвия белән икесе яр буенда... Ну кызык иттем үзен: канга батырганчы кыйнадым... Шәп булды... Бишенчедә мин Сәвияне белми идем әле... Ул сигезенчедә укырга килде... Юк ла, килмәде. Мин аны күрмичә генә йөрдем бугай... Аннары өч ел бергә. Бер җан кебек... Рәмис... Сабантуй батыры Рәмис... Мин киттем, алар бергә калдылар...

— Рәмис белән калмады ул.

— Ә?! Син кем? Син мондамыни әле? Көш моннан! Фу! Кеше кыяфәтендәге Иблистер син! Мине юри диванага сабыштырып, җанны тартып алмакчы буласыңдыр... Барып чыкмас ниятең, яман рух! Кит моннан! Китәсеңме, юкмы? Көш-ш!..

Әмма теге малай кыймшанмады да. Гайрәтне чигерерлек дәрәҗәдә тыныч иде ул. Җитмәсә, һаман бер сүзне тукый:

— Рәмис белән калмады Сәвия.

— Син беләсеңме, мин беләмме, Рәмис белән калды ул. Үзем күрдем!

— Юк дигәч, юк. Рәмис белән калмады. Син сукыр идең ул вакытта. Күңелең сукыр иде. Син хәзер дә сукыр. Мин синең күзләреңне ачарга, җаныңны сафларга килдем.

— Һы, кем соң син ул кадәр?

— Мин — синең бала чагың.

— Ә? Кем-кем?

— Бала чагың, дим бит...

— Андый исем дә буламыни?

— Исем түгел ул. Балачак, балачак инде, белдеңме? Ә безнең исемнәр бер үк — Сәүбән! Сәү-бән!

— Ярар соң, ярар. Мин бит бер сүз дә әйтмим. — Сәүбән сүзне ничек бар шулай калдырырга булды. Чөнки ул барыбер берни дә аңламый иде. Шулай да авыз эченнән генә мыгырдап куймыйча түзә алмады.— Менә әкәмәт...

Авылга кадәр янәшә кайттылар. Бер тамчы сүз сөйләшмәделәр. Сәүбәннең аңына-исенә киләсе бар иде. Әмма басу капкасы буенда булган хәл шулкадәр хыялый-әкияти бер могҗиза кебек иде, Сәүбән үз бәгыренең әллә кайсы җире белән генә тоя-сизенә башлады: нидер булды, гайре табигый вакыйга булды; һәм ул әле озак вакытлар үзенең яңа халәтенә ышанмый, дөресрәге, ышана алмый яшәячәк. Төш кенә булуы да мөмкин бит. Әллә беләкне чеметеп караргамы? Авырта... Санап караргамы? Бер, ике, өч... җиде... ун... Ун... җиде... өч, ике, бер... Дөрес санала бит, чукынчык!

Авылга якынайган саен, Сәүбәннең йөрәге тынгысызланды, ешрак типте. Атылып чыгам-чыгам дип типте. Ничек кенә типсә дә, хуҗасы аны тынычландырыр чара тапмады.

Туган авылыннан чыгып киткәнгә дә әнә күпме вакыт үткән бит! Һәркемгә мәгълүм: Вакыт канатында сагыш бар, сагышта — өмет, өметтә — югалту, югалтуда — кайгы, кайгыда — өметсезлек, чарасызлык... Менә бит ул ничек! Кайда монда дөреслек? Хакыйкать кайда? Вакытны да, хакыйкатьне дә күреп, тотып карап булмый. Тоеп кына була. Тоемың булса инде... Сәүбән әнә шул тоемын югалта язды, ахры.

Унсигез ел үткән дә киткән...

Ул арада дөнья ничек үзгәрде! Сарманай да, аның кешеләре дә үзгәргән булырга тиеш...

Сәүбән үзе дә элеккеге авыл малае түгел инде.

Юк ла, вакыт кешене үзгәртми, аны камилләштерә генә. Бәхетсез чагыбызның күбрәк булуына вакыт гаепле түгел. Шулай ук Күк тә, Галәм дә, йолдызлар да, Кояш та гаепле түгел. Әнә илаһи бөҗра булып тәгәри дә тәгәри ул ут йомгагы...

Ә бит һәркемнең «тормыш бөҗрасы» бар. Акыллы, мәхәббәтле һәм талантлы кешеләр кулында ул «вакыт тәгәрмәче»нә әверелә, бу тәгәрмәч зуррак һәм куәтлерәк булган саен кеше гомере дә озынрак һәм әһәмиятлерәк була...

Сәүбәннең шул «яшәеш бөҗрасы» ватылды, ахры. Туган җирдән аерылуны бәхеттән аерылу белән, яшәештән аерылу белән генә чагыштырырга мөмкин бит. Ә ул үзен туган авылы өчен үлгән дип исәпли иде...

Тормышта иң хәтәре — тереләй үлү. Әлбәттә, үлгәч тә озын-озак гомер кичерергә мөмкин. Сәүбән, үлеп үк бетмәсә дә, чын-чынлап яши дә алмады, ахры...

Табигатьтә төп канун: үлем — гомернең башы. Үлемнән соң һәрвакыт яшәү килә...

Әллә?.. Әллә бу малай аның яңадан тууына ишарә микән?

Сәүбән, барган җиреннән артына борылып карады — һаман барамы, калмаганмы? Юкка чыкмаганмы?

Бара... Олыларча тыныч, салмак... Һәм акыллы! Һәрхәлдә, Сәүбәннән акыллырак. Ул моны әллә кайсы җире белән тоя, сизә... Шуңа күрә сөйләшергә дә шикләнә, хәтта курка...

Баш җитмәслек хәл бит. «Мин синең бала чагың», — диме? Менә дигән малай — шундый таныш, шундый акыллы, мөлаем... Тагын... тагын... шундый газиз!

## 3

Сәүбән юлны бераз онытып та җибәргән, ахры. Ләкин бер нәрсәне ул төгәл белә: басу капкасыннан авылга кадәр шактый барасы... Бала чакта бу ара шундый ерак булып күренә иде, әле дә хәтерле, малайлар белән бу якларга бер мәртәбә генә килеп китеп була иде. Бу яклар дигәнең Кала-тау була инде. Басу капкасына тимичә дә Кала-тауга барып була булуын. Бу яктан кызыграк... Кала-тауга килгәндә инде... Ул авыл малайларын кызыктырып, ымсындырып, чакырып торган иң гаҗәеп, иң серле урын булгандыр...

Әнә ул бер читтә, тонык кына шәүлә булып, артка таба шуыша. Уң кулында — урманнар, куаклыклар, әрәмәлек, инеш буе. Ә сулда — таулар рәте. Урта бер җирдә серле дә, шомлы да Кала-тау үзе калыккан…

Сәүбәннең бу тауны күрмәгәненә төгәл унсигез ел. Нигә гаҗәпләнергә, аның авылга кайтмаганына да шулай ук бит. Кача-поса шушы юлдан чыгып киткән иде ул. Бу хакта хәзер уйлыйсы да килми аның… Әнә Кала-таудан оят…

Сәүбән инде бөтенләй башка кеше. Олыгая башлаган, басынкыланган, күпмедер акыл утырган, күпмедер акылын җуйган, әмма бәхетен таба алмыйча иза чиккән, газаплы-гамьле бер бәндә. Туган җиреннән мәхрүм кала язган үксез җан. Борынгылар әйткән бит: туган җирнең ямен татып карыйсың килсә, читтә яшәп кара, туган җирнең ямен тоеп яшисең килсә, туган иледә тор, дигәннәр. Ягъни туган җир — сагыну өчен түгел, яшәү өчен! Әллә ни аерма да юк — «тату» һәм «тою»… Сәүбән аңлый — аның язмышына «тату» төшкән. Шулай да ул бик озак аерылып торганнан соң кабат кайтып бара. Тату өчен түгел, тою өчен, яшәү өчен кайта. Тоя алырмы? Ул тойса, туган җире аны тоярмы? Шушы Кала-тау аны тоярмы, кабул итәрме, үзенә якын җибәрерме? Әнә бит Кала-тау да бераз чүккән кебек. Ә элек нинди мәһабәт, биек булып күренә иде ул!

— Бер дә чүкмәгән, син үзең үскәнгә шулай тәбәнәк булып күренә ул…

Сәүбән, сискәнеп, тавыш килгән якка борылып карады. Артыннан баягы таныш малай килә иде. Һы, шул арада оныта язган ул бу сәер җан иясен. Ярар, иярсә иярсен. Хәзер Сәүбәнгә барыбер. Ул бөтенесенә дә әзер. Унсигез ел элек кайтмаска ант итеп киткән кеше кайтып килә икән, тагын нәрсә булмас?! Авылга кайткач күз күрер, кем икәнен бик тиз ачыкларбыз…

Сәүбән малайның сүзләренә игътибар итмәде. Дөресрәге, игътибар итмәгәнгә салышты. Ул бөтен ихтыяри көче белән бу яңа танышын онытырга, аны күңел дөньясыннан гына түгел, күз алдыннан да алып атырга тырышты… Ул, теләсә-теләмәсә дә, уйлары белән тагын шул каһәрле санга әйләнеп кайтты: унсигез ел бит! Унсигез ел!.. Әйләнеп кайтуын кайтты, әмма ниндидер бер вакыйгага, хатирәгә эләгеп, ябышып кала алмый иза чикте, башында уйнап йөргән уй гарасатына аның аңзиһене генә ирешерлек түгел иде.

…Вакыт һәрвакыт алга бара. Аның артыннан өлгерә алмаганнар ялгыз кала. Сәүбән дә кайсыдыр бер мизгелдә вакыт арбасыннан төшеп калды, ахры.

…Үткән гомер үзенең максаты белән бәяләнә. Максаты белән мәгънәле ул. Сәүбәннең гомере максатсыз булды. Ә мәгънәсе булдымы?

…Гомер яшәвең белән түгел, яшәвеңне тоюың белән кызык. Сәүбән яшәде, әмма яшәвен тоймады.

…Яшәү — үзгәрү генә түгел, үз-үзең булып калу да. Сәүбән үзен югалта язды, ахры.

…Гомернең озынлыгы еллар белән түгел, кылган изгелекләр белән үлчәнә. Сәүбән начарлыклар кылып яшәмәде, әмма ул изгелекләр дә кылмады!

…Син яшәгән гомерне синнән башка беркем дә яши алмый.

…Һәр гомер үз язмышын иҗат итә. Бу иҗатның төп шарты — көрәш. Көрәш тукталдымы — гомер үлә башлый… Унсигез ел элек Сәүбән дә үз бәхете өчен көрәшүдән баш тартты. Тормыш агымына буйсынды. Вакыт белән Очраклылык ихтыярында калып, иҗаттан, көрәштән китте…

Әйе, дөньяда ике бөек тиран мәгълүм — Вакыт һәм Очраклылык! Сәүбән аларның икесеннән дә күп шулпа эчте. Көчләп эчермәделәр, үзе эчте. Шуңа күрә беркемгә дә үпкәләми ул.

…Кайчакта мең акыл хатасын төзәтүгә караганда бер хис хатасын төзәтү авыррак. Сәүбән дә үз хисләрендә бер ялгышты, һәм берәгәйле ялгышты. Шул ялгышуы аркасында Сәвиясеннән колак какты, язмышын ятим, гарип итте.

Ә бит кеше туганда ук бәхетле булып туа. Әнә шул бирелгән бәхетне саклап калу — кеше тормышының асыл мәгънәсе. Сәүбән үзенә бирелгән бәхетне саклап кала алмады.

…Чынлыкта, бәхет көрәш аша килә. Башкалар белән көрәшмәсәң, үз-үзең белән көрәшәсең. Сәүбәннең сагыштан, борчулардан, авырулардан арыган күңелендә әнә шул көрәш бара иде. Ә бәлки?.. Аның артыннан тотам да калмый ияреп килүче бу сәер малай — аның икенче асылыдыр? Бер кешедә ике «мин» яши диләр бит? Әйтик, берсе аның чын, ихлас «мин», икенчесе — коткы таратучы, җан-бәгырьгә тоз салып торучы дошман «мин». Шул ике «мин» тарткалашмыймы әллә?

— Тарткалаша ди… Әкият чыгарып барма әле! Әйттем бит инде: мин — синең бала чагың. Син моның белән килешергә тиеш. Югыйсә сиңа да, миңа да бик авыр булачак…

Бу гайре табигый хәлдән тәннәре чымырдап барса да, Сәүбән артына борылып карамады. Кайдадыр янәшәдә генә бала чагының кеше кыяфәтендә атлап килүе мөмкинме соң? Юк, әлбәттә!

Сәүбән тагын үзенең күңеленә кереп бикләнде. Артыннан ишетелгән тавышка җавап бирсә, шунда ук зиһененнән язар, тиленәр, диванага сабышыр кебек иде ул… Әмма аның күңелен кузгаткан тормыш фәлсәфәсе дә ниндидер гайре табигый, хәтта илаһи яктылык белән өртелгән, яктыртылган иде.

...Гомерне ярты-йорты яшәп була, әмма аны ике мәртәбә яшәп булмый. Сәүбән дә үз тормышының ярты-йортысын яшәгән инде...

...Кешегә гомер бүләк итеп түгел, бурыч итеп бирелә. Сәүбәнгә дә бурычын түләргә күптән вакыт, ә ул һаман бурыч җыеп йөри...

...Гомер газап та түгел, ләззәт тә түгел. Гомер — олы эш; Сәүбән аны намус белән башкарырга һәм ахырына җиткерергә тиеш!..

...Гомер — үткән көннәр түгел, гомер ул — истә калган көннәр... Сәүбән гомере — үткән көннәр генә, ахры...

...Гомер, бер бөртек тә чәчелмичә, җыелып бара. Сәүбән үз хәтереннән ни дә булса алып атырга теләсә дә, булдыра алмас иде...

— Ә нигә, алайса, мине — бала чагыңны оныттың?

Аның чуалчык уйларын тагын теге малай тавышы бүлде. Сәүбән, үзе дә сизмәстән:

— Кем? Минме? Мин оныттыммы? — дип ычкындырды, ялт итеп артына борылды. Сатин ыштанлы җирән чәчле малай берничә адым гына читтәрәк басып тора иде.

Сәүбәннең чын-чынлап ачуы килә башлады. Ничек котылырга бу каһәрдән? Берәр сихер, зәхмәт эшеме бу? Тизрәк авылга җитәсе иде, бу мәзәк хәлләрне онытасы иде!.. «Их, Кала-тау! Син дә сагаеп күзәтәсең бугай бу маҗараларны... Йә, тынычландыр инде мине, асылыма кайтар... Кала-тау...»

Сәүбән кызу-кызу адымнар белән ары китте. Ул үз артыннан мыштым гына ияреп килүче малай хакында ничек тә онытырга тырышты, үзен көчләп диярлек малай чагыннан калган хатирәләр дәрьясына алып кереп китте. Ә Сәүбәннең бала чагына кагылышлы иң гаҗәеп хәлләр шушы Кала-тау белән бәйләнгән иде.

Иң кызыгы һәм гаҗәбе Кала-тауның түбәсе, очы булгандыр. Дөресрәге, бу тауның түбәсе бөтенләй дә юк иде. Нindидер могҗиза белән аның очын кисеп алып, өстен тигезләп, «сыпырып» куйганнар диярсең... Җитмәсә, Кала-тауның әнә шул өске ягына тигез, шома таш түшәлгән. Чып-чын аэродром инде!

— Булмый торсын әле!.. Беләсеңме күпме тарта хәзерге самолетлар? Йөз тонна!

Сәүбән, таныш тавыш ишетеп, йөзен чытты. Әмма күтәрелеп бәрелмәде, хәтта дәшмәде дә... Ул тагын Кала-тау ягына карап алды. Коткарса ул гына коткарыр бу афәттән. Тәмам тилеләнеп, акылны җуйганчы дип, Сәүбән бөтен җан-күңеле белән балачак хатирәләренә ябышты. Бу хатирәләрнең үзәгендә Кала-тау иде. Әнә бит ул ничек аерылып тора. Ул хәтта тауларга охшамаган да.

Башкалары үз түбәләре белән күк пәрдәсен төртеп тишмәкче булып югарыга үрелгәннәр, Кала-тау гына, арада иң биеге булуына карамастан, әкияти бер җанвар кебек бөгәрләнеп җиргә яткан да йокыга талган... Нindидер серле дә, шомлы да манзара бу. Менә ул уяныр да үкереп-бакырып, тирә-яктагы тауларны, урманнарны әвәрә китереп торып басар кебек...

Ни генә сөйләшмиләр иде бу Кала-тау хакында!

Әле дә хәтерендә, түбән очта бер карт яши иде. Ай-һай сәер карт иде ул. Пәри кызы белән сөешеп «диванага калган» дигән сүзләр дә йөрде. Исеме ничек соң әле? Рәхмиме, әллә Хәсмиме?..

— Хөсни. — Монысын янында барган теге малай әйтте.

Сәүбән бу юлы да аны үз күңеленә артык якын җибәрмәскә тырышты, тыныч кына сөйләшә башлады:

— Ә, әйе, Хөсни... Туктале, каян беләсең син аны, ул бит мин бәләкәй чакта ук каядыр китеп югалган иде?

— Белмәскә, шул синең бала чагың бит инде мин. Һаман ышанмаган буласың. Бигрәк сәер кеше син... Үз-үзеңне танымыйсың...

Малайның бераз үпкәләбрәк әйткән сүзләре Сәүбәннең күңел түренә шом йөгертсә дә, ул һаман әле сер бирмәскә тырышты. «Бәласеннән башаяк, башка дәшмәскә кирәк, җавап биргән саен, сихер үзенә тартучан була»,— дип уйлап алды да кабат баягы уйларының тигез ызанына килеп төште.

...Менә шул Хөсни карт авызыннан чыга иде бөтен хикмәтле сүзләр. Кич ялангага ат сакларга чыккач, бөтен урам малайларын үз тирәсенә җыеп ала да сөйли башлый үзенең әкиятләрен...

Имеш, бу Кала-тау — кеше кулы белән өелгән тау. Әйе-әйе, элек булмаган мондый тау. Тик аны җир кешеләре дә өймәгән. Күктән төшкән кешеләр күтәргән аны.

— Күктән төшкән? Ничек төшкәннәр соң алар?

— Күктә дә кешеләр яшимени?

— Булмас ла... Ялгандыр бу...

Хөсни тыныч кына дәвам итә.

— Бу кешеләр галәмнән корабларга утырып төшкәннәр. Кала-тау өстендәге мәйдан аларның чуен кораблары төшә торган урын булган.

— Каян, каян төшкәннәр соң алар?— дип түземсезләнә кемдер?

— Каян булсын, Айдандыр инде. Иң якыны Ай бит, — ди икенчесе.

Хөсни карт, башын чөеп, бераз вакыт төпсез күккә карап тора да әйтеп куя:
— Чулпан йолдыздан килгәннәр алар.
— Таң йолдызыннанмы?
— Көтүче йолдызыннанмы?
— Зөһрәдәнме?
— Әйе, Зөһрәдән. Ул йолдызда яшәүчеләрнең башында Зөһрә-ана тора. Менә шул Зөһрә-ананың оныклары төшкән безнең Кала-тау буена…
— Ә нигә Кала-тау дип аталган соң ул? Анда бит бернинди дә шәһәр юк?— Теге түземсез малай һаман төпченепме-төпчена…
— Әйттем бит инде: бу урында элек тау булмаган, — дип, сүзен дәвам итә Хөсни. Учак уты яктысында ул үзенең җыерчыклы йөзләре белән әллә нинди серле, әкияти затка охшап тора. Әмма малайлар бу заттан курыкмыйлар. Чөнки аның самими, изге күңелле бер Ходa бәндәсе булуын үзләренең сабый күңелләре белән тоеп беләләр.— Балчык ташып тау өеп куялар башта. Аннары өстенә таш түшиләр, кораб төшәр өчен мәйдан ясыйлар.
— Шуннан, шуннан?.. Шуннан соң шәһәр төзиләрме?
— Туктале син, Хәбип малае. Кума атны ул кадәр. Төн озын, барысын да берәмтекләп сөйләрмен. Тыңлагыз гына… Сез тыңларга, хәтердә калдырырга тиеш боларны. Бу изге тау тарихын, авылыбыз тарихын киләчәккә илтергә тиеш кешеләр бит сез. Ныклап тыңлагыз. Мин сөйләгәннәрнең бер бөртеген дә түкми-чәчми хәтер сандыгыгызга салып барыгыз…
Малайларга Хөсни карт сөйләгәннәрнең барысы да аңлашылып бетми. Әмма аның мавыктыргыч әкият-риваятьләрен тыңлау бик тә кызык, рәхәт. Тик… бераз шомлырак кына. Үзләре дә сизмәстән, малайлар бер-берсенә сыенышыбрак утыралар, ара-тирә Кала-тау ягына да караштыралар…
Хөсни картка тыңлаучы гына булсын. Әле генә шул могҗизалар эчендә булып кайткан диярсең, ышандырып, үзе әйтмешли, берәмтекләп сөйләп бара…
— Галәмнән төшкән кешеләр ә-ә-нә теге әрәмәлек буйларында шәһәр төзи башлыйлар. Әмма җир кешеләренең явызлыгын белмиләр әле алар. Төзеп кенә бетерәләр, җирдәге кыргый затлар бу шәһәргә һөҗүм итәләр, аны яндырып, пыр туздырып китәләр. Шулай берничә мәртәбә кабатлангач, Зөһрә-ана оныклары шәһәрләрен тау эченә салырга булалар…
— Хәзер дә бармы ул шәһәр?
— Хәзер дә бар, безнең Кала-тау эчендә гүзәл шәһәр бар…
Аның бар икәнен Сәүбән үзе дә белә. Әнә бит әнкәсе тиргәгән саен: «Йөрмә шул тауга, эчендәге рухлары чыгып, сихерләп дивана ясарлар»,— дип тирги. Рухлар шул ук кешеләр бит инде. Ә кеше булган җирдә йә авыл, йә шәһәр була да була инде. Тагын шунысы да бар: тау эчендә авыл булалмый. Авылның бит аның басулары, кырлары, күлләре, чишмәләре, таллыклары, сайрар кошлары була. Ә шәһәр гел таштан төзелә. Тау эченә таш өю берни түгел лә ул…
Алдагы көннәрдә ат сакларга чыкмаган, шуның аркасында риваятьнең башын ишетмәгән бер малай сорап куя:
— Каян төшкәннәр соң алар?
Хөсни карт, һич иренмичә, риваятен яңабаштан сөйли башлый:
— Бердәнбер көнне Кала-тау башындагы мәйданга Чулпан йолдызыннан кораб килеп төшә, аңардан кешеләр коела. Су кебек зәңгәр күзле, җирән чәчле, ди, үзләре…
Кемдер дәшми булдыра алмый:
— Безнең кебекме? Безнең авылда бөтен кешенең күзе зәңгәр… Чәче дә җирән…
— Менә-менә!.. Башлы малай булырсың, казаның әйбәт кайный… Менә шул Чулпан йолдыздан килгән кешеләр безнең авылга нигез салган да инде.
Малайлар шаулашып алалар:
— Уһу! Вәт шә-ә-әп!..
— Ничек инде?
— Без… без йолдыздан төшкәнмени?
Хөсни карттан сора гына, ул шунда ук мавыгып сөйли башлый:
— Әйе, Сарманай — менә шул зәңгәр күзле, әлиф кебек төз, зифа кешеләр авылы. Ызначит, без галәм затлары булып чыгабыз…
— Нигә алар кире очып китмәгәннәр соң?
— Нәрсәдер булган инде. Трактор да, матай да ватыла бит, галәм корабы да мәңгелек түгел, ызначит.
— Кая булган соң ул кораб?
— Бөтен хикмәт тә шунда шул: ул кораб юкка чыккан. Тау эченә яшерелгәндер дигән фараз сүзләр йөри йөрүен… Тик менә Кала-тау эченә кереп караган кеше юк әлегә…

...Сәүбән, уйлар дулкынында салмак кына бара торгач, әллә кайсы тоемы белән, үзенең ялгыз калуын сизде. Кырт артына борылып карады. Әһә! Әнә ул малай. Тагын да арткарак калган. Мыштым гына булса да килүен килә үзе. Әллә үпкәләгән инде...

— Әй, адаш, кил әле монда җәтрәк!

Малай аңа карап кына адымын кызулатмады, дәшми-нитми килүендә булды. Бераз сабыр иткәннән соң, Сәүбән түземсезләнеп һәм малайның хәленә керергә тырышып сораша башлады:

— Нишләп артка каласың? Ардыңмы әллә? Әйдә, бергә кайтабыз, миңа да, сиңа да күңеллерәк булыр...

Малай һаман дәшмәде. Ул инде Сәүбән белән тигезләште, аннары, керфек тә какмыйча, авызын турсайткан килеш, килгән җайга узып та китте.

«Да-а... малайны чынлап та үпкәләттем бугай»,— дип уйлап алды Сәүбән. Бала вакытта үл үзе дә бик үпкәчел булды. Берәрсе кирәкмәгән сүз әйтеп рәнҗетсә, хәзер үпкәләргә тора иде. Юк, каккан-га-сукканга әллә ни игътибар итми, ә менә авыр сүзне, бигрәк тә нахакны һәм ялганны күңеле күтәрми иде. Мондый чакта ул эченә бикләнә дә авылдан чыгып китә... Башта ындыр артлап кына инеш буена төшә, аннары Яман кул чокыры буйлап Кала-тауның текә ягына чыга. Нәкъ шул җирдә, стена кебек шома кыя астында урнашкан да инде «Кала-тау» дигән җанварның ыржаеп торган авызы... Сәүбән бу «җанвар»дан һич курыкмый, киресенчә, аның янында тынычланып калгандай була. Үпкә-рәнҗешләр юкка чыга, нахак сүздән тәмам изаланган, менә-менә очып чыгар төсле тибенеп яткан йөрәге дә, үз эзенә төшеп, салмак кына тибә башлый, күңеле дә үз урынына утыра, карашлары җылынып, йөзе яктырып, нурланып китә.

«Җанвар авызы» дигәне тау куышы, мәгарә була инде.

Ниндидер сихер, тылсым бар, ахры, бу тау куышы тирәсендә. Бәлки, якындагы чишмә буеннан киләдер бу тылсым?

— Ул чишмәне онытмагансың икән әле...

Янәшә барган малайның кинәт әңгәмәгә кушылып китүе Сәүбәнне сөендерде. Аның эченә җылы йөгерде. Ул юлдашына сиздермәслек итеп кенә елмаеп куйды. Кеше рәнҗеше — иң хәтәр әйбер бит. Бигрәк тә балалар рәнҗешеннән сак булырга кирәк. «Җанга кара тап булып ята торган әйбер ул»,— ди иде аның әбисе. Әбисе тагын әйтә иде: «Һәр җанда бар ул кара таплар. Аларга тимәсәң, кузгатмасаң, берни дә булмас, әгәр тисәң инде, җаның олтанга әверелер, дөньяң күмер кебек каралыр»,— ди иде мәрхүмә...

— Ник онытыйм, онытмадым... Исемен дә хәтерлим әле — Рух чишмәсе.

— Онытмагансың...

— Изге әйберне онытып буламыни?

— Изге дип тормыйлар, оныталар бит әле.

Сәүбән сагаеп калды. Нәрсәгә төрттереп булыша бу малай.

— Юк, син турысын әйт, сүзеңне уратып йөртмә. Кем оныта? Мин онытаммы?

— Мин бит әле «син онытасың» димәдем...

— Юк, «син онытасың» дип әйткән кебек әйттең!

— Алайга калгач, син дә онытасың.

— Йә, сөйлә...

— Менә безнең әнкәбез изге кешеме?

— Изге... Аннан да изгерәк зат юк минем өчен!

— Шулай булгач, нигә унсигез ел буе янына кайтмый йөрдең? Ник бер мәртәбә булса да кайтып, ике пүлән утынын ярып, коймасын рәтләп яисә бакчасын казып китмәдең? Ә? Хәтердә, истә тоту онытмау түгел әле. Кайтып хәлен белеп йөрү, булышып тору ул онытмау дигән нәрсә...

Малай дөресен сөйли иде. Сәүбәнгә оят булып китте. Шулай да ул акланыр өчен ниндидер сүзләр, дәлилләр уйлап табарга тырышты:

— Әнкәйне мин ел саен ике-өч мәртәбә үз яныма чакырып, кунак итеп, тәрбияләп тордым. Әле ике ай элек кенә булып китте...

Малайга бу дәлилләр бөтенләй дә тәэсир итмәде. Ул тагын да уйчанланыбрак баягы сүзен кабатлады:

— Хәтерләү, истә тоту онытмау түгел әле. Әйттем бит инде... Онытмау ул — туган туфрактан, изге туфрактан, изге чишмәләрдән аерылмый яшәү дигән сүз.

— Ә мин аерылдыммы?

— Аерылдың...

— Син каян беләсең соң, малай актыгы?! Миңа акыл өйрәтеп барган буласың...

— Алай сөйләшмә, сиңа килешми... Беләсең килсә, син минем кебек чакта әдәплерәк, акыллырак идең. Хәзер әллә нишләгәнсең... Дөньяга ачуың чыккан... Җиреңнән, суыңнан, чишмәңнән аерылып, бик озак яшәдең шул син.

Сәүбән аңлап барды. Бу — гади малай түгел. Ходай Тәгалә җибәргән бер рухи зат, ахры, ул. Тагын да тирәнгәрәк кереп уйларга курыкты ул. Авылына барып җиткәнче йә диванага сабышыр… Иң яхшысы — кабаттан бала чакның матур хатирәләренә кайту, сүзне шул вакытның гүзәл мизгелләренә таба борып җибәрү.

— Ә син хәтерлисеңме ул Рух чишмәсен?

— Хәтерләмәскә, син минем кебек чакта ул чишмә буенда күп йөрдең…

— Шуннан, шуннан?..

— Утырган да шуган! Ул чишмәнең бик сәер яклары бар. Йә, әйтеп кара, нинди сәерлеге бар аның?

Сәүбән моны белә иде. Ул, сөенеп, елмаеп җибәрде. Аннары, кинәт уйчанланып әйтеп куйды:

— Җәйнең бер көнендә канлы яше белән елый ул…

— Улагы тулып аккан кызыл суны канлы яшь дип уйлыйлар…

— Улагына да сыймый иде хәтта… Балчыгын кыйнап-кыйнап, ярларына бәреп-бәреп ага иде ул…

— Ул «тау каны»н карарга халык җыела…

— Шулай да якын килергә, ул суга тотынырга куркалар иде…

— Ул канлы суга кычыткан чыпчыгы төшеп үлгәнен Хәләф абзый күргән булган…

— Хәтерлим әле, мин ул суга бармагымны тидереп карадым. Берни булмады. Тырнагы гына төште. Ярты елдан яңа тырнак үсә башлады. Менә, менә кара… Сизелми дә хәтта…

— Бер көн, бер төн акканнан соң, канлы су агудан туктый. Шуннан соң башлана да инде сәер галәмәтләр…

— Нәрсә-нәрсә?— Сәүбәннең бу сүзне ишеткәне юк иде.

— Галәмәтләр димен. Әкәмәт хәлләр дигән сүз инде.

— Шулай диген син аны. Тегеләй… ни… тауның зәһәр тавышлар чыгарып ыңгырашуын, елавын, сыктавын әйтәсеңме?

— Монысын да онытмагансың…

— Әби әйтә иде: «Тәңребез туган көнне шулай була», — ди торган иде. Беләсеңме, Күк-Тәңре җәй көне, июнь уртасында туган бит…

— Анысын мин дә беләм, синең әби минем әби ич инде… Сабантуй бәйрәме Тәңренең туган көнен бәйрәм итү булып чыга, имеш… Кешеләр шулай җитезлектә, егәрлектә һәм батырлыкта Тәңрегә тиңләшергә телиләр, ди. Аны хөрмәтлиләр, алкышлыйлар, ди.

— Ә, искә төште, шулай бит әле. Июньнең иң озын көнендә туган Күк Тәңресе. Тәңре туган көнне мактап, Кояш та күктә бик озак торган, имеш.

— Ә Тәңренең хатыны кем, беләсеңме?

— Юк, белмим.— Сәүбән, бала чакта белгәннәрен зиһене аша кичереп, бөтен хәтерен эшкә җикте. Исенә төшерә алмады.

— Онытмансың… Иң кирәген онытмансың, нәсел йомгагының очын югалткансың…

— Юк ла, хәзер искә төшә ул… Яле, бераз әйтеп җибәр…

— Әйтмим, бу әйберне үзең искә төшерергә тиеш. Шулай иткәндә генә син аны башкача онытмаячаксың.

Сәүбән кыен хәлдә калды. Нәсел йомгагының гына түгел, хәтер йомгагының да очын югалткан иде ул. Шул очны табып тартып кына җибәрәсе дә соң… Хәзер сүтелеп китәр кебек…

Хөсни карт сөйли иде. Иң беренче булып күк йөзе туган, ди иде. Күкнең иясе — Тәңре. Калган бөтен нәрсә — шул Тәңре тудырган дөнья. Ләкин бит Тәңре үзе генә дөньяны ярата алмый. Аңа хатын кирәк. Бөтен планеталар арасында бердәнбер хатын-кыз планета — йолдыз бар икән. Ул — Чулпан, ягъни Венера. Күк-Тәңре менә шул Чулпан-Венерага ярәшкән дә инде. Чулпан-Венера безнеңчә Зөһрә-ана була. Ә Зөһрә-ананың оныклары, Җиргә төшеп, безнең авылга нигез салганнар…

— Уф!.. — дип куйды Сәүбән. — Искә төште.

— Йәле, әйтеп кара.

— Безнең Зөһрә-анага өйләнгән ул.

— Ярый, бөтенләй өметсез түгел икән әле син.

— Рәхмәт инде.

— Кала-тау тавышланганда, бөтен тирә-як дер калтырап тора иде, ә?

— Шул искә төшсә, әле дә тәннәрем чымырдый башлый…

— Ә үзең тауның шул вакытын ярата идең…

— Әллә син чынлап та сихерче сыңарымы?.. Боларның барысын да каян беләсең? Теленә салынып тора дисәм, мин әйткәннең-уйлаганның тап өстенә басып барасың…

— Әйттем бит инде, — мин синең бала чагың, малай вакытың гына... менә кара: бөтенесе дә туры килә: яра җөе дә, күзләрем, чәчләрем дә... — Малай үзенең йөзенә-битенә, күзләренә, чәчләренә төртеп күрсәтә башлады.

— Анысы шулай да соң...

— Исемем дә, сүзләрем дә туры килә. Инде тагын ничек ышандырыйм сине?

— Мин дивана түгел лә! Нишләп, ничек минем әллә кайчангы бала чагым кеше сурәтенә кереп йөрсен ди?! Әйтсәм, адәм көләр...

— Алайса, син генә белгән бер серне ачыйммы?

— Әһә! Менә хәзер тотам мин сине! Яле, кеше белмәгән нинди серем бар минем?

— Йә, әйт инде, әйт! Юри кыланасыңдыр әле...

— Тыңла алайса. Без йөрергә яраткан чишмә өстендә генә, тауны тишеп, мәгарә кереп китә. Шул мәгарә авызында, эчкәрәк кергәч, бер тар тишек бар. Исеңә төштеме? Менә шул тишектән бераз шуышып баргач, олы бүлмәгә килеп чыгасың... Синең беркем белми торган серең әнә шул мәгарә бүлмәсе иде.

— Белдең...

— Хәтерлисеңме, анда сәке сыман урын бар иде. Кипкән печән ташып, шул сәке өстенә түшәк тә әмәлләдең әле...

— Хәтерлим...

Хәтерләмиме соң! Сәүбән барысын да ап-ачык хәтерли. Теге тишектән суырылып кергән яктылык мәгарәнең эчен тоныкы кына яктыртып тора иде. Бу бүлмәдә ул бала чагының иң моңсу, шулай ук иң бәхетле мизгелләрен кичерде. Күңеле үпкә-зардан, рәнҗештән әрнегән вакытта, шушында килеп, үзенчә юанып, олыларча сагышланып-уйланып, сәкесендә чалкан төшеп ята иде ул. Тигез-шома итеп кырылган таш стеналарга, гөмбәзләнеп уелган түшәмгә төбәлеп ятасың да ятасың... Сәүбән ике сәер хәлне бик ачык хәтерли: күз керфекләрен йомшак кына иркәләп, борын эчләрен рәхәт кытыклап, тәмле җил йөри. Әйе-әйе, тәмле-татлы җил! Алмагач чәчәгенең тәме бар иде бу җилдә... Сәүбән белә: үтәли юл булмаса, җил йөрми. Димәк, Сәүбән бүлмәсеннән соң да мәгарә дәвам итә. Унынчыда укыганда бу юлны, ниһаять, тапты ул. Стенадан ыржаеп торган тишекне киңәйтеп, эчкәрәк кереп карады. Тагын ике бүлмә барлыгын белде. Тик анда дөм караңгы иде. Кабызган чыра бик тиз сүнеп бетә, аннары, Сәүбәнгә эчкәрәк керүнең кирәге дә юк иде. Аның үз бүлмәсе бар, үз сере, үз дөньясы бар... Икенче могҗиза да шул тау куышы белән бәйләнгән. Сәүбәннең күп мәртәбәләр искә алганы булды: Кала-тауның йөрәге тибә иде. Кешенең йөрәк тибешенә охшамаган иде бу саңгырау тавыш: дөп-дөп... дөп-дөп... дөп-дөп... Бер дөпелдәвек белән икенчесе арасында әллә күпме вакыт бар. Унга кадәр генә санап булгандыр, мөгаен...

— Тауның йөрәге типкәндә, бөтен дөнья селкенеп куя иде...

Янында барган малайның сүзгә кушылуы Сәүбәнне айнытып җибәрде. «Карале, минем бөтен уйлаган уйны укып бара бу»,— дип уйлап алды ул. Барысын да каян беләдер?

— Барысын да беләсең тагы... Тик мин барыбер берни дә аңламыйм: кем соң син? Йә?.. Үзең уйлап кара: балачак, сабый вакыт кире кайта алмый бит инде. Ул үткән, яшәлгән! Яшәлгән и вәссәлам! Кире кайта алмый ул, по-ни-ма-ешь!..

Малайның җавабы үтә дә сәер иде:

— Кайта шул... Кеше, бала чагым үтте дә онытылды, хәтер чоңгылларына матур һәм гыйбрәтле истәлек булып төшеп, югалып калды, дип уйлый. Һәм ялгыша!.. Аның бала чагы гел янында, гел янәшә йөри... Ничек күрсен ул аны! Тормыш ваклыкларыннан аның күңеле сөрсегән, җаны изаланган, йөрәге җәрәхәтләнгән, бәгыре каткан була. Күзендәге яшәү нуры, өмет нуры тоныкланган, йөз суы кипкән була...

— Инде аңа китсә, менә мин күрәм бит...

— Күрүчеләр дә бар... Күңел сафлыгын, ихлас хисләрен, мәхәббәтен югалтмаган кешегә ап-ачык булып күренә ул — балачак, бал чак...

— Мин... Мин — әйбәт кешемени?

— Ничек дим инде... Әйттем бит, син начар кеше түгел. Әйбәтлегеңә килгәндә... Бу яклап шактый ышандырасың бар әле. Күңелеңне, җан-рухыңны, йөрәгеңне сынап, барлык уйларыңны тагын бер мәртәбә яңартып чыгасың бар.

«Кара ничек матур сөйләшә, берәр акыл иясе диярсең»,— дип уйлап өлгерде Сәүбән. Үзе ниндидер җиңеллек, рәхәтлек тоеп, бертында әйтеп куйды:

— Барыбер рәхәт миңа. Бөтенләй үк беткән кеше түгел икәнмен бит...

Сәүбән моны үзе дә белә. Ихтыярсыз, йомшак рухлы, шактый куркак кеше булса да, ул таш йөрәклләрдән яисә чүпрәк җаннардан түгел. Сәүбән үзендә элеккеге авыл рухын, авылда яшәгән чакларыннан килүче ихлас хисләрне, самими тойгыларны, эчкерсез мәхәббәтне аермачык тоя. Дөресрәге, нәкъ шулар аны тормыш баткаклыгыннан һәм чарасызлыктан, төшенкелектән саклап калды да...

Шәһәрдәге Сәвиясе балага авырлы иде. Тулгак вакытлары җиткән. Сәүбән аның тирәсендә бөтерелеп кенә йөри: тегесен китерә, монысын алып кайта… Юк, бу хәлләр элгәрерәк башланды. Өйләнешеп бергә тора башлагач ук, Сәүбән үзенең бәхетсез икәнен аңлаган иде инде.

Аларның өч ел балалары булмады. «Бала — мәхәббәт җимеше» дигән сүздә дөреслек бар икән. Сәүбән бик еш уйлана иде: «Аерылырга кирәк, аерылырга кирәк… Балабыз да юк… Икебез дә яңабаштан тормыш корырбыз…»

Һәм менә — Сәвия балага узды. Баштарак Сәүбән аңышмады. Хатынына бала табарга вакыт җиткәч кенә җаны чыгырыннан ычкынды. Бала булачак бит! Аларның уртак бәгырь җимеше туачак! Бер-берсен яратмаган ике җанны мәңгелеккә бәйләп куячак! Әле аерылышырга, яңа тормыш корырга, бәхетле булырга ниндидер өмет бар иде. Хәзер ул өмет тә бетте, сүнде…

Өметсез кеше — бәхетсез кеше. Сәүбән эчә башлады. Көннәр буе юкка чыгып, югалып йөрде. Әллә нинди дуслар тапты, пычрак подвалларда, ташландык йортларда кунып калган чаклары да күп булды. Ул көннән-көн тормышның төбенә таба тәгәрәде. Сәвиясе, битен яшь белән юып, йөрәген өзгәләп, күңелен әрнетеп, тумас борын туачак сабыеның җанын имгәтеп, ялгызы өйдә изаланып ятты. Ачыргаланып кычкыра-кычкыра, иңри-иңри мендәр төйгән чаклары да еш булды аның…

Менә шундый ямьсез көннәрнең берсендә Сәүбән, «баш төзәтерлек» кенә акча табу нияте белән, кайчандыр авылдан ияреп килгән иске чемоданын ачты. Ачты да артына егылып китә язды… Кыршылып, таушалып беткән чемодан эченнән мәтрүшкә-бөтнек исе, авыл исе аңкып килеп чыкты! Сәүбән шаша язды! Юк, башта әле ул айныды, аннары гына шашар дәрәҗәгә җитте. Рух чишмәсе буеннан алып кайтып киптерелгән мәтрүшкә сихере үзенекен эшләде: Сәүбән элекке, ихлас хәленә, керсез күңел ярларына кайтып төште. Ул шунда ук басынкыланып-моңсуланып калды. Әмма ул бер нәрсәне күңеленә нык кабул иткән иде: тормыш дәвам итә, кан, нәсел дәвам итә! Ул үз язмышын онытып, бөтен барлыгын, омтылышларын, хыялларын туачак баласына багышларга, аның бәхете өчен җанын да, тәнен дә аямый яшәргә тиеш! Бу — авыл фәлсәфәсе. Бу фәлсәфәдә кемдер чикләнгәнлек, хилафлык күрер, әмма бу фәлсәфә — дөньядагы иң кешелекле һәм шәфкатьле тәгълиматларның берсе! Чөнки ул киләчәк яклы. Кеше үзенең нәсел дәвамы өчен шәхси тормышын, хәтта бәхетле язмышын корбан итә белергә тиеш! Бу — Табигать кануны, әмма бу — Кешелек кануны да! Сәүбән бөтен кешелек өчен җавап биреп бетерә алмый, әлбәттә… Әмма авыл өчен әйтә ала: авылда мондый фидакарьлек бар әле, шуңа да авыл шәһәргә караганда тазарак, иплерәк, өметлерәк…

Авылның чын рухы менә шушындый мәтрүшкә, бөтнек исләренә, шифалы чишмәләр суына, талгын җил сулышына сеңгән. Сәүбән моны яхшы белә хәзер. Үз язмышында татып белә…

— Йә, җитәр сиңа, артык нык тирәнгә төшәсең… Барсын да кузгатма. Авылыңа кайтып барасың бит. Әле монда да күңелеңә авыр таш булып ятардай хәлләр күп булыр. Мин моны сизеп торам…

— Мин дә сизәм…— Сәүбән инде янында барган малай белән үз итеп, кадерле кешесе, туганы итеп сөйләшә башлаган иде.— Минем монда да җанга тияр нәрсәләр күп шул. Кичә генә киткән кеше түгел бит… Унсигез елга катлап-катлап, сылап-сылап, ничә мәртәбәләр генә түшәлгәндер инде бу аяусыз вакыт тузаны?..

— Дөресме шул: йөрәгеңдә җәрәхәтне вакыт тузаны да, тормыш юшкыны да каплап, томалап куя алмады бит. Шуңа да менә кайтып барасың…

— Анысы дөрес, адаш энекәш… Ул җәрәхәтнең исеме — Сә-ви-я…

— Күрәсең киләме?— Малай сак кына, Сәүбәннең күңелен кузгатмасам ярар иде дигән кебек сагаеп-сакланып кына сорады.

— Бик килә!

— Шулайдыр дигән идем аны…

— Мин аны бик еш төшемдә күрә идем. Тик… үтә дә сәер итеп, серле итеп күрә идем.

— Ничек?

— Беләсеңме, элекке яшь вакытын түгел, мин аның хәзерге вакытын күрә идем.

— Кызык… Син чынлап та сәер кеше.

— Нигә мин генә, син дә сәер, димәк. Син бит минем бала чагым! Дөрес булса…

— Шулай булып чыга шул…

— Ә син хәтерлисеңме, Сәвия белән бәйле тагын бер серем бар минем. Әгәр син минем бала чагым икән, ул серне белергә тиеш.

Сәүбән янәшәсендә барган малайга әллә нәрсә булды. Ул үз эченә йомылып, хәтта бераз чүгеп, кечерәеп калды. Маңгайларын җыерып та, йөзен чытып, күзләрен йомгалап та уйланды, әмма җавап бирерлек сүз тапмады. Сәүбәнгә шул гына кирәк иде. Ул, үртәүле тавыш белән:

— Нәрсә, рәт беттеме?— дип сорады.

— Белмим, билләһи, белмим…

— Ә үзең!.. Мактанган буласың… Барысын да беләм, имеш…

— Көлмә. Үзеңнән көләсең. Мин бит синең бала чагың.

— Алайса, нигә авызыңа су каптың? Нигә телеңне тешләдең? Нигә, нигә?
— Ул сер сезнең гыйшык-мыйшык белән бәйләнгәндер әле.
— Әйе шул! Җылына башлады…
— Җылынасы-нитәсе юк, мин барыбер белмим.
— Нишләп?
— Мәхәббәт — бала чактан өстен. Мәхәббәт башланган урында мин үләм. Мәхәббәт — язмыш мәсьәләсе, ә мин… мин… сафлык мәсьәләсе…
— Ярый, ышандырдың ди… Үзең башлы гына булып чыктың, малай. Логикаң шәп синең.
— Йә, әйт инде, нинди сер ул?
— Ә-ә, кызыкмы? Тыңла, алайса, сер итеп кенә сөйлим.
— Ак ант, кара ант? Билләһи газыйм, бу серемне ачсам, җанымнан языйм...
— Син бит минем антны әйтәсең.
— Бәй, мин кем соң?
Сәүбән бот чабып куйды.
— Һи, тагын онытканмын… Һич кенә дә күнегә алмыйм әле бу сихер шаукымына. Менә шул, тыңла. Син беләсең инде, Рух чишмәсеннән авыл ягына бераз баргач, тау башына юкәләр рәте менеп китә. Кем утырткандыр аны, Ходай үзе генә беләдер, әмма бик сәер агачлык ул. Бер рәт булып өскә менеп китә дә, тауны урап, боргаланып-боргаланып, аргы якка барып төшә. Ул төшкән урында тагын бер мәгарә башлана. Хикмәт анда түгел. Хикмәт бу яктагы беренче юкә агачында.
— Сәвиянең ни катнашы бар аңа?
— Бар шул. Без икәү бик еш килә идек Рух чишмәсе буена. Аның суын эчеп, бер-беребезгә сибешеп, матур минутлар кичерә идек. Аннары өсне-башны салып кибенәбез…
— Ничек инде?
— Шулай, якындагы теге юкә агачына барабыз да өскә үрмәлибез. Бераз менгәч, агач ябалдашлары безне авыл күзеннән, якында гына йөргән көтүчеләрдән, печәнчеләрдән, юлчылардан яшереп куя. Менә шунда без чишенеп ташлыйбыз да күлмәкләребезне ботак-чатакка тезеп эләбез…
— Сез бигрәк инде… Оятсызлар кебек кылангансыз…
— Үзем дә аптырыйм, бер дә оят түгел иде безгә. Мин Сәвиягә тимәдем, рәнҗетмәдем. Әмма мин аны һушны югалтырлык дәрәҗәгә җитеп назлый идем… Беренче мәртәбә күкрәкләреннән шунда үптем… Салкын бөркеп, калтыранып торган күкрәк алмаларын борыным белән назлый-назлый үптем… Шытып, күпереп килүче бодай бөртеген иреннәремә алып, шулай назлап капкан килеш: «Мин сине яратам!»— дип пышылдый идем… Чәчләренә, кашларына, керфекләренә, кыенсынудан алсуланган бит, ияк очларына, кулбаш-янбашларына, күкрәк төймәләренә кунган көмеш тамчылар бүген дә күз алдымда… Кендек уймагында да шундый ук көмеш тамчы. Менә ул тамчы, нинди дер җан иңеп, шул оясыннан йөгереп чыга да аска, тагын да серлерәк, сихерлерәк дөньяга таба тәгәри…
— Син, чынлап та, бәхетнең нинди икәнен белеп калгансың…
— Юк, ялгышасың, мин бәхетнең нинди икәнен белми калдым, ә менә сөю-мәхәббәтне бөтен матурлыгында татып белдем.
— Син хаклы… Мең мәртәбә хаклы!
… Авылга җитеп киләләр иде инде. Сәүбән, сискәнеп диярлек, бер сәер уйга барып төртелде: «Бу малайны минем белән күрсәләр? Нәрсә дип әйтермен соң? Көләрләр…»
Малай-Сәүбән, әлбәттә, аның бу уйларын белеп бара иде. Ул җавабын көттермәде:
— Йә, юләр сатма. Мине синнән башка беркем күрми. Бер кеше икәү була алмый бит инде!
— Ә?..

## 4

«Туган туфрак» дигән сүз дөрес икән. Туган авылына, йорт-нигезенә якынлашкан саен, Сәүбәннең йөрәге ныграк җилкенә барды. Баштарак, йөрергәме-юкмы, дигән кебегрәк тибенеп яткан йөрәк, бераздан әчке бер талпыну белән сулкылдарга керeште, аннары чабып-йөгереп үк китте, ниһаять, авыл читендәге инеш аша салынган агач күперне чыгуга, ярсып-ярсып, ярылырдай булып тибә башлады. Унсигез ел аз гомер түгел шул… Бигрәк тә туган туфрактан аерылган кеше өчен… «Туган туфрагыннан башка үлән дә үсә алмый, балам», — ди иде әнкәсе.
Яз көне булды бу хәл. Бишенче-алтынчы сыйныфларда укучы Сәүбән, яланда йөргәндә, очраган бер кыр чәчәген чокып алды да, кайтып, тәрәзә төбенә гөл итеп утыртып куйды. Аның өчен бакчаларындагы иң яхшы туфракны алып керде, көн саен диярлек су сибеп тора башлады.
Юлда кайтканда шиңә башлаган гөл тиздән сынын турайтып җибәрде, терелеп, яшәреп-яшелләнеп китте. Туфрак килеште үзенә — бераздан чәчәк тә атты, тәрәзә төбен бизәп, әллә кайдан янып-балкып тора башлады...

Сәүбән шатлыгыннан очып диярлек йөрде. Бу гөл чәчәкләрен һәр кергән кешегә сокланып, горурланып күрсәтә иде ул.

Кинәт гөлгә әллә ни булды. Берничә көн эчендә чәчәк таҗларын коеп бетереп шиңә башлады. Башта яфрак очларын саргайтты, аннары сабагы да сагыштан зар булган кеше төсле сыгылып төште…

Сәүбән нишләргә белмәде, һаман су сипте, гөлнең төбен йомшартты, кояшлырак урынга күчереп куйды. Ләкин үсемлеккә болар да файда итмәде.

Шунда ул әнкәсенә дәште:

— Әнкәй, карале, матур гөлебез үлә бит, нишлибез инде хәзер?..

— Нишли дә алмыйсың, улым. Туфрагы килешмәгәндер, туфрагы. Туган туфракка ни җитә, — дип, уйчан гына әйтеп куйды әнкәсе.

«Кеше — табигать баласы» дип юкка гына әйтмиләрдер, күрәсең. Ул, туган якларыннан аерылып, нинди генә җиткелеккә ирешсә дә, тулы бәхеткә ия була алмый, үзен ятим сизә, моңсулана, бөега…

Балаларда картлар акылы була икән. Гөлне үз яланына илткәндә, Сәүбән әнә шул хакта уйланып барды.

Сәүбән уй очын төйнәп бетереп һушын җыеп алырга өлгерми калды, үр тыкрыгыннан Май әби килеп чыкты… Май әби! Әй, Май әби! Синме бу? Син шул… Үзгәргән… Үзгәрмәгән! Юк, иң дөресе: үзгәргән дә, үзгәрмәгән дә.

— Исәнлек-саулыкмы, Май әби!

Май әби Сәүбәнгә игътибар итмәде. Колакка электән үк катырак иде ул. Әнә бит Сәүбәнне ишетмәде дә, әллә иске көянтәсен, әллә карт сөякләрен шыгырдата-шыгырдата, болай да бөкре гәүдәсен тагын да алгарак ташлап, һаман баруында булды.

— Май әби, исәнме-саумы!— Бу юлы Сәүбән тавышын кызганмады.

Ниһаять, Май әби, үзенең уй-гамь дөньясыннан аерылып, башын күтәрде, әмма бөкресе шул килеш калды.

— Аллага шөкер, исәнлектә гомер сөрәбез, рәхмәт, балам, матур сөйләшүең өчен.

— Ни хәлләрдә генә торасың, Май әби?

— Хәлләребез Ходай кулында инде… Язганны күрмичә, кара гүргә кереп булмый, балам. Менә һаман җан асрыйм әле… Кем соң син, балам? Бер дә күргән-ниткән кешегә охшамагансың.

— Ныклабрак кара әле, Май әби, кемгә охшаганмын соң?

Май әбигә тулы чиләкләр асылынган көянтәне күтәреп тору кыен иде. Ул, болай да җыерчык сарган йөзен тагын җыера төшеп, Сәүбәнне як-яклап тикшерә башлады. Бу юлы Сәүбән шуны искәрде: Май әбинең башы үрелеп-үрелеп караганда, бөкре гәүдә һаман үз урынында кала, бу хәл карчыкны мескен, зәгыйфь итеп күрсәтә. Сәүбәннең моңа күңеле сызлый, әмма ул аңа берничек тә ярдәм итә алмый иде.

— Кем диим икән соң? Бер дә күзгә таныш кеше түгел, гаепләмә, балакаем, колаклар гына түгел, күзләр дә ялгышалар хәзер.

— Ә менә бу малайны танныйсыңмы?

— Кемне тагы?— Карчык, көянтәле бөкре гәүдәсен кузгатмыйча гына, башын боргалый башлады. Сәүбән дә тирә-ягын барлады. Ул читтәрәк елмаеп басып торган таныш малайны бик тиз эзләп тапты.

— Әнә теге малайны…

— И-и, балам, ни дигән сүз инде ул?! Җаны чыгарга торган карт әбиең белән шаярып торасың тагын… — Май әби, күңеле борчылып, чын-чынлап китәргә җыенды.

Сәүбән бер малайга, бер Май әбигә карап торды да, тәмам төшенеп җитте. Малай аны алдамаган, басу капкасы төбендә аңа чып-чын балалыгы, дөресрәге, бала чагының рухы, рәвеше, образ-сурәте очраган. Һәм ул аныкы гына! Ул гына күрә аны!

Йөрәге шартлар хәлгә килеп җиткән Сәүбән тәмам каушап төште, ул хәтта теге малайга кабат күтәрелеп карарга курыкты.

Шыгырдый-шыгырдый кайтыр сукмагына төшкән Май әбинең кызганыч хәле, ниһаять, аны айнытып җибәрде. Сәүбән, үзен-үзе белештермичә, йөгереп барып, аның көянтәсенә барып ябышты…

— Әйдә, үзем озатып куям, Май әби. Мин бит Сәүбән, танымыйсыңмыни. Сәү-бән! Рәмзия малае. Әйе-әйе, кече малае. Таныдыңмы? Әйдә, бергә кайтабыз… Без бит күршеләр, өегезгә үк озатып куям…

— И-и, балам-балакаччаем! Син Рәмзия улы буласыңмыни? Теге, китеп югалган улымы? Җирле, танымадым… Югалган җан — уылган җан шул… Синең, балам, йөз нурың да, җан нурың да уалгандыр… Алай озак йөрергә ярыймыни читтә?.. Туган җиргә кайткач, һәр туксан яшьлек карттан алып

тугыз яшьлек балага кадәр танырлык итеп яшәргә кирәк, балам. Әле миңа туксан юк, ә мин инде сине танымыйм…

Сәүбәнгә оят, бик тә оят иде бу сүзләрне ишетү. Ул боларның авылга кайткач ишетәчәк авыр сүзләрнең башы гына, яратып әйткәне генә булуын аңлады.

Икәүләп авыл урамына керделәр. Сәүбәннең күптән көянтә-чиләк тотканы юк иде. Ул шактый суны түгеп-чәчеп бетерде, шулай да сер бирмәде, иреннәрен күгәрткәнче тешләп, Май әби артыннан кайтуында булды. Җитмәсә, теге малай да күз көеге булып бара. Сәүбән аңа сыңар күзе белән генә карап ала. Дәшми. Шушы дәшмәве белән үзенең үпкәсен белдерәсе килә. Чынлап та, ни дип ул юлга аркылы төшеп, күңел кузгатып, җан үртәп йөри? Кем кушкан аңа? Кем чакырган аны?

Әле ярый җилкәсендә авыр көянтә бар. Югыйсә Сәүбән, күңеленә тулышкан үпкә-ачуыннан кабарып, өскә күтәрелеп китәр иде, яисә, шулай үпкәсенә тулыша-тулыша, шартлап чәлпәрәмә килер хәлгә җитәр иде…

Сәүбән аңламый түгел, барысын да аңлый. Бу малайның, ягъни бала чагының бернинди гаебе дә юк. Ул бит үзе. Ул үз-үзенә генә үпкәли, рәнҗи ала. Теләсә, кичерә… Теләмәсә — юк… Әйдә йөрсен. Бер уйлаганда, аның булуы, янында йөрүе ярап тора. Япа-ялгыз кеше бит ул; бер иптәш тә булмаса, нишләр иде? Ә бу малай — иптәш кенә түгел, акыллы, зиһенле, һушлы, иманлы бер зат. Әнә бит ничек итеп ул Сәүбәннең җанын талкыды, йөрәген ярсытты, күңел хатирәләрен кузгатты. Бер дә зыянга булмады бугай… Бу малай очрамаса, әзерлексез-нисез килеш ничек итеп кайтып керер иде ул авылына? Көтелмәгән хисләрдән, кичерешләрдән йөрәге шартлар иде дә әрнүле күзәнәкләре белән Кала-тау итәген тутырыр иде.

Кеше — шаккатыргыч дәрәҗәдә сәер зат. Байлыгы, малы китсә, җаны сызып борчыла, ә мәгънәсез үткән көннәре хакында уйларга вакыт тапмый. Сәүбәннең дә мәгънәсез үткән тормыш көннәре күп булды. Аның бу битарафлыгына ис-акыллар китәрлек… Басу капкасы төбендә очраган сәер малай исә аны, ниһаять, уйланырга мәҗбүр итте.

Менә алар Май әбиләр турына җиттеләр. Сәүбән үз уйларын уйлаган арада, күрше карчыгы авыл хәлләрен сөйләп, үзенең карлыккан тавышы белән аның җанын өшетеп кайтты. Сәүбән әбине тыңламады да. Шушы берничә минутта аның уй йомгагы балалык елларын урап кайтырга өлгергән иде…

Менә шушы яшел чирәмлеккә тезелеп утырырлар иде. Кызлар бер якка, малайлар икенче якка. Май әби аларга сый чыгарыр иде. Кара икмәккә калын итеп ягылган атланмайның бераз баллырак, бераз төчерәк тәмен әле дә тел очында йөртә Сәүбән. Май әбинең исем-кушаматы да шушы «май табыны»ннан калган, ахры. Ә, юк… Чынлыкта бу исемнең тарихы борынгылыкка китә. Сәүбәннең укыганы бар: Тәңренең Умай исемле сөйгәнен — Гомер алиһәсен татарлар «Май әби» дип йөрткәннәр. Кендек иясе, нәсел иясе, гомер иясе буларак билгеле ул. Күршеләре Май әби дә тирә-яктагы бөтен бала-чаганың кендеген кискән кеше ләса… Сарманай авылында андый әби-бабайлар тагын бар әле. Ак бабай, Ак әби, Бал әбиләр бар, Алма бабай, Чия бабай, хәтта Шомырт әби белән Җиләк апа, Шире бабай белән Өлге бабай да бар авылда. Сәүбән аларның исемнәрен хәзер төгәл генә аңлата да алмый. Бу әбиләр-бабайлар, үзләренең исемнәрен аклар өчен, балаларга иң соңгы бал-майларын чыгарып бирәләр, алма-чия уңмаган елны, читтән алып кайтып булса да, балаларны алма-чия белән сыйлыйлар. Бу да — авыл рухы. Авыл гадәте. Аның матурлыгы, кирәк икән — бәхете!

Сәүбән үз капкаларын шакыганда, Май әби, рәхмәтләр укый-укый, күрше өйалды эченә кереп бара, ә малай кыяфәтендәге бала чагы таралган томан кебек каядыр очып юкка чыккан иде…

«Их, рәнҗеттем, үпкәләттем бугай, — дип уйлап алды Сәүбән, — башка килмәс микәнни? Ияләшә башлагач кына…» Әмма бу хакта озаклап уйланып торырга вакыт юк иде, өй эченнән әнкәсенең үтә дә таныш, газиз, ягымлы тавышы ишетелде:

— Кем у-ул? Капка ачы-ы-ык!.. Көпә-көндез капка бикләп тотарга без урыс чирмеше түгел лә…

Сәүбән унсигез елдан соң беренче тапкыр җил-яңгырда төсен югалткан, инде какшап-имгәнеп беткән урам капкаларын ачып керде; аны нык кына таушалган, имгәнеп, ян-якка авыша башлаган иске йорт каршы алды. Бу караңгы, шыксыз дөньяда бердәнбер олы куаныч — ишектән үрелеп карап торучы әнкәсенең көләч йөзе иде.

Ике ай элек кенә ике атналап бергә яшәп алсалар да, ана белән бала бик озак аерылыша алмыйча күрешеп-кочаклашып тордылар. Туган нигездәге күрешү бит бу, ана белән баланың илаһи күрешү йоласы. Ун ел күрешмәгәннәр диярсең… Авылда туып үскән укучы аңлар: бу ана белән баланың гадәти күрешүе генә түгел, бала белән туган йортның, туган нигезнең, бу нигездә калган рухларның, кендек канының, улын көтеп, көннәр, төннәр буе намазлык өстендә утырган ана догаларының күрешүе дә иде.

Кутәрмә-болдыр, өйалды идәннәрен шыгырдата-шыгырдата өйгә керделәр. Рәмзия бертуктаусыз улының аркасыннан сөйде. Аннары, үзен үзе тирги-тирги, самавырга барып ябышты:

— И-и, улым кайткан да эш бетте түгел бит әле. Кая чәй куйыйм, юлдан арып кайткансыңдыр. Хәер, хәзер өлгерә ул безнең самавыр… Сөеп кенә кайнатам мин аны…

Сәүбән исә аның гомер буе авыр эш эшләп арыган, ябык-арык кулбашларыннан килеп тотты:

— Әнкәй бәгърем, әйдә, иң элек өй, нәсел рухларына дога кылыйк. Миннән булмас, белгән догаларыңны үзең укы. Тик… кычкырып укы яме. Минем колакка да керсен, күптән ишеткәнем юк инде моңлы дога авазын. Әйдә, әнкәй…

Рәмзия үзенең кыен хәлдә калганын аңлады. Үз улы булса да, Сәүбән алдында нык каушады, әмма әйтәсе сүзенең тәмен югалтмады:

— И-и, үз улым алдында оятка калдым бит. Өйгә керүгә үк Хода сүзен искә төшерергә тиеш идем югыйсә. Улым үземнән акыллырак, иманлырак булып чыкты. Ана белән бала бер олы җан инде. Синең әйтүең — минем әйтүем. Рәхмәт, улым. Нигезеңә матур керәсең, иманлы күңелеңне җәеп керәсең… Әйдә, менә шушында утырышыйк. Менә бу шәмаил ягы кыйбла як булыр.

Ана белән бала ак мич янындагы эскәмиягә янәшә утырдылар, аннары, кулларын алга кушырып, бер мәлгә тынып калдылар. Бераздан өй эчен дога авазы күмде. Рәмзиянең моңлы-ягымлы тавышы бүген аеруча мәгънәле, шул ук вакытта эчке бер тетрәнү белән яңгырый иде: «Әгүзе билләһи минәшшәйтаннир-раҗим. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим». (Рәмзиянең һәр догадан соң аның мәгънәсен әйтеп куя торган гадәте бар. Бу юлы да ул әйткән догаларын ана телендә аңлатып барды.) Рәхәттән сөрелмеш шайтанның явызлыгыннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынамын. Дөньяда да, ахирәттә дә рәхмәт кыйлучы Аллаһы Тәгаләнең исеме белән башлыйм… «Аллаһүммә һуввин гәләйнә һазас-сафара үәтуи ганна бугдаһу. Аллаһүммә аңтәс-сахибу фиссафари үәл-халифату фил-әһли, Аллаһүммә иннии әгүзү бикә миувагсаа-ис-сафари үә кә-абатиль-маңзари үә сууиль-муңкаләби фил-мали үәләһли үәл–уаләди…» Әй Аллаһы! Бу сәфәрне безгә җиңел кылдың… (Рәмзия бу доганы баштан үткән эш итеп аңлата, «кыл» дигән теләк урынына «кылдың» дип, рәхмәт белдереп сөйли иде.) Һәм юлыбызны тиз һәм хәвефсез иттең! Әй Аллаһы! Юлларыбызда үзең юлдаш бул һәм тормышыбызда гаиләдәшләребезгә сакчы-ярдәмче бул! Аллаһы! Мин Үзеңнән ярдәм сорыйм: бу сәфәрнең кыенлыгыннан коткарырга, авырлыклардан сакларга һәм сәламәтлегемә, гаиләдәшләремә, балаларыма зарар килүдән сакларга булыш. И Аллам! Барысы өчен дә мең рәхмәтләр Үзеңә! Амин!»

Дога — һәркем өчен ачык гамәл. Догадан кала, кеше күзеннән яшеребрәк, качыбрак эшләнә торган гамәлләр дә бар. Ана белән бала арасындагы җылы, матур мөнәсәбәтләрне шуңа күрә тәфсилләп язып тормыйм. Аларның бергә әвәрә килеп самавыр яңартуларын, табын әзерләп, чөкердәшеп, озаклап чәй эчүләрен, иске фотосурәтләр карап, әле көлеп-елмаеп, әле моңсуланып утыруларын нечкә күңелле, тоемчан укучы болай да сизенгәндер…

Әмма ике нәрсә хакында укучыга түкми-чәчми әйтергә тиешмен. Сәүбән кайчан да булса анасыннан атасы хакында һәм Сәвия хакында сораячак иде. Бүген ул сорамас кебек. Аның шәһәрваклыкларыннан арыган рухы, мәхәббәтсез тормыштан талчыккан җаны туган нигезендә бераз хәл җыярга, күңел утыртырга тиеш. Авылсыз узган унсигез ел гомеренең тыгыз йомгагын сүтеп җибәрү җиңел түгел, моңа күпмедер вакыт кирәк иде…

Малае янында бераз юангач, Рәмзия, мунча ягарга, кош-корт карарга дип, тышка чыгып китте. Сәүбән, бер кочак фотосурәт тотып, ялгызы утырып калды. Ләкин аның фотолар карыйсы килмәде. Аларда әрнүле хатирәләрдән башка берни дә юк. Сәүбән үзенә бик кызык шөгыль тапты: урам як тәрәзә янына утырды да авылны күзәтә башлады.

Иң элек ул урам башындагы иясез ватык арбага игътибар итте. Аның бер тәгәрмәчен кемдер салдырып алып киткән. Алдагы тәртәләре дә юкка чыккан. Гарипләнеп бер якка янтайган бу арбада Сәүбән үзен танығандай итте. Аның да язмыш тәртәләре кайдадыр югалган, тормыш арбасының бер генә түгел, ике, өч тәгәрмәче ватылып, төшеп калган. Ул да менә хәзер яралы, гарип рухын дәваларга авылына кайтып егылды. Табармы ул монда берәр дәва? Йөрәк түрендә гомере буе йөрткән сагыш төерен сүтә алырмы? Ничә еллар күңелен әрнетеп торган сызлавыктан котыла алырмы?

Әнә кемдер килә. Таныш, түгел… Таныш! Бу бит Әнисә апасы! Башлангычта укыткан Әнисә апасы… Бер үзгәрмәгән… Әнә ничек җил-җил атлап килә, очып йөргән кебек йөри. Мәктәптә каникуллар чоры хәзер. Кая бара икән? Кая барса да барыбер түгелмени… Иң мөһиме, ул исән-сау, һаман элеккечә тере, җитез, якын, кадерле…

Мәктәптә укытучылардан уңды Сәүбән. Әмма укытучыларның әйбәтлегенә ул үзе сәбәпче иде. Аңа уку җиңел бирелде. Сәүбәннең яшь, тәҗрибәсез зиһене белән Ходай Тәгалә яисә нindidер изге рухлар идарә итеп торган шикелле. Өй эшен эшләмәгән чакларында да аның начар җавап биргәне, начар билге алганы булмады. Нindidер илаһи бер көч аның колагына дөрес җавапны пышылдап торган кебек иде. Чыгарылыш сынаулары вакытында Сәүбән тагын бер мәртәбә аптырады. Билет алып утыргач, күзен йомып, хәтерен бер урынга җыеп китерүе була, бөтен укыганы исенә төшә дә куя. Экрандагы сурәт кебек, йомык күз алдында балкып-сүнеп тора башлый… Китап укыганда аның

һәр бите, фоторәсем кебек, күңеленә төшеп кала, кирәк чакта, шул битне хәтер төпкеленнән эзләп табу кыен булмый. Әнкәсе Сәүбәнгә гел әйтә иде:

— И-и, улым! Бигрәкләр дә җиңел бирелә сиңа уку. Хәерлегә генә булсын! Җиңел килгән җиңел китә бит. Килгәч-килгәч, белем сиңа китмәслек булып килсен!.. Миннән теләк шул, — ди иде.

Әллә инде Рәмзиянең улын беренче сыйныфка илткәндә теләгән теләге кабул булды? Ул вакытта: «Ярабби! Улыма тел ачкычлары бир!» — дип теләгән иде ул.

Ләкин Сәүбән бер нәрсә хакында кешегә әйтергә курка. Аңа кемдер даими булышып тора. Аның зиһененә мәктәптән, институттан башка да каяндыр аң-белем, өстәмә мәгълүмат килеп тора. Баштарак ул моңа гаҗәпләнә иде. Хәзер аптырамый инде. Димәк, кемгәдер шулай кирәк. Ходай Тәгаләгәме, Күк-галәмгәме, табигатькәме, әллә Хөсни карт риваятьләрендәге Зөһрә-анагамы?

Урамнан, ике бозау куып, Нигъмәт бабай узды. Бозаулары көр күренә. Димәк, өч сыер асрый бу карт. Иң гади авыл арифметикасы: ике сыерга ике бозау, узган елгы бер бозауны иткә суялар, бер тана бозау нәселгә калдырыла, киләсе елга бозылыбрак киткән сыерны суеп, әлеге башмакны савымга куялар. Шул рәвешле абзарда һәрвакыт өч эре мал тора. Алар тирәсендә ике бозау, өч-дүрт сарык бөтерелә…

Нигъмәт карт — түбән оч белән астурамның Ак бабае. Әйе, авылларда Ак бабай, Ак әби дигән могтәбәр затлар яши әле. Алар мулла да, авыл советы да түгел. Алар — шушы төбәкнең рухи җитәкчеләре, йоланы, милли рухны, әдәпне, тарихны саклаучылар. Мондый картларны беркем дә сайлап куймый, алар бу вазифага гомер буе эшләгән изгелекләре, матур гамәлләре аркасында ирешәләр.

Нигъмәт Ак бабайның да һәр әйткән сүзе мәгънәле, иманлы һәм тормышчан иде. Сәүбән аның һәр сүзен яшәү кануны итеп кабул итә, күңелендә бөртекләп саклап тота. Әле дә хәтерендә, чыгарылыш сынауларыннан соң, яшьләргә фатиха бирү өчен, мәктәпкә Ак бабай килгән иде. Ул, һәрбер баланың кулын кысып, аларның колагына теләк-дога әйтеп чыкты. Сәүбәнгә нәүбәт җиткәч, Нигъмәт карт, аның колагына үрелеп: «Чит-ят аллаларга табынма, үзең салган юлдан абынма», — дип пышылдады.

Ак бабай картайган. Аякларын өстерәбрәк атлый. Шулай да нык әле. Гәүдәсе төз, туры, сыны зифа. Ап-ак сакал-мыеклары йөзенә мөлаемлык, нурлы-иманлы төс биреп торалар. «Иртәгә кереп чыгарга кирәк булыр. Нык кына эләгәчәк үзеннән. Әмма ул хаклы булачак», — дип уйлап алды Сәүбән. Кемгә үпкәләп кайтмый йөрде соң ул? Кемгә нәрсә исбатларга тырышты? Моңардан кемгә җиңеллек килде? Әнкәсенәме, үзенәме? Бәлки… Юк-юк, әлегә Сәвия хакында уйламаячак ул…

Сәвия хакындагы уйларыннан арынырга теләп, Сәүбән урамнан шул уйларын ияртеп җибәрерлек җан иясе эзләде. Һәм тапты! Ул әлеге дә баягы Май әби иде.

Чишмәдән алып кайткан шифалы судан чәй кайнатып, тамак кибүен басып чыккан Май әби бу юлы түбән очка ашыга иде. Әмма ул бик ерак китә алмады, урам чирәмендә үлән чемчеп йөргән яшькелт-сары каз бәбкәләре тезелешеп аның артыннан иярделәр. Май әби аларны кире куа башлады. Оясыз үскән каз бәбкәләрендә азык табучы ана артыннан ияреү инстинкты көчле иде, күпме генә куса да, Май әби аларны капка төбендә калдыра алмады. Ниһаять, тәмам арып-алҗып, ул биш бөртек инкубатор бәбкәсен элекке урыннарында оялатты да кабат өенә кереп китте. Сәүбән, үзе дә сизмәстән, кычкырып көлеп җибәрде…

— Кызыкмы?

— Ә?..

Сәүбән, сискәнеп, артына борылып карады. Ишек катында аның бала чагы — кечкенә Сәүбән басып тора иде. Сөенергәме, көенергәме — Сәүбән әлегә анык кына белми, шулай да, малайны күргәч, аңа рәхәт булып китте. Ялгызлык, күңел тынгысызлыгы, андагы сагышлы авыртыну шулкадәр ялкыткан, Сәүбән ишектән теләсә кем килеп керсә дә, кочаклап каршы алырга риза иде бу минутта. Ә бу малай — теләсә кем түгел, үзенең газиз бала чагы!

— Кая юкка чыктың син? Әллә үпкәләдеңме?

— Юк ла… Әнкәй сине каршы алганда, күзне майландырып тормыйм, дидем. Йә көнләшеп куярмын…

— Ә мин сине үпкәләттем дип уйлаган идем…

— Юк ла, мин бит рух. Рухлар үпкәләми, алар ачулана гына.

— Син мине ачуланмыйсыңмы?

— Юк.

— Димәк, мин бөтенләй үк беткән кеше түгел әле?

— Тагын шул буразнага төштең… Мактатасың киләме?

— Йә, ярый-ярый… Шаярмакчы гына идем…

— Ә беләсеңме, кешенең әйбәтлеге ярата белүе белән билгеләнә, бәяләнә. Ә син ярата беләсең. Тәрәзәдән карап торуыңда да ярату бар бит синең. Ярата белү сәләтеңне югалтмагансың син. Ярата белгән кеше начар кеше була алмый…

— Ә бит ярата белгән кеше — сагышлы кеше...

— Юк, бу башкачарак... Сагына белмәгән кеше ярата да белми. Сагыш — сөю бишеге. Ярату хисе сагышта гына сынала, чыныга, үсә ала. Мәхәббәттән бәхеткә юл — сагыш аша гына!

— Димәк, сагышлы кеше — әйбәт кеше.

— Шулай. Сагына белүче кеше — яхшы кеше. Чөнки бу хис ярату, хөрмәт, итагать хисеннән соң гына туа ала. А–а, синдә сагыш бар...

— Карале, миңа ошый башладың әле син. Баштарак бер дә ошамаган идең. Хәзер күрәсе килеп кенә тора...

— Син дә миңа ошыйсың. Башта мәнсез-мәгънәсез бер адәм заты булып тоелдың, билләһи. Хәзер ярыйсы... Әйдә, дуслашыйкмы?

— Әйдә соң!.. Мә бишне!

— Мә бишне!

Сәүбән, кул сугышыр өчен, бармакларны җәеп, учын алга сузды. Бала Сәүбән дә үзенең нәни учын өскә күтәрде. Әмма учка уч туры килмәде, нәни уч, олы кул-бармаклар аша үтеп, аска төшеп китте...

Сәүбән каршында чын мәгънәсендә илаһи рух басып тора иде.

**5**

Сәүбән соңгы — өченче әтәч тавышына да уянмады. Әнкәсе җәеп биргән ап-ак түшәккә чумып, мәрткә киткән кеше кебек изрәп йоклады да йоклады. Яшькелт-зәңгәр күзләренең шар ачык булуы гына куркыта, шомландыра. Рәмзия, тыштан урап кергән саен, малае ягына карый: күзләре һаман ачык. Догаларын укый-укый тагын чыгып китә. Авылда мәшәкать җитәрлек бит: көтүе, кош-корты, ишегалды, бакчасы... Шулай да, тышта беразюангач, Рәмзия тагын ашыгып килеп керә, тагын малае ягына күз ташлый. Һаман элекке хәл: Сәүбән су төсле күзләрен томрандырып карап ята!

Рәмзия белеп бетерми шул: Сәүбән чынлап та «мәрт йокысы» белән йоклап ята. «Үлем йокысы» дигән сүз ул. Мондый йокы вакытында кешенең җаны үзе белән булмый. Кайдадыр очып йөри. Әмма күзгә күренеп-беленеп тормаган нурлар аша йокы иясенә үзе булган урыннардан сурәтләр җибәреп тора. Кешеләр бу хәлне «төш» диләр. Менә әле дә Сәүбән төш күреп ята.

Күзләр — кешенең иң серле-сихерле урыны. Якты дөньяга ишек. Бу — шулай. Әмма күзләрнең сихри асылы, илаһи хасияте моның белән генә бетми әле. Күзләр һәрвакыт, һәрдаим җан карамагында, җан ихтыярында булган. Кеше җаны шушы күзләр аша хәрәкәтләнә. Күзләр — җан юлы, җан сукмагы... Халыкта «җансыз күзләр» дигән сүз йөри. Кеше үлгәч, җаны чыккач, иң беренче итеп аның күзләрен йомдырып куялар. Җан тәслим иткән, җаны башка кайтмаячак дигән сүз бу. «Күз саклау — җан саклау», «Күзсез калу — җансыз калу» дигән әйтемнәрдә дә бар «күз-җан» тәгълиматы.

Кеше күзенә нур йөгерсә, карашларына якты балкыш кунса, аңа «җанланды, җан керде» диләр. Тагын бер борынгы йола: баласының яисә сөйгәненең күзеннән үпкәндә кеше һәрвакыт: «Җаным!» яисә: «Җанкисәгем!», «Җанашым!»— дип әйтергә тиеш. Бу — катгый таләп. Борынгы йола.

Кайбер төбәкләрдә, уянган кешегә карата: «Җан төбе белән уянды», — диләр, икенче бер урында: «Җанны эретә торган күз карашы», — дип, матурайтып әйтәләр.

Кешегә йотлыгып карап торуны да татарлар «күз ату» диләр. Шуны ук икенче бер урында «күңел ату», «җан ату» дип үзгәртәләр. Гашыйк булу, ярату белән бәйле мондый әйтемнәр дә шушы «җан-күз тәгълиматы»ннан килеп чыга түгелме?

Ниһаять, «күңел күзе», «җан күзе» дигән сүз бар. Бу сүз ике төшенчәне турыдан-туры бәйләп куя. Сәүбән дә менә шушы күңел күзе белән, җан күзе белән карап ята. Күзе бар, ул шар ачык, ә менә җаны кайдадыр йөри, иясенә кайтырга уйламый да...

Рәмзия үзе уйлана, үзе һаман борчыла. Ул инде курка да башлады. Сәүбәненә бер-бер хәл булмасын тагы... Менә ул, якын ук килеп, малаеның ачык күзләренә карап тора, аны йомдырмакчы була... Ана кешегә: «Ярамый, күзләренә тия күрмә! Күзләрен йомдырсаң, харап итәсең, җаныннан мәхрүм калдырасың, аңа кабат кайту өчен юлны ябасың, ярамый, тимә!»— дип әйтәсе, юк, әйтәсе генә түгел, бөтен көчкә иңрәп кычкырасы килә.

Кайсыдыр тоемы белән Рәмзия моны үзе дә белә. Йокылы ачык күзләрне йомдырырга, куркытырга, хәтта уятырга да ярамый. Шуңа күрә ул малаен уятмый, күңеле ничек кенә өзгәләнсә дә, кагылмый, дәшми... Ул йомшак кына тамак кырып ала да, иң моңлы бер җырны сайлап, көйли башлый. Бу көйне, бу җырны тоячак, ишетәчәк аның малае! Ишетәчәк тә җанын кабат үзенә чакырып алачак, җаны белән бергә үзе дә якты дөньяга, авылына, нигезенә, әнкәсе янына кайтачак...

Төш — кешегә Аллаһы Тәгалә биргән иң зур бүләкләрнең берсе. Төш вакытында Кеше үзенең хыял чикләрен узып китә һәм хыял каршында үзенең никадәр мескен булуын аңлый. Аллаһы Тәгалә Кешегә төшне аның Кеше генә булуын искәртү өчен биргән.

Сәүбәннең җаны бу мәлдә Кала-тау янындагы чишмә буенда кош очыра иде. Ул төшендә аермачык күреп ятты: унөч-ундүрт яшьлек чаклары. Рух чишмәсе буенда кош базары… Нинди генә кош юк анда! Алар Сәүбәнне сырып алганнар. Кайсы кая куна ала — шунда куна… Сәүбән үзе ике учын да алга сузган. Учларында да кошлар… Берсе килеп куна, икенчесе очып китә, аның урынына өченчесе килә...

Сәүбәннең күзе чишмә читендә ялгызы басып торган нәни кошчыкка төшә. Нигә ул ялгызы? Нигә ул очмый? Сәүбән аңа якынрак бармакчы була. Теге кошчык читкәрәк очып китә… Менә ул чишмәдән су капмакчы була. Улакның очына ук килеп куна. Ургылып-ургылып аккан агымга нәни томшыгын төртә. Шул мәлдә үк, көчле агымга эләгеп, аска — чишмә казанына төшеп китә. «Ах! Харап булды!»— дип уйлап өлгерә Сәүбән. Йөгереп барып кулына ала… «Исән, исән икән бәгърем!» Сәүбән аны сулышы белән киптерә, терелтә, дәвалый башлый… Бераздан кошчыкка җан керә, шул арада ул инде Сәүбәнгә дә ияләшеп ала, аның учында тыныч кына утыра, канатларын чистарта, башын әле бер якка, әле икенче якка янтайтып, коткаручысын күзәтә, аннары, чырылдап рәхмәт әйтә дә каядыр очып китә…

Бер дә «каядыр» түгел, кайчандыр Сәүбән белән Сәвиянең «мәхәббәт мөнбәре» булган юкәгә табан очкан икән ул. Шул юкә агачының иң урта бер ботагына барып кунган… Нур булып кунган… Юк, бу нур — бөтенләй башка төрле яктылык… Сәвиясе бит бу! Сөйгәне! Нишләптер ул тәнсез, киемсез, тоташ нур гына, йолдыз кебек, Кояш кебек… Ләкин ул чын Сәвия! Нур булса да ул — чын! Ул… ул — фәрештә! Әнә Сәүбәнне үзенә чакыра. «Әйдә, минем янга очып мен!»— ди… Сәүбәнгә шул җитә кала, ул каяндыр пәйда булган канатларын җилпеп очып китә… Әмма ерак китә алмый, чирәмгә егылып төшә. Баксаң, аның иңендә сыңар канат кына икән… Шунда ук аның каршында Хөсни карт йөзе пәйда була. Ул авызын ачмыйча, иреннәрен кыймылдатмыйча гына нидер сөйли. Ничек була инде — үзе дәшми, үзе сөйли?! Төш бит бу, төш! Төштә бөтен нәрсә дә булырга мөмкин ләса. Хөсни картның һәр сүзен Сәүбән үз хәтеренә бөртекләп теркәп барды…

«Кеше — бер канатлы фәрештә. Ә очар өчен пар канат кирәк. Кеше бөтен гомере буе әнә шул икенче канатын эзли. Ул еш кына янәшә яшәрдәй кеше дә таба, әмма бу кеше аңа очар канат куя алмый. Һәм ул, шушы җир тормышына риза булып, җир кануннарына буйсынып яши башлый... Үзенең икенче канатын эзләүдән туктый, бирешә, җиңелә... Шул чакта ул, язмыш юлыннан тайпылып, читкә, бөтенләй икенче якка борылып китә... Кеше үзенең парын тапканчы йөрергә, эзләргә, көрәшергә тиеш…»

Шул сүзләрне әйтүгә, Хөсни картның сурәте юкка чыга, Сәүбән каршында тагын теге карт юкә, аның яшеллеген нурлап торучы Сәвия пәйда була.

Сәүбән юкәгә таба тагын бер мәртәбә талпынып карый. Бу юлы ул иңендә тигезлек, җиңеллек тоя, талпына башлый, әллә җанын, әллә канатларын җилпи-җилпи очып китә, берничә омтылуда юкә очына — нурдан коелган Сәвиясе янына барып куна…

— Сәвия, ничек тордың?— ди Сәүбән.

— Мин бит Сәвия түгел, мин аның фәрештәсе генә, — ди теге нурланыш.

— Барыбер түгелмени?

— Барыбер түгел. Менә син дә чын Сәүбән түгел бит. Син аның җаны, рухи фәрештәсе генә.

— Сәвия дә төш күреп ятамыни?

— Әйе, Сәвия дә төш күрә… Ул бүген көтүгә сыерын чыгарырга да онытты хәтта…

— Ул хәзер шатмы?

— Шат. Әнә сине төштә күреп елмая…

— Чибәрме ул?

— Чибәр, бик чибәр.

— Бит очындагы «мәхәббәт бөҗрасы» да шул укмы?

— Шул ук… Тик аның тирәсенә бер-ике җыерчык кына өстәлде.

— Чәчләре дә бөдрәме?

— Бөдрә-бөдрә… Тик… бу бөдрәлектә ак чәчләр күп хәзер…

— Миндә дә бар алар…

— Моны Сәвия белә…

— Каян белә ул?

— Син күргән төшне ул да күреп ята ич…

— Ә, шулай бит әле. Әйт әле, мин бик картмы? Күрсә, Сәвия миннән курыкмасмы? Гайрәте чикмәсме? Ә?

— Бигрәк бала инде син! Ярата ул сине, ярата… Син бүген дә аның өчен иң гүзәл, иң кадерле җан иясе… Сәвия сине югалтса да, өметен югалтмады. Чөнки ул Сәүбәнен югалтуны кайгы итеп түгел, сагыш итеп кабул итте. Ә сагышта һәрвакыт өмет була, кайгыда — юк… Син аның сагышы, өмете, Сәүбән…

— Мин аңа китергән җәфалардан соң да шулай уйлыймы?

— Кеше булса, рәнҗер иде. Синең Сәвияң дөньяга фәрештә итеп яратылган шул…

— Үзең әле генә «Аның фәрештәсе мин» дигән идең…

— И-и, беркатлы җан! Фәрештәләр ике төрле: күк фәрештәләре, ягъни рухи фәрештәләр булган кебек, җир фәрештәләре дә була. Сәвия менә шул җир фәрештәсе. Алар үпкәли, рәнҗи белмиләр, алар тоташ изгелектән торалар…

— Ә мин кем? Мин фәрештәме?

— Синме? Син беркем дә түгел.

— Ничек инде? Фәрештә булмасам, кешедер бит? Әллә… кеше дә түгелме?

— Кеше, кеше… Тик син җир кешесе түгел… Син — каяндыр очып килгән галәми нәсел кешесе.

— Хөсни бабай «Зөһрә-ана нәселе Чулпаннан — яшел планетадан килгән» ди. Без әнә шул Чулпан-Венера кешеләре булабыз, ахры… Безнең күзләр дә яшел-зәңгәр бит…

— Белмим. Мин җир кешеләрен генә таныйм. Сәвия — җир кызы. Ә мин — аның рухи чагылышы, яклаучысы, фәрештәсе.

— Сәвияне күрәсе иде! Булыш әле миңа!

— Анысы Ходай эше. Вакыты җиткәч, күрешерсез… Ә хәзер миңа китәргә вакыт…

— Аз гына тор инде… Китмә инде!

— Китәргә кирәк. Әнә Сәвия уянып ята… Урамнан Сәүбән кереп килә. Ул шаулап кергәндә, Сәвия уяначак, ул уянганчы, мин аның ачык күзләре аша күңел түренә кереп калырга тиеш… Соңга калсам — эш харап… Йә, сау бул. Әле без күрешәчәкбез.

— Күрешәбезме? Тагын күрешәбезме?

— Күрешәбез. Хуш…

— Хуш, Сәвия…

Юкә агачында Сәүбәннең җаны үзе генә калды. Үзе генә түгел икән. Аның борын төбендә генә, бер яшь ботакта, баягы кошчык талпына; ул, үзенчә сайрый-сайрый, Сәүбәнгә нидер әйтмәкче, аңлатмакчы була. Тик Сәүбәннең җаны аны аңламый…

Шунда аның колагында Сәвия фәрештәсенең соңгы сүзләре яңгырап тора башлый: «Урамнан Сәүбән кереп килә. Ул шаулап кергәндә, Сәвия уяначак…» Кем хакында әйтте ул, нинди Сәүбән, каян, нигә керә?.. Әллә? Аның иясе, торып, Сәвияләргә таба киттеме? Тизрәк кайтырга кирәк, кайтырга, кайтырга…

Әмма Сәүбәннең җаны тиз генә кайтып китә алмады әле. Сәвиянең фәрештәсе аны үз янына очыртып алып менсә дә, юкәдән ул ялгызы үрмәләп төшәргә тиеш иде. Төшкәч тә, чишмә буенда беренче пәйда булган урынын таба алмый иза чикте. Аны тапкач, үзе генә белгән догасын укыды да иясенә кайтып китте…

…Рәмзия Сәүбәннең йомык күзләрен шундук күреп алды. «Җаны кайткан, күңеле тынычланган, барысы да әйбәт», — дип уйланды ул, һәм йокыдан уянырга тырышып яткан улының колагына иелде…

**6**

Сәүбән уянмаган иде әле. Әмма ул әнкәсенең җырын ишетте. Күргән сәер төше генә аңа ныклап айнырга, зиһенен җыярга, күзен ачарга ирек бирми… Әнкәсе исә җырлый да җырлый…

Рәмзиянең беркайчан да сәхнәгә чыгып җырлаганы юк. Әмма Сәүбән аның җырчы икәнен белә. Ул икмәк пешергәндә җырларга ярата иде. Мичтән гәрәбәдәй янып пешкән икмәкләрне алганда, ишетелер-ишетелмәс кенә җырлый да җырлый… Юк, артык моңлы-сагышлы да түгел ул җыр, ничектер күңелләрне җилкендерерлек, җанны дәртләндерерлек, йөрәкне ярсытырлык өмет җыры иде… Рәмзия тагын сөт аертканда җырлый. Бераз оеп китеп, карашларын еракларга — өмет-хыялларына төбәп, сепарат сабын салмак кына әйләндерә дә әйләндерә… Ап-ак тамчылар, чиләктән чәчрәп китеп, ялгыш аның кара-кучкыл (кояш астында күп эшләгәннән ул) йөзенә, тамырлары калкып чыккан кулларына килеп куналар. Кайчакта Сәүбән: «Аның чәчләре дә шул сөт аклыгыннан түгел микән?»— дип уйлап куя иде… Ул чаклардан күпме вакыт узган! Ә әнкәсе һаман җырлавын ташламаган… Җырласын иде, бервакытта да җырын, көен өзмәсен иде! Җыр ул — җан тавышы, җан авазы бит…

Сәүбән ярым уяулы килеш ята бирде. Ул инде әнкәсенең карашын тоя, җан тибрәнешен тоя, хәтта сулышын-тынын тоя… Әнә әнкәсе аның өстенә иелә, колагына изге-хикмәтле сүзләр пышылдый: «Мәтә… Тикә… Умма… Йәрсә… Иллә… Әнни… Һүнни…»

Сәүбән дертләп китте. Нинди таныш сүзләр! Юк, гадәти сүзләр түгел алар, дога сүзләре! Нindидер могҗиза, тылсым белән бәйле дога сүзләре. Сәүбән бу доганың каян килүен дә, нәрсә аңлатуын да белми. Аны беркем белми. Коръән догасы түгел ул. Әмма Сарманайда бу доганы һәр туган бала колагына пышылдыйлар, шулай кырык көн буе пышылдап, әйтеп-яңгыратып торалар. Шулай эшләгәндә ул баланың аң-зиһененә, җан-күңеленә мәңгелеккә кереп кала, аны шушы серле доганың иясе итә, имеш… Сәүбән, үзенең малае тугач та, кырык көн буе шушы доганы кычкырып торды, Сәвиянең «Нинди сихер кертеп булашасың?» дигәненә карамады, ата-баба йоласын җиренә җиткезеп үтәде.

Сәүбән күзләрен ачканда, Рәмзия баягы «Җидегән чишмә» көен көйләп йөри иде. Ул инде өстәл әзерләгән, өй эчен дә ялт иттереп җыештырып, балкытып куйган. Җәй уртасы булса да, мичкә яккан. Үзе генә белгән тәмле ашларын пешерәдер, мөгаен…

Сәүбәннең тиз генә торып китәсе килмәде. Аның күз алдыннан сәер төше, анда үзенең канатланып очып йөрүе, Сәвиянең илаһи рухы белән очрашуы озак китмәде әле. Ул элек тә «канатлы төшләр»не еш күрә иде. Тормышта да ул артык хыялый, җирдән күтәрелебрәк, очыбрак яшәде шикелле… Чынлап та, ул күпмедер күк кешесе, ахры, күренми торган канатлары бар, ахры, аның. Артык хыялый ул… Элегрәк бигрәк тә очынып, хыялыйланып яши иде. Хәзер бераз басылды басылуын. Әмма хыялыйлыгы барыбер бетмәде. Хыяллары да җирнеке түгел, хәтта күкнеке дә түгел… Бөтенләй өченче дөньядан бугай ул. Сәүбән моны тоймый, төгәл белә! Җан-күңел түрендә нindидер билгесез «күк сагышы», юк, күк кенә түгел, «галәм сагышы» саклап яши ул. Бу сагыш, бу моң һич бетми, киресенчә, елдан-ел көчәя генә…

Сәүбән бик еш уйлый: башка юлдан кереп китсә, ул бөтенләй әллә кем — йә бер моңлы җырчы, композитор, яки язучы, шагыйрь булыр иде. Мәшһүр җырчы, мәшһүр шагыйрь булыр иде! Шулай булса, аңа яшәү җиңелрәк тоелыр иде. Гомере буе күңел кылларында чыңлап, гүзәл, әмма үтә дә сагышлы-гамьле дөньялыкка чыгарып җибәрер иде дә, бушанып, җиңеләеп калыр иде… Үз тормышын математика, техника белән бәйләгән Сәүбән бу гамьне тышка чыгара алмый изалана; аны тормыш авырлыгы, яшәеш мәшәкатьләре белән бастырып куйган да, онытырга тырышып, хәтта белмәмешкә салышып яши... Әмма ул бер нәрсәне төгәл белә: кайчандыр бу сагышлы гамь аның күңел, җан түреннән бәреп чыгачак, бөтен дөньяны, тирә-юньне шыплап тутырачак һәм, үз дулкынына ияртеп, Сәүбәнне бөтенләй башка тарафка алып китәчәк…

«Торырга кирәк, югыйсә болай ятып шашарга була», — дип уйлап алды Сәүбән. Кулларын юрган астыннан чыгарып, як-якка җәеп салды. Нәкъ канатлар кебек булды. «Их, менә хәзер калкынып, очып китәсе иде, әнкәйне кочып аласы иде!.. Канатлар кирәк шул, чын канатлар кирәк…»

Шунда, әллә каян гына, бала чакта әнкәсе өйрәткән бер шигырь исенә төште. Рәмзия аны Сәүбәнгә кайсыдыр бәйрәмдә сөйләр өчен ятлаткан иде.

Әллә нинди җитди уйлар
Борчый безнең Саматны.
— Әни, әни, кара әле,
Бөтен нәрсә канатлы!

Һәрбер күбәләктә бар ул,
Һәрбер кошта бар канат.
Сандугачта, карлыгачта,
Акчарлакта, сыерчыкта…
Өлгереп булмый санап.

Самолетта да канат бар,
Кораб канаты — җилкән.
Яңгыр канаты — болытлар,
Галәм канаты җилдән…

Кояшның канаты — нурлар,
Агачта яфрак — канат.
Кинәт… уйланып ала да
Йөгереп килә Самат:

— Әни, әни, әйт әле, — ди, —
Кеше канаты нинди?
Әнисе, малаен кочып:
— Минем канатым — син, — ди.

Сәүбән, шигырьнең соңгы юлларын такмаклый-такмаклый, сикереп торып, мич артында булышучы әнкәсе янына килде.

— Әнкәем минем! Шундый татлы итеп йоклаганмын!.. Бик күптәннән болай ял иткәнем юк иде... Рәхмәт сиңа!..

Рәмзия улының аркасыннан сөеп куйды:

— И-и, балакаччаем, үз нигезеңдә бит син. Нигез рухлары сине таныган, үз иткән. Кабул иткән — шуңа да әйбәт йоклагансың... Әйдә, юынып ал да чәй өстәленә җитеш. Аннары урамга чыгып керерсең, йөреп кайтырсың...

— Ярый, әнкәй, мин хәзер... — Сәүбән йөгереп диярлек тышка чыгып китте. Ишегалдына килеп чыгуга, каршы як койма буенда яткан бүрәнә өстендә утыручы бала Сәүбәнгә барып төртелде. Сәүбән аны онытыбрак җибәргән иде, шуңа да сискәнеп, дертләп китте, ә малай кымшанмады да.

— Ну йоклап та карыйсың син... Кояш төшлеккә җитеп килә бит инде. Оятың бармы синең, юкмы? Әнкәй дә борчылып бетте. Бер-бер хәл булмагае дип курыкты...

— Үзе бер сүз дә әйтмәде болай...

— Әнкәй безнең шундый, күңелендәген һич кешегә сиздермәс...

— Үзең ничек соң?

— Ярый ла... Миңа ни булсын... Сиңа әйбәт булса, миңа да әйбәт, сиңа начар икән — миңа начар...

— Бүген кая барабыз, нишлибез?

— Бар, башта капкалап чык, миндә берничә уй бар, карарбыз...

Сәүбән кое янындагы чиләктә җылына башлаган суда пош-пош килеп юынды да кулларына, битләренә кунган су тамчыларын тирә-якка чәчә-чәчә йөгереп кереп китте.

Бала Сәүбән аның артыннан йөзен чытып карап калды.

Сәүбән өстәл артында уйланып утырды: «Бала чагы аны иң элек кая алып барыр? Төгәл өч җиргә барасылары бар — әткәсе янына, Сәвия янына, Кала-тауга... Кайсын сайлар? Кайсы мөһимрәк?»

Иң кыены — Сәвия янына бару. Бик күрәсе килә! Аның малае бар икәнен белә Сәүбән. Ире бардырмы — төгәл генә белми. Әнкәсе бервакыт шул хакта сүз каткач, Сәүбән аны шып туктатты:

— Җитте, әнкәй, минем өчен Сәвия юк инде,— дип кырт кисте.

Шуннан башлап Рәмзия дә дәшми. «Ярасына кагылмыйм» дидер инде...

Ә күрергә кирәк! Сәвия белән күрешергә, сөйләшергә, аңлашырга кайтты ласа ул. Сәүбән тирәнгәрәк кереп уйларга курка, ә менә Сәвия белән очрашу хакындагы карары нык.

Иң бөек кануннар — йөрәк кануннары. Әмма алар һәрчак дөрес булып чыкмый. Сәүбән дә йөрәк кушуы буенча чыгып китте Сарманайдан. Ләкин ул чакта йөрәге хаклы булгандыр дип кем әйтә ала?

Ул өйдән килеп чыкканда, бала Сәүбән һаман шул урынында утыра иде. Элеккечә җитди, кырыс. Хәтта бераз көлке дә... Сәүбән авызын учлары белән каплап көлгәндәй итте. Малай күзеннән бу гамәл дә читтә калмады:

— Нәрсә көләсең? Үзеңнән көләсең бит, абзый кеше...

— Артык җитди инде син. Бераз балаларча кылан әле, мин бит бала чакта терекөмеш кебек идем...

— Аның каравы хәзер әнә сагыз кебек сузыласың. Авылга кайткач кына бераз җан керде...

— Анысы дөрес. Син булганга ул. Синең янда миңа тынычрак, рәхәтрәк. Син минем бала чагым гына түгел, иманым да, күңел тынычлыгым да, өметем дә, киләчәгем дә...

— Йә, ярый, күп төчеләнмә. Әйдә чәчләреңне тара да киттек.

— Кая киттек?— Сәүбән җитдиләнде. Ныклап уйламаган килеш, Сәвия янына гына алып китмәсен иде...

— Кая булсын, Ак бабай янына. Аның сүзе — авыл сүзе, аның фатихасы — авыл фатихасы, кайтуыңа икенче көн, ә син һаман әле туган җирең белән аңышмыйча йөрисең.

Сәүбән өчен бу тәкъдим һич яңалык түгел. Ак бабай хакында ул үзе дә уйлап куйган иде. Акыллы малай булды бу, Сәүбәннең борынына чиертте.

— Әйдә киттек...

— Әйбәт кенә бар, качкын-угры кебек ашыкма. Син үз авылыңда йөрисең.

Адымын кызулаткан Сәүбән тигез, салмак эзгә төште. Чынлап та, кая йөгерә ул? Кемнән кача? Кемне куа?

Ак бабай аларны, әй, аны инде — Сәүбәнне — ачык йөз белән, көлеп-елмаеп каршы алды. Кәҗә сакалын сыпыра-сыпыра килеп, ипләп, җайлап күреште.

— Исәнме-саумы, олан? Сәүбән буласың бит? Әйдә, менә шунда утыр, бер дога кылып алыйк...

Утырып дога кылдылар. Ак бабай дин эшләренә дә оста икән — бер тоткарлыксыз, матур итеп укып куйды.

— Ишеттем-ишеттем... Кайтканыңны кичә үк ишеттем. Килүеңне дә көтебрәк тордым...

— Әйе, кайткан идем шул. Шактый читтә яшәлгән. Озаграк кайтмаган саен, кайту кыенлаша икән... Менә тәвәккәлләп кайттым... Соңга калганчы кайтып калыйм, куып җибәрмәсләр әле, дидем...

— Ничек соң анда — калада, диюем — хәлләр?

— Ничек дип... Һәркем үз ягына тарткалый... Ә юрган кыска... Шул.

— Гаиләң бармы?

— Бар. Хатыным бар. Малаем үсә.

— Эшеңнән ризамы?

— Шул эшкә дип укыгач, риза инде. Без самолет агрегатлары чыгарабыз.

— Эшең күк белән бәйләнгән икән... Ә җаның, күңелең ни-нәрсә белән бәйләнгән соң?

— Күңелдә барысы да бар, Ак бабай...

— Ул күк белән бәйләнгәнме, җир беләнме? Очамы? Әллә җирдә йөгерәме? Сөйрәлеп кенә йөриме?

— Күңелме? — Ак бабайның сәер сөйләшүеннән Сәүбән бераз аптырабрак калган иде.

— Әйе, күңелең, җаның, барлык хасиятләрең...

— Без барыбыз да җир кешеләре инде, Ак бабай...

— Җирдә син бәхетлеме?

— Эшемнән канәгать, гаиләм... әйбәт кенә... — Сәүбән, «гаиләм» дигәч, бераз төртелеп торды.

— Алайса, тормышың бөтен, күңелең тыныч инде синең?

— Тормышым бөтен, ә менә күңелем тыныч түгел, Ак бабай, яшермим.

— Тормыш урамы яман җилләргә һәрвакыт ачык, күңел белән дә шулай, олан. Ә син тормышыңның беренче юл чатында ук каршы җилгә бирешкәнсең. Шуңа күрә дә гомерең буе күңелеңә тынычлык таба алмый йөргәнсең... Гомерең буе шуның ачысын ашап яшәгәнсең...

— Бик кыен булды шул ул вакытта... Үпкәне, рәнҗүне баса алмадым.

Нигъмәт карт торып йөреп китте. Аннары, кискен борылып, кулындагы чыбыгы белән күккә таба күрсәтте:

— Әллә кошларга очу җиңелме? Йә, җиңелме? Әмма алар аңа карап кына җиргә төшмиләр бит! Ә син, олан, җирдә яшәп тә төшкәнсең... Бу якты дөньяда яшәү — шушы дөньяны ярату ул. Шуңа күрә зарланма. Яшисең икән, димәк ки, бу дөньяда яшәү сиңа ошый. Барысы да җайга төшәр. Зарланма, олан...

Ак бабай Сәүбәнгә каты бәрелә иде. Әмма Сәүбән аңа бер тамчы да үпкәләмәде. Хак дөресен сөйли лә ул. Тик бер әйбер генә аны борчып тора. Ул бит боларның барысын да аңлады инде, ник шулкадәр орыша соң аны Ак бабай?

Сәүбән, ярдәм сорап, өйалды басмасына кунаклаган бала чагына карады. Тегесе иңбашын селкетеп куйды да: «Мин дә берни аңламыйм», — дигән йөз чыгарды.

— Мин барысын да аңладым, Ак бабай. Үз дуамаллыгым белән күп кешеләргә борчу, аһ-зар, күңел тынычсызлыгы китергәнмен... Кайберләрен бәхетсез дә иткәнмен... Инде миңа нишләргә, йә, әйт? Кайту авыр булыр дигән идем. Кайту әллә ни авыр түгел, иң авыры кайткач икән аның... Миңа нык авыр, Ак бабай. Шактый тәртә җимергәнмен бит мин...

— Кайгы-сагыш татымаган кеше яшәү ләззәтенең чын тәмен белә алмый, олан...

Сәүбән телен тешләде. Чөнки Ак бабай дөресен сөйли иде.

— Озакка кайттыңмы соң?

— Күңелем утырганчы торам әле.

— Ә шәһәрдәге газизләрең?

— Алар мине ничек тә аңлар. Әллә аларга җиңелме? Чынлап та, алар янына тыныч күңел, саф, якты җан белән кайтасым килә.

— Мин сине аңлыйм, олан. Син дөрес уйлыйсың. Башкаларны бәхетле итү өчен үзеңнең дә бәхетле булуың кирәк шул. Тагын шуны онытма, олан: мәхәббәт белән нәфрәт бер үк нәрсә, тик... берсе аның — мәхәббәт, икенчесе — нәфрәт кенә. Әмма алар бер үк нәрсә!

Сәүбәндә бу кадәресен аңларлык зиһен егәрлеге юк иде. Ул сүзгә кушылмады, баш кагу белән чикләнде. Ак бабай образлы-кинаяле сүзен дәвам итте:

— Кеше үзенең гомерен мәңге яшәргә килгән кебек яшәргә тиеш. Үткәнеңне, бала чагыңны, яшьлегеңне онытма, алардан аерылма. Үткәнең сине саклап калачак. Унсигез ел иленә кайтмаган кеше — иң соңгы кеше, иң беткән кеше ул. Ә син әле беткәнгә охшамагансың. Нindiдер могҗиза булганын тоям, бик әйбәт фәрештәгә юлыккансың син, шуны күрәм...

— Әйе, Ак бабай, мин бала чагым белән очраштым.

— Шулаймы? — Нигъмәт карт Сәүбәнгә мәгънәле итеп, әмма бераз шикләнебрәк карап куйды.— Нинди ул — бала чагың?

— Беләсеңме, Ак бабай, ул үзе иң гадәти балалар кебек, әмма аңарда йөз яшьлек картлар акылы бар.— Сәүбән үзе сөйли, үзе өйалды баскычында утыручы бала чагын күзәтә. Тегесе исә, киеренке бер халәттә, җитди кыяфәткә кереп, тын алырга да куркып утыра.— Баштарак мин аңардан курыктым. Ышанмадым. Ул минем өчен барысын да эшләде — үз хасиятләремә төшенергә, кешелек асылыма кайтырга булышты. Иң мөһиме — ничә еллар буе каткан күңелемне эретте, җанымны иркәләде… Аннары… Аннары ул миңа элеккеге саф, самими, изге мәхәббәт хисләрен кайтарды, мине бәхеткә ымсындырды, киләчәккә өметләндерде, яшәүгә үсендерде… — Сәүбән баштарак тыныч, салмак кына тавыш белән сөйләсә дә, тора-бара эчке дулкынлануын яшереп тора алмый башлады. Бераздан дулкынлану тетрәнүгә, тетрәнү ярсынуга күчте. Озак көттермәде — Сәүбәннең элеккеге җан борчылуларыннан айнып, котылып кына килә торган күзләреннән беренче яшь бөртеге атылып чыкты…

— Мин барысын да аңладым, олан. Баштарак каты бәрелүем өчен ачуланма. Ачулансаң да үпкәм юк. Мин аларны чын күңелемнән әйттем. Син бу тормышта ниндидер илаһи вазифа башкарасың, олан. Мин бу вазифа хакында ни дә булса әйтә алмыйм, әмма аның олы эш, изге эш икәнен беләм. Ул изге бурыч сиңа төшкән икән, безнең өчен дә әйтеп бетергесез зур горурлык. Тагын шуны әйтәм: бу минутта син үзеңнең җан-пәрәң, күңел офыкларың, яшәү мәгънәң белән миңа караганда өстәрәк торасың. Чөнки син илаһи рухлар белән аралашасың, якты дөнья чиген үтеп, илаһи кырда яшисең…

Ак бабайдан кайтканда, Сәүбән бала чагы белән сөйләшмәде. Тегесе дә ләм-мим. Чынлап та, Ак бабай аларның икесен дә төбе-чиге булмаган уй чоңгылына атты, ахры. Сәүбәннең үзен бер генә сорау борчый: «Бала чагының рухи заты белән аралашканны каян белде соң ул?» Үзе үк җавап та бирергә тырышты: «Ник белмәскә, шуңа да Ак бабай бит инде ул. Ә Ак бабайлар мондый әйберләрне белергә тиеш, күрәсең…»

Сәүбән өенә кереп тормады, кайткан уңайга, ындыр артлап, инеш буйлап Кала-тауга таба китте. Күңеле тансыклаган тынычлыкны ул шунда гына таба алыр кебек иде.

Малай Сәүбән дә мыштым гына аңа иярде. Аның күңеленә дә ниндидер борчу-гамь кергән, ахры.

Сәүбән карап-күзәтеп барды: авыл шактый үзгәргән. Таш йортлар күбәйгән. Аерым хуҗалык йортлары матурайган, әмма авыл үзе бетәшкән — урамнары чүп-чар белән тулган, елга-инеш буйларына тирес өйгәннәр. Үзгәртеп кору җилләредер инде: фермадагы элекке төзек, агарып-балкып торган биналар бушап калган, аларның тәрәзәләре ватылып, ишекләре каерылып беткән. Аның каравы авылда ике мәчет манарасы калыккан. «Мәчетләр салып кую гына иманлылык билгесе булса, эшләр бер дә әйбәт түгел»,— дип уйлап алды ул. Бөтен хуҗалык җимерелеп, элекке колхоз милке таралып-тузып ятканда, яисә инеш буйлары чүп-чар өеме белән күмелгәндә, нинди иманлылык, рухи яңару, чистарыну хакында сүз алып барырга мөмкиндер…

— Ак бабайлар ни карыйдыр…— Бу сүзләрне янәшә барган бала чагы Сәүбәннең авызыннан өзеп алып әйтте.

— Әйе шул, картлар ни карый икән?

— Беләсеңме, мәктәп тә сигезьеллыкка әйләнде бит бездә.

— Да?

— Балалар аз, бөтенләй башлангычка калмагае әле… Исеңдәме, без укыганда, ягъни сез укыганда, мәктәп гөрләп тора иде, ә?!

— Хәтерлим: беренче сыйныфта укыганда, Әнисә апа, һәрберебезне бастырып, кем булырга теләвебезне сорап чыкты. Мин үрә бастым да, Космонавт булам, дидем. Бөтен бала көлде. Әнисә апа да көлде.

Шулай да:

— Космонавт булыр өчен бик күп укырга кирәк, укысаң — булдырасың,— дип җөпләп куйды.

Сыйныф укучылары арасында космонавт булырга теләүче мин генә булганмын икән. Икенче көнне әнкәйне урамда очратып: «Сәүбәнегез мактанчыграк, үзен башкалардан өстен куерга тырыша»,— дигән. Мин моңа бик рәнҗегән идем.

— Ул бит синең сәер төшләрең хакында белми иде.

— Синең дә хәтереңдәме алар?

— Төннәр буе күк, галәм, космос белән хыялланып чыга идең син. Әллә нинди яшел, зәңгәр, көмеш йолдызларга оча идең. Аларда безнең кебек үк кешеләр яши, тик күзләре яшькелт-зәңгәр, чәчләре җирән… Менә синеке кебек…

— Синеке кебек тә…

— Карале, без дә шул йолдызлардан микән әллә? Хөсни бабай да шулай ди.

— Син бит рух, илаһи зат, моны гына белергә тиештер…

— Юк, мин — синең рухың. Мин үзем дә шул галәм рухлары ихтыярында яшим. Алар белән бер очракта гына аралаша алам мин.

— Кайчан?
— Синең белән минем арада тулы гармония урнашкач.
— Шуннан?
— Шул: без икебез тәмам тәңгәлләшеп, аңлашып беткәч, күңелләребез, җаннарыбыз, уй-хисләребез тәмам сафланып, омтылышларыбыз уртак максатка юнәлгәч кенә миңа галәм ишеге ачылачак…
— Син очып китәчәксеңме?
— Юк ла, минем өчен, юк минем өчен генә түгел, синең өчен дә күк капусы ачылачак, һәм без галәм серләре сакланган илаһи дөньяга атлап керәчәкбез… Андагы тереклек цивилизацияләрен ачачакбыз, кайчандыр ватаныбыз булган йолдызларны күрәчәкбез.
— Мин дә очармынмы?
— Юк, син оча алмыйсың. Мин синең күзләрең булырмын…
— Синең, алайса, Кала-тау серенә дә катнашың бар?
— Юк, дидем бит инде. Мин — синең рухың, синең бала чагың гына.
— Аңлашылды…
Бераз тын бардылар. Һәркемнең үз кайгысы иде. Беренче булып тагын малай сүз катты:
— Нигә Сәвия хакында сорамыйсың? Ул да мәктәптә укыта бит. Аның малае да шунда укый.
— Нәрсә сорашыйм инде. Дөресен генә әйткәндә, мин аңардан куркам.
— Куркырлык та шул.
— Йә, син дә өркетмә тор!
— Чынында шулай. Мин рухи зат булып та куркам әле аңардан. Сиңа бик рәнҗегән диләр бит аны…
Сәвия хакында сүз ябышмады. Моны аңлап, икесе дә бу темадан шундук читкә тайпылдылар, юк-бар сөйләшеп кенә бара башладылар.
Шулай сөйләшә-сөйләшә исемсез инешне атлап чыктылар, үргә менеп, Кала-тауга таба киттеләр. Әмма шактый барасы бар иде әле, шуны истә тотып, ял итәргә булдылар, бердәм рәвештә, ах-ух килеп, келәм кебек чирәм өстенә тәгәрәделәр.
Сәүбән карашларын күккә текәп тын калды. Бүгенге күк ниндидер сихри күренешне хәтерләтә. Ниндидер шомлы-караңгы болытлар йөзә… Ә көн үзе аяз!.. Чынлап та, ниндидер мәгънәле күренеш бу: унсигез ел вакыт эчендә болытлар тәмам картайган, ә Кояш шул килеш калган! Гүя Сәүбәннең бар өмете болытларга сарылып киткән, ә якты хыяллары якты килеш торып калган…
Бу күкнең төбе бармы? Болытлар артында, кояш артында ни бар? Сәүбән кечкенә чагында бер кызык күнегү уйлап тапкан иде. Хәзер шуны исенә төшерде: чытырдатып күзләрен йомды, күңел түреннән җанын суырып алды, аннары күзләрен шар ачып, шул җанын тышка, күккә чыгарып җибәрде… Җан очты, очты… Бүген күргән төштәге кебек. Тик бу юлы ул күккә, галәмгә очты. Башта дөнья караңгылана барды, аннары кабат яктырды, бераздан тоташ балкыш-нурга күмелде.. Сәүбән алдында олы йолдыз-планета барлыкка килде. Ул олы, мәһабәт күз алмаларына охшаган иде…
Шунда әллә каян гына җил-гарасат килеп чыкты да Сәүбәнне бөтереп очыртып алып китте. Ул каршы торырга тырышып карады, әмма бу «йолдыз җиле» аның иркен чикләп, ихтыярын үзенә буйсындырып куйган иде инде.
…Сәүбән үз битенә кемнеңдер кагылуын тоеп, айнып китте, күзләрен чылт-чылт йомып, кабат ачты. Ә-кә-мәт! Аның йөзе каршында шар кебек күзләре белән сөзәрдәй булып, кап-кара сыер басып тора иде!
Сәүбән үзен-үзе белештермичә сикереп торды. Менә хыялый түгел диген, ә? Сыер күзләрен планета дип белеп, саташып ята ласа!
Малай чагы да көлемсерәп утыра. Сәүбәннең аңа ачуы чыкты. Тапкан көләр кеше. Үзе рух булгач та... Аңа рәхәт — йоклыйсы да юк, ашыйсы да юк, борчыласы да, куркасы да юк… Армый да, ичмасам…
Сәүбәнгә хәзер унбиш-уналты яшь түгел. Ул чакта бу араны «эһ» тә дими йөгереп үтә иде. Хәзер бит ир уртасы булып бара. Шулай да тизрәк кузгалырга кирәк. Әле кайтасы да бар…
Бу юлы алар кызурак бардылар. Инешне күздән югалтмыйча бара торгач, Кала-тау астындагы чишмәгә бик тиз килеп чыктылар. Инеш дигәннәре шул чишмәдән агып чыккан су була инде.
Ерактан ук Кала-тауның мәһабәтлегенә, олпатлыгына сокланып килде Сәүбән. Очындагы «китек» тә шул килеш. Анда ук менеп булмас. Их, күрәсе килә дә соң андагы «аэродромны»! Авылда шактый юанасы булыр, бер махсус килеп китәр әле. Ә хәзер чишмәгә, бары тик чишмәгә генә!
Мәгарә авызы ерактан ук караеп, бераз шомландырып каршы алды. Элек бер дә болай түгел иде: әнә ничек куркыныч кыяфәттә икән тауның бу ягы. Чынлап та олпат бер җанварга охшаган ул. Әлеге җанвар «җан бар»га әверелеп, үкереп-бакырып торып басар да бөтен тирә-юньне пыр туздырып ташлар кебек…

Сәүбән белә: озак күрми торганга гына шулай ул. Күз бер күнеккәч, бу шом бетәчәк, күңелгә якын бер тау булып кына калачак.

Рух чишмәсенең челтерәвек агышын Сәүбән ерактан ук ишетеп, киләкилешкә аптырап калды. Чишмә тирә-ягындагы сазлык киңәйгән, инеш, киресенчә, тарайган, янындагы таллык сирәкләнгән, аның тирәсендәге чирәмлек пычранган. Агышы шул ук, ярсып-ярсып, тулгак тоткан кебек ага. Улагы да шул, әмма шактый тузган, кителеп, яньчелеп беткән. Бу агач улакны бик борынгыга юрыйлар иде, имеш, Пугач яулары вакытында ук шушы улак булган... Патша гаскәрләреннән качып, Салават Юлай егетләре өч көн шушы чишмә буенда яткан дигән сүзләр дә йөри.

Сәүбән йөгереп килеп чишмә алдына тезләнде, улактан агып төшкән суга учларын куйды. Аннары шул учларындагы суны үзенең битенә, чәчләренә сирпеде. Ниндидер сихергә эләккән кебек, беравык телсез калып, таш сындай катып торды ул. Аның тәне буйлап ниндидер рәхәт дулкын йөгерде. Бу дулкын берочтан Сәүбәннең җанын, бәгырен дә тылсымга төреп, сафлап, иркәләп узгандай булды... Ул шушы мизгел өчен генә булса да авылга кайтырга тиеш иде. Сәүбән моны хәзер ап-ачык төшенде.

Юлда шактый сусаган иде, Сәүбән йотлыга-йотлыга су эчте. Бала Сәүбәнне дә чакырып караган иде, тегесе елмаеп кына куйды: юкка үртәмә, янәсе...

Сәүбән, чишмә читендәге камышлык буена чыгып, аяк киемнәрен салды, ялантәпи калып, малайларча сикергәләргә, кыланырга тотынды. Аның кәефе шәп иде. Шул шәплек белән ул юкәлеккә китте. Сәүбән аларны бүген төшендә күргән иде инде. Ә-әнә теге ботакта ул Сәвиясенең фәрештәсе белән басып торды. Аның үзенең дә рухы гына килгән иде шул...

Сәүбән мәгарәгә бармады. Озак кына карап-күзәтеп торды да, чирәмгә утырып, кайтырга җыена башлады. «Килермен әле, Кала-тауга махсус көн багышлыйм, Ходай кушса...» дип юатты ул үзен. Ә чынында ул мәгарә эченә керергә, хәтта аңа якын барырга да шикләнде. «Нәрсә булмас, бу тауның изге рухлары хәзер инде мине танымыйлардыр да... Үртәп йөрмим, үзем дә әлегә үртәлмим»,— диде ул.

— Син хаклы, бүген кермә. Тау әле сиңа күнекмәгән, ияләшмәгән. Оныткан. Мин моны тоеп, белеп торам.

— Әйт әле, алайса, Кала-тауның рухлары, ияләре бармы?

— Бөтен нәрсәнең дә рухы, иясе була. Кала-тауның рухы — кара рух. Хәтерлисеңме, бу чишмәне дә элек «Кара рух чишмәсе» дип йөрткәннәр. Хәзер генә, балалар курыкмасын дип, Рух чишмәсе дип калдырдылар.

— Ул Кара рух хакында Хөсни бабайның ниндидер риваяте дә бар иде.

— Бар иде. Имеш, җәй көннәрендә, эңгер вакытында, ул шәүлә шушы мәгарә авызыннан килеп чыга икән дә бөтен иңкүлекләрне, үзәнлекләрне айкап йөри икән. Юлында берәрсе очраса, сихерләп, үзе белән тау куышына ала икән...

— Бала вакытта, менә синең кебек чакта минем күргәнем булды ул рухны. Тик... мин күргәне апак иде...

— Ә-ә, анысын әйтәсеңмени? Ак шәүлә булып, томан кебек йөри торганы да бар, имеш. Анысы Кара рухның кызы була инде.

— Бервакыт Сәвия белән икәүләп үзебезнең юкә агачы төбендә гәп сатып утырабыз. Кинәт яңгыр ява башламасынмы?! Без, өскәрәк үрмәләп, куыш сыман җиргә кереп утырдык. Шул вакыт мәгарә ишегеннән ап-ак шәүлә, дөресрәге, зифа кыз гәүдәсе килеп чыкты. Ул кешеләр кебек атламый, аякларын шуыштырып барган кебек йөзеп бара иде... Без өнсез калдык. Теге ак шәүлә чишмә буена килде дә, аның улагына төбәп, куллары белән берничә кискен ишарә ясады. Гаҗәп хәл: чишмә суы ярсып агуыннан туктады, тыйнак-салмак кына йөгерергә кереште. Аннары бу рух озак кына Сарманайга таба карап торды һәм, нидер исенә төшкән кебек, ашыгып-кабаланып мәгарә эченә кереп китте.

Сәүбән бу тау эчендә ниндидер сер яшерелгәнен бик яхшы белә. Ул сер аның үзе белән дә бәйләнгән, ахры. Бервакыт аскы басу очындагы наратны яшен сукты. Бозау эзләргә чыккан Сәүбән нәкъ шул нарат төбендә басып тора иде. Яшен ташы Сәүбәнгә дә кагылып узды. Җитмәсә, өстенә авыр ботак төшеп имгәтә язды. Ул аңын югалтып, җан очырып ята иде инде. Шул вакыт ниндидер ак шәүлә аны күтәреп алды да авыл читенә илтеп куйды. Сәүбәнне бик тиз күреп алып, өенә кертеп куйдылар.

Икенче мәртәбә кышкы буранда адашты ул. Кая барырга белмичә, тәмам хәлдән тайды, тезләренә төшеп: «Бетүем шушы икән, хет берәрсе килеп чыгып, мәетемне генә тапсалар ярар иде»,— дип уйлагандай итте. Аннары якты дөнья белән саубуллаша башлады.

Менә шунда ул бер ут күреп алды. Авыл өйләренә алынган тоныкут кебек, Сәүбәнне биш-алты чакрымлап артыннан ияртеп барды ул. Авыл урамына килеп керүгә, кар астына күмелеп калгандай, кинәт юкка чыкты...

Шул хәлләрне искә төшереп, Сәүбән тагын да ныграк шомланды. Ул чын-чынлап кайту ягына кузгалды. Чишмә буендагы камышлыкны тагын бер мәртәбә бармак очлары белән сыпырып узды. «Чишмә керфеге кебек икән болар», — дип уйланды Сәүбән, һәм үзенең образлы табышына сөенеп елмайды.

Кайтыр юл һәрвакыт кыскарак була. Алар — ике Сәүбән — юлда тын гына, сөйләшмичә генә кайттылар. Авылга кергәч кенә малай сорап куйды:

— Баруын бардың, әмма җаныңа барыбер тынычлык тапмадың… Шулаймы?

— Шулай, син хаклы, — дип, моңсу гына җавап кайтарды Сәүбән.

— Борчылма, тынычланыр көннәрең алдадыр. Бер көндә генә күңелне тынычландырып, иманны яңартып булмыйдыр ул…

— Кайткач, әткәй янына барам, бәлки, шунда юанырмын, тынычланырмын…

— Барма, йөрмә, әткәй хәзер безнең өчен тарих булып кына калды. Аның үз гаиләсе…

— Барыбер барам, күрәм, сөйләшәм! Һәм сорыйм: ни өчен ташлаган ул безне? Ялгыз хатынны ике баласы белән ник урам чатында ташлап калдырган, ә?

— Ташлаган-ташлаган инде… Хәзер кайтарып алып булмый. Яңартма үткәндәге җәрәхәтләрне. Үзеңә үк авыр булачак.

— Син хаклыдыр, әмма мин бер мәртәбә әткәйне күреп калырга, аның күзенә туры карарга тиеш! «Нигә син безне ташладың?» дип сорарга тиеш!

— Юк, сорый алмассың шул инде…

— Нигә?

— Безнең әткәй моннан ике ел элек дөнья куйды…

— Ә?..

**7**

Сәүбәннең үз әткәсе белән булган тарихка кагыласы килмәгән иде. Ә кагылырга туры килә. Аның үлеме-вафаты шуны сорый. Үлем барысын да тигезли бит ул. Кала-тау буеннан кайткач, түшәккә чалкан төшеп, кич буе әткәсен уйлап ятты Сәүбән.

Рәмзия аның янында:

— Авырмагансыңдыр бит, балам?— дип бөтерелә башлаган иде, Сәүбән кырт кисте:

— Юк, әнкәй, бер җирем дә авыртмый. Арытты гына, бераз ятып алыйм әле.

Барысын да әллә каян аңлап торган Рәмзия, улын ялгыз калдырып, тышка, ишегалдына чыгарга җыенды. Шунда тагын Сәүбәннең «теле ачылды»:

— Әнкәй…

— Әү, балам.

— Әткәй үлдемени?

Рәмзия бер мәлгә телсез калды. Ул бу сорауны көтмәгән иде, ахры. Шулай да үзен бик тиз кулга алды.

— Үлде шул, балам. Ике ел элек җирләдек…

— Ничек үлде ул?

— Җиңеләебрәк киткән иде, зиһене саташып үлде. Шулай язган булгандыр инде.

— Сөйлә әле, әнкәй, барысын да сөйлә. Ничек яшәде ул, ничек үлде?..

— Сәлимәдән дә ике малае булды. Тач синең кебек ике малай. Бер ата бит, гаҗәп түгел. Зәп-зәңгәр күзле бу малайларны миңа булышырга еш җибәрә иде әткәң. Үзе килми иде. Күзгә дә күренмичә яшәде ул. Соңгы елларда ялгызы интекте, тик барыбер баш иеп, ярдәм сорап, миңа килмәде.

— Нишләп ялгызы яшәде соң ул?

— Балаларын читкә озатып бетергәч, Сәлимә җир куенына керде. Теге хәтәр авыру бар бит әле? Ярты ел дигәндә шул авыру Сәлимәне якты дөньядан алып та китте. Мин ул хатын белән фермада бергә эшләдем. Зәбир хакында бер начар сүз дә сөйләмәде ул…

— Әнкәй, әткәй нигә китте бездән? Туп кебек ике баласын, сөйгән хатынын ташлап ник китте? Сезнең матур мәхәббәтегез хакында ниләр генә сөйләмиләр иде бит?..

— Ә-ә, син аны әйтәсеңме? Сөйләрлек хәлләр булды шул…— Бераз уйчанланып торганнан соң, Рәмзия тагын дәртләнеп сөйләп китте: — Сабантуй көнне булды бу хәл. Аз гына төшереп алган Зәбир бөтен кеше алдында:

— Рәмзия, миңа кияүгә чык, — дип кулымны сорады.

Мин ялындырган булам:

— Юк, — мин әйтәм, — очраган бер кешегә кияүгә чыга алмыйм мин. Башта егетлегеңне күрсәт, аннары карарбыз, — дим.

— Шуннан, шуннан?..

— Шуннан ни, Зәбиргә җитә калды. Кала-тауга күрсәтеп: «Телисеңме, синең өчен Кала-тау кыясыннан очып төшәм», — ди бу. Халык көлә башлады. Мин дә көләм. Очып төшмәсен беләм бит инде. Шунда Зәбиргә әллә нәрсә булды. Мин моны мәңгегә онытмаячакмын. Мәйдан уртасына чыкты да, чирәмгә тезләнеп, ике кулын өскә күтәрде ул. Үзе дә күккә төбәлде. Мин аны мондый хәлдә башка бервакытта да күрмәдем. Бу минутта ул күк белән сөйләшкән кебек иде…

— Аннары нәрсә булды? Сикердеме?

— Сикерде…

— Ничек инде?

— Томырылып йөгереп барды да тауга үрмәләп менеп китте. Бөтен халык, таң калып, аны күзәтә башлады. Кала-тау кыясының биеклеген беләсең, шактый азапланды әткәң. Шулай да бик тиз менеп җитте. Кыя өстендә тагын теге сәер йоланы башкарды. Аннары текә стенаның читенә үк килеп басты. Халык шаулаша, йөгерешә башлады. Кемдер җөпләп, хуплап кычкыра, кемдер тыярга тырыша…

— Йә, әнкәй, әйт инде, сикердеме?

— Шулай басып торган килеш кулларын ике якка җәеп җибәрде дә, бер адым алга — бушлыкка атлап, убылып төшеп китте. Сабантуй мәйданы аһ итте.

— Бернәрсә дә булмадымы?

— Син беләсең инде: кыя төбен таллык яшереп тора. Нәрсә булганын башта белмәдек. Йөгерешеп килә башлаган идек, тагын бер мәртәбә аһ итеп туктап калдык. Кемнәрдер, куркып, кирегә дә йөгерә башлады. Мин дә үз күзләремә ышанмыйча торам. Таллык артыннан, берни булмагандай көлеп-елмаеп, әткәң чыгып килә. Ул туп-туры миңа төбәп килде дә тагын теге сорауны бирде: «Хәзер инде миңа кияүгә чыгасыңмы, Рәмзия?» Мин риза булып баш кактым…

— Матур тарих… Әкияткә охшаган, әмма бик тә матур тарих.

— Бөтен халык алдында булган чын хәл бу, балам. Шушы вакыйгадан соң аңа шикләнебрәк тә карый башладылар. «Сихер белә», «күк белән аралаша» дигән сүзләр дә күп йөрде.

— Кызык бу…

— Әткәң белән мин сигез ел яшәдем. Үкенмим мин бу тормышка. Тик ул бик сәер кеше иде, балам. Төннәрен Кала-тауга чыгып йөри, күк белән саташа иде. Аннары, тагын бер нәрсә хакында әйтмәкче булам. Кешеләр белән сөйләшкән кебек, күк белән сөйләшә иде ул.

— Ничек инде — күк белән?

— Әйе, берәр нәрсә булса, күккә бага иде, күккә дәшә иде әткәң.

— Ходай Тәгаләне исенә төшергәндер…

— Юк, Ходайга әйтелгән сүзләр түгел иде бу. Ниндидер йолдыз белән сөйләшә иде ул… Шул сәерлеге мине дә куркыта иде. Шуңа да мин аны үз күңелемә якын җибәрә алмадым… Эчеп кайтканда: «Син бит җир кешесе, шуңа да мине аңламыйсың»,— дип ачулана иде.

— Сине рәнҗетмәдеме соң?

— Юк-юк, шулай дип әйтеп куя да йолдызлары янына чыгып китә… Таңда гына кайтып керә иде. Керә-керешкә: «Җидегән йолдыз койрыгы белән таң яктысына борылды. Безнең Чулпан Кояшны каршы алырга калды», — дип сөйләнә иде…

— Әнкәй, Кала-тау кыясында ничек исән калган соң ул? Бу бит чып-чын әкият!

— Юк, балам. Мин сиңа чын дөресен сөйләдем. Әйтсәм әйтим инде: күренми торган канатлары бар иде әткәңнең. Ул җир өстендә дә очып йөргән кебек йөри иде. Менә ул бара-бара да җир өстеннән күтәрелеп китә, бераз очып барганнан соң, тагын гөнаһлы җиргә төшә… Җир кешесе түгел иде, ахры, ул…

— Мин аны аңлыйм, әнкәй…

— Сәлимә дә җир кешесе булмагандыр. Ул да зәңгәр күзле, бөдрә, җирән чәчле иде. Әткәң кебек үк хыялый бер хатын… Шуңа күрә дә алар бер-берсенә тартылганнардыр, дип уйлыйм.

— Әнкәй, әткәй әйбәт кеше идеме?

— Гөнаһсыз бер бәндә иде әткәң. Әмма үтә дә бәхетсез кеше иде…

— Нигә алай дисең?

— Мине нык яратты ул. Ә мин аны аңламадым. Хәзер булса аңлар идем. Ул вакытта аңламадым… Әткәң үзен аңлаган кешене эзләде. Тапты. Әмма аны ярата алмады, мәрхүм.

— Мин аны төшемдә бик еш күрә идем. Гел бертөрле күрә идем. «Үчтеки-үчтеки» уйнатканда, мине күккә чөеп җибәрә дә үрелеп тотып ала. Ә мин ул чөйгән саен өскәрәк, югарырак очам… Йөзен хәтерләмим, ә менә кулларын, беләкләрен, хәтта күзләрен дә аермачык хәтерлим…

— Бала җанлы кеше иде шул әткәң...

— Җан очырганда, әткәй янында берәрсе булганмы?

— Мин булдым.

— Си-и-ин?

— Әйе, мин. Бер дә гаҗәп түгел. Балаларымның атасы бит ул. Үләр сәгате җиткәч, үзе чакыртып алды. Ике малае белән янәшә басып озаттым мин аны ахирәт дөньясына.

— Бик нык ялгышып йөрдеме?

— Юк, алай зыянга түгел. Бер-ике мәртәбә егылып имгәнде, шул гына. Һаман «очам, очам» дип хыялланды, мәрхүм. Шулай «оча-оча», кул-аягын сындырып бетерде. Өлкәнәя башлагач, бик кәефсез йөрде. Кеше белән аралашмас, сөйләшмәс булды. Бер очрашканда серле сөйләшеп торды… «Канатларым сынды минем, Рәмзия, канатсыз калдым… Син минем пар канатым булгансың… Синсез оча алмыйм мин. Хәзер оча да алмыйм, җирдә дә йөри белмим…» — ди бу.

— Бик акыллы, һушлы кеше булган икән әткәй. Гади адәм баласы булмаган… Акыл ияләре кебек сөйләшкән бит.

— Гади кеше түгел иде шул. Бик серле тамгалар белән хыялланып яшәде. «Бисмилла»сыз кыл да кыймылдатмады, ә үзе әллә нинди мәҗүси тамгаларга табынды. Озынаеп киткән шакмакка түгәрәк-боҗра төшерелгән тамгасы бар иде. Бөтен әйберләргә: чиләк-тазга, көрәк-сәнәккә шул билгене уя иде. «Нәсел тамгасы бу, нәсел йолдызыннан ук килгән», — дип тә җибәрә. Мин көлә идем. «Нинди йолдыз ул?! Синең Йолдыз әнә абзарда мөгрәп тора», — димен. Ул вакытта безнең сыер «Йолдыз» исемле иде.

— Җан тәслим кылганда берәр сүз әйттеме?

— «Очам, — диде, — хәзер очып китәм, анда мине каршы алырга җыендылар инде», — диде. Ул бит берни белән авырмады, ятты да үлеп китте. «Зәхмәт авыруы» тигән, дип сөйләнделәр. Үлгәндә үзе бик һушлы булды. Күз карашлары да саф, чиста иде, әле дә хәтеремдә — зәңгәр күз алмалары томырылып карап торалар. Миңа алар хәтта сөйләшә кебек тоелды. «Үзебез белән алып китәр идек, сиңа ярамый, син бит Җир заты», — диләр иде алар. Мин ул чакта үземнән-үзем шикләнеп куйдым. «Саташа башладым бугай, колагыма әллә нинди серле-сихерле авазлар ишетелә башлады», — дип, җиде мәртәбә тоташтан «Фатиха» сүрәсен укыдым. Аны җиде чыгу бер «Коръән» чыгуга тиң диләр бит.

— Күзләрен дә син йомдырдыңмы?

— Олы малаена куштым. Аптырап бетте ул. Йомдыра гына, әткәсенең күзләре тагын ачыла, йомдыра — тагын ачыла… Әллә инде үләсе килми китте, әллә җаны шулай озак, ялындырып кына чыкты…

— Әнкәй, тагын бер сорау биримме?

— Бир, бир, балам. Күңелеңдә калмасын.

— Әткәй безнең хакта сорашмадымы?

— Сорашмады… Теге вакытта Хәйдәр абыең аңа ямьсез сүзләр әйтеп рәнҗеткәч, сезнең хакта сорашмас булды. Ә син киттең дә югалдың. Күреп тормагач, онытып та җибәргәндер инде… Шулай да бервакыт сине искә алды ул. Һәрвакыттагыча, әллә ничек серле сөйләште. «Безнең нәсел сере кече малаеңда кала», — диде ул. «Безнең малайда» димәде, «малаеңда» диде. Мин моңа нык үртәлдем. Шул үртәлү аркасында аның әйткән сүзләренең мәгънәсенә дә төшенеп җитмәдем. Нинди дер бик мәгънәле сүз әйтергә теләде бугай әткәң ул вакытта.

— Әнкәй, сиңа да сер түгелдер: безнең нәселдә чынлап та олы сер бар бит, әйеме?

— Әйе, балам, син дә төшенгәнсең икән…

— Нинди сер ул, әнкәй?

Шул вакыт өйалдында чиләкләр шалтыраган, көянтә, уклау, җилпуч ише нәрсәләр ауган тавышлар ишетелде. Рәмзия кискен генә торып басты. Сәүбән дә таянып торган мендәрләрен рәтли башлады. «Нинди галәмәт бу?»— дип уйларга өлгерә алмый калдылар, үз-үзе белән сөйләшә-сөйләшә, ишектән күрше Зәлифә килеп керде.

— Кеше кереп йөрмәсен дигәннәрдер инде, бөтен ишек буена чиләк тезеп чыкканнар… Өй ияләрегезне котыртып куйдыгызмы әллә, көянтә белән кыйнап кертәләр бит, хәерсезләр…

Менә ул, усал сөйләнә-сөйләнә, тупсаны атлап керде, кергән җайга ишеген дә ябып тормыйча түргә узды, аннары бу гөнаһ шомлыгын күреп, телсез, һушсыз калган ана белән балага кулларын сузып килә башлады. Йөзендәге зәһәр ачуны кояш кебек якты елмаю алыштырды:

— И-и, Сәүбәнкәем кайткан икән. Сагындырып кына йөрисең, малай… Сине күрмәгәнгә күпме инде хәзер? У-һу!.. Ул арада ике иргә барып кайттым бит инде, малай. Әле «афисиаль» генә икәү. Сине көтәм-көтәм дә тагын барып кайтам, көтеп карыйм да тагын китәм… Һи-һи-һи… Йә, ярый, мин шундыйрак инде, аптырама, сүзгә кеше кесәсенә кереп йөрмим. Нихәл соң, күрше?

— Ярыйсы гына…

— Ир кеше «ярыйсы гына» дип торырга тиеш түгел! «Шәп!» диген! Шулай түгелмени, Рәмзия апа?

— Шулайдыр инде, Зәлифә акыллым, син ирләрне күбрәк беләсең.

— Беләм шул. Кияүгә чыкканда барысы да шәп була, ярты елдан чүпрәккә әйләнеп, җебеп төшәләр. Күтләренә тибеп, кире кайтарып җибәрәм мин андыйларны!

Зәлифәнең җилләнеп-һаваланып килеп керүе Сәүбәнне куандырмады. Элеккеге күңелсезлекләрнең Зәлифәдән башлануын онытырлыкмыни! Ул култыклап инеш буена алып төшмәгән булса, Сәвияне Рәмис белән күрмәгән булса, Сәүбән мөшкел хәлдә калмас иде ... Билләһи, калмас иде! «Исән-сау»лап күрешсә дә, бу хатын аның өчен иң хәтәр, иң куркыныч бер зат булып күренде.

— Ярый, сез сөйләшә торыгыз, мин сарыкларны ябып керим,— дип, Рәмзия ашыгып чыгып китте. Зәлифәгә шул гына кирәк иде. Ул тыгыз күлмәк изүеннән шуып чыгам-чыгам дип бүртеп торган күкрәкләрен терәп диярлек, Сәүбәннең янына ук килеп басты. Сәүбән моңа әллә ни игътибар итмәде, борылып, түшәккә утырды.

— Миннән куркасыңмы әллә, Сәүбән?

— Куркам шул, кабып йотарсың дип куркам.

— Дөрес куркасың, минем кабып йота торган җирем дә бар. Һи-һи-һи…

Зәлифәнең төче көлүеннән, дорфа кыланышларыннан Сәүбәннең гайрәте чигеп, хәтта косасы килеп торды. Тегесе тагын да ныграк узынды.

— Хәтерлисеңме, инештә яп-ялангач килеш икәү су кергән идек?..

— Бала гына идек бит әле анда…

— Бала-бала, ә истә кала! Син минем бөтен җиремне әйләндергәләп-әйләндергәләп караган идең. Кытык килеп, үлә язган идем, малай, ул чакта… Һи-һи-һи…

— Безгә бит ул чакта дүрт кенә яшь иде, ә син хәзер килеп шул беркатлы вакытларны авыз тутырып сөйләп торган буласың…

— Бер дә бала булмаганбыз. Минем кызыл чәчәгем сиңа бик ошаган иде… Синдәге «камыр бармакны» да шактый тарткаладым мин ул көнне. Һи-һи-һи…

— Йә, җитте сиңа! Без хәзер бала түгел, әйдә башка нәрсә турында сөйләшәбез.

— Ә-ә, анысы турындамы? Ул вакытта анысы юк иде шул әле. Ә хәзер бар, мулдан, зурдан… Китер әле кулыңны… — Зәлифә Сәүбәннең кул беләзегеннән тотып алды да аны тын-сулыш ритмы белән дулкынланып, күтәрелеп-төшеп торган ярым шәрә күкрәге өстенә куйды.— Менә ул…

Сәүбән башта аңышмады. Җылы, йомшак тәндә изрәп эри башлаган бармакларын кузгатырлык та егәрлек тапмады ул. Шул хәлсез, егәрсез кулы Зәлифәнең күлмәк изүен аерып эчке якка төшә башлагач кына айнып китте.

— Менә ул… Йомшак, җылы, мәхәббәтле урын… — дип сөйләнде Зәлифә. Үзе, күзләрен йомып, башын артка ташлап, хискә бирелеп, тәэсирләнеп тора бирде.

Сәүбән кулын кискен тартып алды да өстәлнең икенче ягына чыгып басты, үзе тотлыга-тотлыга сөйләнде:

— Син нишлисең, Зәлифә? Без бит күршеләр. Күршең белән алай шаярма! Күрше хакы гына түгел, Тәңре хакы да бар, оятсызланма, бар, чыгып кит моннан!..

— Кара, кара!.. Чиртмәс борын чыр-чыр киләсең, нәрсә, син ир түгелме әллә? Хатын-кыз имиеннән шүрләп төштең… Син хатын-кызны егып салып, өстенә атланып утырып көчлә, вәт булырсың чын ир! Чәпчемә, киттем, синнән рәт чыкмасын яшьтән үк белә идем, хәзер дә шул җебек икәнсең. Яшә шулай хатын-кыз бот арасындагы чүпрәк булып!.. Бик кирәгең барые!

Зәлифә җилләнеп чыгып китте, Сәүбән, авыр сулап, гөрселдәп түшәккә ауды. Бу җенле хатыннан котылуына ул ышанып бетә алмый иде әле…

Зәлифә хакында нәрсә уйларга да белмәде Сәүбән. Кемдер язган бит: «Үзең белән аралашкан кешедә бер генә уңай сыйфат та тапмасаң, син аның бала чагы турында уйла. Ул сиңа элеккечә ямьсез күренмәс», — дигән. Сәүбән Зәлифәнең бала чагын белә. Мөлаем, күңелчән кыз иде ул вакытта. Шуңа да аның начар уйлыйсы килми бу хатын хакында. Дөресрәге, бөтенләй дә уйлыйсы килми…

Ичмасам, әнкәсе дә юк бит янында… Ул булса, әйтер иде: «И балам,— дияр иде,— исәрнең таягы кырык, берсе тимәсә берсе тия. Үртәлмә дә, үпкәләмә дә син аңа, исәр бит ул. Андый хатыннар ир белән дә, ирсез дә тора алмыйлар. Ләкин алар да без яшәгән Кояш астында яшиләр. Шуны онытма, улым…» — дияр иде.

— Әйтәсен әйттеме сөекле күршең?

Сәүбән үз янәшәсендә пәйда булган бала чагына сөенеп бетә алмады. Шундук сикереп торды. Ул инде күптән төшенгән иде: ялгыз калуы гына була, нindидер афәткә очрый да тора…

— Син кайда йөрисең? Яндарак бул әле. Син юкта башым бәладән чыкмый.

— Мин бит сине әнкәй белән калдырдым. Әткәй хакында сөйләшергә тиеш идегез сез. Каян килеп кергәндер бу тәмугъ кисәве?..

— Теге вакытта да яшь бәгыремә тозны шул кәнтәй хатын учлап сипкән иде…

— Сөйләштегезме соң?

— Зәлифә беләнме?

— Юк ла, әнкәй белән.
— Эх, энекәш... Әйбәт кеше булган безнең әткәй... Ә мин белмәгәнмен... Күрешеп, сөйләшеп каласы иде дә...
— Бу дөньяда гел шулай була: әйбәт кешеләр белән сөйләшергә, аңлашырга соңга калабыз...
— Рухи зат килеш зарланып торган буласың...
— Рухи булсам да, мин синең чагылышың гына бит... Синең күңелең әрнесә, минеке дә әрни, жаның көйсә — минеке дә көя... Әткәй-әнкәйләр дә бер безнең, аларның язмышы турыдан-туры безнең язмышка килеп кагыла...
— Туктале, энекәш, син бит мин уйлаганны уйлыйсың...
— Әйттем бит инде, без бер үк заттан; син шул затның физик һәм физиологик чагылышы, ә мин аның рухи сурәте. Уйлар безнең бер үк...
— Димәк, син минем язмышта әткәй язмышының кабатланып килүен беләсең?
— Беләм...
— Моның бик аянычлы булуын да беләсеңме?
— Анысын да беләм...
— Ник миңа бу хакта башта ук әйтмәдең? Ник?
— Мин аны әйтергә тиеш тә түгел. Син яшәү мәгънәсенә үзең төшенергә хокуклы, ә мин моңа шартлар тудырырга, рухыңа ныклык, омтылышларыңа максат бирергә тиеш. Аңладыңмы?
Сәүбән дәшмәде. Ул барысын да аңлады, әлбәттә. Әмма бу аңлаудан гына аның хәле жиңеләя торганнардан түгел.
Ул, түшәктә яткан килеш, эчтән көеп, үрсәләнеп әйтеп куйды:
— Әткәйнең язмышы да иясен таба алмаган, минеке дә иясез, мәгънәсез булып чыкты. Ниндидер бер кысага, максатка сыеша алмыйча, бәргәләнеп-сугылып йөрде бугай ул...
— Ни сөйлисең син? Нинди иясез язмышлар хакында сөйлисең?
— Беләсеңме, иптәш бала Сәүбән, бу гөнаһлы жир өстендә кешеләр яши, дөресрәге, жаннар яши. Аларның һәрберсенең иясе, хуҗасы бар. Кемнеке — Ходай, Аллаһы Тәгалә, кемнеке — Тәңре-хан, ягъни мәсәлән, Күк-Тәңре, өченче жанныкы, язмышныкы — Табигать Галижанәп, дүртенченеке — Кояш... Жирдә — язмышлар хәрәкәте. Андагы жаннар «Яшәү боҗрасы» буйлап әйләнәләр дә әйләнәләр... Ә беләсеңме, бу хәрәкәткә, бу «Яшәү боҗрасы»на эләкмәгән, рас килмәгән, ярашмаган жаннар, язмышлар бар әле. Иясез язмышлар. Минем язмыш — әнә шундый язмыш. Әткәйнеке дә шундый булган...
— Мин аңлыйм сине... Рух булып та, Бала чагың булып та аңлыйм... Тик син бу кадәр бетеренмә. Моңа баш бетәрлек сәбәп юк. Синең моңа хакың да юк.
— Ничек булмасын? Мин — бәхетсез бер жан!.. Бу азмыни?! Хакыма, хокукыма килгәндә... Кешенең нәрсәгә хаклы булуын аның язмыш иясе билгели. Ә минем андый иям юк...
— Төссез тормышыңны, йомшак рухыңны, ихтыярсыз теләк-ниятләреңне аклар өчен жайлы сәбәп уйлап тапкансың син! Бик уңай шул: иясе юк, имеш... Тап син аны! Эзлә! Үзең эзлә! Күктән, йолдызлардан көтеп утырма! Син бит көчле идең, акыллы, белемле, зиһенле идең!.. Сиңа бөтен нәрсә жиңел бирелә иде! Жирең-суың, табигатең, йолдызларың сиңа булышып, көч, егәрлек, зиһен һәм рухи ныклык биреп тора иде. Жирдә хакыйкый тормышны жайга салу өчен илаһият сине сайлаган иде. Кая ул сиңа исраф ителгән бетмәс-төкәнмәс рухи егәрлек, илаһилык?.. Шушы вак дөньяда түгеп-чәчеп бетердеңме? Пәйгамбәр булыр урынына түшәктә жан сыгып, күңел сөрсетеп ятучы бер бәндәгә әверелдеңме?
— Син дә тиргәмә инде мине, Сәүбән... Бала чагым минем...
— Бер дә тиргәмәм дигән идем, чыгырдан чыгуымны сизми дә калганмын. Кичер, яме...
— Миңа авыр, моңсу, күңелсез... Мин моны рухи зәгыйфьлектән әйтмим, аек акылым, тере рухым булганга әйтәм. Үзең уйлап кара: әткәй үз гаиләсендә бәхетсез булган. Үзе яраткан кеше белән аңлаша алмаган, аңлашканын яратмаган... Мин дә үземчә яратам хатынымны... Әмма ул мине аңламый... Аңламый! Ишетәсеңме?! Йөрәгем авылдагы Сәвиягә — моннан унсигез ел элек зәңгәр күзләрен тутырып карап калган гүзәл сылуга тартыла, аңа ымсына... Ул гына мине аңлаячак, кабул итәчәк, кичерәчәк... Тик мин хәзер үк, шушы минутта ук әйтә алам: аның белән мин бервакытта да бәхетле була алмаячакмын...
— Ни өчен, беләсеңме?
— Юк, белмим! Ул кадәрен беләсем дә килми...
— Чөнки син мәхәббәтеңә хыянәт иттең. Мәхәббәт — шул ук иман. Мәхәббәттә дә, иманда да хыянәт кичерелми...
— Каты әйттең син...
— Тагы да ныграк әйтимме?
— Йә?

— Ярату гына әле бәхетле булу дигән сүз түгел. Ярату өчен матур йөрәк булу да җитсә, бәхетле булу өчен батыр йөрәк кирәк. Ә синең йөрәгең, матур булса да, куркак иде. Сиңа батыррак булырга кирәк.

— Беләм дә соң… Их, белсәң иде син!.. Миңа шундый кыен хәзер… Минем хәзер нишләргә белми торган чак бит… Әткәй исән булса, иң беренче аңа барыр идем… Юк шул, ичмасам, ул да ташлап киткән…

Сәүбән, үрсәләнеп, йөзен учлары белән каплап, пөхтә итеп җыештырып куелган түшәк өстенә ауды.

**8**

Бүген Сәүбән әйбәт йоклады. Әмма төш күрүдән барыбер котыла алмады. Ниндидер матур, төсле төш иде ул. Бүлмә… Сыйныф булмәсе… Әнисә апалары дәрес алып бара. Бер партада икәү утыра — бала Сәүбән һәм... тагын бер Сәүбән! Өлкәнәя башлаган, ир уртасына җитеп килүче олпат кеше! Укытучы шигырь язарга кушкан. Ике Сәүбән бер-берсеннән күчерә-күчерә шигырь язалар. Аннары үрә катып җавап бирәләр, язган шигырьләрен укыйлар...

Беренче булып малай Сәүбән баса.

Баса да, чатнатып, дөнья яңгыратып сөйли башлый:

Көн дә төштә очып йөрим,
Кош кебек очам, имеш!
Белмим, ничек очамдыр мин
Канатсыз-нисез килеш…

Иртән торуга ук тоям:
Сызлый бөтен иңнәрем.
Очам инде, очам, чөнки
Каз йонынннан мендәрем!

Малай укып бетерә дә тәртипле генә, мыштым мәче кебек, урынына утыра. Хәзер өлкән Сәүбәнгә чират.

Аның тавышы инде карлыкканрак, әмма яңгырашы белән бала Сәүбән тавышына бик тә охшаш:

Гомеремне бер кош кебек яшим,
Кошлар кебек, күккә ярсынам.
Күзләремдә йолдыз балкышлары,
Иңнәремдә канат бар сыман…

Атлап түгел, очып йөрим, ахры,
Төннәр буе сызлый иңнәрем.
Мин чыннан да коштыр, юри генә
Кеше булып йөргән көннәрем…

Сәүбән, чыннан да, иңнәре, кулбашлары сызлап уянды. Әллә кичә күп йөрелгән, әллә төштәге «очып йөрүләр» галәмәте бу…

Күзләре йомык килеш, Ходай Тәгалә бүләк иткән алдагы якты көн хакында уйланып ятты Сәүбән. Кичә кич балачак рухы белән булган сөйләшү исенә төште. Үзеннән-үзе оялып куйды. Күңелен шомлы уй тырнап үтте: «Инде бөтенләй дә кул селтәде микән? Килмәс микән?» Шул вакыт күз кабакларын ялт итеп ачып җибәрде, башын калкытып, өй эчен тикшереп чыкты. Бала Сәүбән бүлмәдә юк иде.

Сәүбәнгә күңелсез булып китте, аның җаны тынгысызланды, йөрәге еш-еш тибә башлады. Инде нишләр ул? Бу тормышта бердәнбер таянычы, рухи кыйбласы, хәтта иманы, дине шул малай иде бит… Ничек ияләшкән иде ул аңа. Хәтта ярата, сөя башлаган иде… Иң аянычлысы: аның язмышында әле бер генә авыр йомгак та сүтелмәгән, бер генә авыр мәсьәлә дә хәл ителмәгән… Иң авырына — Сәвия белән бәйлесенә әле кагылмаган да ул…

Сәүбән йөрәге сызылып капланып ятты да мендәрен кыйный башлады.

— Саташасыңмы әллә, балам?

Сәүбән бәргәләнүеннән туктады, әмма битен мендәр йөзеннән кубарып алмады.

Рәмзия малаен йоклый дип уйлады булса кирәк, аяк очларына гына басып килде дә йомшак кына итеп Сәүбәннең иңбашына кагылды.

— Балам, тор инде, тор. Анда синең янга бер малай килгән. Көттермә, бар, чык…

Сәүбән сискәнеп китте. Кискен башын калкытты, шундый ук кискенлек, өлгерлек белән ал ягына әйләнеп торып утырды.

— Нинди малай ул, әнкәй? Ни сөйлисең син?

Табын карап йөргән Рәмзия бераз көлемсерәп сүз башлады:

— Бер малай шунда, чыккач үзең күрерсең… Күземә күренә дип торам, тач синең бала чагың инде. Кай арада үсеп җиткән диген син аны?!

— Әнкәй, мин саташаммы, әллә син саташасыңмы, бернинди таныш малаем да юк минем монда. Мин бит унсигез ел кайтмаган кеше, көләсеңме әллә, әнкәй бәгъръем?..

— Юк, юк, көлмим… Шаяртып кына сөйләшәм. Чынлап та, бик матур бер малай сораша сине. Ачы таң белән нинди йомышы төшкәндер… Урам эскәмиясендә утыра… Әнә, ышанмасаң, тәрәзәдән карап ал.

«Әллә теге рухым кеше күзенә күренеп йөри башлаганмы?» — дип уйлады Сәүбән. Йөрәге жу итеп китте. Әгәр шулай икән, ничектер чыгарга кирәк бу кыен хәлдән…

Сәүбән тәрәзәгә бармады. Чөйдән җәйге күлмәген үрелеп алды да, изүен төймәли-төймәли, тышка чыгып китте. Нидер сизенгән кебек, Рәмзия башта өстәлдәге ризыклар өстенә чигүле япмасын каплады, аннары утырды…

Баштарак урамга килеп чыккан Сәүбән, күзләре яңа кояш нурларына чагылып, берни дә күрмәде. Күз алдындагы зәңгәр боҗралар юылып, урамны, койма буен шәйләрлек булгач кына капка читендәге утыргычка таба борылды. Аның каршында әлеге дә баягы балачак рухы басып тора иде. Тукта! Рухмы соң ул! Әнкәсе күргән бит…

— С-с-син… Син кем?

Малай, үз алдында басып торган Сәүбәнгә сынаулы караш ташлап, әмма шактый ышанычлы аһәң белән:

— Сәүбән, — дип җавап кайтарды.

— Син… Син минем балачак рухыммы? — Сәүбән шундук мөгезеннән элэктермәкче булды.

— Нинди рух? Мин шушы авыл малае Сәүбән.

— Сәүбән? Нигә Сәүбән?

— Әнием шулай кушкан.

— Синең әниең кем соң?

— Сәвия.

— Сәвия? Итекчеләр урамында яшәүче Сәвияме?

— Әйе.

— Алайса, әйдә утыр, сөйләшик. Әйдә, күрешик башта. Мә бишне.

Кул сугыштылар. Сәүбән моны юри эшләде. Кул сугышу вакытында тәмам аңлап җитте: бу малай — аның рухы түгел. Әллә ул кеше рәвешенә кереп йөри аламы? Әнә бит бөтен киемнәре, йөзебите, чәчләре, иң мөһиме — күзләре, карашлары охшаш… Әле кичә кич кенә сөйләшкән бала чагының коеп куйган нөсхәсе! Шулай да сак булырга кирәк. Ниндидер хикмәтле сер бар монда.

— Әткәң кем соң синең?

— Сәүбән…

— Ничек инде? Әткәң дә Сәүбән исемлеме?

— Әйе.

— Менә сиңа пәрәмәч! Бөтен дөнья тулы Сәүбән икән монда!..

— Юк ла, бездә генә ул исем. Синең белән миндә генә…

— Ә… Ә әткәң?

— Син минем әткәм буласың инде. Шуңа да күрергә килдем…

— Туктале, тукта... Син бит Сәвия малае!

— Әйе.

— Әткәң бармы синең?

— Бар.

— Шулай булгач?..

— Шулай булгач, ни… Син минем әткәм буласың инде. Менә кара: бөтен җиребез белән охшаш без.— Малай түш кесәсеннән ике фотосурәт чыгарып Сәүбәнгә сузды.

«Нишләргә? Алыргамы-юкмы? Берәр сихер булмасын тагын… Алай дисәң, рух та, дух та, шайтан да түгел бугай бу… Тәүбә-тәүбә… Күзләре дә чын кешенеке: әнә ничек зәңгәрләнеп янып торалар…»

Сәүбән, эченнән генә «бисмиллалап», малай сузган сурәтне кулына алды. Алуын алды, әмма егылыплар китә язды. Йөрәге жу итеп, җаны күңел төбенең иң ерак чоңгылларына кереп посты. Посты да, шул ерак чоңгылларның берсеннән бик кадерле бер хатирәне табып, кабат өскә — гүзәл дә, гөнаһлы да дөньяга калыкты. Сәүбән кулындагы сурәтнең берсе беренче сөешү, беренче үбешү, беренче вәгъдәләр билгесе итеп кайчандыр Сәвиягә бүләк ителгән фото иде. Әле дә хәтерендә: сигезенчене тәмамлагач, укуның соңгы көнендә бөтен сыйныф белән кичке уеннар була торган инеш буена төштеләр. Кызлар төрле кызык уеннарга маһир булалар, аларның кайсыдыр: «Һәрберегез бер фото алыгыз, уен вакытында кирәк булачак»,— дигән иде. Сәүбән дә, альбомын актарып, үзе-

нең сурәтен алды. Уеннар, биюләр, шаярулар башланды. Күңел ачуның иң кызган җирендә сыйныфташларына фотосурәтләр алып килергә кушкан кыз, уртага чыгып, әлегә кадәр беркем дә белмәгән уен игълан итте: «Иң элек бөтен фотоларны бергә җыябыз, аннары, аларны шушы өянкегә менеп, аска чәчеп җибәрәбез, соңыннан карыйбыз: кайсы кызның фотосы кайсы егетнекенә якынрак ята — шулар парлашып бииләр… Ахырдан бу парлар фотоларын алмашып, озатышалар… Аңлашылдымы?»

Шулай эшләделәр дә. Сәүбәннең күзе Сәвиягә күптән төшеп йөри иде. Ул, бөтен күңеле белән, үз сурәтенең Сәвия сурәтенә якын төшүен теләп торды. Күктәге Чулпан йолдызга карап: «Мин теләгәнчә булсын, үтенеп сорыйм!» — диде. Яраткан кешегә фәрештәсе булыша, диләрме, әллә күктәге Чулпанның ярдәме тидеме — Сәүбәннең фотосы Сәвия фотосы белән янәшә ята иде…

Моннан соң бөтен биюне дә бергә биеделәр. Кайтканда фотоларын алмаштылар, Сәүбән беренче мәртәбә кызлар иреннәннән шунда үпте. Сәвиянең оялчан иреннәре, калтыранып торган тәне, рәхәт гаҗәпләнүдән шар ачылган күзләре аның күңелендә якты хатирә булып саклана икән ләбаса…

Сәүбән, онытылып, кинәт калыккан истәлекләрдән исерә башлавын аңлады. Шулай да үзен кулга ала алды. Иң гаҗәбе шул: ике фотосурәттән дә бер малай карап тора! Тик берсе аның элеккеге сурәт — каралы-аклы, бераз саргая, тоныклана башлаган, икенчесе исә заманча — төсле, матур, нурларын уйнатып-балкытып тора… Ләкин икесендә дә бер үк малай — бала чактагы Сәүбән!

— Каян алдың минем бу сурәтләрне?

— Берсе генә синеке аның.

— Ә берсе кемнеке?

— Минеке…

Сәүбәннең тәмам башы катты. Сәвия малае булсын да ди. Сәвия белән яратышсыннар да ди. Ләкин аларның бер мәртәбә дә сөешкәннәре, кавышканнары булмады бит! Алайса, каян килгән бу малай? «Туган бала яраткан кешегә охшый» дигән сүз дөресме әллә? Әллә?.. Әллә Сәвия шул рәвешле аны үзенеке итмәкчеме?

— Юк, Сәүбән энекәем, минем беркемем дә юк монда. Малаем да, кызым да… Фотолар охшаган дип кенә… Әнкәң җибәрдеме әллә? Бар, кайтып әйт үзенә, нәрсә генә кыланса да, чит кеше баласын үземнеке димәячәкмен… Охшау бер нәрсә, кан икенче нәрсә…

— Ә җан — өченче нәрсә, әткәй…

— Нәрсә? Нәрсә беләсең соң син җан хакында?

— Мин барысын да беләм, әткәй. Мин бит синең малаең. Ә без — акыллы, затлы нәсел. Без кеше белмәгәнне беләбез, кеше тоймаганны тоябыз, шулаймы, әткәй?..

— Юк дигәч, юк, минем монда малаем юк!

— Ярый, мин сине аңлыйм, әткәй. Әнкәй алдасын да ди. Сине, мине белгән бөтен кеше берьюлы алдасын!.. Ә менә күк алдамый, әткәй. Күк бит ул! Йолдызлар бит ул! Йолдызлар — җан рәвешләре… Җан алдамый. Мин — синең улың. Бу хакта миңа Кала-тау түбәсендәге якты йолдыз әйтте…

— Чулпанмы?

— Әйе..

Сәүбән күңелендәге хәтер җебенең бер очы һаман әле икенчесенә ялгана алмый интекте. Зиһене тәмам чуалган, күңеле тәмам борчылган иде аның.

Ул, тиргәнеп, пыр тузынып, өйгә кереп китүдән башка чара тапмады:

— Юк, барыбер ышанмыйм мин моңа! Сине ниндидер сихер иясе җибәргән. Сиңа ничә яшь хәзер — унмы, уникеме? Ә минем Сәвияне күрмәгәнемә хәзер унсигез ел! Ун-си-гез! Ишетәсеңме? Башны тинтерәтмә, бар, кит моннан! Күземнән югал!..

Өйгә кергәндә үк үзенең кирәкмәгән, ярамаган бер эш эшләгәнен аңлады ул. Әмма күңеленә кереп утырган Иблис сыңары да җиңел генә бирешергә теләмәде. Бу Иблис аңа бертуктаусыз: «Ул синең малаең түгел, каян килеп синеке булсын, аңа бары унике яшь кенә, күп булса унөчтер… Ә синең инде унсигез ел кайтканың юк…» — дип такылдап тора иде.

Сәүбән өйгә кергәндә, Рәмзия ялгызы гына чәй табыны артында утыра иде. Сөйләшмичә генә чәй эчтеләр. Тынлык икесе өчен дә авыр иде, — бу аларның сулыш алуларыннан, күз карашларыннан сизелеп тора. Әмма берсе дә беренче булып сүз башларга кыймый. Сәүбән инде белә: әнкәсе капка төбенә кем килгәнен белгән. «Ниндидер малай сорый», — дип юри генә әйткән. Рәмзия Сәүбәннең бу хакта белүен, әмма сер бирмичә утыруын да белгән. Менә шуңа күрә дә ана белән бала бер-берсенә бераз үпкәләбрәк чәй чөмерәләр…

Бу җан өшеткеч киеренкелеккә әнкәсе түзмәде, дәррәү кузгалып, мич артындагы җим савытын барып алды да: «Чеп-чеп-чеп…» — дип сөйләнә-сөйләнә, ишегалдына чыгып китте.

«Нәрсә бу — заговормы? — дип уйланды Сәүбән.— Нинди малай ул? Кем малае? Нигә ул Сәүбәнгә тагыла? Менә сиңа проблема! Сәүбән малае түгел дә түгел — монысы факт. Тик… Шулкадәр дә

охшар икән аның бала чагына? Тукта! Сәүбәннең малай чагы кайда соң әле? Әллә шул клоунның галәмәтләреме бу?

— Кем клоун?

Сискәнүеннән сикереп үк куйды Сәүбән. Әһә! Менә бит ул. Аякларын бөкләп диван өстендә утыра. Хәзер Сәүбән әйтмәгәнен әйттерәчәк аның…

— Әйттерми генә тор әле! Бу малайга минем бер катнашым да юк. Мин аның нинди малай икәнен дә белмим…

— Шулаймы? Белмисеңме?

— Ышанмыйсыңмы әллә?

— Ышанмыйм. Син бит рух. Барысын да белергә тиеш.

— Мин бит илаһи рух түгел. Син уйлау белән күз алдыңа килә торган рухи образ гына. Боларның икесен бутама, яме…

— Йә инде, үпкәләмә. Аптыраганнан гына сорыйм…

— Мин бер нәрсәне төгәл әйтә алам сиңа: капка төбендәге малай — синең малай.

— Ә?.. Син дә шул якка таба борасыңмы атны?..

— Борасы-нитәсе юк, әле генә син күргән малай — үз малаең.

— Йә, әкият сатма!

— Бөтен рухиятем белән тоям мин моны. Тагын шуны тоям: нык үпкәләттең син аны, хәтта рәнҗеттең…

— Охшаган ул миңа, сүзем юк. Ә арифметиканы кая куясың? Аннары… Аннары Сәвия миннән бала таба алмый.

— Ник?

— Чөнки минем аның белән бер мәртәбә дә йоклаганым юк, аңлыйсыңмы син шуны, юкмы?!

Бала Сәүбән тын калды. Рухи затларга аңлашылмый торган әйберләр дә булыр икән бу фани дөньяда!

Ике Сәүбән арасындагы бәхәснең бетәсе юк иде, әле ярый ишектән Рәмзия килеп керде. Мәсьәләгә ул бераз ачыклык кертте:

— И-и, балам, әйтмәм дигән идем, болай булгач, бөтенесен түкми-чәчми сөйләп бирәм. Сәвия сүз алган иде, биргән сүземне аяк астына салырга туры килә. Сөйләмәс идем, авыл өстеннән ниндидер афәт җиле исә башлаганын тоям…

Үз йөрәген тыңлый белмәгән кеше башкаларны да ишетми. Әнисенә, урамдагы сәер малайга, бөтен дөньяга үртәлеп йөрүче Сәүбән шундыйрак халәттә иде.

— Әнкәй, нәрсә булды сиңа? Ни сөйлисең син?

— И улым, былтыр көз Сәвия кереп утырган иде. Мин дә аңа: «Ни сөйлисең син?» — дигән идем. Ә ул миңа әллә нәрсәләр сөйләп бетерде…

— Нәрсәләр, әнкәй?

— Имеш, аның синнән баласы бар. Менә шул малае каяндыр сизгән моны. Аңа кеше әйткән, ахры, син — коеп куйган Сәүбән — Рәмзия малае, ягъни мәсәлән, син, дигән. Әнкәң уйнаш итеп тапкан, шәһәрдә очрашып йөриләр икән, фәлән-фәсмәтән… Сәвиянең малае шуңа ышанган. Әнкәсеннән сине таптыра башлаган. Сәвия аптырап йөргән-йөргән дә миңа килгән. Бөтен тарих шул.

— Миннән баласы бар дип әйттеме, ялгышмыйсыңмы, әнкәй?

— Әйе, кабатлап та сорадым әле. Кеше ышанмаслык нәрсә бит бу. «Аның баласы» дип, үз туксанын туксанлап тик тора… Менә шундый әкәмәт хәлләр булган иде.

— Әнкәй, ышансаң — ышан, ышанмасаң — юк, Сәвиядә минем балам юк! Теләсә нәрсә белән ант итәм! — Сәүбән чарасызлыктанмы, әллә билгесез бер шик-шөбһәдәнме, шул шик белән бәйле каушауданмы, кычкыра ук башлаган иде. Аның бу ярсынуы Рәмзиягә дә күчкән кебек булды.

Ул да:

— Нишлим соң, балам, нишлим? Синең хакта сүз ишетеп яшәү әллә миңа рәхәт булдымы? — дип өзгәләнде.

— Нинди сүз ул, әнкәй?

— Сине һаман Сәвия белән йөри диләр бит… Тегесен дә әйтер идем инде! Малаена да Сәүбән дип кушкан, ичмасам…

— Шулай диде шул…

— Мин ул малайны күрүгә ук: «Юньлегә килмәгән бу», — дип уйлаган идем аны… Шулай булып чыкты да!

Сәүбән уйчанланды. Тормышта көтелгәнгә караганда көтелмәгән күбрәк. Капка төбендәге малай да шул көтелмәгәннәр рәтенә керә иде. Рәмзия дә сөйләшмәс булды.

Һаман әле диванда аяк бөкләп утыручы бала Сәүбән рухы гына үз сәгате сукканын сизеп әйтеп куйды:

— Да-а-а… Ниндидер сер бар монда. Могҗиза бар. Һәм… Фаҗига бар. Мин аны сизәм, тоям, күрәм… Ул Кала-тау белән бәйләнгән. Дөньялыкта усал җилләр уйный, һавада кара болытлар йөзә, йолдызлар тоныклана, кошлар кыяга бәрелеп үлә, сулар агулана, язмышлар иясез кала, кешеләр адаша… Кешеләр генә түгел, рухлар юлдан яза… Яза, яза, яза… Яза-а-а…

Сәүбәннең күз алдында аның балачак образы, күк томанга әверелеп барып, салмак кына дулкынлана, җәелә һәм, ниһаять, таркалып, чәчелеп бетә…

Рәмзия боларның берсен дә күрми. Аның күрмәве, белмәве әйбәтрәк тә. Үз башына төшкән күңелсез, ямьсез сынауларга улының хыялый рухы да килеп кушылса, җылы куенында ярсып тибеп ятучы авыру йөрәге урталай ярылыр иде, мөгаен…

Сәүбәннең җан халәте, җан рухы да шәптән түгел. Бу көтелмәгән хәлләрдән ул тәмам сыгылып төште. Башта тавышын күтәреп, ачыргаланып, үрсәләнеп ярсыса да, соңыннан, берни дә кыла алмасын аңлап, тынды, дәшмәс булды. Аны хәтта балачак рухының чәчелеп юкка чыгуы да артык гаҗәпләндермәде. Ә теге рух исә бу вакытта, өскә — күк югарылыгына күтәрелеп, киң офыкны иңли. Менә ул авылдан Кала-тауга таба китеп баручы бер малайны күреп кала һәм шул якка таба томырылып очып китә…

**9**

Укучы үпкәләмәсен, Сәвия хакында сөйләүне һаман кичектереп килдем. Аның хакында сөйләү бик тә, бик тә авыр миңа. Сәвия — мин белгән йөзләрчә, меңнәрчә хатын-кызларның иң бәхетсезе. Аның аянычлы язмышы минем күңелне туктаусыз тырнап торса да, моңа кадәр ни дә булса язарга батырчылык итмәдем.

Хәзер инде үзәк героем Сәүбәннең язмышы үзенең шундый борылмаларына җитте, алга таба каләм тибрәткәндә Сәвияне берничек тә урап узып булмаячак.

Бу хатын да төп чыгышы белән Сарманай авылыннан. Авылдагы күпчелек кеше кебек ул да яшькелт-зәңгәр күзле, җирән чәчле. Шундый ук хыялый һәм серле бер зат. Яшьлегендә Сәүбән белән яратышып китүе дә шул серлелегеннән, хыялыйлыгыннан булгандыр. Чөнки алар, кичләрен клубтан яисә инеш буендагы уеннан кайтканда, бер-берсенә күк белән, йолдызлар белән сөйләшә-сөйләшә тартылдылар, бер-берсен йөрәкләренә, бәгырьләренә якын җибәрделәр.

Ходай Тәгалә кешеләрне дөньяга бер-берләре өчен яраткан. Әмма бу хакта кисәтергә оныткан. Сәвия белән Сәүбән дә үз гомерләрен бу хакта белмичә яшәделәр, ахры.

Әлбәттә, теге вакытта, яр буенда Рәсим белән янәшә утырган мәлдә, Сәвия бер гөнаһсыз фәрештә-кыз иде, менә хәзер дә, аның тормышында төрледән-төрле, ачылы-төчеле сәер хәлләр әллә ничә кеше гомеренә җитәрлек булса да, ул элеккеге сафлыгын югалтмыйча гомер кичә белде, һәр уңышка сөенеп, һәр шатлыкны бәхет кебек кабул итеп, үзен-үзе үсендереп, өметкә, хыялга ымсындырып яшәде.

Улы Сәүбән — Сәвия өчен тормышның мәгънәсенә, максатына әверелде. Сафлык, өмет, иман, вөҗдан кебек рухи төшенчәләрне ул әнә шул улының тормышы, аның язмышы аша аңларга өйрәнде.

Ул бердәнбере Сәүбән язмышының иясез һәм өметсез булуы хакында уйларга да курка, аның күрәселәрен күз алдына китерә дә алмый иде әле.

Мин Сәвиянең үткәндәге тормышын тәфсилләп сөйләргә җыенмыйм. Вакыты килеп җиткәч, ул барысын да яшьлектәге сөйгәне Сәүбәнгә түкми-чәчми сөйләп бирәчәк. Елый-елый, үксеп-үксеп сөйләячәк. Ә менә бүгенге тормышын, шушы минуттагы кичерешләрен укучыга тизрәк җиткерәсем килә. Чөнки «иясез язмышлар хакындагы кыйссам» үзенең иң кискен борылышына, хәлиткеч вакыйгаларына җитте.

Ләкин мин Сәвиянең киләчәктәге тормышы хакында сөйләргә дә, бу киләчәкнең вакыт пәрдәсен күтәреп карарга да җыенмыйм. Дөресен генә әйткәндә, мин алдагы язмыш борылмаларын төгәл белеп тә бетермим. Бары тик тоям гына…

…Сәвия Сәүбәннең кайтуын шул көнне үк ишетте. Күрше Оркыя апага Май әби кереп чыккан икән.

Тегесе итәгенә ут капкандай йөгереп керде.

— Ишеттеңме-е-е? Сәүбән кайткан би-и-ит.— Шулай сүзләрнең ахырын сузып сөйләшә ул. Көйләгән, җырлаган кебек. Баштарак, аның сөйләме беренче ишеткән кешенең көләсен китерә. Аннары күнегәсең. Хәтта бу моңлы-көйле тавышны яратасың, озаграк ишетмәсәң, сагына башлыйсың…— Рәмзиянең читкә китеп олаккан малае-ы-ы… Мәрхабә ахирәт күргә-ә-ән…

Сәвия баштарак аңышмады, уй очын таба алмый интекте. Шулай да «Рәмзия малае кайткан» дигән аермачык хәбәр аның сагышлы күңеленә бик тиз төшеп ятты.

«Сәүбән кайтканмы? Мәңгегә кайтмас кебек иде бит… Кайткан… Булмас, бу ул түгелдер… Унсигез ел кайтмаган кеше башка кайтмый инде ул… Унсигез ел түзгән кеше калган гомергә генә түзә… Беренче биш ел, ун ел гына кыен, аннары түзәргә өйрәнәсең… Үзеннән белә Сәвия… Кайткан… Алай-болай, кайгы-мазар чакырып кайтармагандыр бит? Юктыр, Рәмзияттәйне көн дә күреп тора, сөбханалла, күзгә ямь бирерлек матур күренә әле… Әллә? Юктыр, юктыр… Сарманайда малае барлыгын каян белсен ул?.. Юктыр. Сорашыр иде, хәбәр итәр иде… Кайту белән йөгереп килер иде… Тукта, нишләп килсен ул? Малае хакында ишетсә дә, ул бит аның могҗизалы тарихын белми… Ачуланып килсә генә инде… Аннары бетте баш… Ачуланып, дөньяда яшәрлекне калдырмаячак… Юк ла, андый ук усал түгел иде лә ул… Күзнең чите белән генә карарга иде үзенә. Үзгәргәнме-юкмы? Үзгәргәндер шул… Унсигез ел буе туган җирсез яшәп кара әле… Бер елы, бер көне дә саргайта аның. Унсигез ел бит, бер буын алмашынган гомер… Бер гомер…»

— Нәрсә булды сиңа-а-а? Күзеңне акайтып карап катты-ы-ың? Әй ди-и-иим! Әй!

Сәвия шунда гына үзенең тораташ булып катып торуын, бер тиле яки телсез әпә кеше кебек, аңсыз, сүзсез калуын аңлап алды, үзенчә акланырга кереште:

— Ә?.. Нәрсә дисе-е-ең, Оркыя апа-а? Сәүбән кайткан дисеңме-е? — Оркыя белән сөйләшеп торган кеше үзеннән-үзе шулай көйли башлый. Шуңа күрә Сәвиянең бу «ы-ы»лап, «э-э»ләп сөйләшүе бер дә Сәүбәннең кайтуын ишетеп диванага калуы түгел, бәлки Оркыя карчыкның көйле, аһәңле сүзенә ияреп китүе генә.— Кайчан кайтка-а-ан? Кем белән кайтка-а-ан? Хатыны, балалары бармы-ы-ы? Рәмзияттәй бик сөенгәндер инде-е?..

— Сөенгәнде-е-ер, гомергә бер кайткан бит у-у-ул… Әле менә сиңа да әйтим диде-е-ем, кинәт килеп кер-е-еп, акылдан яздырмасын диде-е-ем...

— Ни сөйлисең син, Оркыя апа-а? Акылдан калдырырлык кем соң ул миңа?

— Чит-ят кеше түгел лә-ә-ә?

Шул вакыт урамнан Сәүбән кайтып керде. Оркыя карчык башка сүз озайтып тормады, бөтен әйткәннәрен, әйтәселәрен кабат күңел төенчегенә төйнәп, чыгарга кузгалды.

Бөтен дөньялары белән бер-берсенә береккән ике җан иясе олы бөтен өйдә япа-ялгыз торып калды. Сәвия, ишек катында нидер сизенеп басып торган малае янына барып, аның иңбашына кагылды, сак кына этеп, аны диван янына алып килде, утыртты, үзе дә янына утырды, шулай кочаклап торган килеш (әйтәсе хәбәргә чыдый алмыйча чыгып йөгерер яисә очып китәр дип курыкты, ахры), күзләренә туры карап, йомшак, ягымлы тавыш белән:

— Балам, авылга әткәң кайткан…

Сәүбән бу хәлләрне ничек кабул итәргә — шатланыргамы, борчылыргамы икәнен белми иде булса кирәк, аның тирән, моңсу карашларында әллә ни үзгәреш сизелмәде. Әткәйле тормышның, әткәйле язмышның нинди булуын ул бөтенләй дә белми шул әле.

Шуңа күрә бары тик:

— Әткәй кайткан? — дип кабатлап сорау белән чикләнде ул.

— Әйе, әткәң кайткан. Май әбиең күреп калган. Оркыя әбиеңә сөйләгән. Әле Рәмзия апаңнарда, ди.

— Нигә аларда? Нишләп безгә кайтмаган?

— Рәмзия апаңның малае бит ул. Кеше, авылга кайтканда, иң беренче үз нигезенә кагылырга тиеш, шулай итмәсә, аның гомере кыскара, ди… Йә, әткәңнең гомере кыскарсынмы?

Сәүбән уйчанланды, тәнендә, җанында эчке бер киеренкелек туып, аның уй-хисләренә бушанырга ирек бирми иде. Бөтен тән-җан күзәнәкләре хәрәкәткә килгән мизгел иде бу.

«Зиһене томаланып, җиңеләеп китмәсен тагын бу»,— дип, Сәвия өйдәге киеренкелекне юкка чыгарырга, малаен авыр уйлардан йолып алырга тырышты:

— Насыйп иткән булса, безгә дә килер, улым. Әткәң бит ул синең. Ә син аның улы. Белмәсә дә, ата кеше үзенең баласын — бәгырь итен тоярга тиеш… Көтик, яме, килер, килми калмас…

Малай һаман дәшмәде. Чөнки Сәүбән бу минутта әнкәсеннән акыллырак иде. Ул әнкәсенә караганда ныграк тоя, аңлый, хәтта төгәл белә: әткәй кеше бүген дә, иртәгә дә, берсекөнгә дә аларга килмәячәк. Тоемга, күңелгә, хискә ышанып булмый. Малае барлыгын белмәгәч, әллә ничек кенә тойса да, килмәячәк ул. Аңа әйтергә, хәбәр итәргә кирәк. Тик әнкәсе әйтергә кушмый. Бервакыт Сәүбән шәһәрдә яшәүче әткәсенә хат язып салмакчы иде. Яза да башлаган иде. Әнкәсенең хөкеме катгый булды: «Әйтмисең дә, язмыйсың да! Вакыт җиткәч күрешерсез, ә хәзер миннән бәхиллек юк!» Сәүбән белә: әнкәсе артык та горур аның. Шул горурлыгы белән гомер буе ялгыз яшәгән дә инде ул. Аннары… Унсигез ел туган йортына кайтмаган кеше өчен кайдадыр гомер сөрүче малаена карата булган күңел хисләре бер тиенгә тормаска мөмкин… Әнкәсе шуннан да шикләнә, ахры… Күңеленең кире кайтуыннан курка…

Ана белән бала бик озак тын калып утырдылар. Аларның моңа кадәр салмак кына агып яткан тормыш елгасына давыллы дулкын килеп кергән, тик бу дулкынның кайсы ярга таба шаулап йөгереп китүен беркем дә әйтә алмый иде бу минутта.

Шулай да нәрсәдер әйтергә, нидер кылырга кирәклеген дә белә Сәвия. Әллә берни дә эшләмәскәме? Күтәргә, бары тик күтәргә генә!

— Сәүбән балам, ул якка барып йөрмә, яме. Килешмәс. Бүгенге белән гомер бетми. Мин синнән бу хакта сорый алмыйм. Әмма сорыйм: әткәң янына барма. Бик барасың килсә дә барма. Ходай Тәгалә бар икән, ул барысын да үз урынына куяр, барысын да җайлар. Безгә дә мәрхәмәтле булыр. Кылган гөнаһларыбыздан изгелекләребез барыбер күбрәктер. Ходай ташламас... Бар, хәзер малайлар янына чык. Болай боегып утырма. Тик... әткәң янына барма, яме?

— Ярый, бармам...

Малае чыгып киткәч тә озак кына уйланып утырды Сәвия. Аның уйлары еракка — моннан унсигез ел элек булган күңелсез вакыйгаларга барып тоташты. Сәүбән белән Рәмис сугышкан төн Сәвия тормышында иң кара төн булып калды. Юк нәрсә өчен бит...

Сәүбән белән Сәвия арасындагы мәхәббәт күз тидерерлек дәрәҗәдә көчле һәм ниндидер илаһи нур белән өртелгән иде. Бу хакта бөтен авыл сөйләде. Инде мең мәртәбә сыналган фал: мондый мәхәббәт озын гомерле булмый. Иң бәхетле чакларында, бергә Казанга китеп, авиация институтына укырга керергә, галәмгә, йолдызларга очучы спутниклар төзүче булырга хыялланып йөргән көннәрендә язмыш юллары аерылды да куйды аларның...

Ул көнне Сәүбән уенга чыкмады. Сәвия кич буе күрше Рәмис белән биеде. Рәмис төшеп калган егетләрдән түгел. Өченче ел инде сабантуйларда батыр асты кала. Тимерче Зиннәтне дә ала язды быел. Тегесе аяк чалып кына җиңде. Авыл дөм каршы булса да, картлар шурасы тәкәне Зиннәткә бирдерде, ләкин киләсе елда тагын да хәрәмләшсә, батырлыгын алырга карар иттеләр.

Менә шул Рәмис яшьтән үк Сәвияне ошатты. Әмма Сәвиянең күңелен яулап ала алмады ул. Моңа аның көрәшче булуы да, чибәр йөзе, матур, зифа сыны, калын беләкләре, тулышып, бүртеп торган кулбаш, янбаш мускуллары да, хәтта уңганлыгы-булганлыгы да ярдәм итмәде. Сәвия үз күңелен, йөрәген башкага — югары очта яшәүче Сәүбән исемле егеткә биреп өлгергән иде инде...

Алар сигезенче сыйныфта укыганда, йолдызлы аяз бер төндә, кичке уен вакытында танышып киттеләр. Августта йолдызлар күп була бит. «Йолдыз яңгыры»— галәмнең иң серле могҗизасыдыр, мөгаен. Җаннар дөньяга ачылган, җаннар сызышкан, җаннар аңлаша торган вакыт бу. Күктәге һәр йолдыз — җирдәге җаннарга сихри ишарә, ә йолдыз атылу — шушы җаннарның тибеше, бәхеткә ымсынуы... Йолдыз атылганда матур теләк теләргә кушалар — аның синеке булуы бар, әгәр шулай икән — теләгең һичшиксез кабул булачак.

Илаһи матурлыкка омтылу — алдагы мәхәббәтне тою ул. Сәвиянең күңеленә килеп кергән матурлык та олы мәхәббәткә ишарә иде. Әйе шул, яшәеш ул — матурлыкка омтылыш. Акыл бу омтылышны кысаларга гына кертергә тырыша.

Сәвия уенга барганчы теләк теләп барды. Чөнки адым саен әле анда, әле монда күк йөзеннән йолдыз тамып тора иде... Их, бүген ул бер егетне очратсын иде! Ул чибәр булсын иде! Акыллы булсын иде! Көчле булсын иде! Их!..

Бу йолдыз яңгырында аның җан кисәге дә нурларын уйнатып алган икән. Шушы кичтә теләге кабул булды Сәвиянең.

Сәүбән уенга күп катнашмады. Әйбәт бии ул үзе. Иң әйбәт биючеләрнең берсе. Әнә читкәрәк барып баскан да күкне күзәтә. Күкнең мондый «тере», «җанлы» чагы бик сирәк була шул. Сәүбән аны күреп, күңеленә беркетеп, ятлап калырга тиеш! Төнлә кешенең күз алмалары төсен үзгәртүчән. Сәүбәннең зәңгәр күзләре дә бераз ачылып, ачыкланып, хәтта көмешләнеп киткән. Шушы көмеш күз алмалары белән томырылып, йотлыгып карап тора ул күк диңгезенә... Ә анда... «Йолдыз җиле» уңаена диңгез дулкыннары кебек алтын бөртекләрдән укмашкан сихри йомгаклар әле бер якка тәгәриләр, әле икенче якка йөгереп китәләр... Кайсыдыр бөртек коелып кала, аның урынына яңалары ягыла... Тик бер йолдыз гына, араларында иң яктысы, иң нурлысы, иң җанлысы, беркая да бармый, күкнең бер читенә барып урнашкан да күк диңгезендәге җил-давылны күзәтә; кайчакта борчылган кебек ул, кайчакта көлгән-елмайган кебек... Гөр килгән уен мәйданы читендә басып торган Сәүбән кебек... Ул да әнә шул Чулпан йолдызга баккан да өнсез калган...

Сәвия аның янына ук килеп басты. Сәүбән сизмәде. Аны бу минутта күк сихереннән беркем дә, берни дә аерып ала алмас иде кебек.

— Йолдызыңны таптыңмы әллә, Сәүбән?

Сәүбән кыймшанмады да. Һаман шул килеш җилле-давыллы күк диңгезенә багып торуында булды. Сәвия баштарак, ишетмәде, ахры, дип уйлады. Ишеткән икән!

Бераздан Сәүбән:

— Табасы-нитәсе юк. Мин үз йолдызымны күптән беләм. Ул да мине белә... — дип әйтеп куйды. Әмма карашларын барыбер күк йөзеннән тартып алмады.— Ә беләсеңме, җирдәге бөтен гүзәллек күктән, йолдызлардан, кояштан, ә бөтен яхшылык — кешеләрдән...

Сәвиягә Сәүбәннең җавабы бик сәер тоелды. Ничек инде? Йолдызлар каян белсен ди аны?

— Йолдызлар сине беләме? Алдыйсыңдыр әле.

— Йолдызлар барсын да белеп торалар. Менә без аларга карап торабыз. Алар да безне күзәтәләр... Хәтта сөйләшәләр... Тыңларга гына кирәк... Тыңлый белергә кирәк... Күкне тыңлаганың бармы?— Бу юлы Сәүбән йолдыз нурлары тулы мөлдерәмә күзләре белән Сәвиягә борылып карады.

Әллә инде Сәүбәннең серле җавабыннан, әллә шушы йолдызлы карашыннан, Сәвия аңа гашыйк булды да куйды.

— Ә синең йолдызың бармы?

Сәвиянең йолдызы юк иде. Ул күктәге йолдызларның барысына да бертөрле карый. Йолдызлар аны дулкынландыра, уйландыра, хисләнергә, хыялланырга өйрәтә... Әмма аерым гына йолдызы юк. Нишләп булмагандыр? Чынлап та, һәр кешенең йолдызы булырга тиеш ләса. Йолдыз бит «җан» дигән сүз. Ә! Аның әле икенче исеме дә бар — хыял яисә өмет... Хыял үлсә, өмет бетсә — җан да бетә, үлә. Тән кала, ә җан инде юк... Сәвиянең бу хакта каяндыр укыганы да бар.

— Юк, минем йолдызым юк шул. Ә синең йолдызың нинди, Сәүбән? Исеме бармы аның?

— Әнә ул Чулпан йолдыз, Венера дип йөртәләр. Иң якты, иң нурлы планета шул була инде. Мин аны кечкенәдән үк беләм. Ул да мине шундук яратты...

— Әллә ничек сөйләшәсең син, Сәүбән. Башка малайларга охшамагансың...

— Йолдызлар да бер-берсенә охшамаган бит. Ерактан гына алар шулай бертөсле булып күренәләр. Ә минем планета — иң матуры! Беләсеңме нинди төстә ул? Яшелле-зәңгәрле төсләр бизи аны. Яшел төс — тереклекне, зәңгәре изгелекне белдерә.

— Син боларны каян беләсең, Сәүбән? Үзең шунда булып кайткан кебек сөйлисең...

— Булуын булмадым, ләкин һәр көнне төшемдә күрәм. Яп-якын итеп күрәм. Анда нәрсә бар икәнен белмим белүен, әмма нәрсәдер булуын сизеп торам. Самолет биеклегеннән караган кебек карап торам...

— Кешеләр яшиме анда? Берәрсе бармы?

— Бар, бар. Мин моны тоям. Мин хәтта алар белән сөйләшәм. Тик күрмим генә. Ә бит күктә ничә йолдыз булса, җирдә шулкадәр нәсел бар. Җирдә ничә кеше яшәсә, шулкадәр тарих, гыйбрәт, язмыш бар.

— Сәүбән!

— Нәрсә, Сәвия?

— Бер әйбер сорасам, ачуланмыйсыңмы?

— Нәрсә соравыңа карап инде.

— Юк, син башта әйт: тиргәмәссеңме?

— Юк ла, тиргәмим.

— Сәүбән, синең йолдызың минеке дә булсын әле...

— Һи, шул гынамы? Булсын соң! Анда барыбызга да урын җитә. Аннары... Ул синең йолдыз булырга тиеш тә!

— Ни өчен алай дисең?

— Син дә зәңгәр күзле бит. Ә зәңгәр күзле кешеләр Чулпан-Венера белән кардәш, белдеңме?..

— Ничек кызы-ы-ык... Синең белән шундый кызык, шундый күңелле, әйдә дус булабыз!..

— Әйдә! Безнең йолдызыбыз да уртак хәзер...

Дуслык дуслык булып кына калмады, дәртле ымсынуга күчте, ымсынуярату белән алмашынды, ярату олы мәхәббәткә бөреләнде. Шушы мәхәббәт ихтыярында ике ел үтеп тә киткән. Хәзер Сәвия күрше егете Рәмис белән түгәрәк әйләнә... Начар егет түгел ул үзе. Тик Сәвия яратмый аны.

— Сәвия, иртәгә мин китәм,— дип, кыюсыз гына сүз башлый Рәмис.

— Кая?

— Чаллыга, физкультура институтына.

— Мин синең өчен бик шат, Рәмис.

— Син Сәүбән белән Казанга китәсеңме?

— Әйе, авиация институтына барабыз.

— Сәвия, мин сине яраттым бит...

— Беләм, Рәмис. Бу турыда сөйләшмибез, яме. Әйдә дус булып калыйк.

— Сәвия, әйдә сине бүген мин озатам. Барыбер Сәүбән уенга төшмәде. Беренче һәм соңгы мәртәбә озатуым булыр. Бәйләнеп тә, сөйләнеп тә интектермәскә сүз бирәм. Ант итимме?

— Юк, кирәкми. Болай да ышанам. Тик... Сәүбән киләм дигән иде, аны күрмичә китә алмыйм мин.— Сәвия як-ягына каранып алды, үзенең Рәмисне дә рәнҗетәсе килмәде.

Рәмис һаман үз сүзеннән кайтмады.

— Сәвия, гомердә бер мәртәбә икәү кайтыйк әле. Уен да бетеп килә. Сәүбән дә чыкмас инде. Кайтканда юлда очраса, мин честь биреп китеп барырмын, сез бергә калырсыз. Арагызга керергә җыенмыйм. Кайтыйк бергә, Сәвия, ә?

— Ярый алайса, киттек…

Бу кичтә Сәвия Рәмис белән генә түгел, Сәүбән белән дә мәңгелеккә аерылышты.

Рәмис ел саен җәй кайтып китә. Ел саен Сәвия янына килеп: «Әйдә бергә булабыз, мин бит сине һаман яратам»,— ди. Сәвия дәшми. Көлеп, Рәмиснең сүзен уенга борып җибәрә. Соңгы дүрт елда килгәне юк. Өйләнгән, ди. Авылга кайтканда урамга бик чыгып йөрми, ахры, Сәвиянең күзенә дүрт ел күренгәне юк инде.

Сәүбән дә юкка чыкты… Китте дә югалды. Сәвия аның кайда укыганын да, өйләнгәнен, малай үстергәнен дә белә белүен, тик күргәне генә юк. Шулай да бер мәртәбә күреп калды ул гомерлек сөйгәнен. Шул күрешүнең истәлеге булып зәңгәр күзле малай калды.

Ун ел элек туды аның Сәүбәне. Башта Сәүбән түгел иде әле ул. Яңа гына җан кунган бер ит кисәге иде. Бала табу йортыннан чыкканчы ук Сәүбән дип исем кушты. Әйе-әйе, ике дә уйлап тормыйча, яңа туган сабыена әткәсенең исемен бирде, шуның белән тирә-якта гайбәт таралуга сәбәпче булды.

Яшәү, әлбәттә, көрәштән тора. Әмма көрәш яшәү түгел әле. Сәвия бу хакыйкатьне белми иде.

…Минзәлә педучилищесын тәмамлап, якындагы бер авыл мәктәбендә башлангычларны укыта башлаган чагы иде. Сәвиянең көмәнле булуы күп кешенең күңеленә тиде. Иң беренче булып, үзе укыткан мәктәп «күтәрелде». Ике педсоветта «чайкаганнан» соң, йөкле хатынны эштән чыгардылар. Сәвия Сарманайга кайтырга теләмәде, Минзәләгә килеп паспорт өстәленә эшкә керде, аннары, бер әбидә торып, бала тапты һәм, бер елдан соң, ирем белән аерылдым, дип, Сарманайга кайтып төште.

Ләкин авыл халкы Сәвиягә ышанмады. Сабыйның йөз-бите, гәүдә-сыны Сәүбәннең көзгедәге чагылышы иде…

Кешеләр Сәвиянең йөзенә бәреп әйтмәсәләр дә, аның Сәүбән белән яшерен сөешүе хакындагы хәбәрләр колактан колакка күп йөрде. Үсә төшкәч, дөньяны таный, зиһене утыра башлагач, бу хакта Сәүбән үзе дә ишетте. Ләкин ничек кенә теле кычытса да, кирәкмәгән сораулар белән әнкәсен тилмертмәде. Ни булса, шул булыр дип, кайчандыр әнкәсенең бу хакта сөйләячәген белеп, тыныч кына яшәде дә яшәде…

Берничә мәртәбә Рәмзия дә килде.

— Дөресме шул сүз, Сәвия, Сәүбән минем Сәүбәннең малаемы?

— Әйе, аның малае. Синең оныгың була.

Рәмзия моңа бик нык өзгәләнә. Ләкин орылып-бәрелеп, тиргәнеп йөрми.

— И-и, балалар, балалар…— ди дә, бишек янында казык кебек басып торган Сәвиянең аркасыннан кагып, чыгу ягына юнәлә… Нәрсә дип әйтсен инде аңа Сәвия? Ялганласынмы? Сәүбәннең малае түгел, дисенме? Рәмзия барыбер ике килүендә дә ышанмыйча китте. Әмма аның күңеле һаман матур якка үзгәрә барды. Сәүбәнне шундук үз итте, бәйрәмнәрдә чакырып, сыйлап, кесәсен тәм-том белән тутырып җибәрә торган булды.

…Сәүбән уеннан бик соң керде. Бүген ул аеруча моңсу, күңелсез, телсез иде. Әзерләп куелган сөтне шапырдатып эчеп куйды да, дәшми-нитми генә, юрганы астына кереп чумды…

Ярату өчен матур йөрәк кирәк, бәхетле булу өчен батыр йөрәк кирәк. Сәвиянең йөрәге матур иде, әмма батыр түгел иде шул. Ул Сәүбән хакында озаклап уйларга да батырчылык итмәде.

Икенче көнне дә дөнья үзгәрмәде — Сәүбән Сәвияләргә килмәде. Бала Сәүбән, нидер өмет итеп, урамнарны урап кайтты, аннары Кала-тауга илтүче сукмаклар буенда йөрде, әмма аңа теләгән кешесен күрергә насыйп булмады. Ә бик тә, бик тә күрәсе килә иде аның үз әткәсен!

Кич өйгә кайткач, уңайлы бер вакыт сайлап, Сәүбән әнкәсенә әйтеп куйды:

— Бүген дә килмәсә, иртәгә әткәй янына үзем барам.

Сәвия яңабаштан малаена ялына-ялвара башлады:

— Йөрмә, балам, киләсе булса, үзе килер… Кеше көлдермә…

— Әткәй янына бару кеше көлдерүмени?

— Кем белә инде аны. Килешеп бетмәс дип кенә әйтүем… Бүген аны Кала-тау буенда күргәннәр…

— Әнкәй, нинди ул?

— Кала-таумы?

— Юк ла, әткәйне әйтәм…

— Ул тач синең кебек, суйган да каплаган. Хәзер үзгәргәндер инде, олыгайгандыр…

— Син аны һаман яратасыңмы? Көтәсеңме?

Малаеның ихлас соравыннан Сәвиягә кыен булып китте. Ләкин бу минутта бала белән ана арасындагы мөнәсәбәтләрдә оялырлык нәрсә калмаган иде инде.

Сәвия хисләрен бик тиз җыеп алды:

— Яратам... Көтәм... Тик аның үз гаиләсе бар шул, улым.

Сәүбән моны үзе дә белә иде. Белсә дә, бу хакта әнкәсеннән ишетү бик авыр аңа. Әле чыныгып та җитмәгән бала күңеленә күп кирәкмени — шунда Сәүбәннең күзеннән ике бөртек яшь атылып чыкты да, якты дөньяга карап, гаҗәпләнеп, сокланып, чирек мизгел генә эленеп торганнан соң, берберсе белән ярыша-ярыша аска — ирен читенә тәгәрәде...

Сәвиянең дә күзләре дымланган иде.

Ул күзләрен каплаган яшь пәрдәсе аша малаеның моңсу карашын эзләп тапты һәм, аның колагына иелеп, шундый ук моңсулык белән:

— Бар, әткәң янына бар... — дип пышылдады.

Икенче көнне Сәүбән, таң белән, әнкәсе көтү куарга чыгып киткәч, мыштым гына торып, яңа күлмәген табып киде дә өй артлап кына күрше урамга чыкты, әткәсе кайткан йортка — Рәмзияләргә табан китте...

## 10

Рәмзиянең үз балалары каршында бу кадәр дә кыен хәлдә калганы юк иде. Тик торганнан, уйламаган-нитмәгән җирдән, таң тишеге белән капка төбенә килеп утырган ниндидер малай-шалай янына чакырып чыгарды бит Сәүбәнен. Олы башын кече итеп, шул камыш буе малай алдында түбәнсенеп йөрсен инде... Тегесе дә: «Рәмзия апа, әткәй чыксын әле»,— дип чатнатып тора бит, ичмасам. Күңеле әллә нишләп китте шул бу минутта. Эреп, җебеп төште, ятим баланы рәнҗетмим, чакырыйм булмаса, бер сөйләшеп алсалар да савапка китәр дип уйлаган иде. Әнә ничек килеп чыкты... Чынында, берни дә килеп чыкмады. Болай да кыенсынып, кимсенеп, үз йөрәген «учына кысып» йөргән Сәүбәннең күңелен тәмам рәнҗетте, ахры, ул... Теге баланың яшь йөрәге ничек түзәдер, аңа да бик авыр булгандыр... Әткәсен юксынып, каңгырып йөргән чагы бит... Бер Рәмзия генә түзәргә тиеш тә, бер ул гына ике арада бәргәләнеп йөрергә мәҗбүр булып чыга... Нишләсен, түзә, ана бит...

Шундый авыр уйлар белән йөри-йөри, Рәмзия төшке ашны да җиткерде. «Ат караучы Хәләф абзый янына барып киләм»,— дип чыгып киткән Сәүбән кайтмады да кайтмады... Шулкадәр үпкәләде, рәнҗеде микәнни? Әнә бит бала Сәүбән яныннан кергәч, ул тәмам үз эченә йомылды. Дәшминитми генә юынды да сыңар кабартма белән ярты чынаяк чәй чөмереп, авыр сулый-сулый чыгып китте. Рәмзия белә: күңеленә тынычлык, җылылык эзләп чыгып китте ул. Әнкәсе бирә алмаган җылылыкны каян гына табар ул? Хәләф карт янындамы? Атлар бирерме аңа бу тынычлыкны? Юаныр өчен атлар ярап торыр торуын... Сәүбән кечкенәдән атлар яратты шул. Йолдыз кашкасыннан егылып, кулын да каймыктырган иде. Барыбер ташламады шул атын. Ике җәй буе ындыр табагында җигелеп эшләделәр... Менә әле дә шул атлар белән мавыгып йөридер. Төшке ашка да кайтмады бит әнә...

Рәмзия өстәл өстендәге ризыкларны җәймә белән каплаштырды да, «бисмилла»сын әйтеп, ишегалдына чыкты... Әле бер эшкә тотынды, әле икенчесен башлап карады, әмма бүген аның өлгер кулына бер эш тә ябышмады. Ишегалды тулып яткан бер генә эшкә дә күңеле ятмады Рәмзиянең. Чөнки аның күңеле, тәмам изаланып, тотрыксыз, ният-карарсыз бер хәлгә төшкән иде... Аеруча Сәвиянең малае өчен борчылды ул. Аның бернинди дә гаебе юк ласа. Хода бәндәсе бит ул! Саф, чиста, бер гөнаһсыз адәм баласы. Әнә ничек тилмереп йөри, бәгырькәй. Ул малайның сере кайчан да булса беленер беленүен... Ләкин соң булыр, ахры... Ичмасам, Сәвия белән Сәүбән дә бер-берсеннән качып йөриләр. Ни «а», ни «б» чыкмас авызларыннан... Каян килгән ул малай? Кемнеке ул? Ни өчен Сәүбән исемле? Үз малае булмагач, Сәүбән нигә бу чаклы да нык борчыла соң? Нигә үртәлә?..

Рәмзия уйлаган уйларының очына да, төбенә дә җитә алмады. Кояш түбәнгә төшә башлаган мәл иде, ул, борчулы уйларына ачыклык кертергә теләп, түбән очка — Сәвияләргә китте. Мәктәп ябык, балалар ялда, кая китсен, өйдәдер әле, дип барып керсә, фаразы рас килде — Сәвия үз бакчасында яңгырдан соң ишелгән түтәл читләрен ныгытып булаша иде.

— Нихәлләр, Рәмзия апа, нинди җилләр ташлады? — дип, сагаюлы, хәтта шомлы тавыш белән каршы алды аны хуҗабикә.

— Хәлләр ярыйсы. Уңган кешенең эше дә уңда шул. Уңган булгач, бакчаң да ялт итеп тора әнә...

— Көлмә инде, Рәмзия апа. Быел бакчага һич өлгереп булмый әле...

— Болай да бик матур күренә. Кая соң Сәүбәнең? Булышадыр бит?..

— Булыша, булыша. Гел янымда урала иде, бүген каядыр китеп югалды. Әбәткә дә кайтмады. Сезнең очта күренмәгәндер бит, Рәмзия апа?

— Күренде шул. Килүем дә шуның өчен.

Сәвия сагайды. Кулындагы кәтмәнне коймага сөяп, чәчләрен рәтли-рәтли Рәмзиягә таба килә башлады.

— Бер-бер хәл булмагандыр бит, Рәмзия апа?

— Әлегә белмим… «Әткәй» дип килгән ул. Ә мин, юләр, шундук чакырып та чыгардым.

— Чыктымы соң?

— Әйтәм бит инде, чыгуы юньлелеккә булмады, дим… Колак читен куеп кына тыңладым: бер дә рәтле-чиратлы сөйләшмәделәр. Сүзләренең һич инабәте юк иде… Тегесе: «Син минем әткәем, ә мин — синең улың»,— ди. Монысы һич юл куймый: «Улым Казанда калды. Башка балам юк минем, әтиеңнең кемлеген әниеңнән кайтып сора»,— ди. Синең Сәүбәнең бик үпкәләде, ахры, күзләрен сөртә-сөртә инешкә төшеп китте… Шул китүдән Кала-тауга бармагае дип куркам, аның да зәһәр вакыты җитеп килә, янына барып йөрү әйбәтлеккә түгелдер…

— Ай Аллам, кайда гына йөри икән ул?! Әйттем мин аңа: «Барма, йөрмә»,— дидем.— Әткәсен бик күрәсе килде шул…

— Минем Сәүбән чынлап та аның әткәсемени?

— Аныкы! Рәмзия апа, ышанмасаң, менә шушы кояш белән, якты көн белән, шушы кулларым, күзләрем белән, икмәк белән, иң газиз әйберләрем белән ант итәм: Минем Сәүбән — Сәүбәннең кандаш улы…

— И-и, Сәвиякәем, хараплар гына иттек алайса малайны!..

— Алай димәле, Рәмзия апа, бала бит, уен белән мавыгып, дөньясын онытып йөридер әле. Йә Кала-таудагы куышында ятадыр. Бераз үпкәсе килсә, шул оясына китеп юкка чыга торган гадәте бар…

— Минем Сәүбән дә бәләкәй чагында шул тауга ияләшкән иде. Тырнак очы кадәр дә сүз әйтеп булмый иде үзенә — тота да шунда чыгып йөгерә… Берсендә өч көн эзләдек. Баланың хәлсез гәүдәсен чак күтәреп кайттык…

— Куркытмале, Рәмзия апа. Сабый түгел лә ул. Кайтыр, кайтыр…

— Ничек булды соң сезнең? Сәүбән белән, дим? Шуны гел сорарга йөрим. Сәвия балакаем, хак дөресен сөйлә әле, яшермә. Үзеңә дә җиңелрәк булып калыр. Анда Сәүбән өзгәләнә, монда син сер саклап утырасың… Балаң хакына булса да сөйләргә тиеш син. Шул гөнаһ шомлыгы сер ачылса, дөньялар яхшыга үзгәрер кебек…

— Синең Сәүбәнеңдә бер гаеп тә юк, Рәмзия апа, өзгәләнмә ул кадәр. Ул бит авылда үзенең малае барлыгын белми дә хәтта. Хәзер килеп ничек кабул итсен ул аны?

— Алай булмый бит, кызым. Очрашмыйча, сөешмичә бала булмый!

— Бер тапкыр гына очраштык без, Рәмзия апа. Ун ел элек очраштык… Шуннан соң күрешкәнебез юк.

— Бәрәкалла, ничек алай була инде? Атасына бер тапкыр да күрсәтмичә бала үстереп ятасыңмы? Ни әйтсәң дә, Сәвия кызым, бу бер дә мактана торган эш түгел!

— Беләм дә соң… Тик нишлим? Үзем теләп алган бәхет… Беркемгә дә үпкәләрлегем юк…

— Хәзер нишлибез инде, кызым?

— Өй-каралтыларны бикләштерәм дә Кала-тау ягына барып киләм. Әллә кайда йөрмидер әле, шунда гынадыр. Әйбәтләп аңлатырмын. Сәүбән шикләнмәсен, мин аңа бала тагарга да, үзем тагылырга да җыенмыйм. Ачуланма, Рәмзия апа, куа димә, миңа китәргә кирәк, кайдадыр Сәүбәнем көтеп ятадыр. Тизрәк табып алып кайтыйм әле балакаемны…

…Рәмзия капкадан кайтып кергәндә, Сәүбән түр бакчадан чыгып килә иде. Кәефе шәп күренә. Хәләф карт янында эше пешкән икән.

Киң елмаеп, сөенче алырга кереште:

— Әнкәй, иртәгәгә ат сөйләшеп кайттым, яшел үләнгә менәргә исәп. Саудыра торган сыер кич тә күшәп ятарга тиеш, шулаймы?

— Шулаен шулай да…

— Тагы нәрсә булды? Йөзең борчылган, димме? Кем рәнҗетте? Хәзер без аны...

— Йә, һаваланма, улым. Берни дә булмады. Ә менә сиңа нидер булган. Ник каты кыланасың ул малай белән? Ник рәнҗеттең аны? Хәзер әнә өенә дә кайтмый йөри, әллә кая китеп югалган…

Сәүбән чыгырыннан чак чыкмады:

— Тагын шул малаймы? Тагын шулмы? Нинди афәт бу? Унсигез елга бер мәртәбә авылга кайтам, анда да чит бала ияртеп җибәрмәкчеләр… Әнкәем, бәгъерем, нинди хәл бу? Берни дә аңламыйм!

— Сиңа бала таккан кеше юк бит әле. Сабый бала юкка чыккан анда. Аны иң соңгы күргән кеше — син! Ә сиңа ул «әткәй» дип килгән булган. Хәзер аңладыңмы инде?

— Аңладым да, аңламадым да. Ярый, мин хәзер аны табып гафу үтенәм. Шул кирәкме сиңа? Ә калганы минем өчен мөһим түгел. Чит ояга күкәй салып йөри торган гадәтем юк минем! Шуның белән сүз тәмам, җыелышны ябык дип игълан итәм! Вәссәлам!

Сәүбән ярсып-куптарылып өйгә кереп китте, Рәмзия аптыраган бер кыяфәттә ишегалды уртасында басып калды. Бераздан, уйларын төйнәп бетереп, авыр сулап куйды да кош-корт җиме салынган тагаракка барып ябышты.

Бу юлы Рәмзиянең җаны тынычрак иде. Чөнки ул Сәүбәннең күңеленә корт, шик салып куя алды. Бу шик аны бераз вакыт бимазалап торачак та кабат ишегалдына — әнкәсе янына алып чыгачак. Рәмзия моңа шикләнми. Тик соңга гына калмасын иде. Яшь җиткереп килүче балаларның үпкәсе — күңел үпкәсе генә түгел, җан үпкәсе ул. Ә җан белән бәйле һәрнәрсәнең шомлы, куркыныч һәм фаҗигале бетүе мөмкин…

Сәүбән чыкмады да чыкмады. Көн кичкә авышты. Көтү кайтырга да күп калмады. Рәмзиянең һаман өйгә керәсе килмәде. Ул үҗәтләнеп, эчке бер тоем белән улының чыгуын көтте.

Ниһаять, инде тәмам өмете өзелә язгач, шыгырдап өй ишеге ачылып китте һәм аннан Сәүбәннең борчулы йөзе күренде:

— Әнкәй, кайсы якка киткән соң ул малай актыгы?

Рәмзия теләгенә иреште. Көттеребрәк булса да, Сәүбән ул теләгән сорауны бирде. Елмаеп-көлеп тә җибәрә язды хәтта. Ә көләргә ярамый! Сәүбәннең тәмам ярсыган күңелен үртәргә һич ярамый иде бу минутта.

— Кала-тауда бер яшерен куышы бар ди аның. Шунда түгел микән, дип сөйләп торды Сәвия.

Әйткән сүз — очкан кош, диләрме әле? Әйтелгән сүз әйтелгән инде, аны тотып булмый. Инде шул сүз өчен җавап бирәсе калды.

— Сәвия? Әллә Сәвия янына бардыңмы?

— Урамда очраган иде, сөйләшеп тордык.

— Нәрсә сөйләштегез? Мине сөйләштегезме? Әйттем бит инде — минем бала түгел, дидем. Минеке булса — каршы килер идемме соң?

— Ун ел элек очраштык, ди Сәвия. Сәүбән шул очрашуның истәлеге булып калды, ди.

— Төшендә күргәндер ул. Йә акылга җиңеләйгәндер…

— Һич алдаган кебек түгел шул. Тагын бер тапкыр уйлап кара әле, балам. Очрашмадыгызмы?

— Әнкәй, дим! Ярый, табып бирәм мин сезгә ул малайны! Гафу да үтенәм. Чынлап та, матуррак сөйләшергә кирәк булгандыр… Миңа охшаган икән, исеме дә Сәүбән икән — бу әле минем малай дигән сүз түгел! Әнкәй җаным! Инде сиңа да аңлатырга кирәкмени — йокламыйча бала булмый! Ә минем Сәвияне күргәнем дә, аның белән йоклаганым да юк! — Ярсуы бераз кайткач, тыныч кына сорап куйды: — Шырпы-чыра әзерләле, әнкәй, мин бүген мәгарәгә керәм… Элек әзерләп бирә идең бит. Бераз капкаларга да сал, яме…

**11**

Сәвия малаеның Кала-тауга китүен ишеткәч, Сәүбән күңеленең ерак почмагында нindидер таныш түгел бер хис кузгалды. Бу хискә сөенергәме, көенергәме икәнен белми иде әле ул. Әйе-әйе, нindидер сәер тойгы бу. Үзе шомлы, үзе өмет кебек якты, ымсындыргыч… Бер сүз белән әйткәндә, Сәүбәннең күңелен шомлы өмет тойгысы тырнап тора башлады.

Кала-тау — аныкы, Сәүбәннеке генә иде бит. Баксаң, бу тауның тагын бер иясе бар икән. Ятим калып озак моңаймаган, ахры, ул. Изге җан табылган. Сәвиянең Сәүбәнгә охшаган малае… Кала-тауда яшерен куышы бар диме? Сәүбәннең дә куышы бар иде бит. Үпкәләп киткән диме? Сәүбән дә кыен чакларда шунда китеп югала иде. Нигә Сәүбәнне кабатлый бу малай? Аның эзенә басып йөри. Аның гомерен яши. Кем ул? Аның кеме ул? Соңгы вакытта Сәүбәннең колагында һәм күңелендә бу сорау шулкадәр еш яңгырый, ул инде үзе дә шикләнеп уйлап куя: «Әллә чынлап та минем малаймы?» Юк ла, балачак рухы хакында сүз бармый. Чын малае, кандаш малае түгелме дип уйлый Сәүбән. Бәлки, берәр төрле могҗизадыр бу: бик яраткан, сагынышкан кешеләрнең уртак балалары буладыр? Ул сөю-мәхәббәт нурыннан яраладыр? Ә бит алар Сәвия белән бик яратышалар иде!

Тоймыйча торып, аңлап булмый. Сәүбән шуңа аңламаган да икән. Ул хәзер тоя, бу малайның үз баласы булуын тоя, шуңа да аңлый: моның булуы мөмкин! «Ничек?» дип тә уйламый ул хәзер. Белә, шуның белән вәссәлам!

Сәүбән үзенең балачак образы, рухы хакында уйланды. Кая китте соң ул? Иртән чәчелеп таралган иде, шуннан бирле күзгә күренгәне юк. Әллә ул кабаттан җыела, рухи образга әверелә, оеша алмый микән? Әллә Сәвиянең малае да шундый ук бер образмы, рухмы?

Кешене кеше итеп ике әйбер тота: ялганнан курку һәм дөреслектән курыкмау. Бу юлы кайсы очрак соң? Кем алдый? Дөреслек кайда? Кешелеклелек кайда? Сәүбән белә: бу сорауга Сәвия генә төгәл җавап бирә ала. Нindидер сер бар монда. Ул сер Сәвиядә…

Барырга кирәк, күрергә кирәк тә соң үзен. «Юк, вакыт җитмәде әле, бераз кичектерим, иртәгә, иртәгә…» — ди торгач, әнә күпме заман узган…

Өйдә арлы-бирле йөргән Сәүбән үзен кая куярга белмәде. Әнкәсе кертеп биргән юл капчыгына да тотынмады. Төнгә каршы юлга чыгасы килмәде аның. Юк, куркудан да түгел. Караңгыдагы юл — ялгыш юл, ди иде мәрхүмә әбисе. Унсигез ел аяк басмаган сукмакларда адашып йөрүдән шикләнде Сәүбән. Шул ук вакытта Сәвия малаеның язмышы да бик борчый иде аны. Ул малай хәзер Сәүбәннең язмышына аерылмаслык булып береккән иде.

Рәмзия белән Сәүбән, җәелеп китеп сөйләшмичә генә, кичке чәйне эчтеләр. Сак кына, гафу үтенгән кебек кенә, Сәүбән әнкәсенә Сәвияләрнең хәлен белеп килергә кушты. Янәсе, теге качкын малай кайтканмы-юкмы?

Рәмзия тиз урап килде. Сәвия өендә юк икән. Ишеге бикле, капкасында — терәү, ди. Ниһаять, Сәүбәннең аңына барып иреште: эшләр шәптән түгел. Малай юкка чыккан, аның артыннан анасы да югалган. Өстәвенә бала чагының образ-рухы да чәчелеп, таркалып күккә очкан…

Бер ныклы карарга килеп, Сәүбән ишек катына китте. Юл капчыгын алып аркасына киде, ишек яңагына сөялеп торган чыраларны үрелеп алды.

Тәрәзәдән тышка карап, нindидер борчулы уйга калган әнкәсенә:

— Ярый, әнкәй, мин Кала-тауга таба китәм. Кайчан кайтуымны әйтә алмыйм. Бүген-иртәгә кайтмасам, эзләргә чыгыгыз. Сәвияләргә барып йөр, өенә бер-бер хәл булмагае… Аны да эзләгез.

Рәмзия:

— Уф, улым, куркытасың син мине, әллә иртәгә иртән генә чыгасыңмы?— дип караса да, Сәүбән үз ниятеннән кире кайтмады. Тагын бер мәртәбә саубуллашты да, ирләрчә нык басып, нинди халәт — шундый таләп дигән кебек, үзенең күңел халәтенә түзә алмыйча, Сәвиянең малаен эзләп чыгып китте…

Шул элеккеге сукмагы буенча барды ул. Кояш баерга ике-өч сәгать бар иде әле, авыл читендәге кыр-яланнар, үр-чоңгыллар әллә каян күренеп тора. Әмма Сәүбән күпме генә каранса да, күз күреме җирдә хәрәкәт шәйләнмәде: Сәвия дә, аның малае да, җир астына убылган кебек, кинәт гаиб булганнар.

Инеш буйлап бераз баргач, сөзәк тау менәсе бар. Шул тау итәгенә җитәрәк, Сәүбән аның башында утырган бер яшүсмер баланы күреп алды.

Сәүбәннең җанын «Әллә шулмы?» дигән уй көйдереп үтте. Ул адымын тизләтте. Чынлап та, үр башында иртән капкалары төбендә очраткан таныш малай утыра иде.

Барып җитмәс борын, Сәүбән аны шелтәләргә кереште:

— Әй, малай актыгы! Нишләп утырасың монда? Йәле, марш өеңә! Әниең дөнья бетереп эзләп йөри, хет аның хәленә керер идең. Япа-ялгызың япан тау башында утырмасаң… Ә иртәнге өчен ачуланма, телисеңме, гафу үтенәм… Катырак сөйләштем, үз гаебемне таныйм. Кичер… Синдә дә гаеп бар: беренче күргән кешеңә «әткәй» дип ябышасың… Йә, әйдә кайтыйк, кайта-кайта сөйләшербез, аңлашырбыз, кемнең кем икәнен ачыкларбыз… Без бит ирләр, үпкәләп, кешедән качып йөрү килешми…

— Ә син үзең бала чакта нинди идең соң?

— Нинди дип… Синең кебегрәк инде, үпкәләгән чаклар да була иде, яшермим… Ә син алай булма! Егет бул! Ә чын егет әнисен рәнҗетми. Синең качып йөрүең әниеңне рәнҗетү ул… Бир кулыңны, тор, әйдә киттек. Шаккатсыннар әле өйдә…

— Шаккаттылар ди, көтеп тор… Син нәрсә телеңә салынасың? Мин бит Сәвия малае түгел. Мин — синең бала чагың. Онытттыңмыни?

— Тфү! Син икән бу!.. Ник башта ук әйтмисең аны? Авыз корытып сөйләнеп торган булам, мин — тиле! Күпме вакытны алдың. Иртән чәчелеп юкка чыккач, башка күрмәм дип уйлаган идем инде.

— Мин бит рухи зат. Мин үле дә түгел, тере дә түгел. Мин — просто яшим!

— Һич күнегә алмыйм сиңа… Көне буе кайда йөрдең соң?

— Синең өчен тырышып йөрдем…

— Ничек итеп?

— Бәләкәй Сәүбән артыннан йөреп әлсерәп беттем… Кала-тауга җиткәч, адаша яздым…

— Кала-тауга?

— Иртән синең яннан киткәч, шул тауга чапты бит ул…

— Ну, шуннан?

— Шуннан шул! Чишмә буенда бераз юанды да… Язмышын эзләп китте.

— Ничек инде?

— Югалган язмышын эзләп китте…

— Туктале, болай серле сөйләшмәле син. Нинди язмыш ул? Кая югалган? Ник, ничек югалган?

— Ничек дип… Һәр кешенең үз язмышы була, ул шул язмышын тапса — бәхетле гомер кичерә, таба алмаса — гомер буе каңгырап, шул иясез калган язмышын эзләп йөри… Аңладыңмы?

— Аңладым да… Аңламадым да…

— Димәк, аңладың...
— Исәнме, саумы ул?
— Кем?
— Сәүбән инде! Теге, миңа охшаган малай.
— Синең малаймы?
— Син дә шул сүзне сөйлисең... Каян килеп минеке булсын ул?
— Белмим-белмим... Мин бер генә нәрсәне беләм. Юк, ике нәрсәне беләм икән: ул — синең малай. Һәм ул исән!
— Кайда соң ул малай?
— Менә бу хакта әйтә алмыйм, кичерә күр.
— Әйтергә теләмисеңме? Әллә белмисеңме?
— Мин әүлия түгел. Мин — синең балачак образың гына. Мин сиңа ышаныч, ныклык бирә алам, җаныңа ихтыяр көче өрә алам, әмма мин тормышыңдагы һәр адымыңны әйтеп, күрсәтеп тора алмыйм. Бу дөрес тә булмас иде. Чөнки кеше үз юлын үзе табарга, үз язмышын үзе тудырырга тиеш. Башкаларга сукырларча ияргән кешеләр күңел тоемнарын бик тиз югалталар.
— Килешәм. Ышандырдың. Тик бүген бер авыл малаеның язмышы хәл ителә. Шундый хәлиткеч вакытта да дәшми калырсыңмы?
— Юк, әйтмим. Мондый вакытта язмышлар тагын да зуррак мәгънә алалар. Гомернең кыйммәте, яшәгән көннең әһәмияте арта мондый чакта. Болар синең терелә башлаган җаныңа аеруча кирәк. Сөрсеп, вакланып беткән, авыр сагыштан арыган, тормыштан йөз чөергән җаныңны уятырга, аны яшәүгә, өметкә, мәхәббәткә кайтарырга килдем мин сиңа...
— Алайса, Сәвия малаеның кайда икәнен әйтмисең инде?
— Әйтмим.
— Синең белән вакыт уздырып торган мин юләр! — Сәүбән моны ниндидер ачу катыш үҗәтлек белән әйтте.— Утыр шунда җансыз түмгәк булып! Тик артымнан иярәсе булма! Үзем табам мин аны! Миңа тамашачы кирәкми. Бу — театр да түгел!
Сәүбән, сикереп торып, чалбар балакларын каккалап алды, аркасындагы капчыгын рәтләде. Аннары кызу адымнар белән янәшәдә генә ярты күкне каплап торган Кала-тауга төбәп китеп барды. Бала чагы исә, ул килгәндә ничек утырган булса, шул килеш, каш та сикертмичә, керфек тә чиертмичә, тау башындагы тораташ кебек, элекке рәвешендә утырып калды. Бу бер үк кешенең бер-берсенә, юк ла, үз-үзенә үпкәләве кебегрәк сәер күренеш иде.
Сәүбән бара-барышка аста җәелеп яткан болын буйларын күзәтте. Әнә Кала-тау итәгеннән йөгереп менеп киткән юкәләр рәтеннән башланып китә Аймәт уйсулыгы. Бер якта күк алан төсле, исемсез инеш чәбәләнә, икенче якта җыйнак кына әрәмәлек бөдрәләнә. Шул әрәмәлек читендәге калкулыкта — аны «Убыр күкрәге» дип тә йөртәләр — зират... Тукта! Нәрсә бу? Әрәмәлек буенда бер ак тап талпына... Кош дисәң, кош түгел, ат дисәң, ат түгел... Кеше! Кеше бит бу! Әллә?.. Юк, Сәүбән иртән күргән малайга охшамаган... Бу бит тоташ ак! Әллә берәр рух яисә убыр-ут йөриме? Зират тирәсе бит, нәрсә булмас!
Сәүбән, үзен-үзе белештермичә, шул якка борылды. Бу юлы аны аң-зиһене дә, җан-йөрәге дә йөртми, бу юлы, кулыннан җитәкләп, аны язмыш-тәкъдире йөртә иде, ахры. Маңгай күзе белән күрмәсә дә, күңел күзе белән ап-ачык тоя, күрә ул — бу ак тап (рух, ат, кош, кеше?) теге качкын малай язмышы белән, бәлки, Сәүбәннең үз язмышы белән дә турыдан-туры бәйләнгән...
Ләкин Сәүбән инеш буена төшеп, аръяктагы калкулыкка күтәрелгәнче, теге аклык каядыр китеп югалган иде инде. Ул артык борчылмады, бер килгәч-килгәч, әрәмәлеккә кереп чыгыйм, теге юньсез малайдан хәбәр-хәтер булмасмы дип, юлын дәвам итте. Әмма әрәмәлек аны телсез, мәнсез кыяфәттә каршы алды. Адашып килеп чыккан җилбәзәк җил кызы гына кайбер куакларның яфракларын тарткалап китә... Ниндидер сәер тынлык. Шомлы тынлык. Яңгыр алдыннан гына була торган тынлык. Юк ла, нинди яңгыр булсын мондый аяз көндә?! Бу шомлы тынлык күршедәге зират ягыннан суырылып, ургылып керә, ахры...
Сәүбән, җанын алдындагы сихри-шомлы күренештән кубарып алырга теләп, ниндидер котылу чарасы эзләп, авыл ягына колак салды. Аның күңеленә, колагына еракт ан тонык кына ишетелеп торган көтү тавышы, мал-туар авазлары кереп тулды. Сәүбәнгә рәхәт булып китте. Ул, җанын учына кысып, авыл ягыннан килүче «тормыш тавышларын» югалтмаска тырышып, тәвәккәл адымнар белән зиратка таба китте. Сәвия малае шунда качып ятмыймы? Ул үзе аңлый иде: Сәвия малае сәбәп кенә. Зиратка ул әткәсенең җан-рухы чакырганга керде, ахры...
Каберстанда йөргәндә, Сәүбән аптырап йөрде: нигәдер каберләр тәртипсез урнаштырылган, рәтләр-урамнар тигез, матур тезелеп китмәгән монда... Күңелдәге хисләр, хатирәләр кебек...
Сәүбән, йөри торгач, ниһаять, атасының каберенә килеп чыкты. «Әткәй җаным, син шушында ятасыңмыни? Рухың тынычмы, авыр туфрагың җиңелме, үзең оҗмахтамы?» — дип сораштыра баш-

лады ул, үзе генә белгән җан телендә. «Төн кергәндә нишләп йөрисең монда, улым? Курыкмыйча ничек килә алдың бу әрвахлар бакчасына?» Сәүбән тагын үзе генә белгән телдә җавaплады: «Бер дә йөрмәс идем, әткәй җаным, бүген иртән минем тормышыма бер бала язмышы килеп кагылды. Ниндидер сер бар аңарда, сердән дә бигрәк, сихер бар…» Шул ук тавыш, әтисенең тавышы: «Ул — синең улың, минем оныгым була. Читкә типмә аны, каты сүз әйтеп рәнҗетмә, ул — миңа караганда да, сиңа караганда да өстенрәк, бөегрәк җан, аның сере Кала-тау белән, йолдызлар белән бәйләнгән… Бар, шуннан эзлә ул серне…» Сәүбәндә дә үҗәтлек, әрсезлек җитәрлек икән: «Кала-тау зур бит. Кайсы җиреннән эзлим мин аны? — дип гасабилы, ялварулы тавыш белән сорады ул.— Оныгыңны кайдан эзлим?» Бу юлы аңа беркем дә җавап бирмәде. Теге сәер, таныш булмаган тел дә шул минутта онытылды… Сәүбән бу телнең балачак рухы тарафыннан уйлап чыгарылуын, әткәсенең тавышы шул рух тавышы икәнен, ул рухның кайдадыр якында гына торуын белми калды. Ул: «Хыялланам бугай инде»,— дип борчылып уйланды, китәргә җыена башлады.

Әткәсенең зәңгәрсу-яшел чирәм каплаган кабере белән саубуллашты, кул кушырып дога укыгандай итте, аннары, карашын куе болытлар җәелә башлаган күккә төбәп, хәтер савытының төбендә «әбиле» бала чагыннан калган «күк арбавын» көйли башлады:

Күк өстендә йолдыз бар,
Җирдә җирән кондыз бар…
Якты йолдыз җиргә бага,
Күккә бага ялгыз яр…

Күк йөзендә йолдыз бар,
Җирдә җирән кондыз бар…
Якты йолдыз җиргә төшә,
Күккә менә ялгыз яр…

Күк йөзендә йолдыз бар,
Җирдә җирән кондыз бар…
Якты йолдыз җирдә яши,
Күктә яши ялгыз яр…

Зираттан чыга-чыгышка ук күреп алды ул таныш аклыкны. Бу аклык инде күз күреме җирдә — Кала-тауга илтә торган юл буенда җемелди иде. Аның ак күлмәк кигән, ак яулык бәйләгән хатын-кыз булуында бернинди дә шик калмады. «Ярый әле убыр рухы булмады, шундук афәткә юлыктырыр иде бугай, бәласеннән башаяк», — дип сөйләнә-сөйләнә, Сәүбән адымнарын кызулатты.

Әрәмәлек буенда, зиратта йөреп, ул шактый вакытын югалтты, күктәге караңгылык куера барып, аның бер як читеннән ургылып килеп чыккан кара болытларның һаман ярсып, әрсезләнеп үрмәләвен күргәч, Сәүбән йөгерә үк башлады. «Ничек тә Кала-тауны, андагы тау куышын карап өлгерергә кирәк. Караңгы төшкәнче, авылга кайтып җитәсе дә бар бит әле», — дип уйлап алды ул. Күктәге караңгылыкның кичке эңгер генә булмыйча, яңгыр галәмәте дә булуын ул әле белми иде.

Бу уй аңа әле җәйге кояш нурларын онытып өлгермәгән җылы чигәсенә кунган беренче салкын тамчы белән бергә килде. Сәүбән ышанмады, хәтта бу хакта ныклап уйларга да кыенсынды: «Бусы тагы нәрсә? Юк, булмастыр, каян килсен ул?! Яңгыр алдыннан аз гына җил уйнатып ала. Анысы да булмады…» Чынлап та, теге тамчы ниндидер ялгыз, бәхетсез, саташкан тамчы булып чыкты, ахры. Сәүбән, тынычланып, Кала-тауга илтә торган юл очында җилфердәгән ак күлмәк артыннан, ул ак күлмәккә төрелгән ниндидер бик газиз җанның үзенә якынлыгын, туганлыгын тоеп, йөгерә-атлый баруын дәвам итте…

Шулай бит ул: буласы нәрсә барыбер була. Күктә ургылып, кайнап торган яңгыр болытлары барыбер бервакыт гөнаһлы җир өстенә шыбырдап коелырга тиеш иде.

Сәүбән бу юлы аптырамады. Яңгыр тек яңгыр! Авылга ерак. Ничек тә тизрәк Кала-таудагы мәгарә авызына барып җитәргә, яңгыр үтеп киткәнче шунда посып торырга кирәк. Калганы — Ходай Тәгалә кулында…

Бу минутта Ходай Тәгалә аны оныткан иде: кинәт килеп коя башлаган яңгыр астында Сәүбән бик тиз күшекте, суга төшкән чебеш хәлендә калды, киемнәре дә соңгы җебенә кадәр юешләнде. Ул, капчыгын, андагы азык-төлекне, шырпы ише нәрсәләрне сакларга теләп, якындагы яр буеннан әрекмән яфраклары өзде, аларны капчыгы өстенә ябып, тыгызлап бәйләп куйды.

Мәгарә авызына юл ерак иде әле. Шактый мышнарга туры килде. Менә ул — инеш, чишмә… Сазлык, камышлык… Юкәләрнең шомлы шәүләсе… Өстә — кыя стена. Ул яңгырда бик куркыныч икән: акрын гына авып барган кебек… Монда инде юл тигез, тапталган… Димәк, мәгарәгә керүчеләр бар. Кемнәр йөри икән монда? Сәвия малаеның килүе хак инде. Анысын белә Сәүбән. Шуңа күрә дә монда инде ул. Шушында гына булса ярар иде… Инде соң бит… Өйгә кайтырга кирәк, җылы өй сагындырды!..

Сәүбән мәгарә авызына тәмам мышнап, ах-ух килеп барып җитте. Менә хикмәт: җитүен җитте, әмма, керергә чирканып, аның каршында катып калды. Куркумы бу? Нидер тоеп, сизеп, каушап калумы? Үзе дә аңламады. Әмма шуны аермачык белә иде: мәһабәт ерткыч җанвар авызы кебек ыржаеп ачылып торган бу тау куышы тиздән аның үзен генә түгел, аңа газиз булган бүтән җаннарны да кабып йотачак, аларны яңадан-яңа сынауларга дучар итәчәк.

Өстән койган яңгыр шулкадәр көчле иде, Сәүбән бөтен шик-шөбһәләрен, шомлы уйларын онытып, кайчандыр аның өчен иң изге урыннарның берсе булган тау куышына ничек атлап керүен сизми дә калды. Дөресрәге, кемдер аны аркасыннан этеп-төртеп кертте, ахры.

Килеп кергән уңайга бөтен гәүдәсе белән селкенеп, кагынып алды. Яңгыр биргән бөтен авырлыкны — дымны, салкынлыкны алып ташларга теләде ул. Ләкин бу дым, бу салкынлык аның тәненә бөтен теше-тырнагы белән ябышкан иде шул.

Сәүбән иң элек капчыгын салып куйды. Коеп яуса да, кичке яңгыр күк читендәге ак тасманы һаман каплап бетерә алмый әле, шуңа күрә мәгарә алдындагы киң мәйдан шактый ачык шәйләнә. Тегендә-монда агач-такта кисәкләре ята, менә учак урыны да бар. Сәүбәннең куркына башлаган күңеленә җылылык йөгерде: димәк, монда еш булалар, ул кадәр үк куркырлык түгел…

«Якты чакта учак әзерләп куярга кирәк, — дип уйлады ул. Кибенәсе дә бар бит әле, аннары, хәшәрәт рухлар уттан куркучан булалар…» Үзалдына елмаеп куйды. Һаман шул рухлардан арына алмый икән ул. Күңеленә нидер булды, ахры, аның. Ул бит хәзер рухларны күреп йөри, алар белән сөйләшә, аралаша… Гайре табигый хәл ләса бу! Тукта! Кая китте соң әле теге ак рух? Әй, нинди рух булсын, ак күлмәкле хатын иде лә ул… Әллә чынлап та рух булып чыктымы? Әйтик, Кала-тауның рухы. Сәүбән аны соңгы мәртәбә шушы тау авызына якын гына күргән иде...

Чынлап та, юк бит… Әнә бөтен җир буш… Хет берәр җан әсәре булсын…

— Ә мине кая куясың?

Сәүбән дертләп китте. Коты ботына төште, ботында гына калмыйча, табанына ук төшеп ятты.

— Син дә йөргән буласың… Куркытып үтерә яздың бит, каһәр!— Сүгенәсе дә килә иде, Сәүбәннең теле әйләнмәде. Ул нидәндер, кемнәндер кыенсынды. Әйе шул, кемдер бар кебек бу мәгарәдә. Кемдер аңа төбәлеп карап тора кебек…

Капчык эчендәге әйберләр әллә ни юешләнмәгән. Сәүбән иң элек шырпысын эзләп тапты, аннары,ваграк агач ботаклары җыеп, урта бер җиргә учак тергезеп җибәрде.

— Бар, тик торганчы утын җыеп кайт, бу яңгырның туктарга уйлаганы да юк, өс-башны да киптерәсе бар. Син бит рух, син чыланмыйсың…

— Нәрсә, көләсеңме әллә миннән? Рухи зат булганга күрә җыя да алмыйм инде мин.

— Шулай бит әле. — Янында буталып йөрүче малайга нык ачуы чыккан иде Сәүбәннең. Шул гына аның күңелен тынгысыз итте, шуның аркасында гына булмаган малаен эзләп, адәм көлдереп йөри ул… Тукта-тукта… Сәвия малае да шушы тирәдә — якында гына булырга тиеш ләса! Бәлки, ул менә хәзер мәгарә эчендәге караңгылыктан Сәүбәннең сәер кыланмышларын, тиле кеше шикелле үз-үзе белән сөйләшеп йөрүләрен күзәтеп торадыр? Аның башына бер сәер уй килде: әгәр теге малай монда икән инде, Сәүбән аны хәзер кызык итәчәк, мәгарәнең эчке авызына якынрак килеп, юри куркытып караячак…

— Йөрмә, үзең үк үкенәчәксең.— Моны Сәүбәннең балачак рухы әйтте.

— Кит әле моннан! Буталма аяк астында!

— Үзең кара, миннән әйтү булсын…

Сәүбән, иелеп, учактан бер зур кисәү алды. Аны алгарак сузып, ауга чыккан җанвар кебек сак кына атлап, мәгарәнең тамак төбенәрәк узды. Һәм:

— Чык аннан, явыз зат, чыкмасаң, утта көйдереп үтерәм, — дип, ярым пышылдап, тамак төбе белән кычкырды…

Мәгарә тишеге авыр тынлык белән җавап кайтарды. Юк-юк, бу тынлык олы бер бәланең башы гына булган икән. Шунда мәгарә авызының кайсыдыр аралыгыннан: «Ах!» дигән иңрәү авазы ишетелде һәм аның артыннан ук Сәүбәннең аяк астына бер ак шәүлә авып төште. Бу шәүлә — аның кайчандыр җан атып йөргән сөйгәне — Сәвиянең һушсыз гәүдәсе иде…

## 12

Укучы колагына әйтәсе килгән бер сүзем бар: Беләсезме, иң озын гомерле мәхәббәт нинди мәхәббәт? Беренче мәхәббәт! Чөнки ул беркайчан да бетми. Сәүбән белән Сәвия дә кайчан да булса очрашуга, аңлашуга, димәк, мәхәббәткә дучар иделәр. Менә ул сәгать сукты.

Сәвия бик озак аңына килде.

Ул башта төш күреп ятты. Имеш, ул — әле генә туган сабый — бишектә ята, әнкәсе салмак кына тирбәтә. Бишек әле бер якка, әле икенче якка тайпыла. Шулай тирбәлә торгач, ул бишеге-ние белән

әнкәсенең кулыннан ычкынып китә дә... галәм киңлегендә очып йөри башлый. Як-ягында йолдызлар, йолдызлар... Каяндыр йолдыз җиле килеп чыга да бишекне үзе белән уйнатып алып китә. Менә бервакыт ул бер яшькелт-зәңгәр шар өстенә килеп төшә. Зәңгәр шар дигәнең йолдыз-планета икән. Анда да шундый ук йолдызлар, шундый ук урман-кырлар, шундый ук Кала-тау, Рух чишмәсе... Шундый ук кешеләр... Улы Сәүбән дә шунда ук. Кызы-ы-к... Сәүбән инде үсеп җиткән, ә Сәвия үзе бишектә ята, имеш.

Улы шул бишеккә иелеп сорый:

— Әнкәй, минем әткәй бармы?

— Бар, улым, бар синең әткәң. Ул әнә теге койрыклы йолдызда.

— Нинди йолдыз ул, әнкәй?

— Җир ул, балам, әткәң әнә шул Җир исемле гүзәл йолдызда яши...

— Нигә койрыклы соң бу Җир?

— Койрык түгел, Кояш нурларының чагылышы ул. Җир — Кояш иркәсе, Кояш улы. Ә безнең Чулпан йолдызы — Кояшның сөйгән кызы...

— Әнкәй, Җиргә еракмы?

— Ерак, бик ерак...

— Минем Җиргә барасым килә...

— Әйдә, бишегемә ябыш! Нык тотын, Җиргә — әткәң йолдызына очабыз...

Алар тагын очып киттеләр. Яшькелт-зәңгәр планета еракта калды. Төрле төстәге йолдызларны узып, аклы-күкле болытларны кичеп, Җир өстенә килеп төштеләр. Әрәмәлек буендагы иң матур урынга туры килделәр... Әнә гөлҗимеш куаклары, шомырт-балан агачлары, чикләвек, чия рәтләре... Сәүбән шул агачлар арасында уйнап йөри башлады. Зират... Сәүбән шул зират эченә кереп китә дә тагын чыга, кереп китә дә тагын чыга... Ә бер кергәч... Бер кергәч ул чыкмады. Сәвия бик курыкты... Йөгереп барып, зиратны айкап йөри башлады. Юк. Монда ул юк!.. Сәвия, зираттан чыгып, Калатауга таба китте. Малае шундадыр кебек тоелды аңа. Ләкин ул тауга барып җитә алмады, коеп яңгыр ява башлады... Якындагы авылга таба борылмакчы булды. Ләкин бу ниятеннән шундук кире кайтты. Чөнки авыл ягыннан аңа таба таныш түгел кеше йөгерә иде. Сәвия бик курыкты. Ул, үзенүзе белештермичә, Кала-тау алдындагы олы мәгарәгә кереп китте, түргәрәк үтеп, стенадагы бер тар аралыкка посты. Куа торган кеше, яңгыр эченнән атылып чыгып, Сәвия торган тау куышына килеп керде... Караңгыда йөзе күренми, юк ла, күренә икән. Аның йөзе — ниндидер таныш, газиз, кадерле йөз. Бу бит Сәүбән! Сәвиянең бердәнбер улы! Әле генә каядыр китеп югалган Сәүбән бит бу! Нигә карт соң ул? Ир урталары булыр аңа... Йөзен җыерчыклар баса башлаган, чәченә ак кунган, тик... йөзендәге яра җөе генә аныкы түгел... Кем соң бу? Аның малае кайда? Нәрсә булган аңа? Нинди яра җөе ул? Кайда җәрәхәтләнгән? Бервакыт бу таныш йөз якыная, зурая башлый. Зураеп кына калмый, кызара, алсулана... Нәрсәдән бу алсулык, бу кызыллык? Әһә! Ут-учактан төшә икән ул. Җылы... Хәтта эссе! Ә теге таныш йөз, иелеп, якын ук килеп, сынап, үз итеп, яратып карый. Үзе, дога укыган кебек, бертуктаусыз пышылдый. Тик бу дога бер генә сүздән тора.

— Сәвия... Сәвия... Сәвия...

— Сәүбән балам... Синме бу?.. — Сәвия малаеның йөзен сыйпамакчы, аны иркәләмәкче, назламакчы була, әмма ни өчендер кулын кузгата алмый... Тормакчы була, тора алмый, нидер әйтмәкче була, теле әйләнми... Шул хәлсез килеш ул кабат үз йолдызына — Чулпан исемле яшькелт-зәңгәр планетага очып китә. Тик бу юлы янында Сәүбәне юк инде, ул әткәсе янында — Җирдә торып калган...

Тирә-якта йолдыз яңгыры! Әмма бу юлы алар әрнеп сулкылдыйлар, ара-тирә барысы берьюлы ыңгырашып, ахылдап куялар. Бу вакытта бөтен Галәм иңрәп тора кебек:

— Ыһ!.. Ыһ!..

...Сәүбән ыңгырашып, саташып яткан Сәвия янында төне буе бөтерелде. Әллә куркудан, әллә бәрелүдән, хатын буынын-сынын гына түгел, аң-зиһенен, һушын да тәмам югалткан иде. Ләкин саташуында өмет бар — бертуктаусыз малаен чакыра, Сәүбәнгә эндәшә, димәк, ул әле тормыштан аерылмаган, язмыштан каерылмаган...

Сәүбән ара-тирә: «Сәвия, Сәвия!..»— дип дәшеп куя. Уянмасмы, янәсе. Сәвия әлегә йоклый, җиде төн йокылары белән йоклый. Бу йокыдан уятырга ярамый, шуңа күрә Сәүбән көтә. Янып бетә язган учагына утын ташлый, тагын Сәвия янына килеп утыра, аның, айнып, торып утырганын көтә.

Сәүбәннең өс-башы инде күптән кипкән. Ул үзе дә, учак янында утырып, куырылган борчак кебек була язган. Сәвияне дә учак янына яткырды ул, астына камыш үлән алып кереп түшәде, баш очына капчыгын җәйде. Егылганда ташка төшкән, ахры, башында — нәкъ чигә турысында — кан тамчысы саркып чыккан. Сәүбән аны сөртеп, җәрәхәт урынын чистартып куйды. Хәзер көтәсе генә калды... Сәвия уянганчы, таралып-чәчелеп яткан уйларны җыясы, аны бер бәйләмгә туплап, күңел

күчәренә беркетеп куясы калды. Юкса бу көтелмәгән хәлләрдән Сәүбән үзе дә миңгерәүләнер дәрәҗәгә җитте бит…

…Каршында ярым һушсыз хәлдә пәйда булган Сәвия гәүдәсен ул башта нишләтергә дә белмәде. Кайсыдыр явыз рух дивана итәргә теләп шаяртадыр, дип уйлады Сәүбән.

Каяндыр килеп чыгып, янында утырган бала чагы гына:

— Нишләп карап каттың?! Сәвия бит бу, синең яшьлектәге сөйгәнең, безнең сөйгәнебез — Сәвия… Кара аны, тәрбиялә, дәвала, назла… Тиз бул, бар, күтәреп ал, учак янынарак сал. Әнә бит куркуыннан җан очыра язган, мескен… Әйттем мин сиңа, үз башыңа җилкенәсең, дидем… — дип сөйләнде.

Сәүбән дәшмәде. Каршы дәшәрлеге дә юк иде. Малай кушканча, Сәвиянең элеккечә зифа, җиңел гәүдәсен күтәреп алды да учак янынарак китереп яткырды. Уята башлады…

Тик аны янындагы бала чагы шундук туктатты:

— Бераздан үзе уяна ул, хәзергә тыныч кына йокласын. Аның җанын куркытырга, өркетергә ярамый, чынлап та чыгып качуы бар. Әйдә, урын-җир әмәллә, киемнәрен киптер, чишмәдән су алып мен…

Сәүбәннең күз карашларын Сәвиянең йөз-чырае, суырып алгандай, үзенә тартып алды. Ах итәрлек тә иде шул. Хатынның йөз чалымнары моннан унсигез ел элек ничек булса — шулай калган… Күз читендәге берничә көяз җыерчыкны исәпләмәгәндә… Чәчләре дә шул ук. Бит очындагы «мәхәббәт чокыры»… Ул да шул килеш. Бу «чокыр»га аның чык җыеп эчкәне бар иде. Күзләр нинди икән? Һаман зәңгәрме? Күрәсе иде үзләрен!

Тукта, нишләп йөри соң ул монда? Шунда гына Сәүбән аңышып алды: аның бит малае югалган, шуны эзләп йөридер. Сәүбән дә шул малайны эзләп чыккан иде бит… Димәк, теге ак тап, ак күлмәк Сәвия булган? Ниһаять, уйларының очы-очка ялгана язды. Тик менә бер нәрсә генә аның акылына сыймады: малай кайда соң? Мәгәрә эчендәге оясында булса, мондагы тавышка, ут-учак яктысына күптән чыккан булыр иде… Ә тышта яңгыр ява да ява… Тышта дөм караңгы!..

Сәүбәннең зиһенен, тынгылык бирмичә, тагын бер уй йөдәтте. Ул аны якын китерергә теләмәсә дә, тегесе һаман үҗәтләнеп, иң алга чыгып, күкрәк киереп тора башлады: «Бәлки, ул малай авылдадыр, өйдәдер инде?»

Тукта, бу хакта бала чагыннан сорап караса?

— Сорасы-нитәсе юк, авылда юк ул. Ул — монда. Эзләгез, табыгыз. Тик… ашыгыгыз. Соңга калуыгыз бар.

— Ни дигән сүз инде бу? Ничек соңга калуыбыз бар? Әйтеп бетер, әйтә башлагач инде…

— Болай да тиешеннән күбрәк әйттем.

— Нәрсә әйттең соң? Куркытасың да куркытасың. Шул гына. Мин бит сиңа чит кеше түгел, менә шушы анасы хакына булса да әйт, зинһар!.. Кешеме син, юкмы? Нәрсә, каршыңа тезләнгәнне көтәсеңме? Менә тезләнәм… Хәзер әйтәсеңме?

— Йә, тор, болай түбәнлеккә төшмә. Син бит — мин. Ә мин кечкенәдән горур идем. Безгә килешми… Әйттем бит инде — малаебыз исән. Ашыгырга кирәк, тауга афәт якынлаша, бәла килә…

— Тагын куркытасың… Ичмасам, менә Сәвиягә булышыр идең. Син бит рух, рух! Синдә әллә нинди тылсымлы шифалар бар! Булмаса, сәламәтлегемнең бер өлешен ал да Сәвиягә бир, зинһарлап сорыйм, болай калдырма аны…

— Җитте, әллә нинди гөнаһ сүзләр сөйләмә. Сезнең гомер белән уйнарга мин бит Ходай Тәгалә түгел. Кеше гомере бары тик аның кулында гына, мин берни эшли алмыйм. Әмма Сәвияне аякка бастырам… Үзе торыр дигән идем, вакыт бик аз калды, шуңа күрә, тылсымымны биреп булса да терелтәчәкмен, ләкин беренче һәм соңгы мәртәбә эшлим бу эшне. Кеше, тылсымга күнексә, ихтыяр көчен, яшәү мәгънәсен югалта башлый, омтылышларыннан, көрәштән баш тарта, мескенләнә…

Сәүбәннең балачак рухы үзенең гайре табигый хезмәтенә кереште: учак янында хәлсез-хәрәкәтсез яткан Сәвия янына килеп, уң кулын алга сузды, бераз шулай тотып торганнан соң, уң якка таба хәрәкәтләндереп, үзе генә күрә торган боҗра буенча әйләндереп йөртә башлады (бәлки, «яшәү боҗрасы»дыр?).

Шул вакыт Сәвия дертләп, уянгандай итте, калтыранып куйды һәм тора башлады. Сул кулын хатынның түшенә куеп, малай аны кабат яткырды. Сәвия терелгән, уянган инде, әмма күзен ачмаган әле. Күзен ачмыйча торып, кеше аңлы тормышка кайтып җитә алмый. Сәүбән моны үзе дә белә.

Малай Сәвия гәүдәсе өстендә тоткан учын тагын бер-ике мәртәбә йөртеп алды. Ниһаять, Сәвиянең керфекләре калтыранып куйдылар, әмма әлегә ачылмадылар.

Малай кул хәрәкәтләрен кызулатты һәм Сәүбәнгә таныш дога сүзләрен пышылдады:

— Мәтә… Тикә… Умма… Йәрсә… Иллә… Әнни… Һунни…

Сәвия күзләрен ачты. Зәп-зәңгәр күз алмаларын тәгәрәтеп бөтен тирә-юньне айкап чыкты, бераздан, Сәүбәннең өзелеп, борчылып карап торган карашларына юлыгып, тукталып калды.

— Сәүбән…
— Сәвия…
— Сәүбән, синме бу?
— Мин бу, Сәвия, мин… Уяндыңмы, терелдеңме? Сиңа терелмичә ярамый, малаеңны табасы бар бит… Сәүбәнеңне…
— Сәүбәнне? Кайда соң ул? Кая куйдың аны, нишләттең?.. Сәвия, борчылып, тора ук башлады.
Сәүбән аны сак кына кире яткырды:
— Ят, ят, Сәвия. Сиңа хәл җыярга кирәк. Сәүбәнеңне табабыз без, менә күрерсең. Иң мөһиме — ул исән. Мин шуны төгәл беләм.
— Нигә Сәүбәнеңне дисең, Сәүбән? Ул бит синеке дә…
Сәүбән аны тагын саташа дип уйлады. Тынычландыра башлады. Тегесе һаман үз сүзен тукыды:
— Синең бала ул, Сәүбән. Ул үзе дә моны белә. «Әткәй янына барам» дип киткән иде… Шул китүеннән кайтмады… Нишләттең аны, нәрсә дидең син аңа?
— Сәвия, ни сөйлисең син? Каян минем бала булсын ул? Бөтенегез берьюлы шаштыгызмы әллә? Унсигез ел кайтмаган кешенең ун яшьлек малае була аламы, йә, әйт?! Була аламы?
— Була, Сәүбән, була… Чаллыны исеңә төшер… Стройотряд белән килгән идек… Минзәлә педучилищесы кызларын хәтерлисеңме? Дөм караңгыда ике отряд, берләшеп, дискотека оештырган идек… Аннары бер бүлмәдә икәү генә калдык… Ул илаһи төнне, ул назларны оныттыңмыни?
Сәүбәннең күңелендә гөлт итеп моннан унбер ел элек булган вакыйгалар балкып-кабынып китте. Бу хәтер балкышыннан ул шашар дәрәҗәгә җитте.
Әмма каяндыр кырып-себереп:
— Син идеңмени ул? — дип әйтерлек көч таба алды.

## 13

Ул җәйне алар Чаллыдан ерак түгел генә тавык фермасы төзеделәр. Эш ахырына якынлашып килә, һәркемнең кәефе шәп. Кесәдәге өр-яңа иллелек-йөзлекләрнең шыгырдавы ишетелә башлаган вакыт. Бердәнбер көнне отряд буенча: «Бүген кич кызлар кунакка килә!» — дигән хәбәр таралды. Күптән кызлар йөзе күрмәгән егетләр: «Каян, каян?» — дип каңгылдаштылар. «Минзәләдән, педучилищедан»,— дигәч, күпләрнең шунда ук кикрикләре шиңде. «Әллә ни кырып булмый икән, укытучы халкы, битеннән суырып үпсәң дә: «Әнигә әйтәм», — дип үкереп елый башлый»,— дип, бөтенләй кәефсезләнгәннәре дә булды.
Шулай да күпләр Минзәлә кызларын каршы алырга хәлләреннән ничек килә шулай әзерләнә башладылар. Эштән иртәрәк кайттылар, яши торган барак идәннәрен, бер-ике сәгать лачкылдатып җебеткәннән соң, гөжелдәтеп юып чыгардылар, карават өстенә җәелгән одеалларның рәсем-сызыкларына кадәр җеп буенча тигезләп чыктылар, бүлмәләрне җилләттеләр, хыялыйраклары якындагы яланнан кыр чәчәкләренә кадәр алып кайтып куйды. Ә үзләрен, үзләрен ничек карадылар! Чәч кисү, чәч ясау, чәч тарау китте, җитү сакал-мыеклар юкка чыкты, әллә күпме одеколон исраф ителде, аяк киемнәренә сөртә торган кремның иң соңгы запаслары юкка чыгарылды… Күлмәкләрнең киң, озын якалысы, тар биллесе, чәчәкле-чачаклысы, чалбар балакларының өстән тараеп төшеп, аста хатын-кыз итәге кебек җәелеп китә торганы…
Сәүбән дә нык әзерләнде. Иң яхшы киемнәрен чыгарды. Юынды, чистарынды, хушбуйны кызганмады, күршедәге кыр буеннан күгәрчен күзләре өзеп кайтып, суга утыртып куйды.
Кич җитте, ә кызлар юк та юк. Егетләр, көтә-көтә, бөтен тәмәкеләрен тартып бетерә яздылар, кайберләренең йөзенә «аракы елмаюы» да кунып өлгергән. Кемдер музыка җибәрде, егетләр, кылана-кылана, «тән яза» башладылар. Кызлар белән күрешү насыйп булмаса да, күпләр үзләренең җыештырылган бүлмәләре, чистарынган тәннәре, ымсынып-дәртләнеп алган җаннары өчен чын күңелдән сөенәләр иде.
Ниһаять, эңгер төште. Тирә-юнь караңгы пәрдә белән капланды. Штаб урнашкан барак өстенә эленгән лампочкадан тонык кына ут төшә, биер өчен билгеләнгән мәйдан ай-йолдыз ихтыярында калган…
Егетләр һаман таралмыйлар. Егет күңеле сизенә бит ул, әнә трасса ягыннан чиный-чиный бер иске генә машина килеп чыкты да, пырхылдап, штаб каршына ук килеп туктады. Аның ачык әрҗәсеннән, бер-берсе белән шаяра-шаяра, барысы да бертөрле форма кигән, түшләренә орден планкалары кебек бихисап күп значоклар тезгән кызлар коелыша башлады. Алар сикереп төшә тордылар, бер рәткә тезелә тордылар.
Авиаторлар бу йоланы беләләр иде, — тиз генә җыелышып, икенче якка тезелеп бастылар. Ниһаять, ике отряд та җыелып, тезелеп бетте. Командирларның, бер адым алгарак чыгып, бер-берсен тәбриклисе генә калды.

— Минзәлә педучилищесының «Чулпан» отрядыннан кайнар... Сәлам!

— Казан авиация институтының «Икар» отрядыннан космик... Сәлам!

«Сәлам»нәрен отрядлар хор белән әйттеләр. Аннары танышу башланды. Баштарак отрядлар хакында белешмәләр игълан ителде, аннары командирлар, комиссарлар белән таныштырдылар.

Егетләр күзләрен ничек кенә чекерәйтеп карасалар да, караңгылыкта беленер-беленмәс басып торучы кызларның йөзен аермачык күрә алмадылар. Бу аларның кәефен бераз җибәрсә дә, бөтенләй кызларсыз биеп йөрүгә караганда әйбәтрәк иде.

Кызлар сан ягыннан шактый ким иде, шуңа күрә Сәүбән бүген биюгә катнашмаска булды. Кызларның йөзен, сынын, хәрәкәтен күрү бик мөһим иде аның өчен. Ул гел шулай: кешеләрне күзләренә карап якын итә, күзләренә карап ярата йә яратмый. Күзен дә күреп булмаган кыз белән ни дә сөйләшә алмас иде ул. Аның күзләрен, җанын аңлый алмас иде. Чөнки җан күзләр белән сулый, күзләр белән күрә, күзләр белән ярата...

Музыка башланганчы, ыгы-зыгы киткәнче кереп ятыйм дип кузгалган гына иде, кемдер Сәүбәннең җиңеннән тыйнак кына тарткандай булды. Борылып карамакчы иде, арттан йомшак, назлы кызлар кулы аның күзләрен каплап алды.

Шундый ук йомшак, назлы тавыш:

— Чур, карама, син мине күрергә тиеш түгел; бүген мин синең хуҗаң, ә син минем колым булырсың...

Сәүбән аңына килгәнче, йомшак куллар кай арададыр аның күзләрен яулык белән бәйләп тә куйдылар.

Сәүбәннең бу хакта да ишеткәне бар. Егетләр-кызлар очрашкан вакытта, кызлар азрак булса, алар, егетләрнең күзләрен бәйләп куялар да теләгән кешеләре белән туйганчы бииләр, имеш...

Салмак көй куйдылар, Сәүбән баягы кыз белән вальска басты. Салмак бию ритмына йөзеп-биеп киттеләр. Кыз бик матур йөртә, Сәүбәнгә аның авылчан нык, әмма үтә дә назлы кулын тою рәхәт иде. Үзе бии, үзе уйлый: «Шундый җиңел гәүдәле, нечкә билле, зифа сынлы бу кызның күзләре, чәчләре нинди төстә икән?! Тавышы... Ниндидер таныш тавыш!.. Кайдадыр ишеткәне бар, ахры. Тукта, бу бит авылда калган Сәвиясенең тавышы! Кулы да, гәүдәсе дә... Юк ла... Каян килсен ул монда? Үз Сәвиясен танымаска инде... Сәвия үзе дә шундук танып алыр иде. Онытталмый шул ул Сәвиясен — шуңа күрә дә янында биеп йөргән һәр кыз аңа сөйгәне булып күренә, ахры...

Кыз күп сөйләшмәде. Исемен дә әйтмәде. «Бер матур сер булып калыйм әле тормышыңда»,— диде дә бетерде.

— Күрмәгәч, матурлыгыңны каян белим соң мин?— дип сөйләнде Сәүбән.

— Ә синең уйланганың бармы: туган җир — читкә киткән саен матурая, кеше, киресенчә, якынрак килгән саен матурая, шуңа күрә туган җирнең гүзәллеген читкәрәк китеп кара, кешенең гүзәллеген якынрак килеп кара...

— Фәлсәфәдән башка гына әйтсәң, ничек була инде?

— Кешенең гүзәллеге күңелдә димәкче идем, бу тормышта күрү-күрмәү мөһим түгел, иң мөһиме — кешенең күңел сыйфатлары, аның асылы, яшәү мәгънәсе...

— Монысы белән килешәм... Алайса, ник үзең дә күзләреңне япмыйсың?

— Чөнки мин сине болай да беләм.

— Ничек?

— Менә шулай! Мин бит йолдызлар белән сөйләшәм. Алар миңа синең хакта барысын да сөйләп бирделәр.

— Яле, берәр нәрсә әйтеп кара.

— Хәзер әйтәм... Син... Син — авыл малае. Анаң белән үскәнсең... Абыең бар... Яшьлегеңдә берәүне сөйгәнсең, әмма, авылыңа рәнҗеп, читкә киткәнсең, яраткан кешеңне бәхетсез иткәнсең...

— Стоп! Син кем? Боларны каян беләсең?

— Әйттем бит инде, йолдызлардан, дип...

— Син әүлиямы әллә?

— Бәлки, әүлиядыр да...

— Тагын берәр нәрсә әйтеп кара әле.

— Синең күзләрең зәңгәр, чәчең җирән...

— Анысын үзем дә беләм.

— Битеңдә яра җөе бар...

— Анысы да күренеп торган җирдә. Әйт әле, минем әткәй бармы?

— Әткәң бар, әмма ул башка хатын белән яши. Әткәң дә зәп-зәңгәр күзле...

— Дөрес... Безнең авыл хакында ни әйтә аласың?

— Авылыгыз читендә олы тау бар. Аның мәгарәләрен бик серле диләр. Күктән кораб төшкән диләр аңа...

— Чынлап та, син бит бөтенесен дөрес сөйләп барасың? Каян син? Кем син? Берәр җенме әллә? Пәриме?
— Әйтмим… Шуны гына әйтәм: авылда ялгызын ташлап калдырган сөйгәнең бүген дә япа-ялгыз. Ул һаман сине көтә, сине өзелеп ярата, белдеңме?..
— Ә мин аны яратмыйм. Ул миңа хыянәт итте.
— Ничек хыянәт итте?
— Башка егетләр белән йөри башлады. Минем авылдан чыгып китүемә дә шул хыянәт сәбәп булды…
— Син әле хыянәтнең нәрсә икәнен белмисең икән.
— Нәрсә соң ул?
— Бөтен күңел хыялларын, йөрәк хисләрен таптап-изеп, язмыштан каерылып, илдән аерылып, туган туфракны, нигезне, җир-суны ташлап китү — менә ул чын хыянәт!
— Оялтмакчы буласыңмы?
— Юк, аңлатмакчы булам.
Шулай алар әйләнделәр дә әйләнделәр. Башкалар, заманча биюләргә күчеп, боргаланып-боргаланып сикерә башладылар, ә бу ике җан әллә кайчангы танышлар кебек һаман бер көйгә — күңелләрендә яңгыраган сихри, моңлы бер көйгә салмак кына талпынуларын белделәр. Алар гүя бөтен дөньяларын оныттылар, икәүдән-икәү генә калып, бер-берсенә иң изге, иң садә, иң сагышлы һәм әрнүле серләрен ачалар иде...
Сәүбәннең күңелендә теге, баягы уй бөтерелә: ничек охшаган ул Сәвиягә! Бик сагынган кешең пәри кызы булып куеныңа керер, диләр бит. Әллә берәр сихер эшеме бу?
— Син үзең каян соң, исемсез кыз?
— Мин — Чулпан йолдызыннан.
— Юк ла, мин отряд исемен сорамыйм, туган авылың кайда, дим.
— Туган авылым — нәкъ Чулпан йолдызы астында минем. Шуңа күрә безнең авыл өстендә күк матуррак, йолдызлар яктырак… Отрядыбызга да шул исемне куштырдым…
— Син бик сәер сөйләшәсең, әмма бу сөйләшүең миңа ошый… Син үзең дә миңа бик ошыйсың.
— Мин сиңа кемнедер хәтерләтәмме?
— Хәтерләтәсең шул…
— Кемне?
— Авылда минем сөйгән кызым бар иде. Кара, бая син үзең шул хакта тел чарлап тордың бит… Минем өчен ул юк инде… Син менә шул кызны хәтерләтәсең… Хәтта тавышларыгыз да охшаган…
— Әйдә болай итәбез. Бер минутка гына мин сөйгән ярың булам.
— Бу мөмкин түгел! Хәтта күз алдына китерү дә мөмкин түгел! Ул… ул бик оялчан иде. Ә син әнә ничек чатнап торасың…
— Ничә ел үткән бит инде, бәлки, ул да бераз кыюлангандыр... Бәлкем, ул да безнең кебек кайдадыр төзелеш отряды белән йөридер…
— Син бит әүлия, йә, әйтеп кара — йөриме-юкмы?
— Йөри… Әнә йолдызлар аның юлын сызып күрсәтәләр. Бүген ул бәхетле, әнә йолдызлы күк астында яраткан кешесе белән бию әйләнә…
— Яраткан кешесе бармы аның?
— Бар, бар!..
— Бик тиз оныткан икән мине…
— Онытмаган ул сине, онытмаган!.. Тиле син! Чын тиле! Шуны да тоймыйсың!..
— Тоймыйм шул. Аның каравы сине тоям. Син миңа якын, кадерле, газиз… Беренче күрүдә үк гашыйк булуга ышанмый идем… Мин сиңа күрмичә дә гашыйк булдым, ахры…
— Син миңа күптән гашыйк инде...
— Тагын серле сөйләшәсең…
— Бетте-бетте! Башка сөйләшмим.
— Сөйләшмә. Шушында бетерәбез дә таралышабыз…
— Биюләр кызып кына бара бит әле…
— Арыдым мин. Син дә минем күңелне җилкеттең, үткәндәге хисләрне, сагышларны кузгаттың… Үзеңә дә гашыйк булып барам, ә бу бик куркыныч…
— Син шулай куркак тамыни әле?
— Мин бер әйбердән генә куркам: алданудан. Бер тапкыр алдандым инде…
— Тотмыйм, бар, кер. Әйдә мин сине озатып куям.
— Анысы всегда пожалуйста! Тик бездә дөм караңгы.
— Ә мин караңгыны яратам!
— Кара, мин дә төнне яратам бит…

Сәүбән күзләрен каплап торган яулыкны чишеп, кызга бирде. Хәтсез вакыт капланып торган күз алларында аллы-гөлле бөҗралар уйнаша иде.

Алар, култыклашкан килеш, Сәүбән торган баракка барып керделәр, почмакта басып торган парны өркетмәскә тырышып, сак кына атлап, бүлмәгә уздылар. Сәүбән, кармаланып үзенең түшәген эзләп тапты, дәшми-нитми генә килеп утырды. «Исемсез» кыз ишек төбендә калды.

— Ярый, мин чыгыйм инде,— диде ул, күпмедер дәшми торганнан соң.

Сәүбән үзе күптән телсез иде.

Кызлар белән ялгыз калгач нәрсә эшләргә кирәклеген әлегә белми иде ул. «Бар, чыгып кит»,— дип әйтеп булмый бит инде. Аннары... Чыгарасы да килми аны. Янына утыртып сөясе, иркәлисе, үбәсе килә! Авылда калган Сәвиясенең бөтен чалымнары бар бу кызда, нигә сөймәскә?! Шул Сәвиясенә охшатып сөя ала бит ул аны!

— Кил әле, утыр...

— Чыгыйм инде, югалтырлар...

— Кил әле...

Кыз тавышка төбәп килеп җиткәндә, Сәүбән аңа үз янында урын әзерләгән иде инде.

— Килдем...

— Утыр...

— Утырдым...

— Бер сүз әйтсәм, көлмисеңме?

— Көлмим.

— Көлмә, яме. Мин сиңа гашыйк булдым.

— Син дә миңа ошыйсың.

— Мин сине бик күптәннән беләм кебек, шуңа да кадерле, якын, ахры, син...

— Мин дә күптәннән беләм... Минем сине сөясем, назлыйсым килә...

— Минем дә сөясем-сөеләсем килә...

— Кил мондарак... Кадерлем минем...

— Кадерлем... Бердәнберем...

Мәхәббәттә иң мөһим сүзне хатын-кыз әйтә. Сәвия ул сүзне әйтмәде. Дөресрәге, әйтә башлады, әмма әйтеп бетермәде...

Бу ымсыну, тартылу, бу сөешү, кавышу кинәт үзеннән-үзе килеп чыкты.

Соңыннан бу хакта Сәүбәннең күп мәртәбәләр уйлаганы булды: кызлар янына барып сүз катарга да кыенсынып йөргән кеше, беренче очрашуда ук ничек итеп түшәк кайгысына бирелде соң? Сәүбәннең бу уйлары билгесезлек белән бәхәс, хәтта көрәш кебек иде. Шуңа күрә дә ул соңыннан бу җан изасына бик кагылырга тырышмады. Кайсы яклап кына килеп уйласа да, бу сорауга барыбер җавап тапмаячак иде ул.

...Баштарак аларның җаннары тәннәреннән оялыбрак торды. Беренче оялу, тартыну үткәч, алар сөю назларының иң югары катына мендeләр. Сәүбән үзен сәер тотты, ничек кенә онытырга тырышса да, Сәвиясенә карата булган ихлас хисләрен һаман күңеленнән тиз генә чыгарып ата алмады. Шуңа күрә баштарак Сәүбәннең үбү-назлары әллә ничек кенә ясалма һәм килбәтсез чыкты бугай... Сәвия үзе үбә, назлый башлагач кына Сәүбәнгә җан, шул җан белән бергә егетлек һәм тәвәккәллек иңде. Бу кичтә Сәвиясен хәтерләткән Минзәлә кызы назның иң мавыктыргыч һәм иң тылсымлы катларына алып менде, аны бәхетле итте, үзе дә бәхеткә тарыды...

Бу татлы мизгелләрне Сәүбән күңеле белән мәңгелеккә ятлап калды. Тәннәре аша татлы калтырану узды... Наз аның тәнендәге һәр күзәнәгенә үтеп керә, һәр күзәнәген бәхетле итә иде... Кызның тулышкан күкрәкләре ымсындырып, чакырып тора; Сәүбән аларны күрми, әмма бөтен ирлеге белән тоя... Тәннәре киеренкелектән тораташ кебек каткан иде, бу кыенсыну бик тиз узды, сеңерләр, бушанып, тәннәренә татлы сызлану тараттылар...«Мин үземне синең өчен сакладым...» Аның, Сәүбәннең, хәтта кыз авызыннан чыккан бу сәер сүзләр хакында уйларга да вакыты юк иде, ул сөйде, назлады, тагын сөйде... Сәүбән төшенде: күзләрне йомган килеш сулыш алсаң — тәнгә хәл керә! (Бу ачыштан ул рәхәт кычкырып куйды һәм тагын мәхәббәтле кыз гәүдәсе өстенә капланды.) Кызның зәңгәр күзләреннән дә олы, мәһабәт сөю карап тора иде... Чәченнән су исе, чишмә исе, бөтнек исе килә... Ул бу чәчләрне өскә чөеп җибәрә дә суда коенган кебек коена... Бу чәчнең назыннан үләргә генә мөмкин иде... Бу юлы инде аларның тәненә ниндидер татлы сыеклык тулган кебек матур хис тула башлады... Әллә җанына туламы? Бу мизгелдә аның җанын-тәнен — барысын бергә тау кебек авырлык басты. Сәүбән бу минуттан үз язмышына искиткеч зур җаваплылык алуын тойды... Аның өчен бөтен тормыш өр-яңа мәгънәгә ия булган иде. «Менә хәзер үләргә дә була»,— дип уйлады ул. Сәер хәл: аның җаныннан шик-шөбһә, курку качкан... Үз-үзе белән көрәшүдән туктаган иде ул... Аз гына яратып булмый шул. Ярату — йә бар, йә юк... Бар, димәк, ярату көчле; юк, димәк, ул бөтенләй юк! Вәссәлам! Бу хакыйкатьне аңлау Сәүбәнне алдагы котылгысыз бәладән — ихлас күңел дөнья-

сын югалтудан саклап калды, ахры… Бу кавышу минутлары Сәүбән өчен җан һәм тән чистарынуы иде. Чистарынуның бер юлы сагыш булса, аның икенче юлы — кавышу могҗизасы икән! Кавышу мизгеле хакыйкатькә шундый якын тора!

— Сәүбән, син Аллага ышанасыңмы?

— Күккәме?

— Юк, Аллага.

— Мин Алланы күк кебек, йолдыз кебек күзаллыйм, Сәвия. Шундадыр аның асылы.

— Юк, Алла ул башка. Ул… ул… зуррак…

— Аны гына мин дә беләм. Тик барыбер йолдызларда яши кебек ул. Берни дә эшли алмыйм — шулай тоям мин аны…

— Сәүбән…

— Әү, Сәвия.

— Алланың мәгънәсе нидә, беләсеңме?

— Нидә булсын, изгелектәдер, аннары… көчтәдер. Бөтен нәрсәгә караганда да көчлерәк бит ул.

— Минемчә, Алланың мәгънәсе көчтә түгел, ә хакыйкатьтә.

— Нигә алай дисең, Сәвия?

— Хакыйкать кичерүгә сәләтле, ә көч — юк.

— Син хаклы, Сәвия…

…Сәүбән кызның ничек чыгып киткәнен сизми дә калды. Кай арада җыенып өлгергән! Колагына: «Хуш, кадерлем минем, бүләгең өчен рәхмәт, мин мәңгегә синеке! Синеке генә!..» — дип пышылдады да йөгереп чыгып та китте, зәңгәр күзләре, җирән чәче генә күз алдында калды. Әйе, нәкъ Сәүбәннәр авылындагыча: зәңгәр күзле, җирән чәчле. Нәрсә бу? Очраклы хәлме? Их, сорарга онытты бит. Әллә сарманайлыларның берәр туганымы?

Сәүбән ул кичне оныта алмады. Ниндидер серле, сихри төш булып, хәтеренә ягылып калды. Бу кичтә татыган назларын соңыннан башка кешеләрдән эзләде, таба алмады. Аның бөтен бәхетсезлеге дә шушы кичтән башланды, ахры…

Аңына килеп, тышка йөгереп чыкканда, кызларның машинасы кузгалырга тора иде инде. Кузов өстенә баскан кызлар арасыннан күпме генә эзләсә дә Сәүбән әле генә аның йөрәгенә кереп кадалган, мәхәббәткә тулышып торган чая кызны таба алмады.

Сөю — бәйрәм түгел, ә авыр эш һәм олы җаваплылык. Сәүбән моны тоеп белә иде, әмма ул күңелен бу хакыйкатькә ышандырса да, тормышын аңа көйли алмады…

Кызлар отряды атна саен килеп йөри башлады. Ләкин Сәүбән теге кызны башкача очратмады. Сораштырып та карады: белүче мазар булмады. «Пәри шаярткандыр»,— дигән карарга килеп, Сәүбән бала чактагы догаларын яңартты, бу серле-тылсымлы вакыйганы Ходай Тәгалә сүзе белән йолып калдырырга теләде…

## 14

— Син идеңмени ул төнге фәрештә? Ә мин, тиле, «пәри кызы» дип уйлый яздым… Күпме эзләттем мин сине соңыннан!.. Суга төшкән кебек юкка чыктың…

— Беләм, Сәүбән… Мин бит дивана түгел. Син мине һаман ярата идең, әмма күзләреңдә рәнҗеш күп иде. Бу рәнҗешкә төшеп үләсем килмәде минем. Аннары… Мәхәббәттә горурлыкны югалту — сөйгән кешеңне югалту белән бер дип уйладым ул вакытта. Горур булып калырга тырыштым. Бәлки, башкачарак килеп чыккандыр? Ялганлап, яраткан кешеңнең түш астына яту горурлыкны аяк астына салып таптау белән бердер.

— Ничек шулай начар уйлый алдың? Ник ачылмадың? Ачылсаң, аңлар идем әле, үзем дә аңлатыр идем... Ә бала? Баланы нигә ятим иттең? Ул бит минеке, Сәвия, шулаймы?

— Синеке, Сәүбән…

— Их син, Сәвия!..

Сәүбән учак янында яткан Сәвияне түшәгендә калдырып, торып китте, арлы-бирле йөренә башлады… Ул бу минутта үзен дә, җанын да, хисләрен дә кая куярга белми газаплана иде.

Шулай шул, үткәндәге ялгышларны төзәтүгә караганда битәрләү, сүгү җиңелрәк…

Сәвия хәлсез, әмма күркәмлеген югалтмаган йомшак тавыш белән сөйләп китте:

— Мин сине әллә каян күреп килдем. Машина әрҗәсеннән сикергәндә дә, рәткә тезелгәндә дә синнән күземне алмадым. Йөгереп барып кочаклыйсым килде, яратасым, шашып үбәсем килде… Түздем. Горурлыгым җибәрмәде. Калганын син үзең дә беләсең…

— Беләм? Нәрсә беләм соң мин. Берни дә белмәдем мин ул вакытта! Белгән булсам!.. Мәңгегә үземнеке итәр идем, йә… йә куып җибәрер идем…

— Куар идеңме?

— Куар идем. Чынлап та, нык үпкәләгән идем мин сиңа. Белмим… Бәлки… кумас та идем. Мин бит сине җанымнан артык күреп яраттым…

— Мин бик бәхетле идем ул төнне, Сәүбән. Кайтканда, белгән бөтен догаларымны укып, Ходай Тәгаләдән ялварып сорадым: «Сәүбәнемнең баласы тусын иде, ул да Сәүбәнгә охшасын иде, исеме дә Сәүбән булсын иде!» — дип теләдем.

— Син бигрәк инде. Исемне Ходай Тәгалә куша димени?!

— Шулай теләдем, һәм теләгем кабул булды, исемен дә Сәүбән дип куштым, димәк, Ходай Тәгаләгә шулай кирәк булган.

— Баланы ялгызың таптыңмы?

— Ничек табыйм инде?

— Иргә чыкмадыңмы дип соравым…

— Юк, чыкмадым. Хатын түшәгендә беренче йоклавым иде, сездән кайтканда хәлсезләнеп егылганмын, йөзем агарып каткан, күз алмаларым мәрткә тәгәрәгән… Кайтканның икенче көнендә үк хастаханәгә салдылар, аннан отрядка кайтып тормадым — авылга киттем. Каникул көннәрендә, сине сагынып, төннәр буе елап яттым. Балага узганымны белгәч, тагы еладым. Үзем сөенәм, үзем үкереп елыйм…

— Их син!.. Белдекле баш! Ә мин анда… сине бөтен Минзәлә буенча эзләп йөрим! «Кайда ул кыз, имеш, кайда ул кыз?!» Исемен дә, чуртын да белмим, үзем эзлим! Гүя офыкка барам, барам… Җитеп булмый… Ә үзем беләм: офыкка җитеп булмау офык юк дигән сүз түгел әле… Их син…

— Ачуланма миңа, Сәүбән, шулай булган, димәк, Ходай шулай теләгән. Көчле йөрәктә генә мәхәббәт матур була. Син көчсез идең ул вакытта. Шул көчсез чагыңда ташлап киттем мин сине…

— Укуыңны тәмамлый алдыңмы соң?

— Тәмамладым анысын. Корсагым шактый күпергән иде инде. Белделәр. Соңгы ел булгангадыр, артык бәйләнмәделәр. Кырын карап йөрүче берничә укытучыдан кала, барысы да хәлемә керде. Очраган бер кешедән бала тапмасымны беләләр иде алар…

— Ә эшкә, эшкә ничек урнаштың?

— Укуны тәмамлаганчы ук, хат җибәреп, бер башлангыч мәктәптә урын алып калган идем. Июньдә бала табып, сентябрьдә эшкә чыгармын дип уйлаган идем. Мин уйлаганча булып чыкмады. Әллә инде кара күз яшенә манчылып тугангa, әллә ятим булып яшисе килмәде, — Сәүбәнем туган көненнән үк каты авырый башлады. Үлә, диделәр. Мин дә озак кына мантый алмадым. Икебезне ике якка аердылар. Үзем чак исән ятам, үзем баламны сорыйм икән. Төннәр буе саташып, мендәр имезеп чыккан чаклар да булган…

— Их син! Мин бу вакытта бөтен отрядлар буенча эзләп йөрдем. Тагын чыкмаганмы, янәсе. Ә син… үлем авызында гомер кичеп яткансың… Мендәр имезеп… Их!..

— Көзен эшкә бардым. Мәктәп мине сагаеп каршы алды. Уйнашчы хатын кебек кабул иттеләр. Төпсез чиләк дигән кушамат ябышты. Бу кушаматым укучылар арасына, алар аша бөтен авыл халкына күчте. Кеше почмагының түренә сыйсаң да, күңеленә сыймыйсың, диләрме әле? Ул авыл мине күңеленә сыйдыра алмады. Озакламый эштән чыгардылар, һәм мин, уку елын да бетермичә, Сарманайга кайтып киттем. Ир-атсыз өйдә кояшлы көндә дә эңгер булыр, диләр бит. Минем өйгә дә кояш кермәде. Кояш урынына Сәүбәнем булды. Бердәнбер көнне әнкәй җан тәслим кылды, тормыш берүземә торып калды. Түз генә!.. Бөтен тарих шул, Сәүбән…

— Юк, бу — тарихның башы гына әле, Сәвия. Синең чын тарихың Сәүбән белән башлана. Әнә бит нинди егет үстергәнсең!

— Үсүен үсте дә, менә бәлагә тарыдык бит…

— Анысын бергә җиңәрбез, Ходай кушса…

— Җиңәрсез… Болай күз яше сыгып утырсагыз, җиңәрсез…

Сәүбән шунда гына янында басып торучы бала чагын исенә төшерде.

— Син нәрсә, көнләшәсеңме әллә? Бу бит минем язмыш! Минем язмыш — синең язмыш та ул. Көнләмә, яме…

Каршында яткан Сәвияне сискәндереп, Сәүбән үз рухы белән сөйләшә башлаганын сизми дә калды. Тик соң иде инде…

— Сәүбән? Үз-үзең белән сөйләшәсеңме-е-е? — Сәвия кискен хәрәкәтләр ясап торып утырды, Сәүбәнгә курку тулы күзләре белән карап тора башлады.

— Юк ла… Минем үз тарихым бар, Сәвия. Менә, авылга кайткач, бала чагымны очраттым…

— Ничек — бала чагыңны?

— Әйе, әнә ул әле дә янымда тора.

— Сәүбән, сиңа ни булды? Ник алай сөйләшәсең?— Сәвия күзләрендәге курку көчәйде. Ул хәтта, тезләрен кочаклап утырган килеш, читкәрәк тайпылгандай булды.

— Курыкма, Сәвия. Мин тиле дә, дивана да түгел. Ләкин миңа чынлап та нидер булды. Мин чынлап та үземнең бала чагымны очраттым… Һәм шуны аңладым: бала чактан соң Ватан башлана. Балачак кичерсә дә, Ватан кичерми…

— Сәүбә-ә-ән, әле дә яныңда утырамы ул?

— Әйе, әнә бит…

— Нинди ул, матурмы?

— Балачак ямьсез була димени. Матур, ипле, ләкин артык серьезный. Аннары, бик үпкәчел…

— Синең кебек икән…

— Бәй, мин бит инде ул, Сәвия.

— Тотып карыйм әле, ә, ярыймы?

— Ярамый, менә монысы инде ярамый.

— Нигә?

— Ул бит рух, Сәвия, рухи зат! Аңлыйсыңмы? Аны тотып та, күреп тә булмый.

— Ә нигә син күрәсең соң?

— Мин болай уйлыйм: бала чаклары кешеләргә аларның иң авыр чакларында, гомер юлларының иң кискен борылмаларын ураганда килә. Миңа да шундый вакытта килде бугай ул. Авылга кайтып төшүгә, басу капкасы төбендә утырып тора иде инде.

— Кызы-ы-ык..

— Мин аны синең Сәүбән белән дә бутадым. Шундый охшашканнар алар…

Малае телгә керү белән, Сәвия тагын күңелсезләнде. Йөзендәге елмаю чалымнары юкка чыкты, күзләре моңсуланды…

— Кайда йөри икән инде ул, җанкисәгем минем?

— Ул исән, ул якында гына, Сәвия, борчылма…

— Тынычландырасың гына син мине.

— Юк, чынлап та шулай! Ул исән. Кайдадыр якында гына. Миңа бу хакта бала чагым әйтте.

— Бала чагың? Каян белә ул?

— Ул бит рухи зат, Сәвия. Рухлар барысын да беләләр!

— Белгәч, сорыйк. Сәүбәннең кайда икәнен төгәл генә әйтсен дә, барып алып кайтыйк.

— Бөтен хикмәт тә шунда: без аны үзебез табарга тиеш, аңлыйсыңмы?

— Ни өчен, Сәүбән?

— Чөнки ул безнең язмыш. Һәр кеше үз язмышына үзе хуҗа булырга тиеш…

— Син бит акыллы кеше, Сәүбән. Сүзләрең дә акыллы синең. Тик мин борчылам, Сәүбәнгә берр хәл булмагае дип борчылам….

Өзгәләнеп, ачыргаланып сөйли башлаган Сәвия, тылсымлы магнит кебек, Сәүбәнне үзенә тартып дигәндәй алды. Сәүбән, арлы-бирле йөренгән җиреннән, туктап, аның каршына килеп тезләнде һәм хатынның яшькә чыланган йөзен күкрәгенә алды. Сәвиягә шул гына кирәк иде, ахры. Әллә бәрелүдән сызлаган, әллә ялгыш кына уйлаганда да диванага сабыштырырлык гамьле уйлардан әрнегән башын Сәүбәннең җылы куенына төртеп, үксеп елап җибәрде… Юк, малаен югалту кайгысыннан гына еламый иде Сәвия. Ул бу күз яшьләре белән гомере буе җыелган җан ачысын агызып бетерергә тели иде, ахры…

Учак инде күптән сүнгән. Яңгыр туктаган. Мәгарә авызына таң пәрдәсе эленә башлаган. Сәүбән үзе дә нык арыды. Күп йөрүдән дә, йокысызлыктан да түгел, Сәвиясен, малаен табу шатлыгыннан арыды ул…

— Ятып, йоклап ал, иртән сиңа хәл-егәр кирәк булачак. — Моны бала чагы әйтте. Сәүбән җавап бирмәде, Сәвияне куркытудан шикләнде. Ә хатын һаман елый, Сәүбәннең күкрәгенә ятып, аның куенына елышып, ике кулы белән кысып кочаклап, сулык-сулык елый да елый…

Бая әзерләгән түшәк ярап куйды. Сәүбән, сак кына кагылып, Сәвияне үләннән ясалган шул түшәккә яткызды, аннары үзе дә аның янына сузылып ятты, башын үлән мендәргә төртте, аннары, үрелеп, Сәвиянең чигәсеннән үбеп алды… Сәвиягә шул гына кирәк иде: ул кискен генә Сәүбәнне үзенә таба тартты, аны тагын кысып кочаклады, шул кочаклаган килеш тынып калды… Бераздан хатынның сулышы тигезләнде, Сәүбән аның сабыйларча мышнап йоклавына тәэсирләнеп ятты. Йоклавына гына микән? Яшьлегендә күп назлаган зифа, сылу тәннең тагын янында булуын, ләззәткә, шатлыкка, бәхеткә ымсындырып, мәхәббәткә-сөюгә чакырып торуын тойды. Әмма кагылмады. Йокларга ниятләп, чытырдатып күзләрен йомды. Йокы кермәде.

— Йоклый алмыйсыңмы? Гырлап йоклап китсәң бик сәер булыр иде.

— Их син!..— Сәүбән авыр сулап куйды. Ул һич аңламады, аның бу авыр сулавы бала чагына эндәшүе идеме, әллә үз-үзенә соңлап әйтелгән шелтә булдымы?

Мәгарә эчен тагын тынлык басты. Кыя читеннән тамып торган ялгыз тамчы тавышы гына бу сихри тынлыкка җан ишарәсе биреп тора. Кайдадыр кошлар сайрый башлады. Димәк, яңгыр басыл-

ган. Таң якынлаша… Ике якта ике кош ярсып-ярсынып бер-берсенә хәбәр бирешәләр… Сак белән Сокның тавышы кебек иде бу.

Сәүбән, мәгарәнең төпсез түшәменә караган килеш, адрессыз-нисез генә әйтеп куйды:

— Йә, нишләргә миңа, нишләргә?

Бала чагының коры, кискен тавышы әмер кебек яңгырады:

— Яшәргә!— Бу тавыш бераздан, йомшап, ниндидер сихри, серле аһәңгә төренеп, тагын кабатланды: — Яшәргә…

— Ничек яшәргә?

— Кеше булып яшәргә. Йөрәгең, җаның тойгандыр — бүгеннән тормышыңның мәгънәсе зурайды, яшәвеңнең максаты киңәйде…

— Һәм катлауланды,— дип өстәде Сәүбән.

— Катлауланды, дөрес. Әмма мәгънәсе зурайды! Сиңа хәзер авылдагы улың өчен дә яшәргә туры киләчәк! Менә бу бәхетсез хатынның язмыш юлы да синеке белән янәшә барачак хәзер…

Сәүбән барысын да аңлый, әлбәттә. Күңеле дә, билгесезлектән, чарасызлыктан түгел, ә тәгаен аңлап, аңышып сызыла, сызлана… Бу сызлану, газаплы сызланудан бигрәк, татлы сызлану иде.

Менә аның тагын бер малае барлыкка килде. Тагын бер газиз җан… Юк, Сәвия аның хатыны түгел. Ул аның яшьлек рухы, мәхәббәт рухы, бәхет рухы. Рух ул. Күреп булса да, тотып карап булмый торган, сөеп, назлап, үзеңнеке итеп булмый торган рухи зат. Балачак рухы кебек… Әнә бит ул һәр рухи зат, фәрештә-мәләк кебек, гүзәл, саф, илаһи… Ул аның хатыны түгел! Ул — Ходай Тәгалә ихтыяры, Илаһи Күк ишарәсе… Гомумән, бөтен изге, кадерле, җанга якын әйберләр дә — Күк ишарәсе, Күк ымы… Явызлык кына — җирдән…

«Барыбыз да Күккә кайтасы»,— ди иде аның әбисе. Ягъни мәңгелеккә. Яшибез, нидер исбатларга тырышабыз. Ә бит яшәүнең бөтен мәгънәсе каян килүдә һәм кая китүдә… Изгелек кылуга корылган Мәңгелек Тәгәрмәченең хәрәкәте, Җирдәге ваклыкны, явызлыкны чит-чатка чәчә-чәчә, һаман Тәңре ихтыярын үтәп торачак…

Шушы Мәңгелек Тәгәрмәченең җиленә өрелеп очасың да очасың… Канатың булса инде… Канатың булмаса, Җир сазлыгына егылып төшәсең, соңгы сулышыңа кадәр шунда тыпырчынып ятасың…

Бу талпынуның җан үзәге кайда? Мәңгелек Тәгәрмәченең күчәре, Күк белән Җирнең, Тау белән Үлемнең, Әлмисак белән Кыямәтнең уртасы кайда?

Телдә «Җирнең тарту көче» дигән сүз бар. Бу сүзгә бөтен тереклек дөньясының яшәү мәгънәсе салынган. Ә менә «Күкнең тарту көче» хакында беркемнең дә ныклап уйланганы юк, ахры. Уйланмасалар да, кайбер кешеләр моны бик ачык тоялар, бөтен гомерләрен шушы тоемда, ягъни Күк, Галәм ихтыярында яшиләр. Сәүбән дә шундый кеше, ахры. Ул да канатлы бугай. Бар аның, бар канатлары, пар канатлары!.. Читтә яшәгәндә, ул аларны югалткан кебек иде, ә менә авылга кайткач, апачык тоя башлады: иңнәре үтереп сызлый, канат авырлыгыннан җаны сызлый, бәгыре — канат төбе гел канап тора…

Бу көннәрдә Җир белән Күк арасын иңләп күп талпынды шул Сәүбән. Авыртыр, сызлар да… Канатлы кешегә, оча торган кешегә бәхет барыбер табыла ул. Сәүбәнгә, бәхет булып, малае Сәүбән табылды. Башта ул рух булып күренде, аннары тормыштан йөгереп керде… Хәзер аның өч малае булды. Тагын өч пар канаты…

Шәһәрдә калган малае, гаиләсе нишли икән? Шунда Сәүбән күңелендә бер нечкә кыл чыңлап куйды. Онытa язган ласа ул аларны! Ачынып уйланды: күңеленең тагын бер почмагын рәткә, тәртипкә саласы бар икән — гаиләсе урнашкан җирен...

…Шәһәрдәге Сәвиясенә яратып өйләнде Сәүбән. Озак эзләп, тәмам арып, алҗып килеп тапты ул хәләл хатынын. Әллә шуңа инде, йөрәгенә нык алды ул аны, ихлас җанын биреп, һәрдаим өтәләнеп яши башлады. Яшәмәде, бөтен барлыгын, гомерен багышлады.

Авылдагы Сәвиясен бар көченә онытырга тырышты ул. «Авыл» дигән олы дөньяның соңгы капкаларын ябып, аңа иң нык йозакларны салды. Ә хәтер чишмәсен олы бер таш белән (шәһәрдә таш күп бит) каплап-томалап куйды. Үткәндәге хатирәләр, азмы-күпме саркып ятса да, элеккечә шаулап-гөрләп акмый иде инде.

Ләкин Сәүбән авылдан бөтенләйгә котыла алмады. Җирдә яшәп, Күкне танымау, аны күрмәскә тырышу кебек иде аның бу тормышы. Күккә карамау анда Кояш, Ай, йолдызлар, Чулпан юк дигән сүз түгел бит әле. Кояш барыбер яктырта, Ай моңсуландыра, йолдызлар — өмет, хыял, ә Чулпан… яшәү мәгънәсе бирә… Авыл белән дә шулай. Андагы Кояш та, Ай да, йолдызлар да, алар арасындагы Чулпан да һаман бар, һаман яши, аларның барысы да вакыт юлында мәңгелек сәфәрдә… Бу хакта авылдан килеп торган әнкәсе дә, туган йортка кайткалап йөрүче абыйсы да, әллә нигә бер керүче авылдашлары, балачак дуслары да, күктә йөзгән каурый болытлар да (Сәүбән аларны авыл моржаларыннан чыккан төтенгә охшата), яңгыр да (аңарда Рух чишмәсенең тамчылары да бар кебек),

җил дә (авылның тыны-сулышы булса, җил әнә шул тын-сулыш булып килә сыман) — тагын бик күп нәрсәләр «авыл күген» онытырга ирек бирмиләр иде.

Авылын оныта алмаса да, Сәүбән үзенең беренче мәхәббәтен оныта алды. Онытмаган да булыр иде, Яшәү Гаме дигән олы бер көч аны, бөтереп алып, тормышның урау тыкрыкларына кертеп җибәрде, аннары иң тирән чоңгылларына илтеп ташлады.

Әйбәт яшәделәр. Яратышып яшәделәр. Үзара хөрмәт белән яшәү генә түгел, мәхәббәт белән өртелгән тормыш иде бу. Ләкин Сәүбән барыбер дә тулысынча бушанып, үткәндәге хисләреннән, хатирәләреннән туарылып яши алмады. «Җан хәтере» дигән нәрсә бар бит, шул булды, ахры, Сәүбән үз җанын «яңа» Сәвиясенә өзеп кенә алып бирә алмады. Эчтә, бик тирәндә сулкылдап, әрнеп яткан бу «җан хәтере» кайчакта «тән хәтере»нә әверелде, кайчакта «аң хәтере» булып тынгысызлады. Әле ул Кала-таудагы юкә кәүсәсендәге «мәхәббәт мөнбәре» булып, әле Чаллыдагы «пәри кызы» кыяфәтендә күз алдына килде.

Ә бит мәгълүм нәрсә: җан ял итәргә тиеш түгел. Җан бертуктаусыз эшләргә тиеш. Сәүбән исә озак еллар буе җанын эшсез тотты, шуңа да ул вакытсыз картая башлады, ахры…

Балалары үсеп аякка басканчы сизелер-сизелмәс кенә сызлап яткан бу «хәтер» бигрәк тә соңгы елларда туктаусыз бимазалап интектерде. Йокысы начарланды, булганы да тоташ төштән тора иде.

Кеше җаны Күк белән Җир арасында талпынып, бәргәләнеп яшәгән кебек, Сәүбән дә күңеле белән Казан — Сарманай арасында талпынды, шул илаһи аралыкта яшәде. Аның өчен Казан тир сеңгән Җир булса, авылы ымсындыргыч изге Күк иде. Канат чыкканчы, иңенә каурый кунганчы оча алмасын Сәүбән белеп яшәде. Әмма ул канатланыр көненең килерен дә төгәл белә иде. Һәм менә ул көн җитте… Күк капусы ачылган, Галәмнән хәбәр, чакыру килгән көн иде ул.

Сәүбән авырып түшәккә егылды. Нигә, ни өчен — белми дә, сизми дә калды. Белерлек хәле дә юк иде. Төнлә балконга чыгып, йолдызлы күккә карап торырга ярата ул. Төнге күкне яхшы белә. Шул йолдызлар белән сөйләшеп, гәпләшеп йөргән көне иде. Әнә бер читтә Чулпан-Венера калыккан. Бөтен тирә-юньдә йолдызлар сикерешә — теләк теләргә өлгер генә, ә менә Чулпан тирәсендә хәрәкәт сизелми.

Чулпан янында йолдыз атылу юньлегә түгел. Ул йолдызның шаукымы Җиргә төшә. Җирдә җан яки тән авыруларының күчәюе Чулпан тирәсендәге йолдызларның хәрәкәтенә турыдан-туры бәйләнгән. Шул якта берәр йолдызның атылуы була, кешеләр егәрсез, буынсыз һәм ихтыярсыз калалар, буыннары гына түгел, зиһеннәре дә йомшый башлый, хәтерләре ялгыша, тәкатьләре бушый, күзләре сукырая, телләре тотлыга…

Сәүбән әнә шундый йолдызга юлыкты. Халыкта аны «йолдыз авыруы» яисә «йолдыз шаукымы» дип йөртәләр. Үз күзләре белән карап, күреп, күңеле белән тоеп, теләп, сорап алгандай алды ул бу авыруны. Гөлт итеп кабынып китте дә, аска — Сәүбән яшәгән Җиргә таба атылды ул йолдыз. Артыннан шырпы сызганнан соң чыга торган ут сызыгы гына чәбәләнеп калды. Шул минутта ук Сәүбән үзендә хәлсезлек сизде. Буыннары тотмас, зиһене эшләмәс булды, теле тотлыгып, иреннәре, әйтәсе сүзен әйтә алмыйча, ярдәм сорап кычкыргандай ярым ачылган килеш катып калдылар… Сәүбән, гөрселдәп, балкон идәненә авып төште. Тавышка хатыны, малае йөгереп чыкты. Күтәреп өйгә алып керделәр, түшәккә салдылар. Малае, «ашыгыч ярдәм» машинасы чакырырга дип, күршегә кереп китте.

Сәвия нишләргә дә белмәде. Ары чапты, бире чапты, әмма Сәүбәннең хәлен җиңеләйтер әмәл тапмады. «Ашыгыч ярдәм» белән килгән табиблар да әллә ни кыра алмадылар — Сәүбәннең тәне, зиһене, рухы бер генә уколны, даруны да кабул итмәде. Авыруны ничек бар шулай носилкага салдылар да аста көтеп торучы машинага алып төшеп киттеләр.

Сәүбән хастаханәдә өч көн хәрәкәтсез ятты. Ярым йомык күзләренең ара-тирә калкынып куюы тәнендәге чыкмаган җанга ишарәләп торса да, бу көннәрдә ул тере мәет хәлендә яшәде.

Табиблар диагноз куя алмый интектеләр. Консилиум җыеп, иң яхшы белгечләрне чакырып, әйләндерә-әйләндерә күрсәттеләр. «Психик тетрәнү» дигән сүздән ерак китә алмадылар. Терелергә, аякка басарга берничә ай, бәлки, берничә ел вакыт кирәк булачак, өй шартларында, яхшы тәрбиядә тагын да иртәрәк терелер, диделәр. Терелеп бетмәскә дә мөмкин, гомерлек түшәк иясе, йә аяксыз, телсез калуы бар, акылга да бераз зәгыйфьлек киләчәк, диделәр.

Сәүбәннең фаҗигасен Сәвия бик авыр кичерде, үз фаҗигасе кебек кабул итте. Әмма өйгә алып чыгарга ашыкмады. Баштарак көн саен килеп йөрсә дә, бераздан көнаралаш, атнага бер генә күренә торган булды. Бер ай чамасы шулай күренгәләп йөрде ул. Ә бердәнбер көнне, Сәүбәнне хастаханәдәге практикант кызлар кулына калдырып, җәй елга бер генә килә, отпуск әрәм була дигән сылтау белән, үсмер малаен ияртеп, җылы якка китеп барды.

Сәүбән бу көннәрдә ачык тоеп, аңлап яшәде: бөтен нәрсәне югалткан очракта да бер нәрсә һәрвакыт кала — киләчәк. Киләчәк өметтән дә өстенрәк. Ул хыял белән янәшә. Ә Сәүбәннең бервакыт-

та да хыялыннан баш тартканы булмады. Аның бу хыялы бары тик авылы, туган нигезе белән генә бәйләнгән иде.

Шар кебек күзләрен тәгәрәтеп ятучы Сәүбән үзенең аянычлы, мөшкел хәлен бик тиз аңлап алды. Караучысыз, гаиләсез, кирәксез җан булып өч көн ятканнан соң абыйсы аша әнкәсен чакыртты. Ах-ух килеп, палатага Рәмзия килеп кергәндә, ул йоклап ята иде. «Балам!.. Үлгән!..» — дип, өстенә килеп капланган анасыннан өркеп, аның ачыла башлаган теле кабат тотлыга язды.

Рәмзия савытларга салып чишмә суы алып килгән. Кала-тау төбендәге Рух чишмәсен изге, суын шифалы диләр бит. Иң элек Сәүбәннең бөтен тәнен шул су белән чылатып юып чыкты. Аннары шул ук суны аз-аз гына каптырып, озак итеп эчерде. Эчерер алдыннан нимдидер үлән яфраклары салып тотты. Әллә әнкәсен күрү куанычыннан, әллә шифалы чишмә суыннан, Сәүбән авырганнан соң беренче мәртәбә йокыга оеды. Тәмам йоклап китәр алдыннан ул әнкәсенең колагына: «Мин... торганда... безнең... авыл... догасын... укы... әле... Кала-тау... догасын... Йолдыз... догасын...» — дип, чак пышылдарга өлгерде.

Аннары ул төш күрде. Төше бик хикмәтле иде. Бу юлы да ул очып йөрде. Кош булып түгел, кеше булып очты. Менә шәп-шәрә килеш, Галәм иңләп йөри ул: әле бер якка томырылып оча, әле икенче якка тайпыла... Әнә ул таныш яшел планета. Юк, Җир түгел бу. Яшел булса да, түзеп булмаслык эссе анда. Өстен яшел ут каплаган диярсең... Сәүбәннең шул йолдызга якынрак барасы килә. Менә ул, бөтен көчен җыеп, шул яшел эсселеккә томырыла, ләкин якын ук килә алмый, канатларын көйдереп, кабат аска — Җиргә егыла. Төшкәндә, кайсы җире беләндер төрледән-төрле йолдызларга кагылып, бәрелеп китә. Бәрелгән саен, «тишелеп беткән» шәмәхә күк нимдидер сәер аваз белән ыңгырашып куя: «Мәтә... Тикә... Умма... Йәрсә... Иллә... Әнни... Һунни...»

Сәүбән башта аңышмый, тора-бара исенә, һушына килә: бу бит Сарманайда яңа туган сабый колагына әйтелә торган илаһи дога! Сәүбән санап ята: җиде мәртәбә кабатланды ул. Димәк, нимдидер изге сүзләр бар бу догада. Тылсымлы, шифалы бу доганы Сәүбәннең элек тә ишеткәне бар иде. Авылда чакта еш әйтә иде аны әнкәсе. Бүген әнә тагын шушы сихри дога дулкынында уянып ята. Кабат туып ята. Икенче мәртәбә туа, ахры, ул. Чөнки бу доганы бала туганда гына әйтәләр.

Ул инде тәмам уянып җитте. Ә менә әнкәсе йоклый. Төне буе улын саклап чыккан ана, таң алдыннан гына, малаеның башы салынган мендәргә маңгаен терәп, йоклап киткән...

Сәүбәннең тамак төбе ялкынсынып яна. Эче дә яна, башы да, җаны да... Ул үзе дә сизмәстән, кулына ут капкандай, кискен хәрәкәт белән ян өстәлдәге чынаякка — әнкәсе алып килгән чишмә суына үрелде. Көтмәгәндә ничек үрелеп алган булса, шулай ук шыбырдатып эчте дә чынаякны кире куйды. Башта аңышмады. Аннары гына башына барып җитте: ул бит йөри, тота, эчә ала. Сәүбән шунда гына үзенә тәнен хәрәкәткә китерерлек, кул-аякларын йөртерлек тылсым кагылганын, күктәге йолдыздан иңгән сихер шаукымының юкка чыгуын аңлады.

Әнисен уятмаска теләп, сак кына торып, хәлсезләнгән буыннарын яза-яза, ул акрын гына тышка чыгып китте. Нидер сизенеп уянган Рәмзия бөтен палатага сөрән салды — ачы тавыш күтәрде. Ә Сәүбән бу вакытта, тырышып-тырышып, хастаханә ишегалдындагы чирәмдә кабат йөрергә, дөресрәге, яшәргә, бәлки, очарга өйрәнә иде...

...Сәүбән йокы аралаш пышылдап кычкыра: «Әнкәй! Әнкәй! Мин йөрим, йөрим!.. Менә аякларым, менә кулларым! Мин йөрим!.. Мин очам!..»

Укучым, ялгышма, Сәүбән инде шәһәрдәге йокысыннан уянган, чынлап та хастаханә ишегалдында «аяк яза»...

Хәзер ул үз авылында, үз тавында, бу таудагы мәгарә авызында унсигез ел күрмәгән Сәвиясе белән янәшә йоклап ята. Төш күрә... Төш түгел, шәһәрдәге соңгы гыйбрәтләрне, үзенең авырып терелүе белән бәйле хикмәтле хәлләрне төш итеп кабат күздән кичереп ята, дөресрәге, күңелдән үткәреп, йоклап, юк ла, уянып ята...

Хастаханә табибларының аптыраулы йөзләрен, дусларының бер өй булып җыелып килүләрен, көлешә-көлешә кич утыруларын күрә ул.

...Әнкәсе икенче көнне үк авылга кайтып китте. Сәүбән, кайтам да, кайтмыйм да димәде, берьялгызы өйдә калды. Һәм менә, ныклап йөри башлагач, тәмам терелеп, ныгып җиткәч, Сәвияләрнең ялдан кайтуына ике көн калгач, җыенды-күтәренде дә, бөтен дөньясына кул селтәп, авылына, туган йортына, нигезенә кайтып китте.

Әнә ул юлда үзен-үзе читтән карап бара. Кызык. Тукта! Нәрсә бу? Нимдидер таныш тавыш, дулкынлану... Бала чагының илереп елап калган тавышы яңгырый сыман...

Бала чагы нигәдер ачыргаланып чакыра кебек аны:

— Сәүбән...



— Сәүбә-ә-ән! Сәүбә-ә-ән!..

Ниндидер шомлы, ялварулы тавышка уянып китте Сәүбән. Кемдер аны өзгәләнеп, ачыргаланып чакыра иде. Бу чакыру төштән булды, ахры. Тирә-ягына каранды. Ул бит бүген Сәвия белән бергә мәгарәдә кунды. Юк, төш кенә түгел бу... Әнә бөтен җирдән төтен исе, күмер, көл исе аңкый... Учак сүнгән... Җиргә, табигатькә салкынча дым йөгергән. Җәй уртасы булса да, иртән чык мул төшә... Юк, бу чык түгел, кичәге хәтәр яңгыр юеше... Яңгырдан качып, Сәвия белән икесе шушы мәгарәгә килеп чыктылар, шушында очраштылар бит... Тукта, Сәвия кайда соң?

— Сәүбә-ә-ән...

Сәүбән, ниһаять, уянып җитте. Сикереп торып, мәгарә авызына ташланды. Сәвия белән бер-бер хәл булганмы әллә?

Якты дөньяга уктай атылып чыккан Сәүбәннең башы әйләнеп китте. Ул, иртәнге Кояш балкышына тулышкан көнгә таба бер адым да атлый алмыйча, мәгарә читендәге кыя-ташка барып тотынды. Кала-тау итәгенә җәелеп яткан табигать гүзәллегенә —яңгырдан соң җете яшел төскә кергән тугайлыкка, хатын-кыз күкрәге кебек, инешнең ике ягында күпереп торган пар калкулыкка, кошлар моңына күмелгән таллыкка, кара-көрән тәтиләрен өлгертеп яткан куе камышлыкка сокланып карап торырга Сәүбәннең вакыты юк иде, ул чишмә буенда аптырап, куркынып басып торган Сәвияне борчулы күзләре белән бик тиз эзләп тапты. Иртәнге җиләс җилдә кибенеп өлгергән сукмак буйлап аның янына йөгереп төште.

— Ни булды, Сәвия?

— Сәүбән...

— Ни булды дим?..

— Сәүбән... Чишмәгә әллә нәрсә булган...

Сәүбән барысын да аңлады. Кала-тауның үле су чыгарыр вакыты җиткән. Әнә чишмә улагыннан ургылып-ургылып кызыл су ага... Әнә... Ә? Ике үле кош гәүдәсе ята... Мескен тургайлар... Бала гына бит әле үзләре... Әллә? Әллә иртә таңда сайраган кошлармы болар? Рух чишмәсенә агу төшкән... Хәтәр вакыт... Кала-тау сөйләшә башлаганчы, бу тирәдән тизрәк китәргә кирәк. Китә алмыйлар шул алар. Малайлары бар аларның монда. Ул шушы мәгарә эчендә — үзенең яшерен бүлмәсендә булырга тиеш...

— Шунда ул, шунда, ашыгыгыз, тиз булыгыз. Нинди пошмас җаннар соң сез, ә?

Сәүбән кинәт янында пәйда булган бала чагының шелтә сүзләрен тыныч кына кабул итте дә Сәвияне ашыктыра башлады:

— Сәвия, әйдә киттек, Сәүбәнне тизрәк табарга кирәк, монда эшләр хәтәр булачак.— Аннары, учларын җәеп, чишмәдән су алырга барган Сәвиягә бөтен көченә кычкырып җибәрде: — Кагыласы булма! Күрмисеңмени, тау үзенең үле суын чыгара...— Бераздан тыныч кына әйтеп куйды: — Калатауның сөйләшер вакыты җитте. Әйдә, киттек...

Алар җитәкләшеп өскә менеп киттеләр. Менә-менә, бер читтә сүзсез генә басып торган таныш юкәгә күтәрелеп карадылар. Икесенең дә күңелләрендә ниндидер бер хәтер төере кузгалып куйды, ахры, сүз куешкандай, бер-берсенә борылып карадылар. Әгәр шунда өченче бер кеше булса, ул бу ымсынулы карашларда бер генә мәгънә, дөресрәге, гыйбрәт күрер иде: кеше күңеле аккан су кебек — бер дулкынга ике мәртәбә керә алмый. Ул дулкын агып киткән инде. Ләкин, бер үк суга ике мәртәбә кереп булмаса да, бер елганы ике мәртәбә кичеп була. Икенче тапкырында ышанычлырак, кыюрак та кичәсең әле...

Озаклап тукталып торырга, фәлсәфә куертырга вакыт юк иде... Сәүбән белән Сәвия, кабат сукмакка төшеп, мәгарә авызына килеп чыктылар. Мәһабәт тау аларны кабып йотарга әзер иде...

Сәүбән, капчыгын алып, кирәк-ярак әйберләрне чыгара башлады. Иң элек бер коры чыра алды, аның башына чүпрәк урап, шул чүпрәкле башына керосин сибеп, ут төртте. Шунда ук ике күмәч алып, берсен Сәвиягә сузды, икенчесен үзе капты...

Тагын нишлисе калды дип, озак кына таш идәнгә карап торганнан соң, Сәүбән артыннан бер адым да калмыйча ияреп йөрүче бала чагын исенә төшерде. Тик... мәгарә эчендә бу рухи зат күренмәде. Инде тәвәккәлләп кереп китәбез дигәндә генә, әллә каян, стена-кыя эченнән килеп чыкты ул. Өс-башына тузан-ком кунган, үзе арган-талчыккан... Сәүбән артык кызыксынып тормады, бер генә сорау бирде:

— Вакытыбыз күпме?

— Тәүлек ярым.

Сәүбән, үзен-үзе белештермичә, сәгатенә карап алды. Нәкъ иртәнге алты.

— Өлгерәбезме?

— Белмим... Мин белмим...

— Әйдә безнең белән...

— Сезнең белән керә алмыйм. Тауның үз рухы бар. Ул чит-ят рухларны үзенә кертми...

— Рух чишмәсе дә аныкымы?

— Әйе, анықы. Рух чишмәсе — Кала-тау рухының күз яше булып бәреп чыккан…

—Үзең кермәсәң кермәссең, тик шуны булса да әйт әле: без исән чыгарбызмы?

— Бу тау эченә күпме еллар буе кешенең аяк басканы юк. Шуңа күрә аның холкын беркем дә белми. Исән чыгуыгызны юрый алмыйм. Әмма малаегызны табасыз. Монысы — хак дөреслек! Ә хәзер ашыгыгыз. Кала-тау туй итә башлый. Онытттыңмыни, Тәңре көне бит бүген. Тәңре белән Чулпанның кавышкан көне… Шул көнне сагынып елый Кала-тау…

— Сәүбән, ни булды сиңа, ник дәшмисең? — Монысы Сәвия тавышы. Ул бит Сәүбәннең бала чагын күрми, шуңа да аптырашта калган.

— Бала чагым белән сөйләшәм, Сәвия. Ул безне ашыктыра…

— Кайсы якка китәргә уйлыйсың? — Сүзгә тагын бала чагы кушылды.

— Белмим әле.

— Үзең минем кебек чакта кайсы мәгарәгә йөри идең — шуңа кер. Ул бит синең кан. Димәк, синең җан, синең аң. Ул да синең кебек уйлый, синең кебек яши. Кешеләрне күрәсең килмәсә, дөньяда яшисең килмәсә, кая барыр идең?

— Андый чакта минем качар урыным бар иде.

— Синең урын — аның урыны инде.

— Шулайдыр шул…

Үз-үзе белән сөйләшүче Сәүбәнгә сәерсенеп карап торган Сәвия дәшми. «Әллә чынлап та сихер шаукымы эләккәнме моңа?» — дип уйлый ул. Тик баласын табу теләге бөтен шик-шөбһәдән дә өстенрәк, көчлерәк. Ул элекке сөйгәне Сәүбәнне хәтерләткән шушы хыялый бәндә белән тау тишегенә генә түгел, җир тишегенә дә керергә әзер иде бу минутта.

Сәүбән кулындагы таягына ут кабызды да ян-якта каралып торган бер тар тишеккә якын килде. Ул бала чагында шушы тишектән үрмәләп кереп китә иде. Тезләнеп йөрү кыен түгел, идәненә йомшак, коры ком түшәлгән. Тик башны кискен күтәрергә ярамый — шундук бәреп яньчисең… Үрмәләп, кырык-илле адым барырга кирәк. Аннары коридор киңәя башлый, бормаланып, әле уң якка, әле сул якка тайпыла, ниһаять, тагын да киңәеп, басып барырлык була.

Сәүбән комдагы эзләрне шундук күреп алды. Утырып хәл алганда, туктаусыз нидер каранды, озак кына эзләнде, колагын мәгарә стенасына куеп, тыңлап торды. Шактый арыган-талчыккан Сәвия боларның әллә ни әһәмиятен күрмәде. Әмма Сәүбән өчен мәгарәдәге һәр таш, һәр ком, тузан бөртеге «телле» иде.

Иң элек шуңа игътибар итте Сәүбән: бу тишек ике яктан да ачык. Утның яхшы януы, сулышның иркенлеге, һаваның тымызык җил булып йөреп торуы шул хакта сөйли. Стеналардагы таш шүрлекләргә кунган тузан ара-тирә кубарылып-калкынып куя. Димәк, тау эчендә хәрәкәт бар, җан бар. Әлегә бу җан тибеше сизелер-сизелмәс кенә, ул көчәя барган саен, шүрлекләрдәге ком бөтрекләре аска, идәнгә күпләп коела башлаячак.

Бераз хәл алгач, тагын кузгалдылар. Сөйләшмәделәр. Сүз белән түгел, уй белән, күңел белән сөйләштеләр, ахры. Чынлап та, Сәүбән Сәвиянең бөтен уен белеп барды: малае өчен борчыла ул. «Шунда гына булсын иде!» — ди, догалар укый. Тиздән алар Сәүбәннең яшерен бүлмәсенә җитәчәкләр. Малайлары Сәүбән дә шунда булырга тиеш. Бала чагы әйтте бит. «Ул нәкъ синеңчә уйлый, яши. Димәк, шунда булырга тиеш»,— диде. Булса гына ярар иде. Булмаса, кая барасың тагы… Чуртым белсен!

Басып бара башлагач, адымнары тизләнде, сулышлары тигезләнде. Чыра яктысында әкияти, сихри балкышка күмелгән, әмма үтә дә шомланып киткән мәгарә эче якты дөньяда яшәр өчен яратылган бу ике Хода бәндәсен һаман ныграк йота бара иде.

Сәүбәндә куркуның әсәре дә юк. Гүя ул унсигез ел читтә йөрмәгән, әле кичә генә менә шушында үрмәләп йөргән, тик, нәрсәсендер онытып, шуны алырга гына кергән…

Менә ул! Бу урында бераз тараеп ала да олы, киң бүлмәгә килеп чыга… Икәүләп тагын тезләренә чүктеләр. Бу юлы идән каты иде. Сакланып, иплэп кенә үрмәләргә туры килә. Озак барасы юк, әнә ул караңгы бушлык! Хәтта бераз шүрләтә дә…

Беренче булып Сәүбән сикереп төште, аңа, тотам да калмыйча, Сәвия иярде. Ул шактый хәлсезләнгән, күтәреп төшергәндә, тәнен җыя алмыйча, Сәүбәннең куенына мәлҗерәп керде дә бетте… Сәүбән аны стена буендагы бер таш өстенә утыртып сөяп куйды. Шуннан соң гына, кулындагы факелын күтәреп, тирә-юньне җентекләп карый башлады. Килә-килешкә үк аңлап алган иде ул — монда беркем дә юк. Чөнки яктылык юк, ут юк! Анысы… Утсыз-нисез дә кереп йөри иде үзе… Юк, монда беркем дә юк… Әмма эзләр бар… Әнә учак урыны, таш өеп, күтәртеп ясалган мич сыман җайланма… Көл суык… Түрдәрәк түшәк булырга тиеш. Әнә ул! Озынча таш өстенә түшәлгән иске киемнәрне күргәч, Сәүбәннең эченә җан керде.

Ул шундук Сәвиягә эндәште:

— Кара әле, болар сезнең әйберләрме?

Сәвия, авыр гына торып, Сәүбән янына килде. Аннары, ярсып-кабынып, түшәккә капланды:

— Безнеке!.. Безнеке булмыйча!.. Балакаем минем, шушында яттыңмыни?! Кайда син, кайда, ник дәшмисең? Сәүбән, кайда ул?..

Сәүбән нишләргә дә белмәде. Үзенең күңеле дә урыныннан купкан иде шул.

— Йә, Сәвия, бетеренмә, табылыр… Кая китсен ул, шушында гына булырга тиеш…

— Белмим инде, Сәүбән, юк бит, юк!..

— Юк шул…

Сәвия түшәк өстендә калды, Сәүбән, мәгарәне ныклабрак өйрәнү өчен, факелын алга сузып, әле бер якка, әле икенче якка омтылды.

Кинәт!.. Кинәт аның колагына тонык кына бер тавыш ишетелгәндәй булды. Бераздан бу сәер тавыш тагын кабатланды. Сәүбәннең эченә җан керде, тәненә җылы йөгерде. Малайларының язмышы турыдан-туры шушы тавыш белән бәйләнгәндер төсле тоелды аңа.

Сәүбән йөгереп шул якка барды. Берәр аралык бармы әллә дип, стеналарны карый башлаган иде, кинәт йөз-битен камчы кебек ниндидер салкынлык кисеп үтте. Сәүбән, чирканып, читкә тайпылды. Өстән, түшәмдәге караңгылык эченнән челт-челт итеп тамчы тамып тора иде. Сәүбән факелын өскәрәк күтәрде. Чынлап та, өскә таба бер бушлык иңеп китә, аның шомлы-афәтле бугазыннан ниндидер баулар асылынган… Әллә? Чәч толымнарымы? Бәлки, тау рухының чәч толымнарыдыр ул? Юк ла, тамырлар бит болар, агач тамырлары, юкә тамырлары! Тамчы да шуннан тамып тора икән…

Сәүбән, учына бераз су җыеп, иренәнә тидерде. Чын чишмә суы кебек бу… Юк, төчерәк… Яңгыр суыдыр. Димәк, өстә туфрак калын түгел…

Мәгарәне өйрәнеп урап чыгам дигәндә генә Сәүбән бер сәер тишеккә тап булды. Кайчандыр ул зуррак булган, хәзер ком-таш белән томаланган, кемнеңдер җитез кулы аны чистартып, кереп-чыгып йөрерлек хәлгә китергән. Сәүбән шул тишеккә керергә булды. Бу хакта әйтү өчен Сәвия янына килде. Капчыгын салып, ике-өч факел чырасы, шырпы алды да, калган бөтен нәрсәне — ризыкларны, көрәк, пычак ише нәрсәләрне Сәвия янында калдырды. Факелны ничек кабызырга икәнен өйрәтте.

Аннары гына:

— Мин хәзер урап киләм. Эчтәрәк тагын бер куышлык булырга тиеш, шунда булмагае… Ә син шушында гына көт… Тамак ялгап ал. Эчәм дисәң, әнә анда су тамып тора…

Инде кереп китәм дигәч кире килеп, капчык каешына бәйләнгән бауны алды. Аннары, күңелеңне төшермә, барысы да тәртиптә булыр дигән кебек Сәвиягә карап баш какты да ярым шуышып, ярым үрмәләп кереп китте.

Озак барырга туры килмәде. Хәл ала-ала ун минутлар чамасы баргач, басып йөрерлек коридорга шуып төште. Аның стеналары, кеше кулы тигән кебек, тигез, шома итеп кырылган, матурайтып сырлап эшләнгән иде. Баш өстендәге түшәм дә гөмбәзләп уелган. Идәнгә дә бертөрле шома, тигез таш тезелгән… Кинәт… Әллә нәрсә булды. Шул таш идән селкенеп, хәтта калкынып куйгандай итте. Сәүбән үзе дә чайкалып китте һәм, искәрмәстән, стенага барып ябышты. Бу юлы ул аптырамады. Кала-тауның уяныр сәгате җиткәнен белә бит ул. Шуңа күрә дә, бер кулына факел тотып, икенчесе белән мәгарә коридорының кытыршы, әмма гаҗәеп тигез тезелгән ташларына тотына-тотына, алга баруында булды. Күзен идәннән алмады. Тезелгән ташларның кайберләре сикереп чыгарга теләгәндәй өскә калкынып, селкенеп куя, кайберләре, киресенчә, аска иңәргә теләп, эчкә батып-батып китә кебек... Ара-тирә пәйда булган ком өемнәренә кеше эзләре аермачык төшеп калган; бу Сәүбәннең күңелен юата. Юк, ул тоя, хәтта төгәл белә: шушы шомлы, караңгы, салкын таш коридор аны улы янына алып бара. Бала чагында Сәүбән бу коридор хакында сизенә иде, әмма үз куышыннан эчкәрәк керергә шикләнә иде. Кара син аны, улы кыюрак, батыррак булып чыккан ласа! Кая чаклы кереп йөргән бит! Тизрәк барып табасы иде үзен! Әнә Кала-тау холыксызланырга маташа… Их, җанына төшәрлек итеп рәнҗетте шул малаен. Кем белгән бит аны, кем белгән… Минзәлә кызын оныта алмый йөрүе юкка булмаган икән. Үз Сәвиясен танымасын инде, ә? Аңсыз димә инде... Кем белгән бит аны, кем белгән!..

Шул вакыт таш стена эченнән ниндидер шомлы гүләү тавышы ишетелде. Сәүбән шадра диварга колагын куеп тыңлый башлады. Гүләү көчәйгәннән-көчәя бара, аңа иңрәү, улау, ухылдау тавышлары кушыла… Сәүбән адымнарын тизләтте. Ләкин арыган аяк буыннары аны тыңламый интектерде — адымнары ешайса да, әллә ни кызулый алмады ул. Авыртудан соң ныгып та җитмәгән аяк балтырлары әрнеп калтырана, табаннары кызыша башлады. Ләкин Сәүбән эчке бер тоем белән барды да барды. Аның исәбе буенча, ул инде Кала-тауның үзәгенә җитәргә тиеш иде. Озакламый факел да сүнәчәк, әмма аны алыштырып вакыт әрәм итәсе килми…

Сәүбән үзенең кая барасын белмичә бара. Җирнең, дөньяның үзәгенә, җан җиренә барган кебек бара. Язмышына барган кебек, үлеменә яисә тууына барган кебек, яшәүнең мәгънәсенә ирешәм дип

бара. Бу юлда аның югалган улы — бер сәбәп яисә ым-ишарә генә, ә төп максаты бөтенләй башка — үзенең кемлеген, асылын ачыклау... Кеше үзенең кемлеген белмәсә, каян килүен, кая баруын белмәсә, аңа яшәү кыен, бик кыен. Сәүбән дә үзе хакында бик аз белә, белгәнен дә урау юллардан йөреп, туган туфрагыннан, якыннарыннан, хәтта үз-үзеннән качып йөреп, онытып бетерә язган. Шулай да ул иң кадерле минутларын, иң газиз кешеләрен, күңеленә салып, исән-сау алып чыга алган... Калатау белән бәйле нәсел, күңел серләре, әнкәсе, Сәвиясе, малае, иң мөһиме — бала чагы... Бүген боларның барысы да аның белән, аныкы гына...

Тик... Барыбер тормышыннан разый түгел ул. Нидер җитми аңа. Шул җитмәгән тормышның нигез-әсасын, язмышының иясен эзләп йөри Сәүбән. Шуны эзләп әнә тау үзәгенә кереп бара... Иң хәтәр вакытта — Кала-тауның ачулы чагында кереп бара. Моның юньлелеккә илтмәсен мәһабәт тауның соңгы тузан бөртегенә кадәр белә. Ә менә Сәүбән моны белергә теләми.

Ниһаять, бара торган коридор башында яктылык шәүләсе чагылып китте. Әйе-әйе, яктылыкның да шәүләсе була икән. Сәүбән аны аермачык күрде. Ниндидер зәңгәрсу-көмеш нурланыш... Чыра яисә шәм генә түгел бу. Кояш яктысы кебек, яисә берәр йолдыз яктысы... Әллә... Нигъмәт бабай сөйләгән легендалар дөресме? Бәлки, бу тау үзәгенә берәр йолдыз яшерелгәндер?

Бәлки, җирдәге һәр авыл, һәр шәһәр янында шундый йолдыз бардыр? Алар тау-калкулыклар эченә генә яшерелгәндер? Бу йолдызлар кешеләргә кайсы планетадан очып килгәннәрен искәртеп торадыр?..

Якынайган саен, Сәүбәннең күңелендә шом артты, әмма, бер үк вакытта, өмет тә, ышаныч та артты. Ул, соңгы көчен җыеп, таш коридорның аргы башында ымсындырып, чакырып торган яктылыкка ашыкты...

## 16

Сәүбән «канат» белән туды. Кулларын җилпеп, чәбәләндереп туган балаларга шулай диләр. Әмма ул атасыз туды. Ятимлек аның канат очларын туганда ук кискән иде, шуңа күрә ул, ничек кенә хыялый булмасын, ничек кенә канат җилпергә тырышмасын, теләгәнчә яши, оча алмады... Баштарак ул әтисенең җилкәсенә утырып сабантуйларга йөри алмады, аннары аның белән балыкка, урманга бара алмады, тагын бераздан әткәсе белән җитәкләшеп мәктәпкә бармады, җәй көннәрендә аның эшенә — кырга яисә башка берәр җиргә бармады... Кала-тауга да бармады ул әткәсе белән.

Бишенче яшькә чыкканда, әнкәсе аны Рух чишмәсенә алып китте. Көне буе шул чишмә тирәсендә йөреп, аның суында юынып, юкә агачы ышыгында табын корып, ял итеп, рәхәт арып-алҗып, кичкә таба гына кайтып егылдылар. Шул көннән ошап калган иде аңа Кала-тау.

Үскәчрәк бу якларга сыйныфлары белән күмәкләп йөрделәр. Сигез яшендә Сәүбән беренче мәртәбә ялгызы гына килде. Әнкәсеннән качып килде. Һәм гомерлеккә шунда торып калды. Күңеле белән, язмышы белән калды.

Иң элек ул тар авызлы мәгарә куышын эзләп тапты, каникулында көннәр буе шунда ятты. Аннары эчкәрәк үтә торган юлны чистартты. Ә беркөнне Зәңгәр шар куышлыгына кадәр барып җитте. Бу исемне ул үзе кушты. Чып-чын зәңгәр шар кебек иде бу мәгарә. Әмма шарның эчке ягы кебек... Өстә күзнең явын алып тора торган мәһабәт гөмбәз. Ул яшькелт-зәңгәрсу асылташлар белән бизәлгән. Бу ташлар, электр лампочкалары кебек, бөтен дөньяны балкытып, яктыртып торалар. Ут та, чыра-шәм дә кирәк түгел. Кояшлы көндәге кебек, бөтен дөнья чалт аяз! Тик ниндидер серле ташлар алар. Якын килсәң — иң гадәти таш кебек, читкәрәк китсәң — зәңгәрсу нурларын балкытып яна башлыйлар...

...Әткәсе кайтканын ишеткәч, Сәүбән каушабрак калды. Әткәйле балалардан ишетеп белә ул: әткәйле булу әйбәт тә, кыен да. Әйбәт, чөнки әткәй булганда, малайлар белән курыкмый сөйләшәсең, бер-бер хәл булса, килеп яклар кеше барлыгын белеп торасың бит... Кыен да, чөнки әткәйләрдә озын, киң каеш була. Менә шул каеш эләгеп елаган малайлар әткәйле булуны ул кадәр мактап бетермиләр... Шулай да Сәүбәнгә кызык иде: ниндирәк ул — әткәй дигән кеше?

Әнкәсе гел әйтә иде: «Әткәң шәһәрдә яши, космоска оча торган спутниклар төзи»,— ди торган иде. Исемен дә белә. Ничек белмәсен — үзенең исеме бит инде. Нигә дип әткәсенә дә шундый исем кушканнардыр? Үскәч, икесен бутап йөртүләре бар бит. Бутамаслар, аларның фамилияләре туры килми. Ул бит әнкәсенең фамилиясен йөртә. Атасының исеме урынына да әнкәсен атыйлар. Укытучылар журналга «Сәүбән Сәвиевич» дип язганнар әнә... Оятыңнан үләрсең... Хатын-кыз исеме отчество була димени? Хәтта әнкәсенеке кебек матур исем булса да...

Әнкәсеннән әткәсен күрергә рөхсәт алгач, Сәүбән туп-туры Рәмзия апаларына китте. Бу апа аны бик ярата, күргән саен сөеп китә, төрле тәмле әйберләр ашата, бәрәңге төрмәсе белән чәй дә эчереп чыгарганы бар. Беркем дә булмаганда: «Минем Сәүбәнемә бигрәкләр дә охшагансың. Каплаган да куйган инде. Тач аның бала чагы!» — дип сөя Рәмзия апасы. Бу хакта бөтен авыл белә белүен. Сәүбәннең үзенә дә еш әйтәләр. Тик кемдер яратып әйтә. Кемдер үчекләп китә. Сәүбән аларга игътибар

да итми. Алар бит көнләшеп үчеклиләр. Авылдагы бер генә малайның да этисе космоска оча торган кораб ясамый, ә Сәүбәннең әткәсе ясый! Шуңа күрә дә кайтырга вакыты юк аның. Эше бик тыгыз. Бөтен дөнья, бөтен космос карап тора аңа. Космик корабның иң соңгы шөребенә кадәр ул бора ди бит… Ничек китсен, китә алмый ул аннан…

Бу юлы кайткан… Авылдаш улын — Сәүбәнне күрәсе килгәндер… Ә нигә ике көн буе аның янына килмичә йөрде соң алайса? Арыгандыр шул. Ничә ел буе кайтмыйча эшләп йөр дә, арыма, имеш… Ничә елга ике көн йокы пучтәк ул…

Әткәләре капкасына барып җитүе булды, аның килүен көтеп торган кебек, Рәмзия апасының ялт итеп килеп чыгуы булды. Сәүбән бер сүз дә дәшә алмый калды, аның өчен дә, үзе өчен Рәмзия апасы сөйләде:

— Килдеңме, балакаем? Ярый, килүең әйбәт булган. Чакырыйммы? Ярый, хәзер чакырып чыгарам мин аны. Күрәсең киләме? Күрәсең килер шул. Бер кан, бер җан бит… Хәзер чакырам мин аны, шунда гына утырып тор, яме. И-и, балакаем, икегезнең дә күңеле купкан вакыт шул… Берәр үз урынына утырырмы ул күңел дигәннәре…

Сәүбәнгә әткәсе башта ук ошамады. Рәмзия апаларына кайткан бу кеше әткәйләргә бөтенләй дә охшамаган иде. Чит кеше диярсең әллә нинди хулиган малайга акырган кебек акырды-бакырды да пыр тузынып кереп китте… Шул да булдымы әткәй кеше? Ничә ел көткән әткәсе шулмы? Шушы кешегә космосны, йолдызларны ышанып тапшыралармы? Космонавтлар ничек күрми икән? Бу дорфа, усал кеше ясаган космик аппаратка мәңге дә утырмас иде Сәүбән. Юк, бу кеше аның этисенә охшамаган. Аның әткәсе түгелдер ул. Ялганлап кына йөридер. Әнкәсенең, бөтен авыл халкының башын әйләндерәдер. «Минем андый малаем юк»,— дигән була. Ялынып йөрер ди бугай. Сәүбән андый малайлардан түгел! Моңа кадәр бер малайга да, бер кызыйга ялынганы, ялварганы юк аның!

Шулай да Сәүбәннең күңеленә әллә нәрсә булды. Елыйсы килде… Бу капка төбеннән, бу урамнан, хәтта авылдан чыгып чабасы, бөтенләйгә качып китәсе килде аның…

Һәм ул авылдан качып китте. Юк, Сәүбән елак малай түгел. Күңеле ничек кенә әрнесә дә еламады ул. Күзеннән яше генә акты. Бөтен битен тутырып акты да акты… Ә Сәүбән үзе генә белгән сукмак буенча барды да барды… Аяк киемнәрен дә салып тормыйча, инешне ерып чыкты, әрәмәлек, зират аша үтте, аннары Кала-тауга таба китте…

«Нәрсә ди бит… Андый малаем юк, ди… Булмаса соң, нигә аны кычкырып әйтергә инде… Ишетеп калсалар… Ул аның әткәсе булмаса ни, бу бит әле Сәүбәннең әткәсе юк дигән сүз түгел… Түгел! Бар аның әткәсе, бар, бар! Ул космик кораб кына ясамый, ул… ул… ул үзе оча шул корабта!.. Белдегезме! Ул оча! Ул канатлы!»

Сәүбән дә төшендә гел очып йөри. Әнкәсе дә: «Канатлы булып тудың»,— ди. Йөргәндә җилкә сикертеп куюын да канатка юрый әнкәсе. Әткәсе дә космоста очып йөргәч, Сәүбән үзе дә канатлы булгач, тагы ни кирәк?!

Төшендә мең мәртәбә күрде ул әткәсе белән космоста очып йөргәнен… Тик… Нигәдер һаман Рәмзия апаларына кайткан кешегә охшаган була ул кеше… Юк ла, бөтенләй дә охшамаган. Әйбәт, ягымлы, мөлаем иде аның төштәге әткәсе. Бервакыт ул Сәүбәнгә күктән йолдыз алып бирде. Йолдыз да хәйләкәр… Әткәсенең учыннан төшмәкче булып, читкә сикерде.

Йолдызны икәүләп куа башладылар. Теге барыбер тоттырмады. «Йолдызлар төнге күк өчен яратылган бит, шунда гына торсын, тимик без аңа»,— диде әткәсе. Аның битендә йолдыз кебек яра-җөй калды. Куып йөргәндә, ялгыш йолдыз тиеп киткән икән...

Сәүбән чишмәдә битен чылатып алды да, ике дә уйлап тормыйча, Кала-тауга, үзенең серле куышына юнәлде. Башта якындагы таш бүлмәсендә хәл җыеп ятты, аннары эчкәреге мәгарәгә кереп китте… Тышта котырып яңгыр яуганын да, мәгарә авызында әткәсе белән әнкәсенең бергә төн уздыруларын да, хәтта Кала-тауның уяна башлавын да тоймады ул.

Зәңгәр шар уртасында түгәрәк һәм җәлпәк-яссы таш бар. Аңа нindидер серле хәрефләр, сүзләр дә уелган. Менә шул язулы ташка чалкан төшеп ятарга ярата Сәүбән. Бик серле таш ул. Ике олы сере бар аның. Шул таш өстендә биш кенә минут ятасың, ә чынында бер көн үтеп киткән була… Вакытны кыскарта, «йота» торган могҗизалы таш бу. Икенче могҗизасы да хыялый кинолардан ким түгел. Шул яткан килеш гөмбәзнең иң очына карасаң, гаҗәеп бер күренешкә тап буласың: нәкъ шул урында тар гына ачыклык барлыкка килә һәм шул ачык урыннан бер йолдыз карап тора башлый. Сәүбәннең тау башына менеп тикшергәне булды: бернинди тишек-мазар да юк анда. Ә мәгарә эченнән ул тишек күренә, бу тишек аша теге нурлы йолдыз күренә. Сәүбән аның нинди йолдыз икәнен дә белә. Күктәге иң якты йолдыз ул — Чулпан йолдызы, Венера планетасы.

Тагын бер хикмәте бар икән әле бу Зәңгәр шарның. Монда бер вакытта да ашыйсы, эчәсе килми. Күпме генә торсаң да, тамагың тук кебек, шулай ук хәлсезлек тә тоймыйсың монда; авырткан урыннар да тиз төзәлә…

Менә әле дә шул таш өстендә ята Сәүбән. Ни уяу, ни йокылы килеш, ул бер тәүлек ята инде монда. Күзләре гөмбәз очындагы йолдызда. Шунысы кызык — көндез дә, төнлә дә балкый ул йолдыз. Көндез йолдызлар булмый дисезме? Көндез дә була алар. Кояшның нурлы балкышы аларның тонык яктылыгын күрсәтми тора, шул гына.

Элек Сәүбән йолдызлар хакында бөтенләй башкача фикер йөртә иде. Төнге күктәге йолдызлар, таң тугач, җирдәге кешеләрнең күңелләренә күчеп торалар дип уйлый иде. Ә кич алар тагын күккә калкалар. Бәлки, бу дөрестер дә…

Кинәт… Гөмбәз очындагы Чулпан йолдызы калтыранып куйды. Галәм дертләп киткән кебек булды. Тагын берничә мәртәбә кабатланды бу тетрәү. Сәүбән, сискәнеп, башын калкытты, аннары, нидер сизенеп, үзе яткан таш йөзенә яңагын куйды, тынын буып тыңлый башлады. Күк түгел, Галәм, йолдыз түгел, Кала-тау тетрәнә иде бу минутта.

Сәүбән белә: һәр елны җәй уртасында Кала-тау бер «тавышланып» ала. Бу вакытта аңа керергә, хәтта якын да барырга кушмыйлар. Бәла, афәт китерә торган көн бу. Тәңре туган, Алла туган көн. Изге рухларның явыз рухларга — җен-шайтаннарга каршы аяусыз көрәш башлаган көне. Кара рухлар җиңелеп, дөньяга Тәңренең килгән сәгате. Дөресе ничектер, мәгәр Хәләф бабай шулай сөйли иде. Тагын ул сөйли иде: имеш, Сарманай авылында яшәүчеләр күктән очып төшкәннәр, имеш, алар — Тәңре хатыны Чулпан-Зөһрәдән туган җан ияләре…

Сәүбән үзе боларга ышанып бетми. Әмма Кала-тауны күктән төшкән җан ияләре өйгән булуына ышана. Тау эчен чокып, бу кадәр матур дөнья тудыру өчен бик күп көч, сәләт кирәк бит, ә кешеләр бу хакта белмиләр дә…

Әнә тагын селкенә. Әнә! Сөйләшә дә башлады… Ризасызлык белдереп, эчтә кемдер ыңгыраша, ухылдый, нәрсәдер карышкан була… Сәүбән тизрәк чыгып китәргә кирәген яхшы белә. Кайчандыр Хөсни исемле карт Кала-тауның «сөйләшкән» вакытында кереп киткән дә бүтән күренмәгән, ди. Чыгарга кирәк, кайтырга кирәк…

Әмма Сәүбәннең кайтасы килми. «Әткәң әйбәт кеше, ул космоста очу өчен кораблар ясый»,— дип алдап йөргән әнкәсе янына, «Минем андый улым юк!» — дип пыр тузынып кереп киткән әткәсе янына, хәтта күктә бер гаепсез йөзеп йөргән якты Кояш янына, тәмле сулы Рух чишмәсе янына, җәй-көз буе чикләвеге, шомырты белән сыйлый торган әрәмәлек янына да чыгасы, кайтасы килмәде аның. Яшәп карасыннар әле ансыз да… Сагынырлар әле… Юк, Сәүбән үпкәләми. Үпкәләсә дә — бик аз гына… Менә чәнти очы кадәр генә…

Аңа монда тыныч. Монда сулыш алуы иркен, ашыйсы-эчәсе килми, вакыт та тиз уза… Бер айда олы кеше булып үсәчәк ул. Бөтен кеше шаккатачак аңа… Ялгызына кыен, ямансу булыр дисезме? Юк, кыен да, ямансу да булмаячак. Ул болай да япа-ялгыз бит. Өйдә дә, урамда да, Кала-тауда да, хәтта күңелендә дә…

Баштарак малайлар: «Төпсез чиләктән төшкән», — дип үртиләр, уенга катнаштырмыйлар иде, хәзер үзе катышмый. Бик чакырып карыйлар, ә Сәүбән бармый. Ул бөтен уенда да иң остасы, иң җитезе, иң акыллысы, әмма ул юри кушылмый. Тегеләр шундый үртәләләр, ә Сәүбәнгә рәхәт. «Төпсез чиләк» өчен шулай үч ала ул алардан…

Мәктәптә дә шул ук хәл: ул бөтен балага караганда да яхшырак белә. Әмма беркемгә дә өйрәтми, хәтта күчертми дә. Беренче сыйныфларда кыйнап җәфалаганнарын оныта алмый ул. Якларга әткәсе юк иде шул аның. Шуңа да күбрәк тәпәләнә иде…

Юк. Сәүбәннең бу тау эченнән чыгасы килми. «Аның йокыга ойый башлаган күңелендә бер генә уй, бер генә теләк әрнеп бөтерелә: «Их, әнә теге йолдызга очасы иде, очасы иде, очасы иде…»

## 17

Күңел шундый нәрсә инде: бөтен тән-буыннары хәлдән таеп, кыл өзәрлек егәрлеге калмаган чакта да кешене һаман алга әйди, алга алып бара. Җир асты юлларында йөрүче Сәүбән дә тәмам хәлсезләнде, ул инде үзе бармый, бары тик күңеленә тотынып, ияреп кенә йөри кебек… Күңеленә ияреп тә түгел, канатларын кагынып бара, ахры, ул. Очып бара, ә аяклары таш идәндә сөйрәлеп кенә йөри…

Табигать башта рәнҗи, аннан гына кичерә. Хәзер Кала-тауның хәтәр ачуланган вакыты… Сәүбәннең, аны санга сукмыйча, күпме гомер читтә йөрүенә пыр тузынамы ул? Әллә улын танымаганга, аннан баш тартып, шул сабыйны рәнҗеткәнгә шулай кыланамы? Белмәссең.

Ләкин барыбер кичерәчәк ул. Чөнки Табигатьнең йөрәге саф, күңеле чиста. Сәүбән белә: Табигатьне, Галәмне аның кануннарына буйсынып кына аңлап була. Табигать һәрвакыт хаклы, чөнки ул тулысынча Аллаһы Тәгалә ихтыярында. Шуңа да табигать кешене алдамый. Күп вакытта Кеше үз–үзен алдый һәм… бу алдануын Табигатьтән күрә, аңа сылтый…

Сәүбән үзе кармаланып бара, үзе уйлана. Уйлары да ургылып килә бит аның иң кирәкмәгән чакта… Алар арасында сабырлык, түземлек хакындагылары да бар. Ах, бик кирәк хәзер Сәүбәнгә түземлек, сабырлык, бик кирәк!..

Табигатьтәге гармониянең нигезендә сабырлык, түземлек ята шул. Сабыр кеше генә Табигатьне тоя ала, Табигать ритмына яраклашып яши ала. Бу ритмны тоя алган кеше — бәхеткә иң-иң якын торучы кеше. Чөнки бәхет ул ахыр чиктә — күңел тынычлыгы… Хасиятнең иң бөек ноктасы шул…

Табигатьнең бөеклеге нидәме? Табигать һәрвакыт гүзәл. Хәтта, ялангач, шыксыз, салкын, усал чагында да… Ул кызгануга мохтаҗ түгел. Ул яратуга гына мохтаҗ! Кем мохтаҗ түгел инде аңа… Кеше үзе дә шул табигать баласы бит… Кеше, озын гомерле, имин, бәхетле тормышлы булырга теләсә, табигать барган юлдан барырга тиеш. Дөресе шул: Табигать белән уртак тел тапсаң, ул үзе сиңа туры юл күрсәтәчәк… Тик менә Сәүбәннең генә юлы озынгарак китте… Кайда соң моның очы, башы, төбе, түбәсе, ә?.. Ялгыш юлдан киттеме әллә? Хөрт юлдан… Дию пәрие сукмагыннан… Аларны шушындый мәгарәләрдә яшиләр диләр бит. Монда Дию бар да бар инде! Тау үзәгендәге серле залларны, коридорларны нәрсә белән аңлатасың?.. Бар, бар монда Дию… Элегрәк Кала-тау буенда йөрүче Кара рух хакында күп риваятьләр йөргән. Йөзеп, шуышып йөргән кебек йөри, ди, ул. Үзе бара, ә аяклары асылынып кына тора, тамчы да селкенми, ди… Рух чишмәсенә ятып су эчә, имеш… Бәй, бу чишмәнең исеме дә шул рухтан алынган бит инде…

Их, ялгышты, хаталанды микәнни Сәүбән? Очы-кырые юк бу баз дөньясының… Ә Табигать хаталарны кичерми… Юк, кичерә ул аларны. Әмма ул, кеше ясаган хаталарны кичерсә дә, аларны онытмый… Менә бит нидә хикмәт!

Табигатьтәге һәрнәрсәнең җаны бар, аңы бар. Дию, Җен, Шүрәле, Рух, Ия дип йөртәләр генә. Сәүбәнгә ул балачак рухы булып килде, ахры. Табигать кешеләрне кыен хәлгә куймас өчен генә белгертми тора. Ә Сәүбәнне үз итте: аңа белгертте. Ниндидер тылсым бар бу ишарәдә. Сәүбән шулай дип уйлый. Ул әнә бит, бу җанның тибешен тоя, иңрәвен ишетә… Тоя, ишетә дә үз күңеленә ала, шул ритмга көйләнә. Әллә ничек рәхәт булып китә. Яхшылык эшлисе килә… Һәр кешенең күңелендә Табигать салып калдырган игелек яши. Кемдәдер ул өстәрәк ята, кемдәдер бик тирәнгә яшерелгән була. Әмма ул һәркемдә бар!

Сәүбәндә дә бар ул. Шул игелеге аны авылга алып кайтты, Сәвиясе, малае белән очраштырды, менә хәзер килеп, әллә нинди кыланчык, сәер һәм серле язмышына ияртеп, җир асты юллары буенча тинтерәтеп йөртә!..

Ярату ул — йөрәк хисләренә аеруча бер мөһимлек, мәгънә һәм максат бирергә теләү… Сәүбән моны белә, әмма бу мәгънә һәм бу максат хакында уйларга курка. Курыкмый да, дөресе — ул моңа әзер түгел. Унсигез ел белән ике көн арасында аерма күбрәк шул… Ике йөрәге бар кебек аның. Әгәр бу дөрес булса, ике йөрәге булса, аларны ике Сәвиягә дә төгәл бүлеп бирер иде… Бер генә шул аның йөрәге… Гомере дә бер генә…

Шулай изаланып йөри торгач, сәер бер дөньяга, ниндидер зәңгәр мәгарәгә килеп чыгуын сизми дә калды Сәүбән. Нәрсә бу? Нинди сихри дөнья, илаһи тылсым? Нинди яктылык? Төшме бу, өнме? Җир астындагы берәр зәхмәт галәмәтеме? Кояш эченә, йолдыз үзәгенә килеп кергән кебек булды ул. Ә бу хәл төштә генә була ала. Ут-учак та юк, шәмнәр, факеллар да янмый, тирә-юньдә стеналар яна, гөмбәз сыман түшәм дә, күк тә яна, идәннәр дә яна… Гүзәллеккә соклану өчен бер мизгел җитә, гүзәллекнең үзен тудыру өчен гасырлар, дәверләр кирәк булган.

Зәңгәрсу-яшькелт балкыш… Тизрәк уянырга иде бу төштән, барып табарга иде Сәүбәнне… Кызык әйтелде… Сәүбәнне… Әйе шул, ул үзен-үзе эзләп килде, һәм ул эзләгәнен табарга тиеш!

Сәүбән ничек кенә тырышса да уяна алмады. Чөнки бу өн иде. Караңгылык үзенекен иткән: зәңгәр дөньяга килеп чыккан Сәүбән, күзе чагылып, керфекләрен ачалмыйча, хәтсез вакыт торды. Күз алмаларын әчетеп, авырттырып килеп бәрелгән бу зәңгәр балкыш бераздан аның җанына үтте, бөтен күңеленә сирпелде, йөрәген җылытты, буыннарына таралды. Шуннан соң гына ул тирә-ягындагы могҗизага тутырып карый алды. Әмма барыбер дә үзен серле төш күрә дип уйлый иде.

Төш булса да, өн булса да, нидер кылырга тиеш иде ул. Сәүбән сак кына атлап эчкәрәк үтте. Аяк астындагы дулкынланышны тоеп барды. Диңгездәге дулкын өстеннән барамыни! Төш бу, төш… Өн булса, күптән төпкә батып китәр иде… Тукта, нигә төш булсын?! Өн бу! Әнә бит ниндидер сәер гөрелте тавышы ишетелә, бөтен тирә-як гүләп, ухылдап тора… Ә төштә тавышлар юк — анда сурәт кенә, телсез хәрәкәт кенә…

Сәүбән, мәгарә уртасындагы сәер күренешкә тап булып, тагын бер аптырады: тигез итеп киселгән, шомартылган таш өстендә бер малай ята… Ә? Улы Сәүбән ята?.. Йомгак кебек бөгәрләнеп, хәрәкәтсез, тавыш-тынсыз яткан бу бала ничек килеп эләккән соң монда? Нинди түшәк яисә өстәл бу? Кеше кулы ясаган бит моны!

Сәүбән малайның йөзен әйләндереп карамакчы булды. Шул вакыт бөтен тирә-юнь калтыранып-селкенеп куйды, Сәүбән үзе дә авып китә язды.

Таш калкулык читенә тезләнеп, малайны уятырга тотынды:
— Улым, Сәүбән, тор, тор инде! Моннан тизрәк китәргә кирәк... Улым, Сәүбән, Сәүбән!..
— Ыһ!.. Кем син? Кайсы йолдыздан?..
Аң-зиһенен җыя алмый җәфаланган малайның күңеле һаман әле өн белән төш арасында бәргәләнеп йөри, ахры, Сәүбән торгызып утыртканчы, ул шул мәлҗерек хәлендә калды.
Үзе дә чак-чак аягында, дөресрәге, тезендә торган килеш, Сәүбән малайны күтәреп утыртмакчы булды һәм бертуктаусыз сөйләнде:
— Йә, уян инде... Тор инде... Әнкәң хакына булса да тор. Тау эчендә ул берүзе калды. Сине көтеп калды. Әнкәңне кызган, Сәүбән!
Әнкәсе хакындагы сүзләр, ниһаять, Сәүбәнгә тәэсир итте булса кирәк, ул аягын салындырып торып утырды.
— Әнкәй? Кайда ул? Син кем?
— Әнкәң тышкы бүлмәдә калды. Мин — синең әткәң...
— Әткәй? Юк минем әткәй...
— Бар, бар! Менә ул мин!.. Әйдә тор, тизрәк китик моннан!..
— Юк, кайтмыйм мин. Кайтасым килми...
— Ник, улым?
— Ә-ә-әнә теге йолдыз чакыра мине, — малай гөмбәз очындагы ачыклыкка күрсәтмәкче булды.
Сәүбән дә күрде ул зәңгәр бушлыкны. Шул бушлыктан үрелеп карап торган Чулпанны да шәйләп калды хәтта...
Ләкин иң гаҗәбе таш өстәлдәге язу иде. Чокып-уеп язылган бу чөй тамгаларны күргәч, Сәүбән айнып киткәндәй булды. Чөнки бу серле-сихерле таш өстенә латин хәрефләре белән таныш дога сүзләре уелган иде: «Мәтә. Тикә. Умма. Йәрсә. Иллә. Әнни. Һүнни». Сәүбән үз ачышыннан үзе хыялый була язды. Менә каян килә икән бу сәер дога! Тик... Ни дигән сүз ул? Мәгънәсе ничек? Кем язган аны? Кемгә? Ни өчен?...
Сәүбәннең башында мең төрле сорау бөтерелде. Әмма аларны тәртипкә салырга, билгеле бер юнәлешкә кертеп җибәрергә җай да, вакыт та юк иде. Ул тагын бала Сәүбәнне ашыктырырга кереште.
Тегесе дә тәмам айнып, уянып җитте, ахры. Сәүбәнгә дә ияләшеп җитте. Бүтән карышмады, сорашмады, дулкынланып торган идән буйлап, алпан-тилпән килеп, караңгы коридор авызына табан китте. Сәүбән аңа иярде. Малай караңгыда йөреп күнеккән иде, ахры, туктап та тормыйча, шул караңгы бушлыкка кереп юкка чыкты.
Факелын алга сузып, Сәүбән аның артыннан иярде. Йөгерә-атлый бара торгач, ниһаять, куып җитте. Бу вакытта стена аша ишетелгән гөрелте тагын да көчлерәк яңгырап, ниндидер ерткыч хәшәрәтнең ырылдавын, улавын, ысылдавын хәтерләтә иде. Таш идән әвәрә килеп селкенә, Сәүбәннәрне әле бер як стенага, әле икенче стенага бәрмәкче була. Менә бервакыт ком-тузан коела башлый, өстә нидер кырыла, чытырдый, шартлый, пыран-заран килә. Таш түшәм менә-менә ишелеп төшәр кебек...
Сәүбән нәрсәгәдер абынып егылды. Читкә барып төшкән факелын капшаган арада, бала Сәүбән, йөгереп килеп, булышмакчы булды.
Сәүбән аңа кычкырып җибәрде:
— Бар, йөгер әнкәң янына, йөгер! Мин куып җитәрмен! Әнкәңне тышка алып чыга тор... Бар, бар!.. Миңа карама...
Малай дәшмәде. «Ярар» дигән кебек баш какты да, әткәсе торып, кузгалып киткән арада, караңгылык эченә кереп юк та булды.
Стенадагы ташлар калтырана башлагач, Сәүбән хәлнең мөшкел булуын аңлады. Малае белән Сәвиясе генә исән чыга алсын иде. Ә үзе... Үзенә дә берәр җай табылыр әле...
Сәүбән күпме йөгергәнен дә белми. Әллә ул бер сәгать йөгерә, әллә ике сәгать... Вакытның чамасы югалды. Хәле дә соңгы тамчысына кадәр чыгып бетте. Җаны гына күтәреп бара аның хәлсез гәүдәсен... Иң мөһиме — ул һаман аягында, һаман хәрәкәтләнә, алга бара. Әллә яшәвенә, әллә үлеменә бара, әмма бара, бара!..
Ниһаять! Менә ул урын. Сәүбән, йөгереп килгән уңайга, стенадан караеп күперәп торган тишеккә кереп китмәкче булды. Әмма, эчкә ике өч адым керү белән, ком-балчык өеменә барып төртелде. Кире чыкты, як-ягына карады. Әллә ялгыштымы? Юк, менә эзләр дә бар. Як-якка бүтән юл юк... Сәүбән, мәгарә авызына кабат кереп, кушучлап ком эшерергә керепте... Шулай берничә адым үтте. Юл ачылмады. Киресенчә, җимерелгән мәгарә эчендә балчык тыгызланды, бөтенләй казып булмас хәлгә килде. Сәүбән шунда гына төп юлның өзелгәнлеген аңлады. Ул, балчык өемендә утырган килеш, кулындагы утка карап уйланып алды: Гомер шушы факел кебек ләса. Артык тиз чапсаң, ул

гөлт итеп сүнәчәк... Сәүбән дә шундый хәлдә: тизрәк йөгермәсә — аны тау басачак, артык нык чапса — уты сүнәчәк...

Кеше өчен иң куркыныч нәрсә — бернидән дә курыкмау. Шуңа күрә, мин үзем, автор буларак, Сәүбәннең Кала-тау эчендәге тетрәнүләрдән куркып калуын гадәти бер хәл итеп кабул иттем. Чөнки мин беләм: Яшәеш, Табигать бервакытта да алдамый. Кеше үзе алдана. Сәүбән белә: Кала-тау аңа мәрхәмәтле. Әмма ул Сәүбәннән риза түгел. Шуны белә торып, Сәүбән аны үртәп, борчып йөри. Кала-тауның бу кыланышларын шуның белән генә аңлатырга мөмкиндер...

Сәүбән кабат киң коридорга чыкты. Факел янып бетә язган. Ун-унбиш минуттан пыску кисәүгә калачак ул. Шул ара эчендә бу эчке юлны өйрәнергә кирәк — бәлки, тагын берәр коридор бардыр? Сәүбән факелын алга сузды. Ут ялкыны кире якка авышып яна, димәк, бу юлда ниндидер һава агымы йөри. Шул һава сулышы буенча барса, тышка алып чыга торган берәр мәгарә тишегенә юлыгачак, мөгаен. Сәүбәнгә озак барырга туры килмәде, бер тынга хәл алырга тукталган мәлдә, сул як стенадагы бер олы таш кителеп төшеп, аның урынында кеше сыярлык тишек барлыкка килде. Шунда кереп карарга булды Сәүбән. Кысынкы коридор буенча бераз баргач, аяк астында калтыранып торган сукмак өскә менеп китте. Менә рәхмәт: менәргә җиңел булсын өчен, баскычлар да уеп куелган хәтта.

Сәүбән тәмам хәлдән тайды. Башка вакытта ул, егылып, күптән инде аяк сузган булыр иде. Тауның ара-тирә калтыранып, тетрәнеп алуы аңа көч биреп тора кебек. Юк, бу куркудан туган көч түгел, ничек газизләрен — Сәвиясе белән малаен табу теләгеннән туган көч иде. Ул коткармаса, кем коткарыр бу ике Хода бәндәсен. Малае гына барып җитә алсын иде! Бергә-бергә ничек тә чыгарлар иде әле...

Сәүбәннең факелы янып бетте. Ул инде капшанып, кармаланып кына менә. Аның бөтен җиренә тузан, ком коела, алдагы сукмак очыннан вак ташлар тәгәрәп төшә...

Менә берзаман Сәүбәннең кулы дымлы балчыкка кагылды. Ул, куанычтан, йөрәгенең ярылырдай булып тибүен тойды...

Ул бит җир өстенә якынлашып килә! Дымлы җир — яшәү чыганагы, тормышка юл дигән сүз! Тормышка, яңгырга, күккә, йолдызга юл!.. Ничек сагынды Сәүбән шушы бер көн эчендә зәңгәр күкне, зәңгәр болытларны, зәңгәр киңлекне! Җилне, һаваны сагынды!

Сәүбәнгә инде менә ничәнче мәртәбә каяндыр көч иңде. Ул ике-өч баскычны бер генә сикереп менә башлады. Аяк асты тайгакланды, стена юешләнде. Җир өстенә дә күп калмады, ахры. Әмма һаман да тирә-юнь дөм караңгы, алда, өстә яктылыкның әсәре дә күренми... Шулай кармаланып менеп барганда, Сәүбән кинәт убылып ниндидер коега төшеп китте. Әмма төшеп кенә калмады, тәкмәчли-тәкмәчли ниндидер сулы чокыр буйлап көн яктысына тәгәрәп килеп чыкты.

Сәүбән бераз вакыт һушын җыялмыйча ятты. Керфекләрне ачаргамы-юкмы? Ачса, нәрсә күтә аны? Шул ук караңгы базмы? Әллә Кояшмы? Яктылыкмы? Бик озак төште бит ул... Әйе шул, гомер дә тау кебек — озак менәсең, бик тиз төшәсең...

Бермәл тыны буылып, сулышы өзелеп, сөяк-санагын җыялмыйча ятты. Әлегә Сәүбән сөенергәме-юкмы икәнен белми. Аның сөенерлек тә хәле калмаган иде бугай. Шулай да чайкала-чайкала булса да торып утырды ул. Өс-башына, кул-аякларына күзе төште. Карарлык урыны калмаган. Сынган, имгәнгән җире күренми. Монысы сөендерә. Димәк, аяк басып йөрерлек әле.

Сәүбән Кала-тау итәгенең нәкъ урта җиренә килеп чыккан икән. Түрдәге кыя ягына шактый урап барасы бар. Бармыйча ярамый. Әнә бит тау һаман котыра, ыңгыраша... Эчендә Дию пәриләре тегермән ташы тәгәрәтеп уйный диярсең...

Сәүбән, күңеленнән чамалап, Сәвия белән малае чыгарга тиешле мәгарә авызына таба китте. Озак барырга туры килмәде, кыяның нәкъ өстендә пәйда булды. Аска таба үрелеп карады — беркем дә күренмәде. Чишмә буен, юкәлек тирәсен айкап алды — ул тирәдә дә хәрәкәт-мазар күзенә чалынмады.

Димәк, чыкмаганнар... Чыга алмаганнар... Әллә малай әнкәсе янына барып та җитмәгәнме?

Сәүбән өстән шуып диярлек төште; төште дә шундук мәгарә авызына йөгерде, иртән үзләре кереп киткән тау куышы каршына килеп тә басты. Кермәкче булып башын иде, кулларын алга сузды. Әмма бу юлы да аның бармаклары ком-балчыкка килеп төртелде. Утта пешкән кебек, Сәүбән кулын җәһәт кенә тартып алды. Аның йөрәге тагын ярсыды, җаны сызылды. Иң кадерле кешеләре тау эчендә бикләнеп калган бит, ничек борчылмыйсың да, ничек өзгәләнмисең ди...

Сәүбән бу юл-тишекне казып кына чистартып бетерү мөмкин түгеллеген шундук аңлады. Икенче бер чара табарга кирәк булачак. Кая барырга, нишләргә? Их, адәм баласы табигать каршында шулкадәр көчсез, шулкадәр мескен, берничә минут эчендә яшәү белән үлем арасында аерма юыла да куя...

Үлем булмаса, яшәүнең мәгънәсе булмас иде. Ахыр чиктә, яшәү ул — бертуктаусыз үлеп һәм туып тору. Үлем белән Яшәүнең дәрәҗәләре тигез — алар бер-берсеннән башка яши алмыйлар. Үлемнән курыккан кеше яшәүнең тәмен белми.

Чишмәдән су эчәргә төшкән Сәүбән берни кыла алмады — улактан һаман әле кызыл су ага иде.Ул, соңгы көчен җыеп, якындагы юкә төбенә барып утырды. Аннары, чирәмгә чалкан төшеп ятты да, үзара сөйләшүче юкә ябалдашларына карап тынып калды…

Уйлары гына бертуктаусыз йөгерә, йөгерә, йөгерә…

Тау гына бертуктаусыз гүелди, гүелди…

Ничек коткарырга? Ничек тартып алырга ул газизләрен үлем тырнагыннан? Сәүбән үзе дә чак тере. Ичмасам, эчәргә суы да юк бит аның… Үпкәсе тузанга каткан… Әллә сихер, әллә тау куышында көне буе тузан сулап йөрү галәмәте? Сулавы кыен, уйлавы кыен… Сулышының — ялкын, йөрәгенең салкын чагы…

Нәрсә генә булмасын, иң мөһиме — ул исән. Кала-тау аңа, мәрхәмәтле булып, иң кыен чакта юл күрсәтте. Димәк, ул аны кичерде… Барысын да кичерде… Тукта, нигә аны кичерде соң әле? Нигә аны гына кичерде ул? Ә Сәвиясен, малаен нигә йолып алып калды, нигә аларга мәрхәмәтен кызганды? Әллә бу кичерү Сәүбәннең гөнаһларын аклау бәрабәренәме? Алар бит Сәүбән генә түгел… Әгәр фәрештәләрнең фәрештәсе булса, Сәвия — әнә шул фәрештә инде… Әллә?.. Сәүбәннең бу кайтуы сынау өчен генәме? Аны тагын бер мәртәбә сыныйлармы? Нигә «тагын»? Беренче һәм… соңгы мәртәбә…

Юк, болай ятарга ярамый. Торырга кирәк, нидер эшләргә кирәк! Соңга калуы бар… Әнә ничек үкерә бит тау зәхмәте… Инде кайттым дигәч кенә, эзләгәнне таптым дигәч кенә…

Сәүбән карт юкәнең кытыршы тәненә ябыша-ябыша торып басты. Үрелеп, берничә яфракны өзеп алды да авызына капты, иренеп кенә чәйни башлады. Юкә яфрагы ачы, әмма ул шифалы: сусауны да баса, тәнгә хәл дә кертә. Сәүбән бу хакта онытмаган икән әле.

— Рәхмәт… Әле дә син бар… Әйт әле, юкә, нишләргә миңа, кая барырга? — Сәүбән үзенең юкә белән сөйләшә башлавын сизми дә калды.— Син бит безнең сөешкән чакларны, матур яшьлегебезне күрдең, йолдызлы күккә ымсындырдың, бишегеңдә тибрәттең, кеше күзеннән яшереп иркәләдең… Хәзер дә бер ярдәм итче, юкә?.. Их, юкә…

Әгәр бар икән, әгәр дә ул чын икән, ихлас икән, өмет бервакытта да кешене алдамый.

Кеше рухи көчне җиргә карап түгел, зәңгәр күккә карап ала. Хыялга, идеалга, максатка омтылыш — шәхеслек билгесе. Шушы минутта җир белән күк арасында бәргәләнгән Сәүбән үзен беренче мәртәбә шәхес итеп тойды.

Көтмәгәндә бер сәер хәл булып алды. Каяндыр көчле җил чыгып, юкәнең куе ябалдашларын шаулатып йолкый башлады. Бераздан бу җил янәшәдә торган икенче юкәгә күчте, аннары өченчесенә, дүртенчесенә… Бишенчесенә… Шулай шау-шу куптарып, юкәдән юкәгә күчә барып, бу адашкан җил тау башына менеп китте һәм аның бөкресе артына төшеп югалды…

Сәүбәннең караңгы мәгарә дөньясында йөреп томалана башлаган аңы ахылдап кузгалып куйгандай булды, бераздан, уянып, тернәкләнә башлады. Ничек ул моны элек күрмәгән, тоймаган: - бу юкәләр рәтендә ниндидер сер бар… Бу бит… Бу бит мәгарә юлы! Борынгылар мәгарә юлын шулай билгеләгәннәр! Юкәләр рәте — махсус билге, тамга, ишарә!..

— Дөрес. Тап өстенә бастың.

Сәүбән, сискәнеп, артына борылып карады. Аның янында бер малай басып тора иде.

— Син кем?

— Тау эчендә акылыңны калдырып чыктыңмы әллә? Кереп киткәндә кем озатып калды соң сине?

Сәүбән «бала чагым бит бу» дип уйларга өлгермәде, малай тагын:

— Бүтән онытма, ату үпкәләп куюым бар, үзең беләсең мине… — дип, борынын мышкылдатып куйды.

— Син минем хәлләрне беләсең алайса…

— Беләм.

— Берүзем генә чыктым шул… Үзем калып, хет алар чыксын иде…

— Син миңа ошадың анда… Батыр кеше син. Мин хәтта горурланып тордым.

— Ярдәм генә итмәдең.

— Бу хакта сөйләшмәскә сүз куештык бит инде. Ату үпкәлим…

— Бетте-бетте! Син — рух, рух, рух, рух!.. Син — фәрештә, идеал! Ә мин — кеше, беләсеңме, кеше! Ке-ше! Мин фәрештә түгел! Минем Сәвиям белән Сәүбәнем үлеп ята анда!.. Тыныч кына сөйләшә алмыйм мин… Минем… Менә шушы юкәне йолкып атасым килә! Шушы тауны җимереп, актарып ташлыйсым килә!.. Минем… хәтта үләсем килә!.. Белдеңме? Ә син… җанны үртәп торган буласың… Үпкәлим, имеш. Үпкәлә! Бар! Кит! Олак! Мин сине чакырып китермәдем, үзең килдең… Үзең кит тә!..

Тезләренә төшеп, елый-елый, йодрыклары белән җир төйгән Сәүбәнгә карап, малай бер сүз эндәшмәде. Ул үз теләгенә ирешкән иде: Сәүбәнне елатып, мәгарә тузаны белән укмашып каткан бәгырен эретеп җибәрде ул…

Сәүбән озак үксемәде. Бу минутта аның яшәү тизлеге бөтенләй бүтән кимәлдә, башка чамада иде шул. Ул бая гына күңеленә килеп кергән юкәләр рәтенә кабат әйләнеп кайтты. Баштарак томык, ерак образ булып кына туган бу юкәлек тора-бара ышанычка, яшәү мәгънәсенә һәм, ниһаять, өмет чыганагына әверелде…

Сәүбән, кинәт тынычланып, тезләнеп торган җиреннән кыя тауга, аның да юкәләр рәте менеп киткән ягына күтәрелеп карады.

— Дөрес уйлыйсың, мәгарә юлы ул.

— Анысын беләм.

— Белгәч, уйла…

— Өстән төшеп булырмы, дип уйлыйм.

— Була, нишләп булмасын.

— Кайсы урында икәнен ничек белим соң?

— Уйла, уйла…

— Уйлыйм да соң… Аз гына әйтеп җибәр инде, ә?

— Ярый алайса, тыңла: өстә — иң аста, аста — иң өстә, — нәрсә ул? Шуны белсәң — юлны табарсың…

«Менә сиңа мә! Үзем сорап алдым, сер бирергә ярамый,— дип уйлады Сәүбән. — Нәрсә булыр бу? Өстә — иң аста, аста — иң өстә… Тау дисәң инде… Өстә… Аста… Юк, тау түгел… Агач… Агач та түгел… Нишләп агач булмасын?! Агач! Агач тамырлары!»

Сәүбән үз ачышына сөенеп бетә алмады. Хәзер агач тамырларын Сәвияләр белән бәйләп куясы гына калды. Ничек бәйләргә соң? Ничек? Тамырлар… Агач тамырлары… Шунда Сәүбәннең күпне күргән, күпне кичергән башына «уй сукты»: бу бит юкә тамырлары! Шушы юкә тамырлары. Бу уй артыннан хәтеренә яктылык сирпелде: Сәвия калган мәгарә түшәмендә агач тамырлары асылынып тора иде. Алар бит шушы юкәләрнең җир астындагы тамырлары!

Менә кайда икән хикмәт! Тик ничек бәйләргә соң бу юкә агачларын Сәвияләр калган мәгарәгә? Әнә юкәләр рәте тау өстенә менеп бара. Өскә менгәннәре кабат бер иңкүлеккә, чокырга төшеп хәл җыйгандай итәләр дә тагын югары үрмәлиләр… Мәгарә түшәмендә асылынып торган тамырлар әнә шул иңкүлектәге юкәләрнеке булырга тиеш. Сәүбән моңа шикләнми хәзер. Бу хакта бала чагыннан сорап карарга кирәк әле. Кайда соң ул?

Сәүбән тирә-ягына күз йөртеп чыкты. Бала чагы күренмәде. «Тагын китеп югалган. Нинди тиктормас малай булды инде бу»,— дип уйлады ул. Үзе һәрвакыт чишмә янында була торган сынык саплы көрәкне барып алды, аннары, бил каешына тагылган бауны барлап, кояшта кибеп каткан кылганнарга тотына-тотына, Кала-тауга менеп китте…

Аяклары атламас булып карышса да, Сәүбән үзенчә бик тиз менәргә тырышты. Һәр минуты кадерле. Калтыранып, үкереп ярсыган тау эчендә нинди җаннар өзелеп ята бит. Иң газиз, иң саф җаннар! Алар булмаса, Сәүбән гомере дә бөтен мәгънәсен югалтачак, пар канатлары сыначак. Сәүбәннең пар канатлары — Сәвиясе белән малае. Соңгы көннәрдә шушы пар канат аны яшәтә, җирдән күтәребрәк, ниндидер хыялый дөньяда очыртып йөртә…

Күктән эзләгән җирдән табар, диләрме?

Сәүбән үрмәли-үрмәли өскә менеп җиткәндә, уйсулыкта үсеп утырган ике юкә арасында әлеге дә баягы аның бала чагы басып тора иде.

— Си-и-ин?

— Мин, кем булсын тагы…

Төксе генә сүз алыштылар. Сәүбән, килгән уңайга, малайны узып китте дә уйсурак бер урында казый да башлады. Казыган саен, көрәгә каты тамырга төртелә. Сәүбән, ухылдап, аны кисеп ата, тагын казый, тагын кисә…

— Тамырын кисмә, ул сиңа кирәк булачак әле… — Моны янәшәдә басып торган малай кисәге әйтте.

— Нәрсәгә кирәк соң ул?

— Балчыкны тотып тора бит ул. Ишелеп төшеп, харап буласың бит.

«Әһә, димәк, мин дөрес казыйм, юкса бала чагы бу кадәр кыланып торган булыр иде микән?» — дип уйлады Сәүбән.

— Әле күп бармы?

— Кабер тирәнлеге казыйсың бар әле…

— Кит әле, дивана! Сине тыңлап торган мин дивана!

Сәүбән казыды да казыды. Ул инде, аралап, тамырларны кисмичә калдыра башлады. Чынлап та, кеше тирәнлеге казыган иде, бу «кабер»гә әллә кайсы гына ерынтыктан шыбырдап су агып төште. Их, читтәнрәк аласы калган икән көрәкне! Әнә ул су төшеп китә торган тишек. Су сеңеп юк була, димәк, каядыр аска агып төшеп китә.

Сәүбән үзе казыган «кабер»нең шул тишекле ягын ярсып «кимерергә» тотынды. Дымланып яткан су юлына тизрәк төшмәкче булды ул. Куркыта да бераз. Ишелеп төшеп китсәң? Сәүбән көрәк белән саграк кылана башлады, җыелган балчыкны да өскә көрәк белән түгел, кушучлап атты… Үзле балчык көрәккә сылана, аякка ябыша, әмма Сәүбән моңа әллә ни әһәмият бирми, тауның зәһәр гөрелтесен шомланып тыңлый-тыңлый, үҗәтләнеп казый да казый… Көрәккә ябышкан балчыкны тегe зур ташка кагып төшерә.

Озакламый Сәүбән казыган җир үзе дә мәгарә тишегенә охшый башлады.

Кала-тау аның Сәвиясен, малаен тирәнгә яшергән булып чыкты… «Гомер буе күрми яшәдең, инде тагын беразга түзәрсең», — дигән кебек, мыскыллап көлә, ахры, ул.

Инде бөтенесенә кул селтим дигәндә генә Сәүбәннең кыска саплы көрәге эчкә батып китте, җанына җылы йөгерде. «Менә ул куышлык, менә ул яшәү һәм өмет дөньясына туры юл… Туры микән? Урауның да уравы, ахры, бу…» — дип, көрсенеп уйланды Сәүбән, Сәвияләрне ябып торткан мәгарәне табуына ышанмыйча…

Дөрес сизенгән икән. Бернинди тау куышы да юк монда. Юеш балчык, ләм эченнән ниндидер таш, агач кисәкләре актарылып чыкты. Бу йомры таш ни тагы? Ай-ай-ай… Агач та, таш та түгел, кеше сөякләре бит болар! Менә аяк чатлары, кул чуклары, баш сөяге…

Бермәл аңышмыйча торган Сәүбән, нишләгәнен дә белештермичә, көрәген атып бәреп, өскә сикереп чыкты… «Инде мәет кенә җитмәгән иде… Нинди афәт артыннан афәт соң бу, гөнаһ шомлыгы!..» — дип тиргәнеп алгач кына күңелендә җиңеллек тойды ул.

Шунда гына басып торган бала чагы да озак көттермәде:

— Ник мендең? Нәрсә булды? Сөяк күргәнең юкмы әллә?

— Кеше… Кеше сөяге бит ул…

— Сөяге генә шул. Аның җаны да, сихер шаукымы да йә җиргә иңеп, йә күккә очып беткән инде.

— Бетсә ни… Әллә нинди зәхмәтле кеше булгандыр әле…

— Кем дип уйлыйсың соң?

— Каян белим мин аны?

— Сарманайда Кала-тауга китеп бер генә кеше югалды, син аны беләсең?

— Әйе.

— Каян төшкән соң ул бу кадәр җир астына?

— Төшмәгән, менгән.

— Ничек?

— Ул монда Кала-тау сөйләшкән вакытта килде. Тауның серен бик беләсе килгән иде.

— Белдеме соң?

— Белде. Аны инде син дә, малаең Сәүбән дә белә. Тауның зәһәре төште Хөсни картка. Шуңа да тау аны үзендә йолып алып калды. Стенага баскыч ясап, түшәмгә кадәр менүен менде карт, хәтта өскә юл да казый башлады. Ләкин күп китә алмады. Тау аны үзе чокыган ярыкка кысып үтерде…

— Мине кысмасмы соң, әнә бит ничек үкерә…

— Юк, сине үз итте ул, гаҗәп хәл… Аннары… Рухи зат буларак, мин аңардан бик нык үтенеп сорадым. Фәрештәдәй Сәвияң, изге ирән кебек балаң өчен бөтен тылсымымны чәчеп ялвардым. Ул мине аңлады…

— Рәхмәт сиңа…

— Рәхмәт әйтмә, мин моны синең өчен түгел, Сәвия белән аның малае өчен эшләдем.

— Табармынмы мин аларны?

— Табасың киләме соң?

— Көләсеңме әллә?

— Ник һаман күзле бүкән кебек басып торасың, алай булгач? Казы, казы!..

Сәүбән юеш чокырга кабат сикереп төште дә, ниндидер кыргый бер ярсу белән ухылдый-ухылдый, ыңгыраша-ыңгыраша, казырга керешге. Сөякләрне бер якка җыеп куйды, өзек-өзек кенә хәтерендә калган «Ясин» догасын укыды…

Агач тамырлар вакланып, коры-сары ташлар чыга башлагач, Сәүбәнгә җан керде. Инде күп калмаска тиеш, мәгарәнең эчке стенасыннан тырпаеп чыгып торган ташларның игезәге бит болар. «Тагын бер төртәм дә, тагын бер төртәм дә…» — дип казый торгач, тагын берничә көрәк калынлыгы җир үтте ул. Мәет тә әллә кайда өстә калды. Чокыр тишеге дә адәм буе җитмәслек җирдә хәзер. Казылган балчыкны да учы белән генә алып чөя ул.

Сәүбәннең күңеленә тагын салкын шом кереп тулды. Читкә киттеме әллә? Тагын нинди зәхмәт шаяра аның язмышы белән? Нинди сихер талкый аның баш бирмәс җанын?

Сәүбән, тәмам хәлсезләнеп, чокыр төбенә утырды. Өскә күтәрелеп карады. Хәзер теләсә дә менә алмый инде ул анда кадәр... Бердәнбер юл кала — аска, җирнең бәгыренә төшкәнче, җан җиренә җитеп егылганчы, әчәгесенә уралып үлгәнче аска! Бары тик аска...

## 18

Сәвия Сәүбәннең кулларын үз иңеннән алып куярга кыймыйча озак ятты. Күңеленә тулышкан уйларын тәртипкә салыр өчен уңайлы вакыт иде.

Сәвия бик моңсу иде бу минутта. Гел шулай була: чиксез бәхет белән чиксез бәхетсезлек очрашкан урында моң туа. Мәгарә авызындагы мәйданчык — әнә шундый серле-сихерле моң бишеге булып чыкты.

Сәүбәннең авылга кайтуына ул һаман күнегеп бетә алмый әле. Инде менә күрештеләр, аңлаштылар да, бер түшәктә янәшә яталар. Әмма Сәвия барыбер күнегә алмый аңа. Үз дә ул, ят та... Кайчандыр бәгыреннән өзелеп төшеп калган шул ук җан югыйсә. Юктыр. Хәзер килеп кенә ялгана алмас...

Унсигез ел — күбрәк шул. Бу вакыт эчендә иң олы йөрәк тә күңел хисләрен түкми-чәчми саклап кала алмас иде, мөгаен. Хисләр шактый тузган... Ә менә сагыш шул килеш. Сәвиянең сагышы үзгәрмәде. Ун елда да, унсигез елда да саф, садә килеш калды... Чөнки сагыш ярату ачысы гына түгел, мәхәббәт иркәсе генә түгел, ул — киңрәк төшенчә! Сәвиянең гомерлек сагышы да Сәүбәнне сагынудан, юксынудан яисә аны өзелеп көтүдән генә тормады, бу сагышка матур хатирәләр дә, якты хыяллар да, өмет чаткысы да, язмышның изге-илаһи ым-ишарәсе дә, татлы газап та, газаплы бәхет мизгелләре дә, яшькә чыланган түшәк-мендәрләр дә, кояш кунган тәрәзәләр дә — барысы да кереп беткән. Бу сагышка улы, уллары Сәүбән дә матур гына кереп урнашкан...

Мәхәббәт — бәгырь җимеше. Аны өзсәң, бәгырь дә өзелә. Бәгырь өзелсә — өмет өзелә. Сәвиянең бәгыре исән-сау булып чыкты...

Ярату — аңлаешлы, җайлы, төгәл хис. Чөнки аз гына, бераз гына яисә өлешчә генә яратып булмый. Яратуның кануны катгый: йә яратасың, йә юк. Калганы — күңел көязлеге генә... Сагыш катлаулырак... Сагыш ул — үз-үзең белән көрәш, җан диалектикасы. Шушы көрәштән саф, садә килеш, горур килеш, кәпрәймичә яисә түбәнлеккә төшмичә чыга алсаң — син чын, ихлас кеше. Шул сагыш сазлыгына кереп батсаң — бетәсең; синең гарип күңелең, һәр авырлык алдында тезләнеп, аңа баш иярга гена тора...

Сәвия сагыну афәтеннән кешелеген югалтмыйча котыла алды. Сагыш күлмәгеннән елгыр гына шуып чыкты да үз язмышын үзе кора башлады. Авыр хисләрдән арынырга улы Сәүбән булышты. Баштарак бала мәшәкате, бала назы аның ике кулын, җан-күңелен буш тотмады, аннары кеше гайбәте күңелен катырды, соңга табарак сөю сагышы белән бәйле бөтен хисләре, бер йомгакка укмашып, хәтеренең иң ерак почмагына тәгәрәп төшеп китте. Сәүбәннең кайту хәбәре генә ул авыр йомгакны селкетә дә, кузгата да алмады. Ә менә малаеның үз эткәсен эзләп китүе, аннары үпкәләп юкка чыгуы Сәвиянең күңелен кузгатып җибәрде, ахры. Әмма ул белми иде әле: арыган рух, сагышны күтәрсә дә, бәхетне күтәрә алмый. Сәвиянең арыган, алҗыган рухы да бер мәлгә аптырап калган кебек булды...

Сәүбәннең Кала-тауда булуын күңеле белән сизенеп белә иде ул. Туры шунда барды. Әмма мәгарәнең эченә үк керергә кыюлыгы җитмәде.

«Сәүбә-ә-ән, улы-ы-ым!..» — дип, берничә мәртәбә кычкырып карады да, Рух чишмәсе янына утырып, басынкы гына җыр суздЫ:

Күңелемдә һаман сөю яши,
Мин һаман да өзелеп яратам.
Чишмә суы гел бәхеткә юрый,
Чишмә суларыннан юратам...

Бу чишмә дигәннәре дөньяда исең-акылың китәрлек бер могҗизадыр. Әнә бит ничек тибеп-тибеп ага. Йөрәк кебек...

Йөрәгемә таулар, кодрәт биреп,
Горурлыгын җанга иңдергән.
Җан-күңелнең асыл сыйфатларын
Чишмә суы аша сеңдергән...

Каян килеп керде соң әле бу җыр аның теленә? Әллә нинди сәер җыр ул...

Суларыңны хушлап торган таулар
Туганнарча якын, кадерле.
Күктән җиргә төшкән йолдызларга
Бишекме ул, әллә каберме?

Күк йөзенең ачы күз яшьләре
Бәреп чыккан, диләр, таллыктан…
Ятим язмышларны сыендырып,
Йолдыз саен бер тау калыккан…

Сәвия үз күңелендә тибрәлеп торган әлеге җырның каян килгәнен хәтерләми… Бу мөһим дә түгелдер. Иң мөһиме — ул җыр бар. Димәк, күңеле буш түгел, аның рухы, җаны фани дөнья белән матур бәйләнештә яши… Җыр бит ул — чынбарлык белән күңел дөньясын тоташтырып торган сихри басма, күпер… Кеше, җырга, моңга тартылган саен, үз кадерен ныграк белә бара. Кешенең кадере булмаса, иң матур хыяллар да бернигә тормый.

Сәвия үзенә-үзе аптырады: баксаң, ул такта күпердән чыгып бара… Ниндидер тылсымлы көч алып бара, ахры, аны… Әллә ул Сәүбәннең әрәмәлектә булуын сизеп барамы? Нәрсә чакыра, кем әйдәп йөртә аны? Әйдәп, чакырыпмы, әллә куалап йөртәме? Әнә кемдер чынлап та куалый аны. Кем ул? Кешеме, әллә рухи затмы?

Сәвиянең күңеленә шом йөгерде. Ул, әрәмәлектән чыгып, зиратка керде. Анда тагын да куркынычрак иде. Күктәге болытларның әвәрә килеп тулгана башлавын да Сәвия әйбәткә юрый алмады. Ул, зираттан чыгып, кабат Кала-тау мәгарәсенә таба йөгерде.

Авылга юл ябык, бердәнбер юаныч шунда — малаен үзенә алган Кала-тауда кебек тоелды аңа. Теге адәм заты да аның артыннан калмыйча бара. Шулай, энә-җептәй тагылышып, алар тау куышына җиттеләр. Яңгыр ява башлады… Моннан соңгы вакыйгалар Сәвия өчен сихри төш кебек кенә…

…Сәвия тагын чишмә тавышына игътибар итте. «Чишмә төсле чылтырап, бар моңнарны уяттың…» диясе килде аның. Ничектер үзгә чылтырый ул бүген. Ара-тирә ике кош сайрап ала. Сандугачлар түгелме? Юктыр, сандугач булса да, карлыккан тавышлысыдыр… Чишмә буендагы таллыкка бүген алар хуҗа, күрәсең. Ләкин бу кошлар озак сайрый алмадылар, тындылар, ниндидер шомлы хәл аларны, куркытып, куып җибәрде, ахры…

Сәвиянең аң-зиһенендә тагын берничә нарасый уй бөтерелде.

Әлбәттә, Сәвия хәзер дә Сәүбәнне ярата. Сәүбән дә аны ярата. Бу аның бөтен табигатеннән, эшгамәленнән күренеп тора. Алар бу яратулары белән бәхетле түгелмени? Бәхетнең гомере кыска, әмма аны кеше гомере белән генә үлчәп бетереп булмыйдыр. Сәвия белән Сәүбән мәхәббәтенең, бәхетенең гомере күпме соң? Әгәр алар бәхетле икән, бу бәхетнең гомере нинди?

Сәүбәннең кулын сак кына читкә этәреп, Сәвия торып утырды, чәчләрен рәтләде, яулыгын кысып бәйләде. Башы, бөтен тәне, сызлавык белән капланган кебек, әрнеп тора. Чишмә суында юынсаң, сызлаулар бетәр кебек тоелды аңа…

Моннан соңгы вакыйгаларны да Сәвия төшендә яшәгән кебек яшәде. Агуланып, кан косып ятучы чишмә… Юкә төбендә үз-үзе белән сөйләшеп йөрүче Сәүбән… Мәгарә тишегенә үрмәләп кереп китүләре… Ялгыз калуы…

…Тау төпкеленнән килүче шомлы гөрелтене тыңлап озак ятты Сәвия. Ул Сәүбән калдырган ризыкларга кагылмады, аларны җыеп, төйнәп, кабат капчыкка салып куйды. Бераз хәл кергәндәй иткәч, торып, тирә-ягын өйрәнә башлады. Тамчы тамып торган почмакка барып, учына су җыеп эчте. Шул урыннан ерак та түгел ниндидер баскыч менеп китә. Ул инде кителеп, җимерелеп бетә язган. Каядыр бара бит ул… Әнә өстә асылып торган, тау гөрелдәп куйган саен селкенеп, кузгалып ала торган ике мәһабәт ташка барып төртелә… Ары юл юк… Сәер… Бәлки, ул баскыч та түгелдер… Ниндидер сихри тамгадыр, тылсымлы ишарәдер?

Шушы серле, шомлы тау куышына килеп йөргән икән аның Сәүбәне… Ничек курыкмыйча йөргәндер… Атасы да гел килә иде… Әнә бит ничек курыкмыйча кереп китте… Ничек кермәсен, газиз баласын, үз канын эзләп йөри бит ул… Ходай җан биргәнгә юнь бирер, дигәннәр. Бер җай чыгар әле, бер җай чыгар… Исән-сау гына булсыннар инде. Әнә бит ничек котырына Кала-тау…

Сәвия тагын түшәгенә барып утырды. Учларын алга кушырып озак итеп дога укыды. Әмма барыбер тынычлана алмады. Күңеле шомланып сизенә: нидер булыр кебек, нидер булыр…

«Их, Сәүбәнгә ияреп китәсе калган икән», — дип уйлады Сәвия. — Хет берәр файдам тияр иде…»

Өйдә калган мал-туары да җан-бәгырен әрнетеп тора. Ичмасам, сыеры савылмыйча ята… Кичә күрше апалары керткәндер кертүен, бүген көтүгә кем чыгарыр инде? Кем куар?

Шул вакыт, җан әсәре табан астына төшеп ятарлык итеп, көчле иңрәү, хәтта шартлау тавышы ишетелде. Тау ишелгәндәй, мәгарә җимерелеп төшкәндәй булды. «Бетәм бугай, бетәбез бугай»,— дип уйлап өлгерде Сәвия. Нәкъ шул вакытта тыштан керә торган мәгарә юлыннан тузан болыты атылып чыкты һәм уртасында Сәвия басып торган таш бүлмәне томалап та куйды. Томан бераз сүрелә башлагач, Сәвия сак кына таныш мәгарә авызына таба китте һәм… ах итте: шул арада мәгарә тишеге алсу-күк тау балчыгына дыңгычлап тутырып куелган иде.

Сәвия, буыннары алынып, таш сәкегә утырды. Озак кына һушын җыя алмыйча торды. Тузан томаны басылган кебек, аның күңелендә чәбәләнгән шомлы уйлар да күңел төбенә утыра башладылар һәм «Җир астында калдыкмы әллә?» дигән хәтәр сорау булып укмаштылар…

Сәвиянең моңа һаман ышанасы килмәде. Афәт бөркеп, тасыраеп карап торган тау тишегенә кабат-кабат барды, андагы балчыкны үзенә таба эшереп карады. Аннары, шул таш сәкесенә утырып, мескенлегенә, үксезлегенә түзә алмыйча елап җибәрде…

Хатын-кыз елавы иң ачы, иң авыр әйбердер бу дөньяда. Сезне дә, укучыларым, Сәвиянең күз яшьләренә кагылдырасым килми. Бик озак елады ул. Аның бу елавы каргыш та, ачыну-көенү дә, кайгы шаукымы да түгел, бер изге дога кебек иде… Һәм бу доганы җир, тау, табигать ияләре генә түгел, күктәге Ходай да, галәмдәге йолдызлар да ишетергә тиеш иде. Ишетеп кенә калмыйча, изгелек белән җавап бирергә тиешләр иде. Җавап озак көттермәде, ул малае белән Сәүбән кереп киткән тишектән «Әнкәй! Әнкәй!..» дигән зәгыйфь, хәлсез тавыш булып килеп иреште…

Газиз җир: «Иелгәнгә генә бирермен»,— дигән. Бу өметкә дә, хәтта бәхеткә дә кагыла…

Тонык кына янган чыра утында иелә-сарыла елап утыручы Сәвия башта бу тавышны ишетмәде. Борчулы уйлары белән аның колагы томаланган, күңеле ярсынган иде шул. Ләкин изгелек, бер киләм дисә, үзәкләрне өздереп, кайгы пәрдәләрен ертып керә ул. Бу юлы да шулай булды. Ниһаять, Сәвия ишетте ул тавышны, ишетте!.. Ишетеп кенә дә калмады, тойды, күңеленә, күңеле аша язмышына алды. Малаеның чакыруы булып ишетелгән бу тере тавыш әле генә аның күңелен басып киткән кайгы ташын җир катламы аша тышка бәреп чыгарды…

— Әнкәй, әнкәй…

— Әү, балам!..

Сәвия, атылып-бәрелеп, бая Сәүбән белән малае кереп киткән тар тишеккә омтылды.

— Балакаем! Син кайда?..

— Әнкәй… Тартып ал мине…

Сәүбән үзе күренми. Әмма ул кайдадыр якында гына. Нәрсәдер булган аңа… Үзе генә чыга алмыймыни?

Нәрсә булган аңа, нәрсә, нәрсә?..

Сәвия, ут та алып тормыйча, караңгы тишеккә үрмәләп кереп китте. Әмма күп китә алмады, кабер салкынлыгы сеңгән балчык, таш өслегенә килеп төртелде. «Ай,— дип өзгәләнде Сәвия,— әллә бу юл да томаланганмы? Ә Сәүбәне кайда? Ник дәшми ул?..»

— Әнкәй…

— Син кайда, балам?..

— Мин өстәрәк… Менә… кулымнан тот… Мине… җир басты… Әнкәй… әткәй эчтә калды…

«Әткәй» диме? «Әткәй» ди бит! Их, Сәүбән, Сәүбән, үз башыбызга җилкендек бугай без…

Сәвия, ашыгып-кабаланып, алдындагы комны эшерә башлады. Ниһаять, ул, кармаланып үрмәли торгач, улы Сәүбәннең нәни учларына юлыкты, аларны, мәңге җибәрмәслек итеп, кысып тотып алды…

Балчык астында басылып калган Сәүбән бераздан кыймылдап куйды, әнкәсе булышлыгы белән гәүдәсен өскә чыгарды. Аннары, тырыша-тырмаша торгач, үзе дә суырылып, шуышып чыкты…

— Әнкәй…

— Балам…

Алар — ана белән бала — шул тар гына караңгы тау тишегендә, хәлсез гәүдәләре белән бер-берсенә сыенышып, үксеп елап җибәрделәр. Алар түккән күз яше шулкадәр күп иде, бу яшь ташкыны, чишмә булып, җир астыннан өскә бәреп чыгар сыман иде. Бу бер-берсен табу шатлыгы булып бәреп чыккан сөенеч яшеме, әллә әткәләрен югалту ачысы булып аккан кайгы яшеме — белү мөмкин түгел иде.

## 19

— Нәрсә эшләп утырасың анда? Ник казымыйсың?

Сәүбән, өстән ишетелгән тавышка сискәнеп, күтәрелеп карады. Анда аның җанын үртәп, әлеге дә баягы бала чагы басып тора иде.

Сәүбәннең күңелендә дөнья гаме бетеп барган чак. Ул акыллы, белдекле булып кыланучы, ялганчы бу малайга җавап бирүне кирәк тапмады…

— Нишләп утырасың дим?.. Әй!..

Сәүбән кыймылдамый утыруында булды. Өстәге малайга бу бер дә ошамады, ахры. Ул ах-ух килеп ризасызлыгын белдереп алды да каядыр читкә китеп утырды. Сәүбән тагын ялгызы калды. Аның бәгырен бер генә сорау кимерә иде: «Ялгышты микәнни?» Өстә үпкәләп йөрүче малайга да әллә ни ачуы килми аның, юк-юк… Шул бала–чагага ышанып йөрүе өчен үзен-үзе сүкте Сәүбән.

Ул белә: кара уйлар җанны каралта. Шуңа күрә Сәүбән бала чагыннан бөтенләй үк аерылып бетәргә теләмәде.

— Шушында гомерем өзеләме әллә? Әй, син!..

— Юк. Кеше гомере — мәңгелекнең кечерәйтелгән моделе генә. Ә мәңгелек үлми. Димәк, кеше дә үлми…— Бала Сәүбән үзе күренми, әмма тавышы колак төбендә генә яңгыраган кебек…

— Алайса әйт әле: мин җиңәчәкменме?

— Кеше җиңү өчен туа. Әмма һәр җиңгән саен ул бераз үлә…

— Сөендердең…

— Син, абзый кеше, өч әйберне исеңдә калдыр. Кеше үзгәрмәскә мөмкин, әмма ул яхшырак була ала. Кеше үзен күпмегә бәяли, ул шулкадәр тора. Кеше үзен яратырга мәҗбүр итә алмый, әмма хөрмәтләргә мәҗбүр итә ала.

— Боларның барысы да миңа карыймы?

Бу юлы инде җавап әллә каян тау төпкеленнән ишетелде:

— Сиңа карый. Чөнки син — Күк җибәргән зат…

…Агач тамырлары нык вакланды, берсен берсенә ялгап, толымга үрерлек булдылар. Бу куандыра. Чөнки мәгарә түшәменнән асылынып торган агач тамырлары да шул калынлыкта иде. Димәк, күп калмаган…

«Исән-сау гына булсыннар,— дип уйлады Сәүбән үзалдына,— Сәвияләр белән бер-бер хәл булса, чыкмыйм, өстән туфрак ишеп төшерәм дә капланып үләм, Хөсни карт янында урын җитәр әле…»

Сөю белән үлем бөтен кешене дә тигезли, диләр. Мәхәббәте алдында бер мәртәбә рухын сынап исән калган иде инде Сәүбән. Менә хәзер дә үлем каршында тора ул. Газизләре җир астында калып һәлак булса, аның тормышы үлем афәтенә әвереләчәк…

Сәүбәнгә тетрәнеп, калтыранып торган тау үзе ярдәм итте. Билгеле бер ритмга көйләнеп тетрәнгән тау кайсыдыр бер мизгелдә Сәүбән алдындагы ташларны селкетеп куйды. Калганына кеше кулының да көче җитә иде. Сәүбән кечерәк ташны каерып, читкәрәк тәгәрәтте дә, аның урынында пәйда булган тишеккә кулын тыкты. Сәүбәннең кулы бушлыкта, олы, киң мәгарә өстендә асылып калды…

Сәүбән аска үрелеп карады. Эчтә дөм караңгылык иде.

— Эһе-һей!..

Мәгарә эчендә тонык кына җавап ишетелде. Ләкин Сәүбән тавышының кайтавазы түгел иде бу. «Димәк, кемдер бар»,— дип уйлады Сәүбән.

— Сәвия! Сәүбән!

Тынлык. Кабер тынлыгы. Сәүбән сорауны кабатларга булды:

— Сәвия! Сәүбән!

— Кем син? Җенме, кешеме?

— Кеше мин, кеше. Ә син кем?

— Мин… Сәвия…

— Сәвия!.. Сәүбән андамы?

— Монда, монда… Син чынлап та Сәүбәнме? Бүленеп калдың дип курыккан идек…

— Калган идем, чыктым… Сез ничек анда?

— Икебез дә исән, Сәүбәнне генә бераз баскан… Бөтен җирдән балчык, таш коела. Сәүбән, тизрәк ал безне моннан…

— Хәзер алам. Менә бу бауның очын тотыгыз. Тоттыгызмы?

— Сәүбән, монда ниндидер баскыч та бар…

— Мин тартып алырмын, ә сез шул баскычтан менәргә тырышыгыз. Башта Сәүбәнне бәйләп җибәр…

Сөйләшкәнчә, тар тишеккә кысыла-кысыла, башта Сәүбән менде. Аны танырлык түгел, бөтен җире көлдәй тузанга манчылган, йөзенә, кулларына үзле балчык сыланган… Күзләре тоныкланып калган. Әллә куркудан, әллә арудан, әллә инде балчык басу вакытындагы тетрәнүдән бераз миңгерәүләнгән сыман.

Сәүбән малаен әле тезенә, әле кулбашына бастыра-бастыра, өскә менгереп җибәрде. Арканны кабат мәгарә эченә төшерде. Сәвияне чыгару җиңел булмады. Икесе дә нык арыганнар, куркынганнар, исән калу сөенеченнән, бер-берсе белән очрашу шатлыгыннан нык кына дулкынланалар да…

Сәвияне күтәргәч алар бик озак бер-берсенә сыенышып, кочаклашып тордылар. Танымаслык булып пычранган, кабер балчыгына буялып беткән бу ике тере гәүдә шушы минутта дөньяның иң саф җан ияләре, аның иң изге кешеләре булгандыр, мөгаен.

Сәүбән белән Сәвия кочаклашып басып торган җир кинәт бик нык калтырана башлады. Стенадагы балчык түземсезләнеп, коелырга, ишелергә тотынды… Афәт Сәүбән белән Сәвияне шушы тар чокырда да эзләп тапкан иде.

Иң тәүдә Сәвияне күтәрделәр. Малайлары өстән булышып торды. Сәүбән үзе бик тиз сикереп чыкты. Әле бая гына шушы кое төбендә каңгырап гомер үткәрер кебек иде, хәзер килеп, әнә сикерде дә чыкты. Аның өскә чыгуы булды, кое-чокыр, гөрселдәп, эчке якка ишелеп тә төште… Бу гөрселдәү шулкадәр көчле булды, астагы мәгарә бөтенләй ишелеп төшеп китте, ахры. Аяк астындагы җир дә, аска убыла барып, уйсулык чирәмендә хәл җыеп ятучы өч җан иясен үзенә йотмакчы иде бугай…

Арыган, талчыккан, пычракка батып беткән, тәмам бетәшкән бу өч җан моны сизмәделәр, берберсенә сыенышып, сөйләшмичә-нитмичә, күзләрен дә ачып карарга шикләнеп, исән калуларын, җир афәтеннән котылуларын әлегә тоеп, аңлап та җитмичә, тын гына яттылар да яттылар. Юк-юк, алар җир афәтенең сулышын тоялар инде.Әмма кузгала гына алмыйлар. Ниндидер сихри көч аларны тау өстенә ябыштырып, беркетеп куйган кебек…

Шунда дүртенче зат пәйда була. Аның да исеме Сәүбән. Аңа да ун яшьләр чамасы. Ул да шушы авылдан. Чирәмдә чалкан төшеп ятучы шушы ике Сәүбәнгә бик тә, бик тә охшаган ул. Менә шул сихри зат өлкән Сәүбән янына килә. Чөнки ул аның белән генә аралаша, сөйләшә ала… Чөнки ул — Сәүбәннең бала чагы, балачак рухы.

— Тор, тор! Афәт килә, тау ишелә! Бар, тизрәк төшеп кит моннан! Балаңны, Сәвияңне ал да кит! Тор, тор!..

Сәүбән аны ишетә. Әмма Кала-тау шаукымы, аның белән бергә ниндидер чит-ят язмыш шаукымы көчлерәк, ахры. Аннан котылырга вакыт кирәк. Бәлки, бер мизгел, бер сәгать яисә бер көн, хәтта бер гомер кирәктер? Моны беркем дә белми. Белсә дә Сәүбәннең балачак рухы гына белә.

Шуңа да ул әнә борчылып, өтәләнеп йөри:

— Тор, нишләп ятасың! Харап итәр өчен коткардыңмыни бу газизләреңне? Тор!

Бу юлы Сәүбән сикереп үк тора.

— Ә? Син кем? Без кайда? Болар кемнәр?

Иясенең мондый һушсызлыгын, миңгерәүлеген бала рух шундук кичерә, сабырлык, түземлек белән кабат аңлата башлый:

— Тауга афәт килә. Барыгыз, төшеп китегез. Ашыгыгыз, йөгерегез, очыгыз!..

Сәүбән тирә-ягына күз сала. Тау итәкләрен рәшә пәрдәсе томалап алган… Юк, бу рәшә түгел. Тау үзе шулай дулкынланып тора икән… Ара-тирә бу дулкыннар аска иңеп-убылып китәләр дә тау тәнендә җәрәхәтләр барлыкка китерәләр. Алар инде якында гына, әнә-әнә ике-өч ыргылудан килеп тә җитәчәкләр, Сәүбәннәрне «әһ» тә дими умырып йотачаклар…

Сәүбән аңкы-миңке торган Сәвияне, арудан-талчыгуданмы, басылуданмы — аңсыз-телсез калган малаен ашыктыра башлады, әле берсе янына, әле икенчесе янына килеп, аңнарына китерергә, торгызырга, тормышка кайтарырга, бу хәтәр дөньядан йолып алырга теләде… Сәвиянең битен-йөзен чәбәкләгәндә: «Сулышымның бер өлеше бит син, уйларымның бер өлеше, гомеремнең бер өлеше, мөһим өлеше»,— дип пышылдады. Сәүбән янына килгәндә дә: «Минем үз серемне кайтарасым килә. Син — минем серем. Кайт миңа, серем булып кайт!..» — дип сөйләнде.

Аннары, бу ике Хода бәндәсен җитәкләп, тау читенә, кыя башына таба йөгерде. Аларның өчәүләп йөгергәнен күргән кеше әлеге күренешне тилелеккә, диваналыкка юрар иде, билләһи!..

Бәлки, юрамас та иде. Аларның бүтән чаралары, башка юллары юк лабаса… Атлаган саен тормышлары җимерелә барган кебек… Тик торсаң да убыласың, котылгысыз упкынга очасың... Тик торганчы йөгерү әйбәтрәк, йөгерүгә караганда очу әйбәтрәк... Шуңа күрә дә алар йөгерәләр. Шуңа күрә дә... очалар! Арттан куып килүче тау афәтенең салкын сулышын тоеп йөгерүче Сәүбән үз зиһенендә бик тә сәер һәм кыргый бер уй чагылуын тойды: «Очарга! Очарга!..»

Ник очмаска?! Әнә теге вакытта, сабантуй көнне, әткәсе дә очкан… Оча торган нәсел бит алар! Йолдыз нәселе. Улы Сәүбән дә шул ук нәселдән, Сәвия дә… Очарга! Күккә китәргә! Күккә егылырга! Юк, күккә атылырга!

Кулга кул тотынышып йөгерүче өч җан Кала-тау читенә якынлашып килә иде инде, алар каршында Сәүбәннең бала-чагы кабат пәйда булды. Ул кыяның чит-чатына баскан да ниндидер серле, сихерле тавыш белән үрсәләнеп кычкыра, чакыра:

— Килегез!.. Килегез!.. Очыгыз!.. Очыгыз!..

Сәүбән шунда ук әлеге тавыш сихеренә эләкте һәм юлын кырт кына кыяга таба борды, Сәвия белән малаен да үзеннән калдырмады… Ул бу минутта бик җитди иде. Ләкин бу җитдилек артында ниндидер җиңеллек, яктылык, хәтта бәхет бар кебек. Бәхетнең гомере кыска, әмма аны кеше гомере белән генә үлчәп бетереп булмый, Сәүбәнне, аның Сәвиясен, малаен бәхетле дип буламы? Әгәр бәхетле икән, бу бәхетнең киләчәге нинди?

**20**

Изге кешеләр — табигатьтән, яхшы кешеләр тормыштан туа, диләр.

Очу сәләте кешеләргә бирелмәгән. Кешеләрне очмый, диләр. Әмма мин моңа ышанмыйм. Кеше оча ала, аның да пар канаты бар… Күге бар, кояшы-йолдызы бар… Хыялы, өмете бар… Мин, бу сүзләремне дәлилләп, кырыкка ярылырга уйламыйм, минем белән риза булмаганнар үзләре дәлил эзләсен. Кешеләрнең канатсыз, күксез, йолдызсыз, хыялсыз булуына ышандырсын!

Мин үз геройларымның канатлы булуына ышанам. Мин хәтта бу хакта төгәл беләм! Хәтта күрәм! Әнә ул Кала-тау түбәсендә җилпенеп торучы канат… Әйе-әйе, Сәүбәннең пар канаты — шул балалык рухы — Ак рух була да инде.

Бераздан үзегез дә күрерсез — бу өч җан соңгы мәртәбә талпынып алыр да күккә — болытлар янына очып китәр… Аларны җир өстеннән Сәүбәннең бала чагы үз сихер-ихтыяры белән кубарып алып китәр… Әмма бу хакта алардан башка беркем, беркем белмәячәк… Чөнки кешенең балачак рухы да, аның күңел, җан канатлары да — фани дөнья сере, илаһи дөнья ишарәсе, Тәңре, Күк, йолдызлар бүләге…

— Без кая ашыгабыз, Сәүбән?

— Язмышыбызны эзләргә чыктык, Сәвия…

— Кайда соң ул —безнең язмыш?

— Белмим, Сәвия, язмышыбызның иясез булуын гына беләм…

— Язмышның да иясе буламыни?

— Була, Сәвия… Ул кайдадыр күктә, йолдызда яши…

— Кайсы йолдызда, Сәүбән? Чулпандамы?

— Әйе…

— Нигә бу чаклы йөгерәбез соң без, Сәүбән? Кая йөгерәбез?

— Анда безне канатлы бала чагыбыз көтә…

— Кыядан егылып төшсәк?

— Юк, егылмыйбыз. Безнең бит канатларыбыз бар…

— Нинди канатлар, Сәүбән? Мин берни дә күрмим, тоймыйм…

— Һи, күрергә, тоярга теләмисең генә син… Менә алар — безнең канатлар — синең яндагысы — малаебыз… Минем яктагысы — бала чагым…

— Тагын шул әкиятең икән…

— Әкият түгел ул, Сәвия…

— Арыдым мин, Сәүбән. Сәүбән дә арыды…

— Арымадым мин…

— Әнә бит, арымадым, ди…

— Ә мин арыдым…

— Тагын бераз гына түз инде, Сәвия…

— Аяк буыннарым тотмый, Сәүбән…

— Ә син йөгермә, оч…

— Очам да соң…

— Әнә кыяны күрәсеңме?

— Күрәм… Ниндидер малай да бар анда…

— Син аны да күрәсеңмени?

— Күрәм…

— Ә син күрәсеңме, улым?

— Мин дә күрәм…

— Ул малай — минем бала чагым…

— Ничек инде?..

— Ничек инде?..

— Бала чагымның илаһи рухы ул… Шул безгә канат бирәчәк… Ныклап тотынышыгыз… Менә шулай… Хәзер очабыз…

— Сәүбән, безнең белән нәрсә булыр?

— Берни булмас…

— Без үләрбезме, калырбызмы?

— Һәрнәрсәдә тормыш бар, ә тормышта туу бар, үлем бар, димәк, ул кайчан да булса бер үләчәк…

— Ә без үләрбезме?

— Яшибез әле, Сәвия… Бөтен нәрсә үлеп бетсә дә, галәм белән нәсел калачак…

— Әткәй, әнкәй, килеп җиттек!..

— Сәүбән, калдырма мине...

— Оча-а-абыз…

Кыя читендә пәйда булган өч җанның өчесе дә, бердәй алга омтылып, алларындагы хәтәр бушлыкка ыргылдылар... Ләкин бу өч җан, аска егылып төшәр урынга, ниндидер илаһи, рухи көч ихтыяры белән, күктә очып, хәтта йөзеп йөри башладылар. Алар каршында гаҗәеп матур, серле манзара ачылды: югары оч урамыннан бер төркем кеше йөгереп чыкты да Сабантуй мәйданына таба килә башлады. Өстән бөтенесе дә аермачык күренеп тора: әнә иң алдан Сәүбәннең әнкәсе Рәмзия йөгерә. Ул билендәге онлы алъяпкычын да салып тормаган — ниндидер борчу-гаме аны япан кырга алып чыккан. Аның артыннан ук титаклый-титаклый Май әби килә. Бүген аның бөкресе тураебрак киткән, кулындагы таягы да, таянып йөрү өчен түгел, кырдагы каты камылны аралап бару өчен алынган диярсең... Зәлифә дә шунда гына. Ул, Май әбинең авызына керердәй булып, ләчтит сатып бара, кемнеңдер гайбәтен сөйли... Ярый ла әйбәт гайбәт булса... Әнә Хәләф карт та ияргән... Ул, борчылып, ара-тирә Кала-тауга карап ала, нәрсәгәдер аптырагандай, башын чайкап куя. Тау ягыннан килүче тонык, әмма шомлы гөрелте тынгылык бирми бугай аңа... Рәмзиядән бер адым да артта калмаска тырышып, җил-җил атлап, бер таныш түгел хатын килә. Нишләп таныш булмасын? Сәүбәннең шәһәрдәге хатыны Сәвия бит бу! Янында малае да бар. Ул малай бик кызык икән... Үзе йөгерә, үзе тирә-ягын кызыксынып күзәтә. Аның бит бер тапкыр да авылда булганы юк. Шуңа да һәрнәрсә мавыктыргыч бер могҗиза булып күренә аңа...

Тагын кемнәрдер килә... Араларында бер-ике бала-чага да бар. Ә-ә-әнә тагын бер малай... Анысы читтәрәк — басу капкасы төбендәге эскәмиядә утыра. Берәр якынының кайтуын көтеп утырадыр... Авылына, яшьлегенә рәнҗеп киткән кешеләр күп шул әле...

Их без, җирдә яшәүчеләр, шуны гел онытабыз: Бала чактан соң Ватан башлана. Балачак кичерсә дә, Ватан кичерми...

Кала-тау кыясыннан күтәрелгән өч җан очты да очты... Очсыннар... Аларның бүген оча торган көннәре. Әйе-әйе, кешеләр тормышында шундый көннәр була — оча торган көннәр. Бу көннәрдә аларның язмышлары хәл ителә, тормышлары көтелмәгән урам-тыкрыкларга кереп китә, яшәүләре яңа мәгънә ала... Йөрәкләрендә яшәү дәрте уяна, күңелләренә сафлык, миһербанлык ягыла, күзләренә нур, беләкләренә егәрлек куна...

Тауның тәбәнәге булмый. Тау биек һәм биегрәк кенә була. Бу җан ияләре белән дә шулай.

Ыңгырашып, иңрәп, Кала-тауга таба йөгерүче кешеләр төркеме аларны күрми. Чөнки бу кешеләрнең карашларын, күңелләрен җир гаме, җир кайгысы томалап алган. Ә җир кайгысы кеше өчен күк капусын яба, аның хыялларын сүндерә, канатларын кисә... Кала–тауга таба йөгерүче кешеләрдә «күк тоемы»на, «күк сагышы»на, «күк гаме»нә караганда «җир тоемы», «җир сагышы», «җир гаме» көчлерәк. Шуңа да алар күтәрелеп китә алмыйлар...

Кала-тау кыясыннан сикергән өч җан исә һаман очты да очты... Кулга кул тотынышып, карашларын офык читенә төбәп, хыялларын канат итеп җәеп, күк сулышының салмак дулкынында тирбәлеп очтылар алар. Сез дә, укучыларым, офык читенә күтәрелеп карагыз. Көпә-көндез күк катына балкып килеп чыккан Чулпан йолдызының яшькелт-зәңгәрсу карашын күреп таң калырсыз...

*2001*

Повестьлар, бәяннар

# *ШАРТЛАУ*

*(Повесть)*

**Кайту**

Булатны көзге караңгы төндә кайтарып ташладылар. Ике солдат иярткән яшь кенә лейтенант, хәрби киемдәге врач хатын, военкомат вәкиле, тагын әллә кемнәр арты ябулы хәрби машинадан озын, килбәтсез носилканы сөйрәп чыгардылар да, бәрелә-сугыла, ишегалдына, аннары өйгә юнәлделәр. Өйдәгеләр аңышып өлгергәнче, носилканы түрдәге түшәк янәшәсенә куеп, ана кешегә — солдат капчыгы, ата кешегә күк төргәк тоттырып чыгып та киттеләр. Фәүзия белән Тимерҗан, берберсенә карашып, җансыз, хәрәкәтсез яткан носилка янында аптырап басып калдылар. Шул вакыт эчке бүлмәдән кызлары Гөлназ килеп чыкты.

Күзләрен уа-уа:

— Нәрсә булды, әнкәй? Кем килде? — дип сорады.

Фәүзиягә шушы сорау кирәк булган икән. Ул карашларын, салмак кына, кызыннан идәндә яткан носилкага күчерде һәм, буынсыз булып, шул носилкадагы җансыз улы өстенә сыгылып төште.

— Улы-ы-м!.. Үтерделәрмени?..

Аның артыннан Тимерҗан тезләнде. Иң ахырдан тәмам уянып җиткән Гөлназ Чечняда хәрби хезмәттә булган, ике ай элек хаты килүдән туктап, бөтен өй эчен тынгысыз иткән абыйсына килеп ябырылды...

**Туган нигез**

Булат, өйләренә кайтып кергәнче, ничек каршы алырлар икән дип өзгәләнде. Болай кайтырмын дип ялгыш та уйлаганы булмады шул. Моннан ике ай элек кемдер: «Ярым үлек хәлеңдә кача-поса кайтарып куярлар әле», — дисә, аның бугазына барып ябышыр иде, мөгаен. Кайтаралар икән шул.

Нәкъ ике ай элек Булатның тормышы утлы җәһәннәмгә әверелде. Аның бөтен тәне, буыннары, тәнендәге һәр күзәнәк, сугышка протест белдергән кебек, мәңгелеккә хәрәкәтсез калдылар. Юк, үлмәде алар, бары тик яшәүдән баш тарттылар. Нинди генә хастаханәләрдә ятмады ул, нинди генә врачлар карамады аны, әмма Булат күзләрен шардай итеп ята бирде. «Шардай» дию төгәл булмас. Аның аңы, зиһене эшли, күз алмалары йөгереп тора, карашларында бер генә бөртек, бәлки, соңгы бөртек нур, димәк, өмет тамчысы җемелди.

Менә шундый хәлдә ул әткәсе-әнкәсе каршына килеп басты. Басмады, ятты... Ерак юлдан соң аның хәле хәл иде, әмма ул, капкадан керү белән, сулышы иркенәеп, йөрәгенең ярсыбрак тибә башлавын, тәненең ниндидер бер сихри көчкә, энергиягә тулыша баруын тойды. Булат караңгы чолан аша өйгә үткәндә аеруча нык тойды ул исне. Өйләре исен, туган нигез исен. Бу ис ниндидер әйбер исе генә түгел. Анда чоланга кертеп тутырылган ашлык исе дә, тарттырыр өчен киптерергә җәеп куелган шомырт исе дә, почмак саен кыстырылган бөтнек, мәтрүшкә, әрем исе дә, ярты өйне алып торган мич исе дә, анда пешкән ипи исе дә, ипи алгач тәгәрәтелгән бәрәңге исе дә... Тагын... тагын китап исе! Өйалдындагы шүрлеккә тезелеп, ак пәрдә белән ябылып, тарттырылып куелган алар. Армиядән кайткач, Булат юристлыкка укырга кермәкче иде... Шуны уйлап, бик күп китап җыйды. Хәзер аларның кирәге чыкмас инде. Ә! Тагын юып, кояшта киптереп, төреп куелган сөлге исе дә бар бу туган нигез исендә. Булат һәр елны авыл сабан туенда көрәшә, бүләксез калмый иде. Соңгы өч елда да батыр булды. Узган елда гына бил бирде. Баш батыр булып күршедәге Сикәле авылыннан Дилүс исемле егет калды. Булат дөреслек яулап кына йөрмәде — Дилүс аны хәрәмләшеп, аяк чалып җиңде... Дилүс... Дилүсне ул тагын Чечняда очратты... Военкоматтан ук бергә китәргә тиешләр иде. Булат ничек тә аның белән бер частьта булмаска тырышты, башын исәрлеккә салып, бөтенләй башка командага язылды. Ләкин Ходай Тәгаләне алдап булмый шул. Бәндәне сыныйм дисә, барыбер сыный ул. Ярты ел Самарада әзерлек үтеп, Ханкалага барып төшсә, анда аны, авыз ерып, шул Дилүс каршы алмасынмы!

Бер полкта, хәтта бер ротада хезмәт иттеләр. Еш кына бергә рейдларга, «зачистка»ларга чыгалар иде. Тегесе ничек кенә елышмасын, Булат аны үзенә дә, күңеленә дә якын җибәрмәде. Взвод командиры ярдәмчесе булып хезмәт итүче Булат астыртын, хәйләкәр Дилүскә ай-һай кирәк булгандыр шул. Кайдандыр урланган тушенкалар белән сату итеп тотылгач, йөгереп килеп җиткән. Ул вакытта чынлап та зур бәладән коткарып, яклап калды аны Булат. Якташ дигән булды, ярар бер юлга, диде, бер тотылгач, акылга утырмасмы, диде.

Утырмады... Иман үзгәрә, холык үзгәрми, диләрме әле? Бу шундый очрак иде. Ә бервакытны... Бу юлы инде аларның сукмаклары ныклап кисеште һәм шунда ук мәңгегә аерылышты да...

Тукта! Җиттеме сиңа! Туган йортыңа кайтып керү белән шул имансыз җан иясе хакында уйлап ятмасаң... Нигезеңне рәнҗетеп... Әткәң-әнкәңне рәнҗетеп... Сафтан саф Гөлназны кыерсытып... Әнә алар — өч бөртек җан кисәге — Булат янында тезләнгәннәр дә хәләл яшьләрен түгәләр. Юк ла, әткәсе еламый. Ул ачылмаска төйнәлгән кебек төйнәлгән йодрыкларын тезләре өстенә куйган да тәмам аптырап катып калган. Нәрсә уйлый ул? Уйлыймы соң ул? Әллә каргый гынамы? Сугышны, ул сугышны башлаучы ил башлыкларын, шайтан коткысына бирелгән политикларны, бүре өере кануннары белән яшәүче хәрбиләрне каргыймы? Юк, каргамыйдыр да... Каргый белми Булатның әткәсе. Эшли генә белә. Елның елында, ал дими, ял дими, басудан кайтып керми бит ул. Гомере буе җир сөреп, иген игеп, үз көче белән көн күреп яшәгән кеше каргый белмидер шул. Ә менә әнкәсе... Елый-елый каргыйдыр... Әнә бит ул ничек өзгәләнә...

— Нишләттеләр минем улымны?! Нишләт-те-лә-ә-р?.. Имгәтеп кайтардылар би-и-ит... Харап иттеләр бәгырь кисәгемне-е...— Фәүзия үзе елый, үзе Булатның тәнен капшый, аяксыз балак, кулсыз җиң эзли... Һәм кул-аякларның урынында булуын аңлап, бер мәлгә сискәнеп китә, хәтта, елаудан туктап, малаеның тере, әмма үтә дә сагышлы күзләренә төбәлә.— Балам, синең бар җирең дә исән-сау бит?.. Ник тормыйсың, ник кузгалмыйсың инде? Бик арыдыңмы? Сугышны хәтәр диләр бит, арырсың да шул... Ярар, ярар, ят, ят... Ятып хәл ал... Бөтен җирең дә исән-сау бит, Ходай кушып терелерсең әле... Хәл дә керер, аякка да басарсың... И-и, балакаем, бер дә борчылма, күзләрең күргәч, йөрәгең типкәч, калганын әнкәң үзе карар, яме...

## Чечен Булат

Әнкәсе ничек кенә караса да, тәрбияләсә дә, Булат икенче көнне дә, өченче көнне дә аякка баса алмады. Хәтта теле дә ачылмады аның… Элеккечә хәрәкәтсез булып, авылга кайткач балкыбрак киткән, әмма моңсулыгын югалтмаган күз алмаларын як-якка тәгәрәтеп, әнкәсенең йомшак түшәгенә чумып ята бирде. Гөлназ аның яныннан бер адым да китмәде, хәтта дәресенә дә бармады бугай… Әнкәсе дә эшеннән калды, бөтенләй эштән китү турында сүз кузгаткач, эткәсе шундук җөпләп алды. «Мин эшләгән дә җитәр, карчык, син Булатны аякка бастыр, миннән гозер шул», — диде. Булатның солдат капчыгыннан чыккан хәрби форманы кием элгеченә урнаштырып, түр стенага, андагы шәмаил рамы янәшәсенә элеп куйды. Аннары күк төргәктән чыккан орден белән медальне шул форма түшенә беркетте, соңыннан, турымы, түгелме дигән кебек, читкә китеп карап торды…

Булат боларның барысын да күреп ятты. «Нишлисең син, эткәй! — дип әйтәсе килде аның. — Ник эләсең аларны? Ник Коръән сүрәләре янына эләсең? Сугышып, кеше канын коеп алынган бүләкләр бит алар… Элмә, эткәй!» диясе килде. Тик әйтә алмады. Ул телсез иде, өнсез һәм ымсыз иде. Шуңа күрә каршы стенада эленеп торган хәрби формага һәм аның янәшәсендәге гарәп язуына көннәр буе карап ятарга тиеш булды. Башта ук уйлап куйды: кайчан да булса теле ачылса, Ходай Тәгалә хет бер сүз әйтерлек мөмкинлек бирсә, иң элек бу догалыкка нәрсә язылганын сораячак ул…

Булат кайтканның икенче көнендә үк кеше керә башлады. «Чечен Булат кайткан» дигән хәбәр бөтен авылга таралган булып чыкты. Беренче булып авыл фельдшеры Сәкинә апа килеп керде. Бу мөлаем, җиңел куллы, йомшак телле апага кичә үк язу килгән булган, бу язуда сугыштан яраланып кайткан Булат Гыймазовны дәваларга, аңа күз-колак булып торырга кушылган.

— И-и, Булаткаем, сине карыйсы-нитәсе юк икән. Бөтен җирең дә таза. Тик нишләптер бөтен җирең дә йоклый синең… Монда миннән берни дә тормый, Ходай Тәгалә белән синнән генә тора, Булаткаем, — дип сөйләнде, аннары, кичке якта тагын керергә булып, ашык-пошык җыенды да чыгып китте.

Бераздан Ак әби керде. Кызык әби. Булат аны күпме белә, ул һаман шул килеш. Тамчы да картаймый. Ире сугышта үлеп калгач, бүтән кияүгә чыкмаган. Гомере буе колхоз фермасында бозау караган. Хәзер абыстай булып йөри. Ак әби шау-шусыз, тыныч кына керде дә, Булатның аяк очына утырып, дога кылды, аннары шулай тавыш-тынсыз гына чыгып та китте.

Ак әби чыгып китүгә, классташы Хәлим күренде, ул да, ишек төбендә бераз таптанып торгач, ут капкандай китү ягын карады.

Аннары күршедәге Миңнисәттәй ишектән башын тыкты.

— Мөмкинме, күршеләр?

Мич артында пешеренеп йөрүче Фәүзия алъяпкычына кулларын сөртә-сөртә зал ягына чыкты да, акланган кебек:

— Менә Булатыбыз кайтты бит әле, — дип куйды.

— Ишеттем, ишеттем, йоклый дип тә ишеттем…

— Күзләре ап-ачык килеш йоклый шул, Миңнисәттәй.

— Күзләре тере, алайса… Болай булгач, бер терелә ул, Фәүзия килен, күзләр алар — җан хәбәрчесе.

— Күзләре күрә, тамагыннан үтә, кеше эшләгән бөтен нәрсәне дә эшли, ә менә торып китә алмый. Берәр им-том белән дә кузгатып булмый микән, ә, Миңнисәттәй?

— Авыр авыру бу, кызым. Авыру да түгел ул. Авыруны дәвалап, имләп, өшкереп була. Куркынган аның тәне. Куркынган да үзенең бөтен белгәнен онытткан… Һай, сугыш, сугыш, каһәр генә төшсен шул сугыш чукмарларына!.. Бер төшәр, төшми калмас…

— Аптыраганнан гына әйтүем, ачуланма, Миңнисәттәй. Син бу эш белән бераз шөгыльләнә идең бит. Им-том белән, диюем.

Миңниса әбидән соң да тагын әллә ничә кеше керде. Ләкин Булатның уйлары гел шушы күрше карчык тирәсендә булды. «Авыру түгел, тәне генә куркынган»,— диме? Ә бит ул дөрес әйтә. Булатның тәнендә бер җәрәхәт тә юк. Булганы да күптән төзәлеп бетте.

…Булат беренче медален үк хәләл канын түгеп алды. Чечняга килеп төшүләренә бер атна гына иде әле. Булатны, тагын берничә кешене шәһәр читендәге блокпостка билгеләделәр.

Беренче төндә үк мәхшәр купты. Төрле яктан ата башладылар. Хәтта өстән дә, астан да аталар сыман иде. «Федераллар» да аптырап калмадылар. Биек таш стеналарга уелган тар тишекләрдән җавап уты ачтылар. Әмма дошманны күрү мөмкин түгел иде. Кая туры килә, шунда ата торгач, патроннар бетә башлады. Төнге уникедә миналар яварга тотынды. Булат моннан соң да күпме атыш күрде, үлем белән йөзгә йөз очрашты, әмма бу кадәр мәхшәрне күргәне булмады. Төнге күктән сызгырып килеп төшкән миналар риваятьләрдә генә була торган Иблискә атылган утлы ташлардан бер дә ким түгел иде.

Ханкаладан чакыртылган «вертушка»лар* кайдадыр югалдылар. Бу кадәр караңгы һәм томанлы төндә очып йөрүе аларга да рәхәт түгелдер шул. Якындагы частьтан чыккан группа да засадага эләккән, югалтулар күп, ди.

Мина төшеп, ике солдат үлде. Канлы гәүдәләр күргәч, яшь солдатлар күңеленә курку керде. Блокпосттагыларга башлык итеп куелган өлкән лейтенантның каты яраланганын ишеткәч, бу курку тагын да көчәйде.

Булат, баштарак бик нык каушаса да, тора-бара күнекте. Кеше тәмуг газабына да күнегә, диләр бит. Кычкырып-ыңгырашып кан эчендә ятучы яралыларга да, үлемгә дә күнегә икән бу бәндә дигәнең. Бер сорауга гына җавап таба алмый интекте ул: «Нигә алар монда? Ни калган аларга монда? Бу фаҗигаләрнең берәр мәгънәсе бармы? Кем өчен түгелә бу кан? Кем өчен бу корбаннар? Нәрсә бәрабәренә? Нигә? Нигә? Нигә...»

Төне буе атышып яттылар. Каршы як бераз ял итеп алды да тагын утын көчәйтте. Нык кына якынайдылар, ахры. Таныш түгел телдә сөйләшкәннәре дә ишетелеп кала хәтта. Сүгенүләре генә урысча...

Булат төшенә башлады: хәзер «чехлар»** һөҗүмгә күчәчәкләр. Әнә атышу бераз басылгандай булды. Димәк, һөҗүм алдыннан көчләрен барлыйлар. Бу юлы каршы тора алырлармы, юкмы? Һөҗүм читтән атышып яту гына түгел. Кан күп түгеләчәк, үлемнәр күп булачак... Булат, төнге атыштан томалана башлаган зиһенен бөтен көченә эшләтә башлады. Беренче көнне үк җаны кыелыр микәнни аның? Гарьлек бит бу! Өйдә ни уйларлар? Йөзем ни уйлар? Беренче сугышта ук бирешкән бит, диярләр. Яратасы да калмаган, дияр... Юк, болай булмый. Нидер кылырга кирәк.

Шунда Булатның күзе блокпост уртасындагы чокырга яшерелгән БТРга төште. Мина эләгеп, ул бер якка янтайган, гарипләнеп калган. Шулай да, аңа төялеп, берничә чакрым гына үтәргә буладыр. Иң мөһиме, ничек тә олы юлга чыгарга кирәк, ә аннан инде «вертушка» төяп алып китәчәк...

Булат озак уйлап тормады, тимер машина өстенә барып та менде, механик кабинасына төшеп, кабызырга да кереште.

Тимер өеменә җан керүгә, җир астыннан чыккан кебек, яралы кулын җилкәсенә аскан сержант килеп җитте.

— Нишлисең син, салага! Төш моннан, анаңны шулай итим!

— Яралыларны, үлеләрне эчкә төясеннәр, аяктагылар өскә кунакласын, моннан тизрәк таярга кирәк, юкса...

— Нәрсә, курыктыңмы? Бар, бас стена буена! Марш!!!

— Сержант, акылыңа кил, ярты сәгатьтән берни дә калмаячак монда. Үзем алып чыгам, ей-богу! Яртыбыз кырылды, патроннар аз, бер генә юл кала — чигенергә! Сержант!

— Ярый, ышандырдың, машинаны әзерли тор, мин егетләр белән сөйләшеп киләм.

Атыш тагын көчәйде. Егетләр таш стена артына гранаталар томыра башладылар. Берничә граната бу якка төште. Болай булса, бераздан соңгы сигез кеше дә әҗәл кулына күчәчәк. Авыр яралыларны күптән БТРга төяп куйганнар, исәннәр капка төбенә җыелган. Аның капка дип әйтерлеге дә калмаган — пулялардан, мина кыйпылчыкларыннан теткәләнеп беткән...

Булат та яраланды. Пуля янбашын сыдырып үтте, әмма зыянлы түгел, ахры. Кызулык белән авырту да сизелми. Сугышта авырту, әрнү дигән әйбер юк икән. Анда җиңү белән җиңелү генә бар...

Ниһаять, тәвәккәлләделәр. Сержант кулын изәүгә, исән калган сигез егет дәррәү БТРга менеп кунакладылар. Шуны гына көтеп торган Булат сугыш машинасын үкертә-үкертә хәрәкәткә китерде һәм тышка — караңгы төн эченә алып чыгып китте.

«Чехлар» моны көтмәгәннәр иде. Блокпост эченнән ут чәчеп БТР килеп чыккач, бераз каушап та калдылар, ахры. Алар айнып өлгергәнче БТР шактый ерак киткән иде инде.

Шулай исән калдылар. Булатка — медаль, өлкән лейтенантка — орден, сержантка — отпуск бирделәр. Бу сугыштан соң Булат бер айлап госпитальдә ятты. Пуля эчке әгъзаларын да җәрәхәтләгән булган икән. Ниһаять, берничә операция кичергән Булатка «годен» дигән язу тоттырдылар, яңа хезмәткә билгеләделәр. Бу юлы десантникларны тәэмин итү группасына эләкте. Сугышта булып, яраланып медаль алган Булатны «дух»ларга* башлык итеп куйдылар. Менә шул чакта солдат боткасын туйганчы ашарга туры килде аңа. Тагын гыйбрәт — штабтагы бер офицер: «Мөселманнарны командир итеп куярга ярамый», — дип каршы төшсә дә, комбат үзенекен бирмәгән. «Миңа хет черт булсын, әйбәт кенә сугышсын!» — дигән. Соңыннан беленде: Иванов фамилияле бу командирның әнисе татар булган икән. Әйе, кешенең асыл сыйфатлары иң элек анадан күчәдер шул. Ана каны көчлерәк, ана рухы өстенрәк...

Чечняда Булат әнкәсен еш искә төшерә иде. Юк, бу үлемнән курыкканга түгел. Бу күбрәк җаваплылыктан булгандыр, әнкәсе, әткәсе, сеңлесе Гөлназ өчен, туган нигез өчен җаваплылыктан, аннары нинди генә авыр чакта да күңелен сафлап торган мәхәббәте өчен җаваплылык тоеп үләсе килмәгәндер аның...

Булатның уйлары шунда өзелеп калды, соңгы кунакны озатып кергән Фәүзия, артындагы ишекне шар ачык калдырып, түргә — улы янына ашыкты:

— Балам, Йөзем килгән…

**Йөзем**

«Йөзем» сүзен ишетү белән, Булатның әллә кай җирендә, эчтә, йөрәк янында булса кирәк, бер нәзберек кыл тартылып, чыңлап куйды. Авылга кайтып төшкәннән бирле ул бу кылга кагылмаска тырышкан иде. Ә бит хәтәр шартлаудан соң түшәк иясе булып калгач, иң беренче уе Йөзем хакында иде. Авылда вәгъдә бирешкән кызы ул — Йөзем. Тулы исеме — Гөлйөзем. Ләкин Йөзем исеме Булатка ныграк ошый. Сөешкәндә ул аңа «Йөземем» дими, «Йөзем» генә ди. Син — күңелемнең, бәхетемнең, язмышымның йөзе, димәкче ул. Тормышының чагылышы, ягъни мәсәлән…

Алар бергә үстеләр. Ләкин Булат Йөземне беренче мәртәбә тугызынчы классны тәмамлагач «күрде». Мәмәдәл урта мәктәбендә матур гадәт бар: ямьле май ахырында, дәресләр тәмамлангач, югары класс укучылары Фәрештәләр куагы дигән җиргә күңел ачарга менәләр. Менә шунда унынчыга күчкән Булат белән җиденчене тәмамлаган Йөземне учакка коры-сары җыярга җибәрделәр. Баштарак Йөзем аңа бөтенләй ошамады. Артык оялчан, туры карарга кыймый, тиз кызара; кызарган чагында йөзен каплап алган сипкелләр калкып, беленеп тора башлыйлар, болай да чандыр йөзне ябык һәм шадра итеп күрсәтәләр. Бу тимгел–тимгел сипкелләрнең илаһи нур бөртекләреннән яралганын соңыннан гына аңлады Булат. Аңлады да бүтән үзеннән ерак җибәрмәде Йөземне. Сикәле авылыннан Дилүс кенә аларны аерырга тырышып карады, булдыра алмады. Булат кына түгел, Йөзем дә бөтен барлыгы белән гашыйк булып өлгергән иде инде.

Чечняда чакта да хаттан өзмәде Йөзем. Иң авыр минутларында Булат Йөземнән килгән сагыну хатларын кулына ала, кат-кат укый, күңелен тынычландыра, өметен яңарта, хыялларын барлый…

Ләкин хыяллары тормышка ашарга насыйп булмаган, күрәсең. Шартлау афәтеннән айныгач, Булат Йөземне соңгы мәртәбә исенә төшерде дә шундук мәңгелеккә онытты.

Авылга кайткач та Йөзем тагын бер мәртәбә исенә төшә язып калды. Әтисе кулына эләккән күк төргәктән, орден, медаль документлары, паспорт, хәрби билет белән бергә бик күп хатлар килеп чыкты. Аларның барысы да Йөземнән иде. Ләкин Булат күңел капкачын бик тиз ябып, томалап куярга өлгерде. Йөзем хакындагы уйларны ул моннан соң авыру тәненә һәм әрнүле җанына ялгыш та якын җибәрмәде.

— Балам, Йөзем килгән…

Әнкәсенең тавышы каушап, калтыранып чыкты. Бәндәләрнең вафаты хакында гына шулай хәбәр итәләрдер. Бу очракта Булат үзе тере мәет хәлендә иде. Аның Йөземнең күзенә һич тә күренәсе килмәде. Гарьлек бит! Әзмәвердәй егет башы белән, керфек тә кага алмыйча, бармакка-бармак селкетмичә, үлем көтеп ят инде, ә?!

Булатка бик оят булып китте. Аның җаны өзгәләнде, тәне кызышты. Торып кына китә алмады. Их! Үзенең бичара, мескен хәлен Йөземгә күрсәтмәс өчен, тәрәзәне шар ачып җибәрергә дә… шул тәрәзә аша сикереп төшеп, иркен кырларга чыгып чабарга иде! Булмый шул, булмы-ы -ый!..

Булат җан сулышы белән кычкырып җибәрде. Юк, тавышы чыкмады аның. Ул эчтән генә кычкырды. Соңгы вакытта шулай эчтән сөйләшергә, кычкырырга, хәтта еларга, көләргә өйрәнде ул…

Булат чытырдатып күзләрен йомды. Йөземне күрмәгәч, Йөзем дә аны күрмәс кебек тоелды, ахры…

— Фәүзия апай, Булат кайткан дип ишеттем, дөресме бу?

— Дөрес, балам, дөрес. Кайтты Булатыбыз, кайтты… Үз аягы белән генә кайтып керә алмады балакаем…

Йөземнең калтыраныбрак, куркыбрак чыккан тавышын ишеткәч, Булатның тагын бер мәртәбә йөрәге өзелде. Торасы, торып, сөйгәненең каршысына барасы, аның күзләренә сөеп карыйсы, - шул күзләрдән үбеп аласы килде…

— Әле өйдәме соң?

— И-и, кызым, кая китсен ул… Монда… әнә түшәк иясе булып ята… Тик… йоклый ул хәзер… Йокласын… Төннең төнендә күз йоммыйча чыкты бит җанкисәгем…

— Фәүзия апай, янына барыйм әле, яме?

— Ярый инде алайса, бар. Тик… тавышланма, өнеңне чыгарасы булма.

— Юк… юк, мин үрелеп кенә карыйм…

Үрелеп кенә карый алмады шул Йөзем. Болын кебек түшәк янәшәсенә тезләнеп, башын Булатның күкрәк өстенә куйды. Күзләрен йомды. Ул шулай йөрәгендәге ярсуны басып, күңелен тәртипкә китерде, ахры.

Бераздан пышылдап кына, Булат ишетерлек итеп кенә сүз башлады:

— Мин сине барыбер яратам, Булат… Син барыбер тереләчәксең, менә күрерсең дә торырсың… Үзем терелтәм мин сине… Мәхәббәтем белән терелтәм… Иң мөһиме — син исән… Исән, бәгърем…

Йомык күздән дә яшь чыга икән. Булат күзләрен ачканда, Йөзем елый иде. Озын, зифа керфекләрдән чишмә кебек күз яшьләре тибеп ята.

Шул вакыт әллә каян гына әнисе килеп җитте:

— Ярый, балам, бар, кайт. Хәзер ул беркая да китми инде. Теләгең булса — кереп йөрерсең. Теләмәсәң — кермәссең. Гаепләүче булмас. Һәр кешенең үз юлы, үз язмышы…

— Анысы шулай, Фәүзия апа. Ләкин кешегә бәхет тә бер генә бирелә бит… Минем бәхетемнең исеме — Булат…

— Ай, шулай булса иде, кызым… Менә бит хәлләр ничек… Безнең синең белән мәшәкатьләр күп булачак…

— Булсын, булсын, Фәүзия апа! Кумагыз гына! Мин көн саен кереп йөрермен, яме.

— Ходай кулына тапшырдым инде алайса. Сине дә, Булатымны да… Ә хәзер бар кайт… Булатны ашатасым бар…

— Үзем ашатыйммы, Фәүзия апа?

— Бар дидем мин сиңа! — Фәүзия кычкыра язып калганын сизмәде дә. Шунда ук үзен кулга алып өлгерде: — Сөйләштек бит инде, Йөзем акыллым…

— Бетте, бетте, Фәүзия апа… Китәм. Ләкин мин аны барыбер яратам, яратам, яратам! Ул да мине ярата! Үзе әйтә алмаса да, мин моны аның йөрәк тибешеннән аңладым…

## Гөлназ

Булат өчен иң борчылганы Гөлназ булгандыр. Мәктәптән бушаган вакытларында, тере мәет кебек яткан абыйсы тирәсендә бертуктаусыз өтәләнеп торды ул: «Абыем, тамагың кипмәдеме?», «Абыем, ашыйсың килмиме?», «Абыем, нинди китап укыйм?», «Абыем, бүгенге яңалыкларны сөйлимме?»

Булат берничек тә җавап бирә алмый. Күзләрен генә йомып-йомып ала. Бу аның «әйе» дигән сүзе. Күзләрен йоммыйча, тик карап торса — «юк» диюе. Бер Гөлназ гына белә, ахры, абыйсының ишетеп, аңышып ятканын. Чөнки әнкәсе дә, әткәсе дә Булат янында ул ишетмәгән кебек сөйләшәләр.

— И-и, әткәсе, бер дә терелмәс микәнни Булатыбыз, — ди берсе.

— Белмим, бик каты ята, ди бит врач.

— Кай җирләре генә авыртадыр инде балакаемның? Их, белсәң иде! Ул авыртуның бер өлешен үземә алыр идем, билләһи!

Ә Гөлназ абыйсы белән сөйләшә. Үзе сорый, үзе аның өчен җавап та бирә.

— Абыем, Чечня дигән җирдә кыен булдымы? Җиңел булмагандыр. Әнә бит синең орденнарың да бар, иң авыр сугыштан соң гына бирәләр ди бит ул орденнарны. Шулаймы, абыем?

Бу юлы Булат керфек какмады. Гөлназ аптырады булса кирәк.

— Ник, абыем, алай дисең? Бу орденнарны алу җиңел булдымыни?

Булат тагын дәшмәде. Сырлап, уеп ясалган матча агачына карашын күчереп, авыр сугыш хатирәләренә кереп чумган иде ул.

Орденны Шатой янындагы тауларга оештырылган рейдтан соң бирделәр. Булатның яшь солдатлардан гына торган отделениесен десантниклар группасына беркеттеләр. Шуңа күрә алар «дес»лар кая бара, шунда барырга тиеш булдылар. Корал кирәк-яраклары, азык-төлек, төрле аппаратура, йокы капчыклары, палаткалар күтәргән «дух»лар күбрәк колларны хәтерләтәләр иде. Алар десантниклар артыннан бер тотам да калмый ияреп барырга тиешләр. Ләкин сугышта, бигрәк тә дошман тылындагы рейдлар вакытында, ал-арт дигән нәрсә юк. Шул ук Чечняда, десантникларны үткәреп җибәреп, алар артыннан авыр йөк күтәреп баручы «дух»ларны кулга төшерү очраклары күп булды.

Булатлар төркеменә дә «тау кешеләре»нең һөҗүмен берничә мәртәбә кире кагарга туры килде. Десантниклар аңышып килеп җиткәндә, «дух»лар «тау кешеләре»нең позициясен нык кына таркатып өлгерәләр иде.

Берсендә десантниклар үзләре засадага эләктеләр. Сугыш каты булган, ахры. Булат үз группасы белән мышнап килеп җиткәндә, егерме кешенең өчесе каты яраланган, җиңелчә яралanучылар да бар, ә командир — Коцуба фамилияле өлкән лейтенант — бөтенләй юкка чыккан. Артыннан килеп, башына сукканнар да, исәнгерәйтеп алып киткәннәр, ахры. Таулы, урманлы урыннарда мондый хәлләр еш булып тора.

Бер чакрымнар баргач килеп тапты ул аларны — ике сакалбай белән Коцубаны. Аның командирлыгыннан берни дә калмаган иде — өс-башы теткәләнеп беткән, йөз-битләренә канлы җәрәхәт

укмашкан, башында да бер буй җәрәхәт, куллары артка каерып бәйләнгән. Аяк киемнәре юк, ялан аяклары шулай ук канлы җәрәхәттә. Шулай хәлсез һәм җансыз булып бер читтә ята мескен. Ара-тирә ыңгырашып, ухылдап ала. Ә теге сакалбайлар гамьсез-моңсыз кыяфәттә тамак ялгап утыралар. Үзара сөйләшеп алалар. «Нигә шулкадәр тыныч соң алар?» — дип уйлап алды Булат. Нишләп тыныч булмасыннар, засадага эләккән «федераллар»ның, гадәттә, эзәрлекләргә кыюлыклары җитми бит.

Сакалбайларның берсе, торып, якындагы чишмәгә су алырга китте. Булатка шул гына кирәк иде. Ул мәче кебек хәрәкәтләнеп, җиргә елыша язып үрмәләп барды да, консервасыннан ит чүпләп утырган чеченның башына автоматын орды. Һәм шунда ук су янындагы сакалбайга кычкырды:

— Кузгаласы булма! Югыйсә дөмектерәм! Кулларыңны күтәр! Акрын гына монда кил! Тоткыныңның кулларын чиш!

Теге чечен, тәмам аптырашта калып, үрә катып тора бирде. Шунда гына Булат үзенең татарчага күчүен аңлап алды. Каян белсен бу чечен кешесе аның татарчасын? Мөселман өммәтеннән булу татар булу дигән сүз түгел бит әле! Бер үк дога белү беләнмени?! Бер кавемнән булмагач, бер каннан оешмагач, әллә ни аңлашып та булмый икән шул…

— Ну-ка подойди поближе… Только тихо!.. Развяжи его!

Бу юлы чечен аңлады. Тугандаш урыс теле ярдәмгә килде. Урыс дигән халыкның, урыс теленең барлыгына беренче һәм соңгы мәртәбә сөенүе булгандыр бу чечен кешесенең.

Ике сакалбайны да янәшә бәйләп салды Булат. Юып, чистартып, яраларын бәйләп алгач, командирга кеше төсе керде.

Ходай каргаган бу җирдән тизрәк китәргә кирәк иде. Ләкин нишләргә бу сакалбайлар белән?

Коцуба, шешенеп-күгәреп беткән йөзен җирдә аунап яткан чеченнар ягына ымлап, Булатка кычкырды:

— Убей их!

— Зачем! Они же тебя не убили.

— Убей, говорю!..

— Не буду, сказал…

— Под суд пойдешь, проклятый татарин! Мусульманин, да?

— Да. Но не только поэтому не трону их.

— Ну?!

— Люди же они. Они защищают свой дом. Я их понимаю.

— Ты прав. Но ведь есть долг.

— Да, долг есть. Только вот нечем платить…

— Не то говоришь, сержант.

— На войне нет званий. Есть только люди и нелюди.

— И то правда… Да черт с ними! Пусть живут…

Әмма аларга бу каһәрле җирдән тиз генә котылырга насыйп булмаган икән. Ун-унбиш адым да читкә китә алмадылар, янәшәдәге куаклар артыннан унлап сакалбай йөгерешеп чыкты. Баштанаяк коралланган бу чечен яугирләре, үз телләрендә кычкырына-кычкырына, Булат белән Коцубаны баягы урынга төрткәләп китерделәр. Коцубаның тәненә яңа җәрәхәтләр өстәлде, Булатка да нык кына эләкте: авыз-борыныннан кан китте, сул як янбашы энә белән чәнечкәндәй сызлый башлады.

Бәйләнеп яткан ике чечен картын шундук аякка бастырдылар. Бик олы хөрмәткә ия затлар булып чыктылар тегеләр. Яугирләр алар янында баш иеп кенә сөйләшәләр, йөзләренә, күзләренә күтәрелеп карарга да кыймыйлар хәтта.

Сөйләшкәннәрен аңламаса да, Булат бик тиз чамалап алды: бу минутта аның язмышы хәл ителә иде.

Чеченнар шактый сатулаштылар, каты-каты гына кычкырышып та алдылар. Ләкин теге ике карт чеченның сүзе өскә чыкты, Булатларны җибәрергә булдылар.

— Кыш-ш отсюда! Еще увижу, убью! — дип җикеренде бер чечен егете.

Булатка җан керде.

— Автоматы отдайте. Без них придем — трибунал будет…

— Может, патроны еще отдать?

— Не нужно. Только автоматы.

Булат автоматларын да бирерләр дип уйламаган иде. Бирделәр. Аның күңелен бер сәер тойгы биләп алды: «Сәер кешеләр… Шушы автоматларны тотып тагын киләсебезне белеп торалар бит үзләре… Нинди хәл бу? Җир эше түгелдер, Ходай Тәгалә кулы уйныйдыр монда…»

Кайтканда Коцуба да тәмам ис-акылына килде:

— Скажи, сержант, откуда ты знал, что не убьют?

Булат:

— Обычная психология…— дип кенә котылмакчы булган иде, барып чыкмады, өлкән лейтенант аны солдат тугрылыгы хакындагы әңгәмәгә алып кереп китте. «Долг», имеш, «присяга», имеш. Ә үзе белә, аңлый, шуңа ул рәхмәтле дә — әле яңа гына аны Булат үлемнән коткарып калды бит. Ә командирны үлемнән алып калу элек-электән хәрбиләр арасында батырлык саналган…

Коцуба, рейдтан кайтуга, Булатны орденга тәкъдим итте, ә чеченнар белән «килешүләр» хакында беркемгә бер сүз ычкындырмады.

Шуннан соң ул солдатларга мәрхәмәтлерәк, шәфкатьлерәк була башлады. Юкка-барга һаваланып йөрүен ташлады, үз палаткасында аракы чөмереп тик ятты. Һәм ике сүзнең берендә «обычная психология» дип тәкрарлый торган булды.

…Гөлназга боларның берсен дә сөйли алмады Булат. Сеңлесенең сафлык бөркеп торган күзләренә карап, тере мәет кебек ятуында булды. Кызыйга да абыйсының күзләре бик җиткән. Ул шул күзләр белән сәгатьләр буе сөйләшеп утырырга риза.

— Ә беләсеңме, абыем, Йөзем апа сине шундый нык ярата!..

— Каян беләсең моны, сеңлем? Башың яшь бит әле…— Моны Булатның күзләре әйтте.

— Белдем инде, белдем, бездән чыккач, күтәрмәгә утырып елады… Качып карап тордым…

— Качып карап тору әйбәт түгел бит, — диде Булатның күзләре.

— Карап тору әйбәт түгел дә… Ул бит сизмәде… Мине күргәндә гел елмаеп-көлеп сөйләшкән була, үзе генә калса, елый да елый… Тереләчәгеңне белми, шуңа елый… Ярата ул сине, абыем, бик ярата!..

Икенче бер көнне Гөлназ урамнан яңа хәбәр алып керде:

— Абыем, абыем! Чечняда хезмәт иткән Дилүс абый кайткан, диләр.

— Ә?..

— Дилүс абый кайткан. Сине сорашкан. Кереп чыгам, дигән… Күрәшеп карарбыз, дигән. Көлгән… Тагын бер сүз әйтимме? Юк, әйтмим лә, әйбәт сүз түгел ул… Синең кәефне җибәрә торган сүз ул, абыем…

Булатның күзләре чәчрәп чыгардай булып Гөлназга карап торалар иде.

— Әйт, әйт, ник әйтмисең? Дилүсне белмимме әллә мин. Ул булган җирдә юньле сүз булмас… Әйт! — диләр иде алар.

— Дилүс абый кайткан көнне үк Йөзем апаның кулын сораган. Әтиләре риза булган, Йөзем апа гына каршы, ди…

Булат мондый хәбәрне көтмәгән иде, ахры. Ул бермәл шаккатып Гөлназга карап торды да, эчтән әрнеп-көеп, күзләрен йомды… Салмак кына ябылган күз кабаклары бу минутта салкын кырауга түзә алмыйча йомылган чәчәкне хәтерләтәләр иде…

**Явызлыкның чиге бармы?**

Дилүс аларга көтмәгәндә килеп керде. Көн саен кереп йөри башлаган Йөзем Булатның баш очында утыра иде. Фәүзия аны күпме генә чәй өстәленә чакырып караса да, Йөзем урыныннан кузгалмады, түшәктә яткан хәрәкәтсез гәүдәгә карап утыруында булды. Булатның күзләре йомык. Ул һаман да Йөземгә күзләрен күрсәтми. Күзләрен ачса, күз нурларына ябышып җан-бәгыре суырылып чыгар дип курка, ахры.

Йөзем өчен бу мөһим түгел. Ул бит Булатның аны күргәнен белә. Күңел күзләре белән күрә ул. Чөнки һаман да ярата үзенең Йөземен. Ярата, ярата… Сагына… Юксына…

Йөзем үзе дә бик сагынды Булатны. Менә шушы кап-кара чәчләрен, куе кашларын, үбәсе килеп торган йөз-битләрен, мәхәббәтле иреннәрен, киң кулбашларын, көчле кулларын сагынды…

Дилүс килеп кергәндә, Йөзем Булатның хәлсез, буынсыз кулларын сыйпап утыра иде. Солдат киемендә пәйда булган әзмәвердәй ир-атны кече якта ипи салып йөрүче Фәүзия баштарак танымады.

— Нихәлләр, Фәүзия апа, исән-сау гына торасызмы? — дип, Дилүс иң элек аның белән күреште. — Дилүс бит мин, танымыйсыңмы әллә, Фәүзия апа? Армиягә синең малай белән бергә киткән идем….

— Ә-ә, Дилүсмени-и-и? Исән-сау кайттыңмы, улым? Чын ир булгансың, танырлык та түгел, билләһи. Танымадым шул, озын гомерле булырсың әле. ..

— Яшибез әле, Фәүзия апа. Җимерттереп яшибез. Менә өйләнеп тә җибәрсәм…

Ул инде түр якта, Булат янында утырган кунакны күреп өлгергән иде. Төрттерүле сүзе дә Йөзем ишетсен дип әйтелгән булып чыкты, ахры. Шулай да ул кызны күрмәмешкә салышты.

Түргәрәк үтеп, иң элек Булатка эндәште:

— Привет, служак! — Служагы җавап бирмәгәч, Йөземгә таба борылды: — Син дә мондамыни, бәгырькәем минем? Әле уйламадыңмы? Мин җавап көтәм.

— Озак көтәргә туры килер шул.

— Алай димәле, җанкисәгем. Бу тере мәет сине тиз ялкытачак.

— Булат мәет түгел, түгел!

— Мин андыйларны күп күрдем. Гомер буе имгәк булып яшәячәк ул. Менә миңа кара — бер царапина да юк… Ә бу үләксәнең көннәре күп калмаган.

— Дилүс…

— Әү, бәгърем.

— Сине ничек җир күтәрә икән?

— Җирме? Җир үзе минем кулда, белдеңме? Менә шушы граната кебек… Теләсәм, чәлпәрәмә китерәм мин аны. — Дилүс кесәсеннән кул гранатасы тартып чыгарды. — Ә-ә, сиңа да кызыкмы?

Ул күзләрен шар ачып карап яткан Булатны күреп алды. Бу күзләрдәге нәфрәт, ниндидер сихри көч булып тышка бәреп чыкса, иң хәтәр гранаталардан да хәтәррәк шартлар иде, мөгаен… Әллә шул шартлаудан курыкты, әллә Йөземнең сораулары уңайсыз хәлгә куйды, Дилүс гранатасын кабат кесәсенә тыкты да саубуллашып та тормыйча тышка чыгып китте. Ул басып торган урында шомлы тынлык белән сасы аракы исе генә торып калды.

Бу аракы исеннән Булат та котылып кала алмады. Әлеге ис иң элек аның зәгыйфь күңелен кузгатып җибәрде, аннары тоныклана башлаган хәтер көзгесендә җанны өшетерлек күренешләр чагылып китте.

Ул көнне аларның батальонын район үзәгеннән ерак түгел бер авылга — «зачистка»га билгеләделәр. БТРларга төялеп барып кергәндә, авылда бала-чага, хатын-кыз, карт-корыдан башка кеше калмаган иде инде. Кемдер хәбәр иткән. Чечняда бөтен җирдә колак бар, күз бар. Чеченнар «федераллар»ның бөтен ниятләрен белеп торалар. Моны алар яшермиләр дә. Алдан әйтеп куелмаса да, авыл аксакаллары Булатларны авылга алып керә торган олы юл буенда икмәк-тоз белән каршы алдылар. Аларны күрү белән, командирлардан кемдер сүгенеп куйды. Күрше БТРда баручы Дилүс картлар янына буш аракы шешәсе томырды.

Авыл башында тукталып тормыйча, үзәк мәйданга үттеләр, җиргә коелдылар. Авылда бер боевик та калмаганын белсәләр дә, һәр йортны, һәр базны, подвалны, сарайны карап, тикшереп чыгаргa тиешләр иде алар. Тәртип шундый. Приказ шундый. Ике төркемгә бүленеп авылның ике башыннан кереп киттеләр. Өч сәгать дигәндә авылны урталай бүлеп торган киң урамда очраштылар. Булат үз егетләре белән урамның аргы очында «зачистка» үткәрергә тиеш иде. Бернинди шикле әйбер күренми, кайсыдыр чоланда атмый торган ау мылтыгы табып алдылар, кайсыдыр йорттан бер уч гильзалар килеп чыккан. Бөтен «табыш» шул.

Булатлар эшләрен төгәлләргә торганда, каршы як йорттан бер хатын-кызның өзгәләнеп, үрсәләнеп кычкыруы ишетелде. Бераздан бу тавыш басылды. Ничек кенә тынычланырга тырышса да, әлеге газаплы кычкыру Булатның колагыннан китмәде, бераздан ул аның җан түренә үк кереп ятты. Хатын-кызны рәнҗеткән кешене өнәми Булат. Шулай тәрбияләнгән инде, нишлисең? Кешене дә, бигрәк тә дусларын, хатын-кызга мөнәсәбәтләре буенча бәяли ул. Әнә бит ничек өзгәләнеп ялварды бу хатын. Нәрсә булган аңа? Ире суямы әллә? Булат түзмәде, үзенекеләргә эшне дәвам итәргә кушып, каршы як йортка юнәлде. Ишегалдында да, өйдә дә беркем юк. Ишекләр шар ачык. Келәт ишеге дә ачык, яртылаш баз сыман каралтының да ишекләре каерылган. Тавыш шуннан килә, ахры. Әнә ниндидер хәрәкәт сизелә.

Булат, төлке адымнары белән, стеналарга сыланырдай булып, шул җир алачык ишегенә якынлашты. Аннары, кискен генә этенеп, тар аралыкка барып та керде.

Автоматын алга төбәп, кычкырып җибәрде:

— Кем бар монда?

Тынлык аңа ыңгырашу белән җавап бирде: «Ыһ!..»

Булат һаман аңыша алмый иде әле. Эчкәрәк узып, ишек катыннан читкәрәк тайпылды. Ишектән ургылып килеп кергән көн яктылыгы подвал эчен күрерлек, ни дә булса шәйләрлек хәлгә китерде.

Ә андагы хәлләр җанны өшетерлек иде. Түрдәге сәке кебек җирдә чалкан төшеп ниндидер үсмер кыз ята. Аның карарлык җире калмаган: күлмәкләре ертылып, аерылып төшкән, түшләре, ботлары ачык, йөзе күгәреп, канга буялып беткән, бот тирәләрендә дә кан…

«Көчләгәннәр»… Булатның томаланыбрак киткән аңында интегеп, ыңгырашып шушы уй туды. «Көчләгәннәр… Кайсы хәшәрәтенең эше бу? Әллә безнекеләрме? Чеченнарда хатын-кызга ябышу гадәте юк. Димәк, безнекеләр…»

Булат шунда гына подвал почмагында посып торган шәүләне шәйләп алды. Ул да Булатны таныды, каптырылмаган каешын автоматына шык-шык бәрә-бәрә, ишеккә таба килә башлады.

Барысын да аңлап алган Булат, үзен-үзе белештермичә, әле генә чечен кызын көчләгән «федерал»га барып ябышты:

— Что ты делаешь, сволочь?!

Тегесе каршы әйтеп тә, каршы торып та булашмады, Булатның эткәләвенә, төрткәләвенә риза булып, тышка атылып чыкты. Шунда Булат тагын бер мәртәбә ах итте: аның каршында чалбар-ыштаннарын рәтли-рәтли күрше авыл малае Дилүс басып тора иде!

— Син нәрсә? Син... Син...Син бит үзеңне генә түгел, бөтен армияне, бөтен... бөтен татарны мыскыл итәсең...Моның өчен беләсеңме нәрсә булачак? Моның өчен сине дөмектерергә кирәк!..

— Нәрсә кызасың? Дошман кызы бит ул, боевик кызы, бандит кызы!..

— Нинди дошман? Ни сөйлисең син, адәм актыгы! Кайда күрдең син дошманны? Күрдеңме? Ә? Йә, әйт, күрдеңме? Ник дәшмисең?

— Монда бөтенесе дә дошман. Минем өчен шулай гына. Башкача уйлыйсым да килми. Ә син бар кер, сиңа да бирә әле ул...

— Ах син, мөртәт!.. Иманыңа кайтарырмын мин сине!

Дилүс үзенә уктала башлаган Булатка автоматын төбәде:

— Стоп! Не имеешь пр-р-рава! По-пр-р-ро-буй!..

— Җәзасыннан барыбер котыла алмассың, гад! Моның өчен трибунал тиеш сиңа!

— Трибунал? Мә, тот, тота алсаң. Никаких трибуналов!

Шул минутта ул биленә беркетелгән бер гранатаны шудырып чыгарды да, Булат аңына килеп өлгергәнче, бөҗрасын тартып алып, подвал ишегеннән эчкә — әле генә көчләнеп ташланган гәүдә яткан почмакка ыргытты.

Явызлыкның чиге юк, диләр. Бар икән. Аның чиге Дилүс дигән татар малаеның кара йөрәге аша үтә икән. Подвалдагы шартлауны ул командирларына: «Миңа ыргытам дигәндә, ялгыш үзе шартлап үлде», — дип аңлатты.

Булат, хаклык таләп итеп нидер сөйли башлаган иде, Чечняны аркылыга-буйга иңләгән карт капитан:

— Уже не докажешь... — дип кырт кисте.

Бу хәлдән соң Булат чечен атлы бу милләт кешеләренең күзләренә туры карый алмый башлады, бигрәк тә хатын-кызлары, аналары белән күзгә-күз очрашмаска тырышты, очраша калса, әйтеп-аңлатып бетергесез авыр халәт кичерә торган булды.

Чеченнар бер генә үлемне дә җавапсыз калдырмыйлар. Үч — аларның җан газабы гына түгел, яшәү рәвеше дә. Подвалда шартлап үлгән кыз өчен дә «чех»лар бик тиз үч алдылар. Шул авылда булып кайткан ике солдатны икенче көнне үк суеп китерделәр. Частьны уратып алган таш койма буенда калдырылган кул арбасында яткан җансыз гәүдәләргә баштарак якын барырга кушмадылар. Саперлар килгәнче ярты көн вакыт узды. Мина-мазар табылмагач, гәүдәләрне берәм-берәм эчкә керттеләр. Үлем-китем сугышта гадәти хәл. Әмма бу мәрхүмнәрнең кичергән газаплары иң таш бәгырьне дә тетрәндерерлек иде: аларның ирлек әгъзалары төбе-тамыры белән өзеп алынган һәм бугазларына дыңгычлап тутырылган булып чыкты...

Бу хәлләрдән соң Дилүскә көн бетте. Аны типкелектә йөртә башладылар, «күтен эшергәннәр» дигән хәбәр дә таралды. Бераздан аны, кызганып булса кирәк, башка частька күчерделәр, Булат та яраланып госпитальгә эләкте...

**Уяну**

Бүген Йөзем соңрак керде. Иртән-иртүк яисә төшке аш вакытында — Фәүзия өйдә чактарак керә иде ул. Бу юлы кичке якта, кояш, күк катындагы күчәреннән ычкынып, офыкка юл алгач керде. Бүген ул бөтенләй башка төрле. Кигән киемнәре дә матуррак, үзе дә сылурак, чибәррәк. Юк, Йөзем болай да бик чибәр зат. Әмма ул бүген тагын да чибәррәк.

Иң мөһиме, авырып кайтканнан соң, Булат сөйгәненең йөзендә беренче мәртәбә якты нур, хәтта серле балкыш күрде. Бу балкышның сере Йөземнең ымсындыргыч елмаюында иде! Үбешергә генә яратылган иреннәрендә, үзенә суырып йотып алырга торган мәхәббәт чокырларында, аннары маңгаена төшкән бөдрә чәчләрендә, дөньяга киң итеп ачылган, үлем түшәгендә яткан кешене дә кабат яшәүгә дәртләндерә ала торган кыйгач кашларында, озын керфекләрендә иде...

Үзе еш-еш сулыш ала. Каушый, кыенсына, ахры. Сулыш алган саен, алсу күлмәген төртеп торган күкрәк алмалары, бер күтәрелеп, бер төшеп, җиңел дулкынланалар...

Күбәләк кебек җилкенеп кенә килеп кергән Йөзем, өй эчендә бераз басынкыланып калгандай булды, аяк очларында килеп, Булатка иелебрәк:

— Исәнме, Булат... — дип пышылдады.

Булатның: «Исән шул әле, исән, җан гына чыгып җитмәгән»,— дип әйтәсе килде. Әйтмәде. Әйтә дә алмый иде. Әмма күзләрен дә йоммады. Йөземнең матурлыгына тәмам әсир булган чагы иде - шул.

— Булат, минем синең белән сөйләшәсем килә. Икәүдән-икәү генә... Булат... Әйт әле, син мине яратасыңмы? Әле дә яратасыңмы? Яратасың, яратасың... Беләм мин моны...— Йөзем үзе сөйләнә,

үзе Булатның чәчләрен сыйпый, нәфис бармакларын аның яңакларыннан йөгертеп төшерә, аннары ап-ак җәймәгә кагылыр-кагылмас кына, бөтен гәүдәсе буйлатып, аяк очларына кадәр төшә. — Хәтерлисеңме, куш нарат буасы янында беренче мәртәбә үбешкән идек?.. Аннары су коенган идек... Син иң элек минем күлмәгемне салдырдың, ә күлмәктән башка минем бер әйберем дә юк иде... Хәтерлисеңме? Менә шушы кулларың белән туйганчы иркәләдең мине... Туйганчы үптең... Үптердең...

Йөзем, Булатның кулларын алып, ачык изүе арасыннан йоп-йомшак, балкып килеп чыккан күкрәкләре өстенә куйды.

Булат аларны шундук сизде, тойды. Таныды! Бу мәхәббәт алмаларына кулын гына түгел, башын, яңакларын куясы, аларны оятсыз рәвештә суырып үбәсе килде.

Булатның бармаклары, учлары белән сөйгәненең күкрәкләрен сыйпыйсы, иркәлисе килде... Ул, бөтен булган һәм булачак көчен җыеп, бармакларын хәрәкәткә китерергә, һич югы, кузгатырга тырышып карады. Әллә кыймылдата да алдымы? Юктыр... Күңеленнән генә кузгаткандыр...

Булатның чигәләренә, күз төпләренә, ирен читләренә салкын тир бәреп чыкты. Бөтен җаны-тәне белән терелергә, уянырга тырышкан гәүдә соң чиккә җитеп тулышты, бүртенде, әмма үзенең бер генә бөртек күзәнәген дә кузгата алмады...

— Булат, менә кара миңа. Теге вакыттагы кебек кара... Ныклап кара. Күлмәгемне салам, кара. Кара да ярат. Ир-егет булып, каныңны кызыштырып, күзеңне камаштырып ярат. Бөтен җирең уянсын, җаның куансын, гомерең юансын...

Йөзем, Булат каршында чүгәләгән җиреннән торып басты да, салмак кына хәрәкәтләр белән, кулбашлары күбәләк канатлы алсу күлмәген салып бетерде. Бая ук үзенә ымсындырып, күңелендә әллә нинди сихри хатирәләр уяткан йомры күкрәкләр өстендә шундый ук ал төсле күкрәк япмасы гына торып калды. Булатның, үрелеп, әнә шул соңгы чүпрәк кисәген алып атасы килде. Ул инде күңеле белән үрелде дә... Әмма бармакларын, кулларын кузгата алмады. Шулай да уң кул бармакларына энә кадалган кебек булды, шулай гомерлек йокыга талган нерв җепселләре уяна башлады, ахры... Бармакларындагы авырту белән үк аның тагын бер җире дертләп уянды, шаулап тормышка кайтты, һәм, шыбырдап, көчле кан белән тула башлады...

Йөземнең зифа, сылу тәне күкрәк япмасыннан да мәхрүм калгач, Булат шашар дәрәҗәгә җитте. Чыннан да, бу минутта аның киереп ачылган күз кабаклары, бер соклангыч, бер куркыныч булгандыр. Шул күзләрдән бер минутка да карашын алмыйча каршында басып торган сылу тән Булатны тәмам сихерләп куйды. Аның зәгыйфь тәне башта калтыранып, бәргәләнеп ятты, аннары канга тулышып кызарды, бүртенде, бераздан тынычланып калды, аннары, манма тиргә батып, йоклап китте...Бары тик бармаклары очындагы дуамал нерв тамырлары гына һаман биешәләр, яңадан туууларына сөенешеп, уйныйлар, шаяралар иде.

Фәүзия шаулап эштән кайтып кергәндә, Йөзем, рәхәтләнеп йоклап яткан Булат түшәге читендә исәнгерәп утыра иде. Аның күлмәк изүләре ачык, шул ачыклыктан, бая гына хөрлек рәхәтен тоеп калган күкрәк алмалары кабат тышка чыгарга атлыгып торалар...

Фәүзия, нидер сизенеп, сак кына килде дә, һаман әле күзләрен Булаттан ала алмый утырган Йөземнең кулбашына кагылды.

— Ни булды монда, кызым? Өстең-башың таралган дип әйтимме?

— Ә? Кайттыңмы, Фәүзия апа? Булат терелде бит, беләсеңме шуны? Әнә-әнә карале, бармакларын уйнатып ята...

Чыннан да, Булатның уң кул бармаклары минут саен калтыранып алалар, хәтта, бергә җыйналырга теләгәндәй, учка кысылып куялар. Әмма йодрыкка укмашып бетә алмыйлар, тагын таралып, хәрәкәтсез-җансыз булып калалар...

— Нишләттең син аны, кызым? Чыннан да терелә башлаган бит безнең Булатыбыз...

— Берни дә эшләтмәдем, Фәүзия апа, бары тик чишендем генә...

— Чишендең? Булат каршындамы? Шаяртасыңмы, кызым, әллә... Әллә чынмы?

— Шаяртудан узган инде мин, Фәүзия апа. Солтания җиңгәчәй әйтеп киткән иде, «син аның ирлеген уят башта, аннары үзеннән-үзе тереләчәк ул» дигән иде. Мин нәкъ ул әйткәнчә эшләдем: тәнем белән ымсындырып, ирлеген кузгатырга, кешелеген уятырга тырыштым...

— Җендер син йә берәр фәрештәдер, кызым. Меӊ-мең рәхмәтләр сиңа. Үзең дә бәхетле була күр берүк. Миннән теләк шул.

— Менә ул минем бәхетем, Фәүзия апа. Миңа бүтән төрле бәхет кирәк түгел...

— Беләм, акыллым, беләм...

Боларның берсен дә Булат ишетмәде. Ул тау-таш актарып хәлдән тайган әкият батыры кебек, бөтен җаны-тәне белән изрәп, йокыга киткән иде.

### Яшәү чигендә

Бүген Булат янына Ак бабай кереп утырды. Аңа инде шатлыклы хәбәрне Гөлназ күптән кереп әйткән, Йөзем белән булган хәлләрне дә, белер-белмәс көе, үзенчә сөйләп биргән.

Шуңа күрә сүзне уратып башлап тормады, турыдан ярып салды:

— Фәүзия кызым, Булат акыллым, шуны онытмагыз: мәхәббәт дигән хикмәти сер кешене тормышка кайтара кайтаруын... Әмма тормышта нәфрәт тә бар бит әле, әнә шул нәфрәттә чыныгып кына, шул нәфрәт, әрнеш аша килгән сабырлыкта сыналып кына кеше аягына баса ала, сынын, җанын турайта... Беренчесен җиңел үттегез, икенчесе авыррак булыр. Анысын үтәргә дә Ходай ярдәм бирсен...

Булат баштарак аңламыйча ятты. Нинди нәфрәт, нинди әрнеш? Ләкин күңеленең кайсыдыр җире белән ул тойды: әле болар сынауларның башы гына, җиңеле генә. Иң авыры алда булачак...

«Булачак, булачак! Күңелеңне киң тот!» — дип, үзен-үзе камчылап та алды Булат.

Ак бабайның тагын бер сүзе аның зиһененә уелып калды.

— Кеше хәтәр авырудан терелергә теләсә, шул авыруга юлыккан чагына кайтырга, шул мизгелдән яңадан яшәп китәргә тиеш. Кайчандыр җан хәрәкәте тән хәрәкәтенә өлгерми калган булса, бу юлы инде ул аңа бик тиз ияреп китәргә тиеш...

«Кызык карт бу. Мулла гына түгел. Дөнья карты. Ак бабай. Аның теле белән дөнья үзе сөйләшкән кебек. Дөнья акыллары бар бу затта, билләһи!»

Ә бит ул хак дөресен әйтә. Кайчакта кешенең җаны яшәү белән үлем арасында калучан була, аның җисми яшәешенә өлгерә алмый. Чынлап та, кеше, терелү өчен, иң элек әнә шул мизгеленә, җан белән тән аймылышкан чагына кире кайтырга тиештер, бәлки?

Булат та хәтерли ул хәтәр мизгелне. Аның да үлем белән яшәү чигенә басып торган чагы бар иде...

Әлеге дә баягы «зачистка» вакытында булды бу хәлләр. Кайсыдыр бистәне аркылыга-буйга иңләп, тикшереп чыкканнан соң, часть урнашкан базага кайтырга гына торганда: «Бер чечен кызы минага баскан», — дигән хәбәр китерделәр. «Минага эләгү» түгел бу. Монысы — хәтәррәк.

Булатлар группасын шунда җибәрделәр. Аларга ике сапер егетне дә беркеттеләр.

Хәлләр бик мөшкел иде. «Зачистка» ясап йөрүче «федераллар» эләгеп шартласын өчен, «чех»лар ташландык йортның җир идәненә мина куйганнар. Язмыш шаяртуыдыр инде — әнә шул минага чечен кызы китереп баскан, имеш. Басуын баскан, әмма аягын тартып ала алмаган, сугыш дөньясында үскән кыз бит, аягын алса — шартлап күккә очачагын бик яхшы белгән ул.

Булатлар белән килгән сапер егет бары бер генә сүз әйтте:

— «Лягуха», блин!..

Булат белә, «лягуха» — иң хәтәр миналарның берсе. Аннан якындагы тәрәзә аралыгына сикереп кенә котылып булмаячак. Ул өстенә басып торган кешене генә түгел, шартлый калса, бөтен йортны күккә очырачак. Шулай да күңелне төшерергә ярамый, берәр чара күрергә кирәк. Әнә бит кызый үзе дә чак-чак аягында басып тора. Болай булса, ул үзе үк шартлаячак, аны коткарырга килгән егетләрне дә харап итәчәк.

— Исемең ничек! — дип сорады Булат кыздан.

— Зөләйха.

— Арыдыңмы?

— Арыдым.

— Без сине коткарырбыз, тик син кыймылдама, яме.

— Ярар...

— Бик әйбәт. Хәзер иплап кенә мин сине алыштырам. Башта мин басам, аннары гына аягыңны аласың да менә шушы эзләр буенча чыгып китәсең.

— Мин курка-а-ам...

— Мин дә куркам, нишлисең бит, безнең язмышлар бәйләнгән хәзер... Зөләйха — матур исем. Үзең дә матур. Сиңа әле яшәргә дә яшәргә... Бәхетле булырга...

— Мин инде бәхетсез... Егетемне «федераллар» үтерде. Үземне көчләделәр. Ә көчләнгән кызны беркем дә алмый бездә...

— Ләкин барыбер яшәргә кирәк. Бер җае чыгар әле. Сугыш та бетәр...

— Бу сугыш бервакытта да бетмәячәк. Сез белмисез моны. Ә мин беләм... Без беләбез...

— Ярый, ярый, синеңчә булсын. Тик син, зинһар, сак кылан, яме. Минем дә яшисем килә. Авылда мине сөйгән кызым көтә. Аның да исеме бик матур — Йөзем... Гөлйөзем.

Булатны баштанаяк бронежилетларга киендереп чыктылар, хәтта ботларын, аяк балтырларын да тимер кием белән төрделәр. Башына каска кидерделәр, кулларын да, күзләрен генә ачык калдырып, йөзен дә ниндидер тимер тасмалар белән бәйләделәр. Биленә дә нык аркан бәйләнде, аның бер очы, тәрәзә аша үткәрелеп, урам ягында торган БТРга беркетелде.

Барысы да әзер булгач, Булат мина өстендә басып торган кыз янына килде. Бәхеткә, аның аягы мина уртасында калкыбрак торган запалның бер өлешен генә эләктергән булып чыкты. Булат шуның ачык калган җиренә басарга тиеш иде. Басканда черт иткән тавыш чыкса — эш харап…

Өй эчендә беркем дә калмады. Дөресрәге, чечен кызы белән Булат икесе генә калдылар. Юк икән әле, өченче берәү дә бар — Әҗәл. Ул бер почмакка поскан да, кыенсыныбрак, күренергә куркыбрак тора. Алдан ук куркытмыйм бу Хода бәндәләрен, ди бугай…

Ничек кенә куркыныч тоелса да, Булат белән кыз урыннарын бик тиз алмаштылар. Теге каһәрле тавыш та чыкмады. Булатның тимер киемгә төренгән авыр гәүдәсе минага тын алырга да ирек бирмәде.

Хәзер БТРга тагылган бауга тотынып, тәрәзә аша тышка очып чыгасы гына калды. Әйе шул, тотынып чыгарга кирәк. Билгә бәйләнгән бау аны тәрәзәдән чыкканда ук аркылыга өзәчәк…

Бауны шытырдатып кулына бәйләп куйгач, Булат тәмам тынычланды. Егетләргә баш кагып әмер бирде. Тышкы якта үкереп утырган БТР тагын да үрсәләнергә тотынды. Менә ул урыныннан кузгалып китте, озын бауны өстерәп ялан буйлап чаба башлады. Булат бауның тураеп тартылганын көтте. Менә ул мизгел… Менә ул — Яшәү белән Үлем чиге… Кулындагы бау буенча килеп җиткән хәтәр көчне тою белән, Булат, баскан җиреннән этенеп, ачык тәрәзәгә томырылды… Әллә БТРга тагылып, әллә көчле шартлау дулкынына ияреп, ул күпмедер вакыт очып барды, җиргә капланып төшкәч тә, шактый сөйрәлеп барды. Егетләр ах-ух килеп ябырылганда, Булат чалкан ята иде. Бөтен җире тырналып, сыдырылып беткән, мина кыйпылчыклары тигән урыннарда бронежилетның тимерләре бүлтәеп килеп чыккан…

Беренче йөгереп килеп җиткән солдат гөрелдәп Булат өстенә капланды. Йөрәген тыңлый башлады.

Бераздан ул, тезләрендә торган килеш, кулларын күккә чөеп кычкырып җибәрде:

— Исән! Исән шайтан малае, исән!

Аның сүзен тизрәк җәпләргә теләгәндәй, бу чүпрәк һәм тимер өеменең бердәнбер ачык җире — җанның дөньялыкка чыгып йөри торган иң серле урыны — күзләр — кинәт гөлт итеп ачылып киттеләр һәм бала-чагалар кебек сикерешеп, биешеп йөргән кораллы сабыйларга гаҗәпләнеп, шаккатып карап тора башладылар.

— Әнә, әнә, ачты, күзләрен ачты!

— Күзләрен ачты!

— Димәк, исән!

Сөенечләрен кая куярга белмичә, шау-гөр килеп йөрүче әзмәвердәй егетләр бу күзләрнең Булат тәнендәге бердәнбер исән-сау урын булуын белмиләр иде шул әле…

Булат күзләрен ачканда күк йөзе шундый аяз иде. Әнә бер читтәрәк, каурый болытлар йөзеп йөри. Әнкәсе сөт аерткында чиләктә күпереп утырган күбек кебек… Их, тотып карыйсы килә үзләрен. Менә хәзер кулны сузасы да үрелеп аласы иде. Тик… нигәдер кузгатып булмый бу кулларны, үрелеп алып булмый шул ак болытларны…

Нәрсә булган аңа? Яраланганмы? Юк, бер җире дә авыртмый. Ник бер сызлау, әрнү булсын?! Башы гына чыңлый да, йөрәге генә тибә…

Менә хәзерге кебек… Ак бабай сөйләнеп утыра, ә аның башында һаман әле теге вакыттагы шартлау яңгырап тора, йөрәге ярсып тибә… Ул гына түгел икән, аның инде уң кул бармаклары, бергә җыелып, йодрыкка төйнәлгәннәр. Өйдәгеләрнең күзләре шул йодрыкта. Бигрәк тә Фәүзия сөенеченнән нишләргә белми.

Йөзләрен, күзләрен алъяпкыч итәге белән сөрткәләп ала, бертуктаусыз:

— Ай Ходаем, мең рәхмәтләр сиңа, Ак бабай… Үзеңнең сүзең белән Булатыбызга шифа бирәсең, көч иңдерәсең…

Ак бабайның үз сүзе сүз:

— Фәүзия балам, шуны анык бел: Булатың көчне миннән алмый, ул аны үз эченнән, үз йөрәгеннән таба. Көчле, акыллы бала үстергәнсез сез. Моның өчен сезнең үзегезгә Ходайның рәхмәте төшсен.

— Терелер бит ул, ә, Ак бабай?

— Йодрыгын төйни алган кеше аягына баса да баса инде. Көтәргә кирәк. Көч җитәрлек аңарда. Әмма ул көчне кузгатырлык әйбер дә кирәк. Нәрсә ул? Мин белмим. Булат үзе дә белми әле аны. Бәлки, мәхәббәттер?

Булатка Ак бабайның бу фәлсәфәсен тыңлап яту кызык та, кызганыч та иде. Гүя аның өчен бөтен нәрсәне хәл итеп бетергәннәр инде. Хәзер өметләнәсе генә кала…

Шулчак Гөлназ абыйсына дәшеп куйды:

— Абыем, син ишетәсеңме безне?

Булат керфекләрен какты.

— Ишетә, ишетә, әнкәем, ул безне ишетә! Әйттем бит мин сиңа, ул минем белән сөйләшә, дидем…

Фәүзиянең дә улы белән сөйләшәсе килде, ахры.

Ул Булатның йөзенә үк иелеп:

— Балам, берәр җирең авыртамы? — дип сорады.

Булатның күзләре хәрәкәтсез калдылар.

Фәүзия Гөлназга таба борылды.

— Кара, балам, мине ишетмиме әллә ул?

— Ишетә, әнкәй, сине дә ишетә. «Юк, авыртмый» дигән сүзе ул аның. Күзләрен йомса — «әйе» була, йоммаса — «юк» дигән сүз…

— Ай Аллам!.. Менә бит Ходайның хикмәтләре!.. Сөйләшә ләса үзе, аңлый да, аңлата да… Терелсен генә инде, балакаем, тизрәк терелсен генә…

Гөлназ түзмәде, Булат өстендә яшь түгәргә җыенган әнкәсен тынычландыра башлады.

Моңа кадәр сүзгә кысылмыйчарак торган әткәсе дә йомшак кына әйтеп куйды:

— Еларга түгел, шатланырга кирәк, Фәүзия, улыбыз терелә башлады бит…

— Шатлык яше генә бит, атасы, күз яше аша көләм мин шулай, сөенечтән елап көләм…

— Барыбер елама… Кайгы күз яшен аермый, чакыралар дип хәзер йөгереп килеп җитәр…

Ата кешенең шулай дип әйтүе булды, артларында ишек шыгырдап ачылды. Барысы берьюлы, сүз куешкандай, дәррәү артларына борылып карадылар. Ишекне аркылыга-буйга тутырып, күрше авыл малае Дилүс басып тора иде…

— Гыймазовларга сәлам! Булатны терелә башлаган дигәннәр иде, шуңа керүем. Берүк ачуланмагыз.

— Әйдә, Дилүскәем, кер, син дә минем улым белән бергә хезмәт иткәнсең бит, ачысын да, төчесен дә бергә кичерешкәнсең, соңгы сыныгыңны бүлешкәнсең… Бу өйдә синең урының түрдән, улым… Әйдә, үт, утыр.

Шул вакыт Гөлназ әнисенең колагына үрелеп пышылдады:

— Әнкәй, абыем бу Дилүсне күрергә теләми, әнә күзләрен йомды. Күрәсем килми, дигән сүзе ул аның.

— Исәнлек сорап кергән кешене кире чыгарып җибәреп булмый бит инде, кызым. Кергән икән, бераз торыр да чыгып китәр. Тавышланма, яме.

Дилүс түргә узды.

Түшәктәге Булатка күрсәтеп:

— Йоклыймы? — диде.

— Йоклый шул, әле генә йоклап китте.

Гөлназ үзенең кечкенә гомерендә беренче мәртәбә әнкәсенә каршы чыкты:

— Йокламый ул, йокламый! Аның Дилүс абыйны күрәсе килми. Шуңа да күзләрен йомды. Яратмый ул аны, яратмый…

— Тукта әле, кызым, нишләп алай дисең, алар бит бергә хезмәт иткәннәр…

— Барыбер яратмый абыем аны. Ниндидер начарлык эшләгән ул аңа. Хәзер дә эшләргә тели. Миңа моны абыем үзе әйтте, күзләре белән әйтте…

Еларга җиткән Гөлназ кече якка чыгып киткәч, бермәл тын калып тордылар.

Тынлыкны Дилүс бозды:

— Эшләр болайга киткән икән, ярар, Тимерҗан абый, Фәүзия апа, мин чыгармын инде. Служактан моны көтмәгән идем. Мин бит аны үлем авызына кереп алып чыктым, ә сезне кайгыдан араладым. Изгелек нәрсә булып кайта диләр әле? Нәкъ шулай икән. Сау булыгыз…

Дилүс артыннан ишек ябылуга, бу хәлләрдән бераз югалыбрак калган Ак бабай да исенә килеп өлгерде, торып саубуллаша башлады, артына борылып:

— Ә бит ул алдый, үлем авызына кереп чыккан кеше болай сөйләшми, — диде дә җәһәт кенә чыгып китте.

### Сагыну

Сагынуның нәрсә икәнен белә Булат. Шуңа күрә сагынырга өйрәнәсе юк аңа. Теге хикмәтле хәлдән соң Йөземнең юкка чыгуы аны тагын сагыш кочагына ташлады. «Ник керми ул? Синнән рәт чыкмый, син хәзерназлый да, иркәли дә, сөя дә, сөешә дә белмисең, диме? Син — гарип–гораба, син… син… син — тере мәет, диме? Әгәр шулай уйлаган булса, Булат моны тояр иде, тояр иде дә Йөземгә күңеле суыныр иде, аны шундук онытыр иде… Оныта алмаса да, онытырга тырышыр иде… Димәк, ул алай уйламый, уйламый!..»

Булатның мондый халәтне кичергәне бар иде инде. Чечняда булды бу хәл. Әлеге хәтәр җиргә барып эләккәч, шул көнне үк Йөземгә хат язып салды. Гадәти сөю хаты. Кайда икәннәрен әйтмәде, бары тик хәрби частеның номерын гына күрсәтте.

Йөземнең җавап хатын төгәл бер ай көтте ул. Бу бер ай эчендә Булат үз күңелен бер генә мәртәбә әйләндереп какмагандыр… Андагы һәр бөртек хисне берәмтекләп карап-тикшереп, хәтта сынап чыкты. Йөземнең элегрәк язган хатларын кат-кат укыды. Һәм ныклы бер фикергә килде: ярата аны Йөзем, бик ярата. Ярата һәм көтә. Сагынып көтә. Шуңа күрә Булат аңа үпкәләми дә. Ниндидер гаеп өчен генә үпкәләргә мөмкин бит. Ә Йөзем — бер гөнаһсыз авыл кызы, сөяргә-сөелергә, бәхетле булырга һәм кемнедер бәхетле итәргә яратылган җир фәрештәсе… Сагынды аны Булат, бик сагынды. Аның җылы хисләргә, матур хыялларга төреп җибәргән мәхәббәт сүзләрен сагынды…

Бер айдан соң Йөземнән хат килеп төште. *«Ник язмыйсың, Булат? Нәрсә булды? Әллә яратмый башладыңмы? Әллә берәр чечен кызына гашыйк булдыңмы? Ике хат яздым бит инде, нәрсә булса да яз, мин барысын да күтәрәм… Сагынып, яратып, синең Йөземең»* дигән.

Булатның йөрәге шартлар хәлгә җитеп типте. Ул берни аңламый иде. Нәрсә бу? Язмыш шаяруымы? Әллә берәр юньсез бәндәнең эшеме? Эшеме, үчеме? Булат шундук җыенып РМОга (рота материального обеспечения) китте. Хатлар шунда җыелып бара иде. Анда аның Вася исемле танышы бар. Алар икесе дә бер призывтан, сержантлар әзерли торган бер курстан. Хатларны аңа шул Вася җибәреп тора иде.

— Нихәл, братан? Ник күренмисең бу арада? Исәнме, түгелме дип кайгыра башлаган идем инде.

— Исән, нәрсә булсын миңа. Вася, әйт әле, бу айда миңа хатлар килдеме?

— Килде, обязательно килде. Мин аларны аккурат җибәреп тордым. Синең якташың бар бит әле, күрше взводта? Менә шул сорап алды. «Үзем тапшырам», — диде. Нәрсә, тапшырмадымы әллә? Ну, сволочь, күренсен генә әле!..

Булат бүтән сүз озайтып тормады, авылга җибәрәсе хатларны калдырып, ротасына кайтып китте. Дилүскә каныгып вакланмады. РМОга баргач, аны шәп кенә тәпәләп кайтарганнарын ишетте дә шуның белән тынычланды.

Хат алышу китте! Алар гүя чынбарлык тормышта түгел, хатларда яши башладылар. Йөзем, кызларга хас булганча, бик ачылып китмәде, үзенең күңелен тыйнак кына, сабыр гына чиште, Булат исә бөтенләй туарылды: мәхәббәт сүзләрен сипте генә! Ул хатлардагы сүзләрне хәзер дә кабатлый ала Булат, чөнки мәхәббәт хисләренә юмарт булса да, аларның барысы да чын, ихлас иде. Моны Йөзем дә белә, шуңа күрә Булатның тәмле теленә, күп сүзенә ачуланмый, сөенә генә!..

*«Сөеклем минем,*— дип язган иде Булат бер хатында,— *бу мәхшәр дөньясында син минем бердәнбер күңел яктылыгым, өметем һәм ышанычым. Мин, сугышырга теләмәсәм дә, ил кушканга корал алдым, әткәм-әнкәм ышанычына тап төшермәс өчен хезмәт итәм, әмма яшәвем бары тик синең өчен генә…»*

Икенче бер хатында бөтенләй тәртипсез, оятсыз кыланган ласа… Нишләп алай булсын, чын мәхәббәттә оят була димени?!

*«Сөеклем минем! Мин бүген төне буе синең белән хыялланып чыктым. Күзләремне йомам да, сине күз алдыма китерәм. Син ниндидер су буенда. Җил чәчләреңне йолкый, күлмәгеңнең итәген күтәреп җәфалый. Син аны кулларың белән төшереп торасың, ә ул тагын күтәрә, бөтен дөньяга синең матур аякларыңны ачып күрсәтмәкче була… Бөтен дөнья дигәнем мин инде ул. Минем дәртем кузгала, мин синең яныңа киләм, алдыңа тезләнеп, тезләреңне җил ачып алган арада, зифа, тыгыз ботларыңны үбәм… Шушы мәлне төшемә алып китәргә телим. Төш тормышка охшашрак була бит. Чынрак. Дөресрәк. Күз алдына китергәндә, бөтен нәрсәне дә ачык күреп бетереп булмый. Бигрәк тә күзләреңне күрмим, карашыңны онытам… Ә төштә… төштә яшәп була, тагын да ныграк яратып, сөю ләззәтен ныграк татып була. Тик нигәдер төштә күрмим мин сине…»*

Сугыш хакында, хәрби рейдлар, «зачистка»лар турында язасы килми Булатның. Әмма бу хәтәр мәхшәрдән күңеле җилкенгән вакытларда, әрнүле, газаплы юллар сөю хатларына да кереп киткәли иде…

*«Сөеклем минем! Бүген мине бер карт солдатның яшь солдатка киңәш итеп әйткән сүзләре сискәндерде. «Сугышта уйларга кирәк түгел. Сугышка кадәр уйларга кирәк. Сугыштан соң уйларга була. Шуны бел: сугышта ничек тә исән калырга тырышырга кирәк, шул гына…» — диде ул. «Федераллар»да корбаннарның күп булуы шушы фәлсәфәдән килә. Бу психология белән җиңеп булмый. Беләсеңме, бөтен кызыгы да шунда: карт солдат хаклы…»*

*«Беләсеңме, чеченнар авырту яисә югалту аша гына тоялар. Гаиләләрендә берәрсе үлсә яисә югалса, алар башларын эшләтә башлыйлар. Үчле чечен — иң хәтәре, шул ук вакытта иң акыллысы һәм иң талантлысы…»*

*«Беркөнне яшь контрактник белән карт срочник сөйләшеп торалар. Беренче атыштан соң ук шыр җибәргән контрактник (ялланып, акча өчен килгән солдат) әйтә: «Мин сугыша белмим»,— ди.*

*Срочник (призыв буенча алынган солдат) аның авызын бик тиз томалады: «Мин дә белми идем... Мине көчләп өйрәттеләр... Ә син үзең теләп килгәнсең», — диде».*

*«Блокпост янындагы юл чатында басып торган солдатларны күзәтәм. Юлдан үткән һәр чечен кешесен җентекләп тикшерәләр — кораллары юкмы, мылтыгы, гранатасы, бомбасы... Хәтта балачагаларны да, үлем каршына басарга вакыт җиткән карт-карчыкларны да тентеп үткәрәләр... Шунысы кызганыч: шлагбаумга кадәр тыныч күңел белән, хәтта «федераллар»га теләктәш булып килгән кешеләр бу тентү, түбәнсетүләрдән соң дошманга әверелеп китәләр. Кулларында берни юк, аның каравы аларның йодрыклары — бомбага, йөрәкләре гранатага әверелер дә, шартлап, дөньяның астын өскә китерер кебек...»*

*«...Бүген көне буе засадада яттык. Бер басу юлыннан чеченнарның полевой командиры үтәргә тиеш иде. Сарык көтүе куып баручы тешсез, ябык, җаны менә–менә чыгам дип торган чечен картыннан башка кеше үтмәде. Базага кайткач, командирлар тотып ашый яздылар. Шул өтәләнеп беткән көтүче атаклы полевой командир булган икән».*

*«Сөеклем минем! Әгәр синең хатларың булмаса, мин күптән инде бер диванага әверелер идем. Күңелеңне ныграк аңлаган саен, сиңа булган мәхәббәтем дә көчәя, сине сагынуым да арта... Сагышның да, сагынуның да матуры, бәхетлесе була икән! Әйе, мин бик-бик бәхетле! Минем син бар! Бәхет ул һәрвакыт киләчәк белән бәйләнгән була. Син — минем киләчәгем. Ишетәсеңме, ки-лә-чә-гем!..»*

Хәтәр шартлауга кадәр язып җибәргән хатын да хәтерли Булат. *«Миңа бер-бер хәл була калса, бәхиллегемне, ризалыгымны бирәм. Тик ул кеше миннән ким булырга тиеш түгел»,* — дип язган иде ул, алдагы фаҗигасен сизгән кебек. Йөземнең хаты госпитальгә килде. Күрше караватта ятучы «Тарзан» (чын исемен Ходай үзе генә беләдер), зәңгәр буй сызыклы конвертны ачып, аның һәр битен Булат каршында тотып торды.

*«Син миңа таза, сау-сәламәт килеш кирәк, Булат. Ышанам, синең белән берни дә булмаячак. Сакла үзеңне, яме, минем өчен сакла...»* — дигән юлларны укыгач, Булат тәмам күңелен төшергән иде. Менә кайтып Йөземне күргәч, бигрәк тә теге серле, сихерле очрашудан соң күңеле кабат күтәрелгән иде, Йөзем керми башлагач, тагын сагыш дәрьясына чумды. Әйе, сагышның бәхетлесе дә була. Әмма Булатның бу сагышы — кара сагыш иде...

## Иртәнге шартлау

— Абыем! Абыем! Йөзем апа килә, безгә килә!

Йокымсырап яткан Булат дертләп уянып китте. Бүген төне буе йоклый алмады ул. Тәне сызлап чыкты. Соңгы көннәрдә кул-аякларына җан кертү өчен бик нык тартышты шул. Ә кабат уянып яши башлаган һәр күзәнәк үзәкләргә үтеп сызлый...

Күзләрен йомган килеш кенә иң элек әткәсен, аннары әнкәсен эшкә озатты. Гөлназ да мәктәпкә барырга җыенып йөри. Идәнгә нык басмаска тырыша. Абыйсы янына килеп, өстен япты, озак кына карап торды. Аннары авыр сулап куйды да тәрәзә янына китте. Мәктәпкә бергә барыр өчен, күрше кызларын шулай көтә ул...

— Абыем! Йөзем апа килә!

Булат, үзен-үзе белештермичә, күзләрен ачып җибәрде. Сикереп торып тәрәзәгә карыйсы, капкадан кереп килүче Йөземне күреп каласы килде аның. Тора да, күрә дә алмады. Гөлназ тәрәзә яныннан китәргә дә өлгермәде, нindидер бер рух яисә фәрештә кебек, тавышланмый-нитми генә, ишектән Йөзем килеп керде.

— Мөмкиндер бит? Исән-сау гына торасызмы, Гөлназ акыллым?

— Ярый әле, Йөзем апа...

— Исәнме, Булат...

— Исән генә түгел, терелергә тырыша минем абыем. Әйеме, абыем?

Гөлназ абыйсының җавап бирүен көтеп тормады, китәргә кузгалды.

— Ярар, Йөзем апа, мин киттем, әйбәт кенә сөйләшегез. Абыемны рәнҗетмә берүк, ишетсен колагың... — Аннары, аяк очларына басып, Йөземнең колагына үрелде: — Ул сине бер атна көтә инде...

— Гөлназ акыллым, чак кына торып тор әле. Абыеңнан сорыйсы сүзләрем бар. Сине бит аның күзләрен укый ала, диләр. Дөресме бу?

— Юк, мин аның күзләрен укый алмыйм. Аңлыйм гына.

— Абыеңнан бер әйбер сорасам, аның җавабын миңа әйтә алырсыңмы?

— Сора, Йөзем апа, сора.

Йөзем кыюсыз адымнар белән Булат яткан түшәк янына килде.

Идәнгә тезләнде. Булатның кулларыннан тотты. Ап-ачык күзләренә карады.

— Булат, син һаман мине яратасыңмы?

Янәшәдә басып торган Гөлназ абыйсының күзләренә карап та тормады.

— Һи, мин моны аның күзләренә карамыйча да әйтә алам. Ярата ул сине, бик ярата…

— Туктале, Гөлназ акыллым. Кара син аның күзләренә. Укы. Нәрсә ди?

Гөлназ кинәт җитдиләнде. Якынрак килеп, абыйсының мөлдерәмә тулы торган күзләренә карады.

Бераздан шул күзләрдән аерыла алмыйча гына:

— Ул, ник килмичә йөрдең дип сорый, Йөзем апа, — диде.

— Ник килмәдемме?.. Теге көннән соң нык оялдым мин, кыенсындым, Булат. Әллә ничекләр уйлап бетергәнсеңдер дип курыктым. Аннары… аннары күңелемне, уйларымны, хисләремне тәртипкә китерәсе бар иде…

— Хәзер тәртиптәме инде күңелең? — Булат өчен Гөлназ сөйләшә башлаган иде.

— Хәзер тәртиптә, Булат. Хәзер рухым ныгыды, күңелем урынына утырды. Мин синең белән булачакмын. Мин сине ташламаячакмын…

— Син мине кызганасың гына, Йөзем…

— Мин сине яратам, Булат! Нигә һаман шуны аңламыйсың?..

— Аңлыйм. Беләм. Яратасың. Мин дә яратам. Тик нишлибез соң?

— Мин сиңа кияүгә чыгарга булдым, Булат.

Булат күзләрен йомды. Шулай бераз торганнан соң кабат ачты.

— Бу мөмкинмени, Йөзем?

— Мөмкин, мөмкин, Булат. Мин сиңа кияүгә чыгам. Үзем тәрбиялим, терелтәм, аякка бастырам. Без матур яшәрбез. Безнең балаларыбыз булыр… Күп балаларыбыз булыр…

Йөзем яшькә чыланган йөзен Булатның җансыз кулбашына куйды.

Сулкылдап елый башлады. Шулай озак тордылар алар, Гөлназның чыгып киткәнен дә, аның сызып та бетмәгән эзләре буйлап Дилүснең килеп кергәнен дә сизмәделәр…

Җырлый-җырлый килеп керде Дилүс:

— Сез һаман бергә икән… Сез һаман бергә икән…

— Ни кирәк сиңа, Дилүс? Ачы таң белән кеше куркытып йөрисең?

— Минме кеше куркытам? Минме карачкы? Әнә ул — карачкы! Әнә ул — әтрәк-әләм!.. — Бераз һаваланып алгач, бер читтә торган урындыкны җилтерәтеп кенә әләктереп алды да Булат белән Йөзем янына китереп куйды.

— Ярый, сөйләшәбез алайса…

Борынына килеп бәрелгән аракы исеннән Йөзем читкә борылды…

— Нәрсә, чирканасыңмы миннән? Йөз чөерәсеңме?

— Юк, юк, Дилүс, болай гына…

— Болай гына булмый ул. Син миңа, бәгырь кисәгем, кистереп әйтергә тиеш — минеке буласыңмы?

— Ничек инде «минеке», Дилүс? Мин берни дә аңламыйм.

— Ну… Миңа чыгасыңмы?

— Юк, Дилүс, башта ук әйтеп куям. Мин сиңа чыга алмыйм. Минем Булатым бар. Мин аны яратам, аңа гына кияүгә чыгачакмын.

— Шушы үләксәгәме? Аның бит… Аның бит… Бернәрсәсе дә эшләми!

— Ямьсез сөйләшмә минем белән, Дилүс. Булат хакында да ямьсез сөйләмә. Мин инде барысын да хәл иттем…

— Хәл иттем, хәл иттем, имеш… Хәл иттең пычагым… Ә миңа нишләргә, нишләргә?..

Дилүс, учлары белән маңгаен тотып, үзалдына сөйләнә башлады. Йөзем Булатка күтәрелеп карады. «Мин берни дә аңламыйм»,— дигән кебек карады. Булат үзе дә берни эшли алмый иде шул. Бары тик хәрәкәтләнә башлаган бармаклары белән сөйгәненең кулын эзләп тапты, аннары аның бармакларына юлыкты, нәрсә булса да без бергә дигән кебек, шул бармакларны дымлы учына кысты.

Моны Дилүс тә күреп калган икән.

Ул сикереп үк торды:

— Әһә! Син әле яшәргә тырышасыңмы, гад? Үләсең килмиме? Давай, давай… Моның өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Булмаса, табабыз аны…

Дилүс бу юлы да кесәсеннән граната сөйрәп чыгарды. Бер кулы белән янтимерен кысып, икенче кулы белән аның боҗрасын тартып алды. Бераз уйланып торганнан соң кулындагы үлем йомгагын Булатның ачык учына китереп куйды. Аннары боҗраны бер читкә атып бәреп, бушаган кулы белән, Булатның әле буын ныгытып та өлгермәгән бармакларын, граната өстенә яткырып, йодрыкка кысты…

Булат Дилүстән бу кадәресен көтмәгән иде. Эш шаярудан узган булып чыкты. «Ф–1» гранатасының ни икәнен белә ул. Берничә секундтан соң бөтен өй эчендә мәхшәр кубачак…

Булат, барлык көчен бер урынга җыеп, гранатаны учына кысты. Ул арада Дилүс тәмәке кабызды.

— Хәзер, сержант, Йөземнең гомере синең кулда. Беләм, син үлемнән курыкмыйсың, ә менә Йөземнең гомере өчен тырышачаксың… Хәзер аны ничек яратканыңны карап карыйбыз…

Шул вакыт Йөзем телгә килде.

Ул куркуын, каушавын чак-чак басып, Дилүскә үрсәләнеп ялвара башлады:

— Дилүс, зинһарлар дип сорыйм, акылыңа кил, исәрләнмә!.. Тимә безгә, бәла чакырып йөрмә… Бар, кайт, Дилүс…

Дилүс аның саен үҗәтләнде генә.

— Ә син беләсеңме, бәгырькәем, чекасы алынган граната шартларга тиеш. Артка юл юк. Алда ниләр буласын Ходай гына белә. Аннары… менә Булат белә… Ул күпме түзә ала, шулкадәр яшәячәкбез. Ачуланма, яме, шулай килеп чыкты инде…

— Дилүс, нәрсә кирәк соң сиңа? Мин кирәкме? Менә ул мин… Мин сиңа чыгарга риза, тик Булатка гына кагылма…— Йөзем Дилүснең алдына барып тезләнде.— Менә тезләнепләр сорыйм, калдыр безне. Бомбаңны да кире ал. Бәласеннән башаяк… Син тыңласын өчен тагын ниләр әйтим, ниләр эшлим соң, Дилүс, әйт, нишлим?

Дилүс чынлап та шаярудан узган иде.

Ул, тәмәкесен идәнгә ташлап, аны авыр солдат ботинкалары белән таптады да:

— Менә шунда минем хатыным бул. Буласыңмы? — диде.

— Ничек инде — шушында?..

— Хәзер үк чишен, ят!

Йөзем, тезләнеп торган җиреннән, кискен генә торып басты.

— Юк, монысын эшләмим. Бомбаңа шартлап үлсәм үләм, шакшы тәнеңә түшәк булып ятмыйм. Бөтен нәрсә кешечә булырга тиеш.

— Кешечәме? Мине бер отделение солдат тотып «өшкергәндә» бер дә кешечә дип тормадылар. Шушы имгәгең аркасында кешелектән «төшерделәр» мине… У-у, гад! Хәзер мин шакшымы? Ул әйбәтме? Булмасын әле… Хәзер сине үзе алдында тотып көчлим. Бу тагын да хәтәррәк. Юк, юк, син, бәгырькәем, тиз генә бирешмә, каршы торган бул, тарткалаш… Мин бөтен рәхәтен татырлык булсын…

Дилүс, кулларын алга сузып, Йөземгә таба килә башлады. Йөзем артка — урам як стенага чигенде. Ләкин стенадан ары китә алмады. Әзмәвердәй гәүдә аны тәрәзә арасына китереп терәде…

Булатның хәле шәптән түгел иде. Чарасызлыктан өзгәләнгән йөрәге, шартлар дәрәҗәгә җитеп, ачуга, нәфрәткә һәм әрнешкә тулышкан иде бу минутта. Өй эчендәге хәлләрдән аның йөрәге, күңеле генә өзгәләнеп калмады, бөтен тәне тартышты, каны кызды. Граната тоткан кулында егәрлек бетеп барганын тойса да, ул, әллә каян гына табып, тәненә, аяк-кулларына көч иңдерде, кузгалырга, торырга омтылып карады. Булат белә: табигатьнең үз кануннары. Әмма кеше дигәнең табигатьтән өстен ләса. Аның бит әле табигать биргән көченнән кала, рух көче, уй көче, акыл көче дә бар. Ә сөю көчен, нәфрәт көчен кая куясың?!

Булат торып баса алмады. Әмма аяк-кулларының хәрәкәтләнә башлавын ачык тойды. Ул: «Тагын аз гына тырыш инде, йә, тырыш инде, йөрәккәем минем, каным минем…» — дип, үзен-үзе дәртләндерергә кереште.

Ул арада Йөзем Дилүс кулыннан ычкынып китте, ишеккә таба омтылды. Ләкин Дилүс аңа караганда җитезрәк булып чыкты, мәче кебек бер-ике сикерүдә корбанын барып та тотты. Җен көченә алга ыргылган кызның күлмәге арткы яктан умырылып төште. Шәрә тән күргән Дилүс тәмам кызды, ул инде Йөземне кочакларга, үбәргә омтыла башлады. Берни дә барып чыкмагач, киерелеп сугып җибәрде. Йөзем, сөртенеп китеп, башы белән тәрәзә тупсасына барып бәрелде, аһ итеп, идәнгә сыгылып төште…

— Әле син шулаймы? Тешләшәсеңме? Хәзер мин сине кызык итәм…

Дилүс, күз ачып йомганчы, Булат түшәге янында пәйда булды, калтыранган куллары белән, аның дымлы учларыннан гранатасын алды, аннары түрдә башын тотып, бөрешеп утырган Йөзем янына килеп чүгәләде.

— Бәгырькәем, менә моны күрәсеңме? Менә шушы бармакларымны бушатсам, дүрт секундта монда берни дә, беркем дә калмаячак. Яшисең киләме? Киләме? Килә, килә… Менә шул: яшисең килсә, мин әйткәнне эшлә, яме. Ну?!

Йөзем чак-чак кына сөйләшерлек хәлдә иде:

— Дилүс, синме соң бу? Нишләтеп кайтардылар сине? Ни булды сиңа, Дилүс…

— Телеңә салынма, мин шаяртмыйм, кызый. Соңгы мәртәбә сорыйм: минеке буласыңмы?

— Дилүс... Аны болай хәл итмиләр... Сөйләшербез, аңлашырбыз. Тик акылыңа гына кил. Мин бу җәберләреңне кичерергә риза, тик калдыр гына безне...

Йөзем, стенага таянып, көч-хәл белән аягына торып басты, ертык күлмәгеннән күренеп торган шәрә тәнен яшерергә теләп, изүләрен, итәкләрен тарткалады.

— Юк, беркая да китмим мин! Син хәзер үк минеке булачаксың! Булат моны күрергә тиеш! Юкса...

Булат манма тиргә батты, кызарынды-бүртенде, көчәнеп, шартлар хәлгә җитте. Гранатадан котылгач, хәле бераз җиңеләйгән кебек булды, зиһене чистарды. Ул инде башын бора ала, Дилүс белән Йөзем ягына үрелеп карый ала... Тәнен, гәүдәсен кыймылдата ала! Бигрәк тә аякларын түшәк читенә шудырып китергәч, тормышның чабуына тагын да дәртләнебрәк, тагын да үҗәтләнебрәк ябышты ул...

Булат аягын салындырып торып утырганда, Дилүс Йөземне тәмам җәфалап, интектереп бетергән иде. Кыз да үз язмышы белән килешкән, ахры. Ул инде шәрә тәнен дә яшерми, ялвармый да. Бары тик шыңшып елый-елый, тын гына үз намусы, тәне һәм җаны өчен көрәшә — куллары белән йолкына, аяклары белән тибенә, тезләре белән этенә, ничек булдыра ала, шулай каршы тора. Ул хәтта кычкырмый да, кычкырырга хәле дә юк, бары тик ыңгыраша, бөтен йөрәге белән рәнҗи, юк, рәнҗеми, кара каргыш белән каргый...

Булат боларның барысын да күреп, ишетеп тора, әмма берни дә эшли алмый. Нишләп эшләмәсен, эшли. Ул инде торып утырган, аякларына басарга гына курка. Басса, чәчрәп барып төшәр дә, бөтен тырышканнары юкка чыгар кебек. Ә торырга кирәк, ничек тә аякка басарга, Йөземне бу хәшәрәт кулыннан йолып алырга кирәк!

Тәне, мең урында мең энә кадалып торган кебек сызласа да, Булат хәллерәк уң кулы белән этенеп, торып басты. Карават шыгырдавын Дилүс тә ишетте, кырт борылып, кан сауган күзләре белән Булатка төбәлде. Ышанмады. Күзләрен йомып, башын як-якка чайкап алды. Бу юлы ышанды. Әле генә күзләрен мелт-мелт итеп түшәмгә карап яткан Булат, аякларын аерып куеп, кулларын канат кебек як-якка җибәреп, кешедән бигрәк өрәккә охшаган бер сәер кыяфәттә, нәфрәт тулы карашы белән Дилүсне ашардай булып, аның каршында басып тора иде.

Дилүс, үзен-үзе белештермичә, ялт кына торып басты, ләкин зиһенен дә, көчен дә җыя алмый калды... Каршында басып торган «өрәк» алга сөртенеп китте дә, бөтен көче-куәте белән аны ачык тәрәзәгә таба этеп җибәрде, үзе шундук идәнгә — теткәләнеп беткән күлмәген җан җирендә йомарлап, тын гына сулкылдап ятучы Йөзем янәшәсенә ауды. Тәрәзә яңакларына бәрелә-сугыла тышка очып чыккан Дилүснең якты дөньяда берничә мизгел гомер яшисе калган иде...

### Соңгы сүз

Көчле шартлау бөтен авылны, юк, юк, бөтен тирә-якны, бөтен Рәсәйне, хәтта бөтен дөньяны дер селкетте. Аның шомлы яңгырашы агачлардагы кошларны гына түгел, гөнаһлы дөнья ияләре булган кешеләрне дә, хаклык, сафлык сагында торучы изге рухларны да өркетте. Бу шартлау, Чечняда барган хәтәр сугыш кайтавазы булып, кулына корал тотып яуга керергә әзерләнгән һәр солдатның колагына барып иреште. Бу шартлау сугыш гаме белән йөрүче һәр кешенең күңелен сискәндерде, сискәндереп кенә калмады, аларны киләчәк, хаклык, иман һәм яшәү бәхете хакында уйларга мәҗбүр итте...

Укучым! Менә ерак татар авылында булган «кечкенә Чечня» драмасы үзенең ахырына якынлашты. Бу фаҗигале вакыйга мине генә түгел, сезнең күңелләрне дә тетрәткәндер. Бердәнбер куаныч: Йөзем белән Булат исән калдылар, бергә калдылар. Икесен дә районга — хастаханәгә җибәрделәр. Шул китүдән алар авылга әйләнеп кайтмадылар, өйләнешеп, район үзәгендә калдылар. Булат бик тиз аягына басты, йөри башлады, Йөзем эшкә керде, Булатыннан бер яры да читкә тайпылмады...

Дилүсне, Чечняда хезмәт итеп кайткан солдат дип, авыл зиратының иң түренә күмделәр. Күмгәндә районнан, хәтта Казаннан да килделәр. Мылтыктан аттылар. Мылтык ядрәләренең шартлавы тагын бөтен дөньяны сискәндерде, әмма бу юлы агачлардагы кошлар үз ояларын ташлап очмадылар, кешеләр дә гадәти эш-шөгыльләреннән аерылмадылар. Шартлауга да күнегелә икән шул... Сугышка да, үлемгә дә күнегелә... Тик... Барыбер явызлыкка күнегеп булмый. Булмый!

Укучым! Синең бик начар гадәтең бар. Әсәрне укып чыккач, шунда ук аның геройлары хакында төпченә башлыйсың: «Кемнәр алар? Кайсы авылдан? Хәзер нишлиләр?» Бүтән төрле сорау беткән диярсең. Әйтик, менә мондыйрак сорау: бер үк сугыш кырында йөргән ике кешенең берсе ни өчен рухы һәм холкы белән имгәнеп, зәгыйфьләнеп кайта, ни өчен кешелеген югалта, явыз затка, зомбига әверелә, ә икенчесе шул ук сугышта рухи яктан чистарына, иманын ныгыта, тормыш һәм яшәү өчен аяусыз көрәшкә күтәрелә? Ни өчен һәм ни сәбәпле, явызлык белән изгелек бер үк шартларда туа ала?

Кайчагында мин төн уртасында сискәнеп уянам. Колагыма шартлау тавышы керә. Ул бик озак яңгырап тора да, ниндидер сагышлы көйгә әверелеп, каядыр китеп югала. Тавыш килгән җиренә китә, диләр. Шулайдыр. Колагымда яңгырап торган шартлау да шунда — үзе килгән якка китеп югала... Кабат кайтмасын иде бу тавыш, дип телим, сискәндермәсен иде адәм баласын, аның күңел кылларын тетрәтмәсен иде...

*2001*

## *ТАБЫЛДЫК ХАТЛАР*

*(Повесть)*

**1**

Тормышның караламасы юк, диләр. Шулай килеп чыкты инде: Таһир — бомж. Иң гадәти бомж — илсез, йортсыз, эшсез, паспортсыз, хыялсыз бер дөнья бәндәсе. Гаиләсе дә, туганнары да, дуслары да юк аның. Хәтта исеме дә юк. Таһир — элеккеге, беренче тормышыннан калган исем. Әйе шул, аның ике гомере бар: бомж булганчыга кадәрге гомере һәм менә бүгенгесе — эт типкесендәге тормышы. Беренче тормышында Таһирның да әнкәсе, туганнары, сөйгәне, дуслары булган, исеме булган, әйбәтме-начармы, язмышы, өмет-хыяллары булган...

Бомжлар — шундый ук кешеләр, тик аларны вакыт ташлап киткән. Вакыт белән бергә якыннары ташлаган, дуслары, сөйгәннәре баш тарткан. Һәр язмыш бәхетле булып туа. Ә нәрсә соң ул бәхет? Бәхет һәрвакыт өмет булып яши. Бомжлар — өметсез кешеләр. Бәхетсез, язмышсыз кешеләр. Таһирның да өмете калмаган. Ул — өметсез-хыялсыз гына түгел, вакытсыз, замансыз, киләчәксез бер бәндәви зат. Хәзерге тормышында аны «Почта» дип йөртәләр. Ни өченме? Чөнки ул хатлар җыя. Менә шундый сәер гадәте бар Таһирның. Аның керләнүдән ялтырап торган, майга каткан капчыгында һәрвакыт хатлар булыр. Каянмы? Тарихы озын аның.

Бомжлар, гадәттә, гаиләләр яисә бригадалар булып яшиләр. Бүтән гаиләләргә, төркемнәргә каршы тора алу өчен берләшәләр, «туганлашалар» алар. Таһирлар — алтау, барысы да татарлар. Сүз дә юк, төрле чакта төрлечә була — кемдер беразга юкка чыгып тора яисә төрмәгә, милициягә эләгеп ала. Ләкин барыбер дә шушы алты кеше бер тирәдәрәк яшиләр, бу михнәтле тормышта бер-берсенә таяныч булырга тырышалар...

Таһирларның үз районнары, үз урамнары, йортлары, подваллары бар. Хәзер Казанда иске йортларны күпләп сүтәләр, хуҗалары чыгып киткәч тә, кайбер йортлар айлар, еллар буе буш тора. Бушаган өйләрне беренче кичтә үк бомжлар бүлеп яисә сатып ала. Таһир-Почта да, Кирпеч, Сало, Чүлмәк, Люмин, Бөке дигән үз ишләре белән бергә, Кабан буендагы бер йортта яшәп булаша. Башкалар кебек үк, ул көне буе урамда йөри, вакытлыча эш эзли, шешә җыеп сата, шулай ризык юнәтә, аракы эчә, җайсызрак яткан әйбер булса, урлый, шулай гомеренең очын очка ялгап барырга тырыша.

Иң өлкәне Сало — украин татары. Донбасс якларыннан. Ниндидер гөнаһы булган. Төрмәгә утырмас өчен качып килгән. Ни өчен Саломы? Ул сало ярата, салосыз бер тәгам ризык та капмый. Ашында да, боткасында да сало булыр. Үзе дин тота, күп догалар белә, ураза айларында, гаеттә мәчеткә бара, әмма салосыз аш ашамый. Менә шундый мөселман ул. Эчеп алса: «Адәм баласы тамырлы булырга тиеш. Адәм баласының тамыры — иман», — дип сөйләнергә ярата. «Нинди мөселман инде син?» — дип көлә башласалар, җавабы әзер: «Кешегә дөреслек, иман иң элек үзе өчен кирәк. Мин сезнең өчен яшәмим. Бәйләнмәгез!» — дип кенә җибәрә. Дөрес әйтә. Шуңа шым булалар. Нинди генә булмасын, дөрес кеше ул. Бу очракта «иманлы» дип әйтергә яраса, иманлы, ялгансыз кеше. Шуңа күрә дә «гаилә»нең «касса»сы аның кулында. Гадәттә ул «өйдә» кала, чөнки пешеренергә бик оста. Аның хакында: «Балык кылчыгыннан да аш пешереп куя», — дип сөйлиләр. Ризык табу, базар кайгысы, сату-алу мәшәкатьләре дә аның өстендә.

Кирпеч, исеменнән үк күренгәнчә, сүтелә торган йортлардан «кирпеч кыра». Шуларны сатып көн итә. Авыр холыклы, мыштым кеше. Күп сөйләшми. Мари ягыннан. Йөзендә үк марилык - бар. Кечкенә почык борыны, төпкә баткан зәңгәрсу төртке күзләре, җирән чәче, «ызнакум» дип сөйләшүе — шул яклардан. Ләкин чып-чын татар. Татарлыгы йөзенә чыккан — усал, кырыс йөз, туры, үтергеч караш һәм бертуктаусыз шик-шөбһә каккалап торган күңел ярлары... Шулай да Кирпеч беткән кеше түгел. Кешеләрдән нидер калган анда — ялгызы гына утырганда, үзәкне өзә торган моңлы җырлар җырлый ул. Елатырлык итеп җырлый. Әмма үзе керфек тә какмый... Кемдер, нәрсәдер бик нык күңелен катырган аның. Шулайдыр...

Чүлмәк табылдык хәзинәләр белән эш итә. Ул үз гомерендә ике мәртәбә яшереп куелган байлык тапкан. Икесе дә чүлмәктә булган. Исеме дә шуннан калган. Аяныч хәл: байлык тапса да баеп китә

алмаган. Шулай да Таһирлар арасында иң бае ул. Чөнки иң күп акча аңа кирә. Хәтта сирәк-мирәк кенә булса да алтыны да, көмеше дә, затлы ташлары да кергәли... Гел шулай: бушаган йортка иң беренче итеп Чүлмәкне «җибәрәләр». Ул һәр шүрлекне, һәр ярыкны җентекләп карап, тикшереп чыга — әллә нәрсәләр табып бетерә. Кыйммәтле металлга, бизәнү әйберләренә аның борыны сизгер. Үзе кергән һәр йорттан нәрсә дә булса тапмый калганы юк әле.

Чүлмәк — мишәр егете. Мишәрлек аның бөтен кыяфәтенә, холкына чыккан. Утыз биш яшьләр булыр. Ләкин үз яшенә караганда күпкә карт күренә. Ул инде колониядә дә, төрмәдә дә булып өлгергән. Ни хикмәт, кешелеген, намусын югалтмаган. Бу нәрсәдән гыйбарәтме? Үзеннән көчсезгә тими ул. Карак, бур, ялганчы, әмма хәйләкәр һәм явыз түгел, сатлыкҗан түгел, куркак түгел. Көлке капчыгы. Шул шаянлыгы, уенчанлыгы белән Таһирларны чарасызлыктан, күңел төшенкелегеннән, хәтта бәхетсезлекләрдән аралап тора кебек бу мишәр баласы...

Иң яраткан темасы — хатын-кыз. Ләкин алар хакында начар сөйләми. Аның эчеп алса сөйли торган сүзен һәркем яттан белә. «Ир кешене иң элек хатын-кызның тәне исертә, аннары җаны әсир итә. Икенчесе булмаса, ир-ат хатын-кыздан тиз китә», — ди ул. Таһир һаман килеп уйлый: «Бу сүзләрне әйтә алган кеше начар булмаска тиеш», — ди. Көч тәннән түгел, җаннан дигән сүз бит бу. Нинди дөрес сүз!

Люминнең үз тарихы. Анисы — башкорт татары. Башкортстанда бит татар башкортка караганда күбрәк. Ләкин телләр укмашып беткән! Люмин дә «бармаем», «килмәем» дип сөйләшә. Җырларга, биергә ярата. Ризык табасы булмаса, сүзләре аңлашылып бетми торган озын, моңлы җырлар җырлап көннәр буе тик утырыр иде, мөгаен... Һәр моңлы кеше кебек күп елый. Уңган, булган, күп эшли, әмма күп эчә дә. Эчсә, бигрәк тә җебеп төшә...

Люмин төсле металл җыю белән шөгыльләнә. Алюминийны «люмин» дип йөртә. Кушаматы да шуннан калган.

Бу башкорт татарының да бер сүзе бар. Эчеп алса, шуны әйтми калмый. «Хыянәтне, ялганны кичерү,— ди ул,— гомер кичерүгә караганда да авыр». Күрәсең, ул, кайчандыр, хыянәт газабына дучар булып, авыр гына хәлләр кичергәндер. Бу хакта беркем дә сорашмый. Бомж ул — үткәне, киләчәге булмаган кеше. Алар арасында урынлы-урынсызга сорашу, төпчену гадәте юк. Нигә сорашырга? Күрергә теләгән кеше күрә. Күрергә теләгән кеше генә күрә!

Бөке кушаматлы татарның да үз исеме, үткәне булгандыр. Таһирлар гаиләсендәге бу татар — иң олы сер. Аның кем икәнен, каян килгәнен беркем дә белми. Ул — Бөке, шуның белән вәссәлам! Бөке, димәк, шешәләр җыя. Шешә җыючылар бомжлар телендә шулай аталып йөртеләләр.

Кара-кучкыл йөзле, чем–кара чәчле, чем–кара күзле, кара мыеклы бу чибәр кеше ничекләр генә тормышның төбенә тәгәрәгәндер — Ходай Тәгалә үзе генә белә булса кирәк. «Гаилә» кешеләре аны бик хөрмәт итәләр, хәтта бераз шүрлиләр дә. Илле-илле биш яшьләр тирәсендәге бу кешедән, чынлап та, зыялылык, әдәплелек аңкып, хәтта бәреп тора. Ул күп сөйләшми, дөресрәге, бөтенләй дә сөйләшми, кеше сөйләшкәндә, сүз уңаеннан кайбер акыллы сүзләр генә ияртеп җибәрә...

Бомжлар — үзләренең яшәү рәвешләре, дөньяга карашлары белән философлар. Шунсыз бу каргышлы дөньяда исән калу мөмкин дә түгелдер. Әмма Бөке — философның да философы. Ах, ничек туры килми аңа бу кушамат! Бөке — философ... Нишлисең бит, кушаматны сайлап алмыйлар...

Менә шул Бөкедән чыга да инде хикмәтле сүзләр. Бервакыт кич җыелып алгач, байлык хакында сүз чыкты. Һәркем үзенчә сукалый, һәркем үзенчә хаклы.

Бер читтә дәшми-нитми утырган Бөке үзалдына сөйләгән кебек кенә әйтеп куйды:

— Җыйган байлыгыгызга йөрәгегезне якын җибәрмәгез...

Шунда сүз дә бетте. Уйланырга урын бар иде инде монда. Бик бар иде.

Берсендә Чүлмәк үз тормышларының нинди ирекле, хөр булуы хакында шапырына башлады. Әлбәттә, ул тиле түгел. Беркем дә тиле түгел. Сүз юктан сүз булсын дип сөйли бу. Ләкин Бөке өчен сүзнең уены-чыны юк. Аның өчен сүз генә бар.

Бу юлы да Чүлмәкнең авызын тиз япты ул:

— Ирек колы булу шулай ук коллык түгелме, уйла әле. Ирек ул — Аллаһы Тәгаләгә буйсыну, — диде дә урамга чыгып китте.

Чүлмәккә генә түгел, башкаларның башына да уй төште. Йөрәкләргә җәрәхәт булып төшәрлек уй иде ул. Ләкин бу уй ничек кергән булса, шулай чыгып та китте. Чөнки йөрәкләрдә яңа җәрәхәтъяра өчен урын калмаган иде.

Таһир — бөтенләй башка дөнья кешесе. Ул кәгазь әйберләр, китаплар, журналлар, газеталар җыя. Үз карамагындагы урамнарны «тикшергәндә», чүп савытларын актарганда, бигрәк тә ташландык йортлар сүткәндә, бөтен язма, басма әйберләрне күз уңыннан кичереп бара. Кирәкмәгәннәрен «Стимул»га тапшыра, сирәгрәк китапларны «Букинист» кибетенә сатарга куя, китап күпләп җыелган вакытларда колхоз базарына чыгып та утыргалый.

Эш булмаганда яисә урамга чыгарга иренгәндә, Таһир рәсем төшерергә керешә. Ташландык кәгазьләр арасыннан берәр буш бит чыкса, аның өчен олы бәйрәм инде. Ул шунда ук, кесәсеннән каләм-карандаш алып, берәр нәрсә сызгалый башлый. Юк, онытылмаган әле аның укыганнары. Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән сәләте дә үз урынында.

Күбрәк үзе кебек урам сукбайларының сурәтләрен төшерә Таһир. Казан урамнарында, подвалларда, чардакларда көн күрүче бу мәхлук җаннарның кәгазьгә төшерелгән йөз-битләре кемгә кирәк соң? Таһир моны үзе дә әйтә алмый. Тормышның төбендә яшәгән бәхетсез бәндәләрне, шушы рәвешле булса да, тарихта калдырырга телиме? Әллә бу сукбайлардан үз шәхесенең өстенлеген күрсәтергә, расларга тырышамы?

Боларның икесе дә бардыр. Әмма өченче бер сәбәп тә бар. Бомжлар арасында искиткеч кызык типажлар очрый. Йөзе җимерек, авыз читендә бердәнбер теше тырпаеп торган, йөзен аркылыга-буйга җыерчык баскан сукбайның бәхетле елмаюы ни тора! Бәхет кошы тотканмыни! Бәлки, аның бүген тамагы туйгандыр? Бәлки, ул бер йотым аракылык акча тапкандыр? Ә бәлки… Бәлки, бу Хода бәндәсе якты көн туганга, кояш чыкканга, көн җылынганга, кошлар сайраганга сөенәдер? Ә бәлки, ул бу мизгелдә үз якыннары, балалары, дуслары хакында яхшы хәбәр ишеткәндер? Яисә менә бу теләнче малай сурәте. Аны да Таһир ташландык йорттагы кылка бүлмәсенең түр стенасына, теге сукбай карт сурәте янәшәсенә беркетеп куйды. Учларын алга сузып, ялварулы чырай белән хәер сорашып торучы бу татар малае ни хакта уйлый икән? Бу рәсемгә карагач, Таһирның күңеленә бик сәер уйлар килгәли. «Татар халкы да шушы малай хәлендә түгелме соң?» дип уйлый ул. Дөнья, тормыш арбасыннан төшеп калса да, ул сизенә: нәрсәдер бара бу хәятта, ниндидер буталчык вазгыять заманы бу… Ул, шешә җыеп йөргәндә, Ирек мәйданында ирек даулап йөрүче халыкка карап шаккатып торган иде бервакыт. Кешегә кушылып, үзе дә: «Азатлык!» — дип, берничә мәртәбә кычкырды әле…

Таһирның кәгазьгә иң күп төшергән кешесе — Сало. Кызык тип. Йөзенә карап кына аның бәхетле яисә бәхетсез булуын белеп булмый. Хисләрен, тойгыларын бик тирән яшерә ул. Әмма күзләрен, карашларын һич яшерә алмый. Шуның белән кызык та аның йөз-кыяфәте.

«Гаилә»дәгеләрнең барысын да иренмичә акка төшереп бара Таһир. Төшергәч, һәр сурәтне кадерләп салып куя. Артыграк эчеп-исереп йөргәндә генә, юмартланып китеп, ясаганнарын чәчептуздырып бетерә. Бу вакытта бер генә сурәтне кадерләп саклый. Кайчандыр, элеккеге тормышында төшергән хатын-кыз сурәте ул…

Таһирның иң яраткан шөгыле — хатлар уку. Берәр газета яисә китап арасыннан, яки ашъяулык астыннан, матча ярыгыннан хат кисәге килеп чыкса, ул нишләргә дә белми, үзе хат алган кебек кылана, әллә нинди хыялый хисләр өермәсендә яши башлый. Иң элек хатның иясен күз алдына китерә, аннары хат алган кешенең йөз-бит чалымнарын, күз карашын, холкын, күңел хасиятләрен күзалларга керешә, ахырдан алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, хис-тойгыларны, язмышларны уйлап чыгара. Шуннан соң гына хатны ачып укый башлый. Моннан биш, ун, утыз, хәтта илле-алтмыш ел элек язылган хатларны укудан да ләззәтлерәк минутлар бар микән?! Таһир-Почтаның хәзерге тормышында иң гүзәл мәл — шушы вакыт. Ул инде күптән кеше хатлары, кеше хисләре һәм кеше язмышлары белән яши, борчыла, сагышлана яисә сөенә, шатлана… Бу хатларны ул кадерләп, бөртекләп җыеп бара, күз карасы, бәгырь кисәге кебек саклый, барлап тора… Ул хәтта үзе дә, хыялы белән генә булса да, шушы чит-ят язмышларга кереп, кушылып яшәргә, шул хыялый яшәүдән тәм һәм ямь табарга, мәгънә алырга күнегеп китте.

Шушы хатлар коткарып калды да бугай аны. Дөньядан ваз кичеп, тормыштан йөз чөереп, бомжлар, бичлар типкесендә йөргән беренче елларында үләсе килгән чаклары күп булды аның. Кыйналып, канга батып, өшеп-туңып яткан вакытларында күңеленнән генә хат яза иде ул. Кемгәме? Беркемгә дә түгел. Тормышка. Дөньяга. Дөнья иясенә. Юк, Ходай Тәгаләгә түгел. Ул үзенең Аның каршында гөнаһлы булуын белә. Әле бит Тормыш иясе, Дөнья иясе бар. Булмаса, булырга тиеш! Нәрсә карый ул? Ниләр эшли ул үзенә тапшырылган адәм балалары белән?!

Мондый хатлар аның бөтен булган-булмаган җан җылысын, соңгы күңел хисләрен суырып чыгара иде. Бервакыт Таһир бу күңел аҗаганнарыннан баш тартты, бүтән кешеләрнең хатларын укырга күнегеп китте. Бу хат ияләренең язмышлары аныкына караганда күпкә җиңелрәк, аңлаешлырак иде. Үзенең хәтер капкачын томалап куеп, башын күтәреп, калкытып, дөнья гаме белән яши башлады.

Һәркемнән бер хәтер кала…

Хәтер хөкеме — иң хәтәр хөкем…

Таһир боларны белә. Исән-сау булса, кайчан да булса бер килеп тотачак ул аны. Кеше күңеле артына, кеше хисләре эченә, хәтта кеше язмышына качып кына котылып кала алмаячак. Шулай да болай тынычрак, җиңелрәк. Тормышны алдабрак, дөресрәге, аңа алданыбрак күпмедер яшәп була әле.

Ә хатларның ниндиләре генә юк! Язмышларның ниндие генә юк! Таһир гел шуны искә ала: аның күңелен сабырлыкка, түземлеккә күндерсәләр дә, хатлар арасында бәхетлеләре бик сирәк. Сагышлы, борчулы хатлар күбрәк. Юк, юк, өметсез диясе килми. Кешеләр бер-берсенә ышанырга тиеш. Ышануда өмет нуры яши. Өмет барыбер кала ул. Кеше шундый инде: иң авыр вакытында да йөрәгенә бер бөртек өмет чаткысы төреп калдыра. Шуның белән яши, кайчакта бу чаткыдан әллә нинди матур һәм мәгънәле яшәү учаклары кабынып китә…

Бер хатны Таһир мәңге онытмаячак. Аның иясе сөйгәненә йөрәк каны белән шундый сүзләр язган:

*«Кадерлем! Бәгърем!* — дигән ул. — *Мин бик-бик бәхетле кеше. Шуны аңладым: бер мәртәбә бәхетле булсаң, син һәрвакыт бәхетле икән. Ә мин бәхетле булдым. Бер мизгелгә генә булса да бәхетле булып калдым… Рәхмәт сиңа, җанкисәгем!»*

Икенче бер хатта да яшәү гыйбрәте ап-ачык ярылып ята. Монда борчу-сагыш та, өмет-ышаныч та бер үк хискә төреп бирелгән:

*«Сөеклем минем! Ничек сагынганымны белсәң иде! Их, аерылышу өчен мең сәбәп табу да кыен түгел, очрашу өчен бер сәбәп табу да кыен икән… Кичер мине, бәгърем…»*

Тагын бер хатны гел хәтерендә йөртә Таһир: *«Ярату — кичерү түгел әле. Әйе, акыллым, мин сине яратам, хәтта мин синсез яшәүне күз алдына да китерә алмыйм. Әмма мин сине кичерә дә алмыйм… Беләсеңме, җиңел килгән мәхәббәт кенә хыянәтне кичерә ала. Ә минем мәхәббәтем авыр килде, күңел гарасатларын җиңеп, йөрәк ярсуларында җәрәхәтләнеп, сагыш дәрьяларын кичеп килде… Шуңа да кичерә алмыйм. Сорама да, үгетләмә дә…»*

Ә бу хатта Таһир үз мәхәббәтен таныды:

*«И җаным! Син үзеңнең үпкә-битәрләрең, битарафлыгың белән минем олы, саф мәхәббәтемне өркеттең, куркыттың. Хәзер син үз ярларыңа кайттың, мин дә тынычландым. Курку үтте… Тик менә нәрсә: мәхәббәттә курку үтә, ләкин үзе белән мәхәббәтнең матурлыгын да алып китә икән. Ачуланма, яме. Мин сине элеккечә матур итеп ярата алмаячакмын…»*

Ана хатлары, бала хатлары… Аларны бер сүз белән «балачак хатлары» дип тә әйтергә мөмкиндер. Кеше гомере кош булса, балачак — аның канатлары…

Ана хаты: *«Улым, бала чагың сәлам әйтә…»*

Бала хаты: *«Әнкәй, сагындым мин аны — бала чагымны… Һаман да шулай инеш буенда бәбкә саклап йөриме ул?..»*

Ана хаты: *«Ул инде үсте, улым. Хәзер ат сакларга йөри. Кызлар белән кичке уенга чыга…»*

Бала хаты: *«Минем кебек, атлар ратамы ул?»*

Ана хаты: *«Бәй, син үзең бит инде ул, улым!..»*

Бала хаты: *«Ә! Шулай бит әле… Үзем булсам да, барыбер сагындым мин аны, әнкәй!»*

Тагын менә мондый хатлар:

*«Балам, сагындым, кайт!»* — дип яза ана кеше.

*«Әнкәй, акча сал әле»,* — дип җавап бирә бала кеше.

*«Балам, син кайда? Кайтмасаң кайтма, бер бөртек сүз язып кына җибәр»,* — ди ана кеше.

*«Әнкәй, мин күптән кайттым инде, килергә вакытым гына юк»,* — ди бала кеше.

Мондый хатлар Таһирга ошамый. Андыйларны ул аерым җыя. Ярый әле күп түгел алар. Димәк, борчулы, кайгылы, бәхетсез аналар да күп түгел…

Кайчакта хатлар төргәкләп, янчыклап, хәтта капчыклап та табылалар. Бер яки берничә хатта гына кеше язмышын тоеп, аңлап бетерү кыен. Ә менә берничә хатта кешенең бөтен тормышы, яшәү бәхете яисә яшәү драмасы ачыла да китә…

*«Мин шундый кыен хәлдә калдым,* — ди бер хат иясе. — *Акылым белән күңелем бәхәсләшә. Берсе сиңа дәшә, икенчесе тыя… Нишләргә дә белмим…»*

*«Минемчә, чын мәхәббәттә йөрәк акыллы булырга, ә акыл хисләнә белергә тиеш. Син аларны аерма. Алар бергә яшәсен, бергә яратсын»,* — ди җавап хаты.

*«Булмый, булмый! Бер минутта йөрәк «яратам» дип тибә, икенче караганда «яратмыйм» ди!»*

*«Ялгышасың, акыллым. Йөрәк «яратмыйм» дигән сүзне белми. Ул «яратам», «сөям» дигән сүзләрне генә белә. «Яратмыйм» дигән сүзне акыл әйтә…»*

*«Һәр кешенең үз сәгате бар. Шул сәгате суккан вакытны туры китерә алса гына кешегә бәхет капусы ачыла… Димәк, минем сәгатем сукмаган әле…»*

*«Син суккан сәгатеңне көтеп утырган арада, мин үземнең тиңемне таптым инде. Аның сәгате юк. Аның олы һәм матур йөрәге генә бар…»*

Күңелгә иң тигәне — ачылмаган хатлар. Әйе, андый хатлар да очраштыра. Элегрәк Таһир аларны шундук ачып укый иде. Шулай кабаланып хат ияләренең язмышларын хәл итәргә, кирәк булса, аларны яхшы якка үзгәртергә телиме ул?.. Язмышның барышын, гомернең вакытын куып җитеп булмый анысы… Ничек кенә, нинди сәбәпләр аркасында гына ачылмыйча, укылмыйча калды -

икән бу хатлар? Ә бит алар арасында да кешенең язмышын хәл итә торганнары, яшәү мәгънәсен, бәхетен-бәхетсезлеген билгели торганнары бар.

Кайберләрен Таһир яттан белә. Аларны һаман-һаман күңеленнән кичереп яши.

*«Балам, газизем Гарифулла!*

*Мин бу җомгада Ходай каршына барырга җыенам. Ун ел кайтканың юк. Анаңны соңгы юлга озатып җибәрергә булса да кайт. Күреп каласым, күз карашларыңның нурын, кулларыңның җылысын үзем белән дә алыр идем. Анда да сагынылыр бит... Кайт, Гарифулла балам... Ялварып сорыйм, кайт...»*

Хат ачылмаган... Укылмаган... Ана белән бала күрешә алмаганнар... Нәрсә булган? Ник? Нигә? Язмыш шаяруымы, әллә бала кешенең гадәти битарафлыгымы? Таһирның йөрәге шушы сорауга җавап эзләп бер генә әрнемәде. Ул шул ук вакытта үз анасы хакында уйлады. Аның анасы да улын күрмичә китеп барды. Таһир ул вакытта шабашниклар бригадасы белән хәер эстәп йөри иде. Ул вакытта аның айныган чагы сирәк булды шул. Анасының үлүен дә ярты елдан соң гына, Казан урамында очраган бер авылдашыннан ишетеп белде. Каберенә генә булса да кайтып килергә уйлаган иде. Кайта алмады. Туган җире кабул итәргә теләмәде үзенең мәнсез баласын. Халкың, илең сине яратмый икән, димәк, синең гөнаһың бар, дигәннәре дөрес ул, бик дөрес. Таһирны да кабул итмәде туган ягы. Чөнки туган җир белә ул: балалыгын югалткан кеше кешелеген дә югалта...

Хәзерме? Хәзер үзенең кайтасы килми инде...

Ул вакытта аны бик каты кыйнадылар. Булган әйберләре дә, документлары да шунда юкка чыкты. Ике ай буе җир астындагы җылылык трассасында сынган кабыргаларын, имгәнгән күкрәк сөякләрен, яңакларын, кара янган йөзен, янбашларын дәвалап ятты. Нинди дәва инде ул! Үз ишләре калдырып киткән аракы белән юып куя да, калганын эчеп, дивана кебек иңке-миңке килеп тик ята...

Сало эзләп тапмаса, шул караңгы җир астында мәңгелеккә калыр иде, мөгаен. Шул украин татары аякка бастырды аны. Ләкин йөзендәге тирән җәрәхәт җөйләре, кыйшаебрак калган ияге һаман әле шул чордагы күңелсез хәлләрне искә төшереп тора...

Тагын бер ачылмаган хат Таһирның күңеленә тирән уелып калды. Монда да язмыш... Бала язмышы...

*«Искәндәр, бәгърем,* — диелгән иде бу хатта. — *Ник кайтмыйсың? Белмисеңме әллә? Безнең балабыз булачак... Шушы көннәрдә якты дөньяга киләчәк. Больницасын белешеп куйдым инде. Тик... Синсез үстерәсем килми ул баланы. Кайтмасаң, тапкан җиремдә калдырып чыгам. Кайт, Искәндәр, кайт... Бала тапканда үләрмен кебек... Кайт! Зинһар, кайт! Көтеп, синең Галияң».*

Бу хатны укыгач, Таһирның күңелендә туган беренче уй Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәре хакында булды. «Болары инде безнең заман Искәндәрләре», — дип уйлап та куйган иде ул вакытта.

Ә үзе соң, үзе... Үзе кайсы ягы белән яхшырак соң бу хаттагы Искәндәрдән? Ул Зөһрәсе белән ирле-хатынлы булып, тигез, бәхетле тормыш корып яшәргә тиеш иде бит. Балалары булыр иде... Их!..

Ачылмаган хатлар Таһирга аеруча күп борчу китерделәр. Шуңа күрә дә ул андый хатларны ачмас, укымас булды. Аерым бер төргәккә җыя башлады. Төргәк дип, бөтенесе өч-дүрт хат җыелгандыр... Өч-дүрт бәхет... Яки өч-дүрт бәхетсезлек... Бәхете бар микән соң? Әллә гел бәхетсезлек кенәме? Нигәдер ачылмаган бит алар, ачылмаган!.. Аларны укымаганнар! Укырга теләмәгәннәрме? Укырга бирмәгәннәрме? Адреслары ялгышканмы? Әллә язмышлары ялгышканмы?

Таһирның үз язмышы да кайчандыр шушы серле дә, зарлы да хатларга бәйләнгән иде. Зөһрәсе белән дә хат аша гына серләште. Ниндидер бер күтәренкелек, дәрт белән, эчендәгесен бөртегенә кадәр түгеп бетереп, тәмам хисләнеп, әсәрләнеп яза иде ул хатларын. Аның илаһи догалары да, яшәү тәгълиматы да, сихер-ырымнары да шушы хатлар булды, ахры...

Иң соңгы хатын ул җиде ел элек язды. Зөһрәгә атап язган шушы хаттан соң гамьле тормыш белән араны өзде, хәзерге гамьсез, ямьсез һәм мәнсез дөньяга күчте.

## 2

Язмыш гел сөюдән тора, калганы — ялгыш, диләрме әле? Әйе, һәр язмыш бәхетле булып туа. Бәхетсезлек яшәү белән килә.

Шундый матур танышканнар иде алар! Казанның «Шәрык» ресторанында булды бу очрашу. Түбән Камада бизәүче-рәссам эшенә укып чыгып, Казанга эш эзләргә килгән чагы иде Таһирның. Танышлары аша берничә эш белеште. Икенче көнне иртән килергә кушып җибәрделәр. Кичне ничек үткәрергә? Әлбәттә, бер матур кичлек кенә акчасы бар аның. Иң элек авылда бергә укыган Наилне эзләп тапты. Берничә көн аңарда кунып чыгарга булды. Шул уңайдан, бергәләп, «Шәрык» ресторанында күңел ачып утырырга уйладылар.

Күңел белән бергә берничә шешә шәраб ачылды. Сыра соратып алдылар. Әллә ни исермәделәр, күңелле генә сөйләшеп утырдылар да утырдылар…

Бервакыт ишектән, шаулаша-шаулаша, ике егет, ике кыз килеп керделәр. Көлешә-көлешә түрдәге буш өстәл артына барып утырдылар. Яныннан узганда кызларның берсе ак чәчле, икенчесе кара чәчле булуын гына шәйләп калды Таһир. Егетләр официантны чакырдылар. Заказ бирделәр. Тагын көлешергә тотындылар…

Таһир һич кенә дә аңламады: нигә күңелен шул яктан ала алмый соң әле ул? Колагы белән Наилне тыңлый, ә күзләре белән бая килеп кергән яшьләрне күзли. Серен дә белә кебек… Бик матур мөлаем тавыш бар анда. Таныш тавыш… Нинди кыз соң ул? Кем? Каян? Кайда очраштылар икән? Ниндидер мөлаем тавыш… Көлүләре… Әгәр фәрештәләрнең тавышы бар дисәләр, шушындый буладыр ул тавыш…

Таһирның җаны тынгысызланды. Ул инде Наилне бөтенләй тыңламый. Наил дә моны күрә. Серле елмаеп, Таһирны күзәтә.

— Бар, биюгә чакыр…

— Нәрсә?.. Кемне…

— Кем дигән кешене. Баядан бирле шул кыздан күз дә, колак та алмыйча утырасың бит…

— Анысы шулай… Ничектер… җанга төште шул тавыш… Әллә күргән бар инде…

— Бәлки, ул синең Зөһрәңдер?

— Нинди Зөһрә? Мине Таһир дигәч тә, Зөһрәләр, алга чыгып, көтеп торалар ди… Әнә аның үз Таһиры бар…

— Каян беләсең аны? Болар — иң гадәти студентлар. Икәүдән-икәү булсалар, парлап кереп утырырлар иде. Психологияне белмисең син, парин…

— Әйе шул, дүртәүләп йөрмәсләр иде…

— Шулай булгач, бар, чакыр.

— Туктале! Иң элек ныклап кара — ниндирәк ул? Чибәрме?

— Кайсысы?

— Кайсысы, ди… Тиле! Миңа ошаганы, матур тавышлысы… Зөһрә дигәне…

— Нәрсә-нәрсә? Зөһрә дип юри әйттем бит мин… Болай гына, үзең Таһир булганга гына. Әллә ышанып утырасың инде?..

— Кара инде, ниндирәк ул?

— Әллә… Миңа икесе дә бер…

— Тыңла башта… Берсенең тавышы бигрәк тә матур… Көлгәндә челтерәп китә… Кыңгырау кебек… Юк, чишмә кебек…

— Хыялый син, Таһир. Сиңа шагыйрь булырга кирәк, белдеңме?

— Наил, давай серьезно?!

— Хәзер-хәзер… Әһә… Әнә ул… Кара чәчлесе, кара кашлысы, кара күзлесе шулай көлә икән… Чибәр бу, малай… Моңа якын барсаң, бетәсең син, парин…

— Бәхет ягы ничек, бәхет ягы?

— Хатын-кыздан бәхетле булган кеше үзе үк бәхетсез инде. Аның гомере тынгысызлыкта үтә. Шуңа күрә сорама…

— Берьюлы бәхетле дә, бәхетсез дә булып буламыни, тиле!

— Димәк, була!

Таһир тәвәккәлләде. Аның күңелен аңлагандай, яңа бию көе куйдылар. Салмак, моңлы музыка, дәртле борылмалары белән җаннарны җилкендереп, бөтен зал эченә таралды. Бу көй шаукымы шулай көчле идеме — Зөһрә утырган өстәл ягыннан да шаярып көлү тавышлары ишетелми башлады. Зөһрә дә моңлы кыздыр шул. Чын татар баласыдыр. Шуңа да, бу моңлы шәрык көен ишетеп, әллә нинди сихри уйларга талгандыр, бәлки әле, алдагы гомер юлында зарыгып көтеп торучы мәхәббәтен дә тойгандыр, шуны тоеп, йөрәге ярсынгандыр?.. Ул бит Зөһрә, ә Зөһрәнең Таһиры булырга тиеш. Булмаса, ул үз Таһирын эзләп табарга тиеш! Таһир үзенең Зөһрәсен эзләгән кебек.

Таһир кискен генә торды да, кулындагы ашъяулыгын урындыгына томырып, җәһәт адымнар белән түргә табан китте. Менә ул өстәл… Менә алар… Менә ул кызый… Зөһрә… Тукта, тиле! Нинди Зөһрә булсын ул?! Бернинди дә Зөһрә түгел! Хәзер белә ул аның исемен… Исемдәмени хикмәт! Нишләп исемдә булмасын! Исемдә шул! Әбисе әйтә иде: «Исем буенча җанны таныйлар», — ди иде…

— Сезне биюгә чакырырга рөхсәт итегез…

Ап-ак чәчле кыз белән серләшеп утыручы «Зөһрә» Таһирга борылып та карамады. Аны иң элек «сары чәч» күрде. Аннары каршыларында утырган ике егет, сәерсенеп, бер-берсенә карашып куйдылар. Кем бу, янәсе.

«Сары чәч», «Зөһрә»нең беләгеннән тотып, Таһир ягына ымлап күрсәтте. Бу аның, әнә сиңа килгәннәр, дию иде бугай.

Менә ул — «Зөһрә»! Кара чәчле, кара шомырт күзле кыз борылып карауга ук Таһир аңлап алды: шул! Зөһрә! Күңелендәге ташы эреп, җанына җиңеллек инде, аннары канат яралды; җаны шул канатларын җилпеп, дөньяны иңләп-буйлап, очып, очынып йөри башлады. Җан бит ул үзе генә булганда «җан» дип атала, ә канатлы җан «мәхәббәт», «сөю» дип йөртелә…

— Сезне биюгә чакырырга мөмкинме?

— Мөмкин түгел! Тай моннан! — Моны кызмачарак чырайлы егет әйтте.

— Мөмкин, нишләп мөмкин булмасын… Ә син, Хәлил, тик кенә утыр. Синнән сорамыйлар бит… Барыбер берегез дә бии белми…

«Зөһрә» биюгә һәвәс булып чыкты. Таһир үзе дә кимен куймый. Шулкадәр бер-берсенә күнегеп киттеләр, әйтерсең гомер буе шулай бергә биеп йөргәннәр. Биеп кенә йөргәннәр…

Таһир һаман да әле «Зөһрә»не ныклап карый алмый. Маңгаендагы «ай» чәчләренә шунда ук игътибар итте итүен. Ә менә күзләреннән китә алмады. Бер төшеп батты да, чыга алмыйча, шул сихри дәрьяда чайкалуында булды… Бик үк чыгасы да килмәде…

— Сезнең исемегез ничек?

— Ә сезнең?

— Ә мин сезнең исемегезне беләм… — Әллә нинди җен тартты Таһирның теле очыннан. Каян белсен ул бу кызның исемен?! Беренче генә күрүе бит… Тиле! Телен тыя алмаган тиле! Ә теле, чынлап та, аңа буйсынмый иде инде. Теле аның җанына, күңеленә генә буйсына иде…

— Сезнең исемегез Зөһрә…

— Зөһрә шул. Каян белдегез?

— Ә бит мин сезне күптән беләм.

— Беләсез?.. Каян? Йә әйтегез инде!..

— Хыялымнан ук беләм… Сез бит минем хыялымда күптән бар инде… Ә сез чынлап та Зөһрәме?

— Зөһрә…

— Бу бит нindидер могҗиза! Чынлап та Зөһрәме? Алдашмыйсызмы?

— Зөһрә, Зөһрә… Ә сез мине каян беләсез?

— Белмим, үзем дә белмим, ей-богу!

— Шаяртасыздыр әле… Беләсездер…

— Шаяртмыйм, мин сезне беренче мәртәбә күрәм.

— Мин дә беренче күрәм. Телисезме, мин дә сезнең исемегезне белергә тырышып карыйм. Мин аны беләм дә инде… Таһир — шулаймы?

— Таһир… Каян белдең?

— Зөһрәсе булгач, Таһиры да булырга тиештер бит?

— Ә синең Таһирың бармы соң?

— Сингә кучтекмени?

— Әйдә күчәбез! Без бит Таһир белән Зөһрә! Беләсеңме безгә ничә яшь?

— Юк, белмим…

— Безгәме?.. Хәзер әйтәм… Безгә… мең яшь! Менә бит хикмәт нидә! Каян беләм дип уйлаган идем аны. Без бит инде мең ел таныш! Ә син хәтерлисеңме мине?

— Хәтерлим дә, хәтерләмим дә…

— Алай булмый ул.

— Була икән…

— Була, була. Миндә дә нәкъ шундый хәл. Туктале, ник җаваптан качасың? Синең Таһирың бармы, дип сорадым бит мин.

Зөһрә яңгыратып көлеп җибәрде.

— Бар, бар! Менә бит ул — каршымда басып тора.

— Шаярмале, Зөһрә. Миңа кадәрге «Таһир»ың хакында сорыйм мин синнән.

— Бу сиңа бик кирәкме?

— Кирәк.

— Үзең әле генә әйттең бит, безнең очрашу — серле могҗиза, дидең. Ә син беләсеңме: күп сорау могҗизаны үтерә…

Алар шулай очраштылар. Аларның очрашуы, танышуы чынлап та илаһи бер могҗиза кебек иде. Исемнәре туры килүен әйт. Икесе дә бер-берсен шундук ошаттылар. Яраттылар дип әйтергә дә ярыйдыр. Бер-берсенә гашыйк булдылар. Гашыйкларны вакыт ташлап китә, ди. Бу ике яшь йөрәкне дә ташлап китте ул. Бию көе күптән беткән, Зөһрәнең группадаш дуслары да, Наил дә аларны көтеп зарыкканнар, ә Таһир белән Зөһрәнең бөтенесе дә әле башланып кына килә иде.

Алар, очрашырга сүз куешып, кул биреп, моңсу гына аерылыштылар. Таһир Зөһрә кулындагы көмеш беләзеккә игътибар итте. Шундый килешеп тора иде ул кызның зифа беләгенә! Зөһрә үзенең биофакта укуын, биология укытучысы булачагын әйтте, Таһир үз тарихын сөйләде.

Кыз нишләгәндер, әмма Таһир кайтып җиткәнче Наилнең колагына тукып кайтты:

— Наил, әйт инде, ошадымы ул сиңа? Чибәр бит, әйеме? Беләсеңме, беркемгә дә охшамаган ул. Үзенә башка бер кыз… Үзе чая, үзе тыйнак. Менә әйт әле, шушы ике сыйфат берьюлы бер кешедә яши аламы?

Кайтып керсәләр — телеграмма. Туганнан туган абыйсы суккан. «Фәүзия апаның бөереннән таш таптылар. Операциягә әзерлиләр. Тиз кайт» дигән.

Бәхет һәрвакыт ялындырып килә.

Мәхәббәт җиңел генә бирелми шул. Аны күңелеңә алганчы, әллә күпме сынаулардан үткәрә сине Ходай Тәгалә. Җиңел генә килгән мәхәббәт шикләндерә дә. Җиңел килгән җиңел китә. Таһир шулай уйлады. Уйламады да, тойды, сизенде. Әнкәсе янына кайтып, аны дәвалап, терелтеп, ана күңелен юатып килә дә… Зөһрәсен кабат эзләп таба… Аерылу — гашыйклар язмышы, сагыш — аларның күңел халәте. Таһир бу аерылуны аңлап кабул итте, яңа гына туып килгән күңел хисләрен яшь йөрәгенә төреп, ачы таң белән авыру анасы янына кайтып китте.

Ләкин Таһир Казанга тиз генә килә алмады. Бер ай гына түгел, ярты ел да, бер ел да үтте. Түбән Камада эшкә урнашты, әйбәт кенә эшләп китте. Бөтен буш вакытын әнкәсенә багышлады. Аның бердәнбер караучысы булып Таһир калган иде шул…

Зөһрәне ул бер минутка да хәтереннән чыгармады. Хәтта… һаман ныграк яратты. Сагынды. Юксынды. Кабат очрашуга ымсынып яшәде. Өметләнде. Ләкин эзләмәде. Хат та язмады. Нәкъ бер елдан Казанга барып чыккач, Казан дәүләт университетыннан эзләп тапты. Зөһрә дәүләт имтиханыннан чыгып килә иде. Бер ел элек күргәндәгечә, яңгыратып көлеп килә… Очып килә…

Таһирны күрүгә, шундук «җиргә сикереп төште». Йөзендәге бәхет тә, чәлпәрәмә килеп, шушы гамьле, борчулы җиргә «коелды». Таһир биргән роза чәчәген дә теләр-теләмәс кенә алды ул. Аннары, матур керфекләрен киереп ачкан килеш, «син дә исәнмени?» дигән аптыраулы карашы белән Таһирга төбәлеп катып калды. Бу аптыраулы караашта ниндидер шом, курку бар иде. Таһир кайсыдыр бер мәлдә Зөһрәнең әлеге моңсу карашында нәрсә өчендер үкенү, хәтта кемгәдер бетмәс-төкәнмәс үпкә, битәр шәйләп калды.

Ләкин ул үзенең шатлыгын яшермәде. Күңелендәгесен йөзендә, күзендә тотты. Дулкынлануын гына яшереп бетерә алмады.

Каушавыннан бераз тынсыз-өнсез калып торганнан соң, бер ел буе йөрәгендә йөрткән сөю хисен бер матур сүзгә ияртеп, күңел читлегеннән очырып чыгарып җибәрде:

— Зөһрә!

— Таһир!

— Исәнме!..

— Исәнме…

— Менә тагын очраштык…

— Очраштык… Чәчәгең өчен рәхмәт…

— Сөйләшәбезме?

— Нәрсә хакында?

— Барысы хакында да. Синең хакта, минем хакта… Аннары… икебез хакында…

— Нигә?

— Белмим. Әлегә белмим… Мин сине нык аптыраттыммы?

— Аптыраттың… Бер ел буе кайда йөрдең соң? Очрашабыз дидең дә юкка чыктың…

— Шулай килеп чыкты инде. Көттеңме?

— Анысы мөһим түгел. Әйткәч, сүздә торырга кирәк, шул гына.

— Зөһрә, ачуланма, әнкәй бик авырды минем. Телеграмма белән чакыртып алдылар… Мин сине бер минутка да истән чыгармадым.

— Хәзер терелдеме инде?

— Терелде. Аның башка карар кешесе юк бит. Шуңа күрә Түбән Камада калдым. Эшкә урнаштым. Менә… Беренче мәртәбә чыгып киттем. Туры монда килдем. Ә син ничек?

— Бүген соңгы экзаменны тапшырдым.

— Бишледер инде?

— Эш билгедәмени?! Бүген минем бик бәхетле көнем иде. Сине күргәнче…

— Ничек инде? Аңламадым…

— Аңламассың шул. Шуңа күрә сорама. Син сорама, мин әйтмим… Килештекме? Ә килүең өчен рәхмәт. Күңелем булды. Чын!

Шул вакыт каяндыр бер чандыр егет килеп чыкты да Зөһрәнең беләгеннән тотып алды, аннары Таһирга игътибар да итмичә тезеп китте:

— Зөһрә, бишлеме? Бишледер инде, нәрсә булсын. Сиңа рәхәт, эшең бетте. Минем әле башланмаган да. Кайта торасыңмы? Мин бүген соңгарак калам. Егетләр Казанка буена төшеп утырабыз, ди-

ләр. Берәр тәмле нәрсә пешер, яме. Илдар белән Гөлүсә ияреп кайтачак. Ну, ярый. Тиргәп тор. Эт итеп сүк. Берәр дүртле эләкмәсме… Тукта, ник болай ямансу соң әле син? Берәр җирең авыртмыйдыр бит? Бар, кайт, йокла. Бу кадәр укуыңа… Ну, пока!..

— Пока, Таһир, ни пуха!..

— К черту!

Бер Таһир китте, икенчесе авызын ачып басып калды. Басып калганы бер Зөһрәгә, бер үзенең адашына карый. Дөресрәге, аның эзенә, шәүләсенә, өрәгенә карый…

— Таһир? — Таһир теге озын, чандыр егет киткән якка караган килеш сораша башламасынмы… — Кем ул? Нинди Таһир?

Миннән башка да Таһирлар бармыни бу дөньяда, дигән кебек сорады ул. Ләкин, шушы сорау белән бергә, аның ачык, садә, хәтта самими күңеленә шомлы уйлар йөгереп керә башлаган иде инде.

Бу уйлар белән бергә аңына да Зөһрәнең йомшак, әмма үтә дә борчулы тавышы килеп иреште:

— Монысы минем Таһир… Ул быел юрфакны тәмамлый…

— Ни өчен Таһир?

— Син үзең әйттең бит, һәр Зөһрәнең Таһиры булырга тиеш, дидең… Менә… эзләп таптым. Бөтен университетка бердәнбер Таһир ул. Булганы шул, ошамаса — ачуланма…

— Нәрсә сөйлисең син, Зөһрә?

— Мин дөресен сөйлим, Таһир. Үзем эзләп таптым. Сине көттем-көттем дә, эзләп киттем… Ник килмәдең, Таһир, ник?..

Зөһрәнең күзләре яшь белән мөлдерәмә тулы иде. Ул менә-менә елап җибәрер дә бөтен дөньяны аһ-зарга тутырыр кебек…

— Зөһрә, мин берни дә аңламыйм… Менә килдем бит…

— Бер елдан соңмы? Мин бит сине икенче көнне үк көттем. Өченче көндә дә, дүртенче, бишенче, унынчы көннәрдә дә көтә идем әле. Ярты ел көттем! Ун ай көттем! Көн саен, сәгать саен көттем… Ошадың син миңа ул вакытта, Таһир… Әкияттән чыккан бер серле зат кебек килеп чыктың да, гипнозлап, үзеңә гашыйк итеп китеп бардың… Их, Таһир!..

— Зөһрә, менә бит мин, менә! Ник елыйсың? Кичер мине, зинһар, кичер… Әнкәй хакына кичер, киләчәгебез, бәхетебез хакына кичер... Зөһрә!

— Кичерер идем дә… Без бүген, экзаменнар алдыннан, загска гариза биреп чыктык. Аңлыйсыңмы шуны, юкмы? Без… өйләнешәбез, Таһир…

— Сез? Син? Шушы Таһир беләнме?

— Әйе, шушы Таһир белән. Үзем тәкъдим ясадым…

— Зөһрә, бу… Бу минем төшемме? Чемет әле, ә?

— Өн бу, Таһир, өн! Ник тагын кузгаттың йөрәгемне, ник борчыдың күңелемне? Ник килдең?

— Белмим… Мәхәббәтем алып килде… Мин бит сине бик сагындым!

Зөһрә дәшмәде. Ул, бөтен җан-рухы белән басылып, тын гына елый иде. Таһир аның иелгән башын күкрәгенә алырга, назлап, иркәләп сыйпарга, сөяргә теләде… Юатмакчы булды. Ләкин урыныннан кузгала алмады, каккан казык кебек басып торуында булды…

— Туегыз кайсы көнне?

— Бер айдан…

— Зөһрә, мөмкинме, мин сиңа хат язам… Туегызга кадәр язам, һәр көнне язам. Минем сиңа әйтер сүзләрем күп җыелды. Мин аларны үзем белән алып китә алмыйм, алар мине синнән җибәрмәячәкләр…

— Яз, Таһир, яз… Хат кына язарга ярый…

…Таһир утыз көнгә утыз хат язды. Утызынчы хатны почта тартмасына төшергәч, өенә кайтып әйберләрен җыештырды да, әнкәсеннән бәхиллек алып, күзе кая караса, шул якка чыгып китте…

**3**

Таһир Зөһрәсен әнә шулай югалтты. Ә югалтмыйча табып булмый. Аның гомер күгендә кояш сүнгәндәй булды. Күңелендә туктаусыз чыңлап торган моңлы да, дәртле дә көй ишетелмәс булды. Яшәвенең мәгънәсен, тормышының гамен югалта язды. Әмма тиз генә бирешергә дә теләмәде. «Җилгә йөзеңне куй, — ди иде аңа күршедәге Шакир карт. — Аркаңны куйсаң, йөзең белән егылуың бар». Таһир да, җилгә йөзен куеп, язмышына каршы китте. Ләкин каршыга искән җил-давыллар көчлерәк булып чыкты, ул иң элек башын иде, билен бөкте, аннары тезенә төште, соңыннан бөтенләй биреште, тормышның иң иләмсез һәм мәнсез төбенә сузылып ятты…

…Ташландык йортның ташландык бүлмәсендә кергә каткан сәләмәләргә төренеп яткан Таһир үткәндәге тормышы хакында уйланды. Үткәндәгеләрне исенә төшерергә яратмый ул. Әмма бүген хәтерен күңеленә якынрак җибәрде. Шундый тойгы, шундый хис — бүген нәрсәдер булыр кебек… Йөрәге сизенә, рухы тынычсызлана — нидер булыр кебек… Шуңа да Зөһрә исенә төште, әнкәсе күз

алдына килде. Шушы ике образдан башка берни дә юк аның теткәләнеп, җәрәхәтләнеп беткән үксез күңелендә.

Нидер булыр кебек… Ни булыр? Нәрсә булыр соң?

Йортның бүлмәләренә таралган сукбайлар торып чыга башладылар. Көннәр көзгә авышып килә. Төннәр суынды. Өшеп, калтыранып йөргән Люмингә карап гайрәтең чигәр, билләһи. Үзе Уралдан, ә үзе аз гына суыкка да чыдамый, зәңгәрләнеп-күгәреп чыга…

Учак исе, шулпа исе таралды. Димәк, Сало торган, ашау ягын кайгыртырга керешкән. Таһир да торды. Уң як янбашы һаман сызлый, иртән торганда бигрәк кыен — хәрәкәтләндереп, язып җибәрмәсәң, көне буе гарип-гораба кебек йөриячәк ул…

«Гаилә» һәр көндәгечә Сало янына — мич торган зур бүлмәгә җыелды. Чүлмәк кенә юк. Ул «сход»ка киткән. Бүген анда бомжлар «патша»сы Барон сүтәр өчен йортлар бүлә. Некрасов, Мөштәри, Островский урамнарында йортлар бушаган. Чүлмәк, «гаилә»нең бөтен кассасын алып, шунда китте. Булган акча җитәрме, юкмы? Әле милициягә дә, ЖЭУга да, урам шпаналарына да түлисе бар.

Җәелеп китеп сөйләшмичә генә, каткан ипи телемнәрен җебетә-җебетә, шулпа чөмерделәр. Барысының да уенда — Чүлмәк. Кайчан кайтыр? Нинди хәбәр алып кайтыр? Сүтәргә йорт юнәтә алсалар, бер айга эш бар дигән сүз. Эш бар икән, акча бар. Тагын бер-ике атна урамда хәер эстәмичә, чүплектә казынмыйча тамак туйдырырга, яшәргә була.

Булган төпчекләрен барлап, тәмәке кабызырга да өлгермәделәр, Чүлмәк кайтып керде. Кайтып керде дә, табактагы ашны бер олы тәлинкәгә аударып, кашыксыз-нисез генә чөмерә дә башлады. Эше барып чыккан, ахры. Кәефе ярыйсы күренә. Алайса, нигә дәшми соң ул? Ник суза?

Менә ул ашын эчеп бетерде, тәлинкәсенең читләрен ялап куйды, җиңе белән авыз читләрен сөртте, аннары гына, бәхет кошы тоткан кеше кебек, йөзендәге бөтен җыерчыклары белән елмаеп җибәрде. Шундук ике як кесәсеннән ике шешә аракы тартып чыгарды.

— Булды, егетләр! Мөштәри — безнеке! Базар минеке булды. Менә савыт-сабага да калды әле…

— Чынмы, Чүлмәк?

— Неужели?

— Круто!

Һәрвакыттагыча артыгын сөйләшми торган Бөке тыныч кына әйтеп куйды:

— Кеше эшне түгел, эш кешене таба…

Барсы да дәррәү шул якка борылдылар. Күлмәк җиңенә ямау салып утырган Бөке бу сүзләре белән нәрсә әйтергә теләде соң? Нәрсә әйтергә теләсә дә барыбер түгелмени? Иң мөһиме, аларның эшләре бар! Бүген аларга бәхет елмайды! Ә бәхет, мәгълүм булганча, өмет булып килә…

Шешәләрне дә бушатып алгач, йортка тәмам җан керде. Сало үзенең яшьлектәге мәхәббәт маҗараларын сөйли башлады. Люмин белән Кирпеч кәрт сугарга керештеләр, Бөке кичә җыйган шешәләрен юарга тотынды, Таһир балта, кораллар тутырылган иске шкафка барып ябышты. Ашаганнан соң алар шулай «ял итәләр». Ашыгасы юк. Калдык-постык ризык белән корсакларын тутырып куялар да, аракы кабып, тәмәке суырып, иңке-миңке бер халәттә яшәп алалар…

Һәрвакыттагыча бүген дә аларны Бөкенең акыллы, әмма бик үк аңлашылып бетми торган сүзе сискәндереп, айнытып җибәрде.

— Дөньяның гына түгел, һәр кешенең дә кыйбласы була. Кузгалыйк…

Кем «бисмилла»сын укып, кем «урам теле» белән теләкләрен теләп, дәррәү юлга кузгалдылар. Таһирның күп мәртәбәләр уйланганы бар: шушы сәләмә, иләмсез, бәхетсез кешеләр дә үз иманнарын югалтмыйча яшәргә тырышалар бит. Паспортлары юк, әмма күңелләре сау. Үзенчә ярата да аларны Таһир. Кешелекле, ярдәмчел булганнары өчен үз итә. Кеше булу өчен кеше булу гына җитми, әлбәттә. Ләкин кеше булу өчен иң элек кеше булу кирәк. Бөтен башка сыйфатлары булып та кешелеген, иманын саткан җаннар күпме йөри бу гөнаһлы җир өстендә?!

Әнә алар — әзмәвердәй алты ир, алты татар — таушалган, тузанга, корымга буялып, майланып каткан йөзләренә җитди кыяфәт чыгарып, ниндидер бер мөһим җаваплылык тоеп, эшкә баралар. Алар эшне сагынганнар, җаваплылык тойгысын, өмет хисен сагынганнар. Тормышларының кайсыдыр бер борылышында вакыт арбасыннан төшеп калган бу адәми затлар, Хода бәндәләре, кайсыдыр бер мизгелдә йомшаклык күрсәткәннәр, сынатканнар, рухларын какшатканнар, тормышның иң караңгы почмагына тәгәрәгәннәр. Ләкин кешелек сыйфатларын югалтмаганнар!

Андыйлар да бар бомжлар арасында. Ләкин алар — ялгыз «бүреләр». Яисә «төлкеләр», «куяннар», «күселәр»… Әмма алар — ялгызлар! Читкә тибелгәннәр, каргалганнар! Ул бичлар хәленә төшәргә Ходай язмасын! Таһирның да, менә бу кешеләрнең дә чүплектән ашаганы юк әле. Ачлык бугазларыннан алса, урлап ашадылар, әмма бервакытта да түбәнлеккә төшмәделәр…

Мөштәри урамына барганда, Таһир шулар хакында уйлады. Әнә ул йорт. Ике катлы бина. Тәрәзәләре дә урынында. Ишекләре генә каерып ташланган… Аның Зөһрәсе дә шушы тирәләрдә яшәде.

Кайда, кайсы йортта яшәгәндер, Таһир төгәл генә хәтерләми инде. Әмма конверт тышына «Мөштәри урамы» дип акка кара белән язып куя иде.

Утыз хат язды ул Зөһрәсенә. Төгәл бер ай буе, көн саен бер хат язды. Аз да түгел, күп тә түгел — утыз хат! Кайда, нинди чүплектә, кайсы караңгы чоланда яисә чормада ята икән ул хатлар? Әллә учакта көл булып очтылармы? Юк, утка атмас аларны Зөһрә. Ул да ярата иде бит Таһирны… Их!.. Менә шушы йортларның кайсынадыр почтальон көн саен хат китергән… Зөһрә көн саен аларны йөгереп чыгып алган, укыган… Кайда икән ул хатлар, ә, кайда икән?

Шул вакыт янәшәдә барган Бөке, Таһирның уйларын укыган кебек, авыз эченнән генә мыгырданып әйтеп куйды:

— Бөтен нәрсә дә хакыйкатьтән килә һәм хакыйкатькә китә…

Таһирның йөрәге жу итеп алды, җаны бәрелә-сугыла әллә кая аска — күңеленең иң тирән чоңгылларына төшеп китте. Күңел йөзлегендә бер генә уй торып калды: «Ә бит дөрес әйтә! Бер нәрсә дә юктан бар булмый, бер нәрсә дә юкка чыкмый! Бу бит… Бу… өмет һәрвакыт бар диган сүз! Хакыйкать өметнең яшәү рәвеше түгелмени?!»

Алты татардан торган «гаилә» язмышына төшкән йорт аларны бик моңсу каршы алды. Ә менә тәрәзәләре көлеп торалар! Үксез, бәхетсез кеше күңелендә калган өмет нурлары кебек!

Ишек төбендә туктап, бераз тын алдылар, тәмәке кабыздылар. Чүлмәк алдан кереп китте, Кирпеч йортның кирпеч стеналарын җентекләп карый башлады. Сало, куенынннан таушалып беткән блокнот чыгарып, нидер язарга кереште. Ул шулай һәр сүтелгән йорт хакында мәгълүмат туплап бара. Нәрсәгә кирәктер бу — беркем дә белми. Үзе дә белми, ахры. Бервакыт Таһир сораша башлаган иде, кулбашын гына сикертеп куйды. Люмин дә тик тормый, әнә өзгәләнеп беткән электр чыбыкларын күзли, койма тишекләренә ямау итеп салынган алюмин калайларны «өйрәнә»…

Ярты сәгать дигәндә ишектә кабат Чүлмәк күренде. Авызы — колагында! Нидер тапкан бу, билләһи! Бу кадәр дә түбәсе күккә тимәс иде.

— Ник елмаясың? Алтын таптыңмы әллә? Йә, күрсәт…

— Менә нәрсә таптым мин, егетләр, — Чүлмәк түш кесәсеннән көмеш беләзек тартып чыгарды. — Ачуланмагыз, көмеш кенә булды. Мең сум акча сыгып чыгарырга була моннан. Менә бу китек урынын күрмәсәләр…

— Каяле, кая… — Таһир, нидер сизенеп, Чүлмәк янына килде. Аның кайдадыр күргәне бар бугай мондый беләзекне. Тик кайда, кайчан? Әй, булмас ла… Беткәнмени беләзек тагып йөрүче кызлар?! Беткәнмени мондый беләзекләр!

Чүлмәк чыгуга, өйгә каударланып, хәтта бәреп диярлек барып керделәр. Керделәр дә җан-фәрманга эшкә тотындылар. Кирпеч подвалга төшеп китте, Сало ишек-тәрәзәләрне сүтә башлады, Бөке калдык-постык йорт җиһазларын, табак-савытны, төрле җирдә чәчелеп яткан шешә-банкаларны барларга кереште. Люмин тимер-томыр җыярга тотынды. Чүлмәк кенә бер читтә теге табылдык беләзекне әйләндергәләп утыра. Менә ул аны түш кесәсенә ипләп кенә салып куйды да бүлмәләр буенча йөреп китте. Читтән карап торган кеше аны тиле бер бәндә дип уйлар иде, мөгаен. Уйларсың да шул. Әнә бит — бер-ике адым атлый да туктап тыңлап тора, бер-ике атлый да, туктап тыңлый… Нәрсә тыңлый ул? Алтын-көмеш чыңы ишетеләме аның колагына, әллә акча исен сизенәме ул? «Ниндидер мистика бу, чын түгелдер»,— дип уйлап куйды Таһир.

Таһир үзе дә бу вакытта бөтен өй эченә чәчелеп яткан кәгазь әйберләрне өйрәнә иде. Өйрәнә дию дөресрәк булыр, чөнки ул кулына алган һәр кәгазь кисәген җентекләп карый, тикшерә һәм үзенә тиешле өемгә куеп бара. Шулай итеп, газеталар өеме, журналлар, китаплар өеме, мәктәп тормышы белән бәйле язмалар, ниндидер өй документлары, иске страховкалар, рецептлар һәм… телефон кенәгәләре…

Соңгылары үзе бер өем. Укытучылар яшәгән булырга тиеш монда. Шулкадәр күп кәгазь укытучы өендә генә була. Әнә мәктәп белән бәйле язмалар да бихисап. Табигать, хайваннар, үсемлекләр хакында белешмәләр, рәсемнәр, схема-таблицалар… Биология укыткандыр бу йортның хуҗасы. Хатын-кыз затыннан булуы да бик мөмкин. Әнә ничек матур, тигез итеп яза ул. Әйбәт холыклы, итагатьле, игелекле булырга тиеш бу укытучы ханым. Язуы, почеркы буенча кешенең холкын, әхлагын, хәтта язмышын ачыкларга була, ди бит. Бу кеше бик ипле, җайлы һәм бәхетле кешедер. Димәк, укучылары да бәхетле булгандыр аның…

Зөһрә дә укытучы булырга укый иде. Ул да биология укытырга тиеш иде! Туры килүен әйт инде, ә! Юк, туры килеп бетми. Аның Зөһрәсе кияүгә чыкты, гаилә корды. Хәзер балалары да үсеп беткәндер…

Ә монда… Бала-чаганың эзе дә, әсәре дә юк. Хет бер бала рәсеме чыксын! Балалы йортта, бала искеләре белән бергә, бала рәсемнәре, альбомнар, төсле журналлар, тышы купкан, сызылып, ертылып, чәйнәлеп беткән китаплар чыга. Ә монда берни дә юк. Дәреслекләр, дневниклар, гербарийлар

юк та юк инде. Барысы да ап-ачык: бу йортта, нәкъ менә шушы фатирда, япа-ялгыз биология укытучысы яшәгән.

Ник бер хат табылсын! Таһир хәтта аптырый башлады: хет бер хат кисәге яисә конверт калдыгы чыгарга тиеш бит инде! Әллә болар беркем белән дә хат алышмаганнармы? Аралашмаганнармы? Кешеләрдән, дөньядан ваз кичеп яшәгәннәрме? Дуслары, туганнары, сөйгәннәре юкмы аларның? Балалары юк та юк инде. Ләкин бит һәр кешенең ата-анасы, туган-тумачасы була! Кемнәр яшәгән монда? Нинди гаилә яшәгән?

Таһир үзе кәгазьләр актара, үзе эченнән генә кемнедер битәрли, хәтта аңа үпкәләмәкче була, шулай үзенең кеше булуын, дөресрәге, һаман да әле кеше булып калуын расларга тырыша. Хәтта… үзенең кызганыч һәм бәхетсез тормышын онытып, башкаларны яшәргә өйрәтмәкче була…

Бәй, хат язмыйча яшәү мөмкинме соң? Хат бит ул — җаннарның бер-берсе белән сөйләшүе, аралашуы, җырдагыча:

Минем сиңа язган хатларымны
Җаннар йөри канат иттереп…

Теге вакытта, Казаннан Түбән Камага кайтып төшкәч, Таһир да җан сызлавын җиңеләйтүнең бердәнбер чарасын тапты — Зөһрәгә хатлар яза башлады. Беренче хатын газаплы кичерешләр белән, күңелендәге хисләрнең ташып-түгелеп китүен чак-чак тыеп торып, әмма кешелеген, ир-егетлеген югалтмаска тырышып язды. Ул гүя Казанга үзенең җанын очырып җибәрде.

*«Зөһрәм, кадерлем!*

*Бу хатым белән мин синең күңелеңне яуларга да, нәрсәгәдер ышандырырга да, үгетләргә дә, бәхетеңне чикләргә дә теләмим. Соң икәнен беләм. Тагын шуны беләм: мин шушы ай эчендә күп нәрсәгә төшенергә, бөтен үткәнемне, киләчәгемне, язмышымны моңлы-сагышлы йөрәгем аша үткәрергә тиеш. Бу хатлар күбрәк минем үзем өчен кирәк, ә син… Син сабыр гына тыңла. Ләкин көлмә дә, кызганма да… Кайчан да булса берәр вакыт, бәхетле минутларыңның берсендә, кинәт мине исеңә төшерерсең дә моңсу гына елмаеп куярсың. Мин шуңа да риза.*

*Мин сине табарга да өлгермичә югалттым. Тапмыйча гына югалткан да кадерле, газиз була икән! Мин кемне югалтканымны хәзер генә аңладым. Аңламадым да, аңларга тырышам гына. Бу югалту белән йөрәгемә гомерлек авырту алдым, борчу алдым, анысын төгәл беләм.*

*Гомер — ярату өчен бирелгән вакыт. Ә бит мин гомеремне яши генә башлаган идем. Яратуның ни икәнен дә ныклап белми калдым. Гашыйк булып, шул серле-илаһи хис шаукымында яшәгән гомер кисәгеннән башка бернәрсәм дә юк хәзер минем…»*

Шулай башланып китә Таһирның беренче хаты. Аһлы-зарлы иде бу хат. Хәзер килеп ояла анда язганнары өчен. Һәм аңлый: ул вакытта ниндидер өмет булган әле, шушы хатымны укыр да, күңелемдә сызылып яткан хисләремне йөрәгенә алып, миңа булган мәхәббәтен яңартыр, кабат үзенә чакырыр, дип уйлаган.

Икенче, өченче, дүртенче хатларда да өмет, ышаныч булган әле. Аннары инде бу өмет, ышаныч сүнә-сүрелә башлаган, ниндидер бер билгесез, моңа кадәр кешелеккә таныш булмаган хис булып кына калган…

*«Зөһрә, кадерлем!* — дип язды ул бер хатында. — *Мин сине бары тик бер мәртәбә күреп калдым, синең белән бер мәртәбә биеп калдым. Ләкин гомер буе синең белән яшәп аерылышкан кебек аерылыштым. Үз язмышыңа, үз бәхетеңә тигән кеше белән аерылышканда шулай буладыр ул. Яшәүнең мәгънәсе булса, син минем өчен шул яшәү мәгънәсе, сөйгән ярның минем өчен яратылганы, хәләл җанның язмышыма язганы идең…»*

Тагын бер хат исендә. Анда инде күңеле утырган, хисләре тынычланган.

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Син миннән көн саен, хат саен ераклаша барасың. Син ераклашкан саен, язмышым да ерагая, тоныклана. Мин инде аны күрмим, тоймыйм… Шулай да яшәргә кирәк, бәхетле булам дип түгел, бәхетсез булмыйм дип яшәргә кирәк…»*

**4**

Беренче каттагы кәгазьләрне, китап-журналларны җыеп бетереп, түр почмакка туплап-өеп куйганын гына күтәп торган кебек, Таһирны өске катка дәштеләр:

— Әй, Почта! Монда синең өчен хатлар бар! Гони сюда!

Кайчандыр Зөһрәсенә язган хатларны күңеленнән кабат кичереп утыручы Таһир бу хәбәргә сискәнеп китте, хәтта бер мәлгә каушап калды. Теге тавыш янә кабатланды:

— Дөмектеңме әллә, Почта? Тебе же говорят!

Бу юлы Таһирның зиһене тиз эшләде. Ул, җавап биреп тә тормастан, биек баскычларны бер-ике генә сикереп, өске катка атылып менде. Аның каршысында, пөхтә итеп бәйләнгән хатлар төргәге тотып, Чүлмәк басып тора иде.

— Мә, әзи, ал. Болар — синең өлеш…

— Хәзер карыйбыз, нинди хәзинә таптың икән бу юлы…

— Иң кыйммәтле хәзинәләрдән кыйммәтлерәктер шул бу хатлар. Кеше язмышлары бардыр монда, ей-богу! Әнә күпме душу мотали!

— Рәхмәт, Чүлмәк… Миңа бу шактыйга җитә әле. Рәхмәт…

— Да я знаю… И завидую…

Шунда нидер эшләп булашкан Бөке, гадәттәгечә, беркемгә дә аңлашылмаган телдә «бака боты» кыстырып куйды:

— Яр сөйгәннәр күп, җан сөйгәннәр аз…

Шуның белән сүз дә бетте. Чүлмәк чормага менеп китте, Таһир, кабат аска төшеп, бер буш бүлмәгә кереп «яшеренде».

Шундук ябырылып укый башламады әле ул бу табылдык хатларны. Гадәтенчә, иң элек, уйларга бирелеп, хат ияләрен күз алдына китерергә тырышты.

Кеме бар икән соң бу биология укытучысының? Кеме булган? Булган да онытылганмы? Онытылмаса, бу хатлар чүп-чар эчендә ятмаслар иде…

Менә бит ул ничек! Кемдер кемгәдер үзенең иң матур, иң ихлас, иң газиз хисләрен багышлый, бу хисләрне бөртекләп түгә-түгә, күңелен, җанын ача, язмышын баглый, ә шул… «кемгәдер» бу «кемдер»не уена кертеп тә чыгармый… Ә бит иң бәхетле кеше — кеше хәтерендә калган кеше. Онытылган, һай онытылган бу хатларны язган кеше! Үзе бу хакта белсә, үзәкләре өзгәләнер иде мескенкәйнең…

Туктале-туктале… Нигә алай уйлый соң әле ул? Ә бәлки, бу хатларны язган бәндә өй хуҗасының тырнак очына да тормыйдыр? Юк, барыбер, кем генә язса да, хатнамәләрне кеше типкесенә калдырырга ярамый. Яндыр син аны, көл итеп галәмгә очыр, тик кеше йөри торган сукмакка ташлама!

Хат һәрвакыт ике канатлы бит ул. Хат язган кеше бар, хат алган кеше бар. Димәк, бу күңел елъязмасында шушы йортта гомер кичергән биология укытучысының да язмыш гаме бар. Ул да кайчандыр ике канатлы, бәхетле булгандыр?.. Шулай булып чыга. Шуңа күрә аның бу гамәлен берничек тә акларга ярамый…

Таһир, тынгысыз, борчулы уйларын төйнәп куеп, кулындагы төргәкне сүтәргә керешә. Вакыт кояшы астында уңа башлаган зәңгәр тасма идәнгә шуып төшеп китүгә, ничә еллар буе интегеп, кысылып яткан хатлар, канатларын җәеп, Таһирның алдын тутырып ташладылар. Иң өстә яткан, күп укылудан читләре, почмаклары таушалып беткән беренче конвертның язуы, укысаң-укымасаң да, үзе күзгә кереп тора иде: *«Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 18 нче йорт, Фәйзуллина Зөһрәгә…»*

Менә сиңа мә! Монда да Зөһрә исемле кеше яшәгән икән… Анысы да Фәйзуллина… Әллә? Юктыр… Таһирның Зөһрәсе әллә кайчан кияүдә бит, бүтән Таһирда тормышта…

Таһирның күңеленә, күңел ярларында гына туктап калмыйча, җанына ук серле дә, шомлы да, әмма үтә дә ымсындыргыч җылы дулкын йөгерде. Ул һич кичекмәстән хатларның каян килүен, аларның иясен ачыкларга тиеш иде. Шул… Шул? Шул! Шул таныш адрес: *«Түбән Кама, Химиклар проспекты, 15 нче йорт, Сәлмәнов Таһирдан…»*

Нәрсә бу? Нинди әкият? Нинди сихер, ырым?

Нинди әкият, ырым булсын?! Әнә бит аның язуы, аның кулы! Ничек башта ук искәрмәгән ул моны?.. Шулай да ниндидер сер бар монда, ниндидер шаукым бар… Әллә… Әллә язмыш аның үксез, ятим җаны белән тагын бер мәртәбә шаярырга уйлыймы? Сынарга яисә сындырырга телиме аны?

Ничек кенә булмасын, хакыйкатьтән чыгарма юк. Бөке шулай ди. Таһир да бу чынлыкны, бу хакыйкатьне нык күңел, олы йөрәк белән кабул итәргә тиеш.

Күтелмәгән хәлдән исәнгери башлаган зиһене, ниһаять, кабат үз урынына утырып, аны аек акыллы булырга, аһ-зардан өстен булырга чакырды…

Таһир, бу табылдык хатлар төргәге белән бергә кулына, кулына гына түгел, тормышына килеп кергән олы серне тизрәк ачыкларга теләгәндәй, дулкынланудан каушап-каударланып, алдында яткан беренче хатны ачып укый башлады.

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Бу хатым белән мин синең күңелеңне яуларга да, нәрсәгәдер ышандырырга да, үгетләргә дә, бәхетеңне чикләргә дә теләмим. Соң икәнен беләм. Тагын шуны беләм: мин шушы ай эчендә күп нәрсәгә төшенергә, бөтен үткәнемне, киләчәгемне, язмышымны моңлы-сагышлы йөрәгем аша үткәрергә тиеш…»*

Ниһаять, Таһир ышанып бетте. Шулкадәр таныш иде аңа бу юллар. Ул кәгазьгә төшеп калган бу хис-тойгыларны үз күңелендә җиде ел буе түкми-чәчми саклап яшәде. Ә Зөһрә аларны ташлап калдырган… Бу хатлар аның күңелен кузгата алмады микәнни? Нишләп кузгатсын, ул бит тормышта, кешедә, бүтән дөньяда…

Таһир, күңелен талкыган сорауларга җавап эзләгәндәй, ашыга-кабалана кулына эләккән хатлардан күзгә керерлек, күзләр аша җанга төшәрлек сүзләр барлады: *«Мин сине табарга да өлгермичә югалттым…»* Менә тагын: *«Гомер — ярату өчен бирелгән вакыт…»*

Тукта! Нигә болай кабалана соң әле ул? Кем куа аны? Кая куа? Тормыш арбасы аның язмыш тукталышын күптән узып киткән инде. Утыр да рәхәтләнеп укы үзеңнең күңел догаларыңны, сөю догаларыңны…

Таһир шулай итте дә. Әмма ул бу юлы хатлардагы хисләр ташкынын күңеленә бик якын җибәрмәде, үзен чит-ят кеше хатларын укыгандагы кебек хис итәргә тырышты.

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Мин Сиңа тиңләр өчен сүзләр күп эзләдем. Хатымны «кадерлем» дип башласам да, бу сүз генә Сиңа булган ихлас мөнәсәбәтемне белдереп җиткерә алмый. «Сөйгәнем», «сөйгән ярым» сүзләренә дә тормышның бөтен матурлыгы, күңелемнең бөтен төсмерләре сыеп бетмәгән әле. Тормыш бит сөюдән генә тормый, көю дә җитәрлек анда. «Җанкисәгем» сүзе дә ошап бетми. Чөнки Син җанымның бер кисәге генә түгел, Син шул җанымның үзе инде! «Алмам», «җимешем» сүзләрендә төчелек, ясалмалылык бар. «Кошчыгым», «сандугачым», «былбылым» сүзләрен әйтергә куркам, кошка тиңләп әйтсәм, очарсың да китәрсең кебек… «Күбәләгем» димим, чөнки аның гомере бик кыска… «Чәчәгем», «гөлем» дияр идем, үзем дә гөлләр яратам, ләкин аларның гомере дә бер җәйлек кенә шул…*

*Мин Сиңа «язмышым» дип дәшәм.*

*Минеке булсаң-булмасаң да, Син инде минем язмышымда, юк-юк, Син — минем Язмышым!»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Сагыш та таң кебек икән — башы бар, ахыры юк. Тик аерма шунда — таң ата, көн туа, ә менә миндәге сагыш күбрәк шәфәкъны хәтерләтә, минем кояшым — кара, көнем — караңгы… Ләкин һәр караңгылык артында ниндидер яктылык була. Якты Кояш була. Кояшы булмаса, Ае була… Минем Кояшым сүнгән, Аем әле калыкмаган…»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Мин үземне бәхетсез дигән булам. Ә мин барыбер бәхетле кеше. Ни өченме? Син мине онытмаячаксың, шулай бит? Онытма мине. Бәхетнең дә төрлесе була. Кеше хәтерендә калган кеше бәхетле түгелмени? Мине бәхетле итәсең килсә, онытма!..»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Бүген шул хакта уйладым әле: нинди төстә иде соң Синең күзләрең? Күк төсендәме? Шомырт кебек карамы? Өрәңге яфрагы төсле көрәнме? Әллә тагын башка берәр төстәме? Белмим… Онытканмын… Ул вакытта мин күбрәк Синең күңелеңә, җаныңа карап калырга тырыштым шул. Шуңа күрә дә күзләреңнең төсен хәтерләмим, ә менә ачык, нурлы, мөлаем, мәхәббәтле карашыңны мәңгегә ятлап калдым. Күзләреңдәге бу сихри балкышта дөньяның чагылышын тоеп калгандай булдым. Ә дөньяда - бәхетле минутлар да, сагыш, аһ-зар да, өметле, хыялый минутлар да, күңел төшенкелектә яшәгән чаклар да җитәрлек…*

*Мин тагын… Синең күзләреңнең төсен оныттым дигән булам. Баксаң, алар тормыш төсендә, мәхәббәт төсендә булган икән…»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Бүген күңелемдә бер якты хис тә юк. Шуңа күрә, үземне үртәп, синең бәхетле җаныңны үртәп, берни дә язмыйм. Күңел халәтемә туры килә торган бер шигырь күчерәм дә, шуннан барысын да аңларсың…*

*Күзләремә дөнья сыйган,*
*Күңелемдә — иман.*
*Тик шулай да синең күзгә*
*Карарга кыймам.*

*Көндез якты кояшым син,*
*Төннәрен — аем.*
*Сиңа багып, таңда торам,*
*Кичләрен байыйм…*

*Кояшка карап булмавын*
*Беләм, бик беләм.*
*Иман тәкъдирне чакыра,*
*Тын гына үләм…*

*Мең үлеп һәм мең терелеп*

*Яши йөрәгем.*
*Иманым белән сөюем —*
*Күңел терәгем!..»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Соңгы вакытларда күңел, иман, илаһият хакында уйланам. Күк, оҗмах, тәмуг, Ходай Тәгалә ихтыяры, аның мәрхәмәте, Тәкъдир көче, Язмышның язганы хакында уйланырга кирәк икән ул. Бу арада мин дә уйларымны, зиһенемне, күңелемне тәртипкә китердем. Үз-үземә күп нәрсә ачыкларга өлгердем. Хәтта бер ныклы фикергә килдем: Үзе күктә яшәсә дә, Аллаһы Тәгаләнең көче җирдә...»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Бүген бик кызык төш күрдем. Мин дөньяга Синең күзләрең аша карап йөрдем. Бу дөньяның нинди матур, күркәм булуына сокланып, шаккатып йөрдем. Моңа кадәр ничек күрмәгәнмен бу матурлыкны?! Ничек тоймаганмын аны?! Беләсеңме, синең күзләрдә күк аязрак, кояш яктырак, урман-кырлар җетерәк, алардагы кошлар моңлырак, агымсулар тәэсирлерәк... Иң мөһиме, кешеләр әйбәтрәк, миһербанлырак, рәхимлерәк, аларның йөзләре яктырак, күңелләре изгерәк, хыяллары өметлерәк...*

*Шуны аңладым: мәхәббәт ул — дөньяга икенче кеше күзләре белән карау икән...»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Сине азга гына булса да онытырга, авыр сагыштан котылырга теләп, бөтен көнемне эш белән, мәшәкать белән шыплап тутырырга тырышып яшим. Сиңа булган мәхәббәтемне кеше күзенә күрсәтәсем килми. Сөюемне дә, сагышымны да беркем белән дә уртаклашасым килми. Син — минеке генә. Мин синеке түгел, әмма син — минеке! Син моның белән берни дә эшли алмыйсың, белеп тор. Мин сине үземнең хәтер чоңгылларыма алып кереп адаштырдым, күңелемнең иң ерак почмакларында югалтып калдырдым... Бу хакта якыннарымнан, дусларымнан беркем дә белми. Белмәсен дә! Чөнки чын мәхәббәт кеше күңеленнән читтә яши...»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Моңа кадәр дусларым, остазларым хакында Сиңа бер авыз сүз дә язганым булмады. Мин мондагы бер остаханәдә хезмәт итәм. Училище буенча укытучым Хәсәнша ага кул астында эшлим. Бик әйбәт кеше ул. Изге җан иясе. Шушы карт мине рәсем ясарга өйрәтте. Портрет, сурәт төшерергә өйрәтте. Беләсеңме сурәттә иң мөһиме нәрсә? Күзләр! Менә шул күзләргә җан өрергә өйрәтте Хәсәнша ага.*

*Ачуланма, бу хатымда бүгенге халәтем, күңел хисләрем хакында язмадым. Әгәр язган булсам, ул хаттагы һәр сүз бертөрле генә яңгырар иде: сагынам, сагынам, сагынам, сагынам, сагынам...»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Мин кулыма тагын кәгазь һәм карандаш алдым. Сурәтеңне төшерәм. Мин бит кайчандыр бик күп ясый идем, хәтта яшь рәссамнар күргәзмәсендә дә катнашканым булды.*

*Кулым каләм-карандашны сагынган. Ә күзләрем синең гүзәл образыңны өзелеп сагынган... Тагы ни кирәк? Менә дигән портрет килеп чыкты. Әмма... барыбер үзең түгел инде. Син бит үз сурәтеңнең иң уңышлы, иң талантлы варианты!..»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Мин һаман үз-үземне тиргим. «Соңгы очрашуда нигә ышандыра алмадың? Ышандырырлык сүзләр уйлап тапмадың... Шундук бирештең, сындың, сыгылдың, хәтта җебеп төштең, — дип битәрлим. — Яратмаса соң, яратырга да өйрәнергә мөмкин бит. Өйрәнер иде әле, Сиңа бераз сабыр, түзем, чыдам гына булырга кирәк иде. Һәм... аның үзен дә өзелеп-өзелеп яратырга кирәк иде... Их, син, пешмәгән!..» — дим».*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Бүген күңелем белән Синең янда булып кайттым. Имеш, Син якын дусларыңны туган көн мәҗлесенә җыйгансың... Һәркем тост әйтә, матур теләкләр тели, котлый, бүләкләр бирә... Миңа да чират җитте. Ләкин ни бу? Әйтергә дип әзерләгән бөтен матур сүзләремне онытттым да куйдым. Торам шунда бүкән кебек. Син дә үзеңнең матур күзләреңне мөлдерәмә тутырып карап торасың, җитмәсә... Шунда бер могҗиза булды — Ходай Тәгалә колагыма бер матур теләк пышылдады. Мин ул илаһи теләкне шундук Сиңа җиткердем: «Зөһрә, кадерлем! Гомерең бәхетле, бәхетең гомерле булсын!» — дидем.*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Әнкәй минем янга кунакка килде. Аның белән рәхәт. Мин торган фатир хуҗасы Мөршидә әби дә аны шундук үз итте. Чөкердәшеп яшиләр. Бергә намазга басалар, бергә авыз ачалар, кибеткә йөриләр...*

*Әнкәй бит ул — күңелемдәге борчуларны шундук сизде. «Нәрсә булды? — ди. — Күзләреңдә сагыш бар, моң бар, кем рәнҗетте?» — ди. Нәрсә диим инде. Шаярган булып, елмаеп-көлеп, сүзне икенче якка борып җибәрдем.*

*Әнкәйнең шул соравына да күңелем була тагын. Ул үзе дә җавап өчен сорамый кебек. Хәлен, сагышын, кайгысын җиңеләйтим дип сорый бугай...»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Әнкәй Синең сурәтеңне табып алган. Юк, мин аны яшермәдем дә. Шүрлектәге китаплар арасына гына кыстырып куйган идем. Әнкәй озак кына шул сурәтеңә карап торды да: «Чибәр бала. Самими җан. Акыллы. Тәүфыйклы. Тик ул синеке түгел»,— диде. Каян белгән ул? Мин бит Синең хакта аңа берни дә әйтмәдем. Күрәсең, бу сурәткә мин үземнең иң ихлас хисләремне, бетмәс-төкәнмәс сагышымны, күңел тетрәнүләрен төшергәнмендер... Шулайдыр...*

*Дәшмәдем. Сүземне йотып, хисемне тыеп калдым. Ә әйтәсем бик тә килгән иде. «Мин аны сөям, яратам. Ул минем язмышым, киләчәгем, бәхетем...» — диясем килде. Дәшмәдем. «Яратам» дигәч, «ә ул мине яратмый» диярга тиеш идем шул мин. «Син каты авырып егылгач, яныңа кайтып торганда, икенче бер Таһирга язмышын баглаган ул», — дип әйтә алмыйм бит инде...»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Мин шул хакта уйлыйм: мин Сине аз яратканмын. Бер кеше икенче кешене болай яратырга тиеш түгел. Берәүнең яратуы икенчесенә ап-ачык булып, аяз көндәй, киң офыктай аңлашылып торырга тиеш! Кояш кебек балкып янарга тиеш сөю! Аның моңы, көе, кош сайравы кебек, бөтен дөньяга ишетелеп торырга тиеш! Сөйгән яр, бу көйдән, бу моңнан үзенә аталган ноталарны шунда ук танып алып, үзенең күңел кылларында яңгырата башларга тиеш...*

*Сөюнең төне юк, көне генә бар! Сөюнең кышы да юк, язы гына бар! Мин моны белмәгәнмен... Мин, йөрәгем белән сөйсәм дә, бу сөюемне, сөю булып калыккан күңел кояшымны сиңа белдермичә, күрсәтмичә яшәгәнмен. Мин аз яратканмын. Күбрәк яраткан булсам, син барыбер бер тояр идең, сизәр идең һәм минеке булу өчен барысын да эшләр идең. Мин моңа ышанам».*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Соңгы вакытта мәхәббәт темасына язылган әсәрләр күп укыйм. Үземнең күңел тарихын, җан тарихын башкаларныкы белән чагыштырып карыйм. Гыйбрәт алам. Көнләшәм. Битәрлим. Сокланам. Үпкәлим. Яратам. Яратмыйм... Күп кенә «мәхәббәт геройлары»на нәфрәтләнәм дә! Нәфрәт — коллык хисе. Һәр нәфрәтләнү, һәр рәнҗү — кешене бераз үтерә. Әмма бу мине куркытмый. Яшь йөрәкләрне кыерсытып, тузгытып йөрүче шакшы җаннарга барыбер рәнҗим мин!*

*Әллә күпме мәхәббәт тарихлары белән танышып чыкканнан соң күңелемә бер тойгы кереп урнашты: күпчелек әсәрләрдә ничек яратырга кирәклеге турында язмыйлар, ничек яратмаска кирәклеге хакында язалар. Менә шул шул: минем тарихны да кемдер роман итеп язса, ул әсәр дә шушындый сафсата романнар рәтенә өстәлер иде...»*

*«Зөһрә, кадерлем!*

*Бүген инде мең енче тапкыр Сине күз алдына китерергә тырыштым. Син курчак кебек, коеп куйган чибәр зат түгел, Син — матур, күркәм, мөлаем кеше. Синең бөтен җиреңнән нур балкып тора. Син... Син фәрештә дә түгел. Синең җаның, күңелең генә фәрештәнеке. Чөнки Синең йөзең, күз карашларың моңсу. Фәрештәләр гел шат, гел бәхетле булырга тиештер ул. Ә Синдә сагыш бар...*

*Бүген мин Синең сурәтеңне өр-яңадан төшердем».*

...Айнып киткәндә Таһирның йөрәге тибүдән туктыйм-туктыйм дип тибә иде. Шулай булмый ни — кайсыдыр ташландык йорт идәнендә үзенең иң газиз, иң якты хисләрен кушып язган хатларны укып утыр, имеш! Таһир тоя, хәтта белә, әмма бу могҗизага һаман да ышанып җитә алмый...

Язмыш, бер шаярса, ахырына кадәр шаяра бит ул. Бу юлы да шулай булды.

Таһир, үз хатлары белән иләсләнеп, дөньясын онытып утыра иде, кайсыдыр бүлмәдән Сало шәрран ярды:

— Почта, ә, Почта?!

Таһир дәшмәде. Дәшәсе килмәде. Берәр вак-төяк хакында сорап аптыратадыр әле.

— Почта, син кайда? Әй, Почта!

— Нәрсә кирәк? — Таһир ялкау гына җавап бирде, әмма урыныннан кузгалмады.

— Почта, сиңа килгәннәр монда... Чык давай... Хатлар синдәме?

— Миндә...

Сулышы капланып, ашыгып килеп кергән Салоны күргәч, Таһир телдән кала язды.

— Ну... миндә... Шуннан ни булган?

— Шуннан шул, әнә хатлар артыннан килгәннәр.

Таһир идәндә чәчелеп яткан хатларны ашык-пошык кына җыештырды да, күкрәгенә кысып, Сало артыннан иярде. Ул берни дә аңлый алмады: кем килгән, ни өчен килгән, нигә килгән?

Йортның урталыктагы олы бүлмәсенә килеп кергән Таһир ниндидер таныш түгел хатын белән йөзгә-йөз очрашты. Туктале... Нишләп таныш булмасын... Таныш... Бик таныш... Таһирның күңеле гөлт итеп кабынып, балкып китте! Ул шунда ук барсын да аңлап, төшенеп алды. Әлеге балкышлы

җаны тетрәнеп куйды да, бөтен авырлыгы белән аһ итеп, табанына төшеп китте… Таһир шул мәлдә үлеп терелүен тойды. Һәм кайчандыр язмыш бүләк иткән олы серне югалтуын, аңа алмашка кечкенә өмет уты табуын аңлады…

Зөһрә бит бу! Зөһрәсе! Сөйгәне! Аның газизе, хәләле, бәгырь кисәге, җан иркәсе… Бәхете һәм бәхетсезлеге… Язмышы һәм… ялгышы. Үткәне һәм… киләчәге…

Таһир Зөһрәне күрүгә каушап төште, уңайсызланудан нишләргә дә белмәде, баскан урынында таптанып, ык-мык итеп тик торды. Бу кыен хәлдән аны идәнгә коела башлаган хатлар коткарды. Алар да кыенсыналар, оялалар иде, ахры. Әллә бу бәхетсез җаннардан тәмам өмет өзеп, берәр кая качарга, яшеренергә телиләр идеме?

Идәнгә чәчелгән хатларны җыяр өчен, икәүләп аска чүгәләделәр. Зәңгәрле-аклы конвертларны җыеп бетереп кабат Таһир кулына туплаганчы сөйләшмәделәр. Гүя бу хатлар инде Таһирныкы, ә Зөһрә аларны үзенә ниндидер тылсымлы, серле юллар белән сорап алырга тиеш.

Бәй, алар исәнләшмәгән дә бит әле!

— Исәнмесез!

— Исән… месез… Исәнмесез! — Бу бомж тормышы белән яшәп, Таһир кешечә исәнләшергә дә оныта язган ласа…

— Мин шушы йортның хуҗасы булам. Исемем — Зөһрә…

— Беләм… Беләм дип… Хуҗа икәнегезне аңладым димәкче идем.

— Ә сез кем?

— Минме? Мин — Почта… То есть… Таһир.

— Таһир? Таһир… Матур исем.

Зөһрә ниндидер күңел сагышы белән, тирән сулыш белән, әмма яратып әйтте бу сүзне. Ләкин ул бу минутта каршында басып торган бомж Таһир хакында түгел, бүтән Таһир хакында, үз Таһиры хакында уйлый иде.

Таһир шунда гына аңлап алды: Зөһрә аны танымады! Ул һаман әле үткәндәге тормышы, элеккеге Таһиры белән яши!

— Сезгә нәрсә кирәк? — Зөһрәнең танымаганын белгәч, Таһир кыюланып китте.

— Менә… шушы… хатлар кирәк иде.

— Шушы хатлармы? — Нигә кабатлап сораган буладыр — Таһир үзе дә аңламый. Берәр нәрсәгә өметләнәме? Нинди өмет инде монда? Тизрәк хатларны бирергә дә мәңгелеккә саубуллашырга кирәк! Бомж бит ул хәзер… Каян танысын… Йөз-бите генә түгел, күңеле, йөрәге дә гел җәрәхәттән, җөйдән тора… Корымга, тузанга батып беткән, сакал-мыек баскан бу чыраен әнисе булып әнисе дә танымас иде, билләһи! Адәм мәсхәрәсе!.. Аерылышканнарына җиде генә ел. Ә танымады… Танымады-ы-ы!..

— Әйе, шушы хатлар. Нәкъ утыз хат.

— Ә ни өчен утыз? — Таһирның зиһене белән күңеле икесе ике яссылыкта, ике төрле образга кереп яши башлаган иде. Акылы: «Җитте сиңа, тукта, нигә инде сиңа бу? Ник үзеңә авырту, гөнаһ аласың?» — ди, күңеле: «Сөйләш, сөйләш, сөйләшеп кал, бәлки, бу синең соңгы сөйләшүеңдер, сөйләш, үкенечле булмасын», — ди. Һәм ул сөйләшә: — Ни өчен егерме түгел яисә илле?

— Шулай булды инде. Утыз көнгә утыз хат. Айның һәр көнендә — бер хат.

— Бу хатлар Сезгә атап язылганмы?

— Миңа… Менә бит «Зөһрәгә» диган. Ә мин Зөһрә исемле. Әйттем бугай инде. Хатларны язган кеше дә Таһир исемле. Менә сезнең кебек…

— Кайда соң ул хәзер?

— Кем?

— Сезнең Таһир? Нигә кирәк булды бу хатлар? Алай килеп, эзләп йөрерлек булгач, нигә ташлап калдырдыгыз соң аларны?

Таһирның күңеле бу минутта, ярсу, дуамал ат кебек нык кына чыгымлый башлаган иде. Ул аңа: «Җитте, җитте, кая чабасың?» — дип карый. Юк, тыңламый күңел дигәннәре, әллә кайда югалып калган язмыш җебенең очын тотарга уйлый, ахры…

Зөһрә исә Таһирның сорауларына һич кенә дә аптырамый. Төгәл итеп, берәмтекләп җавап бирергә тырыша. Хәтта бу сөйләшү аңа ошый да. Күрәсең, ул күңелдәгесен бик күптәннән җыеп килгәндер, борчуларын беркемгә дә ача алмыйча яшәгәндер. Хәзер менә бик әйбәт җай чыккандыр…

— Таһирның кайда икәнен белмим. Җиде ел элек югалды ул. Бер күрүдә гашыйк итте үзенә. Ул да яратып калган кебек иде. Ләкин бер елга юкка чыкты да куйды. Мин, аның белән очрашуга өметемне өзеп, икенче Таһир белән таныштым. Бөтен университетка бер Таһир иде ул. Эзләп таптым, үземне үзем димләдем. Беренче Таһирым: «Зөһрәнең Таһиры булырга тиеш», — дип әйтә иде. Шуңа күрә дә шулай эшләдем.

— Бүтән бервакытта да очрашмадыгызмы? — Таһирның Зөһрә хакында күбрәк беләсе килә иде.

— Бер елдан очраштык, тик соң иде инде. Икенче Таһирым белән язылышырга вәгъдә бирешеп өлгергән идек. Яраткан Таһирым ялынмады, ялвармады, түбәнчелеккә төшмәде, мәхәббәтле, әмма бик тә сагышлы, моңсу күзләре белән карап торды-торды да кире Түбән Камага кайтып китте. Бик сәер аерылыштык без. Таһир, бер ай буе, без загска кергәнче, һәр көн саен хат язып торырга булды. Һәм үз сүзендә торды. Бу хатлар — әнә шул хатлар…

— Ник… Үзегез җавап язмадыгызмыни?

— Таһирның утызынчы хатын укыгач, язып җибәрдем. Фотомны да салдым. Кияүгә чыкмый калуымны, аны көтәчәгемне әйтеп яздым. Бүтән хат килмәде. Алса, килер иде, алмагандыр. Рәнҗегәндер дә, бәлки… Әллә нәрсәләр уйлап бетергәндер… — бераз уйланып торганнан соң, моңсу күзләрен күңел офыгына төбәп дәвам итте. — Эзләдем мин аны, үземнең Таһирымны… Бөтен җирдән белешеп чыктым, беркаян да юньле-өметле хәбәр ала алмадым. Әнкәсе үлгәнен белдем. Дусларыннан сораштым. Эзли торгач, паспортына, документларына юлыктым. Алар Вахитов районы милициясендә яталар. Ә Таһирым үзе юк та юк… Менә шундый аянычлы булды безнең мәхәббәтебез. Бер тапкыр күреп тә кешене мәңге йөрәктә саклап була икән…

Таһир нишләргә дә белмәде. Зөһрәне кысып кочып аласы килде. «Менә ул синең Таһирың! Мин ул, мин!» — дип, өзгәләнеп, сөйгәненең алдына тезләнәсе, аның аякларыннан кочасы, кулларыннан, йөзләреннән, күзләреннән үбәсе, колагына үрелеп, иң матур, иң җылы сүзләр пышылдыйсы килде. Булдыра алмады. Хәленнән килмәде. Аңа оят иде…

Ә Зөһрә сөйләде дә сөйләде. Бер бушана башлаган күңелен тәмам бушатып бетерергә тели иде бугай.

— Бу хатлар — шул Таһирымның истәлеге. Бердәнбер истәлеге… Иң газиз әйберем кебек кадерләп сакладым мин аларны, иң авыр көннәремдә шуларны укып юандым, көч алдым, рухымны, иманымны ныгыттым… Борчу-сагышларым гына түгел, куаныч-шатлыкларым да шушы хатлар булды…

— Әйтегез әле, Зөһрә, сез Таһир белән Зөһрә легендасын беләсезме? Ышанасызмы аңа?

— Беләм. Таһирны югалткач, мин бу поэманы махсус эзләп таптым. Аның берничә төрлесе бар. Әмма аларның барысы да бер төрле тәмамлана, Таһир белән Зөһрә бергә була алмыйлар. Шуңа күрә мин үзебезнең тарихка да аптырамыйм инде. Башта ук шулай юралган булган ул…

— Сез язмышка ышанасызмы?

— Белмим… Ышанамдыр, күрәсең. Ышанмасам, шушы хатлар артыннан килмәс тә идем.

— Нигә ташлап калдырдыгыз соң алайса?

— Ташламадым, ташлыйммы соң!

— Менә бит…

— Мин хастаханәдә ятканда бик тиз генә күченергә кушканнар. Мин булмагач, әйберләремне абый күчергән. Ашыккандыр инде… Күчкән чакта ниндидер хатларга әллә ни игътибар итмәгәндер. Ярый әле югалмаганнар. Рәхмәт инде сезгә. Әйбәт кеше кулына эләккәннәр бит, кадерлеләрем… Шуннан соң язмыш, тәкъдир юк дип кем әйтә ала?!

— Авырыйсызмы әллә?

Бу сорау бөтенләй дә кирәк түгел иде. Ни эше бар аның ниндидер хатынның больницада дәваланып ятуында? Эх, теле кычытты инде. Бик беләсе килде шул Зөһрәсенең хәл-әхвәле хакында…

Бу юлы да Зөһрә шөбһәләнмәде, дөрес итеп, ихлас күңеленнән җавап бирде:

— Әллә ни авырмыйм да, борчылам. Йөрәк тынгысызлана. Соңгы вакытта бигрәк тә. Үземне үзем изалап, борчып яшәгәнгә ул. Ялгыз кешенең йөрәге авыру була, диләр иде, дөрес икән… Аннары… Ярый, анысы сезгә кызык түгел.

— Юк, сез әйтеп бетерегез, бу миңа бик кызык.

— Әйтсәм, көлмәссезме соң? Көлмәм дип сүз бирегез…

— Сүз бирәм.

— Шушы хатларны язган Таһирны төшемдә күрдем мин. Ләкин танымаслык булып үзгәргән иде ул. Йөз-битләрендә яра җөйләре, тирән җыерчыклар, җиту сакал-мыеклар… Әмма барыбер матур үзе… Менә сезнең кебек… Әйе шул, карап-карап торам да аптырап уйлап куям: төшемдә күргән Таһир сезгә нык охшаган иде. Урам сукбаеннан бер дә ким түгел… А–а!.. Авыр сүз әйтсәм, кичерә күрегез берүк…

— Юк, юк, берни дә юк. Барыбыз да бер юлдан, бер эздән йөрибез ләса…

— Менә шул төшемдәге Таһирым әйтә: «Мин исән-сау, көт!» — ди. Нәкъ шул көндә йөрәгем ялкынсынып китте, хәтта «скорый» чакырырга туры килде. Болары сезгә бөтенләй кызык түгел инде...

Зөһрә китәргә җыенды. Таһир биргән хатларны иплә кенә төреп куйды. Аннары, сумкасын актарып, ике йөзлек чыгарды. Бераз вакыт ул акчаны кая куярга белмичә аптырап торгач, Таһир янәшәсендәге җимерек өстәл өстенә шудырды.

— Мәгез, сезгә акча кирәктер… Менә бөтен булганын калдырам. Яхшылыгыгыз өчен булыр…

— Сез нишлисез? Хәзер үк кире алыгыз!

— Рәнҗетмәгез мине, Таһир, алыгыз…

— Сез нәрсә?! Мин моны акча өчен эшләмәдем. Мин, гомумән, бернинди яхшылык та кылмадым.

— Алыгыз, сезнең алуыгыз миңа кирәк. Дога кылырсыз. Җаным тынычланыр, ичмасам. Хәер итеп алыгыз… Тормышымдагы иң кадерле әйберемне табып бирдегез бит... Югалган булсалар, үземне кичермәс идем, тыныч кына яши алмас идем…

— Беләсезме, сез болай итегез. Миннән рәтле-башлы дога чыкмас, бу акчаны алыгыз да мәчеткә барыгыз. Хәер багышлап, Таһирыгыз исәнлегенә дога укытыгыз. Һәм моны ышанып, ышанып кына түгел, инанып эшләгез: исән әле ул сезнең Таһирыгыз…

— Исән? Ничек исән? Сез каян беләсез?

— Минме? Мин менә шушы хатлардан укып белдем. Бу хатларны язган кеше тиз генә югалырга тиеш түгел. Аның мәхәббәте шулкадәр зур һәм көчле, аңа ул югалырга ирек бирмәячәк, Зөһрәсе хакындагы хатирәсе булып, яшәргә дәртләндереп торачак. Шул Зөһрәсе хакына, киләчәге, бәхете хакына яшәтәчәк… Ул, бәлки, әллә кем дә түгелдер, бәлки, менә безнең кебек, менә минем кебек, урамда яшидер, әмма ул чын, ихлас, дөрес кешедер… Иманлы бәндәдер… Мин моны тоям, хәтта беләм дә… Алыгыз акчагызны, барыгыз мәчеткә, дога укытыгыз, теләкләр багышлагыз. Табылыр Таһирыгыз, табылмый калмас…

— Рәхмәт, мең рәхмәт сезгә. Акыллы кеше икәнсез. Халык бит сезнең кебекләрдән курка, шикләнә. Ә сез менә нинди икән… Шуның өстенә Таһирымны да хәтерләтәсез. Юк, йөзегез, тавышыгыз белән түгел. Күңелегез белән Таһирга охшагансыз сез…

Хатын күз төпләрен сөрткәләп алды. Кыюсыз гына үрелеп, өстәлдәге йөзлекләрне дә кире сумкасына салып куйды. Китәргә җыенды. Тагын бер мәртәбә йөзен күтәреп, Таһирның күзләренә тутырып карап торды.

Кемнедер таныргa теләдеме? Нидер сизендеме?

Ләкин ул ныклап танып, тоеп бетерә алмады булса кирәк, салмак кына борылып, ишеккә табан китеп барды.

Таһирның эчке бер җирендә, җан яшәгән урында, ниндидер нечкә кыл тартылып куйды. «Китә бит! Тагын китә! Югала!..» Нидер кылырга, нәрсәдер эшләргә кирәк! Бик мөһим бер сүз, сәбәп уйлап табарга кирәк!

— Зөһрә ханым!

— Ә?..

— Зөһрә ханым, яңа адресыгызны калдырмыйсызмы соң?

— Ә нигә ул сезгә?

— Нигә дип… Тагын хатлар табылса? Ничек тапшырырмын соң аларын? Сезне ничек табармын?

— Юк, юк… Утыз гына хат иде алар. Барысы да шушында, рәхмәт...

— Шулай да калдырыгыз адресыгызны… Тагын нәрсә дә булса табылып куйса, китерербез…

— Ярый алайса, языгыз…

**5**

Зөһрә килгән көннән соң Таһирның күңеленнән тынычлык китте, аның урынына моң керде. Сагыш та, борчу-мазар да түгел, нәкъ менә моң! Чын татарча, безнеңчә моң! Аны бер сүз белән генә аңлатып та булмыйдыр… Әллә буламы? Бәлки, көрәштер ул? Әйе, моң — көрәш ул. Бәхет белән бәхетсезлек көрәше. Аларның бергәлеге, хәтта гармониясе!

Таһир күңелендә дә бер үк вакытта аяусыз һәм итагатьле көрәш бара. Ул бит Зөһрәсен тапты! Югалткан язмышын тапты! Хикмәт шунда: ул үз язмышына якын бара алмый. Чөнки… Язмышы аны чит итте, танымады. Ул инде йөзен югалткан, әмма ихласлыгын югалтмаган һәм… бары тик күңеле белән генә торып калган…

Ничек төште соң ул бу хәлгә? Аерылу ничек кенә авыр булмасын, әнә Зөһрә үз язмышы өчен көрәшергә көч тапкан бит, мәхәббәте хакына, кемгәдер биргән вәгъдәсеннән, ярәшкән кешесеннән, загс һәм табигать кануннарыннан баш тартырга да көч тапкан. Җиде ел ялгыз яшәп, үзенең чын Таһирыннан йөз чөермәгән, аны көткән, эзләгән, сагынган, яраткан… Ә Таһир? Рухын сындырмаса да, җанын ярып, иманын сатып эчмәсә дә, ул инде тормышның төбендә, кешелек хәятының чүплек башында. Аның һәр почмагыннан, йотам дип, дөнья җәнлегенең иләмсез авызы ырҗаеп тора.

Таһир — бомж. Урам сукбае. Бич! Аны инде сөйгән кешесе дә танымый. Дуслары, туганнары, үлгән, юкка чыккан, дип уйлыйлар. Хәтта милиция дә аңа кул селтәгән…

Ничек төште соң ул бу хәлгә?

Зөһрәгә утызынчы хатын язып, шул ук көнне Түбән Камадан чыгып киткәч, авылдагы анасы янына сугылды да якын-тирә совхозларда «Яшәсен перестройка!», «Яшәсен базар мөнәсәбәтләре!»

дигән плакатлар язып йөри башлады. Ара-тирә ил башлыкларының тук йөзләрен төшерергә дә туры килә иде. Күңелендә тынычлык булмагач, эштән дә, тормыштан да ямь таба алмады, эшләгән бар акчасын эчеп бетереп барды. Юк, кеше көлдереп, исереп, егылып ятмады, тик айнып та бетмәде… Аның тирәсенә үзе кебек моңлы-сагышлы, рухлары какшаган, күңел канатлары сынган җаннар җыелды. Шулай колхоздан колхозга, районнан районга күчә-күчә, алар бердәнбер көнне Казанда пәйда булдылар.

Зур калада яшәү кануннары үзгәрәк булып чыкты. Таһир бу шартларга әзер түгел иде. Берничә фабрикага бизәүче рәссам булып эшкә урнашып карады, мәктәптә стена газеталары чыгарды, кинотеатрларга афиша язарга ялланды, әмма юньле-рәтле эш табып, мантып китә алмады.

Торган җире дә ах итәрлек түгел иде. Ул ниндидер исерек урыс карчыгында фатирда торып булашты. Бу карчык акча алмый, әмма Таһир аңа көн саен бер шешә аракы алып кайтырга тиеш иде.

Бервакыт эшкә алмый башладылар. Ул, бомжларга, төрле әтрәк-әләмнәргә ияреп, кайчакта кичә генә төрмәдән чыккан шикле бәндәләргә кушылып, иске йортлар сүтеп йөрде, базарда йөк ташыды, бер дә булмаса, шешә җыеп тамак туйдырды. Ләкин кеше таларга күнегеп китә алмады. Сорамыйча алгалады, әмма урамда сату итүче татар карчыгының соңгы тиенен тартып алырга аның кулы да, күңеле дә күтәрелмәде. Бомжлар рәтенә төшүдән Таһирны ике генә әйбер тотып тора иде — аның паспорты бар, һәм ул әле һаман да урыс карчыгында фатирда тора…

Бердәнбер көнне ул алардан да колак какты. Кыйналып, ике ай урын өстендә аунаганнан соң, бөтенләй кешелектән чыгып, дөньялыктан ваз кичеп, кайчандыр кем тарафыннандыр уйлап чыгарылган сәер бер тормышта яши башлады.

Таһир алай ук көчсез түгел иде бит. Өметсез булса да, бу кадәр көчсез түгел иде… Их, шул өметсезлек кешелектән чыгарды да инде аны! Зөһрә аңа караганда мең мәртәбә көчлерәк булып чыкты. Ул үз хыялыннан, үз максатыннан бер тамчы да кире чикмәгән, өметен өзмәгән. Йөрәген какшаткан, әмма рухын имгәтмәгән…

Таһир үз өмете, үз максаты өчен ник көрәшмәде соң? Язмышы, бәхете өчен ник көрәшмәде? Үзенең кешелеген саклап калу өчен нигә кыл да кыймылдатмады? Мәрхәмәтсез, игелексез тормыш агымына бөтен чүп-чар белән бергә иярде дә китте…

Табарга була иде бит, ник эзләмәде ул Зөһрәне? Зөһрәнең кияүгә чыкмыйча аны көтеп ялгыз калуын ник тоймады? Мәхәббәт — тоем бит ул. Ник тоймады? Аракы сөреме аның бөтен күңел тоемын, җан җылысын бетергән булганмы? Ник? Нигә? Ни өчен?

Зөһрә килде дә китте, ә Таһир мең төрле сорау белән ялгызы торып калды. Ул үз күңелендәге авыр, газаплы моңны кая куярга да белмәде. Аптырагач, эштән бушап торган араларда, кәгазь-карандаш алып, Зөһрәнең яңа сурәтен төшерә башлады.

«Гаилә»дәгеләр Таһирның хәлен бик тиз аңлап алдылар. Шуңа күрәдерме, аны борчымаска, юкка-барга күңелен талкымаска, итагатьле, игътибарлы булырга тырыштылар.

Бүген Таһир гадәттәгедән иртәрәк уянды. Уянып, дөньяны тыңлап ятты. Әнә башкалар да, соңгы берничә елда туганлашып киткән дуслары, милләттәшләре дә уяныша башладылар. Һәрвакыттагыча, Сало белән Чүлмәк талашып алдылар. Люмин, бу ыгы-зыгыны ишетмәскә теләгәндәй, ниндидер шомлы, кыргый бер җыр шыңшып йөрде. Бөке, өйдәге тавышның тынганын гына көткән кебек: «Усал кеше үз каныннан чишмә ясап эчә», — дип, иртәнге гаугага үзенчә нәтиҗә ясап куйды. Аңа каршы килүче дә, җөпләп сүз әйтүче дә булмады. Бу көйсез җаннардагы бөтен усаллык шул бер-ике әрепләшү сүзе белән чыгып беткән иде. Салкын иртәдә дер калтыранып уянган урам сукбаеның күңеле ничек тыныч булсын да, үзенең шыксыз тормышына җаны ничек үртәлмәсен?! Шуңа күрә иртәнге талаш-гауга — бомжлар арасында гадәти хәл. Таһир моны аңлый, шуңа да күңеле тыныч аның.

Ашарга чакырдылар. Бүген табын мул иде. Кичә шактый акча эшләнгән. Җылы аш булмаса да, кайнар чәй һәрвакыт бар. Ит бар, май бар, ипи бар. Иртән аракы эчү тыелган. Сало көн саен иртәнге аш алдыннан әйтә торган сүзен әйтүгә, барысы да, дәррәү килеп, ташландык каплардан әмәлләп ясалган өстәлгә ябырылдылар…

— Ризык — дога кебек, күңелең белән никадәр ихлас кабул итәсең, ул шулкадәр сихәтлерәк, — диде Сало. Ул инде Чүлмәк белән татулашкан, алар, үзара көлешә-көлешә, юньсез мәзәк сөйләшәләр.

Таһирга боларның берсе дә кызык түгел. Аның күңелендә моң бар. Ул аны беркая да куя алмый. Бу моң хәтта Зөһрәнең сурәте белән дә чыгып бетмәде. Ул сурәтне дә Таһир үзе куна торган бүлмә стенасына элеп куйды. Озак кына карап торды. Шуны искәрде: Ул Зөһрәсен һаман элеккечә ясый. Йөзенә сары сагыш пәрдәсе эленгән, күз читләренә җыерчык кунган яңа Зөһрәсенә һаман күнегә алмый әле. Хәтта… Бу Зөһрәләр икесе ике кеше кебек. Күзләре генә шул ук. Тагын… Тагын йөрәкләре, җаннары бер. Таһир аны шундук таныды. Зөһрә дә тойды. Ничек диде әле ул? «Сез Таһирымны хәтерләтәсез» дидеме?

Таныды, тойды, аңлап кына җитә алмады. Таһир моңа сөенде генә. Ярый әле аңламады! Аңлап алса, болай да авыру йөрәге тәмам ярылып, яргаланып бетәр иде…

Юк, болай булмый. Булмый! Таһир Мөштәри урамына күтәрелгәндә дә, эшләп йөргәндә дә шул хакта гына уйлады. Нидер кылырга, нидер эшләргә кирәк! Хет хәзер килеп, кеше исемен, ир-егет исемен, үзенең легендар исемен акларга тиеш ул! Ничек?

Паспорт! Аның паспорты бар бит! Барып кына аласы!

Авыл! Аның авылы бар! Якыннары, туганнары бар! Бергә укыган дуслары бар! Остазлары бар!

Туган җире бар! Туган теле бар!

Хәтере бар! Иманы бар!

Мәхәббәте бар!

Бу азмыни?!

Бу күп, бик күп, яңадан чын кешеләр арасына, олы тормышка кайтып яшәрлек күп…

Тик… алар арасына кайту өчен, аларны да ышандырасы бар әле!

Зөһрәне дә ышандырасы бар.

Иң мөһиме, Таһир үз-үзен ышандырырга тиеш.

Әнә ул үзе йорт сүтә, үзе һаман уйлый. Уйлый-уйлый башы авырта инде аның. Ә йөрәге, җаны, күңеле, киресенчә, тынычлана бара, хисләре үз ярларына кайта, иманы кыйблага йөзе белән борыла… Таһир әлегә ныклап тоеп бетерми, әмма аның тормышына ургылып өмет керә башлаган иде инде.

Кичке якта Сало бөтен «гаилә»не үз бүлмәсенә җыйды.

Сүзен әйләнгечтән уратып йөртмәде, турысын ярып салды:

— Йә, егетләр, Почта белән нишлибез?

Бу сорауга «Почта»ның үзеннән башка беркем дә гаҗәпләнмәде.

— Ни булган миңа?

Сало Таһирның соравын ишетмәгәнгә салышты. Киресенчә, үзе үк сораша башлады.

— Синең чын исемең ничек?

— Минемме?

— Кем белән сөйләшәм соң мин?

— Таһир…

— Сиңа килгән хатынның исеме Зөһрә идеме?

— Әйе.

— Эчкән саен, син безгә сөйләп, туйдырып бетерә торган Зөһрәме?

— Әйе.

— Һаман да яратасыңмы?

— Әйе.

— Ә ул сине ярата мы?

— Әйе.

— Аның белән буласың киләме?

— Әйе.

— Нәрсә син! «Әйе» дә «әйе»! Бүтән сүз белмисеңме әллә?

— Беләм…

— Ну, әйт, нишлибез соң?

— Белмим…

— Мин дә белмим. Уйларга кирәк. Йә, кемдә нинди уй бар?

Сало һәркемгә аерым-аерым туктал ып карап чыкты. Аннары, карашын кабат Таһирга кайтарып, бермәл тын калып, уйланып торды.

Шунда Бөке телгә килде:

— Изгелекне туктатыр каршылык юк.

Аның сүзенә әллә ни игътибар итүче булмады. Әмма үзара әңгәмә башлап җибәрү өчен шул җитте.

— Таһирга бәхет елмайды. Надо поддержать! — диде Кирпеч.

— Таһирны кешеләргә кайтарырга кирәк,— диде Чүлмәк.

— Киендерергә, ызначит, адәм рәтенә китерергә дә Зөһрәсе куенына илтеп салырга, башка вариант юк, ызначит,— дип елмайды Люмин.

— Документ проблемасы булачак. — Чүлмәк сүзен тәмамламаган булган икән.

— Документ бар, — диде Сало. — Вахитовта ята. Барып кына аласы. Ләкин ментларны бәхилләштерергә кирәк булачак. Сүтә башлаган йорттан паспортлык кына сәмән чыгар дип уйлыйм. Әле киенергә дә калыр… Ә хәзергә син үзеңне рәткә китер. Ишетәсеңме, Почта… Таһир? Иртәгәдән эшкә чыкмыйсың. Авылыңа кайтырга әзерлән, калганын үзебез карарбыз…

Чүлмәк аны хуплап алды:

— Почтага акча кирәк булачак, Сало, банкуем, да?

Салмак кына торып, һәркем банк ролен үтәүче кәнфит кабына акча салып чыкты. Иң ахырдан Сало бер пачка акча куйды. Соңыннан ул каптагы акчаларны, бөртекләп җыеп алып, Таһирның кулына тоттырды.

Таһир бу кадәресен көтмәгән иде. Аның күңеле тулды, күзләренә яшь тыгылды. Күптән елаганы юк иде. Бүген елыйсы килде. Шушы сукбайларның һәрберсенә, туганнарча кочып, иң җылы сүзләр белән рәхмәт әйтеп, кадер-хөрмәт белдереп чыгасы килде. Ләкин ул белә: бомжлар тормышында андый гадәтләр юк. Болай да бөтенесе аңлашылып тора…

Таһир төчеләнмәде, бары тик:

— Рәхмәт, туганнар, — дип кенә әйтте, аннары, дымлы күзләрен яшеребрәк, урамга чыгып китте.

Аның артыннан Бөкенең таныш фәлсәфәсе ияреergә тырышып карады:

— Кеше булу өчен герой булу мәҗбүри түгел…

Һәр кеше гомере — мәңгелекнең бер мизгеле, диләр. Ләкин кеше гомерендә дә мәңгелеккә тиң мизгелләр була. Таһирның хәзер шундый мизгеле. Үтә дә җаваплы чоры, сынау һәм сыналу вакыты…

Икенче көнне Таһирны эшкә ияртмәделәр. Ләкин өйдә дә калдырмадылар. Сало, һәрвакыттагыча, берәгәйле итеп әйтте:

— Паспортыңны үзем кереп алам. Бирмәсәләр, Баронга әйтермен. Ә син бар, Зөһрәң белән контактка кер, — диде. — Только смотри, кешелегеңне һәм ирлегеңне җуйма!

Таһир Зөһрә белән контактка керергә уйламады да. Шушы кыяфәте белән ничек күренсен ул аңа? Нәрсә дисен? Күренеп, беренче очрашуда ук гайрәтен чигерсенме? Ләкин, шул ук вакытта, Зөһрәгә ниндидер ым, ишарә бирергә дә кирәк. Моның юлын-чарасын да бик тиз уйлап тапты Таһир. Хат язарга булды ул. Утыз беренче хатын язып, Зөһрәсенең үз кулына тапшырырга тиеш ул.

Шулай эшләде дә. Бер аулак урын табып, ярты көн буе кулыннан каләмен төшермәде. Төрлечә язып карады. Ничек кенә язса да, Зөһрә аңа ышанмас кебек тоелды. Ышандыру бер хәл. Куркытудан, өркетүдән курыкты. Зөһрә үз Таһирының бомжга әверелүен белергә тиеш түгел иде.

*«Зөһрә, кадерлем!* — дип, элекке хатларындагыча башлап китте ул.— *Син мине беләсең дә, белмисең дә. Мин — Таһир. Җиде ел элек югалткан Таһирың. Курыкма, шикләнмә. Мин теге дөньядан кайтмадым. Ләкин бу дөньяда да яшәмәдем. Мин яшәгән дөнья — җир белән күк арасында. Дөресрәге, яшәү белән үлем арасында. Син ул тормышны күрдең. Мөштәри урамындагы йортыңнан хатларыңны табып биргән бомжны хәтерлисеңме? Таһир дигән бәндәне? Син: «Таһирымны хәтерләтәсең», — дигәч, җир тишегенә кереп китә язган ир затын? Шул Таһир — Син җиде ел элек югалткан Таһирың була инде. Танымадың… Танырлык түгелдер шул хәзер мин. Танымавың хәерлерәк тә. Күзеңә бомж булып, сукбай булып күренәсем килми. Бүген мин Сиңа лаек түгел. Җиде ел буе үз күңеленә тугры калган Зөһрәсенә лаек Таһир булып, чын кеше булып күренәсем килә. Киләм әле мин Сиңа, Зөһрә, кайтам әле. Көт мине. Үтенәм, үзең эзләмә. Бераз вакыт бир. Тормышымны, күңелемне җайларга мөмкинлек бир. Шуны онытма: минем саф күңелем, ихлас мәхәббәтем, сине өзелеп ярата торган олы йөрәгем бар. Хәтерем бар, иманым бар, хыялым бар…*

*Барысы өчен дә кичер мине, кадерлем. Сиңа китергән кайгы-борчуларым өчен кичер!*

*Һәм… мең-мең рәхмәтләр Сиңа! Тугрылыгың өчен, сабырлыгың өчен, кече күңеллелегең, олы йөрәгең өчен рәхмәт!*

*Вәгъдә — иман. Сиңа вәгъдәмне, сүземне бирәм — мин тиздән олы тормышка, кешеләр арасына кайтачакмын. Син әле минем өчен горурланачаксың…*

*Мин тормышны шундый сагындым, Зөһрә! Мин Сине өзелеп сагындым!*

*Көт мине, көт!*

*Синең Таһирың».*

Зөһрә яшәгән йортны эзләп табу кыен булмады. Фатиры да икенче катта гына икән. Әмма ишек бикле иде. Таһир нишләргә белмичә таптанып торган арада, каршы яктагы ишек ачылып китте. Аннан берсеннән-берсе тазарак ир белән хатын килеп чыктылар.

Ишек төпләрендә торучы сәләмә сукбай шикләндергәндер шул.

Әзмәвердәй ир шундук сорау ала башлады:

— Син кем?

— Почта… Ә-ә… Таһир.

— Нәрсә кирәк монда?

— Менә бу фатирның хуҗасын көтәм.

— Син аның кеме?

— Беркеме дә түгел.

— Шулай булгач?

— Нәрсә?

— Шулай булгач, ычкын моннан, пока исән-сау чакта.

— Юк, миңа Зөһрәне күрергә кирәк.

— Ычкын диләр моннан! Ну?

— Мин нишләгән соң? Мин просто көтәм… Беркемгә дә тимим…

— Син нәрсә, аңламыйсыңмы әллә? Кулны пычратасы килмәгән иде… Юньле чакта күз алдыннан олак! Юкса…

— Нәрсә — юкса?..

— Күзеңне төртеп тишәм! — Теге бәндә, ике бармагын тырпайтып, Таһирга табан килә башлады.

Ләкин Таһир белә: көч тәннән түгел, җаннан! Шуңа да курыкмый.

— Чыкмыйм. Син мусор түгел, мин шалава түгел!

— Әле шулаймы? Хәзер мин синең бетле башыңны сугып ярам!..

— Кем кемнекен ярыр әле…

— Ах, урам бич-ч-чурасы!.. — Теге гәүдә, аю кебек алпан-тилпән атлап килде дә кизәнеп сукмакчы булды. Ләкин сугарга өлгерә алмый калды. Ул кизәнгән арада, Таһир яшен тизлегендә үрелеп, аның иягенә бәреп алды. Әзмәвердәй ир заты бераз чайкалып торды да, артка таба янтаеп, стенага барып бәрелде, аннары, шул стена буйлап, салмак кына идәнгә шуып төште.

Янында басып торган хатынга шул җитә калды, ул, җир ертып кычкыра-кычкыра, баскычтан аскы катка ташланды, аннары урамга ук атылып чыгып китте. Аның:

— Үтерәләр!.. Үтерәләр!.. Милиция!.. — дип ачыргаланып кычкырган тавышы шактый вакыт һаваны ярып торды әле.

Ир кеше, бераздан исенә килеп, Таһирга күтәрелеп карады, аннары, ыңгыраша-ыңгыраша торды да фатирына кереп бикләнде, теленә нәрсә килә шуны әйтеп, сүгенергә кереште.

Таһир дәшмәде. Зөһрә ишеге янына барды да, хуҗасының ишек ачуын көтеп утырган эт кебек, стена буена чүгәләп, сабыр гына көтә башлады. Күңеленә Бөкенең: «Әдәплелеккә әдәпсезләрдән дә өйрәнеп була» дигән сүзе килде. Елмаеп куйды: ә үзе соң, үзе!..

Милиция тиз килеп җитте. Подъезд төбенә чыелдап килеп туктаган машина тавышына Таһир, сискәнеп, торып ук басты. Күп ташыдылар аны бу машинада, кан косып күп ятты ул аның пычрак идәнендә… Юньлегә түгел бу… Таһир үзенең нинди бәлагә тарганын шунда ук аңлап алды. Бу биек йортларга якын бармаска ант иткән чаклары бар иде инде. Бу юлы Зөһрә дип килде шул. Шуңа да үкенми, Зөһрә белән бәйле бер нәрсәгә дә үкенми ул…

Сулышлары буылып чабып кергән милиционер егетләр, Таһирны, кулларын артка каерып, йөзе белән таш идәнгә егып ташладылар. Арттан аякларын күтәреп, каерылган кулларына шытырдатып бәйләп тә куйдылар. Таһир белә: ментовкада моны, көлеп, «ласточка» диләр. Аз гына да селкенерлек түгел. Селкендеңме — бөтен сеңерләрең, кан тамырларың шытырдап өзелә башлый, сөякләрең сөяктән, итең иттән куба…

Таһир нидер кычкырырга тырышып карады. Ләкин бер авыз сүз дә чыгара алмый калды, таза өч егет каты башлы итекләре белән аның бил-күкрәк турысына типкәли башладылар.

— Син кем?

Таһирның дәшәрлеге калмаган иде, җитмәсә, таш идәнгә егылганда, ул авыз-борынын нык кына җимергән булган икән…

— Кайсы фатирны басарга иде исәбең, гад? Ну? Әйтәсеңме-юкмы? Юкмы? Мә, алайса, мә, мә!

Таһирның кан тулышкан авызыннан ыңгырашып-иңрәп бердәнбер сүз чыкты:

— Ф-ф-а-ш-ш-ист…

— Бирермен мин сиңа фашистны! Менә шундый була ул фашист, менә, менә, менә!

Кинәт үлем тынлыгы урнашты. Таһир сагайды. Әллә чынлап та үлдеме ул? Авырту да сизелмәгән кебек… Сизелә… Әнә йөрәгенә төшеп сызлый… Бөтен тәненә энә кадап чыкканнар диярсең…

Шул вакыт җанга илаһи дога булып ята торган таныш тавыш ишетелде. Әмма бу догада усаллык та бар иде:

— Нишлисез сез? Ник кыйныйсыз аны? Прекратите!

— Бомж бит ул. Рәхмәт әйтегез әле. Өегезне таларга кергән әнә... Гад! Менә, күршеләрегез күреп калган.

Идәндә йөзтүбән капланып яткан Таһир башын Зөһрә ягына бормакчы булды. Булдыра алмады.

— Зөһрә-ә-ә…

Зөһрә иң элек, сискәнеп, читкә тайпылды, аннары, ниндидер үтә дә таныш, хәтта кадерле, газиз тавыш ишеткәндәге кебек, идәнгә тезләнде.

— Кем син? Каян?

— Таһир мин… Почта… Хат китердем…
— Таһир?.. Мөштәридәнме?..
— Әйе… Почта… Хат…
Зөһрә, торып, милиционерларга җентекләп аңлата башлады. Элек Мөштәри урамында торуын, күптән түгел генә шушы йортка күчеп килүен, хатларын онытып калдыруын, аларны шушы Таһир дигән кешенең табып бирүен, өй адресын аңа үзе биреп калдыруын тәфсилләп сөйләп чыкты, Таһирны җибәрүләрен үтенде.
Ышандылар. Җибәрделәр. Юкка шау-шу куптарган өчен каршы як күршеләргә шелтә белдерделәр. Чыгып киттеләр.
Таһир, кара кан йотып, таш идәндә утырып калды. Тәннәрен, аяк-кулларын язарга тырышып карады — сынган, имгәнгән җире юкмы… Юк бугай. Калганы төзәлер, йомшак җир тиз төзәлә ул. Ә менә күңел нинди икән? Катымы, йомшакмы? Күңелне күргән яки тотып караган кеше юк шул, юк…
Зөһрә өенә чакырды. Таһир кермәде. Ул киемнәрен тәртипкә китереп булашкан арада, Зөһрә үз фатирыннан юеш чүпрәк, йод, мамык алып чыкты. Ләкин Таһир аның ярдәменнән баш тартты.
Кесәсеннән таушалып беткән конверт чыгарды да:
— Миңа китәргә кирәк. Сезгә хат кына калдырмакчы идем. Ә менә ничек килеп чыкты. Зинһар, гафу итегез…
— Үзегез ачуланмагыз. Нинди хат ул? Кемнән?
Зөһрә сагайды. Йөзендәге җыерчыклары тагын да ныграк беленеп тора башлады. Күзендәге якты нурны шомлы уй юып төшерде…
— Таһирдан.
— Кемнән?
— Әйе-әйе, Таһирдан хат бар. Менә, алыгыз…
— Аның бөтен язган хатлары да миндә. Утыз хаты да… Тагын нинди хат ул?
— Утыз беренчесе, димәк… Ышанмасагыз, конверт тышына карагыз. Аның кулымы?
— Аныкы…
— Димәк, бу хат Таһирдан?
— Шулай булып чыга…
— Алайса алыгыз…
— Рәхмәт…
— Ярый, сау булып торыгыз. Онытмагыз. Таһирыгызны онытмагыз. Көтегез. Бер килер ул, көтегез…
— Рәхмәт сезгә, Таһир… Ләкин мин берни дә аңламыйм. Сез шаяртасызмы? Әллә нидер беләсезме? Әйтмисез генәме?
— Юк, шаяртмыйм. Минем шаяртудан узган инде. Күреп торасыз… Хушыгыз…
— Хушыгыз… Таһир…
Таһир, башын күтәреп, Зөһрәнең күзләренә карый алмады. Көче җитмәде. Авыру җанын, җәрәхәтле тәнен алып, йөгереп чыгып китте. Ул хәтта Зөһрәнең: «Нинди хат бу, Таһир? Монда бит яңа адресым язылган… Ә ул минем күчкәнне белми, белми!.. Нинди хат бу? Син үзең кем, Таһир? Син — Таһир? Таһи-и-ир!..» — дип үрсәләнеп кычкырып калуын да ишетмәде. Ишетсә дә кире кермәс иде. Аның, тизрәк Кабан буендагы фатирына кайтып, рәтлерәк киемнәрен киеп, төргәккә төйнәлеп куелган рәсем-сурәтләрен алып, Мөштәри урамында эшләүче дуслары янына сугылып, Сало табып биргән паспортын кесәсенә салып, туган якларына кайтып китәсе бар иде.

**6**

Туган яктан китү — җанның бер өлешен югалту ул. Таһир исә туган ягында җанының бер өлешен генә түгел, бу җан дигәннәрен бөтенләе белән калдырган булган, ахры. Ул хәзер менә шул җанын эзләп кайтып килә.
Кайтышлый ук әнкәсенең каберенә кереп чыгарга булды. Аның вафатыннан соң беренче кайтуы Таһирның. Күмәргә дә кайтмады бит... Аннан соң да… Бөтенләй бүтән дөньяда, бүтән гамь белән яшәде шул ул соңгы елларын. Җансыз тормышта яшәде…
Ләкин әнкәсенең кабер өстендә дә Таһирның җан әсәре күренмәде. Зират аны үлем тынлыгы белән каршы алды. Әнкәсенең рухын да тоймады ул. Аны бу минутта бөтен рухлар, җаннар, әрвахлар ташлап киткән иде. Ташлар да шул. Кем ул хәзер? Адәм затымы? Әллә Иблис токымыннанмы? Хак мөселманнан ни-нәрсә калган аңарда? Өрәк! Менә кем ул? Җансыз, кыяфәтсез, бәхетсез бер бәндә!

Әнкәсе дә беравыз сүз сөйләшмәде. Үпкәләгәндер, рәнҗегәндер шул. Бәлки, аның ятим рухы улының адәм карамаслык кыяфәтен, җәрәхәтләнеп, кутырга каткан йөзен күреп торгандыр? Бәлки, Зөһрә кебек, ул да Таһирны танымагандыр? Ана булып та танымагандыр…

Зираттан чыккач, Таһир туганнан туган тиешле абыйларына китте. Әнкәсен соңгы юлга озаткан кеше ул. Бу хакта Казан урамнарының берсендә йөзгә-йөз бәрелешкән авылдашы хәбәр итеп киткән иде. Шуңа күрә, Таһир аңа бик рәхмәтле. Әйбәт кеше ул. Кешелекле. Туган җанлы.

Әмма бу юлы Хөсәен абыйсы Таһирны салкын каршы алды. Шулай да бер начар сүз дә әйтмәде, кырын да карамады, шундук өенә, күңеленә сыйдырды, аякка басканчы, башлы-күзле булганчы үзләрендә яшәп торырга кушты.

Өстәлдәге сыйлар янына аракы шешәсе чыгып утыргач, Таһир йөзен чытты. Хөсәен абыйсы да эчми башлаган икән, ул, бик тиз аңлап алып, шешәне җәһәт кенә өстәл астына төшереп җибәрде.

Сүз сүзгә ябышмады. Таһир төшенеп алган иде инде — аның үксез җаны туганнары янында да юк. Юк! Бу хакта белгәч, ул артык борчылмады да. Хөсәен абыйсы йортында бер атналап яшәгәч, Сало җыеп биргән акчага бер кат киенеп, чистарынып, төзәнеп-ясанып алгач, ул Түбән Камага китәргә булды. Аның югалган җаны, бәлки, шундадыр? Шундагы бер каен агачына яисә миләш куагына эләгеп калгандыр? Бәлки, Кама яры буенда яшь сыгып, моңсуланып утырадыр?

Ләкин шәһәр дә аны кочак җәеп каршы алмады. Таһир тегендә сугылды, монда сугылды, әмма аны яннарына сыендырырга теләүче кешеләр табылмады. Элекке җан дусларыннан беркем дә калмаган, Наил дә, өйләнеп, Себергә китеп барган, ә кайчандыр исәнләшеп йөргән таныш-белешнең үз борчулары да баштан ашкан.

Урам чатында, бу башны алып кая гына олагырга инде дип аптырап басып торганда, Таһирны кемдер дәште. Тавыш иясен эзләп, ул як-ягына каранды, әмма халык арасында бер генә таныш йөз дә күрмәде. Шулай да бераздан юка гына гәүдәле, ап-ак чәче өстеннән җыйнак түбәтәй кигән, шундый ук ак сакал-мыектан бер картның җилфер-җилфер үзенә таба килүен шәйләп алды. Бәй, бу бит Хәсәнша ага! Хәсәнша остаз! Училищеда рәсем сәнгатеннән укыткан атаклы рәссам! Нишләп башта ук уйламаган икән Таһир аның хакында? Ә бит ул кайчандыр бу карт рәссамның иң яраткан шәкерте иде.

— Таһир! Таһирҗан! Синме бу?

— Хәсәнша ага? Сез? Сезме бу?

— Таһирҗан, чынлап та синме бу?

— Мин…

— Син шул! Югалган, үлгән дигәннәр иде… Нишләп йөрисең? Син исәнмени?

Хәсәнша картның сәер соравына Таһир һич кенә дә үпкәләмәде. Каршы йөгереп барып, кочаклап ук алды.

— Мин бу, Хәсәнша ага. Менә тотып, чеметеп карагыз. Нәрсә булсын миңа…

— Шулаен шулай да… Нык кына үзгәргәнсең икән… Дөнья шактый кыйнаган, ахры… Бөтен җиреңдә үзенең эзләрен калдырган…

— Булды инде… Үзегез ни хәлләрдә соң? Һаман шул килеш икәнсез.

— Юк, картаерга исәп юк әле.

— Һаман шундамы?

— Шунда. Балалар белән рәсем ясарга өйрәнәбез. Юк, сезнең чыгарылыштан соң әллә кем күренми… Үзең хәзер кайда?

— Кайда дип… Әлегә җир белән күк арасында… Менә… бу якларга кайттым.

— Рәсемне ташламадыңмы?

— Юк, вроде… Күбрәк портретлар ясыйм… Карандаш белән… Аз-маз графика… Пейзаж…

— Ярый, анысын карарбыз. Авылыңа кайттыңмы?

— Кайттым. Әнкәй мәрхүмә янында булдым.

— Анысы яраган. Хет бераз рухы тынычланыр. Күмәргә дә кайтмадың…

— Хәсәнша ага, мин бит…

— Стоп! Мин сине битәрләргә җыенмыйм. Кирәкми, дәшмә. Бөтен күргән-яшәгәнең үзең белән. Нәрсә булганын сорамыйм, берәр вакыт сөйләрсең әле.

— Хәсәнша ага, сез ничек таныдыгыз мине? Мине бит хәзер беркем дә танымый.

— Кулларым калтыранса да, күзләрем үткен әле минем. Рәссам күзләре! Таныдым, шундук таныдым.

— Күзләрегез генә түгел, йөрәгегез дә үткен, яшь әле сезнең.

— Ә менә син картайгансың, Таһирҗан… Аңлавымча, сиңа эш кирәк? Әйдә минем янга — остаханәгә…

— Әле ул һаман да бармыни, Хәсәнша ага? — Таһир сөенеченнән кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

— Бар, бар. Нәрсә булсын аңа? Алайса, иртәгәдән үк эшкә чыгасың. Миндә яшәп торырсың. Җиһан әбиеңнең тагын бер түшәк әмәлләрлек кенә рәте бардыр әле…

Шулай кинәт кенә хәл ителде дә куйды. Эш тә булды, торыр урын да җайланды. Таһирның күңеле урынына утырды, җаны тынычланды. Ул бөтен вакытын, көчен, талантын Хәсәнша карт остаханәсендәге эшкә бирде.

Бу остаханә төрле хөкүмәт заказларын башкара икән. Ишек башындагы язулардан алып, затлы залларга эленә торган зур картиналарга кадәр язарга туры килә. Таһирның кулы эшне сагынган, иҗатка дәртләнеп тора, ә күзләре — дөнья төсләрен, күңеле хисләргә тоемын онытмаган икән әле!

Боларның барысы да төш кебек кенә. Бомж тормышы белән яшәгәндә, ул бу төшне еш күрә иде. Имеш, аның каршында иксез-чиксез картина… Таһир шушы картинага тормышны яза… Шунысы гаҗәп, аның төшергән һәр образы, терелеп, җанланып, гадәти кеше тормышы белән яши башлый. Шуңа күрә картина һаман буш, һаман ымсындыра…

Таһир хәзер белә — аның җаны иҗатта булган икән. Чөнки ул кулына пумала алгач кына җанының тынычлануын, матур, бәхетле мизгелләр кичерүен тоя иде. Ниһаять, ул җанын тапты, аны үз урынына кайтарды!

Кайтарып бетерде микән?

Ә Зөһрә? Казан уртасында серле-могҗизалы хат тотып калган Зөһрәне кая куясың? Ярый ла Таһир, үз горурлыгына баш бирмичә, Түбән Камага качып котылды. Ә Зөһрәгә нишләргә? Аның җаны бу минутта өзгәләнми дисеңме?! Таһир аның янында үз җанының бер өлешен, бик матур өлешен калдырмадымыни?!

Ничек кенә Казанга, Зөһрәсе янына ымсынса да, Таһир, бөтен күңел җегәрен җыеп, тыелып калды. «Иртәрәк әле, иртәрәк. Элекке кебек тагын Зөһрәнең күңелен кайтармаммы» дип уйлый иде ул.

Ләкин Зөһрәсе янына кайтып әйтерлек сүзе юк шул әле аның. Тормышы да, горурлыгы да, максаты да юк.

Нишләп булмасын?

Бердән бер көнне Таһир Хәсәнша картка Казаннан үзе белән ияреп кайткан сурәтләр циклын күрсәтте. Күрсәтмәде дә. «Менә күз төшерегез әле, болар — Казанда чакта ясаганнарым», — дип, кыенсынып кына тоттырды да, үзе каядыр чыгып китте. Шулай озак кына югалып йөрде. Ул остаханәгә кайтып кергәндә, алар белән эшләүче ике оста, агач юнып, пыяла кисеп, Таһирның рәсемнәрен рамнарга урнаштырып булашалар иде.

— Нишлисез сез? — дип сораганын сизми дә калды Таһир.

— Кушканны эшлибез. Картлач һәр сурәтне рамга урнаштырырга боерды. Күргәзмәгә җибәрәбез, ди. Бәхет елмайды сиңа, Таһирҗан…

Шунда Хәсәнша ага үзе кайтып керде.

Ул тын-сулышын тигезләгәнче, Таһир сорап өлгерде:

— Хәсәнша ага, нишләтәсез боларны?

— Күрмисеңмени, Казанга әзерлибез…

— Нинди Казан? Ни өчен?

— Күргәзмә өчен… Күргәзмәгә җибәрәбез синең бу циклны.

— Нинди күргәзмә?

— Ярый, анысы черт с ним! Беләсеңме син кем?

— Кем?

— Син… Син… Талант! Гений! Хотя… бу хакта синең үзеңә әйтергә ярамый бугай…

— Мин берни дә аңламыйм…

— Беләсеңме нәрсә?.. Синең бу эшләрең бөтен дөньяны шаккаттырачак әле… Каян таптың бу образларны? Бу типларны каян эзләп таптың? Бу бит… ачыш, могҗиза! Портрет төшерүдә переворот, революция ясагансың бит син, малай актыгы! Шуны төшенәсеңме? Әллә һаман күзле бүкән кебек аңгыраеп торасыңмы?

— Берни дә аңламыйм, ей-богу!

— Аңламыйсыңмы?

— Юк…

— Менә кара бу портретка. Бу бит чын портрет түгел. Бу бит — символ, заман символы! Бу кадәр шартлылык, фантазия… Әмма шунысы гаҗәп — ул тормышны тормышның үзенә караганда да чынрак сурәтләнгән! Менә бит хикмәт нидә! Ә менә монысы! Күзләренә, күзләренә кара. Әнә-әнә, син бит, егеткәй, бу күзләрдән җан суырылып чыккан вакытны тотып алгансың… Күрәсеңме, әнә ул, әнә җан бөртеге… Ә менә монысын кара! Моңа кадәр, бәхет белән бәхетсезлек бергә яши алмый, диләр иде. Ә синдә алар бергә! Алар дуслар! Алар туганнар! Алар аерым-аерым яши алмыйлар. Сурәттә яңа фәлсәфә бу, яңа дин, если уж на то пошло! Их син, Таһирҗан, ярый кайттың әле, сөендердең картлачның җанын… Рәхмәт сиңа, балакай…

Таһир Хәсәнша картны танымады. Ул шундый матур иде бу минутта, яшь иде, бәхетле иде, канатлы иде! Бер сурәттән икенчесенә очып йөргән кебек бу сабый күңелле картны кочаклап аласы килде Таһирның.

Хәсәнша картны туктату мөмкин түгел иде.

— Аңламасаң, бик аңларсың әле… Сиңа аңламасаң да ярый. Син эшлә генә, иҗат ит! Аңларга тиешлесен без аңларбыз, аңлатуын да аңлатырбыз… Ә син беләсеңме мин каян кайттым? Менә әле генә каян кайттым? Юк, белмисең. Почтага барып килдем. Казанга телеграмма суктым. Үзәк күргәзмәләр залында «Замандаш портреты» дигән халыкара күргәзмә ачыла. Шуңа синең исемне җибәрдем. Күптән бер кеше сорыйлар иде. Ул дәрәҗәдә куярлык рәссам булмагач, хәбәр итми тордык. Ә менә бүген синең исемне атап кайттым…

Таһир барыбер берни дә аңламады. Аңламаса да, бик рәхәт иде аңа. Ул рәхмәттән башка бер сүз дә белми иде бу минутта.

— Рәхмәт, Хәсәнша ага…

— Рәхмәт? Без рәхмәт әйтергә тиеш сиңа, Таһирҗан. Ходай Тәгалә мәрхәмәтенә ирешкән җан бит син. Кулыңнан да аның фәрештәләре йөртә… Югалма бүтән, үтенеп сорыйм, син безгә кирәк, халыкка кирәк, кешелеккә кирәк.

— Хәсәнша ага, Ходай Тәгалә сурәт ясарга кушмаган бит…

— Начар ясарга кушмаган ул, беләсең килсә. Кеше сурәтен иләмсез, ямьсез, мәнсез итеп ясаганнарын күргән дә, сурәт ясаудан тыйган. Шул гына. Ә син әйбәт ясыйсың. Синең эшләрне күрсә, Ходай Тәгалә сурәт ясауны тыймас иде, билләһи! Мин шуны гына беләм: туфракка төшкән орлыктан аермалы буларак, кеше күңеленә төшкән орлык һәрчак шытып чыга. Синең күңелең уңдырышлы булган, орлыгың тук, үсентесе көчле-егәрле булган… Шул.

— Миңа хәзер нишләргә соң, Хәсәнша ага?

— Берни дә эшләргә кирәк түгел. Йөз илле эшеңне, рамнарга урнаштырып, пыяла белән каплыйбыз да Казанга җибәрәбез. Каталогын үзем төзим. Бу циклга исем уйлап табасың гына кала.

— Нинди исем?

— Шундук хәтергә сеңеп кала торган булсын ул!

— Алайса, уйлап торасы да юк. «Сало, Кирпеч, Чүлмәк, Бөке, Люмин һәм башкалар» дип кушыйк.

— Шулаймы? Болар кушаматлармы? Кемнәр соң алар?

— Алар… Алар минем дусларым. Урам сукбайлары. Үксез, әмма горур җаннар…

Хәсәнша карт, башын кискен күтәреп, сынаулы карашы белән Таһирга төбәлде.

— Шулай да каян килеп чыктың син, Таһирҗан?

— Шушы Сало, Кирпеч, Чүлмәк, Люмин, Бөкеләр яшәгән тормыштан кайттым мин, Хәсәнша ага. Тормыш мәктәбеннән, дисәм, кеше көләр. Их, Хәсәнша ага, менә сезнең кебек, безнең кебек кешеләр күрми торган тагын бер тормыш, дөресрәге, тагын бер яшәү яссылыгы бар бит бу җир өстендә. Анда да кешеләр яши, ул тормышның да үз кануннары, үз борчулары, үз бәйрәмнәре бар… Андагы җаннарның, бәлки… өрәкләрнеңдер, бу безнең җир белән бер бәйләнеше дә юк… Документлары да, гаиләләре, туганнары да юк аларның, хәтта язмышлары да юк… Мин бу циклымны әнә шул тормыштан төшереп алып кайттым…

Тик сез бу адәми затлар өчен әхлак, йола, иман, вәгъдә, сүз, сурәт юк икән дип уйламагыз. Алай уйласагыз, бик нык ялгышырсыз.

Алты татар яшәдек без. Бер гаилә булып яшәдек. Алтыбыз Алты яктан, алты тарафтан… Алар мине үлемнән алып калдылар, җир астыннан йолып, якты дөньяга күтәреп чыгардылар… Минем тамагымны туйдырдылар, өстемә җылы кием бирделәр. Ә вакыт җиткәч, соңгы акчаларына мине юлга әзерләделәр, көне-төне йорт сүтеп, шешә сатып алган акчаларына паспорт юнәтеп бирделәр… Ләкин бу гына түгел әле!.. Алар миңа җиде ел югалтып йөргән мәхәббәтемне табарга булыштылар. Ә бит алар моның өчен миннән берни дә сорамадылар, Хәсәнша ага! Беләм, бу дөньяда сорыйлар, бугазыңа басып сорыйлар. Ә ул дөньяда сорамыйлар, анда изгелек — гадәти хәл. Ул дөньяда сорар әйбер дә, бирер әйбер дә юк. Анда кеше йә бар, йә ул юк…

Таһирның күзләре генә түгел, күңеле яшькә тыгылды. Ләкин сөйләнәсе сүз сөйләнеп бетмәгән иде әле. Менә ул күз төпләренә тибеп чыккан яшь тамчыларын күлмәк җиңе белән сыпырып алды да баягы сүзен дәвам итте:

— Беләсеңме, Хәсәнша ага, мин күпмедер вакыт төшемдә яшәгән кебек булдым. Ниндидер хыялый, әмма үтә дә котсыз бер дөньяда яшәп алдым. Анда да туктаусыз көрәш бара: иман белән имансызлык, сафлык белән фахишәлек, горурлык белән ялагайлык арасында кискен көрәш бара. Анда да кешеләрнең исәбе-хисабы юк, әмма югалган кешене анда эзләп тормыйлар. Балалар тиз картаялар, кызлар сафлыкларын сабый чакта ук югалталар… Мин яшәгән дөньяның бу ягы да бар иде, Хәсәнша ага. Ул ягын да күрдем. Әмма барыбер бомжлар бервакытта да егылган кешегә тимиләр, карт-корының соңгы телемен тартып алмыйлар, сабыйларны рәнҗетмиләр, мохтаҗларга ярдәм

итәләр. Алар, дуңгыз ите ашасалар да, намаз укыйлар, аракы эчсәләр дә, мәчеткә хәер илтәләр. Мине шуларның барсын да шушы сурәтләремдә алып кайттым мин, Хәсәнша ага…

— Мин сине аңладым, Таһирҗан. Син заманыбызның төбенә төшеп айкарлык сурәтләр иҗат иткәнсең. Бу сурәтләрең кешеләрнең күзләрен ачарга тиеш. Җаннарын каерып ачарга тиеш. Бомжлар дисең син… Чынлап та, бомжлар чоры хәзер. Бомж кешеләр, бомж гаиләләр, бомж авыллар, бистәләр, шәһәрләр, бомж кырлар, басулар… Бомж дәүләтләр, илләр… Бомж халыклар… Ягъни без определенного места жительства…

Хәсәнша карт сөйлгәннәрдән Таһир сискәнеп китте. Тагын сәясәт, тагын шау-шу… Теләмәгән иде Таһир дөньяның бу ягына кагылырга… Юктыр шул, сәясәттән читтә яшәп булмыйдыр…

Хәсәнша карт сүзләре бер сискәндерерлек, бер уйландырырлык иде шул.

— Бомж сәясәт… Бомж кануннар…

— Бомж мәхәббәт… — Монысын Таһир әйтте.

Ул үзенчә уйлый. Болай дип уйлый: «Ныклап, бөртекләп уйлап карасаң, туган җиреңне ярату, аны кадерләү — үзе сәясәт ул! Ике кеше арасында туган сөю хисләре сәясәт түгелмени?! Бер татар егете бер татар кызына, чын татарча итеп: «Яратам, сөям сине!» — дип әйтә икән, бу — сәясәтнең дә нindие әле! Иң олысы, иң мәгънәлесе! Телсез калган халыклы, илсез калган дәүләтле бомж сәясәт, бомж дөнья, бомж өмет түгел инде…

…Бергәләп, кич буе күргәзмәгә әзерләнделәр. Таһир сукбайлар циклына Зөһрә сурәтен дә өстәргә булды. Иң алга Зөһрәнең җиде ел элек төшерелгән сурәтен куйды, композициянең ахырында — бүгенге портреты. Ә уртага, үзәккә, Таһирның үз сурәте, көлгәндә бер якка чалшаебрак китә торган иреннәрен ерып төшкән зур автопортреты куелачак…

Бер атнадан барысы да әзер булды. Таһирның сурәтләр циклын Казанга алып киттеләр. Автор үзе Түбән Камада калды. Күргәзмә ачылырга бераз вакыт бар. Туган якларында калып, күңел ярларының бер ягыннан икенче ягына бәргәләнгән тынгысыз уй-хисләрен тәртипкә китерәсе бар әле аның. Бу уйларның иң күбесе Зөһрә хакында иде.

Ничек ул анда? Ни уйлап яши икән? Таһир хакында: «Тагын китеп югалды, юньсез икән», — диме?

Әллә хат язып салыргамы үзенә? Таһир Казанга барып чыкканчы шушы хат ике арада сукмак булыр иде… «Зөһрә, кадерлем! Миңа тагын бераз вакыт бир. Күп калмады инде, мин ул очрашу көнен күрәм, тоям… Көт, аз гына көт, кадерлем!» — дияр ул бу хатында.

Юк, юк, күп язды инде ул хатларны. Зөһрәгә болай да кыен. Ул бит көтә дә көтә, көтә дә көтә… Юк, Таһир үзе барырга тиеш, һич кичекмәстән барырга тиеш!

Шулай да, күргәзмә ачылырга берничә көн кала, Казанга Хәсәнша карт үзе генә китеп барды. Аңа берничә шәкерте иярде.

## 7

Рәссамнар конкурсында җиңеп чыгуы хакында Таһир юлда, автобуста барганда ишетте. Кайчандыр Чүлмәк бүләк иткән кечкенә транзисторыннан Татарстан хәбәрләрен тыңлап бара иде. Диктор тантаналы тавыш белән игълан итте: «Казан шәһәренең Үзәк күргәзмәләр залында узган яшь рәссамнар конкурсында Татарстаннан Таһир Сәлмәновның «Сало, Кирпеч, Чүлмәк, Бөке, Люмин һәм башкалар» дигән портретлар циклы Беренче премиягә лаек булды. Якташыбызны шушы олы җиңүе белән котлыйбыз һәм алдагы иҗатында яңадан-яңа казанышлар телибез!»

Таһир ничек Казанга барып җиткәнен, ничек Үзәк күргәзмәләр залында пәйда булганын сизми дә калды. Бөтен стеналары сурәтләр белән шыплап тулган заллар умарта оясы кебек мыжлап тора иде. Таһирны беркем дә белми, танымый. Бу — яхшы. Ул үзе дә беркемне белми. Шуңа күрә кыенсынмыйча, рәхәтләнеп карап йөрергә була.

Ләкин монда бик алай җәелеп, рәхәтләнеп йөрерлек түгел икән шул. Залдан залга күчә-күчә, үз эшләре элengән бүлмәгә барып җиткәнче шактый вакыт узды. Ләкин Сало, Кирпеч, Чүлмәк, Бөке, Люмин сурәтләре карап торган стенага барыбер якын килә алмады. Бу кадәр кеше арасыннан түргә үтәргә мөмкинлек юк иде.

Таһирга баскан урынында таптанып торудан башка чара калмады. Ул янәшәсендәге ике сакалбайның сөйләшүенә колак салды.

— Кем ул — Таһир Сәлмәнов? — дип сорады аларның яшьрәге.

— Белмим шул. Колакка кергән исем түгел. Тумышы белән Түбән Кама ягыннан икәнен беләм.

— Чит илдә берәр студиядә укып кайтты микән әллә? Безнең сәнгатьтә өр-яңа юнәлеш бу.

— Күрәсең, шулайдыр… Дөньяның чикләре киңәйгән бу сурәтләрдә.

— Шәхес бар монда. Ә шәхес вакыт чикләренә сыеша алмый. Монда бер якка да чик юк. Зур сәнгать бу, яңа сәнгать…

— Килешәм. Әмма талант ярсулы елга кебек ул. Елгага да ярлар кирәк.

— Анысы шулай. Бу сәнгатьнең ярлары булса, ул — мәхәббәт. Шушы сукбайларның йөзенә кара әле. Күзенә кара. Ниндидер олы хис бар анда. Аның да ниндие! Тормышка, яшәүгә, кешеләргә мәхәббәт! Пародокс, әмма факт! Менә бу теләнче малайга игътибар ит. Ул ач, ул ялангач, ятим, аның беркеме дә юк, әмма ул дөньяны үлеп ярата! Ватан дигәннәре аларны чүплек башына, вакыт елгасының баткак ярына чыгарып ташлаган, әмма бу кешеләр шушы Ватаннарын үз итәләр. Димәк, алар — чын кешеләр, иманлы затлар. Иманлы кешеләрдә генә Ватан хисе, ил тойгысы, халык гаме була…

— Чынлап та, иманлы дөнья бу. Каргышлы, гарип дөнья, әмма иманлы да!

— Әйе шул, кешенең иманы булмаса, аның яхшы тәртибе бернигә тормый. Ә без боларны буташтырабыз. Кешенең киеменә карыйбыз, тәртибенә карыйбыз. Бу кием астында нинди йөрәк булуы хакында уйлап та тормыйбыз. Ә тәртипне уйнап була. Күпме артист йөри менә бу кешеләр арасында! Театрга килгәннәр. Үзләрен күрсәтергә килгәннәр, ник бер күтәрелеп карасыннар шушы сукбайларга… Заман сурәте менә шушында! Теләгән кеше килсен дә карасын!

— Күбрәк беләсе иде бу циклның авторы хакында!

— Кулын кысасы иде…

Таһирның күңеле тулды. Аның бу ике кеше янына барып: «Мин ул Сәлмәнов Таһир, мин!» — диясе, бераз мактанып аласы килде. Ләкин Таһир шулай уйлады гына. Ул бер дә мактанчык түгел, хәтта бөтенләй дә мактанчык түгел. Бу шыгрым тулы зал эчендә аңа кыен иде, һәм ул, кешеләргә бәрелә-сугыла, урамга чыгып китте.

Колагына баягы таныш сүзләр ишетелгәләп калды:

— Кем соң ул — Таһир Сәлмәнов?

— Кулын кысасы иде!

Хисләр тулышкан күңелен алып, җиләс дөньяга килеп чыккан Таһирны каршы алган урам бу минутта сабантуй мәйданыннан бер дә ким түгел иде. Нишләр иде икән ул бу сабантуйда,әле ярый бер як читтән Хәсәнша карт килеп чыкты. Тирә-яктагы халыктан ул аклыгы, сафлыгы белән аерылып тора. Ак чәчләре өстенә киеп алган яшел түбәтәе аның илаһи бер дөньядан килгән булуына ишарәләп тора кебек… Менә шул изге карт — татарларда Ак бабай дип йөртелә торган Хода бәндәсе — бөтен кешене каратып, Таһирны кочаклап алды.

— Таһирҗан, җиңдек бит, беләсеңме әле?

— Беләм, Хәсәнша ага…

— Котлыйм сине, егеткәй, беренче уңышың белән котлыйм! Сөендердең картлачны! Инде үлсәм дә үкенмим… Тик мин әле үләргә җыенмыйм. Яшибез әле болай булгач!

— Хәсәнша ага, ничек болай булды соң? Шулкадәр кеше арасында…

— Ышанырга кирәк, Таһирҗан. Рәссамнар күп, ә син берәү генә. Аңлыйсыңмы шуны, юкмы — син берәү генә! Илле рәссам арасында берәү генә! Тик кара аны, ышанмыйм дип, иртәгә килми калма. Иртәнге унда котлаулар була, ишетсен колагың! Бүләге дә бар — ун мең доллар. Тормышыңны рәтләргә җитә ул. Ә хәзер бар, ял ит. Стоп! Кайда тукталдың? Кунар урының бармы? Булмаса, әйдә, урнаштырам…

— Бар, бар, монда минем дусларым күп. Аларны сез беләсез инде. Портретлары буенча…

Хәсәнша карт кесәсеннән берничә чакыру кәгазе чыгарып бирде.

— Менә болары дусларың өчен. Килсеннәр, күрсеннәр… Мине дә таныштырырга онытма, кара аны!

— Таныштырырмын… Барысы өчен дә рәхмәт сезгә, Хәсәнша ага…

— Ярар, ярар… Син рәхмәтеңне әйттең инде. Мин телеграфка киттем. Җиһан әбиең белән сөйләшергә… Сәлам әйтимме?

Таһирның җавабын көтеп тә тормыйча, Хәсәнша карт кеше арасына кереп юк та булды. Ул, чынлап та, бу дөнья кешесе түгел, ахры. Аның аягы җиргә тигән кебек тә түгел. Әгәр җирнең үз фәрештәсе булса, ул шулдыр… Кызык… Һәм кызганыч… Аның сурәтен Таһир бер мәртәбә дә ясап карамаган икән…

Әнә әле анда, әле монда яшь рәссамнар җыелышып торалар. Күбесенең йөзен күрәктәй сакалмыек каплап алган. Таһирга да сакал җибәрергә туры килер микәнни? Гомер булмаганны… Болар күргәзмәгә куелган картиналарның авторларыдыр инде. Таһир мондый тормышны белми. Шуңа күрә, ул бүген беркем белән дә аралашмады, кичке якта бераз бушый төшкән залларда тәмам туйганчы йөрде дә, урамга чыгып, Мөштәри урамында сүтелә торган таныш йортка китте. Бу вакытта аның дуслары табын артына җыелган булырга тиешләр. Сало ипи теләдер, Кирпеч моңаеп утырадыр, Чүлмәк, авыз тутырып ашарлык калын телемнәр белән, колбаса кисәдер, Бөке вак-төяк белән булашадыр, ә Люмин кибеттән кайтып җитмәгәндер… Их, шулар белән бергә утырып, өстенә колбаса куелган кара ипи телеменнән авыз итәргә! Аннары «газировка» белән тамак чылатып җибәрергә… Сагындырган… Бомж тормышы да сагындырыр икән!

Бу вакытта Чүлмәк берәр мәзәк сөйлидер. Кирпеч һаман шулай моңсудыр. Ул гел моңсу. Бүген, Таһирны күрүгә, елмаеп-көлеп җибәрер иде, аның уңышына сөенер иде. Башкалар да сөенерләр. Бөке генә үзенең серле сүзен әйтеп куяр иде. Нәрсә дияр икән? Әһә! Ул, мөгаен: «Башкалардан өстен булу — башкалардан яхшырак булу дигән сүз түгел әле»,— дияр. Бу аның «Шапырынма!» дигән сүзе булыр.

Ләкин Мөштәри урамындагы йорт сүтелеп беткән, ә аның урыны җир белән тигезләнгән булып чыкты. Таһир бер барган җиреннән тукталып тормады, Кабан буена төшеп китте.

«Гаилә» тулысы белән «өйдә» иде. Табын артына утырганнар гына. Хәзер аларның чын өстәлләре, чын урындыклары бар икән. Чын өйләрдәге кебек…

Сало, иң олы кеше буларак, беренче килеп күрешеп, Таһирның аркасыннан кагып куйды:

— Хәлләр ничек, Таһир? — Ул «Таһир» сүзенә аеруча басым ясап әйтте. Чүлмәк, Таһирны күрүгә, үз телен онытып ук җибәрде бугай:

— Ну, Почта, тебя не узнать!

Бөке дә, Кирпеч тә, Люмин дә бик җылы күрештеләр. Люмин күзләрен сөрткәләп алды. Бөке дә үз репертуарында иде.

Ул, Таһирга күтәрелеп карамыйча гына:

— Кешеләр камил түгел, кешеләр бер-берсенә мөнәсәбәттә генә камил була алалар, — дип, Таһир белән очрашуның рәсми өлешенә үзенчә нокта куйды.

Шау-гөр килеп, өстәл тирәсенә утырыштылар. Сало аш бүлә башлады. Тәлинкәсендә сало кисәге күреп, Таһир үзалдына елмаеп куйды. Чүлмәк ике шешә аракы чыгарды. Таһир да ике шешә коньяк, әллә күпме закуска алып килгән иде.

Шуларны исенә төшереп, ишек төбендә калган дипломатын барып алды. Болай да шыплап тулган киң түгәрәк өстәлгә бу күчтәнәчләр дә кереп бетте.

— Ну, ничек анда авылда, сөйләп җибәр, — дип, Сало иң мөһим сорауны бирде. Шушы сорауны гына көткән кебек, башкалар да, ашауларыннан калып, Таһирга төбәлделәр.

— Ничек дип… Әнкәй каберендә булдым. Абыйларда… Ә хәзер Түбән Камада торам. Эшлим.

— Казанга нинди юллар алып килде?

— Хәтерлисезме, мин сезнең портретларыгызны ясаган идем. Менә шул сурәтләрне Казанга рәссамнар күргәзмәсенә җибәрделәр. Конкурска…

— Ну, ну?

— Шул: беренче урынны алганмын.

— О-һо! Беренче премия?

— Ничә сум инде ул?

— Ун мең…

— Нинди төстәгесе?

— Валютада…

— Да, повезло…

— Состояние бит бу!

— Кая куясың бу акчаларны?

— Белмим әле…

— Безгә ышан: кая куярга икәнен әйтербез…

— Йәгез әле, шаярмагыз… Беләсеңме, син тот та Казанда бер йорт ал!

— Туктагыз әле, кулга кермәгән акчаны бүлеп утырмагыз, ә! Аннары... мин Казанда яшәргә җыенмыйм да...

— Ә Зөһрә? Зөһрәне кая куясың? Алып китәсеңме?

Салога Чүлмәкнең салулап каядыр кереп китүе ошап бетмәде булса кирәк, ул Таһирга барысын да үзе җентекләп сөйли башлады:

— Без бит хәзер Зөһрәдә эшлибез. Ул барыбызны да үз мәктәбенә эшкә алды. Мин — завхоз, Бөке — вахтада, Люмин — слесарь, Кирпеч — ташчы, плотник… Чүлмәк кенә иректә кеше булып йөри әлегә… Тиздән аңа да эш табылачак… Юк, син берни дә уйлама. Без эш сорап бармадык, Зөһрә үзе килде. Сине сорашып килде, өенә чакырды, эш бирде… Без берничә мәртәбә кунак та булдык аңарда… Ул сине һаман да ярата, Таһир… Ярата һәм көтә…

— Көтә, Почта…

Таһир ышанырга да белмәде, ышанмаска да җөрьәт итә алмады. Дөрес түгелдер бу, шаярталардыр, дип уйлады. Аннары, шундук бу уеннан кире кайтты. Юктыр, шаяртмыйлардыр. Сало бит ул… Сало шаяртмый…

— Минем хакта берәр сүз әйттеме?

— Юк, сорашты гына. Елады. Бик нык елады…

— Ярата ул сине, Почта. Бар син аның янына, көтә ул сине, көтә…

— Барам, барам… Тик бүген түгел. Иртәгә. Ә бүген сездән кемдер бара.

— Ничек инде?

— Иртәгә булачак тантанага чакыру илтергә кирәк. Тагын бер мәртәбә генә булышыгыз, ә?

— Аңлыйм, аңлыйм… Люмин, хәзер үк йөгер. Сиңа үз өлешеңне калдырырбыз… — Салонның сүзе кире кагыла алмый торган катгый әмер булып яңгырады… — Тик… бердәнбер көнне безнең изгелек явызлык булып әверелмәсме?

Шунда Бөке телгә килде:

— Кеше изгелек кылганда да, явызлык эшләгәндә дә беркем күрми дип уйлый. Кеше бервакытта да ялгыз түгел, аның янында һәрвакыт Ходай Тәгалә тора.

Шуның белән шул. Берьюлы барысы да хәл ителде. Ялтыравыклы чакыру билеты тоттырып, Люминне Зөһрә фатирына җибәрделәр. Таһир хакында ялгыш та сүз ычкындырмаска куштылар. Калганнар, Люминның өлешен бер як читкә куеп, күчтәнәч коньякка ябырылдылар…

Ни хикмәт — бүген беркем дә исермәде. Чүлмәк, гадәттәгечә, мишәрчәләп, моңлы җыр сузып җибәрде. Аннары Сало җырлады. Ахырдан бергә җырладылар… Хәтта Кирпеч тә кушылып җырлады.

Бөке кушылмады. Ул бүген аеруча уйчан иде. Моңсу иде. Сагышлы иде. Шуңа күрә, аның кинәт кенә, искәрмәстән генә:

— Бәхет бервакытта да ялыктырмый,— дип әйтеп куюын беркем дә аңлап җиткермәде.

Аңлап бетермәсә дә, Таһир күңеленең кайсыдыр җире белән тойды: бу сүз иң беренче чиратта аңа атап әйтелгән иде.

Әйе, ул бүген бик бәхетле. Сизеп тора — олы бәхетенең башы гына әле бу. Табылдык хатлар җыючы Почтадан бөтен дөньяга билгеле рәссам Таһирҗан Сәлмәновка әверелү вакыты. Җиде ел элек югалткан Зөһрәсен тапкан көне… Бу бәхетле тарих әнә шул табылдык хатлардан башланды да инде. Хәзер кайда икән аның хатлар коллекциясе? Ул бит аларны шушында калдырып торган иде. Исәнме алар? Әллә?

Таһир авызын ачуга ук, Чүлмәк эчке бүлмәләрнең берсенә йөгереп кереп тә китте, шунда ук, кулына бер олы кап тотып, килеп тә чыкты:

— Менә, әзи, синең хатларың. Берсен дә югалтмадык, бөртекләп сакладык. Все же, сәер кеше син, Почта. Нигә инде сиңа бу хатлар?

— Белмим. Үзем дә белмим. Тик алар кадерле миңа. Иң кыен чакта мин шуларны укып юандым. Андагы тарихлардан гыйбрәт алдым. Бу хатлар минем кешелегемне саклап калырга булыштылар…

— Ышанам, әзи. Сүзнең көче зур аның…

Таһир һәр хатны тотып карап, ниндидер кадерле әйберен иркәләгән кебек, аларны сөеп, сыйпап чыкты. Ә болары — ачылмаган хатлар. Биш хат… Биш язмыш. Кешеләр ачарга теләмәгән, укырга, белергә теләмәгән биш тарих…

Үзе дә сизмәстән, Таһир хатларның берсен ачып укый башлады. Гүя, бу үзе түгел, ниндидер көч, тылсым аның кулыннан йөртә, аның күзләреннән карый, хәтта бөтен зиһенен, аңын биләп ала…

*«Исәнме, Гөләндәм сеңлем! Сиңа күптин-күп, чуктин-чук сәламнәр кушып хат язучы Мәйсәрә апаң дип белерсең. Күптин-күп сәламнәр шулай ук барча туганнардан, таныш-белештән, авылдашлардан.*

*Син исәнме-саумы — белмим. Киттең дә югалдың. Адресың алышынган дип тә әйтәләр. Барыбер хат язарга булдым. Син алып укымасаң да, Ходай Тәгалә күрә ул, белә ул. Шаһитым ул булыр. Ярдәменнән ташламас, иншалла.*

*Гөләндәм сеңлем! Мин гомерем буе ялгыз яшәдем. Мәхәббәтемне югалткач, бер ирнең йөзенә дә күтәрелеп карамадым. Хәзер яшем олыгайды. Янымда таянычым юклык көннән-көн ныграк сиздерә. Менә шул. Сездә бит төрле-төрле танышу урыннары бар. Бер әйбәт кенә татар абзые килеп чыкса, таныштыр әле, сеңлем. Мин үзем дога белән сөйләшәм, намаз иясе булып йөрим. Бу ягын да искә ал. Иң мөһиме, әйбәт кеше булсын. Мин аны хөрмәтләп, кадерләп яшәтер идем.*

*Гөләндәм сеңлем! Беренче мәртәбә күңелемне ачтым, серемне бүлештем. Көлмә, яме. Аңла карт апаңның ятим йөрәген. Ялгызлык нык ялкытты. Шуңа да язам. Хәерлегә булсын.*

*Барысы өчен дә рәхмәт. Изге теләкләр белән, апаң Мәйсәрә».*

Таһир хатны кычкырып укып чыкты. Бүлмәдә тынлык урнашты. Һәркемнең үз уе, үз фикере.

— Каяле, китер әле монда ул хатны. Адресы бармы? — Сало, кыю гына үрелеп, Таһир куллындагы хатны тартып алды. Үзалдына укый башлады…

Таһир икенче конвертны ачты. Сукбайлар өстәл тирәсенә якынрак елышып утырдылар. Алар тагын бер язмышның, бу язмышка ияреп, тагын бер могҗизаның дөньяга тууын көтәләр иде булса кирәк.

*«Дамир балам!*

*Сагынычлы сәламнәр белән хат язучы әниең дип белерсең. Хатыңны алдым. Әмма ул мине куандырмады. Син «Әтисез яшәү кыен» дип язгансың. «Әтиең син туганчы ук ташлап китте» дигәнне ко-*

*лагыңа да элмисең. Һаман «Башка эти табарга иде, әйбәт абыйлар, безнең кебек үк ялгыз кешеләр күп бит» дип язасың. Анысы шулай. Ләкин мин — татар хатыны. Таныш түгел ир-атка: «Минем тормыш юлдашым бул, ирем бул», — дип, ничек күзләремне күтәреп әйтим? Ә якын танышлар арасында юньле кеше очрамады... Ачуланма, битәрләмә, балам. Язмышыма язса, яңа әтиең дә булыр әле. Бардыр ул, кайдадыр йөридер, ул да бәхетен эзлидер.*

*Ә син интернатыңда әйбәт яшә. Тәрбиячеләрне тыңла. Укуыңда тырыш. Хат язып тор. Яратып, сөеп, үбеп, әниең Мәйсәрә».*

— Каян бу хат? — Чүлмәк аягүрә басты.

— Чистайдан.

— Бир әле миңа... Ә нигә? Мин бер малайны гына аякка бастыра алмаммыни? Малае янына кызы да булачак әле!

Могҗиза дәвам итте. Өченче хатта да ялгыз, ятим язмыш бар иде. Бөтен гомерен балалар укытуга багышлаган, соңыннан диссертация язып, фәнни институтка күчкән бер ханым үзенең элекке иренә хат яза. *«Мин сине бик-бик яраттым, гомерем кебек күрдем. Ә син: «Миңа фәнгә чукынган мондый сәер хатын кирәк түгел», — дип китеп бардың. «Синңа беркем дә карамаячак», — дип түбәнсеттең. Ә мин әйтәм: караячак. Үзем кебек үк сәер бер җан килеп чыгачак әле каршыма. Аңлаячак ул мине. Һәм... яратачак! Бу хатымны шуның өчен генә язам: син мине мәңгелеккә югалттың, дип әйтү өчен генә...*

*Мәйсәрә».*

Сорамаса да, Таһир бу хатны Бөкегә тоттырды. Бөке карышмыйча алды. Әмма Сало белән Чүлмәк кебек тиз генә укырга ябышмады. Күзләрен өй артындагы, хәтта ерак офыклар артындагы бер ноктага төбәп, үзе генә белгән уйларын уйлый иде ул. Күрәсең, күңелендә, очы очка ялганып, берберсенә берегеп бетмәгән моңнар, сагышлар, гамьле хатирәләр шактый калган булгандыр...

Дүртенче хатны күңелне авырттырмыйча уку мөмкин түгел иде. Анысын да Мәйсәрә исемле хатын яза. Бу хат, бүтән хатлардан аермалы буларак, язылып та салынмыйча калган булып чыкты. Адресаты да юк. Биектау авылында яшәүче бу хатынның хәлен аңларга була. Ул дүрт иргә чыгып караган, әмма берсеннән дә рәхәт күрмәгән. Һәрберсеннән берәр бала калган. Аңардан туганнары, якыннары йөз чөергән. Япа-ялгыз калган Мәйсәрә эчүгә сабышкан, тормышның төбенә төшеп җитә язган. Балаларын төрле интернатларга таратып бетергәннәр. *«Кешеләр!* — дип яза ул. — *Арагызда мине аңлардай берәр җан-бәгырь юкмы? Йорт-җирем бар, уңган кулым бар. Шундый кеше чыкса, тормышымны җайга салу өчен, балаларымны кайтару өчен бөтен көчемне куяр идем. Мин Биектауда яшим. «Тегүче Мәйсәрә» дип сорасагыз, юлны күрсәтерләр...»*

Хат укылып беткәч, бераз тын калып тордылар. Аннары барысы берьюлы Кирпечкә күтәрелеп карадылар. Кирпеч кыенсынып китте, әмма сер бирмәде, дәшми-нитми генә, Таһир кулындагы хатны үрелеп алды.

Бишенче хат иң кызыгы иде. Таһир аны көлә-көлә укыды. Ул укып бетергәндә генә Люмин кайтып керде.

*«Исәнмесез, хөрмәтле вә гыйззәтле Галим абый Әсәнов! Шагыйрь абый! Мин Сезне матур шигырьләрегез буенча беләм. Сез мине белмисез. Мин бит бик еракта яшим. Агыйдел буендагы бер авылда. Ләкин минем Казанда яшисем килә. Мин дә шигырьләр язам. Шагыйрь булу — иң-иң олы хыялым!*

*Тик... Казанда минем бер танышым да юк. Ялгыз йөрүче берәр Урал егете күренмиме шунда? Таныштырыгыз әле, зинһар. Хат алышыр идек, аннары очрашыр идек. Ул мине Казанга чакырыр иде. Тик... Нечкә күңелле, матур җанлы кеше булсын ул. Монда хәзер бөтен егетләр дә аракыга биреләделәр. Яшермим, берсенә кияүгә дә чыгып карадым. Ул минем бөтен шигырьләремне утка якты. Мин аннан киттем. Әбием белән генә яшим. Тап әле миңа, Галим абый, бер егет. Ләкин безнең як татары булсын. Мине бу якларда туган кеше генә аңлар кебек...*

*Алдан ук рәхмәт әйтеп, Мәйсәрә дигән кыз».*

Люминга хат нык тәэсир итте. Ул, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, арты белән үк борылып утырды. Хатны кат-кат укып чыкты, аннары, пөхтәләп бөкләде дә, кире конвертка салып, куенына яшерде.

**8**

Иртән-иртүк тордылар. Соңга калыбрак ятылса да, көр күренәләр, кәефләре яхшы. Колонкадан кертелгән салкын суда шаярыша-шаярыша юынып алдылар. Якын-тирәдә бөтен йортлар сүтелеп беткән, шуңа күрә кеше-мазардан кыенсынып торасы юк. Юынып, тән язып алгач, шәрә аркаларын иртәнге кояшка куеп, тезелеп утырдылар. Сало ашарга җайлап йөри. Чүлмәк, Сало юклыктан файдаланып, әңгәмәнең дилбегәсен үзенә алмакчы:

— Ну, Люмин, сөйләп җибәр, ничек каршылады сине Зөһрә?

— Әйбәт каршы алды. Чәй эчәргә чакырды. Утырмадым. Почта хакында әйтеп җибәрермен дип курыктым.

— Әйтсәң соң? Әйбәт кенә булыр иде.
— Әйтергә кушмады бит…
— Чакыруның кемнән булуын сорамадымы соң?
— Сорады. Интектереп бетерде. «Бер әйбәт кеше бирде», — дидем.
— Ышандымы?
— Ышанды да, ышанмады да… Ул нәрсәдер сизенде, минемчә… Ләкин кабатлап сорамады.
— Кәефе ничек иде, кәефе?
— Ничек дип… Моңсу. Почта хакында сорашты. «Килмәдеме?» — ди. Чын менә, нидер сизенә ул. Шуңа да тизрәк чыгып качтым.

Сало ашарга чакырды. Кичәге сыйдан калган ризык-тәгамнәрне шундук юк иттеләр. Өстәл ялт итеп калды. Аракыга кагылмадылар.

Тантана башланырга берәр сәгатьләп вакыт бар иде әле. Һәрберсе, юынып-кырынып, иң яхшы киемнәрен киеп куйдылар. Барыбер әллә ни үзгәрмәделәр, әмма йөзләрендәге, күзләрендәге шатлык нуры, күңелләрендәге бәйрәм тантанасы бу урам сукбайларын да танымаслык итеп яшәрткән иде.

Таһир да җентекләп әзерләнде. Хәтта, Чүлмәктән күрмәк, чалбарына кадәр кызган таба белән үтүкләп куйды. Урамга чыгар алдыннан дусларына затлы чакырулар таратты.

Кузгалдылар. Ишекне бикләп алдылар.

Бөке әйтеп куйды:

— Өй ишегеңне бикләп йөрсәң дә, күңел ишегең биксез булсын!

Ләкин барыбер вакыт күп иде әле. Юл уңаеннан мәчеткә кереп, Таһирның алдагы уңышлары өчен хәер биреп, дога укытып чыгарга булдылар.

Мәчеттә кеше аз. Якын-тирәдә хәзрәтләр күренми. Бердәнбер хәзрәт каршында нindидер кеше тора. Ләкин ул бер дә мөселман әһеленә охшамаган. Сөйләшүе дә, кыяфәте дә урысча.

Хәзрәт сорый:
— Вы хто?
— Иван.
— Как, как?
— Иван Иванович Иванов.
— Уруский, ызначит?
— Да, русский.
— Мусульман, штоли?
— Нет, христианин.
— Что хочете?
— Я хочу дать деньги Вашей мечети, чтобы Вы читали молитву во благо моих близких.
— А пчаму в церковь не идешь?
— Я туда хожу молиться. Но деньги оставляю Вам, потому что точно знаю, они до Вашего Аллаха обязательно дойдут. Прочтите, пожалуйста, какую-нибудь хорошую молитву, вот Вам деньги…
— Вы от чистого сердца спрашиваете?
— Да. До этого Ваш Аллах еще не подводил. Я Ему очень благодарен.
— Хорошо. Слушай. Руку держи вот так. На всякий случай…

Хәзрәт, иренмичә, бер сүзен дә төшереп калдырмыйча, әллә күпме дога укыды, башта татарча, аннары урысча теләкләр теләде.

Йөзен сыпырып куйгач, урыс Иванының аркасыннан сөйгәндәй итте:
— Все будет ладно, хороший человек. А час иди домой… Если душа скажет, приходи…

Урыс кешесе чыгып киткәч, Таһирлар да хәзрәт каршына килеп бастылар. Чүлмәк, һәрвакыттагыча, түземсез иде.

Алар алдында әле генә булган сәер күренеш хакында сорамыйча булдыра алмады:
— Дөрес эшме бу, хәзрәт?
— Дөрес, ник дөрес булмасын. Бөтен нәрсә дә Ходай Тәгалә ихтыярында, ул гына барысын да күреп, белеп тора. Бу бәндәнең күңел төбен дә яктырта аның илаһи нуры. Анда ни барын бер Ходай гына белә. Күзләрендә ихласлык бар бу адәм затының. Ә инде урыс булуыннан шикләнсәгез, китапта әйтелгән: хак исламда бер генә милләт — мөселман өммәте генә бар, диелгән.

Сало, сүз алып, хәзрәттән Таһирның уңышлары өчен дога укуны үтенде. Хәер бирде. Шул ук теләкләрне Чүлмәк, Кирпеч, Бөке, Люмин дә кабатлап әйтеп чыктылар. Алар да хәер бирделәр.

Хәзрәт барсын да аңлады. Ул, Таһирның исем-атын төпченеп белеште дә, моңлы тавышы белән күңелләрнең иң ерак почмакларын айкый-айкый, дога укый башлады. Таһирның йөрәге җилкенеп, тәне чымырдап торды. «Иман дигән әйбер шушы икән. Бар икән ул. Әнә бөтен җирне калтырата. Җан-рухны дәртләндереп, үсендереп йөри, яшәүгә, киләчәккә өмет бирә…»

Инде эш бетте дигәндә, китәргә җыенганда гына Таһир хәзрәткә табан кискен генә борылды да:
— Минем дусларыма багышлап та дога укыгыз әле. Аларның иминлеге, бәхете, мәхәббәте өчен укыгыз...
Хәзрәт сабыр һәм игелекле иде.
Ул мөлаем, нурлы йөзе белән Таһирның дусларына берәм-берәм карап чыкты. Аннары исем-атларын сораша башлады. Бу хәлгә беркем дә әзер түгел иде. Үзләренең чын исемнәрен онытмасалар да, бу урам сукбайлары элеккеге тормышлары белән бәйле бөтен нәрсәне дә мәңгелеккә хәтер төпкеленә салып, аны авыр моң ташы белән бастырып куйганнар иде, ахры...
— Сез кем, атагызның исеме?
— Мин... Сало...
— Мөселманча исемең нинди, мулла кушкан атың?
— Мөхәммәд Гайса улы булам мин...
— Ә сезнең исем?
— Чүлмәк... Ягъни мәсәлән — Дамир Сиражи улы...
— Ә мин — Бөке. Мөселманча исемем — Байгелде Наҗарбай улы...
— Люмин... Равил Илдар улы...
— Сөбханалла, барыгыз да мөселманнар икән. Догалар беләсезме?
— Беләбез. Бераз намаз да укыйбыз... Хәзрәт, ачуланмагыз, без — бомжлар. Чын дөресе шул. Менә Таһирдан башкалар. Бомжлар да мөселман була ала бит, хәзрәт? Дөресме бу? Без бит мөселманнар?..
— Сез бомжлар түгел, туганнар. Ялгышасыз. Сез бит Ходай Тәгалә яраткан олы бер өйдә яшисез. Иманыгыз бар икән, сезнең иманыгыз — шул нигезегез, өегез була инде.
Хәзрәт, иренмичә, тәфсилләп, тагын догалар укыды, бу догаларны каршында басып торган мөселманнарның һәрберсенә багышлап, теләкләр теләп чыкты.
Юлда сөйләшмәделәр. Һәркем үз эченә бикләнеп, үз дөньясы белән яши иде. Аларның эчке дөньяларына алып керә торган ишекләр каерып ташланган да үзләре исә чын исемнәре белән илаһи-изге догага, Ходай Тәгалә ихтыярына барып ялганганнар, имеш... Шуны тою, белү Таһирга рәхәтлек бирә, ул үзенең дуслары өчен күңеленнән сөенеп бара иде.
Рәссамнар йорты аларны моңсу каршы алды. Иртәрәк килгәннәр икән. Шулай да, бу — җиңүченең үзе була, дип ышандыргач, ишек төбендә сакта торучы егет аларны үткәреп җибәрде.
Ичмасам, заллар буш чакта иркенләп карап калдылар. Сало үз портреты каршында озак кына тукталып торды. Разый булып, баш кагып куйды. Кирпеч тә үзен ошатты. Чүлмәккә, киресенчә, үз сурәте ошамады. Үзен стенада күргәч, Люминнең күзләре яшьләнде.
Бөке исә:
— Бәхет аз гына булса да һәр кешедә бар. Хәтта бәхетсез кешеләрдә дә... — дип, үтә дә мәгънәле сүз әйтеп куйды.
Күргәзмә залларына халык тула башлаганда, Таһирлар эчке залларның берсендә төрек рәссамының картиналарын карап йөриләр иде.
Ишек ягыннан ишетелгән халык тавышына борылып караулары булды, шул килеш, авызларын ачып, баскан урыннарында катып калдылар. Түрдәге зал уртасында, Таһир эшләре эленгән стенага текәлеп, ялгызы гына бер хатын басып тора. Шундый таныш хатын!.. Зөһрә... Зөһрә! Аны шундук таныдылар! Барысы да дәррәү Таһирга табан борылдылар. «Инде хәзер нишлисең?» димәкчеләр бугай. Ә Таһир... Таһир исә Зөһрәдән күзен дә алмый! Үз Зөһрәсен ул шундук таныды! Яшь-яшь, чибәр, мөлаем, мәхәббәтле, бәхетле! Әмма бераз куркынган йөзе аны бу серле дөнья белән бөтенләй үк бәйләп бетерә алмый бугай. Ул бу серле могҗизага, чынбарлыктан кучкән төшкә, әкияткә һич кенә дә ышанып бетә алмый, ахры... Ышаныр да иде, әмма могҗиза дәвамлы булып чыкты — Зөһрә шушы гаҗәеп якты, затлы залда үзенең чын язмышына, гомерлек сөйгәне булып әверелгән Таһирына тап булды...
Зөһрә тиз генә күрмәде әле аны. Стенадагы сурәтләргә карап торган килеш, эчке бүлмәләрнең берсеннән кемнеңдер утлы карашын тоеп, шул якка борылып карады.
Алар, күңелләрендә кайнаган хис дулкыннарын җыеп ала алмыйча, бераз карашып тордылар, аннары, ниндидер илаһи бер ым белән, берьюлы кузгалып, бер-берсенә таба килә башладылар. Шул ук илаһи дулкын аларны бәхетле очрашу мизгеленә китереп җиткергәндә, олы залдагы микрофон тавышы конкурс нәтиҗәләренә багышланган тантананың башлануын хәбәр итәргә керешкән иде.
Таһир белән Зөһрә бу мәлдә үз күңелләрен генә тыңлыйлар, үз йөрәкләрен генә ишетәләр иде. Алар күптән күрешмәгәннәр, бер-берсен өзелеп сагынышканнар, шуңа күрә Ходай Тәгалә бүләк иткән бу бәхетле мизгелдә алар өчен шушы бәхетле мизгелдән башка бернәрсә дә юк иде. Алар иң ихлас-изге теләкләренә ирештеләр, шуңа күрә бер-берсенең күзенә туры карый алалар: Таһир Зөһрәсе каршына бомж, сукбай булып түгел, түбәнчелеккә төшмичә, горур җаны, олы йөрәге белән килсә,

Зөһрә исә Таһиры янына саф мәхәббәтен саклап, үзенең сабырлыгы, түземлеге һәм тугрылыгы өчен, күңел күтәренкелеге кичереп килде. Шуңа күрә алар, бер-берсеннән кыенсынмыйча, оялмыйча, олы бөтен зал уртасында килеп кочаклаштылар, аннары, бер–берсенә кадер-хөрмәт күрсәтеп, тыйнак кына сыенышып тордылар. Шунда ук, фәрештәләр кебек, тын алырга да куркып, Сало, Кирпеч, Чүлмәк, Бөке, Люмин торалар…

— Таһир… Почта…

— Зөһрә… Кичер мине…

Сөйләшмәделәр. Шушы берничә сүз аларның бөтен сагышын, газабын, шатлыгын, бәхетен, кыскасы, бөтен язмышларын үзенә сыйдырган иде.

Микрофон Таһирның исем-фамилиясен кычкыра башлаганда, Сало сак кына аның кулбашына кагылды.

— Бар, сине чакыралар. Барысы да алда, кочаклашырсыз да, көлешерсез-елашырсыз да… Олы бөтен гомер алда… Ә хәзер бар, Таһир, сине анда көтәләр…

Таһир, Зөһрәсеннән аерылышасы килмичә генә аерылып, халык арасына кереп юк булды. Зөһрәне култыклаган Сало аның артыннан иярде. Калганнар да халык төркеменә таба кузгалдылар.

Шул вакыт халык ягыннан ике кеше аерылып чыкты да каршыларына килә башлады, Зөһрә аларның берсен шундук танып алды. Ул кайчандыр бергәләп загска гариза биреп йөргән юрист Таһир иде.

— Исәнме, Зөһрә, чын күңелдән котлыйм, — дип, елмаеп килеп күреште ул.

— Рәхмәт, Таһир…

— Таныш бул: минем хатыным Зөһрә.

— Зөһрә?

— Әйе, һәр Таһирның үз Зөһрәсе булырга тиеш, ди идең бит. Эзли торгач, мин дә таптым Зөһрәмне.

— Исәнмесез…

— Исәнмесез…

Шул вакыт тагын берәү халык төркеменнән аерылды. Ул да бу якка таба килә башлады. Аны танып бетерә алмадылар, әмма, күренеп тора, ак сакаллы, ак чәчле бу карт аларны таный, белә…

— Исәнме-саумы, Зөһрә кызым?

— Бик исән, кем абзый…

— Мин… ни… Хәсәнша карт булам. — Таһирның остазы мин, укытучысы… Ә менә син — Сало, син — Чүлмәк, син — Кирпеч, син — Бөке, син — Люмин… Каян беләмме? Таһир ясаган сурәтләрдән беләм. Зөһрә, мин сине дә беренче мәртәбә шул сурәтләр буенча күрдем. Рәхмәт сиңа, кызым. Үзеңнең мәхәббәтең белән, гомерең белән тормышка кайтардың син безнең Таһирны… Сезгә дә рәхмәт, туганнар. Сездән дә өлеш күп булгандыр. Иң мөһиме, сез аның игелекле, ихлас һәм моңлы җанын саклап кала алгансыз. Рәхмәт сезгә, балакайлар…

Бердәм кузгалып, тантана уза торган залга керделәр. Алар кергән чакта гына Таһирга алтын хәрефләр белән язылган дипломнар һәм зәңгәр каймалы олы конверт тапшырдылар. Арттарак торган Чүлмәк: «Почтага хат бирделәр», — дип, шаяртмакчы булган иде, Сало аның чабуыннан тартты. Вак-төяк бүләкләр дә күп җыелды. Ләкин Таһир үзе һаман телсез калып тора; ул халык арасыннан үзенә төбәлгән Зөһрәдән күз карашын ала алмый… Кемдер этеп-төртеп диярлек микрофон алдына чыгаргач кына, үзенең кайда икәнен исенә төшерде бугай.

— Рәхмәт… — дип кыюсыз гына башлап китте ул сүзен. Шушы «рәхмәт» белән бетерергә дә уйлаган иде, ләкин бер почмакта тыйнак кына басып торучы Хәсәнша картны күреп калды. Шунда ук кыюланып китте, сынын турайтты, тавышы да көрәеп, ышанычлырак чыга башлады. — Рәхмәтемнең иң зурысын менә шушы кечкенә, әмма олы кешегә — остазыма, укытучыма әйтәсем килә. Кил әле монда, Хәсәнша ага! Күрсеннәр үзеңне! Үз яныма менә шушы чибәр, мөлаем ханымны да чакырам. Ул бүген минем янәшәмдә булырга тиеш. Аның исеме — Зөһрә. Һәр Таһирның үз Зөһрәсе булырга тиеш, шулаймы? Ул минем Зөһрәм була инде. Рәхмәт, Зөһрә. Син мине гомерем буе мәхәббәтең белән саклап килдең, яшәүгә дәртләндердең, ә образың мине рәссам итте. Рәхмәт… — Кочагындагы чәчәк бәйләмнәрен Зөһрәгә тапшырганда, Таһир аның кулындагы таныш беләзекне шәйләп калды. «Чүлмәк эше бу», — дип уйлады ул. Дусларына күтәрелеп карады. Әнә алар бер читтәрәк кыюсыз гына басып торалар. — Юк әле, сүзем моның белән генә бетмәде әле. Гафу итәрсез… Мин шушы түргә үземнең дусларымны да чакырырга телим. Сез аларны беләсез дә инде. Картиналардагы сурәтләре буенча беләсез… Алар үз гомерләрендә авыр сынаулар кичергәннәр, кыен хәлләрдә калганнар, якыннарын, гаиләләрен, йортларын, хәтта исемнәрен дә югалтканнар… Әмма Кеше дигән иң төп исем-атларыннан ваз кичмәгәннәр, кешелек сыйфатларын югалтмаганнар. Минем монда басып торуымда шушы дусларымның да өлеше зур. Бүген сез мактап телгә алган сурәтләрдә аларның да йөзләре, күзләре, күңелләре чагыла! Тагын бер карагыз ул сурәтләргә — кем аларны бәхет-

сез дип әйтә ала?! Бәхетле булырга шушы үксез җаннардан өйрәнергә кирәк безгә… Мин аларны аңлыйм, мин аларны яратам! Мин сезне яратам, дусларым!

Туганнар! Тирә-юнебездәге адәм балаларына игътибарлырак, миһербанлырак булырга иде безгә! Урамда өшеп-туңып, ач-ялангач йөргән сукбайларны каргап-сүгеп яки төрткәләп-типкәләп китәргә дә мөмкин, әлбәттә. Ләкин Ходай Тәгалә күктә яшәсә дә, аның көче җирдә. Адәм баласы да шул җир туфрагыннан яратылган бит. Тәңре барсын да күрә — изгелекне савапка ала, явызлык өчен җәзасын бирә. Шуны онытмаска иде, дусларым. Ходай Тәгалә шаһит булсын, сез шаһит булыгыз — мин бу акчаны урам сукбайларын җыеп яшәтерлек йорт салу өчен бирәм. Фатир ачкычын дусларымның кулына тоттырам. Ул аларга кирәгрәк, шулаймы, Зөһрә?

Барысы өчен дә рәхмәт! Бүген мин иң бәхетле минутларымны кичерәм. Бүген мин кабаттан халкымны, илемне һәм мәхәббәтемне таптым. Менә күпме яңа дуслар таптым! Рәхмәт!

Алкышлар астында Таһирны, Таһир белән бергә Зөһрәне чәчәккә күмделәр. Сало, үз кулына килеп кергән фатир ачкычын, чынмы бу дигән кебек, меңенче кат әйләндереп карап булаша. Кирпеч, Чүлмәк, Люмин Хәсәнша карт белән ниндидер җанлы әңгәмә корып җибәргәннәр. Бер читтә ялгызы басып торган Бөкенең үз фәлсәфәсе.

Ул:

— Бөтен нәрсә дә хакыйкатьтән килә һәм хакыйкатькә китә. Бәхет ялындырып килә, әмма бер килсә, һич китәргә теләми, — дип, Таһир белән Зөһрә тарихына үзенчә нокта куя.

*2000*

## *ТИМЕРЧЕ*

*(Кыйсса)*

### 1. Фәлсәфә

Давыт нәселендәге ирләрдә ике генә исем бар — беренчесе Давыт булса, икенчесе — Тимершәех. Шулай алмашынып торган: Давытның атасы — Тимершәех, бабасы — Давыт, аның атасы — Тимершәех, аның атасы — Давыт… Тимерчеләрдә шулай булырга тиеш, шулай гына була ала икән. Йола шундый, борынгылардан килә торган гадәт шундый…

Давыт — нәселләрендә сигезенче буын тимерче. Бәлки, алдарак та тимерчеләр булгандыр. Алары төгәл билгеле түгел. Ә менә җиде буын билгеле. Чөнки аларның авылына да җиде буын кеше гомере инде! Ырыс авылының беренче кешеләре белән бергә килеп утырган Давытның ерак бабасы. Утыруын утырган, әмма аңа авыл эчендә яшәргә рөхсәт булмаган. Борынгылар уйлавынча, тимерчеләр — имчеләр-сихерчеләр, шаманнар, әүлияләр белән бер. Аларга кешеләр арасында яшәргә ярамаган. Начарлыктан да түгел бу. Гадәти кеше булмагангадыр, күрәсең. Чөнки тимерче җир тәнен сыгып тимер коя, шул җир тәнен кыяр өчен кораллар ясый. Ул Ходай Тәгалә өлешенә керә, тимерченең язмышы да Ходай Тәгалә мәрхәмәтеннән һәм бәхиллегеннән тора. Аңа Ходай зәхмәте төшсә, бу зәхмәт бөтен халыкны харап итәчәк икән. Әлбәттә инде, Ходайның рәхмәте дә төшәргә мөмкин. Тимерчеләр бит алар кешене — кеше, ирне — ир, илне ил итә торган кораллар ясыйлар, шул рәвешле илдәшләренә иген игәргә, җан асрарга, дошманнарына каршы көрәшергә булышалар. Шулай да адәм баласы, Ходайның рәхмәтенә караганда, аның зәхмәтен, каргышын күбрәк көтә. Шуңа да тимерчеләрне авылдан читкә куа. Ә бәлки… Кумыйдыр да. «Безнең кебек гөнаһлы бәндәләр белән яшәмә, әнә үзеңә аерым урын, шунда гомер сөр, ә без сиңа, синең оста кулыңа табынып яшәрбез…» димәкче булалардыр?

Давытлар нәселе дә элек-электән авылдан читтәрәк, сөзәк кенә бер тау куенында нигез корып яшәгән. Давыт үзенең хатыны белән, малае белән хәзер дә шул ялгыз йортта тора. Алачыгы да шунда гына. Сарайлары, мунчасы, ындыры, келәтләре дә, утар булып, шул тау итәгенә чәчелгәннәр…

Давытның сигезенче буын тимерче булуы әйбәт фал, әлбәттә. Әмма бу изге фал аның өчен язмыш шаяруы булып та чыкмагае… Чөнки, шул ук борынгылар сүзе буенча, җиденче буыннан соң, сигезенче буын тимерче иң көчле сихерче булып исәпләнгән, ул кубыз коярга тиеш булган, бу кубыз кешеләрне дәвалаган яисә, киресенчә, уйдан, зиһеннән яздырган, төрле шаукымнарга дучар иткән, хәзергечә әйтсәк — гипнозлаган…

Боларның барысын да белә Давыт. Каян беләме? Ә менә каян белгәнен белми. Анысы мөһим дә түгел. Белүе хак — шул җитә. Аның хәтта кубыз да эшләгәне бар. Мәктәптә оештырылган балалар ансамбле өчен җиде кубыз коеп бирде ул. Сигезне койды, берсен үзенә калдырды. Тирәнгә кереп уйлап тормады, бары тик калдырды гына. Хәтта, ирененә куеп, өреп тә карамады. Ләкин барыбер

дә колагында кубыз моңы яңгырап киткәндәй булды: ж-ж-ж җ-җ-җ… з-з-з… Зың-ң… зың-ң… ж-ж-җ-җ-з-з…

Ул бу кубызны кая куйганын да белми. Беләсе дә килми. Шаукым, гипноз белән бәйле әйберләргә кагыласы килеп тормый әле. Болай да «имче» дигән даны чыга язды…

Бервакыт «кот койдырдылар» аңардан. Һай… Ул хакта сөйләп китсәң… Бүтән уена да алмаска уйлаган иде, алмыйча булмас, ахры…

Авылдан Хәерниса дигән карчык килеп сорамаса, мәңге эшли торган эше түгел иде югыйсә. Давыт бу хәерсез йоланы ул карчык өчен дә түгел, аның үлем каршында калган оныгы өчен эшләде.

Тагын шул ук сорау: каян белә соң ул бу йоланы? Каян белсен — әнә шул җиде буын бабасыннан. Ничекме? Ә-ә… Белер идегез бугай… Шуңа күрә Давыт бу хакта дәшми кала…

Ә йоласы болай. Иң элек бөтен мич алларын, мич юлларын ачып куясың. Аннары почмакка карап, тәрәзәдән, ишектән урамга карап һәм мич авызына карап яки аңа башны тыгып кычкырасың… Шуннан соң иң кызыгы башлана: ногыт борчагы кадәр генә кургаш бөртеге аласың да корыч кашыкка салып эретәсең, аннары сулы табакка коясың. Суга килеп төшү белән, сыек кургаш бер рәвешкә кереп ката, шул каткан кургаш нәрсәне, кемне хәтерләтсә, шуңа карап фал ачалар — кешенең күңелен, гомерен, бәхетен юрыйлар…

Сүз дә юк, Давыт Ырыс авылы халкы китергән табак-савытларны рәтләп биргәли иде. Кемгә барсыннар инде — тимер-томыр, бакыр-чакыр әйберләрен күтәреп һаман шул тимерчегә киләләр. Кирәк булгач, Давыт ялындырып тормый — ямап, чүкеп, тишек урыннарына кургаш коеп, тагын берничә елга чыдарлык итеп бөтәштереп җибәрә. Ә менә им–том белән шөгыльләнгәне бик юк иде...

Иң элек авыру баланы алып кереп, түшәккә салдылар, аның янына, буе буенча сузып, ак сөлге җәйделәр. Аннары Хәерниса карчык дога укып алды, теләкләр теләде. Давыт сабыр гына үзенә чират җитүен көтте, коралларын рәтләштерде.

Хәерниса карчык имләп китергән кургаш борчак тимер мичендә бик тиз эреде.

Ул эрегән арада, Давыт кирәкле әфсенне укып алды:

Әй син, котым, син, котым,
Чакырганда кил, котым.
Хаста төште башыма,
Иясен табып бир, котым!..

Кургаш тамчысы чажылдап суга килеп төшүгә, Давытның сүзләренә Хәерниса карчык үз әфсенен ялгап китте:

Улкаемның коты чыккан,
Кил коты, кил коты!
Күгәрчен күк гөрләп кил!
Кыр казы күк тезелеп кил!
Ак җилен күк савылып кил!
Кил коты! Кил коты!

Давыт су эченнән кургаш кисәген алырга ашыкмады. Ул кургаш тамчысының су эчендә нинди рәвешкә керергә мөмкин булуын үзенчә юрарга кереште.

Кер коты, кер,
Ишектән дә кер,
Тишектән дә кер,
Ат булып кешнәп кер,
Сыер булып мөгрәп кер,
Каз булып какылдап кер,
Үрдәк булып бакылдап кер…
Кер коты, кер!..

Бала куркудан чирләп китсә, ялгыша башласа, зиһенен буташтырса, шушы йоланы башкаралар. Анысын Давыт белә иде. Әмма бу йоланың шулкадәр төгәл, ипле килеп чыгуына ул бик аптырады. Ә бит бу ырым йоласы — үтә дә җаваплы гамәл. Уйлап кына карагыз: Кот коючы турыдан-туры авыруларның җаны белән эш итә! Татарда «коты чыккан», «коты качкан», «коты киткән», «коты ботына төшкән» дигәнрәк сүзләр бар. «Коточкыч!» дигән сүз дә хәтәр хәлләргә карата әйтелә. «Котырган» сүзен генә алыгыз. Дөресе — «коты орган». Менә шуларга каршы оештырыла да инде «кот кою» йоласы. Шул йола белән кешенең яшәү гамен, аңын, акылын, сәламәтлеген, ягъни язмышын, җанын, бәхетен кайтарырга тырышалар… Әйе-әйе, «кот» дигән сүз белән «җан» гына, хәтта «гомер» генә дә бәйләнмәгән, ул турыдан-туры «бәхет» дигән төшенчәләргә килеп тоташа.

Ә Ырыс авылына гомер-гомергә бәхет ялындырып кына килгән. Бәхет хакындагы хыяллары шулкадәр көчле булган ки, хәтта авылга да Бәхет дип исем биргәннәр. Әйе-әйе, «ырыс» сүзе борын-

гылыкта «бәхет» дигәнне белдергән. Ырыс капка да нәкъ шуннан килә. Йортка бәхет алып керүче капка булган ул! Ырыс авылында да күп андый «бәхет капкалары». Бу капкалар шундук күзгә бәреләләр — аларның түбәләре була, шул түбәләренә кояш яисә ай уелган була. Давыт үзе генә дә каладан күпме ай, кояш ясагандыр шушы ырыс капкалар өчен!

Әмма барыбер авылда бәхет артмады. Аның ташлы басуларында иген дә әллә ни уңмады, гомер бакый халыкның тамагы туймады, тормышы бөтенәймәде. Хәзер бигрәк тә эшнең рәте китте. Колхозлар таралды; андагы бөтен техника, кирәк-ярак урланды, халык эчә башлады, эшсез калдылар, башларын юләрлеккә яисә азгынлыкка салдылар. Кемдер дингә бирелде, кемдер базарга — акчага…

Хәерниса карчыкның оныгына «әтәч» төште. Аны утка, таңга, вакытка, димәк, озын гомергә юрадылар. Аннары бәхеткә юрадылар. Ничек кенә килеп чыккандыр, әмма Хәерниса карчыкның бәләкәй арбага утыртып алып килгән оныгы үз аягы белән кайтып китте. Шул көннән соң авыл халкының Давытка мөнәсәбәте үзгәрде, аңа Имче дигән исем тагылды. Әмма бу исем белән генә аның күңеленә юл сала алмадылар — ул бүтән «кот коймады»! Самавырлар ябыштырып, тырмаларының сынган тешләрен утыртты, атларын дагалап җибәрде, кубыз, курай эшләп бирде, әмма сихергә кагылмады. Чөнки белә иде — кешеләрнең бәхете Ходай кулында. Алай гына да түгел, иң элек үзләренең кулында! Кеше үз язмышына үзе хуҗа булып яшәргә тиеш. Ходай юл гына күрсәтә ул, ләкин синең язмышыңа ия була алмый. Ул — синеке генә, башка беркемнеке дә түгел!

Давыт үзен бәхетле кешегә исәпли. Аның һөнәре бар, бөтен, тигез гаиләсе бар, дәвамчысы — Тимершәех исемле малае бар… Өстәвенә аның якты дөньясы, Кояшы, Ае, урман-кырлары, сулары, чишмәләре, таулары бар… Йөрәге, җаны, иманы бар аның. Кыскасы, язмышка лаеклы кеше булу өчен кирәкле бөтен нәрсәсе дә бар. Шуңа күрә Давыт үз эшен эшләп, үз җаен җайлап кына яши бирә. Тимерче авылга һәрвакыт кирәк. Иң соңгы трактор сүнеп, иң соңгы тырманың иң соңгы теше төшеп, иң соңгы атка иң соңгы дага кагылгач кына кирәкми башлаячак ул. Ләкин, шушы җир булганда, бәхеткә сусаган адәм балалары булганда, аларның күңелендә соңгы өмет тамчысы калганда боларның берсе дә бетмәячәк, шуңа күрә Давытка борчылырга урын юк. Һәр кеше гомерендә терекләнгән дөнья белән мәңгелекне тоташтырып торган юллар барыбер, бер килеп, аның җиргә сеңгән алачыгы аша узачак…

## 2. Тереклек

Давыт яратып өйләнмәде. Кызганды ул үзенең Зәлләсен. Әти-әнисе кышкы буранда калып туңгач, әбисе белән генә үскән кыз ул. Әбисе әлеге дә баягы мәңгелек юлларына китеп баргач, кыз бөтенләй ятим калды. Давыт үзе барып алып кайтты. Аның үз әтисе дә дөнья куйган чак иде. Әнисе дә авыру — соңгы көрчегендә яшәп ята. Зәллә килгәннең өченче көнендә, күңеле тынычланып, ул да җан тәслим кылды.

Менә шулай яшәп киттеләр алар — Ходаның ике бәндәсе. Икесе дә сафтан-саф, иптән-ипле җаннар. Икесендә дә сер бар, шаукым бар. Бу яклап алар бервакытта да кеше теленнән төшмәделәр. Ләкин үзләре моңа бик борчылмадылар. Авылның бердәнбер бәхетле кешеләре булып яши бирделәр. Чынлап та, алар уртак бәхетләрен бик тиз төзеделәр. Жәлләп кенә алган Зәлләгә Давыт чын-чынлап гашыйк булды, бигрәк тә матур малаен кулына тотып сөя башлагач, бөтен күңелен хәләл хатынына юнәлтте, гомерен дә аңа багышлады.

Соңгы вакытларда тормышлары кысылды кысылуын. Зәллә күптән инде колхоз эшенә йөрми. Эшлисе килмәгәннән түгел, эш юктан. Колхозның рәте киткән, Давыт кулыннан да эш төште. Түләү бетте, ризык каты-котыланды. Шулай да, сирәк-мирәк кенә булса да, теге тимерне чүкергә, бу калайны кисәргә яисә арба кендеге ясатырга киләләр. Шул вакытта рәхәтләнеп эшләп кала Давыт. Зәллә дә килеп булыша башлый. Малайлары бер читтә карап утыра. Давыт шуңа күнеккән: берәр мөһим эшкә керешкәндә, Тимершәехне янында тота, күрсен, шушы саф, чиста, гөнаһсыз күзләре белән барысын да ятлап калсын, ди. Давытны да әтисе шулай үстергән, гел үз янында йөрткән.

Их, иртәрәк дөнья куйды шул ул. Югыйсә бик тә таза, сәламәт кеше иде үзе. Илле яшен дә тутырып бетерә алмыйча китте. Илле яшь — тимерчеләр яше. Шундый сүз бар. Тимерчеләр шулкадәр генә яшиләр. Давыт моны белә. Әмма эшен дә ташламый. Ничек инде язмышыңны ташлыйсың ди, ничек нәселеңнән баш тартасың?!

Илле яшьтән узарга да, озын гомерле булырга да тырышып яшәми Давыт. Барыбер язмыш бер килеп тотачак, барыбер «йөрәге яңгырап» үләчәк ул. Әйе-әйе, тимерчеләрнең беркөн килеп «йөрәкләре яңгырый»! Гомер буе сандал өстендә талпынып торган, кан тамырлары бүрткән беләкләре яңгырап тора-тора да бервакыт бу яңгыраш аларның йөрәкләренә килеп тия…

Зәллә күрек тарта, мичтәге күмерләрне яңарта, Давыт чүкеч уйната. Кайчакта алар бергә эшлиләр — Зәллә озын кыскыч белән сандал өстендәге тимерне тотып тора, ә Давыт шул тере, кызыл

чәчәкне чүкече белән «сыйпый», «назлый». Ике мәртәбә йомшак кына кагылып үтә, аннары бөтен көченә бәреп куя; шушы өченче бәрүгә аның җан көче, гомер көче салынган була. Шушы бәрү белән тимерченең көче чыга бара, чөнки тимерне шундый фидаи көч-егәрлек белән генә буйсындырырга мөмкин.

…Бүген эшләре аз булды. Көтү кууга, авылда фермер булып йөргән берәү трактор арбасы өчен ике тимер кендек чүкетеп китте. Бераздан әллә каян гына ике нәни кызчык пәйда булдылар. Курчакларын утыртып йөртә торган уенчык арбаларының күчәре сынган — шуны яңартырга килгәннәр. Кулларында икешәр күкәй. Анысы — хезмәт хакы. Давыт курчак арбасы белән булашкан арада, кызлар Тимершәех белән уйный тордылар, бераздан Зәллә аларның өчесен дә йомырка тәбәсе белән сыйлады.

Урталай сынык пычак күтәреп кергән Флорисны сәерсенебрәк каршы алдылар. Беренчедән, нык кына исерек иде ул. Икенчедән, кулындагы пычак күңелне шомландыра. Өченчедән, исеме… Флорис… Нәрсә инде бу? Исем — кешенең җаны белән тоташкан була бит. Шуңа күрә дә күп кенә исемнәргә «җан» сүзе ялгыйлар да. Бу Флорисның җаны нинди икән соң?

— Менә шушы пычакны рәтләп бир әле, малай, ә? Тавык чалырга дип тота идек, баз капкачын каерганда сынды да чыкты. Нигез туфрагына яшерелгән чәкүшкә артыннан төшмәкче идем… Тизрәк эшләп бир, малай, югыйсә өйдә үтерәләр…

— Юк, моннан рәт чыкмас, мин сиңа яңаны эшләп бирәм. Әзерләбрәк куйган әйберләрем дә бар.

Давыт, Флорисны ияртеп, алачыгына керде. Аңа кирәкле коралларны барлап куярга кушты. Сандал янында да кул пары булды Флорис. Икесе дә бик җитди иде. Эшләгәндә Давытның сөйләшә торган гадәте юк. Флорис та телсез калган. Ул тимерче алачыгындагы сәер дөньяга шаккатып тора, ә алачык хуҗасының тимерчеләр йоласы буенча кылган гамәлләре аны тагын да ныграк гаҗәпләндергән...

Давыт исә, мич бугазында яткан җемелдәвек күмер өеменә якын ук барып:

Ал чәчәк, гөл чәчәк,
Күтәрергә җиңел чәчәк,
Уф-уф, һоп-һоп!.. —

дип, әфсен-догасын пышылдый, аннары күмерләрне ялан кулы белән бутый башлый. Давыт Флорисны күрми дә, ул шул утлы күмерләр белән сөйләшә:

Күрер күзгә җиңел чәчәк,
Күтәрергә авыр чәчәк,
Аллы-гөлле матур чәчәк,
Тимә минем кулыма!..

Утка күмер өстәгәндә дә әйтеп куя торган сүз бар икән:

Ут күңелен күрәем,
Аңа азык бирәем…
Ут күңеле көр булсын,
Буйсынганы ир булсын!..

Пычак ясарга дип алдан ук әзерләп куелган юка тимерне дә серле сүз әйтеп алды Давыт.

Күмергә — тимер,
Тимергә — гомер,
Гомергә — күмер…

Ә менә бу әфсен белән Давыт кыздырып яткан күмер өеменә тимерне тыга:

Каралып керсен,
Кызарып чыксын!

Чүкелгән тимерне чыжылдатып суга тыкканда да дәшми кала алмый тимерче:

Тауга мендем, таудан төштем,
Җирдән атка атландым,
Күлгә төштем.
Чыж-ж-ж!..

…Җәлпәк тимер кисәге күзгә күренеп пычакка әверелә башлады. Йөзенә бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан Давыт үз эшеннән канәгать иде. Флорис та үзенең сәер халәтенә күнекте бугай, шаярткан булып әйтеп куйды:

— Үткер булсын, кара аны! Кайрап та бир, яме.

Давыт шаярырга уйламады да.

Кулындагы баш бармагының йөзеннән пычагын сыйпап-шудырып алгач, үтә дә җитди кыяфәт белән сөйләп китте:

— Пычакның үткенлеге кайрактан да, ничек кайраудан да тормый. Пычакның үткенлеге тимерчедән тора. Менә кара — үткен ягының ике йөзе дә бер үк авышлыкта төелгән. Болай ул үтмәсләнми, чөнки киселгән әйберне аның ике йөзе дә бер үк төрле кабул итә.

Флорис башын чайкап куйды.

Давыт, үз эшен эшли-эшли, сүзен дәвам итте:

— Элек ирнең ирлеген, останың осталыгын билендәге пычагына карап бәяләгәннәр. Пычагының үткерлегенә карап…

Флорис гомердә дә сөйләшми торган Давытның тәмам «телен чиште».

Каян гына уйлап тапкандыр, ниндидер акыл иясе кебек, башын бер якка кыегайтыбрак, уйчан гына, әмма кискен рәвештә сорап куйды:

— Ә менә әйт әле, Давыт, ни өчен бездә «пычагым да юк» диләр? Беләсеңме? Әллә белмисеңме?

Давыт «беләм» дә, «белмим» дә димәде. Сандалда кызарып яткан пычакны чүкечнең очлы башы белән төя-төя, үзалдына сөйләнгән кебек кенә сөйләп китте.

— Явыз Иван Казанны алгач булган бу хәлләр. Башы арбадан калкып торган бөтен ир затын үтереп, татарларны шәһәрләрдән, елгалардан 60 —70 чакрым читкә сөргәннәр. Иң элек татар яшәгән йортлардан бөтен пычак-хәнҗәрләрне җыеп чыкканнар. Икмәк кисәргә дә, бала кендеген өзәргә дә пычак калмаган бервакыт… Бик җәфаланган халык. Бөлгән. Талчыккан. «Пычагым да юк» дип әйтерлек хәлгә килгән. Бәгыренә төшкән аның бу җәфа. Бәй, уйлап кара, басудагы игенне йолкып җый, имеш, киекләрне тәпәч белән сугып үтер, балыкны биш бармагыңны ерта-ерта тырнап чистарт, туныңны да кисеп текмичә генә ябынып йөр, имеш…

— Шуннан? Тагын кайчан пычак тотарга рөхсәт булган соң?

— Шуннан шул. Патшаның иң зур вәзирләренә җыелып барганнар татарлар. Аларның да иң абруйлылары, иң кыюлары барган… Әйткәннәр: «Һәр гаиләгә хет бер пычак тотарга рөхсәт итегез, болай яшәү яшәү түгел бит… Юкса!.. Юкса үзебез хәл итәбез, кулыбызга пычак алабыз. Күрәләтә балаларны ачка үтереп булмый. Үзегез карагыз, без әйтәсен әйттек. Татарларны беләсез…» Рөхсәт итми нишләсеннәр! Татарлар белән шаярырга ярамаганны белгән патша. Ниһаять, һәр гаиләгә бер пычак тотарга рөхсәт ителгән, ул пычак аш-су өстәленә чылбыр белән бәйләп-кагып куелырга тиеш булган. Шул чордан калган да инде бу «пычагым да юк» дигән сүз…

Флорис Давытның сөйләгәннәрен тагын бер мәртәбә күңеленнән үткәрде дә башын чайкый-чайкый кайтып китте, Давыт исә, гамьсез генә хәрәкәтләр белән алачыгы ишегенә терәү сөяп, өенә юнәлде. Тыштан гамьсез күренсә дә эченнән яна-көя иде ул: «Дөрес эшләмәдем бугай, юк, дөрес эшләмәдем. Шундый пычак тоттыралармыни адәм баласына? Бу бит тимәс борын кисә торган пычак. Үз гомерендә берничә генә шундый пычак ясады Давыт. Барысы да бәхетсез булдылар. Берсе бүләккә ясалган иде. Ул вакытта әйтте Давыт, кат-кат әйтте: «Пычак бүләк итәргә ярамый, бәхетеңнән мәхрүм каласың», — диде. Шулай булды да. Бәхетеннән генә түгел, гомереннән дә мәхрүм калды ул кеше, шул пычакны бүләк иткән адәм кулыннан суелып үлде. Икенчесе баласыннан мәхрүм калды, өченчесе төрмәгә эләкте…

Менә бүген дә шундый «тере», «җанлы» пычак әвәләде Давыт. Ә җанлы пычак җан сораучан. Хәерлегә генә булса ярар иде, бәласез-казасыз гына үтеп китсен иде бу көн, бу гомер…

Төшке ашны чамалабрак йөри торган әлеге дә баягы шул Хәерниса карчык килеп кергәч, Давыт барысын да аңлады: авылда борчулар бар. Шуңа күрә, бөтен эшен ташлап, инде туган булып бетә язган карчыкка иярде.

— Оныгың ни хәлдә соң, Хәернисәттәй? — Зәллә дә сүз оеткысын сала белә икән. — Бер дә ияртеп йөргәнең юк…

— Кая ул! Әзмәвердәй егетнеме? Һи, балакаем, теге вакыттан соң кинәт үсеп китте бит ул. Үсә дә үсә, тотып торып та булмый үзен. Күзнеияләштерә алмыйча җәфаланабыз… Менә быел әрмиягә китеп барды. Хатларын язып тора, Ходайга шөкер…

Зәллә — акыллы хатын. Озын итеп йөртә торган чем–кара чәчләрен артка ташлый да өстәлдәге ризыкларны кунакка таба этkәләгән булып, иң мөһим сорауларны бирә. Аның зәңгәрсу күзләрендә «инде бөтенесе дә мәгълүм, авылда ни булганын гына әйтәсең калды» дигән уй яктырып китә.

Хәерниса карчыкның «теле ачыла».

— И-и, балакайларым, бәхетсезлек бар бит әле авылда. Хәлим белән Нәфисәнең Гөләш исемле кызлары үз-үзенә кул сала язган. Кияүгә чыга торган егете: «Син — кыз түгел»,— дип баш тарткан…

— Йоклап йөргәннәрме әллә?

— Йоклаганнар, ди шул… Күрше авылдан икән теге егет кисәге. Төнгә калгач, түшәк җәеп биргәннәр. Барыбер кушыласы инде дип, икесенә дә бер бүлмәгә җәйгәннәр…

— И Аллам! Нәрсә була инде хәзер?

— Белмим инде... Теге кызый «Мин барыбер яшәмим» дип әйтә, ди. Врачка күрсәткәч, анысы: «Бозылып-нитеп йөргән кызга охшамаган», — дигән диюен.

Ниһаять, Давыт та сүз кыстырып куйды:

— Бәхет ашыктырганны яратмый шул...

— Балакаем, бәхетсез кеше булмый, диләр бит. Боларның бәхете дә ялындырып килә. Ничек шуны яшьләргә аңлатасы? Ничек бу хакта бәхетнең үзенә белдерәсе? Аңа: «Кеше язмышы хәл ителә, берүк соңга кала күрмә», — диясе... Җаннар белән шаярырга ярыймы соң?

Шунда сүз бетте. Хәерниса карчык тынычланып кайтып китте. Тимерче Давыттан нидер өмет итеп китте. Хәзер ул авылга кайтып әйтәчәк. «Имче Давыт барыбер болай гына калдырмас, бер-бер хәл кылыр — яшьләрне татулаштырыр», — дип әйтер. Хәерниса карчыкның өмете бөтен авылның өметенә әверелер... Шулай итеп, Давыт, бер-берсе белән аңлаша алмаган, үз тәннәренә һәм үз күңелләренә баш була алмаган ике яшь кешенең язмышы өчен җавап бирә торган бердәнбер кеше булып әверелер...

Эшләр болайга китсә, Ырыс авылы, тәүбә-тәүбә, ике яшь йөрәкне ялгыштырган Иблисне генә түгел, һәрнәрсәдән өстен булган Аллаһы Тәгаләне дә оныта башламагае...

Хәерниса карчык чыгып китүгә үк, Давытларга, Коръән мәкамендәге кебек моңлы итеп исәнләшеп, Хәмзә бабай — авылның могтәбәр мулласы килеп керде. Алла исемен күңелгә алуның бер галәмәте булды, ахры, бу. Тимерче Давыт өенә дога иясенең беренче керүе иде. Ул шундук ишек башында эленеп торган шәмаилгә игътибар итте. Аңа бик озак карап торды. Аннары гына түргә узды.

Озаклап сөйләшеп тормыйча, йомышын әйтте:

— Давыт улым, авылга яңа мәчет салырга җыенып йөрибез бит әле. Картлар белән киңәшләшкәннән соң шундый уйга килдек: яңа мәчетнең аен син ясарга тиеш.

Давыт «әйе» димәде, «юк» димәде. Бары тик: «Кайчанга кирәк?» — дип кенә сорады.

Чыгып киткән чакта, Хәмзә хәзрәт, ишек башындагы шәмаилгә күрсәтеп:

— Монда нәрсә язылганын беләсеңме соң, улым? — дип сорады.

Давыт анда нәрсә язылганын белми иде. Шуңа күрә җилкәсен генә сикертте.

— Әллә ничә бабайдан килгән инде ул... Коръәнчә булгач, начар сүз түгелдер әле...

— Начар сүз түгел түгелен... «Кешене илә җенне миңа гыйбадәт кылганнар өчен генә халык иттем» диелгән бу язуда. Илле беренче сүрә бу!

Әллә ниндидер бер эчке тантана белән, әллә кисәтеп әйтте Хәмзә карт бу сүзләрне — Давыт өчен билгесез булып калды. Әмма аны тирән уйларга да салды...

Авыр уйларыннан айнырга теләгән кебек, Давыт Тимершәехне җәһәт кенә күтәреп алды да үзенең эш урынына юнәлде. Аның бүген, Иблистән дә, Ходай Тәгаләдән дә яшереп, бер мөһим эш эшлисе — «бәхет дагасы» бөгәсе бар иде.

Һәрвакыттагыча, эшен «дага әфсене» белән башлады. Дага бөгәргә керешкәндә: «Аягым — ат, кулым — камчы!» — дип әйтергә тиеш ул.

Мич кайнар килеш. Күмер бар, көч-куәте җитәрлек. Уйлап, баш ватып торасы да юк. Үз гомерендә йөзәрләгән дага койган беләге бөтенесен дә үзе эшли... Шуңа күрә тиз арада дага әзер дә булды. Соңгы эш итеп, Давыт даганың йөзенә «Бәхетнең исеме — кадер» дип чүкеп язып куйды. Бу — аның үз тамгасы, үз әфсене...

Даганы бәхеткә юрыйлар. Ырыс авылында да ишек төпләренә ат дагасы кадакланган йортлар байтак. Бу йола борынгылыктан килә. Ат кешенең юлдашы, дусты булган чаклардан. Ат бәхет китергән, муллык китергән, җиңү, дан китергән. Ат тагын... ат, ягъни исем китергән кешегә. «Бәхетле дага гына төшеп кала» дигәннәр. «Алтын дага» дигән сүз дә бар. «Ырыс аты» — әнә шул алтын дага, бәхет дагасы йөрткән ат була инде. «Ырысак атлар» дигән сүз дә шуннан калгандыр әле...

Давыт зәңгәрләнеп-көмешләнеп торган даганы, бер чүпрәккә төреп, күмергә ысланып ялтыраган халатының ян кесәсенә төшереп җибәрде. Аннары бик озак авыл ягына карап торды. Аларның хуҗалыгы авылдан өстәрәк — тау битендәрәк урнашкан, шуңа күрә, җентекләп караганда, авылдагы йортларның барысын да берәмтекләп карап чыгарга була.

Әнә ул йорт. Хәлим белән Нәфисә утары. Шуларның капка төбендә ятарга тиеш «бәхет дагасы». Гөләш — Хәлим белән Нәфисәнең бердәнбер кызлары — шушы «бәхет дагасын» капка төбеннән табып, инде ничә еллар сөешеп, вәгъдәләшеп йөргән егетен кире кайтарып алырга, үзенеке итәргә тиеш. Шуңа күрә бу сәер, әмма изге гамәлне Давыт бүген үк башкарып чыгачак, көтү генә кайтсын, төн генә җитсен...

### 3. Гыйбрәт

Һәрнәрсәнең үрнәге генә түгел, гыйбрәте дә була. Яхшылыкның да, начарлыкның да. Давыт та, үзенә аңлашылып бетми торган гамәлләр кылып, тормышына гыйбрәт, күңеленә авырлык алды.

Иң элек Хәерниса карчыкның армиядәге оныгы хакында аянычлы хәбәр китерделәр. Ул баланың хезмәттәшләре тарафыннан кыйналып имгәтелүе хакындагы бу хәбәр бөтен авылны тетрәтте. Аның артыннан ук тагын бер канлы вакыйганың шаһиты булдылар. Флорис бергә аракы чөмереп утырган җирендә, дус егетеннән «пычак алган»... Юк, моның белән генә бетми әле — Давыт «бәхет дагасын» ташлап кайткан көннең икенче көнендә үк Хәлим белән Нәфисәнең бердәнбер кызлары Гөләш үзенә кул салган. Җанын саклап калганнар калуын, ләкин бик озак мантый алмас, бераз «җиңеләйгән» дә, диделәр...

Бер авыл өчен, бер көн өчен бу кадәр кайгы-хәсрәт күп, һай күп иде. Давыт өчен баш-акыл җитмәслек хәлләр иде болар. Өч хәбәр дә кайсы яклаптыр аның үзенә кагыла, аның үз язмышыннан сурылып чыга ласа. Шул аның җанын бертуктаусыз талкып, әрнетеп тора. Нәрсәдер дөрес уйлап, дөрес эшләп бетермәде, гомумән, бик үк дөрес яшәмәде, ахры, ул. Язмышыннан узып яшәргә уйлады, Ходай өлешенә керде, Ходай эшенә тыгылды. Кешеләр язмышын гап-гади кеше хәл итә аламы соң?! Ходай Тәгалә дә кайчакта һәрнәрсәне урынына куеп чыга алмый әле...

Нишләп гади кеше булсын? Тимерче бит ул! Тимерне буйсындыра ала торган көч иясе! Җиде буын бабасыннан җыелып килгән егәре бар аның!

Давытның күңеле әле бер якка, әле икенче якка чайпалды, әле төшенкелеккә бирелде, әле, ярсып, дуамалланып, баш күтәрде... Ләкин үз армиясендә имгәнеп яткан татар егетенә дә, шешәдәш дусты кулыннан җәрәхәт алган Флориска да, сөйгәненең нахак сүзенә түзә алмыйча, беләгендәге кан тамырларын өзгәләгән Гөләшкә дә ярдәм итә алмый иде Давыт. Җан түрендә бер генә җылы уй калган: аларның барысы да исән. Исән! Тәннәре яраланса да, җаннары кыелмаган! Калганы Ходай Тәгалә кулында һәм... Давыт кулында...

Ә Давыт кулында хәзер тылсым булырга тиеш. Ул бит сигезенче буын тимерче! Ул... ул — боларның барысы өчен дә җаваплы! Ул боларның барысын да үз йөрәге, үз язмышы аша үткәрергә тиеш.

Ике көн буе үз алачыгына аяк атламаган Давыт дәррәү сикереп торды, тиз-тиз генә киенеп, җыенып, йөгерә-атлый тимерчелеккә китте. Алачык ишеген ачып керү белән, түр чормадагы шүрлеккә үрелде, ашыгып капшанган арада өстенә вак-төяк әйберләр, калай савытлар, катыргы каплар коелды. Бу шүрлекне бушаткач, Давыт икенчесенә тотынды, аннары өченчесенә, дүртенчесенә... Озак эзләнде ул. Бөтен алачыкны таратып, туздырып ташлады. Нидер хәтеренә төшерергә теләгәндәй, бераз уйланып торды. Тагын дуамалланып эзләргә кереште... Менә ул! Менә шушы агач тартма эчендә булырга тиеш аның эзләгән әйбере... Шул. Шул!

— Ж-ж-җ-җ-з-з-... Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з... Зың-ң-ж-ж-ж-җ-җ-з-з...

...Авыл бу моңлы тавышны шундук ишетте. Ниндидер илаһи күренешкә тап булгандай, сихри гипнозга эләккәндәй, сынын турайтып, башын калкытты.

— Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з... Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з... Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з...

Бу моңлы да, шомлы да көй кешеләр күңеленә иң элек курку алып килде. Курку начар хис түгел. Әгәр дә аның артында өмет тулы күңел һәм каһарман йөрәк торса. Икесе берьюлы бик сирәк биреләләр шул алар адәм баласына. Бу да куркыныч түгел. Шуларның берсе генә булса да куркуны җиңеп була, гыйбрәт алып була, тормышка кайтып була...

— Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з... Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з... Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з...

Ырыс авылында бәхет аз булса да, өмет җитәрлек... Шуңа күрә тимерче алачыгы ягыннан ишетелгән көйдә шомлы аһәң бик тиз басылды, әллә кая — таулар, офыклар артына китеп югалды. Өмет калды, ышаныч калды. Шул өмет, шул ышаныч кайгы-хәсрәтле бу авылны киләчәккә, яшәүгә, бәхет ягына алып китәргә тиеш иде.

— Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з... Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з... Зың-ң-ж-ж-җ-җ-з-з...

*2003*

## *АЛЛАЛАР КАЙДА ЯШИ?*

*(Бәян)*

* * *

*Минем бер танышым бар. Бик күп еллар элек тулай торакта янәшә бүлмәләрдә яшәгән идек. Ихлас, ачык күңелле, сабый җанлы авыл малае буларак хәтердә калган. Ул вакытта барыбыз да шундый идек...*

*Беркөнне шул танышымны очраттым. Кәттә генә киенгән берәү каршыма килеп чыкты. Чак таныдым. Якын туганын очраткан кебек килеп күреште. Хәл-әхвәл сорашу китте...*

*Урамда басып торып кына сүз бетәмени? Карышып тормадым, кайчандыр тулай торакның кысан бүлмәсендә гомер кичергән дустымның бүген ничек яшәвен бик беләсе килә иде.*

*Кыйммәтле чит ил машинасына кереп чумуга ук аңлап алдым: мул тормышта яши бу танышым. Әнә бит сөйләшүе, үз-үзен тотышы, күз карашлары да байларча хәзер аның. Ләкин күзләрендә, йөз чалымнарында бүгенге яңа татарларга хас усаллык, ерткычлык күренми... Димәк, ул элеккеге ихласлылыгын югалтып бетермәгән әле.*

*Танышымның торган йорты хәзер коттедж дип йөртелә. Өч катлы мәһабәт йорт янында сарай чаклы гаражы, ап-ак бурадан мунчасы, заманча каралган бакчалары хуҗа кешенең никадәр хәлле һәм уңган булуын кычкырып әйтеп торалар.*

*Өй эчендәге галәмәтләрне сөйләп тормыйм, мин моңа кадәр аларның күбесе хакында бу әкәмәтләр әкиятләрдә һәм чит ил фильмнарында гына буладыр дип уйлый идем. Шулай да иң аптыратканы бөтенләй бүтән нәрсә иде. Танышымның ялан чаклы йокы бүлмәсендә, ындыр табагы кадәр ятак янәшәсендә бер сәер сын-скульптура, борынгы мәҗүси бабаларыбыз телендә әйтсәк, серле «балбал» басып тора. Алтын йөгертелеп эшләнгән бу затлы сын шулкадәр гайре табигый иде — аның хатын-кыз сыны, ир-ат сыны икәнен дә төгәл генә әйтү кыен. Бу матур, әмма килбәтсез һәйкәлнең корсагы бүлтәеп алга чыккан, күкрәкләре салынып төшкән, башы кечкенә, пеләш, йөзе шадра, әмма аллаларга хас булганча, тигез, матур, хәтта мөлаем, нурлы... Читтәнрәк караганда бу зат бераз аракы шешәсенә охшаган. Тик аның нәзек, кыска булса да куллары, тәбәнәк, чатан булса да аяклары, төртек күзләре һәм зур, ачык авызы бар... Нидер кычкырып, оран салып ачылган авыз түгел бу, ашап бетерәм, кабып йотам, дип ачылган... Кыскасы, үзе нурлы, үзе шомлы әйбер бу. Иң беренче уем да шул хакта иде. Нурлы да, шомлы да булгач, алла инде бу, изге балбал, мәҗүси пот, идол...*

*Шулай да сорарга булдым.*

*— Нәрсә бу?*

*— Ә, бумы? Бөтен кеше аптырый аңа. Бу минем аллам.*

*— Ә?.. Аллаң?*

*— Нигә аптырыйсың аңа, аллам шул. Табына торган әйбер алла була бит инде.*

*— Син... Син мөселман түгелмени?*

*— Мөселман. Хак мөселман. Мәчетне хәер-садакадан, күңелемне догадан өзмим.*

*— Ә бу нәрсәгә?*

*— Кирәк. Мин ансыз — ни-ни... Иртә белән йокыдан торгач, алдына тезләнеп, куш учымны кушырып тотып, юлым уңсын, малым артсын дип сорап, ниятләп китәм: шөкер, юлым уңа, малым артып кайта. Менә бүген дә әйбәт, төшемле көн булды. Мин аңа үз өлешен кайтарырга тиеш.*

*Танышым түш кесәсеннән бер төргәк акча чыгарды да, йөз долларлык кәгазьне аерып алып, алтын сынның киереп ачылган иләмсез авызына төшереп җибәрде. Үзе шундук, кулларын күкрәк турысында бөкләп тотып, башын өскәрәк чөйде дә, күзләрен кысыбрак, йөзенә серле мәгънә чыгарырга тырышып, эчтән генә ниндидер дога укый башлады...*

*— Кызык икән... Ә күпме җыелды инде анда? — Кызыксынуым шулкадәр көчле иде, мин бу хакта сорамый кала алмадым.*

*— Белмим... Нишләп? Беләм! Бер... йөз мең чамасы.*

*— Йөз мең сум?*

*— Йөз мең доллар.*

*Миңа бу сан таныш түгел иде. Миңа бу дөнья, бу фәлсәфә һәм бу дин дә таныш түгел иде. Һәм мин китәргә җыена башладым. Тагын бер сорау бирәсем калган икән әле.*

*— Хатыныгыз, балаларыгыз бармы? — Мин «сез»гә күчүемне сизми дә калдым.*

*— Хатыным бар иде, хәзер юк инде.*

*— Аерылыштыгызмы?*

*— Озын тарих бу. Бер сөйләрмен әле. Хәзер сорама... Әйдә инде бераз утыр. Әле юньләп сөйләшеп тә булмады...*

*Бу йорттан, бу танышымнан, аның алтын сыны янынан тизрәк чыгып китәсем килде. Озаграк торсам, бу пот, бу сын, теге йөз доллар акчаны, аны гынамы, әлеге танышымның тормышын, язмышын йоткан кебек, минем үземне дә кабып йотар төсле тоелды...*

*Ашык-пошык кына саубуллашып, элгечтәге киемнәремә ябыштым. Танышым аңлап-төшенеп алды, ахры, бүтән кыстамады, матур гына озатып җибәрде. Кайтканчы күз алдымнан теге алтын пот, ә колагымнан танышымның «Озын тарих бу» дигән сүзләре китмәде.*

*Шул мәлдә минем күңелдә язучылык инстинкты уянып, калкынып куйды. Мин агулана башлаган зиһенемне, иләсләнә башлаган күңелемне бушатырга теләп, теге «озын тарих»ка җан өреп, хикәя язарга булдым.*

Айнып киткәндә, Газинур тормышның иң түбәнге баскычына чак-чак кына тотынып, дөресрәге, эләгеп тора иде. Бу «соңгы баскыч» дигәне буш аракы шешәсе булып чыкты. Кәгазеннән Гимаев бабайның көләч йөзе карап тора. Әйтерсең шушы аракыдан да ләззәтлерәк әйбер юк, махмырдан да рәхәтрәк, бәхетлерәк минутлар юк…

Үзе канау буенда ята. Салкынча. Җәй ахырында була торган салкын чык чирәм өстенә бәрхет келәм кебек сырпаланган. Томан бар… Рәшәме? Әллә күз аллары шулай томаланып торамы? Шулкадәр эчүгә… Ничә көн айныганы юк инде аның хәзер? Берәр атна бардыр… Әллә бер гомерме?

Шәһәр читенә охшаган. Авылны хәтерләткән бер катлы урамнар. Әллә үзләренең авылындамы ул? Әнкәсе янындамы? Юктыр, бер дә кайтыр кебек түгел иде. Авылы, әнкәсе хакында соңгы мәртәбә уйлаганына да бишбылтыр…

Газинур шешәсен кочаклаган килеш торып утырды, авыр, борчулы гәүдәсен өстерәп, юл читенә үрмәләп менде. Тирә-ягына каранып, тормышка, яшәешкә алып кайтырдай сәбәп, җай эзли башлады.

Тынлык. Әйе-әйе, тып-тымызык тынлык…

Томан. Әллә, рәшәме? Бүтән берни дә юк. Аннары менә шушы шешә бар. Үзе бар. Ягъни… Газинур исемле Хода бәндәсе бар. Исеме ни тора бит аның! Геройлар исеме. Газинур дошман пулеметын күкрәге белән каплап үлгән әнә. Ә ул? Бәхетсез, ваемсыз, түбән бер бәндә…

Юк, болай гына, геройлар исеменә ябышып үз-үзен оялтырга тырышып кына кайта алмаячак ул тормышка. Ниндидер бүтән нәрсә кирәк, бүтән сәбәп…

Ә сәбәп юк. Нишләп булмасын, бар, бар! Кеше, көрчегенә җиткән бер вакытында үзенә бердәнбер сорау бирә: «Яшәргәме, юкмы?» Газинур да үзенә шушы сорауны бирергә тиеш. Туктале, ул бу сорауны бирә аламы соң? Моңа хокукы бармы?

Ул болай да яшәр-яшәмәс кенә гомер кичерә. Эше юк, тормышы юк, хыялы юк. Хәтта бу яшәешеннән гаме дә, кайгысы да юк аның. Бүген үлсә, беркем дә аның хакында борчылып уйланмаячак. Әнкәсеннән башкалар, әлбәттә… Ә! Әнкәсе бар бит аның. Әнкәсе өчен яшәргә була! Бала кайгысы аны түшәккә егачак, болай да авыру йөрәген теткәләп бетерәчәк ... Ничә ел кайтканы юк инде аның? Ике, өч ел? Әллә бишме? Бер гомерме? Эшен, дустын, яшәү мәгънәсен, ихтыярын югалтуына да бер гомер узганмы? Шулай булгач, әнкәсе өчен үлгән инде ул. Ну, почти үлгән ...

Димәк… Яшәргәме, юкмы? Яшәргә… Ә нигә яшәргә? Яшәү дип атала аламы бу тормыш? Алайса, яшәмәскә… Их,әле бит юньләп яшәмәде дә, яшисе иде бераз, кешеләрчә яшисе иде… Аннары… барасы урында ни барын кем белә? Белмәгән, күрмәгән күзгә рәхәт дисеңме әллә?Нишләргә соң — яшәргәме?

Газинур шунда гына буш шешә белән сөйләшеп утырганын аңышып алды. Аны читкә атып бәрмәкче булды. Кизәнгән килеш, тыелып, тукталып калды. Нишләп? Бу шешәнең нинди гаебе бар соң? Ул да буш… Газинурның буш зиһене, буш күңеле, буш гомере кебек… Бу яклап алар игезәкләр, туганнар. Туктале, ул бит дусларча, туганнарча ярдәм итә ала Газинурга. Менә хәзер шушы тигез юл өстендә уйнатып, боргалап җибәрәчәк тә үзенә гомер, язмыш юраячак… Башы белән карап торса — Газинур яшәячәк,төбе белән борылса… Аңлашыла инде.

Газинур шулай итте дә. Кояшта каралып, җир тузанында пычранып беткән, майга катып, ялтырап торган бармаклары белән шешәнең биленнән кысып тотты да зырылдатып әйләндереп җибәрде…

Яшәү чыкты. Газинур үзе уйлап тапкан язмыш уены хакында онытып, буш шешәне, кушучлап күтәреп алып, үбәргә тотынды… Күзләреннән яшь атылып чыкты.

Ул, шешәне күкрәгенә кысып, сулкылдап елый-елый, дога укыгандагы кебек тәкрарларга кереште:

— И син минем язмышымның фалы!.. Ходай җибәргән изге-илаһи хәбәр! Ымың, ишарәң өчен мең-мең рәхмәтләр сиңа! Ярабби, мин синең мәңгелек колың булырмын…

Бераз тынычлангач та Газинур буш шешә белән әңгәмәсен дәвам итте.

Бу юлы инде аның теле белән тормыш, яшәеш, дөнья үзе сөйләшә иде:

— Яшим әле мин! Менә хәзер үк сине тиешле урынга илтеп тапшырам. Миңа синең өчен тәңкә ярым акча бирәчәкләр. Шул акчаны үрчетеп, мин ныклы, бай тормыш корырга тиеш. Әгәр бу юлы да булышсаң, сиңа алтыннан һәйкәл куячакмын, юк-юк, мин сине аллам итеп таныячакмын!

Газинур бу минутта үзенең нәрсә сөйләгәнен аңлап бетерми иде бугай. Зиһене белән күңеле берничә атна буе аракы сөременнән томаланып яшәгән кеше ни сөйләмәс тә, ни кылмас… Ләкин аның максаты шулкадәр ачык, ә җаны, рухи тоемы шулкадәр көчле иде, әгәр читтән берәү карап, күзәтеп торса, ихлас сокланыр иде, чын күңеленнән үзенең изге теләкләрен теләр иде, догаларын багышлар иде.

Дога ихлас булса, барасы җиренә барыбер бер барып ирешә, диләр бит. Газинурның ихлас догателәкләре, ант-вәгъдәләре (ә вәгъдә — иман, бу һәркемгә мәгълүм) бигрәк тә тиз барып иреште,

ахры. Әллә каян гына — әллә җәһәннәм тишегеннән, әллә оҗмах түреннән бер моңлы да, шомлы да тавыш ишетелде.

— Ярый, адәм баласы, шулай булсын. Синең теләкләрең тәкъдиреңә язып куелды. Тик шуны да онытма, адәм баласы, ант-вәгъдәң дә теркәлде, аны бозсаң — фанилыкта да, бакыйлыкта да рәхәт күрмәячәксең…

Газинур телсез калды. Зиһененә килеп ирешкән бу гайре табигый гөрелдәвек тавыш аны айнытып, терелтеп җибәргәндәй булды.

Ул, бу хәлне бик җитдигә алып, элеккечә тезләнеп торган килеш, алдындагы салкын бушлыкка баш ия-ия, тәкрарларга кереште:

— Мин барысын да эшләрмен, мин сиңа мәңге тугры калырмын, йа Илаһым!..

## 2

Бер сум илле тиен унбиш сумга, унбиш сум йөз илле сумга, йөз илле сум мең биш йөз сумга әйләнгәнче шактый вакыт узды. Эчеп, азып-тузып йөрмәсәң, шешә җыеп, шешә тапшырып та шактый акча эшләп була икән. Иренмә генә, аягыңны гына кызганма! Башың гына эшләсен! «Шешә эше»ндә баш бик кирәк. Шәһәр урамнары буенча маршрутларны дөрес билгеләгәндә, ял паркларында, стадионнарда «кирәкле кешеләр» белән сөйләшә белсәң, анда үтә торган чаралар хакында хәбәрдар булсаң гына кесәң акчадан, авызың бал-майдан өзелми…

Газинур үзендәге мондый үҗәтлеккә үзе үк аптырады. Ул юньләп ашамады, эчмәде, ачы таң белән чыгып китеп, төнлә генә кайтып керә торган булды. Беренче меңне кулына тоткач, бер шешә сөт белән ак ипи алып, «бәйрәм өстәле» оештырды. Икенче, өченче, унынчы меңнәрдә өстәл баерак иде, үзе яратмаса да, балык уылдыгына кадәр алып кайтты. Бераздан ул, иске барактан бер кечкенә бүлмә сатып алып, өр-яңа тормыш корып яши башлады.

Шешә җыеп гомер итүче Газинурдан бөтен дуслары, таныш-белешләре читләште, кайчандыр йөреп булашкан кызлары, аңа кул селтәп, кайсы-кая кияүгә чыгып беттеләр. Газинур әллә ни борчылмады, үзенең үҗәтлеген, ният-максатларын түземлегенә төреп, сабыр гына яши бирде.

Ә бер вакыйгадан соң аның «шешә бизнесы» тагын да ипләнебрәк, җайланыбрак китте, тормышы бик тиз бөтенәйде, ә максаты якыная төште…

Максат дигәннән, Газинурның әллә нинди баш җитмәслек хыялы да юк. Кешеләрчә, тигез, матур тормыш кору, гаилә төзү, балалар үстерү, бәхетле булу. Шул гына. Әмма ул шуны белеп бетерми иде — яшәү мәгънәсе, бәхет белән мул, иплe, бөтен тормыш арасындагы чик-чама кайдан үтә соң? Яшәешне, күңелнең кайсы урыннарын телеп үтә бу чик? Газинур яшь, тәҗрибәсез иде, чын тормышка әле кайтып кына килә иде… Кайтып җитә алырмы, әллә ярты юлда егылып калырмы — анысын да бер Аллаһы Тәгалә генә беләдер.

Газинурның тормышына яңа мәгънә биргән вакыйга да шул Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән эшләнде, ахры. Беркөнне аның ишеген шакыдылар. Кем булыр бу? Шәһәрдә аның беркеме дә юк ласа. Авылдан килүчеләр дә көтелми. Дуслары күптән бизеп бетте. Газинур сагайды. Бәласеннән башаяк дип, ул ишекне ачмыйчарак торды. Тагын шакыдылар, тагын, тагын…

— Кем анда?

— Ни бу… Күршең… Иван дәдәй була. Ни… Газинур, син өйдәме соң?

— Өйдә булмыйча, кем сөйләшә соң синең белән?

— Кем белә, берәр черттыр, мужыт… Дәшми торасың бит…

— Черт дәшмимени? Нәрсә кирәк?

— Ач әле, ач, ачкач сүләшербез.

Бу керәшен карты бер ябышса, тигәнәк кебек ябыша инде, моны белә Газинур. Барыбер ачтырачак… Бурычка акча сорыйдыр, исерек тәре!

Иван дәдәй бөтенләй башка үтенеч белән килгән булып чыкты.

— Ыслушай, Газый, — Газинурны ул шулай дип кенә йөртә.— Син барыбер тапшырасың бит, менә минем шешәләрне дә бергә алып кит әле, ә? Егерме тиенен үзеңә алып кал, тамакны чылатасы иде, акчасы хәзер үк кирәк… Булыш, ә?

Шулай итеп Газинур, алыш-биреш юлы белән, үзенең беренче унике сумын эшләп алды. Әйе, тик торганнан гына кулына унике сум керде дә куйды. Эшнең, базарның бу ягы да бар икән… Иң кызыгы шунда — бу базарны ул үзе оештыра ала…

Шулай итте дә. Әлеге дә баягы Иван дәдәй аша ул бөтен тирә-якка хәбәр таратты. Һәм… шешә башыннан егерме биш тиен бәрабәренә махсус пункт ачып җибәрде. Хөкүмәтнекеләр юньләп эшләми, тирә-яктагы халык тиз арада Газинурның ишегалдында торган иске сараена агыла башлады. Бу сарай калдыгы аңа барактагы фатиры белән бергә эләккән иде.

Газинур инде шешә җыеп йөрми, көне буе үз «офисы»нда шешә кабул итеп утыра. Акчасын шундук түли. Кич җитүгә, алдан ук сөйләшеп куйган кешеләр аның җыелган продукциясен машиналарына төяп алып китәләр. Аларга да өлеш төшә. Калганы да бик җиткән, тиенләп кенә керсә дә, иренмәгәч, ул тиен тиз арада бер сумга, бер йөзгә, бер меңгә әверелә…

Тик!.. Бизнес дигән нәрсәнең төрле яклары бар икән. Бер көнне, налог полициясеннән килеп, сараен пыр туздырып, штраф салып киттеләр. Бу вакытта Газинур сөйләшергә өйрәнеп беткән иде инде, матур итеп сөйләшкәч, шул ук полиция кешеләре, шул ук штраф акчасына аңа «ЧП» ачып бирделәр.

Ул арада Газинурның күңеле дә, тәмам уянып, тирә-яктагы матурлыкны күрергә, танырга өйрәнеп җиткән иде. Ул хатын-кызлар белән дә шаяртып, үз итеп сөйләшә башлады, хәтта кайберләренең күңел кылларын да тарткалап карады.

Ә беркөнне…

Газинур ул кызны күптән күңеленә алган иде. Кыш буе шешә ташыды бу кыз аңа. «Ташыды» дигәч тә, дүрт-биш шешә китерә дә, учындагы тәңкәләрне саный-саный, күршедәге ипи кибетенә кереп китә… Гади генә киенеп йөри торган, татарча тыйнак, хәтта артык оялчан бу кызый тышкы чибәрлеге, мөлаемлылыгы белән генә түгел, эчке күңел сафлыгы белән дә әсир итте Газинурны. Күзләре шешенеп беткән, йөзләре җимерек хатын-кызлар күбрәк керә шул аның алачыгына. Ә бу кыз бөтенләй башка илдән, башка дөньядан. Ул дөньяны кайчандыр Газинур да белә иде, әле дә онытып бетерми, тансыклап, сагынып яши. Бу кыз шул элеккеге таныш дөньядан изге хәбәр, илаһи ымишарә кебегрәк тоелды Газинурга.

Бервакыт кыз юкка чыкты. Бер-ике атналап күренмәгәндер… Шул ук дүрт-биш шешәсен күтәреп килеп җиткән. Газинур бу юлы аны тиз генә җибәрмәде, берәмтекләп, озак итеп шешәләрен тикшерде, аннары акча санап вакыт уздырды. Үзе каш астыннан гына кызны күзәтә. Бу юлы ул бик ябыккан, талчыккан, хәтта авырган кебек тоелды. Ниндидер кайгысы бар аның, әнә бит борчуы йөзенә чыккан. Ә үзе элеккечә чибәр, итагатьле, саф…

Газинур сорау биргәнен сизми дә калды:

— Сезгә бер-бер хәл булдымы әллә?

— Юк… Юк-юк…

— Сезнең исемегез ничек?

— Нигә ул сезгә?

— Болай гына… Бер урамда торабыз бит…

— Бүтән сорамагыз. Кирәкми…

Газинур барыбер сорашып белде. Исеме Гөлнәзирә икән. Әнисе белән генә яшәгән. Ике атна элек әнисе гүр иясе булган. Мәктәпне тәмамлагач, үзенең бөтен вакытын өч ел түшәктә яткан әнисен карап, дәвалап үткәргән. Әнисе үлгәч, беркемсез, бер тиенсез калган. Үзе дә авырый башлаган. Кеше белән дә аралашмый икән. Менә шундый хәлләр…

Газинур үзенең күңелендә ниндидер бер таныш түгел хиснең уянуын тойды. Мәхәббәт хисе түгел әле ул, мәхәббәткә омтылу хисе. Шулай була бит: сөю үзе әлегә юк, әмма аны инде тоясың, телә-сәң дә, теләмәсәң дә күңелеңә аласың… Әлбәттә, кызгану хисе дә бар. Ләкин аннан олырак, күңелнең иң изге, иң тирән урыннарыннан чишмә кебек сулкылдап агып яткан олы хис тә шунда, якында гына…

Шулай туры килде — бер килүендә Гөлнәзирә Газинур белән аулакта калды. Кызу эш көне — кеше-мазар күренми… «Нәрсә булса да булыр, тәвәккәлләргә кирәк», — дип уйлап алды Газинур. Үзе нәрсәгә яки нәрсәне, ничек «тәвәккәлләргә» икәнен күз алдына да китерә алмый иде.

Барысын да Ходай Тәгалә язмыш юлы белән хәл итте. Шешә тапшырып торган җиреннән Гөлнәзирә һушын югалтып егылды. Якын-тирәдә беркем дә юк. Газинур мондый көтелмәгән хәлдән каушап калды, әмма шундук исен-акылын җыеп, башын стенага терәп идәндә утырган Гөлнәзирәгә ярдәмгә ташланды. Аның җиңеләеп калган ябык гәүдәсен көчле куллары белән йомшак кына кочаклап, күтәреп торгызды, урындыкка утыртты, үзе бертуктаусыз: «Әй, әй! Нәрсә булды? Ач күзеңне! Әй!» — дип, ярсынып җилтерәтергә керешә. Шуннан соң гына, ата-бабалардан калган гадәтне исенә төшереп, Гөлнәзирәнең кансыз, җансыз битенә учлары белән суккалый башлады.

Кызның матур керфекләре артыннан пәйда булган пар кояштан тирә-як дөнья гына түгел, Газинурның күңел түрләре дә яктырып киткәндәй булды.

— Гөлнәзирә! Гөлнәзирә!

— Сез… Син…

— Гөлнәзирә…

— Син… Каян беләсең… минем исемне?

— Беләм инде, беләм. Мин синең хакта барысын да беләм. Хәлең ничек соң? Ну куркыттың да соң…

— Хәзер ярыйсы... Рәхмәт.

— Нәрсә булды? Авырыйсыңмы әллә?

— Авырмыйм... Хәлем генә юк...

— Юк шул... Ә хәзер дөресен әйт: ничә көн ашаганың юк инде?

— Нигә ул сиңа?

— Ничә көн дим!..

— Ике, өч...

— Менә сиңа мә. Ач торырга өйрәнгәч кенә... Шулай ярыймы инде?

Газинурның шаярырга тырышуына Гөлнәзирә тыйнак елмаю белән җавап бирде. Елмаю да түгел иде ул, әллә Газинурның чабаклавыннан, әллә күңеленә иңә башлаган яшәү дәртеннән алсуланып, балкып киткән йөз нуры иде.

Бу минутта Газинурның зиһененнән яшен тизлегендә: «Хәзер үк нидер кылырга! Бүтән җибәрмәскә бу кызны! Ул бит миңа ошый. Яратам дип тә әйтергә мөмкин. Ә менә кыз үзе яратырмы? Яратыр, нигә яратмаска тиеш ди... Начар кеше түгел лә ул... Аның яшь йөрәгеннән чыккан хисләрен, күңел җылысын, дәртле сөюен тоеп, Гөлнәзирә дә ярата башлар... Мәхәббәтле җан мәхәббәт чакыра, диләр бит... Бу юлы да шулай булыр...» — дигән уй чагылып үтте.

— Гөлнәзирә... Чык миңа кияүгә, ә? Әйдә бергә яшибез.

— Ник көләсез миннән?.. — Кызның җитдиләнеп, тартылып киткән йөзе тагын «сез»гә күчте. — Кимсетмәгез мине... Миңа кайтырга кирәк...

— Мин чынлап әйтәм, Гөлнәзирә. Көлергә уйлаганым да юк. Әйдә бергә булабыз. Мин сине күптән күзәтеп йөрим. Мин сине беләм. Иң мөһиме, син миңа ошыйсың, мин сине... мин сине яратам да бугай инде...

— Тагын көләсез...

— Көлмим! Көлмим! Көлмим! Телисеңме, бу хакта бөтен урамга кычкырам, ишегалдындагы бөтен кешегә әйтеп чыгам...

— Исәр... Тиледер син... — Гөлнәзирә битендәге моңсулыкны югалтмыйча гына елмаеп куйды. Ә бит үзенә бу тәкъдим ошый. Үзенә рәхәт. Ул хәтта бераз бәхетле дә. Гомерендә беренче мәртәбә бәхетле...

— Тиле... Тиле! Булсын тиле! Син генә риза бул, Гөлнәзирә... Ә?

— Ярый, мин китим инде, кем... Мин бит синең исемеңне дә белмим. Ә син, бергә яшик, дисең...

— Газинур мин, исеңдә калдыр, Газинур!

— Аңладым, Газинур. Ә хәзер... саубуллашыйк...

— Ничек инде — «саубуллашыйк»? Юк әле, сөйләшеп бетмәдек... Аннары, кая барасың хәзер бу хәлеңдә? Ике-өч урам үтәсең бар. Мин монда гына яшим, әйдә, миңа кереп ятып тор. Курыкма, тимим мин сиңа, эшем беткәч илтеп куярмын.

Гөлнәзирә бу юлы дәшмәде, буйсынучан кыяфәттә баш кагып куйды.

Газинур моңа гына риза булмады, үҗәтләнеп, үзенекен итте:

— Барыбер сөйләшәбез әле бу хакта! Яме? Ошап китсә, бүген үк калырсың... Менә дигән итеп яшәрбез.

Гөлнәзирә тагын җавап бирмәде. Әмма Газинурга керүдән баш та тартмады. Үз хәле хәл булгандыр шул. Үзе генә кайтып җитә алмаячагын аңлый иде, ахры... Ә бәлки... Бәлки, аның күңелендә дә Газинурга карата җылы хис калкынып куйгандыр, өмет уянгандыр. Бәхет өмет булып туа, мәхәббәт булып яши, диләр бит...

**3**

Шулай яшәп киттеләр. Әкият бу, диярсез. Дөнья бу, якты дөньяда ниләр генә булмас. Бәхете дә, бәхетсезлеге дә җитәрлек анда. Ә бу ике бәхетсез җанның бер-беренә ымсынып, тормыш гаменнән котылырга, яшәүнең мәгънәсен табарга омтылуыннан һич көнләшмик, изге теләктә булып, сак кына күзәтик...

Юк әле, баштарак алар абыйлы-сеңелле булып кына яшәделәр. Гөлнәзирәне аякка бастырырга кирәк иде. Газинур үзе дә күңелендә кайнаган хисләрен, уйларын тәртипкә китерергә тиеш иде. Бер ай вакыт үтте. Хәл кереп, өй тирәсендә йөри башлаган Гөлнәзирә һаман ачылып китеп сөйләшми, буйсынучан хезмәтче кебек, Газинур нәрсә кушса, шуны эшләп тик йөри. Ул инде елмая, көлә. Әмма күпчелек вакытта хыялында ук калган ерак ноктага текәлеп, моңаеп утыра.

Газинур үз сәгатенең җитүен аңлады. Ул болай да чак түзеп яши. Гөлнәзирәнең юка гына күлмәге аша үтәли беленеп торган зифа сыны, нечкә биле, йомры кулбашлары, калку күкрәкләре аның дәртен кузгата, канын котырта башлаган иде инде. Юк, бу ниндидер усал дәрт түгел, назга сусаган, мәхәббәткә, сөюгә ымсынган ихлас дәрт иде.

Һәм бер кичне ул Гөлнәзирәне үзенеке итте. Кыз каршы иде, хәтта үзенә тимәвен үтенеп, ялварып елап та алды. Ләкин Газинур барсын да иплe, матур итеп эшләде. Назын, татлы сүзләрен кызганмады, сөюен кызганмады. Кыз моны аңлады. Күз яшьләре аша елмаюы, инде хәзер үз итеп, яратып елмаюы шул хакта сөйли иде.

Гөлнәзирә, өй эшләреннән бушаган арада, Газинурга да булыша башлады, аларга Иван дәдәй килеп кушылды. Кайчандыр бу карт бухгалтер булып эшләгән икән, ә безнеста бухгалтерсыз булмый, Газинур аны шундук хисапчы итеп алды. Тегесе эчүен ташлады, култык астына папка кыстырып, матур, пөхтә итеп киенеп йөри башлады.

Өендә, күңелендә тыныч булгач, Газинурның эшләре тагын да җайланыбрак китте. Ул тиз арада шәһәрнең төрле почмагында шешә кабул итү пунктлары ачты. Машинасын алыштырды, «девятка» янына йөк машинасы алды, яңа офис төзетте, фатирын алыштырды. Авыл белән, әнкәсе, туганнары белән аралаша башлады, дуслары барлыкка килде. Ул тормыш, яшәеш белән, Гөлнәзирәсе белән шулкадәр мавыгып китте, хәтта эшенә дә салкын карый башлады. Ләкин бик борчылмады: «Нык-лап аякта басып торырлык тормыш кордым, тапканым җитә, артыгы нигә?» — дип уйлады ул.

Беркөнне Газинур эшенә бармыйча калды. Гөлнәзирәсе белән аеруча сөешкән таң иде бу. Шулай да булыр икән: бер-берсеннән һич кенә дә туя алмадылар алар. Бер-берсеннән аерылышасылары килмичә, иркәләнешеп, назланышып яттылар да яттылар. Өермә кебек кабынып киткән дәртләренә түзә алмыйча әүмәкләшеп алалар да, ах-ух килеп, сулышларына буылып, тагын ике якка тәгәрәшәләр. Бераз хәл алгач, тагын куллар кулга сузыла, чәчләр чәчкә, хисләр хискә бәйләнә... Изге, илаһи мизгел иде бу. Серле мизгел. Аның серлелеге дә шунда — ниндидер бик мөһим бер әйбер хәл итәлергә тиеш иде бу мәлдә. Ул хакта икесе дә беләләр, белмәсәләр дә — сизәләр, тоялар. Ачыктан-ачык сүз кушмасалар да, бу минутта Газинурның йөрәге дә, Гөлнәзирәнең йөрәге дә «ба-ла, ба-ла, ба-ла» дип тибә иде...

Беренче булып Гөлнәзирә «җиргә төште».

— Газинур, нәрсә булды сиңа бүген, эшкә соңга калдың бит, хәзер нишлисең инде?

— Берни дә эшләмим. Менә синең белән яшим. Яшәү — үзе эш түгелмени?! Сөешү, яратышу эш түгелмени?! Бәхетле булу эш түгелмени?! Ә, түгелмени?!

Шулай үзалдына сөйләнә-сөйләнә, Газинур Гөлнәзирәне киң түшәк өстендә әйләндергәләп, әвәрә китереп йөртә башлады...

Гөлнәзирә дә гомердә булмаганча көлде, шаярды бу иртәдә.Ул үз күңелендә яңа, моңа кадәр таныш булмаган бер көй тууын, бу көйнең бала гаме, бала язмышы белән турыдан-туры бәйләнгән булуын аңлый башлаган иде инде.

Шулай алар шаярышып әүмәкләшә торгач, кочаклашкан килеш, түшәк-мендәрләре белән бергә, идәнгә — йомшак келәм өстенә килеп төштеләр. Бер уңайдан янәшәдә торган өстәл өстендәге алсу шешәне дә тибеп төшерделәр. Андый шешә булмый, диярсез. Ә менә Газинурда бар. Элекеге, исерек тормышында ук тапкан иде ул аны. Табып алып кайтып куйган иде. Төсен үзгәртә торган шешә. Көндез караңгы төскә керә, төнлә яктыра, кич — күк, иртә белән алсу төс ала!

Сәер, бик сәер, тере, җанлы кебек бу шешә. Шуңа да Газинур аны сатмады, чыгарып та атмады, күпме генә сорасалар да, дусларына да бирмәде.

Менә шул алсу шешәгә Газинур тәңкәләр җыя башлады.Күп акча кергән көннәрдә шул шешәгә акча салмыйча калмый иде. Ә беркөнне... Беркөнне ул шешә сөйләшергә кереште, һәрхәлдә Газинурга шулай тоелды. Бу кичне ул аның авызына акча төшерергә оныткан иде.

— Акча, акча! Кая акча? Кая акча?

Бер уч акча салгач кына тынды шешә. Газинур моннан соң акча салырга онытмады.

Менә шул шешә төшеп ватылды.Бакыр тәңкәләр идәннең иң ерак почмакларына кадәр чәчелделәр. Шундук күңелгә моң кереп тулды. Бу моң артыннан ук Газинурның йөрәге янында бер кыл зыңлап куйды. Ул, көчәя барып, җанны өшетерлек шомга әверелде һәм, күңелен әрнетеп, җанын газаплап тора башлады.

Газинур, башын ике як чигәсеннән кысып тотып, торып утырды. Ләкин теге моң, теге шом бетмәде дә бетмәде, киресенчә, көчәйде генә.

Менә ул, еракларга китеп, тонык кына гөрелдәвеккә әверелде һәм, аермачык өн-аһәң булып, кире урап кайтты:

— Әй, адәм баласы! Кайда синең вәгъдәң, антың? Миңа биргән сүзең?

— Син... кем? Кем? — Газинур кычкырып җибәрә язды.

— Мин — синең аллаң. Шешә тотып ант иткәнеңне оныттыңмы?

— Кайда соң син? — Газинур бу мәлдә үз тавышыннан үзе курка иде. — Кайда?

— Күктә. Аллалар күктә яши, үзең беләсең...

— Ә янда гына кебек...

— Без җиргә бик нык чакырсалар гына төшәбез. Син чакырдың, мин төштем. Сүземдә тордым. Ярдәм иттем. Хәзер син сүзеңдә тор инде — миңа табынам дидең, әйдә табын!

— Мин бит мөселман.

— Түгел. Үз Аллаһыңа иман китерә алмадың син. Шуңа да ул сине ташлады. Хәзер син минеке! Минеке генә!

— Табынмасам нишләтәсең?

— Табынырсың… Акча, байлык шундук табындыра… Мин әйтте диярсең…

— Ә мин баерга теләмәсәм?

— Теләмәсәң дә баерсың. Тәкъдиргә язылган булса, байлык күктән булса да ишелеп төшә ул…

— Икесе берьюлы була алмыймыни? Байлык белән иманны әйтәм…

— Юк, байлыкның үз алласы. Ул Нәфес дип йөртелә. Иманның үз алласы. Анысын Вөҗдан диләр. Алар мәңгелек каршылыкта. Мәңгелек көрәштә… Ләкин алар бер-берсеннән башка тора да алмыйлар…

— Ничек инде?

— Шулай. Алар хакыйкатьнең ике чиге кебек — берсе кешеләргә мал, байлык тойгысы китерә, икенчесе игелеклелек, шәфкатьлелек хисе алып килә. Ә син шуларның Нәфес дигәненә баш орып ант иттең. Мин дә нәкъ менә аның ихтыяры белән килдем.

— Хәзер миңа нишләргә соң?

— Яшәргә. Калганы безнең ихтыярда. Тәкъдиreң безнең ихтыярда бит. Ничек кирәк булса, шулай язарбыз. Без инде бер язган идек. Күңелең көчлерәк булып чыкты. Мәхәббәткә юлыгып, аның ни икәнен белдең, татый алдың син. Мәхәббәт Нәфес белән бергә була алмый. Шуңа күрә, мин синең күңелеңнән мәхәббәт хисен кире алам. Йә, хуш хәзергә… Миңа һәйкәл куячагыңны онытма, кара аны! Тизрәк эшлә моны. Юкса…

Өянәге тоткан авыру кебек, түшәгендә калтыранып утырган Газинурның иләс-миләс хәлгә төшүен чамалап, Гөлнәзирә үзе дә исен-акылын җуя язды.

Шулай да, барлы-юклы һушын җыеп, сорый алды:

— Нәрсә булды сиңа, Газинур? Кем белән сөйләшәсең болай?

Газинур тынычлана башлаган иде инде.

— Алла белән… Аллам белән сөйләштем мин, Гөлнәзирә. Безнең бит үз аллабыз бар, беләсеңме шуны? Әйбәт, игелекле, итагатьле алла ул…

— Кем? Алла? Ни сөйлисең син, Газинур?

— Барысы да җайланыр, борчылма, яме. Байлыгыбыз бик тиз артачак, дөнья безнең кулда булачак… Шул. Ә хәзер… Бар, эшеңне кара. Миңа да эшемә барырга кирәк. Байлык юлы — авыр юл. Миңа хәзер өйдә бик сирәк булырга туры киләчәк, син аңларга тырыш, яме…

Газинур кискен хәрәкәтләр белән торып басты, ашык-пошык киенде һәм, салкын гына саубуллашып, эшенә чыгып китте. Әле генә хискә тулышып тантана иткән мәхәббәтле шәрә тәнен кочаклаган Гөлнәзирә таушалып, изелеп беткән түшәк читендә берьялгызы утырып калды…

## 4

Газинурның тормышы тагын кискен борылышка кереп китте. Ул үз эченә йомылыбрак яши башлады. Көне-төне эштә булды, ярсып, үҗәтләнеп байлык туплады. Озакламый ул беренче кибетен ачты. Аннары икенчесен, өченчесен, унынчысын. «Газинур» дигән аракы кибетләрен Казанның һәр урамында очратырга мөмкин хәзер.

Гөлнәзирә үзенең балага узганлыгын белгән көнне Газинур өйдә юк иде. Ул бу вакытта чит илдә фирма кибетләре белән танышып йөри иде. Телефоннан сөйләшеп белгәч, бик күп бүләкләр төяп кайтты. Ләкин артыгын эшләмәде — назламады, иркәләмәде, матур сүзләр дә әйтмәде хатынына, бер-ике көн уйчан гына йөрде дә тагын юкка чыкты, эшенә күмелде…

Гөлнәзирә карынындагы балага җан кергәндә дә Газинур товар юнәтеп Кытайда — дөнья читендә йөри иде. Бу йөрүеннән ул кеше буе алтын сын алып кайтты. Бик зур акча түләп, бер кытай монахыннан алган. Алтын йөгертелгән булса да, нурлар балкытып торса да, ул гайрәтне чигерерлек дәрәҗәдә килбәтсез һәм котсыз иде.

— Шундый бүләк буламыни? — дип аптырады Гөлнәзирә.

— Бусы — бүләк түгел. Алла кебек бу, изге сын, изге пот. Бик борынгы заманнардан — җиргә аллалар төшкән дәверләрдән калган. Мондый сыннарның эчендә җаны була, диләр…

— Әбәү, әстәгъфирулла! Ни сөйлисең син, Газинур? Теге вакытта да «Аллам белән сөйләшәм» дип аптыраткан идең… Күңелең борчылган синең, мәчеткә барып, хәер-садака биреп, иман сафландырып кайт, бар… Бала көткәндә күңел тыныч, иман якты булырга тиеш ул…

Газинур дәшмәде. Гүя хатынының өзгәләнеп әйткән сүзләрен ишетмәде дә. Ул йокы бүлмәсенең иң түренә кереп баскан, олы таба кебек корсаклы, ыржаеп торган шыксыз авызлы, киң, калку яңаклы, киң йөзле «алласы»ның кара төрткеле алсу-кызыл күзләренә текәлеп карап тора иде. Шулай сүзсез генә алар үзара сөйләшәләр кебек иде.

Гөлнәзирә беренче мәртәбә ирен танымады, беренче мәртәбә тетрәнеп тойды: Газинурдан дөнья гаме китеп бара иде. Аның ире үзенә ниндидер яңа дөнья, яңа гамь уйлап чыгарган да, шул дөньяда, шул гамь белән яши башлаган иде. Ләкин Гөлнәзирә бер сүз дә эндәшә алмады, халат кесәсеннән кулъяулыгын капшый-капшый, кухня ягына чыгып китте. Газинур исә кесәсеннән бер төргәк акча чыгарып, аны алтын сынның ачык авызына төшереп җибәрде дә хатыны артыннан иярде.

Гөлнәзирәнең күңеленә корт керде. Аның ире мал, байлык, акча колына әйләнеп бара ласа. Ул хәзер сихерләнгән кеше кебек йөри. Китә, кайта, китә, кайта... Күп сөйләшми, көлми, шаярмый... Бала хакында да сүз юк, гамь юк. Гөлнәзирә әйтсә генә теленә ала. Анда да: «Нишли анда минем банкирым?» — дип бер елмая да, тагын «сүнә», тагын җитди, моңсу битлеген киеп куя...

Ул хәзер яңа коттедж төзи. Гөлнәзирәнең әле анда барганы юк. Газинур бик чакырам дип тә тормый. «Кызыгы бетә»,— ди. Шулай да кайсы катта нинди бүлмә булачагы хакында хәбәр итеп тора.

Алып кайткан сызымнарын өстәлгә җәеп салып:

— Менә бусы йокы бүлмәсе, монысы ашханә, ял бүлмәсе, балалар бүлмәсе, сейф... — дип хисап биреп бара.

— Сейф? — дип сорый Гөлнәзирә.— Өйдә нигә кирәк инде ул? Без бит банк түгел!

— Кирәк. Кирәк булгач кирәк, — ди Газинур. — Без бит акчалы, хәлле кешеләр. Ә акчалы кешенең сейфы булырга тиеш.

Газинур күрсәткән сызымда бер генә бүлмә хакында сүз булмады. Гөлнәзирә бу хакта сорарга курыкты. Чөнки өйнең иң түрендә урнашкан ул олы шакмакка кызыл кара белән «Алла» дип язып куелган иде.

Бердән бер көнне Газинур белән Гөлнәзирә аерым бүлмәләрдә яши башладылар. Ир кешенең әйткән сүзе бәхәсләшергә урын калдырмады:

— Син бала көтәсең. Мин җайсызлыйм гына... Болай да соң кайтып бимазалап бетерәм, иң яхшысы — аерым йоклау...

Гөлнәзирә көндезләрен күптән ялгыз иде инде. Хәзер төнгелеккә дә япа-ялгыз калды. Ялгызлыктан курка ул. Бигрәк тә әнкәсе үлгәч, күршедәге исерек ирләр ишек-тәрәзәләрен дөбердәтеп йөри башлагач... Ул чакта чак кына акылдан язмый калды Гөлнәзирә. Шуңа да иң беренче кулын сораган Газинурга кияүгә чыгып китте. Хәзер ишек шакып, акырып-бакырып йөрүче юк, әмма барыбер куркыныч. Әллә нинди рухи затлар яши ди бит кешеләр белән янәшәдә. Ялгызларга тиз иялә-шәләр икән. Бигрәк тә авырлы хатыннарны ялгыштырырга тырышалар, ди. Ана карынында яткан бала җаны — рухларның иң олы нияте, иң нәфесле теләге, аларны изгелеккә, мәңгелеккә якынайтучы сихри тәгам икән. Шуңа күрә, кояш баегач, түбән рухлар авырлы хатыннарны ауларга чыгалар, имеш...

Шуларны уйлый да Гөлнәзирә калтыранып сикереп тора, күрше бүлмәдә изрәп йоклап яткан Газинур янына атылып барып керә...

— Нишлисең син, әй, хатын? Кем тисен сиңа?! Кемгә кирәк син? Аннары... менә шушы алла саклый безне... Безнең бит аллабыз бар!

Гөлнәзирә, җәймәсенә төренеп, кире чыгып китә. Ярсыган күңелендә авыр тойгылар кала. Рәнҗеми ул Газинурга, үпкәли. Ярый ла аның алласы бар... Бөтен буш вакытын шуның белән сөйләшеп үткәрә ул хәзер... Әллә инде яратмый башлады Гөлнәзирәне? Аның хатыны да, гаиләсе дә, мәхәббәте дә шул алтын пот бугай...

Ул алтын сын Гөлнәзирәнең төшенә кереп тә җәфалый. Җәфаламый да, өстенә ава. Ыржайган авызын турсайтып, күзләрен акайтып авып төштем дигәндә генә томан кебек таралып юкка чыга, Гөлнәзирә үзе дә дертләп уянып китә...

Берәр вакыт уянып өлгерә алмаса, алтын пот өстенә төшәр, изеп, сытып бетерер кебек тоела Гөлнәзирәгә. Ул үзе өчен дә курыкмый, йөрәк янында яткан баласын уйлап борчыла... Теге пот нәкъ менә шул туачак балага каныккан кебек шул. Чөнки ул нәкъ менә Гөлнәзирә балага узгач килеп керде аларның өенә, керде дә Газинурны әллә нишләтте, аның күңелен йомшартты, рухын зәгыйфьләде, иманын какшатты. Аннары хатыныннан, баласыннан аерып алды, мәхәббәтен томалап куйды...

Гөлнәзирә бу шомлы уйларыннан арынырга тырышты, бөтен күңелен, гамен туачак баласына бирде. Бүген аның иманы да, алласы да әнә шул бала иде. Газинурдан ерагайган саен, ул баласына ныграк якынайды, иренә булган хисләре суына барган саен, баласына булган мәхәббәте артты. Ләкин ул иреннән китеп өлгермәде баласына килеп җитә алмады, үз язмышын үзе хәл кылганчы, кояшлы көзнең бер көне аның гомер юлын бөтенләй башка якка борып җибәрде...

## 5

Беркөнне Гөлнәзирәне Иван дәдәй чакырып алды. Аның авырып китүе хакында хәбәр килеп ирешкән иде инде. «Керәм, керәм», — дип, эчтән көеп йөрсә дә, Гөлнәзирә бу керәшен карты янына һич барып җитә алмады. Бүген килеп үк алдылар.

— Сине дә күрер көннәрем бар икән, кызым, — дип каршы алды аны үлем түшәгендә яткан карт. Янында берничә шәм пыскый, почмакка икона сөяп куелган. Ишек төбендә карадан киенгән ике карчык чукына-чукына ниндидер дога укыналар…

— Исәнме, дядя Ваня…

— Исән дисәң дә ярый, үлгән дисәң дә була… Ярым-йорты шунда…

Үзе елмаерга тырыша. Үлем чигендә яткан бу картның күңел көрлеге, яшәүгә омтылышы Гөлнәзирәнең күңелен нечкәртеп җибәрде.

Аның күз яшьләрен Иван дәдәй күреп тә калган.

— Җылама, кызым. Мин сине җылап утырырга чакырмадым. Сөйләшергә дәштем. Ә сөйләшер сүзләр күп җыелды... Мин синең өчен бик борчылам, кызым. Тормышың гына түгел, язмышың куркыныч астында синең. Сәбәбен үзеңнән эзләп интекмә. Сәбәбен иреңнән эзлә…

— Шул хакта әйтергә чакырдыңмы мине, дядя Ваня?

— Шул хакта да. Бүтән нәрсә өчен дә… Анысы соңрак. Ә хәзер әйтә башлаган сүземне әйтеп бетерәм, бүлдермә мине…

— Әйт, дядя Ваня, нәрсә әйтәсең килсә, шуны әйт. Мин барысын да күтәрәм…

— Әйтәм… Тыңла… — Иван дәдәй күзләрен йомган килеш сөйләп китте: — Иманы какшаса, рухи ярлары җимерелсә, кеше кешелеген югалта башлый, ул үз ниятенең, үз хыялының колына әверелә… Ул ният, ул хыял еш кына Нәфес булып килә кешегә. Ирең Газинур белән дә әнә шул Нәфес дигән шайтан эш йөртә башлады, сизәсеңме, килен?

— Шуны әйтергә чакырдыңмы, дядя Ваня? Болай сөйләшсәң, китәм…

Әллә үпкәләп, әллә кыенсынып әйтелгән сүз үлем түшәгендә ятучы картны сискәндереп җибәрде.

Ул шундук бая әйткәнен төзәтергә ашыкты:

— Юк-юк, кызым, сиңа әйтәсе сүзем ул хакта түгел иде. Боларын мин күккә — фәрештәләргә якынрак торган кеше буларак кына әйтәм. Мин аларны күрәм, хәтта сөйләшәм дә. Алар арасында Нәфес тә бар. Сез аны Иблис дисез… Мин аларның күз карашларын тоям. Әнә шул Иблис Газинурга карап тора…

— Җитте, җитте, дядя Ваня! Җитте, кирәкми! Әйтәсе сүзеңне әйт тә мин китәм…

— Әйтәм… Шуңа чакырдым да. — Карт бер мәлгә башын артка ташлап, күзләрен йомып торды. — Озакламый мин үләрмен… Менә шул чакта миңа дога чыгарсың… Хак мөселманча, үзегезчә… Минем ерак бабамнар күңелләрен Аллаһыга баглаган булганнар, телләрендә Коръән догасы йөргән. Димәк, алар хәзер дога сорап яталар, минем изге юлымда аларның да катнашы бар…

Гөлнәзирә үз күзләренә үзе ышанмый иде. Аның каршында гомер буе почмактагы иконага чукынып яшәгән, ә хәзер мөселман Алласына иманын багышлаган керәшен карты ята иде…

«Ярар» димәде, «юк» димәде, тәмам вәсвәсәгә төшкән Гөлнәзирә, кискен генә урыныннан торып, чыгып китәргә җыенды. Ишеккә җиткәч, артына борылып карады. Куркынып түгел. Шундый итеп карады, гүя бу йортта, бу нигездә бер гөнаһсыз күңеленең матур бер өлеше төшеп калган иде…

Өенә кайтып керүгә, ул Газинурның авыр, усал карашы белән очрашты.

— Кайда йөрисең син?

— Дядя Ваня янына барып килдем.

— Ә, ул карт янынамы? Акылдан калып бара диләр, сак бул аның белән…

— Бер дә тиле түгел ул, миннән синнән акыллырактыр әле…

— Шулай булмый ни… Нәрсә калган сиңа анда?

— Үлем көтеп ята карт. Үзең дә бер барып күренер идең, хәлен белер идең, чит кеше түгел бит…

— Әллә берәр туганмы ул? Юк инде, үлем көтеп ятучы һәрбер карт янына барып йөри башласам, минем бөтен бизнесым тукталачак…

— Ул бизнесны сез бергә башладыгыз түгелме соң?

— Йә, туктале, нәрсә син бәйдән ычкынган эт кебек ябыштың әле?! Болай да эш муеннан, син дә юк белән башны катырма… Бар, әйберләрне җыя башла, бүген күченәбез…

Гөлнәзирә бу юлы берни эндәшмәде, буйсынучан кыяфәт чыгарып, үз бүлмәсенә кереп китте, Газинур да үз бүлмәсенә узды. Бераздан ул, затлы бәрхеткә төрелгән «кытай алласын» күтәреп, тагын ишек төбендә пәйда булды. Нидер сорашырга дип үз бүлмәсеннән ашыгып чыгып килүче хатыны белән йөзгә-йөз бәрелеште…

Авыр пот үз эшен эшләде: Газинур белән кочаклашкан килеш, шактый юанаеп киткән Гөлнәзирә өстенә авып төште. Шул ук кичтә «ашыгыч ярдәм» машинасы алып киткән хатын әле яңа гына йөрәге тибә башлаган газиз баласыннан мәхрүм калды…

**6**

Бу көннәрдә шатлык-сөенеченнән балкып йөрүче Газинурны танырлык түгел иде. Ул бит яңа фатирга күчте, дөресрәге, шәһәр читендә җиткезелгән мәһабәт йортында көн күрә башлады. Төннәрен, нindидер шаукымга бирелеп, күк катында яшәүче рухлар, аллалар белән саташып чыга иде ул…

Андый алла Газинурның үз өендә үк яши. Хатыны яңа коттеджларына күчүдән баш тарткач, аның күңел юанычы булып шул алтын пот калды. Эче акча белән шыплап тутырылган бу алла сыны күз явын гына түгел, һушны, зиһенне дә алырлык иде шул. Көндезен байлык артыннан куып, акча эшләп вакыт узганын сизмичә йөргән Газинурның җаны, төн җитсә, нишләргә дә белми бәргәләнә иде. Үзе түгел, үзе күптән әнә шул пот-алла кулында инде, җаны өзгәләнә иде аның. Үзе табып алып кайткан сынга төннәр буе табынып утыручы бу Хода бәндәсе хакыйкатьтән, иманнан һаман ераклаша бара иде шул…

Әйе, Газинур Иван дәдәйнең үлем түшәгенә егылганына да, хатыны, яңа йортка күчмичә, элекке фатирларында аерылып, каерылып калганына да артык кайгырмады. Киресенчә, олы бер эштән, җаваплылыктан котылган кеше кебек дәртләнеп, көлеп-елмаеп йөри башлады. Гөлнәзирә үзенең элеккеге фатирына кайтып киткәч, Газинурның язмыш юлында аның эзе бөтенләй уралып юкка чыкты. Хатыныннан бушап калган күңеленә шундук, ургылып, иләс-миләс уйлар, шомлы шаукымнар керә башлады.

Менә алар дөнья каршында икәүдән-икәү генә калдылар: үз күңелендә айнымаслык булып саташкан, адашкан адәм заты һәм иманын дөнья гаменә, байлык вәсвәсәсенә алыштырган рухи зат, алла. Затлы кәнәфидәге йомшак мендәрләренә таянып, үзалдына сөйләнеп утыручы Газинур читтән караганда тиле-миле кешене хәтерләтә иде. Ләкин болай уйлау һич дөрес түгел. Искиткеч максатчан, тырыш һәм тәвәккәл кеше аллага якынайса, күп нәрсәгә ирешә бит ул.

— Бүген көнең ничек үтте? — дип сорый алла Газинурдан.

— Әйбәт үтте. Әйбәт табыш керде. Тагын ике кибет ачу буенча эш башладым, банкта яңа счет ачтым…

— Анысы әйбәт. Ә менә күңелең… күңелең ничек соң?

— Күңел? Нәрсә күңел? Күңел күңел инде. Мин аннан бөтен чүп-чарны, кешене түбәнлеккә төшерә торган вак хисне чыгарып түктем. Минем үземә генә дә әйбәт. Миңа болай әйбәтрәк тә әле. Тынычрак…

— Ә Гөлнәзирә? Гөлнәзирәне дә күңелеңнән чыгарып ташладыңмы? Син аны ярата идең бит.

— Ә хәзер яратмыйм. Ул минем күңелгә авырлык кына китерә. Ышанычымны какшата. Уйларымны, хисләремне бутый. Син бит беләсең: хис дигән нәрсә кешенең рухын йомшарта. Мәхәббәт дип, гаилә, бала дип, мин дә үземнең ихтыяр көчемне, рухи асылымны югалта яздым…

— Ә бәлки, киресенчәдер?

— Юк, көч бөтенләй башка нәрсәдә — акчада, байлыкта. Синдә!

— Миндә?

— Синдә. Сиңа биргән антым, сиңа булган ышанычым, өметем мине саклап калды, кыенлыкларны җиңәргә булышты, кеше итте!

— Кеше итте? Син кешеме?

— Ә син алламы?

— Әйе, мин — алла.

— Мин дә кеше. Кеше аллага тартыла, ә мин сиңа ымсынам, димәк, мин — кеше!

— Син кеше генә түгел, син — акыллы кеше. Юктан бар итеп, дөнья кадәр байлык тупладың. Әмма күңелең зәгыйфь синең. Күккә баккан кешенең күңеле саф, таза, бөтен булырга тиеш.

— Тиеш! Тиеш!… Тиеш нәрсә күп лә ул… Миңа күп кирәк түгел, миңа син җиткән. Син — минем аллам!

— Ә бит аллалар күктә яши, шуны беләсеңме? Алласын сөйгән кеше күкне дә хөрмәт итәргә тиеш. Сиңа да күк белән исәпләшергә туры киләчәк.

— Күкне син ярат, ә мин сине үз итәм. Шул җитмәгәнмени?

— Чынлыкта син мине түгел, миндәге акчаны яратасың, шулаймы?

— Алай түгел, түгел!

— Аңлатып бир.

— Ничек аңлатыйм соң? Син бит алла, үзең аңларга тиеш…

— Аңлат, югыйсә мин ачуланам…

— Хәзер, аллам… Әгәр мин акча гына яратсам, мин ул акча, байлык, мал дигәннәрен Гөлнәзирә белән ничек тә яраклаштырырга тырышыр идем. Ә мин, Гөлнәзирәдән баш тартып, сине сайладым. Дөресен генә әйткәндә, гаиләмнән, киләчәгемнән баш тарттым мин… Сиңа шул дәлил җитмимени?

— Җитә, бик җитә. Мин боларны беләм. Үзеңнең аңлавың мөһим иде. Ачуланма, җаныңны бераз кузгатып җибәрдем.

— Ачуланмыйм. Ул җан урынында күптән таш утыра инде...

Беркөнне Газинурның юлы уңмады. Ул сөйләшкән, килешкән алыш-биреш аның ай буе ниятләп йөргән уйларын пыран-заран китерде, хыялларын җимерде. Кабат аякка басу өчен бик күп көч һәм акча кирәк булачак.

— Нәрсә булды? Кайда акчаң?

— Юк, бүген сиңа акча юк…

— Алай булмый, син һәр көнне миңа акча салып, бәхилләп торырга тиеш!

— Нахал син. Юк диләр бит сиңа, юк, юк, и баста!

Җене, дөресрәге, җаны кузгалып өлгергән Газинур барысын да әйтеп бетерергә булды. Ул, хәтта караватта капланып яткан җиреннән сикереп торып ук утырды.

— Син нәрсә авызыңны ыржайтасың? Алла булдыңмы? Миннән башка булыр идең пычагым! Мин тудырдым сине! Мин сине үтерә дә алам!

Шул вакыт әллә нәрсә булды. Газинур сикереп торып, алласы каршында кизәнгән генә иде, ниндидер көчле җил-давыл чыгып, аны кабат түшәгенә атты, атып кына калмады, баш та калкытмаслык итеп сылап,ябыштырып куйгандай итте.

Давыл туктап, дөнья бераз тынычлангач, алтын пот яныннан тонык кына тавыш ишетелде:

— Минем белән алай сөйләшмә. Сабыр булырга өйрән. Юкса эшне бозып куюың бар…

— Нинди эш?

— Син шуны бел, адәм баласы: мине тудыруың хак, әлбәттә. Ләкин аллалар күктә яшиләр. Мин инде күктә. Мин синеке түгел. Мин хәзер үзем синең өчен күк алдында җавап бирәм. Бүгенге кыланышың өчен дә җавап бирергә кирәк булачак.

— Кичер мине, аллам…

— Кичерәм…

— Рәхмәт.

— Аллаларга дога багышлыйлар. Кая синең догаң?

— Укыйм-укыйм, догасын да укыйм… Кичер генә, ташлама гына мине, зинһар… И аллам! Сиңа да, үземә дә сабырлыклар телим…

— Син тотырган акчалар бераз кысанлый кысанлавын, шулай да түзәм, байлыгыңның алласы бит мин. Мал, нәфес алласы, ягъни мәсәлән.

— Нәфес алласы? Ә үзең ипле генә сөйләшкән буласың…

— Мин бит алла! Начар алла юк. Аның җиргә, адәм балаларына иңдергән ихтыяры гына төрлечә булырга мөмкин.

— Ә-ә, хәзер аңладым. Алайса, алтынга манылган бу сын — син үзең түгел, синең кабыгың гына!..

— Син дә шундый. Синең асылың — җаныңда, ә тәнең… Тәнең күк өчен мөһим түгел. Алып китсәм дә, мин синең нәфескә табынган җаныңны гына алып китәчәкмен…

— Ә акча? Бу кадәр акча белән нишлибез? Кибетләр дә, банклардагы счетлар да монда каламы? Бу бит дөрес түгел!

— Дөрес, күк белән бәйләнгән бөтен нәрсә дөрес, хәтта илаһи, изге!

— Бу кадәр акча җирдә калгач, нигә дип җыя соң кеше ул байлыкны, малны, акчаны?

— Белмим, монысын мин дә белмим. Аллаларга да бөтен нәрсә мәгълүм түгел…

…Газинур белән алла һәр төн саен сөйләшеп, гәпләшеп утыра башладылар. Һәр төн саен Газинур алласына ныграк якынайды, алласы исә, киресенчә, күккә, үз ватанына омтылды. Бердән бер көнне ул Газинурны да күккә — аллалар янына чакырды. Аңлап бетермәсә дә, Газинур тәкъдимне кире какты, әмма күңеленә билгесез бер шом кереп өлгергән иде инде.

— Син көн саен күккә менеп йөрисеңме? — дип сорады ул бер кичтә. — Ничек менәсең, бу бит мөмкин түгел!

— Мөмкин. Син бу кытай чыраена карама, минем асылым эчтә, үзәгемдә…

Газинур, күк гаменә бирелеп, дөнья гамен онытыбрак җибәрде, эшенә салкын карый башлады, дусларыннан, хәтта якыннарыннан бизде. Әнкәсен кайтып алырга, үз янында яшәтергә булган иде, анысын да онытты.

Беркөнне аңа кайчандыр тулай торакта бергә торган танышы очрады. Бу танышын, ай-ваена карамыйча, өенә алып кайтты, үзенчә кунак итәргә тырышты. Әмма күңелләр төрле иде, берни дә ба-

рып чыкмады, алар салкын гына аерылышып, икесе ике якка китеп бардылар. Газинур аңлады — адәм балалары аны яратмый башлаган, ул үзе дә кешеләрне ятсынып өлгергән инде…

Газинур үз язмышын җир белән бәйләп торучы җан тамырларының көннән-көн өзгәләнеп-тузып баруын тойды. Иң элек ул бакыйлыктан иңгән илаһи сын белән бәхәскә керде, аннары тыныч кына, дустанә сөйләшергә, гәпләшергә өйрәнде, бераздан алласының һәр әйткәненә, һәр ымына разый булып, баш кагып тора башлады…

Ә беркөнне… Бер кичне… Бер төнне ул үзен бөтенләе белән алласына, күккә багышлады… Бу хакта гөнаһлы җир дөньясы белмичә дә калды, ә күк дөньясы үзенең бихисап күп серенә тагын бер сер өстәде.

## 7

Аның үле гәүдәсен алтын йөгертелгән кытай статуясы кыйпылчыклары арасыннан табып алганнар. Алтын сын эчендәге акча байлыгы юкка чыккан, статуяның ыржайган авызыннан бер тәңкә илле тиенлек кенә тәгәрәп килеп төшкән, диделәр. Бер шешә бәясе. Газинурны табындырган, нәфесенә абындырган бер сум илле тиен!

Кемдер: «Караклар эше генә — әнә бит акчасын сыпырып алып киткәннәр», — дип, җир гамен сөйләсә, икенче берәүләр: «Ходай Тәгалә ихтыяры белән эшләнгән гамәл бу; акчага чукынган кешеләрне ул гына шушы хәлгә төшерә ала», — дип, болай да шомлы күңелләргә тагын шом гына өстәделәр.

Җинаять эшен алып барган тикшерүче бик нык аптырашта калган, диделәр. Мәетнең тәнендә бер күгәргән, имгәнгән урын да юк икән. Йөрәге дә сау-сәламәт, зиһене дә тәртиптә булган, ди. Алайса, кеше тик торганнан гына ятып җан тәслим кыла аламы?

Ала икән шул. Бу хакта үләргә ниятләп тә үлми калган Иван дәдәй әйтте.

— Кешедә яшәү гаме бетсә, ул үлә, — диде ул. — Яшәү гаме бетмәсә, үлем дә ала алмый аны.

— Яшәү гаме дигәнең язмыш буламы инде? — дип сорап куйды кемдер.

— Юк, язмыш башка. Яшәү гаме ул… яшәү гаме. Шуның белән барысы да әйтелгән. Язмыш — Ходай Тәгалә ихтыяры, ә яшәү гаме — кешенең үз ихтыяры, аңладыңмы инде?

— Аңладым…

Шул ук тикшерүче Иван дәдәйгә ияреп килгән, бер читтә мыштым гына басып торучы Гөлнәзирәгә бер кәгазь кисәге тоттырды:

— Менә васыяте… Күптән язылган булса да, дөрес. Ирегез бөтен малын, байлыгын сезгә һәм булачак сабыегызга калдыра…

Гөлнәзирә кәгазьне алды алуын, аны укыгандай да итте… Тик түземлеге, тәкате озакка бармады, башын Иван дәдәйнең кулбашына куеп, сулкылдап елап җибәрде.

— Ник ташладым икән аны?.. Нигә дип шушы котсыз алласына ташлап киттем икән?.. Шул гына үтерде аны, шул гына үзенә тартып алды…

Гөлнәзирәнең әрнүле сүзләре тирә-яктагыларны сискәндереп җибәрде. Тикшерүче дә өстәл өстеннән башын күтәрде. Аннары, күзләрен кыса төшеп, җирдә аунап яткан җимерек статуяга борылып карады. Әмма шунда ук, йөзен тагын да чытыбрак, кабат кәгазьләре өстенә иелде.

Аның кәефе төшүен аңларга була: аллаларны эшләгән җинаятьләре өчен кулга алып та, җәзага тарттырып та булмый. Чөнки аллалар, кешеләрдән аермалы буларак, күктә яшиләр.

* * *

*Язманы тәмамлап, басмага бирергә җыенып кына тора идем, күптәнге бер танышым шылтыратты. Өзек-өзек сөйләшүеннән бик нык дулкынлануы, хәтта шик-шөбһәгә төшүе аңлашылып тора иде.*

*— Ни бит, ишеттеңме әле, общагада бергә яшәгән күршебез үлгән… Теге… ни… синең уң ягыңда тора иде бит әле… Мактанчыграк… Соңгы вакытта бик баеп киткән иде… Күргәнең булмадымы? Соңгы вакытта ниндидер аллага табынып йөргән, хәерсез!.. Әллә чын, әллә ялган… Менә шул үлгән, әллә үтергәннәрме? Анысы да булыр… Таш потына тутырылган акчасын ватып алганнар… Тиеннәр генә калган… Вәт малай, байлык артыннан кусаң… Барыбер жәл, үзебезнеке бит, күз алдында йөргән кеше… Әлү, син тыңлыйсыңмы мине?*

*— Тыңлыйм… Кызганыч… Үзе дә… Аерылып калган хатыны да, тумас борын ахирәткә китеп барган баласы да, авыру әнисе дә кызганыч, бик кызганыч…*

*— Ә? Аларын каян беләсең? Хатыны, баласы, анасы хакында ишеткәнең булдымы әллә?*

*— Беләм… Булды… Кызганыч, бик кызганыч…*

*— Мин дә шулай димен бит. Син үзең дә бик сәер әле бүген: серле сөйләшәсең. Бер-бер хәл булмагандыр бит?*

*Булды шул, булды! Күптән күрешмәгән танышым минем күңелемне каян гына, ничек кенә аңлап бетерсен?! Бу ачы, аянычлы язмыш минем үземне дә, җирдән куптарып, җанымны кузгатты, күңел терәүләремне какшатты, офыкларымны артка чигерде... Бу хакта һәр кешегә сөйләп йөреп буламыни. Мин бит... Мин бүген үзем дә бераз гына шул серле дә, шомлы да куккә якынайган кебек булдым.*

*2004*

# *БАЛА ХАКЫ*

*(Бәян)*

## 1

Әхияр картның күзенә йокы кермәде. Ул, хастаханәдән чыкканнан бирле, төшке якта, өйлә намазыннан соң, бераз йоклап, черем итеп ала. Бүген оеп, онытылып китә алмады. Күзләрен генә йома, каршына моннан ун ел элек армиядә үлгән оныгы килә дә баса. «Дәү әти, — дип әйтә кебек ул. — Син мине онытмадыңмы әле? Онытма, яме. Мин синең кебек герой була алмадым... Бер орденсызнисез җир куенына кердем. Монда барысы да тигез, ә менә синең янда беркем дә юк... Үлгән чагыңда, соңгы йотым су салып бирергә оныгың да булмаячак бит...»

Газизнең мәетен күрү белән, атасы да, анасы да буынсыз калдылар. Бер ай эчендә бер-бер артлы йөрәк өянәгеннән китеп тә бардылар. Бала хакы ай-һай кыйммәт шул ул... Борынгы заманның бер шәүләсе булып, Әхияр карт берьялгызы торып калды. Ул да бик сырхау. Соңгы юлга чыгарга да күп калмагандыр шул... Әле яшәргә булыр иде. Яшәүнең кызыгы гына бетте... «Яшәүнең кызыгы бетсә, гомер бетә», — ди иде аның фронтташ дусты. Беренче яуда ук башын салды мескенкәй. Ә менә ул — гвардия сержанты Хаков Әхияр Рамазанович — сугыш беткәннең 60 нчы елында да яшәп ята... Әллә? Әллә ул инде күптән үлгәнме? Бу тормышны яшәү дип атап булмыйдыр, бәлки?

Әхияр карт, болай уйланып-изаланып ятуның чынлап та мәгънәсез булуын аңлап, торып утырды, иң беренче эләккән сырмасын ябынып, башына кояшта уңа башлаган эшләпәсен киеп, урамга чыгып китте. Ерак йөрмәде, хәтәр авырудан калган хәлсезлек үзен сиздерә әле... Ул, йортлары каршындагы мәйданны аркылы үтеп, аулак бакчага барып керде, иң беренче эскәмиягә килеп утырды. Башын артка ташлап, күзләрен йомды...

...Ниндидер сәер тынлык. «Үлем тынлыгы» дигән сүз бар. Әнә шундый үлем тынлыгы, кабер тынлыгы бу... Ә бит яшисе иде әле, ай яшисе иде... Тормыш белән бәйләп торучы, яшәүгә дәрт, тәнгә дәрман бирүче кыллар, моңнар күбрәк булса иде! Өзелеп, тузып бетмәгән шундый берничә генә кыл чыңлап торса да, яшәүгә, тормышка теше-тырнагы, җаны-бәгыре белән ябышыр иде ул!

Шул вакыт Әхияр картның күңел түрендә, җан үзәгендә нидер тартылып, хәтта чәнчеп куйгандай булды. Әһә, теге тормыш кылларының берсе бу... Яшәүгә ымсындыра торган, гомер хакына бәрабәр чың... Ләкин бу чың анык түгел, ул кайдадыр читтәрәк... Аның кайтавазы гына тормыш яраларыннан яргаланып беткән күңел ярларына килеп бәрелә.

Әхияр карт күзләрен ачты. Тирә-ягына каранды. Бакчада беркем дә юк. Чынлап та, кая китеп беткән бу халык? Эштә микәнни? Челлә дисәң, дөресрәк булыр... Әнә теге сабыйны исәпкә алмасаң, бөтен дөнья тоташ сурәт кебек катып калган... Туктале... Теге чың шул сабый ягыннан килә түгелме соң? Нинди чың ул? Нинди сабый? Нишләп йөри ул монда берьялгызы? Аның ата-анасы кайда? Язмышы кайда?

Карт янәшә эскәмиядә уйнап утыручы 7— 8 яшьлек малайга таба борылып утырды. Җентекләп күзәтә башлады.

Малай бик тере, хәрәкәтчән күренә. Үз буе кадәр утыргычка бер менә, бер төшә, әле, кулларын як-якка җәеп, кош кебек очып китә, әле, утыргычка атланып, атта чаба башлый. Аннары, кинәт уеныннан тукталып, бакча ишеге янында торган белдерүләр тактасына төбәлеп тынып кала... Менә ул сикереп тора да шул такта янына йөгерә, тырышып-тырышып, иҗекләп укый башлый. «Кем-гә эт ки-рәк?», «Мә-че са-там, а-ла-сыз-мы?», «Тутый кош бар, те-ләгән ке-ше шу-шы ад-рес бу-ен-ча кил-сен...», «Фа-тир са-там, кем а-ла?», «Фа-тир...», «Фа-тир...»

Фатир хакындагы белдерүләр иң күбе булып чыкты. Малай аларны укып тиз ялыкты, шундук үзенең эскәмиясенә килеп утырды. Тагын баягы уенына бирелде...

Кеше юк дисәң дә, кеше бар икән. Әнә бер карт оныгын җитәкләп узып китте. Алар күздән югалганчы, малай тын да алырга куркып торды. Болай да үзен кая куярга белмичә йөргән бу кечкенә адәм баласы тагын да моңсуланып, күңелсезләнеп калгандай булды. Кояшта янып, матураеп киткән йөзе, туры, зифа борыны, кызларда гына була торган ай кашлары, алсу, сусыл иреннәре кеше-

ләргә илаһи ым буларак кына бирелә торган күксел зур күзләре бу малайны яратмас җиреңнән яраттыралар иде. Пөхтә чәчләре, пөхтә киемнәре исә аның хәлле, ипле генә гаиләдән булуын хәбәр итеп торалар.

Белдерүләр тактасы янына килеп баскан ул кешене беренче булып малай күрде. Аның, уенын ташлап, әлеге өлкән генә кешегә йотлыгып карап торуы Әхияр картка кызык тоелды. «Гадәти малай түгел бу, монысы аңлашыла. Тик... нәрсә кирәк аңа бу белдерүләр тактасында? Кемнедер эзлиме, берәрсен югалтканмы? Алай дисәң, бер дә урам малаена охшамаган...»

Ул арада теге кеше, белдерү кәгазен ябыштырып китеп барды. Малайга шул гына кирәк икән — ул, сикереп торып, бакча ишегенә таба йөгерде. Саргая башлаган кәгазьләр арасында берьялгызы агарып, балкып торучы кәгазьне җентекләп өйрәнә башлады...

Малай бу белдерүдән дә теләгәнен таба алмады, ахры, олыларча авыр-авыр атлап, кабат үзенең утыргычына юнәлде...

Берәр сәгать вакыт эчендә белдерүләр тактасына тагын берничә кәгазь ябыштырып киттеләр. Һәр яңа белдерү саен, күршедәге малай, һич иренмичә, бакча алдына бара, яңа белдерү белән танышып, тагын үз урынына килә.

Әхияр карт инде төгәл белә: бу малай нииндидер белдерү, игълан көтеп утыра. Бик сирәк очрый торган, хәтта бик сәер белдерү булырга тиеш ул. Әллә сорашып караргамы? Уйлап кына сүз башларга кирәк. Бу баланың күңеле бик нечкә, бик нәзберек булырга охшаган. Әхияр үзе дә балаларны ярата. Тик күптән аралашканы юк. Оныгы аннан бер тотам да калмый ияреп үсте. «Кемне күбрәк яратасың?» — дип сорасалар, ике дә уйламыйча: «Дәтине!» — дип җавап бирә иде. «Дәү әти» дигән сүзе инде ул аның.

Әхияр картны аяклары үзләреннән–үзләре малай янына алып киттеләр. Күңеленә тартылган җан кылы үзенекен эшләде — картны шушы таныш түгел язмыш иясенә — кечкенә адәм баласына — мәңгелеккә беркетеп куйды.

— Исемең ничек, олан?

— Ә? Минемме?

— Синеке булмый минеке булмас бит... Монда бүтән беркем дә юк.

— Газиз... Ә синеке?

Әхияр сискәнеп үк китте. «Газиз» диме? Оныгының исемен әйтеп тора ласа! Каян туры килә дигән, ә? Бер үк җәрәхәткә ике мәртәбә кагылган кебек бу...

— Ә синеке?

— Әхияр мин. Әхияр бабаң булам.

— Алдыйсың. Андый исем булмый... Минем ишеткәнем юк.

— Син ишетмәгән, белмәгән әйберләр ай-һай күп булыр, олан. Хәтта мин ишетмәгән, мин белмәгән нәрсәләр дә бар әле бу дөньяда.

— Нәрсә дигән сүз ул — Ах-яр...

— Әхиярмы? Хәерләр дигән сүз. Хәерле, изге әйберләр, ягъни мәсәлән...

— «Хәерле», «изге» — нәрсә соң ул?

— Ходай кушканча яшәү дигән сүз.

— Ә, аңладым. Син — ангел...

Бераз тын калып, сөйләшми утырдылар. Малай эскәмия тирәсендә, машина булып, тырылдап йөрде, Әхияр карт исә аны каш астыннан гына күзәтте. Аның колагында һаман әле Газизнең соңгы сүзләре яңгырап тора иде: «Ә, аңладым... Ангел...»

Нәрсә генә аңлады икән соң бу бала кисәге? Ходай кушканча яшәү хакында ни белә ул? Шул гомер яшәп, Әхияр карт үзе дә белеп, аңлап бетерми әле Ходай ихтыярын.

Ул арада тагын берәү белдерү ябыштырып китте. Сәләмә генә киемнәр киенгән карт урам чатына кереп китү белән, Газиз белдерүләр тактасына йөгерде. Ләкин шундук урап та килде. Башын салындырган, кашларын җыерган, иреннәрен бүлтәйткән...

— Нәрсә карыйсың син анда?

— Ә?

— Белдерүләр тактасыннан нәрсә карыйсың, дим. Берәр нәрсә эзлисеңме? Берәрсен көтәсеңме?

— Юк, болай гына...

— Әйтмәсәң әйтмә, сер икән, сер булып калсын...

— Сер түгел...

— Алайса әйт.

— Минем бабам юк. Дәү әтием дә юк. Дәү әтисез кыен... Берәр бабай кеше «Миңа онык кирәк, берәр малайга дәү әти булыр идем» дип язса, шундук риза булыр идем... Ышанмыйсыңмы әллә?

— Ышанам, нигә ышанмаска?!

— Ышанмыйсың... Көләсең генә...

— Көлмим, көлмим... Дәү әтисез малайдан көләләр димени?! Күптән эзлисеңме?

— Күптән... Йөз ел!

Әхияр карт елмаеп куйды. Аның күзләрендә хәйләкәр нурлар биеште.

— Әйтәм бит көләсең дип...

— Бу юлы яшермим, көләм... Мин синнән дә яшь булып чыгам бит. Шуңа көләм...

— Сиңа ничә яшь?

— Сиксән.

— Сиксән?!

— Әйе, йөзгә нәкъ егерме ел тулмый.

— Беләм, беләм, мин инде санарга өйрәндем. Йөздән сиксәнне алгач, егерме кала. Мин инде икенче класска күчтем. Гел бишлегә укыйм.

— Тырышасыңмы?

— Тырышам. Өйдә минем барысы да әйбәт. Әни дә бар, компьютер да... Дәү әти генә юк. Ә ул миңа бик кирәк...

— Әтиең юкмыни?

— Бар. Килеп йөри. Ләкин ул бит дәү әти түгел, әти генә. Ә миңа дәү әти кирәк! Мин беләм. Кайдадыр берәр дәү әтигә минем кебек малай кирәктер... Менә синең оныгың бармы?

— Бар иде...

— Үлдеме?

— Үлде.

— Сиңа тагын онык кирәк түгелме?

Әхияр карт бу кадәресен үк көтмәгән иде. Нинди бала бу? Бала түгел, Ходай үзе сөйләшәме әллә шушы бала теле белән? Бала хакы — иң зур хак, диләр бит. Әллә Ходай Тәгалә Әхиярны шул хак хакында искәртеп, аңа берәр яшерен ым бирәме?

Әхияр Газизнең соравын җавапсыз калдырды. Малай да бүтән сорамады, уен гаменә бирелде.

«Дәү әти кирәк» ди бит... Үзенә онык эзләп йөрүче берәр бабай чыкмасмы дип көтә инде балакай... Көләсе дә килә, елыйсы да... Күбрәк елыйсы килә... Нидер булган бу дөньяга, бу кешегә нидер булган. Балалар дәү әти эзләп йөриләр... Аталар балаларын ташлыйлар... Илне сакларга киткән егетләрнең үле гәүдәсе тимер табутларда кайта...

...Алар саубуллашмадылар. Карт кеше белән бала кеше, бер-беренең йөзен, күз карашларын ятлап алып калырга телгәндәй, сынабрак карашып тордылар да, җәһәт кенә кузгалып, икесе ике якка китеп бардылар. Хастаханәдән соң Әхиярга күп, озак йөрү кыен шул. Авыруыннан арынып кына килә торган ябык, хәлсез тән түшәк сорый. Малайны да аңларга була — көне буе бакча капкасы төбендә утырып, бер генә өметле белдерүгә дә очрый алмады бит. Шуңа да күңелсез ул, ялгыз, хәтта бәхетсез... Чөнки аның дәү әтисе юк, тормышка өйрәтүче, яшәүгә күнектерүче, иманга күндерүче, рух тәрбияләүче кешесе юк...

Әхияр карт шулай уйлады. Дөрес уйлады. Гомумән, ул бүген үзенең хакыйкатькә якынаюын, изгерәк була баруын тойды. Бүген Ходай Тәгалә аңа яшәү хакын, бала хакын аңларлык көч-куәт, зиһен бирде...

**2**

Бакча буенда очраган малай Әхияр картның тынычлыгын алды. Шулай килеп чыкты инде, Газизнең күңел тынычсызлыгын ул бөтенләе белән үзенә кабул итте, шул авыр йөк белән яши башлады. Дәү әти эзләүче бала хакында уйламый калган көне булмагандыр аның. Кайчакта, сабырсызланып, таныш бакчага чыгып китә, сәгатьләр буе түземсезләнеп көтеп утыра, әмма Газиз күренми дә күренми. Әхияр карт, авыру тәне белән калтыранып ютәлли-ютәлли, кире кайтып китә...

Ялгыз кеше бит. Ялгыз кеше ялсыз кеше инде ул. Әхияр карт та тынгысыз яши, бер минутка да күңел борчуларыннан арына алмый. Һаман шул мәрхүм оныгы күз алдына килеп баса. Газиз, күзләрен мөлдерәтеп карап: «Яшәгән кебек тә булмадым,— ди. Аннары, бераз сынап карап торгач: — Кайтам әле мин... Юк, җаным, рухым белән генә түгел. Рухым белән мин болай да синең янда. Шул җанымны, рухымны берәр газиз затка төреп кайтачакмын әле... Дәү әти, көт, яме... Кайтам мин, кайтам...» — дип өзгәләнә.

Кем кайтсын инде ул яклардан?! Бер әләккәч, кайту-китү юк инде ул...

Ә кем белә? Кем белә бу Ходайның ихтыярын? Бөтен нәрсә аның кулында, аның мәрхәмәтендә бит... Беркайчан беркем белән булмаган эшне эшләр дә куяр — Әхияр исемле татар картына оныгын кайтарыр да җибәрер. Ялгызы гына күңелен газаплап, бәгырен телгәләп ятмасын, иш булсын, иптәш булсын, дияр...

Бәлки инде, җибәргәндер дә... Әнә теге Газиз исемле малай кебек, аның Газизе дә, дөнья бетереп, дәү әтисен — Әхияр картны эзләп йөридер...

Әллә? Әллә ул бала — аның онысымы? Исемнәре дә бер бит хәтта... Оныгы Газизнең җан-рухы шушы кечкенә кеше җисеменә төренеп килмәгән дип, кем әйтә ала? Беркем дә әйтә алмый. Менә ничек каерылып борыла дөнья кучәре!

Әхияр карт үз уйларыннан үзе куркып китте. Күңелендәге тынгысызлык ниндидер таныш та, таныш түгел дә моңга, аннары шомга әверелде... Әгәр чынлап та шулай булып чыкса? Урамда белдерүләр карап йөргән Газиз аның оныгы булса? Алайса... ник танымады ул үзенең оныгын? Ник күңеленә, тормышына ала алмады? Шул танымавы белән аны рәнҗетте, кыерсытты...

Кинәт, гөлт итеп, Әхияр картның зиһенендә бер якты уй кабынып китте. Бу уй, бераз серле нур булып балкып торганнан соң, күңеленең иң төбенә бер шифалы җылылык, өмет булып төшеп ятты...

Әгәр ул бөтен шәһәр буенча белдерүләр элеп чыкса? Ул белдерүгә «Мин — Әхияр карт — үземә онык булырдай малай эзлим» дип язса? Газиз исемле бала аны укыса? Белдерүдә күрсәтелгән адрес буенча килеп тапса?.. Алар бер-берсен танып, шатланып яши башларлар иде... Бәхетле булырлар иде...

Әхияр карт бу уйларыннан дәртләнеп, канатланып китте. Сызланулары онытылды. Җан тынгысызлыгын күңел мәшәкатьләре алыштырды. Ул соңгы елларда беренче мәртәбә хыялга бирелде, үзенең киләчәге, яшәеше һәм язмышы хакында уйланды. Күңел төбендә пыскып яткан өмет, бәхет кебек изге төшенчәләрне өскәрәк калкытып, әзерләп куйды...

Кәгазь-каләмнәр әмәлләп, өстәл артына килеп урнашкач та бик озак уйланып, күңелен кирәкле көйгә көйләп утырды әле ул. Изге ниятләр алдыннан укыла торган догаларын исенә төшерде. Ата-бабалар йоласын да онытмады. «Саваплы эш — аяклы эш, кулдан йөрмәсен, юлдан йөрсен»,— дип, әфсенле ырымын да укып куйды.

Әхияр картның күптән инде кулына каләм алганы юк. Кәкре-бөкре чыккан хәрефләргә карап, ул ниятеннән кире кайтырга да уйлаган иде, әмма дәртләнеп, яшәреп киткән йөрәге бу хакта ишетергә дә теләмәде — каләмен аның катып, сөялләнеп беткән бармакларына беркетеп, ябыштырып ук куйды.

Бер көне белдерүләр язып үтте. Икенче көнне үк урамга чыгып китмәде әле. Көне буе хәл җыйды, көч туплады, аннары тагын шул хәл: бертуктаусыз уйланды, монсуланды, шомланды...

Ниһаять, тәвәккәлләде. Сәфәрен Газиз исемле малайны очраткан бакчадан башлады. Таныш белдерүләр тактасына берьюлы ике кәгазь ябыштырып куйды. Бераз эскәмиядә утырып торды, хәл алды. Аннары тагын кузгалды. Акрын гына кыштыр-кыштыр йөри торгач, төш вакыты җитте, ул арада яңгыр явып үтте, кайдадыр йоклап яткан көзге җил дә, уянып, аяк астындагы яфракларны тузгытып йөри башлады.

Белдерүләрнең яртысы ябыштырылмаган иде әле. Әхияр карт кире борылырга булды. Көчәя барган салкын җил дә аны өенә таба куган кебек иде. Ачык изүенә кереп, авыру йөрәгенә үрмәләп булашучы суыктан сакланырга теләп, Әхияр карт үзенең якасына үрелгән генә иде, хәлсез бармаклары арасында тыпырчынган кәгазь кисәкләре, бер-бер артлы шуышып чыгып, очына-очына юеш урамга таралдылар... Карт моңа сөенде генә. Мәшәкать калмады. Инде тынычлынып кайтып китәргә дә була. Ходай язган булса, ябыштырган кадәресе дә җитәр. Язмаса, бөтен шәһәр урамын кәгазь белән түшәп чыксаң да табылмаячак аның Газизе.

Белдерү язып элгәч, күңеле урынына утырыр, җаны бераз тынычланыр дип уйлаган иде Әхияр карт. Ә бөтенләй киресе килеп чыкты: аның өчен авыр көтү чоры башланды. Кешене борчуга салып, чиргә сабыштыра, аны вакытсыз картайта торган нәрсә ул — көтү... Әхияр карт моны белә. Оныгыннан бер ай хәбәр килми торгач, көтә-көтә ярты гомерләреннән мәхрүм калдылар. Кая ярты гомер генә булсын. Газизнең ата-анасы, Әхиярның ялгызын гына калдырып, бөтенләй үк китеп бардылар. Ахирәттә очрашсалар ярый да бит... Әллә очрашмадылар микән? Әнә бит Газиз, кайтам, ди...

Әхияр карт, күңелендәге гөнаһлы уйларны читкәрәк куарга тырышып, догаларына ябышты. Белгәннәрен кат-кат укыды. Чынлап та, бераз җиңелрәк булып китте. Күңеле уйнаклап, иләсләнеп алды. Әхияр карт, кармаланып, мендәрләрен барлады, терсәге белән йомшак түшәккә таянып, күзләрен йомды... Аның бик тә, бик тә мәрхүм оныгын — Газизне күрәсе килә иде. Шулай йоклап китәр алдыннан ниндидер серле сурәттә, рәшә, томан кебек кенә килеп китә ул дәү әтисе янына...

Ләкин бу юлы Әхияр карт йокыга китә алмый калды. Оныгын да күреп өлгермәде. Ишек шакыдылар...

**3**

Әхияр картның белдерүен тотып кергән беренче кеше аның күршесе иде. Трампаркта эшләүче Мирзаһит эштән кайтып бара икән. Юл буендагы белдерүләр баганасына да ялгыш кына караган. Үз йортларының адресын күргәч, кызыксынып укый башлаган...

— Син нәрсә, Әхияр абзый, бераз тегеләйме әллә? Кем шундый белдерү яза инде…
— Мин…
— Ну, син. Шуннан?
— Мирзаһит балам, сез өйләнешкәнгә ничә ел инде? — Әхияр картның соравы Мирзаһитны гына түгел, картның үзен дә аптырашка калдырды. Нигә сорарга җөрьәт итте соң әле бу хакта? Нинди дер мәгънә салып бирде ләса ул бу сорауны…
Ниһаять, Мирзаһитның «теле ачылды»:
— Биш ел була инде. Нигә сорыйсың әле бу хакта, Әхияр абзый?
— Бала кирәк сезгә, бала… Баласы тугач кына кеше үзенең чын гомерен яши башлый.
— Аңынчы яшәмимени ул?
— Юк, яшәргә әзерләнә генә.
— Димәк, мин әле яшәмим?
— Юк, яшәмисең.
— Кызык бу… — Бераз уйланып торгач, моңсу гына әйтеп куйды: — Ә бит дөрес әйтәсең… Башта уку дидек, аннары фатир булсын дидек, фатир алганга да ике ел… Бала хакын хакламагач, нинди яшәү ул?! Ай дөрес тә кеше син, Әхияр абзый… Урынсыз сүзләрем өчен ачуланма, яме…
— Юк, юк, Мирзаһит балам, ачуланмыйм…
— Моны нишләтим соң? Кире илтеп ябыштырыйммы?
— Йөрмә, балам. Алар бик күп… Күрәсе кеше күрерлек кенә бар…
Икенче кеше дә Әхияр картның көткәне түгел иде. Журналист. Яңа гына укуын тәмамлап, яшьләр газетасында эшли башлаган. Шаккатыргыч мәкаләләр язып, кеше башын катырып йөри икән.
Оялып-нитеп тә тормыйча:
— Ничек шундый хәлгә төштегез? — дип сорады ул. Күзләрендә дә шул ук үҗәтлек: «Менә хәзер мин сине бөтен дөньяга фашлыйм, картлач, бөтен кеше алдында рисвай итәм!..»
— Кызым, сиңа ничә яшь? — дип сорады аңардан Әхияр карт.
— Егерме бер. А что?
— Ата-анаң бармы?
— Бар. А что?
— Әби-бабаң бармы?
— Бар. А что, что?
— Так шту… шул: кайчан соңгы мәртәбә кайтып, якыннарыңның хәлләрен белдең?
— Былтыр…
— Бик ерак яшиләрмени?
— Чаллыда.
— Ерак икән шул. Мин аңлыйм сине. Син — яшь, бөтен дөньяны алдыңа тезләндерәсең килә, шулаймы? Тик менә эти-әниләрең, әби-бабаларың аңлый микән? Монда йөреп зерәгә вакыт үткәргәнче, бар — өеңә, газизләрең янына кайтып кил, ичмасам…
Кыз каушап калды. Хәтта елар дәрәҗәгә җитте. Әмма бик тиз үзен кулга алды.
— Кичерегез мине. Зинһар, кичерегез! — диде дә йөгереп диярлек чыгып китте.
Шуннан соң бик озак кеше килми торды. Дәү әти эзләп йөрүче беренче бала өченче көнгә чыккач кына килеп керде. Кулында — таныш язу.
Җирән чәчле, йөз-битен эре сипкел баскан бу малай исәнләшеп-нитеп тә тормыйча, шәрран ярып әйтте дә салды:
— Дәү эти шушында торамы?
— Шушындасын, шушында да… Син кем буласың соң?
— Марат мин. Миңа дәү эти кирәк.
— Дәү этиең юкмыни синең?
— Бар.
— Булгач, ник килдең?
— Икәү булсын. Бүләкләр дә, тәмле әйберләр дә икеләтә эләгә бит. Әйдә, киттек!..
— Сиңа дәү эти тәмле әйберләр, бүләкләр бирсен өчен генә кирәкмени?
— Ә тагын нәрсәгә кирәк ул?!
— Белмим тагы… Күңел өчен… Бергә борчылу өчен, бергә шатлану өчен… Бергә яшәү өчен кирәк!
— Бергә яшәргә минем әнием бар. Дәү эти караңгы бүлмәдә үзе генә яши… Пенсиясенә бүләкләр, күчтәнәчләр ала. Шуңа гына тотабыз без аны.
— Мин дә шунда — караңгы бүлмәдә яшәрменме?
— Әйе, тагын бер караваt куеп була анда…

— И балакаем, мин сезгә бармам инде. Мин бит үз оныгымны таптым. Газиз исемле малайны… Шуңа күрә, мин синеке була алмыйм, ачуланма, яме? Аннары синең бер бабаң бар бит инде. Аңлап торам, әйбәттер ул, игелекледер. Сине яратадыр, көтәдер.. Дәү әти бер генә була ул, аның кадерен бел, һәр сүзеннән, һәр киңәшеннән мәгънә табарга тырыш…

Малай борчылырга, ачуланырга уйламады да. Ул, берни булмагандай:

— Алайса, мин киттем. Пока! — диде дә чыгу ягына юнәлде.

Әхияр карт, бу хәлләргә ышанырга да, ышанмаска да белмичә баскан урынында каккан казык кебек торып калды.

Бер-бер артлы тагын өч малай керде. Берсенең балалар бакчасына йөрисе килми икән, икенчесе балыкка йөрергә иптәш эзли, өченчесе әбисен җәлләп килгән. «Әбиемә бабай кирәк», — дип чатнатып әйтеп тора.

Әхияр карт боларын елмаеп каршы алды, аннары, чәй белән сыйлап, үзенчә матур киңәшләр биреп, җөпләп-юмалап озатып җибәрде.

Аннары ике хатын керде. Бер-берсенә охшамаган ике хатын. Ике ана. Бердәнбер охшаш яклары — икесе дә малайларын ялгыз үстерәләр. Тагын бер уртак яклары бар икән. Ничек туры килә диген — икесе дә Луиза исемле, малайлары да бер исемдә — Рөстәм…

Беренче Луиза, килеп керү белән, исәнләшеп тә тормыйча түргә узды, бүлмә бетереп эзләнеп йөри башлады.

— Синмени инде ул теге белдерүне язган карт? Дәү әти… Нәрсәң бар соң синең? Әллә нәрсәң юк икән, банкка салдыңмы әллә бар байлыгыңны? Җә, ник сүләшмисең, синнән сорыйлар бит…

— Нәрсә кирәк сезгә? Кем кирәк? — Әхияр карт, гомердә булмаганча, үртәлә башлады. Шулай да булдыра алган кадәр итагатьлелек сакларга тырышты. — Сез үзегез кем?

— Мин? Мин Луиза булам. Менә шушы белдерүең буенча килдем. Күреп торам — монда рәт чыкмаячак… Бар җирең дә йолкыш — фатирың да, үзең дә… Эш хакы биреп кенә котылып булмас, ашатырга да туры киләчәк сине…

Әхияр карт барысын да аңлады. Бу хатынның баласына дәү әти кирәк. Бабай, ягъни мәсәлән. Няня. Каравылчы. Иптәш, япьтәш зат…

— Аягымны да атламас идем бу әтрәк-әләм оясына. Бала хакы дип кенә йөрүем. — Хатын, йөзләрен чытып, тирә-ягына чирканып карана-карана, сөйләнүендә булды. — Рөстәм таптырганга гына… Кибеттә сатыла торган нәрсә түгел шул, тиз генә табармын димә!.. Ну, нишлибез, картлач?

Әхияр карт бу сорауны ишетмәде. Дөресрәге, ишетмәмешкә салышты. Аннары, бөтен исен-акылын җыеп, ана кешегә әйтелергә мөмкин иң авыр сүзне әйтте.

— Син бит малаеңны яратмыйсың… Шуны беләсеңме? — диде.

— Нәрсә-ә-ә?

Хатын, шартлар дәрәҗәгә җитеп кабарынып-бүртенде дә пыр тузып чыгып китте… Әхияр карт аның артыннан бәрелеп-сугылып калган ишеккә кагылырга өлгермәде, арткы яктан тыйнак кына кыңгырауга бастылар. Ишек ниндидер сихер ярдәме белән үзеннән-үзе ачылып китте, Әхияр карт каршында фәрештә кебек мөлаем бер ханым пәйда булды… Әле бая гына чыгып киткән Луизадан соң һәр хатын-кыз фәрештә булып күренәдер шул… Ә бит чынлап та фәрештәгә охшаган бу хатын — башына, уранып, ап-ак яулык бәйләгән, өстендә — акка буй-буй яшькелт сызыклар төшерелгән озын күлмәк… Йөзе дә ап-ак, карашы да, елмаюы да ап-ачык…

— Син кем?

— Луиза…

Әхияр карт сискәнеп үк китте, үзе дә сизмәстән:

— Малаең Рөстәм исемлеме? — дип сорап куйды.

— Әйе… Каян белдегез?.. Нигә килгәнне дә беләсезме әллә?

— Беләм. Син Рөстәм исемле малайга дәү әти эзләп йөрисең, шулаймы?

— Әйе… Каян белдегез?

— Әнә бит минем белдерү кулыгызда.

— Ай Алла, күрсәтергә онытып торам икән әле… Рөстәмгә дәү әти дип килгән идем шул. Кайта да ямансулый, кайта да ямансулый… «Нәрсә булды?» — дип сорагач: — «Дәү әти кирәк», —ди. Әтисез үсә ул. Әти дияргә кыенсына, дәү әти кирәк, дигән була. Иптәш кирәк аңа, ир заты кирәк.

— Алай икән… Ә ирең кайда соң? Рөстәмнең әтисен әйтәм…

— Юк ул… Еракта. Күрше урамда гына яшәсә дә, күңелдән бик еракта…

— Син үз күңелең хакында әйтәсеңме?

— Әйе…

— Әле бит бала күңеле бар. Аның хакында кем кайгыртыр? Ирең улы хакында беләме соң?

— Белә… Ярата да ул аны… Мин китермим. Теләмим… Бик нык түбәнсетте ул мине, кимсетте…

— Ничек? Ничек кимсетте?

— Үзенең анасын миннән өстен куйды.

— Алай икән... Ана хакы белән бала хакы бары тик Ходай Тәгалә ихтыярында, диләр. Мин... Мин бер сүз дә әйтә алмыйм... Син дә үзең генә хәл итә алмыйсың балаң хакын... Луиза бит әле? Менә шул, Луиза балам: синең Рөстәмеңә әти кирәк. Ә ул инде бар. Шуңа күрә, аңа дәү әти эзләп йөрмә, кайт та уйлан, нык уйлан. Үз язмышың хакында гына түгел, баланың язмышы хакында да уйлан. Күңелеңне изгелеккә көйлә. Яшәү мәгънәсе нәфрәттә түгел, мәхәббәттә... Онытма... Миннән сүз шул...

Луиза сүзнең бөтенләй башка якка кереп китүенә аптырабрак калган иде. Ләкин Әхияр картның сүзләрен дә кире какмады. Тыйнак кына рәхмәт әйтеп, китәргә җыенды. Ләкин, ишек катына җиткәч, кинәт туктап калды, борылып карарга кыймыйча гына, баядан бирле күңелен борчып торган соңгы сорауны бирде:

— Ә сез ничек? Сезнең белән нәрсә булыр? Үзегез генә калырсызмы?

— Син, кызым, минем өчен борчылма. Минем оныгым табылды. — Әхияр карт теле белән үзе түгел, гүя аның күңел моңнары, йөрәк ярсулары, уй-хыяллары, хәтта язмышы сөйләшә иде. — Мин шул оныгымны көтәм. Газиземне көтәм... Килә ул, килә... Килми кая барсын... Ә син бар кайт, кызым, өеңдә Рөстәмең көтәдер. Ходай сабырлыклар бирсен, догасыннан ташламасын...

— Рәхмәт, изге кеше. Үзегезгә дә шуны ук телим. Сезгә сабырлык күбрәк тә кирәк әле, күңелем шуны сизә...

**4**

Әхияр картның даны бөтен тирә-якка таралды. Кемдер чынлап та «дәү әти» эзләп килде, кемдер, бу сәер хәлләрдән кызык табып, «акылга җиңеләя башлаган карт»ны күрәсе килеп кенә керде. Андыйлар озак тормыйлар. Ә менә «әти» яисә «дәү әти» дип килгәннәр озаклап утыралар. Әхияр карт каршында үз тормышларын, хәта язмышларын ачып салалар, аңардан нindидер илаһи ым, ишарә көтәләр, аннары, дус булып, якын бер кеше яисә ахири затлар булып аерылышалар... Күпләр кабат киләләр, малайлар, кызлар авыру Әхиярдан тиз туялар, ә менә аларның әти-әниләре һаман ташламыйлар, ничек кенә булса да ярдәм итәргә, картның моңсу дөньясына булдыра алган кадәр ямь бирергә тырышалар.

Шулай ике атна, өч атна, ай узды. Хәтәр авыру Әхияр картны кузгалмаслык итеп түшәгенә «кадаклап куйды». Көнгә берничә мәртәбә тәрәзә янына барып килә алса, бик әйбәт инде. Анда да бармас иде, Газизен карыйсы бар. Газизем урамнан урап китәр дә күрми калырмын дип курка Әхияр карт. Инде аның янына килүчеләр дә азайды. Бөтен карап торганы — күршеләр. Әле дә алар ташламый — сөтен, ипиен кертәләр, ашарына пешереп куялар, врачка йөгерәләр. Бигрәк тә Мирзаһит нык бөтерелде...

Тиздән Газиз исемле малай белән бәйле өметләре үлем, теге дөнья хакындагы шомлы уйлары астында басылып, томаланып калды. Сүнеп-сүрелеп үк бетмәсә дә, ул малайның йөз-сурәте һаман тоныклана, төссезләнә барды.

Әхияр карт үләргә әзерләнде. Аның соңгы юлга чыгарга әзерләнеп беткән хәләл җаны каршына мәрхүм оныгы ешрак килә башлады. Бу юлы ул дәшми, сөйләшми. Моңсу йөзләре белән дәү әтисенә карап тик тора. Әхияр үзе генә сөйләшә.

— И улым, бер дә әйбәт түгел әле минем хәлем. Ни яшәп булмый, ни үлеп булмый дигәндәй... Син дә һаман кайтып җитә алмыйсың... Өметем, дәртем уянып, күңелем күтәрелеп алган иде дә, менә тагын өзелде, сүнде, — дип зарлана ул алдында ап-ак томан булып эленеп торган Газиз-җанга. Бераз сулышы җиңеләйгәч, хәл алгач, сорап куя: — Син белмисеңме соң аның кайда икәнлеген? Килергә, табарга тиеш ул мине. Мин бит ул килмичә үлә алмыйм, беләсеңме шуны?! Үлеп китәрмен дә, ул килеп җитәр... Алдакчы булып калырмын... Син бит рух, син белергә тиеш... Килерме ул, юкмы?

Газиз-җан дәшми. Аның ап-ак йөзе тагы да агарып, моңсуланып китә. Аннары сыеклана, тоныклана башлый, бераздан, таралып, бөтенләй юкка чыга.

— Димәк, син дә белмисең...

...Беркөнне Әхияр карт бөтен күршеләрен үз янына җыйды. Аның ап-ак түшәктә ап-ак юрганга төренеп ятучы ап-ак йөзе бу дөньяныкы түгел иде инде. Нindидер сихри, серле мәкам белән әйтелгән сүзләре дә бүтән дөньяныкы иде.

— Мең рәхмәт сезгә... Мин китәрмен инде... Юлда чагымда догаларыгыздан ташламагыз... Мин киткәч, Газиз исемле малай килер... Бу йортны аңа тапшырыгыз... Ул... Ул — минем оныгым булыр... Бала хакы — Ходай хакы... Ходай хакы өчен сорыйм, ярдәм итегез аңа... Ә хәзер... барыгыз, чыгыгыз... Үземне генә калдырыгыз... Хушыгыз... Бәхил булыгыз... Үлемтеккә дигән акча — баш очымда...

Картның үтә дә сәер сүзләреннән аптырабрак калган халык бераз тын торды, аннары, бер-беренә карашып аңлашкандай иткәч, акрын гына кузгалыша башлады. Кешеләр, ишек ягына борылгач та, каерылып, чын булдымы соң бу дигән кебек, күзләрен йомып, ап-ак иреннәрен кыймылдатып, үз эченнән дога укып ятучы картка карап-карап алдылар. Чын иде бу. Чын әкият иде. Ләкин әкият моның белән генә бетмәде, шул вакыт ачык ишектән, кешеләрне аралап, дәшми-нитми генә бер малай килеп керде. Кулында — бөгәрләнеп, тузып беткән белдерү кәгазе…

Менә ул, килеп кергән уңайга, кабаланып түргә — Әхияр карт яткан түшәк очына узды. Аннары, үзенең кояшта янып каралган кулларын юрган өстендә яткан ап-ак беләкләргә куйды да Әхияр карт, аның изге җанлы күршеләре, бөтен кешелек, бөтен дөнья тилмереп көткән серле сүзләрне әйтте: «Дәү эти…»

*2004*

## *САГЫШЫҢ БУЛСА, СУГА САЛ*

*(Повесть)*

### 1

Дөреслектә, таш таулардан елгалар ага, зур таш ярылса, эченнән су чыга һәм, Аллаһыдан куркып, таулардан таш ярылып төшә…

*«Коръән тәфсире»,*
*«Сыер» сүрәсеннән 74 нче аять*

Сайдәгә әллә нәрсә булды. Болай да үз эченә бикләнеп яшәүче кыз бөтенләй күңеленә йомылды, дәшмәс-сөйләшмәс булды, көннәрен өйдән, авылдан читтә — Җидесу елгасы буенда үткәрә башлады. Элек-электән: «Сагышың булса, суга сал, халык аңламаса, балык аңлар», — дигәннәр бит. Сайдә дә моң-сагышын суга салырга уйлады, ахры, әмма ни гаҗәп, һәр китүеннән ул тагын да сагышлырак, ямансурак булып кайтты…

Рәхилә кызын бу сәер гадәтеннән тыярга тырышып карады. «Суны сагышка, диләр, балам, йөрмәле шунда, су җеннәренең алып китүе бар, быел да кар өстендә аларның ялан тәпи эзләрен күргәннәр… Алып китмәсәләр дә, алыштырып, җиңеләйтеп куймагайлары…» — дип, бер генә түгел, йөз мәртәбә әйтте.

Сайдә аны тыңларга уйламады да. Иртән торуга, җилкапка келәсенә бау ташлап, Җидесу елгасына алып баручы үр сукмакка төшә. Бу сукмак буенда берничә чишмә агып ята. Сайдә аларның һәрберсеннән берәр уч су эчеп китә, гүя ул шулай Җидесуга үзенең киләсен алдан ук хәбәр итеп куя…

Рәхилә үзенең ана күңеле белән аңлый да соң, — Сайдәсе болай гына, юктан гына йөрми. Язмышын эзләп йөргән кеше генә шулай онытылып, сагышланып йөри ала. Газиз анасын тыңламыйча чыгып китә ала. Язмыш эше бу, язмыш… Бүтән нәрсә түгел.

Ә бәлки? Бу хакта бик ачылып уйларга кыймаса да, Рәхилә кызындагы үзгәрешләрне тагын бер нәрсәгә юрарга тырышып карады. Кияүгә чыгарга, тормыш корырга вакыты җитмәгән микән аның? Шуңа да яшь күңеле ялкынсынып йөрми микән?

Ә бит Сайдәгә әле егерме яшь кенә. Ике ел элек мәктәпне тәмамлагач, колхоз фермасында сыер савып йөргән иде. Начар эшләмәде, гел алдынгылар рәтендә булды. Ләкин быел яз колхоз таралды, колхоз белән бергә ферма да таралды. Калган малларны элек тирече булып йөргән Хөсәен сатып алган, диләр. Ул хәзер фермер булып йөри икән.

Кияүгә сораучылар бар барын. Шул ук Хөсәеннең Рәзил исемле малае Сайдәгә аяк атларга да ирек бирми, йөдәтепме йөдәтә. Шул бәйләнчек аркасында Сайдә Хөсәеннәргә эшкә бармады. Урамда очраганда да аулак почмакка сөйрәп җәфалый бит ул. Югары очтагы Зәйтүнә балага узгач, аның кем икәнлеге ачылды ачылуын… Ләкин бу азгын бәндәне берни эшләтә алмадылар, район прокурорына сыер илтеп котылган, диделәр. Булыр да. Әтисе токкан малларның итен сату белән шөгыльләнә бит ул. Хәзерге вакытта районда май заводы төзеп ята, ди. Авылга яңа тегермән корырга уйлый, ди…

Сайдәгә әйтмичә генә, әллә ничә мәртәбә Рәхиләгә дә сүз катып карады Рәзил. Юмалап булашты, янаган кебек тә булды. Берсендә ике капчык бодай китергән, күз дә йоммыйча:

— Сайдәне бирсәң, байлыкка күмәм, әлегә менә шулар, — дип тора, оятсыз.

Күмәр дә анысы, тирә-якта бер бай бит ул; тик бер байлык белән генә нишлисең, ярты айлык кына бит ул.

Рәхиләләрнең оннары бетеп, иписез утырган чаклары иде.

Кашларын җыерып булса да:

— Нәрсә эшлим мин бу ашлык белән, аны ничек, кайда тарттырыйм?.. Җидесудагы тегермән туктаганга да бишбылтыр бит инде, — дип сөйләнде.

Рәзил ике капчык бодайны кире алып китәргә мәҗбүр булды, әмма, ике көннән өч капчык он итеп, кабат китереп куйды…

Бу хакта Сайдә дә белде. Әнисенә бик нык үпкәләсә дә, дәшмәде. Аның җир белән күк арасында яшәгән вакыты иде шул. Алай гына микән? Шундый адәми җаннар була, алар тормыштан түгел, тумыштан гамьле, сагышлы булалар. Сагыш — аларның гомер юлдашы, җан җылысы, хәтта… рухи таянычы да.

Сайдә кечкенәдән боек карашлы, моңсу йөзле кыз иде. Кеше күзенә күренеп үсмәде. Өйдә чигү чигеп тик утырды. Сигез яше тулганда, әтисе үлеп китте. Нәрсәдән үлгәнен дә белми калдылар. Бик ярата иде Сайдә үзенең әтисен. Алар икәүләп Җидесуга балыкка йөриләр иде, яр буенда утырганда, әтисе аңа кызыклы тарихлар сөйли иде. Бу тарихлар бер дә әкиятне хәтерләтмиләр, Сайдә аларга бөтен күңеле белән ышана иде. Бигрәк тә Түләк белән Сусылу хакындагысын тыңлаганда, Сайдәнең кечкенә йөрәге ярсып тибә башлый иде…

*«Бачман хан — бер хан углы иде, халкы, нигъмәте, акчасы күп, йорты киң иде. Алтмыш егет хезмәтчесе бар иде, һәрберсен баласыдай киендереп, бизәп йөртер иде. Алтмыш беренчесе Миркасыйм углы Түләк атлы иде. Түләкне хан үз катына алды.*

*Көннәрдән бер көнне Бачман хан ауга чыкты. Нинди генә кош очса да, аны Түләкнең ябалагы ала торган булды. Алтмыш егет аңа көнләшеп, хөсетләшеп карадылар, атының тоягына үткер тимер кадак суктылар. Хозыр Галәйһиссәлам очрап, Түләккә әйтте: «Әй углым, алтмыш егет, сиңа дошманлык кылып, атың тоягына үткен тимер кадак суктылар. Шушы «Исме әгъзам» догасын укып өшкерсәң, кадаклары төшеп, атыңның аяклары сау булыр», — диде.*

*Иртә булды. Атларына атландылар. Түләк бер күл буена китте. Егетләр хәйлә уйладылар. Берсе Түләк атының йөгәнен алып, икенчесе бик каты итеп камчыларга килештеләр, ат үзенең иясен бәреп-сугып калдырырга тиеш иде.*

*Чынлап та, Түләкнең аты алты көн туктамыйча чапты, җиденче көнгә чыккач, ул олы дәрья буена килеп туктады.*

*Ул сәгатьтә Түләк үзенең аты туктап калган җирдә бер кызны күрде: йөзе гаять гүзәлдер, кем күрсә, гыйшкыннан җан бирердәй булыр иде. Ул су пәрие Чачдар хан дигән падишаһның Сусылу исемле кызы иде. Бу кыз, Тәүләкнең аты туктаган җиргә килеп, һәр иртәдә чәчен тарар иде. Кыз чәчен тарап утырган вакытта, Түләк, атыннан төшеп, аның янына килде. Кыз тоймады. Чәченең озынлыгы алтмыш карыш бар иде; чәчен ике яңагына салып, тарап утырган вакыты иде. Түләк килеп кызга сәлам бирде. Кыз, чәчен йөзеннән күтәреп, әйләнеп карады, Түләкне күрде, аһ итеп, үзалдына әйтте: «Бу егетне берзаман алдаламасам, ияреп китүем бар», — диде. Кызның ул сәгатьтә барча тәне калтырады, торырга һич дәрманы калмады. Түләккә ул шундук гашыйк булды…*

*Түләк кызга җыру әйтте:*

Инеп килдем атымнан,
Имде күрәсең үзеңә,
Сәлам бирдем мин сиңа,
Айтик күрекле йөзеңә.
Гашыйк булдым мин сиңа —
Нәзек зифа буеңа,
Сүзең әйтче, Сусылу!

*Кыз Түләккә әйтте:*

Мин усалның үзенә
Гашыйк булма, бай углы;
Безнең җирләр каты җир,
Түзалмассың, бай углы;
Хаста булып үләрсең,
Кайтып киткел, бай углы! —

*дип, Түләкне калдырып, үзе суга чумды. Алтмыш карыш чәченең алты карышы суга кермәгән иде — Түләк кызның чәчен беләгенә урап алды. Шулай ияреп барып, кыз судан чыкканчы беләгеннән җибәрмәде…»*

Сагышлы кеше ятим үсәргә тиеш, дигәндер инде, Ходай Тәгалә Сайдәнең әтисен бик иртә үзенә алды, аның каравы әнисенә ныграк якынайтты, бер җан, бер тән итеп, бер-берсенә беркетеп-ябыштырып куйды. Бер итеп бетерә алды микән соң? Әнә бит Рәзил белән ничек сөйләшеп, килешеп йөргән аның әнисе… Аны ничек тә аңларга тырыша Сайдә. Ялгыз бит ул. Ә ялгызлык авырудан да, шаукымнан да хәтәррәк…

Бүген шул хакта уйланып йөрде Сайдә. Ана күңеленә изгелек кыяфәтендә үтеп керергә тырышкан Рәзил хакында. Мәхәббәт хисен, сөйгән ярларны сатып алып була микәнни соң? Мәхәббәт язмыш кебек бит ул, исәп-хисап белән бер уртаклыгы юк аның. Әнә бит Түләк батыр, үзенең мәхәббәте өчен, Сусылуга ияреп, дәрья төбенә үк төшеп киткән, үзен айсыз, көнсез дөньяга дучар иткән.

Шулайдыр, мәхәббәт — үзе кояштыр. Бөтен кайгыларны оныттыра, караңгы дөньяларны, уйларны яктырта торган изге кояштыр... Их, килсен иде Сайдәгә дә шундый мәхәббәт! Очрасын иде бер батыр егет! Сайдә аның белән җиде кат күккә дә, җиде кат җир астына да, хәтта, Түләк кебек, су астына да төшеп китәргә риза булыр иде.

Җидесуның буйларыннан
Таптым ал кашлы йөзек.
Су төпләренә төшсәң дә,
Алып чыгармын йөзеп...

Сайдә үзалдына җырлап җибәргәнен сизми дә калды. Ул бит әле җырларга ярата! Анысы да әтисеннән. Ул Сайдәгә бик күп җырлар өйрәтеп калдырды. Әтисе кебек, Сайдә дә халык җырларына Җидесуны кушып җырлый. Аны кушсаң, җыр тагын да моңлырак, мәгънәлерәк чыга. Уйлап, борчылып, кайгырып утырасы да юк, бары тик тоясың гына, шушы дөньяны, табигатьне, агачларны, елганы, андагы һәрбер дулкын чайпалышын тоясың... Җыр кешегә шуның өчен кирәк тә — тояр өчен; әтоем ул — изгелек, илаһилык билгесе...

Җидесуларны буйласам,
Буйласам — буйламасам,
Уйламасам гына йөрим,
Һуштан язам уйласам...

Җидесу елгасы — бик кызык, хәтта сәер елга. Камышлы авылын урап чыга да Агыйдел ягына китеп югала ул. Ә менә аның каян агып килгәнен төгәл генә әйтә алмыйлар. Ул якка ерак барырга тырышмыйлар. Куе, кара урман төпкеленнән ургылып килеп чыга, ди ул, шул гына мәгълүм...

Җидесу сулары кебек
Тар сулар булмас инде.
Минем йөрәккәем кебек
Ярсулар булмас инде.

Үзе тар гына булса да, тирән һәм гайрәтле елга ул. Җидесу аша йөзеп чыкканда, атлар ага торган булган. Ул үзенә алган адәм балаларының исәбе-хисабы юк, ди. Анда су җеннәре яши дип тә сөйлиләр. Камышлыга килгән зыянны шуңардан күрәләр дә. Су өстеннән салмак кына ага торган томанга төренеп йөри, имеш, бу су рухы. Ә үзе чын кеше кебек, ди...

Җидесуларда күк томан,
Җилсез таралыр микән?
Сагышлар уратып алса,
Кемнәр аралар икән?

Бу «су җене»н кайчандыр тегермәнче булып торган Аманулланың өрәге дип тә сөйлиләр. Күргән кешеләр дә бар икән — тач шул тегермәнче, ди... Кайчандыр аны хатыны белән бергә тегермән ташы басып үтергән булган, җиде яшьлек малайлары сәер генә юкка чыккан. Сайдә әле дә хәтерли — бу мәрхүмнәрне аның әтисе белән бер көндә күмделәр... Кешеләр, бер-берсенә пышылдашып: «Бер көндә өч сәер үлем...» — дип сөйләнделәр.

Сайдә боларның барысын да аермачык хәтерли. Шул вакытлар турында уйлый башласа, йөрәге жу итеп китә, шундук теге тегермәнчеләр белән бәйле шомлы фаҗига исенә төшә... Шуңа күрә дә ул елга буйлап ерак бармый, урман эченәрәк бераз керә дә, Камышлы авылы күренер-күренмәс кенә калгач, тегермәнгә алып бара торган юлдан ярга таба тайпыла, аннары, тезләрен бөкләп, куе, тыгыз булып үскән бәбкә үләненә утыра... Текә ярга сырпалана-сырпалана агучы суга төбәлә... Аратирә генә карашларын күтәреп, чәбәләнә-чәбәләнә урман куелыгына кереп киткән елга очына карап ала, үзе дә, күңеле белән шул елга суына ияреп, серле дә, шомлы да Карурманга кереп китә. Әйе, халык аны ничек бар шулай — «Карурман» дип йөртә. Менә шул Карурман эченә Җидесу буйлап ярты чакрымлап кергәч, кыя-тау кебек караеп, тузып, зәгыйфьләнеп, бер якка кыйшайган су тегермәне каршы ала да инде. Елга буйлап тагын да арырак китсәң, җиде инеш суының, бергә кушылып, елга булып ага башлаган урынына җитәсең... Җидесуның атамасы да әнә шул инешләрдән алынган булып чыга.

Елганың сере моның белән генә бетми әле. Әлеге җиде инеш суы да, җиде яклап, кеше үтә алмаслык куе әрәмәләр, төпсез сазлыклар белән уратып алынган Ябалак тавы төпкелләреннән чабып килеп чыга... Ул таудагы иңкүлекләр, мәгарәләр хакында риваятьләр йөри Камышлыда! Оча торган кеше турындагысы бигрәк тә кызык һәм... куркыныч. Имеш, ул кеше кыяның иң очына менә икән дә, кулларын канат кебек як-якка җәеп, астагы елга куенына башы белән төшеп чума икән. Югалган малларын эзләп йөрүче көтүчеләр күреп калган...

Ябалак тавына бик йөрергә кушмыйлар. Шулай да бала чагында Сайдә, әтисенә ияреп, берничә мәртәбә шул якларга барган иде. Җиде су бергә кушылган урында елга җәелеп, киңәеп китә. Әнә

шул дәрья сыман урында балык күп була торган иде. Тегермән тирәсендәге яр куышлыкларында да балык әйбәт эләгә. Тирә-яктагы күлләрдә дә...

Әйе-әйе, Җидесу елгасыннан читкәрәк тайпылып, урман куелыгына керсәң, шунда ук күлләр тезмәсенә тап буласың. Нindиләре генә юк аларның — Сары күл, Ачылы күл, Сагышлы күл, Елак күл, Сакаллы күл, Тулгак күле... Һәр күлнең, һәр исем-атаманың үз тарихы бар. Хәзерге Камышлы кешеләре аларны белеп тә бетермиләр инде. Имеш, бу күлләрнең суы җир астыннан үзара тоташып беткән, алар хәтта Җидесу елгасына кадәр саркып чыгалар, ди... Элегрәк моңа бик ышанмыйлар иде. Ачылы күлдә батып үлгән кунак кызын Җидесудан табып алгач кына моның шулай булуына тәмам ышандылар.

Тегермән янындагы ике текә яр арасына асылмалы күпер тартылган. Аның да сере бар — һәр язда, кешеләр ул якларга барып җиткәнче, күпернең сынык такталарын, җимерек киртәләрен кемдер төзәтеп, алыштырып куя. Элек бу эшне тегермәнче Аманулла башкарган, хәзер ул аның өрәгенә калган, дип тә сөйлиләр... Тәүбә-тәүбә, Алла сакласын! Иң мөһиме, кешеләр килгәндә, ул күпер йөрергә әзер булып тора, ди...

...Бүген елга тыныч ага. Өстеннән дулкыннар да йөгерешми, яр читендәге күбек тә калын түгел. Җәй уртасында елга нәкъ шулай була. Җитмәсә, аның кытыршы йөзен тупыл мамыгы сырып алган...

Нindидер серле-сихерле, хәтта моңлы, шомлы, шаукымлы мәл бу. Елга өчен генә түгел, күңел өчен дә. Иң мөһиме, Сайдә бу моңны аермачык тоя, сизә. Җаны белән, язмышы белән тоя. Аңлап бетерми, бу әллә ни әһәмиятле дә түгел, тоя гына.

Шуңа күрә тирән уйларга бирелеп, борчылып уйланмый, бары тик моңлы итеп җырлый гына:

Җидесуның суы салкын,
Төбе комлыга күрә;
Моңлы җаннарны яратам,
Үзем моңлыга күрә.

Кичке эңгергә дә күп калмаган. Әмма кайтасы килми. Җидесу буенда тагын утырасы килә, җырлыйсы килә, шушында мәңге каласы килә!..

Җидесуларны буйлама,
Бик күп уйлар уйлама;
Бик күп уй уйлаган бала
Була икән дивана...

— Дивана булып каласың бит инде, кызым, йөрмә шул су буйларында дип ничә мәртәбә әйтергә кирәк сиңа?!

Сайдәне әнисе орыша-орыша каршы алды. Бер сүз дә җавап кайтармыйча, кыз әнисенә булышырга кереште, көтүдән кайткан малларны ябып, сыерларын саварга әзерли башлады. Ләкин Алмакайны саварга туры килмәде — аның имчәгендә бер генә тамчы да сөт юк иде...

— Сауганнар... — Рәхилә, нindидер бәлагә тарган кеше кебек, сөмсере коелып, буыннары йомшап, утар коймасына сөялде.

Авыл көтүендәге сыерларның сөтсез кайтуы хакындагы хәбәрләр моңа кадәр дә ишетелгәли иде. Бу хәлне төрлечә юрап карадылар. Кемдер әлеге хилаф эшне яланда уйнап көн итүче авыл балаларыннан күрде, кемдер урманнарда яткан качкыннар, этрәк-әләмнәр хакында гәп куертты, өченче берәүләр: «Бу теге Су җененең эше генә, бүтәнчә түгел», — дип, авыл халкының болай да шик-шөбһәле күңеленә шом җибәрде...

## 2

Ул — Аллаһ — күктән яңгыр иңдерде дә һәр елга үзенең микъдарынча агар булды; -
кечкенә булса да, зур булса да, елгадагы ташу суы үз өстенә чыккан күбекне күтәреп агар...
Су — Коръәннең мисалыдыр, әмма күбекләре — батыйль диннең мисалыдыр...»

*«Коръән тәфсире»,*
*«Күк күкрәү» сүрәсеннән 17 нче аять*

Бүген көн аеруча матур. Үзенчә матур. Әле кояшлы, әле яңгырлы. Яңгыр явып китә дә кояш чыга, явып китә дә кояш чыга. Гел шулай — җәйнең тап уртасында шундый берничә көн булып ала. Борынгылар бу мәлне «Тәңре туган көннәр» диләр. Ягъни дөнья яралган көн. Су белән уттан яралган бит ул. Кешеләр дә, бөтен тереклек тә... Шулай да иң беренче су булгандыр. Чөнки бүтән бөтен нәрсәләргә дә җан Тәңребез тарафыннан иңдерелгән, ә су башта ук җанлы булган. «Су — дөньядагы иң тере әйбер,— ди иде Сайдәнең әтисе. — Су — тормышның, яшәүнең нигезе; җан да уттан түгел, судан укмашкандыр әле, әнә бит фәндә язылган: кешенең күпчелек өлеше судан тора, диелгән...»

Бер чыланып, бер кибенеп Җидесуга таба баручы Сайдә үзенең уйларыннан үзе куркып китте. Куркырлык та, аптырарлык та шул — ул соңгы вакытта дөнья, галәм, кешелек, тереклек гаменә биреләп, яшәешнең асылы, тормышның мәгънәсе хакында күп уйлана икән. Дөресен генә әйткәндә, ул зур дөнья өчен җаваплылык тоеп яши башлаган икән.

Кеше якындагы бәхетен, дөресрәге, язмышын тойганда шулай була. Гүя менә хәзер, берничә мизгелдән аның тормыш юлы, кискен борылып, бөтенләй бүтән якка кереп китәчәк, бу юлның очында аны изгелек һәм ихлас мәхәббәт каршы алачак…

Җидесу буенда Сайдәне юл читендә печән чабып йөрүче Мәннән карт каршы алды. Сайдәләр урамында яшәүче бу карт аларга әтисе ягыннан туган тиешле. Ләкин алар аралашмыйлар. Сайдәнең әтисе аны яратмаган, алар арасында ниндидер серле мөнәсәбәтләр булган. Ул серне мәрхүм үзе белән кабергә алып киткән.

— Нишләп кенә йөрисең, кызым?

— Менә су буена төштем әле…

— Анысын күрәм. Нинди эшең төште, димен…

— Эшем юк. Болай гына йөрим.

— Сәер бит бу, балакай. Ялгызың гына су буенда йөрүең, димен.

— Сәер? Ә нишләп сәер булсын?

— Хәзер бит без барыбыз да эш кешеләре. Ә син… эшсез генә йөрисең… Шул сәер дә.

— Бер дә сәер түгел, Мәннән абзый. Мин йөрим, уйлыйм, җырлыйм…

— Кара аны, балам, урманның да, суның да шаукымы тиеп куя кайчакта адәм баласына. Урман зәхмәте, су сихере кагылмасын, шуңа борчылып әйтүем…

— Борчылуың өчен рәхмәт, Мәннән абзый. Син дә әни әйткәнне әйтәсең. Бернәрсә дә булмас, бездә табигать әйбәт ул, игелекле, мәрхәмәтле…

— Шулай була күрсен. Тик… барыбер… озак йөрмә, яме?..

— Ярар, Мәннән абзый, озак йөрмәм. Сау булып тор…

Сайдә елга буйлап эчкәрәк керде. Авыл күздән югалып, алда иске су тегермәненең килбәтсез шәүләсе караеп күренә башлады. Ләкин Сайдә бер тамчы да курыкмады, хәтта шикләнмәде дә. Әле урман эченнән, әле елга буендагы үзәнлекләрдән чалгы кайраган тавышлар ишетелеп кала, әле машина-трактор тавышлары гөрләп куя, кайдадыр якында гына көтү йөри. Беренче карашка гына тыныч кебек; искә алып торсаң — бөтен җирдә тормыш кайный, дөнья шаулап тора…

Сайдә тагын да эчкәрәк керергә булды. Янәшә пар сукмакны хәтерләткән иске арба юлыннан атлый торгач, ул җил-яңгырдан караеп торган мәһабәт тегермәнгә килеп чыкты. Шунда ук алъяпкыч кесәсендә йөргән түгәрәк көзгене капшап куйды. Ялт кына кулына алып, үрелеп карады. Ап-ачык йөзе дә, зур зәңгәрсу күзләре дә, ярым ай кебек зифа кашлары да, тар, матур иреннәре дә, яңгырда чыланып, кояш астында бераз бөдрәләнеп кибә башлаган чәчләре дә үз урынында иде. Хәтта бит очларындагы мәхәббәт чокырлары да кояшлы яңгыр астында уңмаган, юылмаган булып чыкты…

Кинәт көзгене исенә төшерүе юктан түгел. Бу да әтисеннән калган гадәт. Явыз рухлар, җен-пәриләр куа чыкса, артка ташлап калдыру өчен кирәк ул. Әкиятләрдәге кебек. Ике арага ташласаң, көзге шунда ук үтеп булмаслык дәрья-суга әверелә дә явыз затларның юлын бүлә, сиңа якын җибәрми…

Дөрестерме, юкмы, әмма Сайдә моңа ышана, үзе белән һәрвакыт көзге йөртә. Аның әтисе бервакытта да ялган сөйләми иде. Шүрәленең судан курыкканын да, өрәкләрдән су сибеп котылып булганын да, күз тиюдән җиде вакыт чишмә суы яисә иртәнге чык белән юынып терелеп булганын ул әтисеннән ишетте. Менә әле дә әтисенең рухы аның белән кебек; ул кызын төрле бәлаләрдән саклап, аралап бара кебек…

Әтисен исенә төшергәч, Сайдә батыраеп китте. Кара такталары белән өркетеп каршы алган су тегермәне аның күзенә бераздан җимерек алачык булып кына күренә башлады. Аның инде чыгыры юк, ялгашлары тузып, чәчелеп ярда ята. Ишек-тәрәзәләре шар ачык; су эчендәге терәү баганалар янтаеп авып төшкән дә, тегермән диварларын җимереп, эчкә кергән… Тирә-ягында ватык арба тәгәрмәчләре, мичкә кыршаулары, иске-москы такта-киртәләр ята.

Кошлар күп икән монда. Каргалар… Шулай да иң күбе күгәрченнәр… Араларында аклары да бар. Ак күгәрченнең әйбәткә юралуын Сайдә белә. Шуңа күрәме ул, тагын да ышанычлырак атлап, тегермәнне узып киткәнен сизми дә калды. Тиздән иске ат юлыннан калган пар эз ялгыз сукмакка әверелде. «Кеше йөри икән әле моннан, — дип уйлап куйды Сайдә, тирә-якка шом биреп торган мәһабәт нарат-чыршыларга, биек усакларга игътибар итмәскә тырышып. — Балыкчылар, аучылар йөридер инде. Әллә… рухлар эземе бу? Әнә бит сукмак юлында бер эз дә юк. Кешеләрдән соң эз булырга тиеш иде! Йөргәннәр, ә эз юк… Сәер бу… Нишләп булмасын, әнә бер эз. Сайдә алдыннан гына кемдер ялан тәпи үтеп киткән. Ләкин бала-чага түгел бу. Нишләп? Олылар яланаяк йөрмиме әллә? Кыр сукмагында яисә юл тузанында яланаяк йөрү үзе рәхәт ләса…»

Сайдә дә чүпрәк чүәкләрен салып кулына тотты. Шунда ук сукмакның дымлы комында, баягы зур эз янында, Сайдәнең ялан тәпиеннән төшеп калган кечкенә тамга пәйда булды.

Алда Җидесуның туган бишеге — киң дәрья күренде. Елга да, дәрья да тынгысызланып, күбекләнеп ага бүген. Яңгыр явып торган көнне су күбекле була шул. «Кешеләр судан яралса, яман затлар аның күбегеннән барлыкка килгән», — дип сөйли иде Сайдәнең әтисе.

Бер сөзәк урынны сайлап, кыз су буена йөгереп төште, аннары, тубыктан суга кереп, аягына килеп сырпаланган дулкыннар назына рәхәтләнеп, түргәрәк узды… Әтисе белән балык тотып утырган урыннарны карап үтте, каршы ярдагы карлыгач ояларын күзәтте…

Кинәт ява башлаган яңгыр шулай ук кинәт кенә туктап калды. Сайдә, яр башына менеп, якындагы куш каен төбенә барып сыенганчы, манма су булды. Юкка йөгергән икән, ул арада кояш чыгып, бөтен тереклекне өтеп-яндырып алырга теләгәндәй, зәһәр кыздыра башлады. Сайдә, күлмәген салып, каен ботагына элде, үзе, шәрә тәнен кояшка күрсәтергә кыенсынып, каенның җиләс ышыгында урын җайлады…

Яңгырдан соң су өсте караеп тора. Хәтта кояш та яктыртып бетерә алмый аны. Әкиятләрдә генә сулар сөттәй ак була бит ул… Әкиятләрдә генә сөт дәрьялары була…

Шунда ук Сайдәнең ниндидер сер-могҗиза сизенеп җилкенә башлаган күңелендә Түләк белән Сусылу хакындагы дастан яңарды.

*«Сусылу, Түләкне каратып, үзе суга чумды. Алтмыш карыш чәченең алты карышы суга кермәгән иде — Түләк кызның чәчен үзенең беләгенә урап алды. Шулай барып, кыз судан чыкканчы, беләгеннән җибәрмәде.*

*Берзаман Түләк көн, ай күренмәс җиргә чыкты. Бер пулат-сарай торыр. Аның алдыннан бертөрле инешләр агып барыр — берсе балдан, берсе сөттән, берсе нурдан, калган дүртесе судан иде. Түләк кызның чәчен һаман җибәрмәде. Кыз Түләккә әйтте: «Инде син — минеке, мин — синеке, чәчемнән җибәр; мин сарайга керим, түшәк салыйм, аннан соң сине чакырып алыйм».*

*Түләк кызга әйтте:*

Алты көн дә җиде көн
Атым алып килердер;
Алдамачы, Сусылу,
Ай йөзеңнән бер үпми,
Һич җибәрмәм, Сусылу!

*Аннан соң кыз әйтте:*

Алты көн дә җиде көн
Атың алып килердер;
Ашыкмачы, бай углы,
Бар буем синекедер;
Сабыр итче, бай углы!

*Кыз шулай дигәч, Түләк аның чәчен җибәрде. Кыз, сарайга кереп, бикләрен төшерде. Шул сәгатьтә сарайның Түләк басып торган җире һавага калыкты, әмма өч көн, өч төн үтсә дә, кыз Түләк янына чыкмады. Түләк намаз өстендә догалар укып әйтте: «Илаһи, бу кызны, кауме-халкы, малы-туары белән бергә, көн эсселеге белән бергә дәрмансыз ит!» — диде.*

*Шул сәгатьтә сарай тирәсендә аккан җиде елга да — бер бал елгасы, бер сөт елгасы, бер нур елгасы һәм дүрт саф сулы елга — барысы да тәмам корып беттеләр, һичбер эчәрлек су калмады, тереклек ияләре тәкатьсез булдылар…»*

Сайдә, үзен-үзе белештермичә, үзалдына пышылдап әйтеп куйды: «Җиде су, монда да җиде су!» Аның әтисе дә белгән бу хакта! Шуңа да Сайдәгә Сусылу белән Түләк әкиятен сөйләгән…

Сайдә уйларының очына чыгып җитә алмады, елга өстендәге күк йөзендә яшен чыбыркысы уйнап алды, аннары бөтенләй икенче яктан — су тегермәне тирәсеннән — галәм арбасы гөрелдәп узды. Ап-аяз көнне яшенле яңгыр башланды. Сайдә, күлмәген аннан-моннан гына эләктереп, каенның куерак ышыгына кереп чумды. Тирә-якны сырып алган сәрби куаклары арасыннан башын чыгарып, Җидесу дәрьясына төбәлде.

Һәм шунда ук ах итте! Телсез калды. Телсез генә түгел, аңсыз, хәтта җансыз кала язды. Яңгыр тамчылары биюеннән шадраланып, кытыршыланып торган су йөзе буйлап Сайдәгә таба бер сәер җан иясе йөзеп килә иде! Әллә яңгыр пәрдәсе шулай котсыз итеп күрсәтәме аны? Бер нәрсә ап-ачык иде — бөтен су өслеген тутырып таралган озын чәчле, алгарак чыгып торган зур күзле, килбәтсез озын куллы, гәрәбә тәнле бу җан иясенең адәми затлар белән берниндн уртаклыгы да юк иде.

Әллә яңгырдан, әллә куркудан Сайдә калтырана башлады. Тагын яшен яшьнәде, күк күкрәде.

Кыз, елга өстеннән күзен алмыйча гына, яшенгә карата әйтелә торган әфсенне исенә төшерде:

Ялт итте, йолт итте,

Елгага төшеп китте…
Тфү, тфү, тфү!
Елгага төшеп китте…

Сайдә бер нәрсәне чамалап алган иде: бу гыйбрәтле зат — су заты, бәлки әле аның ияседер, рухыдыр? Су анасыдыр? Риваятьләрдәге кебек, чәчләре ничек озын… Юктыр. Су анасы түгелдер. Әнә бит ул ничек киң алып йөзә, яурыннары калын, аркасындагы мускуллары бөкрәеп өскә калкып чыккан…

Яңгыр басылгандай булды. Су заты, йөзеп килгән җиреннән кинәт туктап калды, бермәл нәкъ Сайдә басып торган якка, яр буендагы куш каенга төбәлде… Сайдә тын алырга да, күзләрен йомарга да куркып, баскан урынында тораташ кебек катып калды. Су заты тагын бераз карап торса, билләһи, йөрәге ярылып, җан тәслим кылыр иде. Ярый әле теге хәшәрәт, бу якка карап торган килеш, салмак кына су астына чумып китте. Бүтән күренмәде. Һичшиксез бу Су җене иде, юкса ул су астында ничек яши алыр иде?

Сайдә, куышыннан чыгып, авылга таба йөгерде. Юлда тагын Мәннән карт очрады. Ул аты-ние белән бергә, иске тегермән ышыгында басып тора иде.

— Нәрсә булды, кызым, җеннәр куамы әллә?

— Мәннән… абзый… анда… анда… Су җене бар… Үзем күрдем… Елгада йөзеп йөри иде…

— Ә? Җен дисеңме? Беләм мин ул җенне.

— Беләсең? Каян беләсең?

— Күргәнем бар.

— Ничек инде? Ник бу хакта беркемгә дә әйтмисең?

— Ни файда?.. Барыбер беркем дә ышанмаячак… Көләчәкләр генә…

— Нигә көлсеннәр, чын бит ул, чын! Үз күзләрем белән күрдем!..

— Үзе күрдеме соң сине? Күрсә — әйбәткә түгел.

— Белмим… Бәлки, күргәндер дә… Бик озак карап торды. Аннары чумып китте… Кем ул, Мәннән абзый, ә? Кем ул?

— Кем булсын, Ходай бәндәсе…

— Җен түгелмени?

— Эчендә кем утырадыр, тыштан кеше ул.

— Су кызымы?

— Юк шул, Су егете.

— Ә? Су егете дә буламыни? Су кызы, Су анасы хакында гына сөйлиләр бит…

— Артык күп сорашасың син, балакай, әйдә утыр, кайтыйк булмаса… Әнә яңгыр да туктаган…

Алар кайтканчы сөйләшмәделәр. Карт атын тиргәп кайтты. Сайдә бу гаҗәеп хәлләрне ничек итеп әнисенә сөйләячәге хакында уйлап барды.

Ләкин аңа бу хакта кемгә дә булса сөйләргә туры килмәде.

Аерылышырга вакыт җиткәч, Мәннән карт кискен генә әйтеп куйды:

— Кызым, бу хакта дәшмәвең хәерлерәк. Хәтта әниеңә дә әйтмә. Шулай кирәк.

Сайдә, каршы әйтеп, сорашып тормады. «Ярар», — диде дә өенә йөгерде. Җидесуда йөзеп йөргән Су егете хакында беркемгә дә әйтмәде ул. Әнисенә бик әйтәсе килсә дә, телен тешләп түзде; әйтсә, аның үзенең тормышы, язмышы гына түгел, бөтен дөнья кителер, уалыр төсле тоелды аңа.

## 3

Аллаһ кешене бер тамчы судан халык кылды…

Вә ул — Аллаһ — җир өстендә дәрьяларны бар кылды һәм файдаланырга сезгә имканият бирде…

Вә ул, җир тетрәсен өчен, аның өстенә мәхкәм тауларны ныгытты вә сезгә елгалар бар кылды, җирдә һәм диндә юллар бар итте; шаять, Аллаһ күрсәткән туры юлдан китәрсез!

*«Коръән тәфсире», «Нәхел»*
*(Умарта кортлары) сүрәсенең 4,*
*14—15 аятьләре*

Җен-пәри күргән кешенең холкы үзгәрә, диләр иде, дөрес икән. Сайдәне күрше-күлән генә түгел, әнисе дә таный алмады. Аның кызын бер көндә алыштырдылар да куйдылар. Ул Җидесуга бармас булды, моңаеп-сагышланып утырмас булды, әнисеннән бер тотам да калмыйча, көйсез бала кебек ияреп тик йөрде. Моңа кадәр сөйләшмәгәннәрен кире кайтарырга теләгәндәй, бертуктаусыз сөйләнде, мең сорау биреп, әнисен йөдәтеп бетерде.

— Әнием, әйт әле, син яшь чакта нинди идең?

— Әнием, син әтиемә яратып чыктыңмы?

— Әнием, мине каян алдыгыз, кәбестәдәнме, әллә Җидесудан тоттыгызмы?

— Әнием, мәхәббәт нәрсә ул?

Иң ахырдан бөтенләй сәер сораулар бирә башлый.

— Әнием, син җен-пәриләргә ышанасыңмы?

— Алар нинди була? Акмы, карамы? Күзләре нинди?

— Шул ук кешеләрдер, әмма алар ниндидер бер могҗиза ярдәмендә табигатьтән туганнардыр, әйеме?

— Әнием, Су аналары, Су кызлары бар бит, ә менә Су егете буламы, юкмы? Ә?

Баштагыларына Рәхилә ничек тә җавап бирергә тырыша, ә менә җен-пәриләр хакында сүз чыккач, аптырабрак кала. Бар, дисә, хәвеф-хәтәрдән, кызның күңеленә тәшвиш кертүдән курка. Юк, дисә, хакыйкатькә хилафлык килер кебек. Бар бит алар, бар, моны бөтен кеше белә. Күзгә генә күренеп йөрмиләр. Су кызы булгач, Су егете дә бардыр; ул булмаса, алар нәселләрен ничек дәвам итәрләр иде соң…

Шуларны уйлый да, Рәхилә кызының соңгы сорауларын җавапсыз калдыра. Ул белми шул, Сайдә аңардан Су егете хакында болай гына сорый, ул аның бар икәнен белә инде, әнисенә караганда да, бүтәннәргә караганда да яхшырак белә. Ул аны күрде, юк, юк, алар бер-берсен күрделәр, таныдылар… Сайдә аны бераз гына ошата да, хәтта ярата да башлады инде… Аның бүгенге күңел күтәренкелеге, яшәү дәрте, ургылып, ташып торган йөрәк ярсуы шушы ымсындыргыч, серле-сихри тойгы белән бәйләнгән дә…

Өч көннән Сайдә үзенең элеккеге халәтенә кайтып төште. Элеккечә моңсу-ямансу кызына карап, Рәхиләнең җаны өзгәләнде. Ләкин ул бу юлы да үз җаныннан өзелеп төшкән бәгырь кисәген аңлый алмады. Бу шулай булырга тиеш иде. Ходай Тәгалә табигать кануннарын шулай яраткан инде: кеше үзенең язмышын мәхәббәт булган җирдән эзли, ә мәхәббәт сер булган җирдә яши, сер — табигатьнең асылы. Шул рәвешле кеше үзенең тәкъдирен түгел, язмышын эзләп, кешеләр арасына түгел, иң элек табигатькә, аның серенә, могҗизасына бара. Бигрәк тә бу сергә кагылып, аны тоеп өлгергән булса, ул инде аннан китә алмый, аны табуны, үзенеке итүне тормыш максаты, хәтта яшәү мәгънәсе итеп куя.

Сайдә белән дә шулай булды. Сер кайда, чынлык шунда, ди бит. Өченче көнгә чыккач, ул, ашыкпошык кына җыенды да, әнисенә дә әйтеп тормыйча, йөгерә-атлый Җидесу буена төшеп китте. Ул хәтта һәр барганда тукталып, суын кабып үтә торган чишмәләргә дә игътибар итеп тормады, иске тегермән яныннан да артык дулкынланмыйча, күңеленә якын алмыйча, шомланмыйча гына узып китте. Таныш куш каенга җиткәнче йөрәгенә кагылмады, күңелен җилкендермәде.

Ләкин, күзләрен авырттырып, кая ул күзләрен генә, йөрәген авырттырып, күпме генә күзәтсә дә, бу көнне Җидесу дәрьясында Су егете күренмәде.

Икенче, өченче көннәрне дә Сайдә теләгенә ирешә алмады. Аннары туп-туры Мәннән картларга китте. Карт барысын да белә икән инде.

Сайдәне күрүгә үк, исәнләшеп тә тормыйча әйтте дә салды:

— Син, балакай, яңгырлы көнне бар. Яңгыр яуганда чыга ул, диде. Үзе, Сайдәнең, берәр сүз әйтеп, бөтен эшне бозып куюыннан курыккандай, тиз-тиз генә өенә кереп китте.

Яңгыр озак көттерде. Сайдә, дөньядан ваз кичеп, яшерен уйлары белән яшәде дә яшәде. Рәхилә баштарак борчылып йөргән иде дә, соңрак кызының элеккеге халәтенә, үзенә, асылына кайтуын күреп сөенде генә. Чөнки ул белә, — Сайдәнең күңел халәте — әкиятләрдән, риваятьләрдән күчкән рухи образлар, каһарман йөрәкләр, тетрәндергеч язмышлар…

*«Көнсез, кояшсыз илдә су дәрьясы тәмам корыды, эчәргә су калмады, барысы да тәкатьсез булдылар.*

*Ул кызның сарае тирәсендә кырык хезмәтче бар иде, барчасы зифа йөзле пәриләр иде. Алар, җыелышып, кыз сараена килделәр, кычкырыштылар. Кыз тәрәзәләрен дә, ишекләрен дә ачмады.*

*Бу халыклар Түләкне күреп калдылар, аның бик матур егет булуын белделәр. «Кыз бу егеттән качып бикләнмеш икән, бу хәтәр эш шушы егеттән тора икән! — диделәр.— Инде ни кылмак кирәк, бу хакта кызның атасы Чачдарга барып әйтергә кирәк».*

*Аннан Чачдар ханга барып әйттеләр.*

*Чачдар хан ачуланып әйтте: «Ни өчен андагы халыкны һәлак итә ул? Егетне үзе кабул итмәгән булса, ул адәм бу җиргә килер идемени?! Барып кызыма әйтегез: сарайның ишек-тәрәзәсен ачсын, ул егетне үз катына алсын, гозерләр теләсен, дога үтенсен»,— диде.*

*Атасы әйткәч, кыз сарайның ишекләрен, тәрәзәләрен ачты. Шул вакыт кызның тәненә кояш яктысы төште һәм, күкрәгеннән кереп, аркасыннан чыкты,— кыз янып үлде. Пулат-сарай да ут эчендә калды. Шунда Түләк сарайга керде, кызны күрде, аның чәченнән урап алды, пулат-сарайның ишегенә сукты — кызның зиһене кайтты. Ул исен җыйды, күзләрен ачты һәм Түләкне күрде…»*

Андый яңгырлар җәйгә бер генә ява. Коеп кына түгел, чиләкләп яуды ул көнне кара яңгыр. Төшкә кадәр урамга да чыга алмады Сайдә. Иртән болай да соңга калып чыккан көтү, таралып, төшлек-

кә авылга кайта башлады. Алмакайны абзарга кертеп япкач та Сайдә тәрәзә каршында шактый утырды әле.

Ниһаять, көн ачылгандай булды. Кара яңгыр Агыйдел ягына китеп барды, җир өстенә томан кебек капланып сибәләп торганы Камышлы тирәсендәге урманнарга, әрәмәләргә ябышып калды.

Сайдә су үткәрми торган япмасын бөркәнде дә үзенең таныш сукмагына төште. Ләкин ул көнне аңа Җидесу ярындагы куш каенга барып җитәргә насыйп булмады. Иске тегермән ышыгында шашлык кыздырып торучы өч исерек егет аның изге юлына аркылы төштеләр. Мондый чакта нишләргә кирәген белми иде Сайдә.

Егетләрнең:

— Кая барасың бу яңгырда, әйдә безнең белән генә кал, бергә күңел ачарбыз, — дигән бәйләнчек сүзләренә:

— Китегез юлдан, юкса бөтен авылга рисвай итәм, — дип янады, аларны оялтмакчы, хәтта куркытмакчы булды.

Ләкин егетләр курка торганнардан түгел иде. Алар өчесе өч яктан Сайдәгә табан килә башладылар. Берсе кинәт туктап калды:

— Стоп, егетләр! Бу бит Рәзилнең булачак хәләле. Әйдә китсен үз юлына, бәласеннән баш-аяк!..

Икенчесе аңа каршы төште:

— Булса соң! Без белмәдек, и баста! Ә кызы шәп, моны ычкындырырга ярамый… Рәзил үзе дә кызлар ярата, безне аңлар…

Өченчесе Сайдәнең язмышын тәмам хәл итәргә тиеш иде. Ә аның сүзе кыз файдасына булып чыкмады.

— Рәзил үзе әйтеп торды, минеке булмаса, тотып сезгә бирәм, чиратка салырсыз, диде. Так что… рөхсәт бар…

Өч кешелек төркемдә явызлык күбрәк булып чыкты. Шулай да Сайдә аларга караганда көчлерәк иде. Чөнки аның максаты бар, барыр юлы, сукмагы бар, сере бар, могҗизасы бар… Бу серле могҗизага ирешми торып, явызлык кулына бирелә алмый ул, илаһи мәхәббәт ләззәтен татымаган килеш исерек ирләр астына да ята алмый!

Сайдә, бер якка кискен генә тайпылып, бөтен көченә йөгерә башлады. Ул үзенең авылдан каршы якка — Җидесу култыгына таба йөгерүен бераз баргач кына төшенеп алды. Куучыларның үзләрен күрмәсә дә, аларның аяк тавышларын, сүгенү сүзләрен, ара-тирә, берәр нәрсәгә абынып егылгач, ахылдап сүгенеп куюларын аермачык ишетеп барды. Сайдәнең зиһененә бик авыр барып җитте — ни өчен Карурман эченә, Җидесу дәрьясына таба йөгерә соң ул? Ни өчен авылга кайтмый, ни дип үз афәтенә таба чаба?

Сайдә бу сорауларга җавап бирә алмый иде. Аның катлаулы тормыш борылмаларыннан тукылган язмышы хакында, әле туып-яралып кына килүче, сәер, әмма саф, изге, бөек мәхәббәте турында Ходай Тәгаләдән башка беркем дә белми иде шул.

Сайдә, алдын-артын карамыйча, үлеменә барган кебек йөгерде дә йөгерде. Кагылган саен агачлардан сибелеп калган яңгыр чыгына чыланып, манма су булды, тотып калырга теләгәндәй каршына чыккан гөлҗимеш, сәрби куакларына сыдырылып, тырналып бетте, аягы таеп, берничә мәртәбә тайган сукмак ләменә капланып төште, торып тагын йөгерде, тагын егылды, тагын торды… Куркудан онытылган һәм, кайсыдыр егылуында кесәсеннән төшеп калган көзге хакында да белми калды...

Җидесу дәрьясы ярына килеп чыккан Сайдә, адәм балаларыннан бигрәк, өрәкне хәтерләтә иде. Үзе күз иярмәс тизлектә чаба, үзе эчке бер ачыргалану белән сулкылдап, шыңшып, хәтта чыелдап елый, кемнедер ярдәмгә чакыра, кемнедер сүгә, каргый…

Менә ул үзенең куш каены белән тигезләште һәм… беренче мәртәбә аны узып китте… Каен исә, туктале, болай тиз генә миңа хыянәт итә алмассың дигән кебек, суларын коя-коя шаулап, җилләнеп алгандай булды; шул вакыт Сайдәнең аягы таеп китте, һәм ул, тотынып калырга теләгәндәй, кулларын як-якка җәеп җибәрде, әмма тотыныр терәк таба алмыйча, текә ярдан аска — Җидесуның күбекләнеп кайнап торган суына егылып төшеп китте…

Җидесу аңа ят иде; ул Сайдәне, аның кечкенә вакытында әтисе белән килеп йөргән чакларын, һәр килгәнендә, күлмәгеннән бер җеп өзеп: «Алма мине, менә сиңа корбаным»,— дип, аны суга салуын оныткан иде.

Бу юлы күлмәгеннән җеп өзеп яисә берәр бөртек чәчен алып суга бирергә вакыты булмады аның. Бүген ул, ихлас җанын, саф тәнен яман бәндәләрдән саклап, үлемнең күзенә карап килде…

Шуңа күрә дә бу юлы Җидесу аңа ярдәм итмәде. Сайдә, ничек ярдан яралы кош сыман очкан булса, шул килеш Җидесуның төбенә төшеп тә китте.

Су төбенә төшә-төшә, ул егылганда кычкырган соңгы иңрәүле авазын да ишеткән кебек булды хәтта: «А-а-аh!..»

Сайдә үз хәлен бик яхшы аңлый иде. Зиһене яшен тизлегендә эшләсә дә, куллары-аяклары аны тыңларга теләмәделәр. Юк-юк, суга батып үләчәген тоеп һич үкенмәде ул. Аның бөтен үкенече, күпме көтеп тә, күпме ымсынып та курешмичә калган Су егете белән бәйле иде. «Их, күреп тә, сөйләшеп тә калып булмады, ичмасам,— дип уйлады кыз,— аңлашып өлгергән булсам, ул мине бу хәлдә калдырмас та иде…»

Аннары Түләк белән Сусылу хакында уйлады Сайдә. Менә алар су астында яши алганнар… Берберсен ярата, сөя алганнар… Әкиятләрдә генә була шул мондый хәлләр… Ә Сайдә чынбарлыктан, хакыйкатьтән ерагайды. Иң мөһиме, хакыйкать… Аның каравы һәр туу — хакыйкатьне раслау, һәр үлем дә хакыйкатьне раслау, шул гына…

Сайдәнең, сулышы буылып, зиһене томалана башлады. Гомеренең соңгы мизгелләрен тоеп, ул киң итеп күзләрен ачып җибәрде. Җидесуның караңгы, шомлы төбендә нәрсә күрергә теләгәндер ул, әмма бу караштa нindидер билгесез өмет чаткысы, алай гына да түгел, илаһи бер ишарә бар иде…

Бу өмет, бу ишарә Сайдәгә су төбеннән менеп килүче яктылык булып күренде. Ул яктылык йомгагы, як-якка нурларын чәчеп, һаман якыная барды. Тик шунысы гына, бу кояшның нурлары таралган чәч кебек кап-кара иде. Аннары бу кояшның күзләре бар иде, кашлары, калын матур иреннәре, куллары бар иде…

Менә бервакыт шул көчле куллар Сайдәнең үлеп баручы, хәлсез гәүдәсенә килеп кагылдылар да өскә — җем-җем итеп торган яктылыкка күтәреп алып менеп киттеләр… Әллә тыны-сулышы тәмам бетеп, әллә инде көтелмәгән очрашудан зиһене таралып, Сайдә аңын югалтты һәм илаһи нурдан гына торган бүтән сихри дөньяга китеп барды…

**4**

Әйт: «Корыда һәм суда караңгылыктагы курыкынычлардан сезне кем коткарыр?» Ул Коткаручы заттан түбәнчелек белән әшкәрәдә һәм яшерендә һәлакәтләрдән коткаруын сорыйсыз, әгәр бу һәлакәтләрдән коткарса, әлбәттә, Аллаһыга итагать итеп һәм гыйбадәт кылып шөкер итүчеләрдән булыр идек, дисез…

*«Коръән тәфсире»,*
*«Терлек» сүрәсеннән 63 нче аять*

Сайдәне авыл башындагы чирәмлектән Мәннән карт табып алып кайтты. Кыз җир белән күк арасында калган иде, шулай да инде үлем афәте узган, яшәү өчен көрәштә тереклек җиңгән иде.

Кыз бертуктаусыз әтисен чакыра, аннары нindидер Түләк, Сусылу белән сөйләшә, шушы изге сүзләргә ияреп, кабат тормышка кайтмакчы була иде…

*«Берзаман кыз исенә килде, күзләрен ачып карады, Түләкне күрде, әйтте: «Әй егет, бу эшне мин нәүмизлегемнән кылмадым. Мин җир-су асты патшасының кызы булам. Бу эшне дә атама фаш булсын дип кенә эшләдем». Ул янә әйтте: «Әй егет, моңа кадәр эшебез хәтәр иде, хәзер, Хак Тәгаләгә шөкер, эшебез дөрес булды. Атамнан рөхсәт бар, сине җефетлеккә алырга хәбәр килде…»*

*Түләк, Сусылуның бу сүзләрен ишетеп, олы мәхәббәт белән кызның муенына кулын салды. Кыз Түләккә әйтте: «Инде минем гаебемне кичер, — диде, — бу эсселектән хәлебез мөшкел булды, инде Хак Тәгаләдән үтенеп дога кыл, ул, гафу кылып, безне бу михнәтләрдән коткарсын. Егет әйтте: «Әй җаным, мәхәббәтем минем, бер сәгатькә генә сабыр бул, мин аулак җиргә барып, Хак Тәгаләдән хаҗәт теләрмен, син теләктә тор», — диде. Һәм, сарайдан чыгып, ике рәкәгать намаз кылды, «Исме әгъзам» догасына иман китерде, башын сәҗдәгә куйды, әйтте: «Илаһым, барча мөшкел эшләр дә сиңа җиңел торыр; бу кавемгә дә рәхмәт кылып, көн эсселеген китәреп, аларга мәхәббәтле яшәү бир»,— диде. Шул вакытта ягымлы салкын җил исеп, бал дәрьясы, сөт дәрьясы, нур дәрьясы, аннары дүрт яктан су дәрьялары ага башлады. Халыклар туйганчы йоклап, хәл җыеп, өч көннән соң тордылар, мал-туарларын карадылар…*

*Шул көннән соң Түләк белән Сусылуның мәхәббәтләре көннән-көн артыграк була барды…»*

Ап-ак түшәк өстендә тормышка кайтырга тырышып, саташып ятучы кызы өчен бигрәк тә Рәхилә өзгәләнде. Аңа күршедән кергән Сания абыстай белән Нәзилә ахирәте кушылдылар. Сания абыстай, ак яулык чылатып, «су ырымы» белән өшкереп-имләп тә алды:

Синнән — саулык, миннән — яулык,
Киртә тоттым, казык кактым,
Име-томы шул булсын!

Сайдәнең битенә капланган юеш яулыкны чеметеп алып, Нәзилә Җидесуга чыгып йөгерде, ә Рәхилә яулык чылатылган суны бакчаларындагы җиде еллык алмагач төбенә кертеп сипте…

Бөтен им-том шул булды. Әллә шушы ырымлы йола тәэсир итте, әллә әнисенең ягымлы сүзләрен ишетте, бераздан Сайдә күзләрен ачты, башын калкытты.

— И балакаем, исән генә булсаң иде инде, зәхмәтләрдән, шаукымнардан арынсаң иде; бер-беребезне кадерләп, бер-беребезгә таяныч булып, бик бәхетле тормышта яшәр идек… Ачсаң иде син күзләреңне, и кызым…

— Әнием?..

— Ә? Әү, кызым… Тордыңмы, уяндыңмы?

— Кайда ул?

— Кем, кызым? Кем?

— Түләк… Су төбендәге егет…

— Белмим, балам… Кемне әйтәсең соң син? Су төбендә кеше яшәми бит…

Куркынып калтыранган ана, йөрәген авырттырып булса да, кызының сәер сүзенә кушылып китте.

— Яши, әнием… Ул мине коткарды…

— Кем иде соң ул, балам?.. Мин берни дә аңламыйм. Нәрсә булды синең белән? Нишләттеләр сине?

— Мине… Рәзилнең егетләре куды…

— Сине?.. Мәсхәрә иттеләрме?…

— Юк… Су егете… Түләк коткарды…

Рәхилә бүтән каршы эндәшмәде, кызының сүзен җөпләп кенә торды:

— Бик әйбәт булган, кызым. Нинди изге җан очраган юлыңа… Мең рәхмәтләр аңа… Саулыклар, бәхетләр…

— Кайда ул, әнием?

— Белмим шул, балам. Түләк исемле егет безнең авылда юк бит. Сине бәбкә яланыннан Мәннән абзый табып алып кайтты…

— Мәннән абзый? Ул белә, әнием, ул барысын да белә… Су төбендә яшәүче Түләк хакында да… Минем аның янына барасым килә, аны күрәсем килә, әнием…

— Мәннән абзыйнымы?

— Су егетен, Түләкне!

Рәхиләнең бүтән әйтерлеге дә, түзәрлеге дә калмады.

Ул:

— И кызым, бу юлы нинди зәхмәтләр генә кагылды икән үзеңә? Хәерлегә генә булсын иде инде, хәерлегә генә… — диде дә, йөзен итәге белән каплап, кычкырып елап җибәрде.

Сайдәнең Җидесу буеннан иләс-миләсләнеп кайтуы хакындагы хәбәр шундук бөтен авылга таралды. Камышлы бер атна буе гөжләп торды. Ләкин баштарак кара сихер шаукымы дип кенә уйласалар да, берничә көннән килеп ирешкән хәбәр авылны сагаерга, Сайдә алып кайткан сүзгә ышанырга мәҗбүр итте. Хәбәр шуннан гыйбарәт иде: көтүчеләр Рәзилнең өч куштанын, иске сөзгеч-җылымнарга уралган килеш, Җидесу буендагы куш каен башыннан табып алганнар. Гади авыл кешесе генә күтәреп менгерә торган эш түгел бу. Димәк, рухлар эше. Теге Су рухы хакындагы сүзләр дөрес булып чыга. Рәзилнең хәчтерүшләре һаман да сөйләшә алмыйлар, ди. Күзләрен шардай итеп, ык-мык килеп тик торалар, ди. Аларның телләре ачылгач, хәл ачыкланыр анысы, әлегә Сайдә сөйләгәннәргә ышанырга туры килә; ышанмаган очракта да уйланырга, шикләнергә урын бар монда, гөнаһ шомлыгына каршы…

Чакыртылган фельдшер хатын Сайдәне озаклап карады, башын селки-селки, кабат-кабат кан басымын, йөрәк тибешен тикшерде.

Аның сүзе сискәндерерлек дәрәҗәдә сәер иде:

— Үлеп терелгән бу кызый… Йөрәге туктаган булган. Әнә әле дә ныклап эшләп китә алмый. Болай электрошок кына терелтә ала.— Гаҗәпләнүен яшерә алмыйча, аптырабрак калган фельдшер тагын бер нәрсә хакында сорап куюны кирәк тапты.— Миңа кадәр беркем дә карамаган идеме, «скорый» чакыртмадыгызмы?

Каян килсен Камышлыга «скорый»?! Аның килмәгәнен фельдшер үзе дә белә. Тик ул үз күзләренә һаман ышана алмый,— бу кызга карата ниндидер көчле шаукым кулланганнар. Шифалы, әйбәт шаукым. Су егете коткарган, Су рухы терелткән дигән сүз дөрес булып чыга микәнни?

Сайдә бик тиз терелде. Икенче көнне үк аягына басты, өченче көнне урамга чыкты. Һәм шунда ук кешеләрнең шик-шөбһәле, хәтта каһәрле карашы белән очрашты. Монысын һич тә көтмәгән иде ул. Аның нинди гаебе бар соң? Үзенең шундый булуында, табигатьнең, дөньяның шундый булуында нинди гаебе бар? Артыннан күрше урам башында яшәүче Сапый карчык таш атып калгач, Сайдә әнә шул хакта уйланды. Иң кыены алда булган әле — ул тиле-миле карчыкка ияреп, урам балалары да Сайдәгә таш ата башладылар…

Ул урамга чыкмас, кеше белән аралашмас булды. Үз тарихының шаһиты булган Мәннән карт аңа ничектер якынаеп киткән иде; бер кичне, эңгер-меңгер төшә башлагач, Сайдә кача-поса шул карт янына китте.

Мәннән карт аны көтеп торган кебек каршы алды, бу юлы да сүзне үзе башлады.

— Син, кызым, бер дә аптырама. Ничек яшисең, шулай яшә, калганын Ходай Тәгалә үзе җайлап урынына урнаштырып бетерә ул.

— Кыен миңа яшәү, минем нинди гаебем бар соң?

— Син бүтәннәргә охшамагансың, кызым, син... син безнең дөнья бәндәсе түгел, күбрәк табигать баласы, шуңа шулай ул...

— Син үзең дә шундыйрак бугай, Мәннән абзый...

Мәннән карт бу юлы дәшмәде. Нигә дәшәргә, болай да аңлашылып тора бит... Табигать иясе иисә Хода бәндәсе дисәләр дә, дөрес булыр иде. Шушы сәерлеге аркасында кайчандыр кешеләр аннан ваз кичә язганнар да инде. Бу хакта уйлавы да куркыныч хәзер.

Аның каравы Сайдә үзенең күңелен әрнетеп торган иң мөһим сүзне әйтте:

— Мәннән абзый, минем Җидесуга барасым килә, теге Су егетен күреп, рәхмәт әйтәсем килә. Әнием җибәрми, зәхмәт тияр, дивана булырсың, ди...

— Йөрәгең нәрсә куша, шуны эшлә, балакай, миннән сорама. Бер гомер эчендә болай да күңелемә күп авырлык алдым.

— Нинди авырлык ул, Мәннән абзый?

— Бер сөйләрмен әле... Сиңа сөйләргә ярый. Тик... Әлегә иртәрәк.

Мәннән картның «Йөрәгең нәрсә куша, шуны эшлә» дигән сүзе Сайдәгә «Бар, бар, Җидесудагы ул егет янына бар» дигән кебек ишетелде. Кыз шул көнне үк таныш сукмакка чыкты, тик бу юлы, чишмәләр ягыннан узганда, этисе өйрәткәнчә:

Су анасы Сылубикә,
Су атасы Сөләйман,—

дип, эчкән суына бәхиллек сорады, йола кушканча, үлән йолкып, ялгашлары буйлап агызды...

Көн кызу иде. Кояш, кадаклап куелган кебек, көне буе баш өстендә эленеп тора. Бераз яр буендагы куш каен ышыгында юангач, Сайдә су коенып алырга булды. Иң гаҗәбе, аның күңелендә куркуның әсәре дә юк. Үзе дә аптырады. Киресенчә, ул бөтен күңеле, йөрәк ярсуы белән Су егетенең чыгуын теләде. Белгән догаларын укыды, Ходайга ялынды, ялварды, әҗерләр, гозерләр әйтте...

Су егете күренмәде. Бу көнне дә, икенче, өченче көннәрне дә, аннан соң да күренмәде. Сайдә, тәмам гаҗизләнеп, кабат Мәннән карт янына китте.

Бу юлы карт аны көлеп-елмаеп каршы алды. Бәхет кошы тотканмыни!

— Ә беләсеңме, ул бит сине күрә, кызым. Ул сине үз итте, яратты.

— Каян беләсең боларны, Мәннән абзый?

— Беләм, ул сиңа зыян эшләми, шуннан беләм. Бүтән берәү булса, күптән бер-бер хәл кылыр иде инде.

— Ләкин ул бит күренми!..

— Иң мөһиме, ул сине күңеленә алды, калганы — җиңел эш...

— Җиңел булгач, ник әйтмәдең соң миңа?

— Ә син сорамадың...

— Әйт инде, Мәннән абзый, тизрәк әйт, нишләргә миңа?

— Йөзегең бармы? Көмеш булсын, кашлы булсын.

— Бар, бар! Кояш кашлы ярыймы? Әтием бүләк иткән иде.

— Ярый. Шул йөзегеңне елганың тап урта бер җиренә төшереп җибәр. Калганы Ходай Тәгалә кулында. Аның әле моңа кадәр табигатькә, мәхәббәткә каршы килгәне юк...

Сайдә йөгереп кайтты да этисенең истәлеге булып калган йөзекне эзләп алды. Бармагына киеп куйды. Зур көзге каршында әйләнгәләп торды. Аның күңеле күтәренке иде; ул инде эзләгәнен тапкан кебек, бәхетенә тарган кебек кылана иде.

Әллә шушы кыланмышлары белән үзенә үзе күз тидерде — бүген дә аның янына Су егете чыкмады. Йөзеге генә әрәм булды. Әнисе белсә, җанын алачак инде, монысы хак.

Сайдә күпме генә көтсә дә, күпме генә Җидесу уртасында йөзеп йөрсә дә — теләгән кешесен (Кешесен? Ә кешеләрдән кайсы җире белән ким соң ул?!) көтеп ала алмады. Су өстендә чакта кинәт кенә кемнеңдер көчле беләкләрен тойган кебек тә була, ләкин, таянам дигәндә генә, терәк тапмыйча, суга чума да китә, чума да китә...

Икенче көнне дә шул ук хәл кабатланды, Җидесуда япа-ялгызы йөзеп йөрүче бу кызны берәрсе күреп калса, чынлап та тилергән икән мескенкәй дип уйлар иде, мөгаен. Күргәннәрдер дә. Әнә бит

әнисенә әйтеп кайтарганнар: «Кызың Су җене белән ярәшкән икән, аның баласы бака булып туачак», — дигәннәр.

Сайдә елый-елый кайтып китте. Икенче көнне тагын шул куш каен төбенә килеп утырды. Бу урын аңа шулкадәр якын, кадерле булып китте, бары тик шушы агач төбендә генә ул үзен бәхетле итеп сизә, тоя ала икән бит.

Сайдә йөгереп килде дә, каен төбенә түшәлгән чирәмлеккә чалкан төшеп, сузылып ятты. Кулларын өскә сузып, ниндидер бер мөһим, изге сүз әйтмәкче булды. Бу сүз белән аның бүгенге бәхете, киләчәктәге язмышы хәл ителер төсле иде.

Ләкин ул бу матур, изге сүзне уйлап өлгерә алмый калды, аның кулы ниндидер бауда эленеп, балкып торган таныш йөзеккә тиеп китте.

Сайдә шундук сикереп торды, як-ягына каранды. Беркемне дә күрмәгәч, тагын йөзеге янына килде. Тапкан бит, тапкан! Менә ул — аның кояшлы йөзеге! Әтисенең истәлеге! Ах аны! Ничек хәйләкәр ул! Үзе китермәгән, күрер әле, табар әле дип, шушы каенга элеп киткән!

Сайдә нишләргә дә белмәде. Ул хәтта биеп, сикергәләп алды. Аннары тиз-тиз генә чишенде дә ярдан йөгереп төшеп китте. Күңел ярсуына түзә алмыйча, йөзеп-йөзеп, чумып-чумып уйный башлады. Үзе күңеленнән генә таныш җырны көйләде:

> Җидесуның буйларыннан
> Таптым ал кашлы йөзек.
> Су төпләренә төшсәм дә,
> Алып чыгарсың кебек…

Шул вакыт Сайдәнең бәхеткә тулышкан йөрәгендә ниндидер бер мөһим кыл чыңлап куйды. Бу чыңның нәрсәгәдер ым-ишарә булуы көн кебек ачык иде. Һәм Сайдә шушы илаһи ишарәне эзләргә кереште, күл өстен карап чыкты, ерактан сөмрәеп торган Ябалак тау итәкләренә, яр читендәге әрәмәлекләргә, камыш диңгезенә төбәлеп торды, аннары гына каршындагы яр башына күтәрелеп карады һәм… ах итте. Яр өстендә, андагы каенның өченче кәүсәсе булып, бер сәер кеше басып тора иде. Егет кеше. Сәерлеге дә әнә шул егет булуында, ахры. Аның киң кулбашына озын чәче таралып төшкән. Ә кояшта янган тән-гәүдәсе шулкадәр матур һәм камил, ул бары тик әкиятләрдә генә була торган әзмәвердәй каһарманнарны хәтерләтә иде. Биленә капланган тире итәге исә аның борынгы кыргый заманнардан килгән зат булуына тагын бер ишарә иде.

Ә йөзе… Ә күзләре! Алар шулкадәр тере һәм мәхәббәтле иде, Сайдә шундук үлеп гашыйк булды, аның шушы олы, матур күзләреннән карашларын ала алмыйча интекте. Су егетенең иреннәренә кунган сихри елмаюны күрергә теләде кыз.

Һәм ул күрде, күрде! Күрде дә тагын бер тапкыр гашыйк булды.

Сайдә судан чыгып яр башына күтәрелгәнче, егет шулай елмаеп басып торды. Аның йөзендә гаҗәпләнү белән аптырауның әсәре дә юк, гүя ул Сайдәне күптән белә, белү генә түгел, ярата, сөя!..

— Син кем? — Тамчы да курыкмыйча, шикләнмичә, беренче булып Сайдә сораша башлады.

Егет җавап бирмәде. Элеккечә елмаеп торуында булды.

— Рәхмәт, йөзек өчен рәхмәт.— Сайдә бармагындагы йөзегенә төртеп күрсәтте.— Әтиемнең бүләге ул…

Егет һаман шул килеш тора бирде. Сайдә, үрелеп, бармак очлары белән генә аның бүртеп-кабарып торган беләкләренә, кулбашларына, күкрәкләренә кагылып үтте, аннары чәчләрен сыйпап куйды. Егет тә шуны ук эшләде — Сайдәнең янбашларына, күкрәкләренә, яңакларына учларын куйды, чәчләрен тотып карады.

Сайдә шундук чамалап алды — бер дә рухларга, җеннәргә охшамаган бу егет. Балыкныкы кебек тәңкәләре дә, баканыкы кебек кул-аяк ярылары да юк, койрыгы-мазары да күренми…

— Син кем? Исемең ничек? — Сайдә тагын бер мәртәбә сорап карарга булды.

Егет кинәт җитдиләнде, әмма җавап бирмәде. Нидер әйтергә теләде, әмма шыңшып-ыңгырашып кына куйды.

Сайдәгә барып җитте — бу егет сөйләшә белми бит! Шулай да кыз аңа үзенең исемен әйтергә булды, шушы исем белән ике арадагы серле-сихерле халәтне мәңгелеккә беркетеп куярга теләде, ахры.

— Мин — Сай-дә! Сай-дә! — Сайдә уң кулын күкрәге өстенә салды. Егет тә уң кулын үзенең күкрәгенә якын китерде. Нидер әйтергә теләп, матур иреннәрен ачты, тик әйтә алмады, баягы кебек шыңшып, иңрәп кенә куйды.

Су кешесенең тәмам кәефе китте.

Ул бермәл, елардай булып, өзгәләнеп-ачыргаланып, Сайдәнең күзләренә карап торды, аннары, кырт борылып, елга ярына таба йөгерде. Шулай йөгереп барган уңайга, бар көченә этенеп кулларын як-якка җәеп җибәрде дә аска очып төшеп китте, артыннан су шапылдаганы гына ишетелеп калды.

Бу хәлләрдән Сайдә үзе телсез кала язды. Ләкин телсез калса да, хәтта аңсыз-җансыз калса да, ул бүген бик тә, бик тә бәхетле иде!

**5**

Ул — Аллаһ — ике зур суны янәшә агызды, ул суларның берсе эчәргә тәмледер, икенчесе эчәргә ачы һәм тозлыдыр, вә алар арасына пәрдә кылды вә бергә кушылудан тыя торган яшерен көчне араларына куйды.

*«Коръән тәфсире»,*
*«Аеручы» сүрәсеннән 53 нче аять*

Алар көн саен диярлек очраша башладылар. Бер-берсен көтеп, сагынып алалар. Сайдә кайчан гына пәйда булса да, Түләк (егеткә шулай дип исем куштылар) аны шундук килеп таба. Түләкнең үзе генә белгән аулак урыннары бар икән. Күбрәк шунда уйнап йөзделәр, сөйләшеп утырдылар. Дөресен генә әйткәндә, Сайдә сөйли, ә Түләк тыңлый. Ул бит кеше телен аңлый, тик җавап кына кайтара белми. Үзенең исемен әйткәнче дә хәтсез вакыт узды…

Сайдә аның кем икәнлеген һаман белми — адәм баласымы, әллә берәр рухи затмы, җенме, пәриме? Шулай да кешегә ныграк охшаган ул. Рухи затларның кул, аяк бармаклары йә дүрт, йә алты була, ә бу егетнең бөтен бармаклары да исән-сау, кешеләрнеке төсле. Албастыныкы кебек, култык астында куышлык та юк, Шүрәленеке кебек, аркасында эчке әгъзалары да күренеп тормый. Рухларның күз каралары да, кендекләре дә булмый… Ә Түләкнең бөтен җире дә үз урынында һәм шундый матур, камил!..

Сайдә әлегә аның кайда яшәгәнен дә, нәрсә ашаганын да белми, сорашырга курка. Ул бары тик аны сагына, аңа бөтен җаны-тәне белән тартыла, ымсына… Чын, ихлас мәхәббәттәге кебек. Ә мәхәббәт ул илаһи әйбер, җирнеке генә түгел… Ходай Тәгалә үзе дә мәхәббәт телендә сөйләшә, ди бит…

Иң авыры Рәхиләгә төште. Шул хыялый кызы аркасында аңардан бөтен авыл читләште. Ләкин ана кеше бик бетеренмәде, борчылмады. Чөнки аның кызы бәхетле иде. Баласы бәхетле булган ана нигә кайгырып утырсын ди... Шатланырга тиештер ләса...

Сайдә анасыннан бернәрсә дә яшермәде. Ничек бар — шулай сөйләп барды. Үз уйлары, күңел хисләре, шатлыклары белән уртаклашты. Рәхилә баштарак: «Йөрмә, кызым, бер очы чыгачак моның, юха пәриләре, сылу егет кыяфәтенә кереп, кеше алдап йөриләр, ди, шулай булмасын, кара аны», — дип кисәтеп торса да, бераздан дәшмәс булды. Кызының мондый шат, бәхетле чагын күргәне юк иде әле аның. Җитмәсә, тегесе ана кеше күңеленә тынычлык, сабырлык бирә торган сүзләр таба белде. Сайдә: «Шундагы көтүче егетләрнең берсе кебек кенә ул, әнием, аның хакында Мәннән абзый да белә, ышанмасаң, үзең сорап кара», — дигәч, Рәхиләнең күңеле тәмам урынына утырды, Ходай нәрсә язган булса, шул булыр, дип, ул язмышына буйсынып яши башлады.

Рәхилә тынычланды, ә менә Камышлының үзендә хәтәр җәнҗал туып, көчәеп кенә килә иде. Рәзилнең егетләре, телләре ачылуга, Су җене хакында бөтен күргәннәрен тәфсилләп сөйләп биргәннәр. Сүзе чыккач, күзе дә чыга дигәндәй: авыл кешеләре арасында бу су хәшәрәтен күргән кешеләр дә табыла башлаган. Имеш, ул шулкадәр килбәтсез икән, аны күрүгә, кеше шундук телсез, аңсыз кала икән. Әллә ничә куллы, әллә ничә аяклы бу җеннең маңгаенда бер генә күзе бар, ди, тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр…

Аның су өстенә кайчан чыгуын да беләләр, имеш. Яңгырлы көнне генә күренә ди ул; соңгы вакытта кояшлы көннәрне дә күргәләгәннәр, нәкъ көндезге сәгатьләрдә үзенең сылу хатыны белән уйнап-уйнап йөри ди теге җен заты…

Мәннән карт кына әйткән, имеш: «Ничә еллар буе бергә яшәгән бит — зыяны тимәгән, хәзер дә шулай яшәрбез, без тимәсәк, ул да тимәс, борчылырга урын юк», — дигән. Аңа каршы Рәзил хәбәр тараткан: «Барыбер тотып иманын киям мин аның, авылны өркетеп ятмасын анда», — дигән. Аңа бүтәннәр кушылган. Кемдер югалган сарыгын, кемдер сыерын исенә төшергән. Хәтта берничә ел элек суда батып үлгән кыз бала фаҗигасен дә шушы Су җененнән күрә башлаганнар.

Бу хәбәрләр Сайдәнең күңел тынычлыгын алды. Ул хәтта берникадәр вакыт Җидесу буена, Су егете янына бармыйча йөрде. Аның артыннан ияреп барырлар да Түләкне тотып алырлар кебек тоелды аңа.

Түзмәде. Китте. Түләк аны бик сагынган иде. Ул хәтта сөенеченнән, башын күккә чөеп, иңрәп кычкыра башлады. Егетнең бу кыланышы Сайдәне сискәндереп куйды — хайваннарга гына хас кыргыйлык бар иде аның бу кычкыруында…

Ләкин Түләк шундук көлеп-елмаеп җибәрде, Сайдәнең бөтен җирен карап, тоткалап чыкты, аннары, ымлап, кызны су коенырга чакырды.

Сайдәнең суга керәсе килмәде; ул, бер аулак җир табып, Түләкне сөйләшергә өйрәтә башлады.

— Син — Түләк…

— Син — Тү-ләк…

— Син түгел, мин…

— Син түгел, мин…

— Юк, син әйтергә тиеш: «Мин — Түләк», — дияргә тиеш…

— Мин — Түләк…

— Ә менә мин — Сайдә.

— Син… Сай-дә…

— Менә бит була. Тагын тыңла, исеңдә калдыр: менә бу — су, елга, ә анда — урман, урман артында — авыл, анда — кешеләр…

Түләк бик талантлы укучы булып чыкты. Берничә атна эчендә ул иң кирәкле сүзләрне белә иде инде. Сайдәгә шулай тоелды. Түләк кайчандыр бу сүзләрне инде белгән булган, хәзер ул аларны исенә генә төшерә. Әнә бит таныш сүз чыккан саен сөенеп куя, балаларча сикергәләп, уйнап ала…

Сайдә сизенә, хәтта төгәл белә: ниндидер сере, могҗизасы бар бу Су егетенең. Һәм бу сер, бу тарих иң элек кешеләр белән бәйләнгән.

Әнә бит Түләк үзе үк әйтеп тора.

— Мин — Түләк,— ди.

«Кеше» сүзен өйрәнгәч: «Мин — кеше», — дия башлады. «Тегермән» сүзеннән соң: «Мин — тегермән», — дип белдерде. Җитмәсә, бер — үзенә, бер — тегермәнгә төртеп күрсәтә. Нәрсә әйтергә тели соң ул — Ходай гына беләдер. Ләкин аның сере тегермән белән дә бәйле; бу көн кебек ачык.

Сайдә аңа һаман өйрәнеп җитә алмый әле. Егетнең матур, зифа тәне аны әсир итә, дәртле йөрәген ярсыта башлый; ул, үзе дә сизмәстән, Түләкнең тыгыз тәнен иркәләргә, назларга керешә. Ә Түләк… Түләк, Сайдә нәрсә эшли, шуны эшли, Сайдә нәрсә кылана, шуны кылана. Сайдә аның күкрәген сыйпап-назлап куйган иде, Түләк тә аның күкрәк япмасын күтәрде, бармак очлары белән сак кына кагылып, кызның тыгыз күкрәкләрен назларга кереште. Сайдә рәхәтлектән аңын югалта язды. Аның күкрәкләренә егетләр кулының кагылганы юк иде әле. Күзләрен йомып, хатын-кызлар гына татый ала торган татлы назга исереп күпме торгандыр, айнып, уянып киткәндә, Түләк аның бүртеп, зураеп киткән күкрәк очларына иреннәрен тидерер-тидермәс кенә кагылып, үбеп тора иде. Ә үзенең күзләрендә яшь, кешеләрдә генә була торган чып-чын күз яшьләре!

Нәрсә кичерә икән бу егет? Нәрсә тоя? Ни уйлый ул, исенә төшерергә тырыша? Кем ул? Каян?

Сайдә, бер бәхетеннән шашып, бер борчылып, Түләкнең җиләс җилдә тузынып очып торган чәчләреннән бөтереп тотты да үзенең сөю, наз тәмен белә башлаган ак-саф күкрәкләрен аның калын, мәхәббәтле иреннәренә таба этте…

Сайдә Түләкнең кеше булуына ышанып җиткәч тә шикләреннән арына алмады. Бу шик, әлбәттә инде, су белән, елга белән бәйләнгән иде. Кешеләр җирдә яшиләр, ә Түләк нишләптер су заты бит! Ул суда, су астында яши, аның бөтен тормышы су белән бәйләнгән. Сайдә янына да ул судан килеп чыга, Сайдәдән соң да суга кереп югала… Тын алмыйча ничек кенә яшидер? Нәрсә белән тукланадыр?..

Бер килгәндә Сайдә бу хакта да сүз кузгатты, Түләктән нәрсә дә булса ашарга табуын сорады. Түләк шундук аңлап алды һәм, кулларын канат итеп җәеп, яр башыннан елгага томырылды, чумып, юк та булды. Бик озак торып чыкты ул. Ике сикерүдә ярга менеп тә җитте. Кыз Түләк кулындагы әрекмән яфрагында ысланган балык күреп аһ итте.

Сайдә кайтып кергәндә, Рәхилә ишек төбендә елап утыра иде.

— Нәрсә булды, әнием? — дип, шундук йөгереп янына барды.

— Жәл, теге Су егете жәл… Харап була бит мескен…

Ярты сәгать элек кенә Түләк белән Җидесуда йөзеп уйнаган Сайдә өчен әнисенең җавабы аяз көндәге яшен кебек булды.

— Нәрсә-ә? Ни сөйлисең син, әнием?

— Кызым, авылны акылдан яздырдың бит, шуны да белмисеңмени? Әнә итче Рәзил, синең теге җенеңне тоту өчен, кеше җыя башлаган...

— Нәрсә сөйлисең син?! Җен түгел ул, әнием, кеше ул, чын кеше! Менә минем кебек, синең кебек…

— Шулаен шулайдыр да. Кешеләрне моңа ничек ышандырырга соң? Кеше булгач, нигә авылда, үзе кебек кешеләр арасында яшәми соң ул? Нигә суда яши?

— Белмим, әнием, монысын мин дә белмим. Монысына үзем дә аптырыйм…

— И бала, бала… Тагын ниләр күрербез икән инде?..

— Кайчан баралар ди соң?

— Кая?

— Ауга, үзең әйттең бит…

— Иртәгә, кояш төшкелеккә күтәрелгәч кузгалалар, ди. Нәкъ шул вакытта су өстенә чыга, ди бит ул.

— Әнием, аны ничек тә кисәтергә иде, күрергә иде!
— Юк, кызым, бу юлы җибәрмим. Өйдә генә утыр! Болай да йөрәгем үз урынында түгел.
— Әнием!
— Юк дигәч, юк!
— Әнием! Мин бит аны яратам, үлеп яратам!.. Мин ансыз яши алмыйм!..
— Ә?..

**6**

Аллаһ сезгә күктән су иңдерде, ул су белән чәчәккә күмелгән күп җимеш бакчаларын үстерде, ул бакчаларның агачларын үстерү сезгә лаек булмады, ягъни көчегез җитмәде, Аллаһыдан башка тагын бер Илаһы бармы? Әлбәттә, юк, бәлки, алар хак юлдан авыша торган кавемдер».

*«Коръән тәфсире», «Нәмел» (Кырмыска) сүрәсеннән 60 нчы аять*

Су җене хакындагы имеш-мимешләр Камышлы авылын кыл урталай бүлде. Берәүләр, аны әзәрлекләп, табигатьне, илаһиятне үртәмәскә киңәш иттеләр, икенчеләр, бигрәк тә Сапый карчык белән Рәзил яклылар, бу хәшәрәтне кешеләр каршына бастырырга, бастырып кына калмыйча, утта яндырып үтерергә өндәделәр. Шундук олы ауга әзерләнә башладылар, чормада күгәреп яткан ау мылтыкларын чистартып куйдылар, патроннарын тутырдылар, капкыннар, күсәкләр, колгалар юнәттеләр, сөзгеч-җылымнар әзерләделәр.

Тик ауга кадәр, иң элек Рәхиләләр капкасын килеп кактылар.

— Һәй, өйдә берәрсе бармы? — Егетләрен урамда калдырып, ишегалдына үткән Рәзилнең тавышында үҗәтлек, хәтта усаллык бар иде.

— Бар, бар, кем анда? — Рәхилә сыер абзарыннан чыкмыйча гына җавап бирде.

— Без бу, Рәхилә апа, чыгыгыз әле, сөйләшәсе бар.

Алъяпкычына кулларын сөртә-сөртә килеп чыккан Рәхиләнең тавышына шом кунып өлгергән иде инде.

— Бәй, Рәзил, сөйләштек бит инде, җибәргән оның өчен дә Сайдәдән эләкте, үзегез сөйләшегез, үзегез килешегез инде...

— Бүген сүз ул турыда түгел, Рәхилә апа.

— Тагын нәрсә турында, Рәзил?

— Тегермән суындагы җен хакында, белмәгәнгә салышып тормале, Рәхилә апа.

— Минем ни эшем бар аңарда?

— Сезнең эшегез юк, ә менә Сайдәнең эше бар. Ул кайда, өйдәме, чыксын әле...

Өй ишегендә Сайдә күренүгә, баштарак икесе дә шым булдылар.

Беренче булып Рәзил сүз башлады.

— Сине Су җенен күргән диләр.

— Юк, күргәнем юк...

— Сине минем өч әтрәк-әләмнән кем коткарды соң?

— Белмим, күрмәдем...

— Сайдә, яхшылык белән сөйләп бир барысын да... Юкса...

— Юкса нәрсә була?

— Берни дә булмый... Үзең җенгә әвереләсең, шул гына.

— Ничек инде?

— Ничекме? Җенгә ярдәм иткән кеше үзе җен булып чыга, шул гына... Әнә Сапый карчыктан сора...

Бөтен тирә-якта даны чыккан сихерче карчыкның исемен ишетүгә, Рәхилә кызып китте:

— Сиңа нәрсә кирәк бездән, Рәзил? Уратып-нитеп тормыйча, турысын гына әйт әле!

— Кызың Сайдә безгә ул җенне тотып бирергә тиеш. Шунда гына авыл каршында йөзе ак булачак. Минем алда да...

— Синең алда? — Сүзгә тагын Сайдә кушылды. — Син кем соң?

— Мин синең булачак ирең. Белмәгәнгә салышма. Бүген әле мин сине ала алам. Оятына, гайбәтенә карамыйча алам. Күңелгә нык кереп өлгердең син, кызый... Ә менә иртәгә соң булачак, җенеңнең белән тотып утка ягачаклар сине. Ялынырсың-ялварырсың, мин булмам.

— Ялынмам...

— Ялынырсың. Җаның кадерле булса, ялынырсың. Ә җан кадерле ул...

— Туктале, малай актыгы, нәрсә сөйләп булашасың син, нинди җен, нинди җан, бирермен мин сиңа җанны, — дип, моңарчы чак-чак түзеп торган Рәхилә кулындагы сәнәген күтәреп Рәзилгә таба килә башлады. — Бар, ычкын моннан яхшы чакта, оныңны да алып кит, мин аның бер тамчысына да тимәдем!

— Рәхилә апа, туктале, тукта… — Рәзил, сүзнең кирәкмәгән якка кереп китүен аңлап, өтәләнә башлады.

— Туктамыйм да, нитмим дә… Шушы сәнәк җилкә тамырыңа кунганчы, бар, чыгып кит, бүтән күземә күренәсе булма!

Рәзил чыгып киткәч тә тиз генә тынычлана алмады ана кеше. «Кара син аны, җен белән башлады, җан белән бетерде», — дип, шактый вакыт үзалдына сөйләнеп йөрде.

Сайдәгә дә эләкте.

— Син генә гаепле, кызый! Шушы яшемдә кеше көлдереп йөрмәс идем мин, җен-җен дип тәкатеңне корытмасаң…

— Әнием!..

— Дәшмә миңа! Яратырга кеше беткәндер, суда яшәүче пәри егетенә гашыйк булмасаң!

— Әнием…

— Нәрсә, нәрсә? Нәрсә әйтмәкче буласың, нәрсә генә әйтә аласың син, ә? Бөтен авылга рисвай булдык бит, кызым. Аңлыйсыңмы шуны? Моннан соң ничек яшәрбез, шул турыда уйлаганың бармы?

— Әнием… Мин кеше бит әле… Ничек уйланмыйм ди инде… Ләкин мин аны бик яратам, җанымнан да, гомеремнән дә артык күреп яратам… Аның белән бер-бер хәл булса, ничек яшәрмен соң мин, әнием? — Күңел тетрәнүләренә түзә алмыйча, Сайдә, сулкылдап елый-елый, әнисенең күкрәгенә килеп капланды.

Гөнаһлы җир тормышының иң хәтәр ярсуларына да чыдам, сабыр ана йөрәге шундук кызын тынычландыра алырлык сүз уйлап тапты:

— Иртәгә иртүк кузгалырсың, балам, ә хәзер ял ит…

Нинди ял итү инде ул! Сайдә төне буе иләсләнеп, уйланып ятты. Ул бит хәзер мәхәббәт белән нәфрәт уртасында калды. Мәхәббәт ул — күзеңне йомгач та кояшның балкып калуы, нәфрәт — күзләр шар ачык чакта да көпә-көндез күкне болыт каплап алу… Сайдә мәхәббәткә якынрак тора. Аннары ул Түләк хакында уйланды. Сизә микән ул үзенә бәла якынлашканын? Сизәдер… Табигать иясе бит ул, табигать баласы… Ә табигать барысын да сизә, тоя. Әллә сизмиме? Бөтен дөньясын онытып, Сайдә хакында уйлап ятамы? Мәхәббәт табигать тоемын томалый, диләр бит… Ярата бит ул Сайдәне. Әлегә яратам дип әйтә алмаса да, ярата, сөя! Чын әкиятләрдәге мәхәббәт ияләре кебек…

*«Түләк белән кызның мәхәббәтләре көннән-көн арта барды. Кыз Түләккә әйтте: «Әй егет, син миңа рөхсәт бирсәң, һәр иртәдә чыгып, чәчем тарап, йөземне бизәп килер идем»,— диде.*

*Егет кызга рөхсәт бирде. Һәр иртәдә кыз аулак җиргә чыгып, чәчен тарап, йөзен бизәп килер иде. Беркөнне Түләк Сусылудан: «Нинди җиргә чыгып чәчең тарыйсың?» — дип сорады. Кыз әйтте: «Кайсы җирдә чәчемнән килеп тоттың, шул җирдә тарармын»,— диде. Шунда Түләк әйтте: «Әй җан мәхәббәте, анда минем атым белән кошымны күрмәссеңме? Кыз әйтте: «Ә син миңа гашыйк булмадыңмыни? Атымнан һәм кошымнан бизәм, дип әйтмәдеңмени?» Түләк кызга әйтте: «Ул көн бүтән көн иде, бу көн янә үзгәрде, күргән булсаң, әйт!» — диде. Кыз Түләккә әйтте:*

Атың аты Җилҗитмәс,
Аңа җитәр җир кайда!
Атың торыр ябыгып,
Кошың торыр боегып,
Үзең ташлап киттең бит,
Хәзер нигә сорарсың?

*Шуннан соң Түләк кызга әйтте:*

Атым торыр ул ярда
Минем өчен зарыгып,
Айлык җирне бер баскан,
Ирене-күзе калыгып;
Атым алып килергә
Дәрман әйтче, Сусылу,
Хәлеңнән килер булса,
Алып килче, Сусылу!

*Түләккә кыз җавап бирде:*

Атың, кошың бу җиргә
Килеп җитмәс, бай углы,
Бу хезмәтне кылырга
Хәлем җитмәс, бай углы.
Теләгең Хактан теләгең,
Ашыкмачы, бай углы,
Ул хезмәтне Хак бирер,
Кайгырмачы, бай углы!

*Түләк торды, ясигъ намазын кылды, мәхкәм китерде, башын сәҗдәгә куеп әйтте: «Илаһым, барча авыр эшләр сиңа җиңел бирелә: атымны, кошымны шушы җиргә китерсәң, моңа кодрәтең бар! Мин бичараның хәлен белсәң иде!*

*Кыз белән ятып торганнар иде, тышта Җилҗитмәс кешнәп җибәрде, кошы чыңгылдап аваз бирде.*

*Түләк аларның каршына китте. Ияләрен күрүгә, аты сикергәләп, кошы кагынып куйды — алар шулай сөенечләрен белдерделәр.*

*Өч дус тагын бергә яши башладылар.*

*Ләкин Түләк янә кыз мәхәббәте белән хаста булды, саргайды, ябыкты — бу аның йөзенә чыкты. Үзе бу хакта белмәде. Кыз, иртә белән, чәчен тарап, бизәнергә чыкканда, Түләк үзен күрсен дип, көзгесен түшәк өстендә калдырды. Түләк кызның көзгесен табып алды, ачып карады, үзенең йөзен күрде: йөзе сап-сары булмыш, яшәү нуры коелмыш иде. Шуннан соң Түләк әйтте: «Аһ, нинди аяныч хәл, хаста булдым, үлем хәленә килдем!» — диде...»*

Авылны чиләк, таба каккан тавышлар уятты. Төрле яктан ишетелгән шомлы авазлар акрынлап иске тегермәнгә илтә торган юл очына җыела башладылар. Кешеләргә, нindидер шайтан туе башланачагын сизенеп, ярсынган этләр иярде. Сапый карчыкның карлыккан тавышы этләр өрүендәге ыгы-зыгыдан да хәтәррәк булып ишетелә иде.

Бу кара йөзле, кылыч борынлы карчык, очлаеп алга чыгып торган ияге белән һаваны сөзә-сөзә, үзенең кара ырымын башкара:

> Кортның башын җуяем,
> Баш астына куяем.
> Киләсең булса — кил, гөмбә,
> Китәсең булса — кит, гөмбә;
> Кара диңгез артына
> Бар да төплән син, гөмбә!

Үзе чиләге төбендәге гөмбә кисәкләрен, башы өзгәләнгән корт калдыкларын җыелган кешеләр өстенә чәчеп йөри, янәсе аларга җеннәр белән алышырлык «көч-куәт кертә...»

Карурман авызында «шайтан туе» җыела башлаган вакытта, Сайдә иске тегермән яныннан узып бара иде инде. Каршысына кемнеңдер килгәнен ишетеп, ул тегермәннең кытыршы бурасына сыенды. Кулына тәпәч алды. Аны баш очына күтәрде, берәр яман кеше чыкса, сугарга әзерләнде.

Сугарга туры килмәде. Каяндыр ашыга-ашыга Мәннән карт кайтып килә иде. Аны күрүгә, Сайдә яшеренгән җиреннән чыкты.

Бу юлы Мәннән карт чынлап та курыкты, ахры.

Сайдәне танымаганга салышып:

— Синме соң бу, кызым? — дип сорады.

— Мин бу, Мәннән абзый, Сайдә. Танымыйсыңмы әллә?

— Таныйм да соң... Гаепләмә, кызым, бүген олы сихер көне. Кемнең кем кыяфәтендә йөргәнен дә белеп бетермәссең... Сак була күр. Болай ялгызың гына кая китеп барасың әле?

— Синме соң бу, Мәннән абзый? Әллә берәр җенме? Түләккә куркыныч янаганын үзең дә беләсең бит. Ничек тә хәбәр итәргә иде үзенә, әнә кан исен сизеп котырыналар тегеләр. — Сайдә авыл ягына ымлап күрсәтте.

— Беләм. Акылсыз малай да түгел үзе. Тик явызлыкны акыл да каплап куя алмый шул. Юлың изге. Тик беркая да барырга кирәк түгел. Ул инде белә.

— Каян белә?

— Белә. Калганын сорашма.

— Син әйтү генә җитми аңа, Мәннән абзый. Ул мине көтә, беләсеңме, мине!

— Мин Ходай Тәгалә түгел. Бәлки, син хаклыдыр да... Күңелең нәрсә куша, шуны эшлә, алайса... Тик соңыннан үкенәсе генә булма!

Алар шулай аерылыштылар. Һәркем үз юлыннан — үз язмышына каршы китеп барды, ләкин бу юл аянычлы иде: берничә минуттан Мәннән картны Рәзилнең исерек иярченнәре кыйнап, имгәтеп ташлаячак, ә Сайдә инде бик озак вакытка үзенең туган нигезеннән, газиз анасыннан аерылачак иде...

«Шайтан туе», урман өстенә карга өере күтәреп, тегермәнгә якынаеп килә иде инде, Сайдә, үзе генә белгән сукмакка төшеп, Түләк янына ашыкты. Кояш, җирдә барган ыгы-зыгыга игътибар да итмичә, күк гөмбәзенә үзенең нур-канатларын җәеп өлгергән инде, Сайдә белән Түләкнең очраша торган вакытларына да күп калмаган; менә шушы әрәмәлекне үтәсе дә, карт чикләвек куагы төбеннән үзәнлеккә килеп чыгасы гына кала...

Сайдә, мәхәббәтләренә шаһит булып басып торучы куш каенны үтеп, икесе генә белгән аулак урыннарга юнәлде. Тик яр буйларын, камыш дәрьяларын күпме генә айкап йөрсә дә, Түләкне таба алмады. Аның җанкисәге, сөйгән яры, суга төшкән кебек, кинәт юкка чыккан иде!

Ул арада, тегермән ягыннан килүче «шайтан туе» тар урман сукмакларыннан куш каен янына саркылып чыга башлады. Сайдә, бу вакытта Ябалак тавы итәгендәге әрәмәлек буенда басып тора иде. Ул шундук яр башында күпереп утырган гөлҗимеш куаклары артына посты, елганы күзәтә башлады. Яр буендагы шау-шуны ишетеп, су өстенә килеп кенә чыкмаса ярар иде аның Түләге... Сайдәнең иң беренче уе шул хакта булды.

Икенче, өченче, аннан соңгы уйлары да шул хакта гына иде.

Авылдан килгән халык төркеме куш каен янында калды, Рәзил, берничә егетен ияртеп, яр буен тентергә кереште. Алар мылтыкларын төбәп килеп чыкканда, Сайдә Түләк белән икесе генә белгән яр авызында еларга җитешеп утыра иде; текә балчыгы эшерелеп, үзәнлекне уеп кергән кызыл яр, суга тия язып үсеп утырган яшь таллык аны күзләре аракы сөреме һәм кыргый үч белән томалаган исерекләрдән яшереп-саклап торды. Кемдер яр өстендә сакта калды, бүтәннәр ары киттеләр. Елга буендагы камышлыкта оя корган кошларны өркетеп, берничә мәртәбә мылтыктан аттылар. Сайдәнең куркудан йөрәге ярыла язды. Колагын куеп тыңлап торды. Юк, болай гына аталар икән. «Үзләренең җаннары да аяк табаннарында йөри, ахры,— дип уйлап алды кызый,— әнә бит ничек пошаманга төшкәннәр…»

— Ялгыз гына йөрмәгез, мылтыгыгыз корылган булсын, — дип кычкырды кемгәдер Рәзил. Бераздан тавышын басыбрак өстәде: — Үлән селкенсә дә атыгыз, юкса үзе җаныгызны алыр…

— Җеннәрне үлми диләр бит, — дип шөбһәләнде кемдер.

Аңа икенчесе кушылды:

— Күзгә күренмичә дә йөриләр, ди, алар…

— Прекратить панику! — Рәзил төшенкелеккә бирелүчеләрне шундук урыннарына куйды.

Тагын бер-ике тапкыр мылтыктан аттылар. Елга эчендә ике көймәгә төялеп җылым сөйрәп йөрүчеләр ярдагыларга мылтыктан атып җавап бирделәр. Менә бервакыт моңа кадәр яр читендә эшсез торган этләрне, бәйләреннән чишеп, елга буена өстереп җибәрделәр. Аларның берсе туп-туры Сайдә яшеренгән яр буена чабып килде дә, яшь таллыкка карап, ярсып өрә башлады.

Сайдәнең тагын бер мәртәбә йөрәге ярыла язды. Ләкин, йөрәге ярылырга өлгерә алмый калды, тирә-яктагы куаклыкта бер-бер артлы мылтык ядрәләре ярыла башлады. Чынлап та, ышаныпмы, әллә кызык өчен генәме, — аучылар, бер-берсен уздыра-уздыра, эт өреп торган яр астына ата башладылар.

Мылтык тавышлары, этләрнең хәтәр өрүе, исерекләрнең ачы сүгенүе бергә җыелып, Сайдәнең аң-зиһенен томалап алды. Ләкин аның куркынган тәне, кул-аяклары бу минутта бөтенләй аерым, мөстәкыйль тормыш белән яши башлаган иде инде. Шуңа күрә ул үзенең ничек сикереп торганын, яшеренгән җиреннән йөгереп чыкканын да сизми калды. Өстә торганнар яр астыннан атылып чыккан кызны шундук күреп алдылар, «Әнә ул, әнә ул җен!», «Тотыгыз, тот!», «Атыгыз!» — дип кычкырыша башладылар. Тагын мылтык тавышлары яңгырады. Кинәт Сайдәгә, артыннан килеп, башына күсәк белән суккан кебек булды, ул алга таба сөрлегеп, абынып китте, аннары, ухылдап, су читенә капланып егылды…

Яшәү — үлемгә әзерләнү ул. Әмма үлем куркынычы кешене озаграк яшәтә.

Сайдәнең аң-зиһене кайта башлады. Зиһене белән бергә йөрәгендәге авырту көчәя барды. Иң беренче аның башына «Менә ничек була икән йөрәк ярылу» дигән уй килде.

Кемдер Сайдәне йөзе белән борып яткырды.

— Әһә, эләктеңме!

— Бәй, кем бу?

— Су кызы?

— Су җене?

— Нинди җен булсын, безнең авыл кызы ласа бу!

— Рәхилә кызы!

— Сайдә!

— Рәзил, синең җенең шушымы?

— Кемне үтердек без, Рәзил?

— Нәрсә бу, Рәзил?

— Берәр сүз әйт, Рәзил, югыйсә үзеңне атып үтерәм!

Үлеп барган Сайдә Рәзилнең сүзен ишетеп бетерә алмады. Аның каравы яр буендагы мәхшәргә калтыранып уянган агачлар, камышлар, Җидесу ишетте ул каһәрле тавышны.

— Җитте сезгә, җебек хөрәсәннәр! Төрмәгә утырасыгыз килмәсә, суга төртеп төшерегез дә шуның белән вәссәлам! Барыбер яшәмәячәк ул, йөрәгенә тигән… Ну! Нәрсә карап торасыз?!

Су буенда нишләргә дә белмичә аптырап торган ирләр, үзләренең кулларын үзләре тоймыйча, Сайдәнең суынырга да өлгермәгән гәүдәсен этә-төртә Җидесуга төшереп җибәрделәр… Кемдер сүгенеп куйды, кемдер белгән догасын укый башлады…

Йөзенә салкын су бөркелүгә, Сайдә тагын аңына килде, күзләрен ачты. Хәтта уйлап та өлгерде әле: ул инде икенче мәртәбә шулай су төбенә төшеп бара. Беренчесендә аны караңгы су дөньясыннан яктылык, юк, өмет, яшәү, тормыш булып килеп чыккан Түләк коткарган иде, бу юлы кем коткарыр соң? Кем булсын?! Түләк! Аның сөйгәне! Әнә ул, әнә килә дә инде!

Сайдә су төбеннән кулларын сузып йөзеп килүче таныш йөзне күреп елмаеп җибәрде…

Бу юлы елмайган килеш үлеп барган Сайдәне Түләкнең көчле куллары өскә — якты дөньяга алып чыкмадылар, киресенчә, каһәрле, гөнаһлы җир йөзендәге яшәештән ераграк яшерергә теләгәндәй, Җидесу төбендәге иң тирән, иң караңгы төпкелләргә алып төшеп киттеләр…

## 7

Ул имансыз дин тотучыларның гамәлләре тирән дәрьяда дулкынланудан барлыкка килгән караңгылык кеби. Ул диңгезне дулкын каплый, ул дулкын өстеннән янә дулкын каплый, вә ул дулкын өстеннән кара болыт каплыйдыр, ошбу караңгылыклар — берсе икенчесенең өстенә караңгылыктыр. Ошбу катлы-катлы караңгылык астында калган кеше, әгәр кулын чыгарса, ифрат караңгылыктан кулын күрергә мөмкин булмас. Аллаһ кемгә иман нурын бирмәсә, әлбәттә, аның иман нуры булмас!

*«Коръән тәфсире», «Нур» сүрәсеннән 40 нчы аять*

Сөйгәне белән су төбенә китеп барган Сайдә авылдагы хәтәр хәлләрне белмәве белән бәхетле иде.

Су җененә ауга чыккан Рәзил егетләре каршыларына очраган Мәннәнне кыйнап ташладылар. Кабыргалары сынган картны хастаханәгә алып китмәкче булганнар иде, «Үлсәм шушында гына үләм»,— дип, ул үзе теләп өендә калды, аның янына авыл фельдшеры килеп йөри башлады.

Рәхиләнең су буена дип киткән кызы шул китүдән гаип булды. «Рәзил егетләре мәсхәрәләп суга салгандыр» дигән сүз ишетелеп калган иде дә, Рәзил бу хакта сөйләп йөрүчеләрнең авызын акча белән томалап куйды; акчага килешмәгәннәрен янап-куркытып чыкты.

Кызын югалткан Рәхилә авырып түшәккә егылды. Бер айлап күршеләре күз-колак булып торды. Аякка баскач та аның авыруы узмады, ул хәтта бераз «җиңеләебрәк» калды. Көннәр буе Җидесу буенда, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, кызын эзләп йөри башлады…

Рәхиләнең кызын районнан килгән кешеләр дә эзләп карадылар. Милиция киемендәгесе хәлсез хатыннан ике сәгать буе сорау алды. Рәхилә ничек бар шулай сөйләп бирде. Җидесудагы Су егете хакында да, ул мәхшәр көнне Рәзилгә ияргән авыл ирләренең шул егетне ауларга чыгуларын да, Сайдәнең аны кисәтергә, коткарырга китүен дә түкми-чәчми хәбәр итте.

Култык астына күн папка кыстырып йөрүче милиция кешесе Рәзилне дә, аның иярченнәрен дә берәм-берәм чакыртып сөйләште, әмма гаепләрлек берни дә таба алмады. Шуның белән эш туктатылды. Рәхиләдән башка Сайдәне эзләүче кеше калмады.

Бердән бер көнне Рәхиләне Мәннән карт чакыртып алды.

Көннәр көзгә якынлашкан вакыт иде. Августның яңгырлы көнендә пычрак ерып килеп кергән хатынны карт елмаеп каршы алды. Рәхилә үзендә аңа каршы елмаерлык көч таба алмады. Саимә абыстай авыру карты яткан түшәк янына артсыз урындык китереп куйды да үзе каядыр чыгып китте.

— Рәхилә туганкай, исәнме?.. — Картның күзләрендә җитди уйлар күп иде, ләкин матур елмаюы да һаман югалмады.

— Саумы, Мәннән абзый. Нигә чакырдың? Мине бит хәзер беркем дә чакырмый. Минем белән беркем дә сөйләшми. Минем арттан «тиле Рәхилә» дип кенә калалар хәзер…

— Утыр әле, сөйләшәсе бар.

— Нәрсә хакында, Мәннән абзый?

— Сайдә хакында…

Кызының исемен ишетү белән, Рәхилә шундук сагайды, әзерләп куелган урындыкны бер як читкә алып куеп, картның түшәгенә үк барып утырды.

— Сайдә хакында?

— Рәхилә туганкай, исән-сау синең кызың. Өзгәләнеп- изаланып яшәмә.

— Исән? Сайдә исәнме? Кайда ул?

— Ашыкма, барысын да әйтермен.

— Әйт инде, Мәннән абзый, әйт тизрәк — бәгыремне телгәләмә! Нәрсә булган аңа? Ник кайтмый ул?

— Исән ул… Егете янында. Суда яшәүче егете янында.

— Су җене янындамы?

— Җен түгел ул, синең ирең белән бер көндә үлгән тегермәнчеләрнең югалган балалары. Бүтән берни дә әйтә алмыйм. Болай да артыгын сөйләдем. Сайдәнең исән булуын гына белдерермен дигән идем…

— Күрергә буламы аны, ә, Мәннән абзый? Аларны?..

— Вакыт җиткәч үзләре эзләп табарлар; ә хәзер бар кайт, ял ит, күңелеңне тәртипкә китер…

— Рәхмәт, Мәннән абзый.

— Сау бул, кызым. Бирешмә. Ана теләге дәрья төбеннән чыгарыр, диләр бит. Теләгеңнән өзмә…

— Рәхмәт. — Инде ишеккә барып тотынгач, Рәхилә, кырт борылып, сорап куйды:

— Мәннән абзый, әйт әле, сез минем Низам белән нигә килешмәдегез, нигә аралашмадыгыз? Туганнар бит сез? Нәрсә булды сезнең арада?

Карт дәшмәде. Йоклаганга салышып, тын гына ята бирде. Рәхиләгә чыгып китүдән башка юл калмады. Аның инде күңеле күтәренке иде, йөрәге дә үзенең салмак, тигез эзенә төшеп: «Яшә, яшә, яшә», — дип тибә иде…

Юк, барыбер тынычланып җитә алмады Рәхилә. Уйларында шик-шөбһәләр, шомнар күп иде әле. «Сайдә хакында Мәннән карт каян белә соң? Аның исән икәнен, әлегә күрешә алмаячакларын, үзләре килеп табачагын каян белә? Әллә?.. Әллә алар янына барып йөриме бу карт шайтан? Ай Аллам! Үзе дә бер җенме әллә? Теге вакытта Низам әйтә иде бит: «Безнең Мәннән җеннәр белән бәйләнгән. Хәерлегә булсын», — ди иде. Шуңа да яратышмаганнардыр әле…»

Рәхилә, яңгыр димәде, җил димәде, һаман да, буш вакыт тигән саен, тегермән артындагы Җидесу буена барып килә иде. Еш кына кулына, төенчек итеп төйнәп, кызының кием-салымнарын, башка вак-төяген алгалый. Берсендә, шул төенчеген куш каен кәүсәсенә элеп, хәл җыеп алмакчы булды. Оетып җибәргән, борчулы уйларына басылып, йоклап киткән… Уянып, күзләрен ачса, каендагы төенчеге юкка чыккан, аның урынында кызының кояш кашлы көмеш йөзеге эленеп тора!..

Ул көнне бәхетен тапкан кебек куанып, шатланып кайтты Рәхилә. Тагын төенчек төйнәде, тагын куш каенга барды, күренерлек итеп элеп куйды, күзләрен йомды… Бер генә мәртәбә түгел, берничә көн рәттән шулай эшләде… Әмма, ике-өч көннән соң да, ике-өч атнадан соң да аның бу төенчеген килеп алучы булмады…

Тагын боекты Рәхилә. Үз эченә бикләнде. Йөгереп фермасына барып кайта да, сәгатьләр буе, Каруман ягына карап, капка төбендә утыра яисә, иренең иске япмаларын ябынып, тегермән ягына китеп бара.

Томанлы бер көн иде. Рәхилә бу көннән бернәрсә дә өмет итмәде. Күнегелгән гадәте буенча гына чыгып китте ул. Алмакае күзгә чалынмасмы, дип чыкты. Төшлеккә кайткан көтүчеләр: «Көтүдән калды, тыңламады», — дип әйтеп киттеләр…

Тегермәнгә җитәрәк Рәхиләнең күңеленә, җанын тынгысызлап, бер билгесез шом килеп керде. Моңа кадәр курыкмый иде бит ул бу ярым җимерек су тегермәненнән… Нәрсә булды, нинди шом бу?

Элек әйтәләр иде: томаннан курыксаң, җырла, «томан әфсенен» җырла, диләр иде. Һәм Рәхилә, кабалана-кабалана бала чагыннан ук хәтеренә төшеп калган шул әфсенне көйли башлады:

Ак чыбылдык эчендә
Айны ничек табаем?
Күк чыбылдык эчендә
Көнне каян табаем?..

Рәхилә өчен галәмәт хәлләр башлана гына иде әле.

Иске тегермән белән тигезләшүгә, аның караңгы диварлары артыннан бер шәрә кеше килеп чыкмасынмы! Кеше дисәң кеше түгел, җен дисәң җен түгел!.. Аның Җидесудан чыккан җен егете булуы турында баштарак Рәхилә уена да китерә алмады әле.

Ләкин, куркып, исен-акылын да югалтмады ул. Чөнки бу шәрә нәрсә аның каршында ихлас елмаю белән елмаеп басып тора бит. Ул, җен-пәри булган очракта да, кешеләргә начарлык кыла алмыйдыр кебек тоелды Рәхиләгә.

— Кем син? — дип сорый алды ул бераздан. Рәхиләнең күңеле ниндидер бер матур әкиятнең башланып китүен сизенә башлаган иде инде.

Матур, зифа тәнле, әмма тәртипсез рәвештә як-якка таралып торган озын кара чәчле егет, уң кулын күкрәгенә куеп, исемен әйтте:

— Мин — Ту-ләк…

— Түләк? Сайдә?

Бу исемне Рәхилә Сайдәдән ишетеп белә иде. Шуңа күрә дә тизрәк кызының исемен әйтергә ашыкты. Ана йөрәге сабырлыгын югалта башлаган мәл иде бу.

— Сай-дә...— Егет Рәхилә артыннан кабатлады.

— Сайдә — минем кызым. Кайда ул? Исәнме ул? — Рәхилә түземсезләнеп сораша башлады. Ул хәтта бу сәер затның каршына ук барып басты.

— Сай-дә — и-сән. Те-ре-лә. А-ңа — әй-бәт...

— Кайда ул?

Түләк бераз уйланып торды, аннары, йөзендәге табигый елмаюын саклаган килеш, баш бармагы белән җиргә төртеп күрсәтте.

— Ан-да.

— Кайда? Җир астындамы?

— Әй-йе.

— Ай Аллам! Тере килеш җир астына кермәсә! Ә ни өчен ул анда? Ник аннан чыкмый? — Рәхилә дә баш бармагы белән җиргә төртеп сораша башлады.

— Ул... Ул — а-вы-рый... Ме-нә мон-да а-выр-та... А-ңа ат-ты-лар...

Рәхилә тагын бер аһ итте. Теге вакытта җен атып йөргән Рәзилнең генә канлы эше бу. Үзенә сорап йөри иде, үчен алган икән, кабахәт!

Күз яшенә мөлдерәмә тулган карашларын кая куярга белмичә тагын бераз таптанып торды әле Рәхилә. Куркуның әсәре дә калмаган. Киресенчә, шундый якын, кадерле булып киткән иде аңа бу егет. Кыенсына гына, кочаклап сөяр иде бер. Кызым өчен рәхмәт, сакла аны, кадерлә, яшәт, дияр иде. Җенгә бер дә охшамаган, нишләп охшасын, тегермәнчеләрнең югалган баласы бит ул...

Җир астында яшибез, диме? Нинди генә җирдер инде ул? Караңгыдыр, салкындыр... Рәхилә тиз-тиз генә өстен чишенә башлады. Сырмасын, яулыгын салып, Түләккә тоттырды.

— Мә ал, балакаем. Сайдәгә бирерсең. Өшемәсен. Кирәк булса, тагын китерермен...

— Ки-рәк-ми. Без-дә бар...

— Тагын кайчан киләсең?

— Мән-нән... бе-лә...

— Ә? Мәннән абзыймы?

— Әй-йе. Ул бе-лә...

Шул вакыт агачлар арасында кыштырдаган тавышлар ишетелгәндәй булды. Рәхилә, сискәнеп, шул якка борылып карады. Урман эченнән, агач ботакларындагы яңгыр чыкларын коя-коя, аның көтүдән калган Алмакае килеп чыкты...

Рәхилә, сөенечен уртаклашырга теләп, Түләк ягына борылды. Ләкин егет урынында юк иде инде. Тегермән ышыгындагы куе томан гына, бөтерелеп, күккә агып китеп бара...

Мәннән... Низамның абыйсы Мәннән... Менә кемдә ул серләрнең ачкычы... Юк, бу юлы аңардан барысын да сөйләтәчәк!..

Рәхилә, сыерын лапаска ябып, өстенә икенче сырма киеп чыкты да туп-туры Мәннән картларга китте. Тын-сулышы буылып барып кергәндә, йорт хуҗасы аны көтеп утыра иде инде.

— Күрештегезме? — Мәннән карт барысын да белә иде.

— Күрештек...

— Әйбәт булган.

— Мәннән абзый, әйт әле, син кем?

— Ә сиңа кем кирәк, туганкай?

— Син җенме, әллә кешеме?

— Тыңла алайса. Аннары үзең хәл итәрсең: җенме мин, әллә...

Мәннән карт берникадәр вакыт тәрәзәгә карап торды. Күренеп тора: уйлары, хисләре чуар иде аның, тәртипсез иде. Ләкин күңелен тәртипкә салырга вакыты юк, шуңа күрә ничек бар шулай сөйләргә тиеш иде ул.

— Ул тегермәнчеләр безнең төбәккә Кавказ якларыннан килгәннәр. Татар милләтеннән түгел, балкарлар иде алар. Әмма нәкъ безнеңчә сөйләшәләр. Үзләре үк әйтеп торалар: «Без бер нәселдән, безнең нәсел бабасы — Кубрат хан, — диләр. — Аның «болгар» дигән халкы, өчкә бүленеп, бөтен дөньяга таралган, бер өлеше көнбатышка киткән, бер өлеше көньякта калган, бер өлеше Идел–Кама буйларына килгән», — дип тә җибәрәләр. Менә шул балкар кешесе тагын әйтә иде: «Бер нәсел кешеләре кан белән генә түгел, су белән дә туганлашкан булалар», — ди иде.

Ышандык. Шулайдыр. Без дә су буенда яшибез, су яратабыз бит. Диңгез буенда яшәгән элеккеге нәсел-нәсәбне кан хәтерлидер шул... Бергә яшәп киттек. Аларның байлыклары бар иде, агач юнәтеп, су тегермәне кора башладылар. Бөтен авыл булышты. Онга, икмәккә бөтенәйдек. Килмешәк туганнарыбызга рәхмәтебез иксез-чиксез иде...

Бервакыт тегермәнчеләр хакында яшерен сүз таралды. Төннәрен кара сихер белән шөгыльләнәләр, имеш. Барып, сиздермичә генә карап торганнар. Кемнең ашлыгын тарталар, шуның онынnan

бер уч алып калалар икән дә, өшкереп суга сибәләр икән. Бераздан бу кешенең өендә берәр кеше үлә йә булмаса малы кырыла башлый икән.

Менә шуннан соң аларны эзәрлекләү башланды. Башлап йөрүчеләр арасында Низам да бар иде. Мин аны тыярга тырышып карадым. Ул: «Коммунизм төзегән бер вакытта кара хорафатларга урын юк, төптән корытырга кирәк аларны», — дип кенә җибәрә иде. Мин аны хәзер аңларга тырышам, партия әгъзасы булган бит ул, дингә ышанучыларга каршы булган. Минем белән дә шул тегермәнчеләр аркасында сүзгә керде. Ә мин аңламый идем, ничек инде үз халкыңның нигезеннән килгән кешеләр турында начар уйларга мөмкин?

Әйе, мин алар белән дус идем. Сөйләшеп, гәпләшеп бер генә төн үткәрмәдем. Берара алар янында эшләп тә йөрдем әле.

Ә беркөнне Низамнар, авыл коммунистлары, җыелып барып тегермәнчеләрне акылга утыртмакчы булганнар. Берни барып чыкмаган. Низам әйткән: «Хәзер үк китмәсәгез, үзегезгә үпкәләгез»,— дигән. Иртә белән тегермәнче һәм аның хатынын тегермән ташы астында тапканнар.

Иртән халык җыелганда, тегермәнче исән иде әле.

Ул бөтен кеше ишетелерлек итеп пышылдады:

— Үтерүче безнең белән күмеләчәк, — диде. Аннары үз янына мине чакырды: — Улымны табып ал, ләкин кешеләргә бирмә,— диде.

Ул көнне өч кешене берьюлы күмдек: тегермәнчене, аның хатынын һәм кинәт кенә үлеп киткән Низамны… Боларын үзең дә беләсең…

Тегермәнченең җиде яшьлек малае суга төшкән кебек юк булды. Ул чыннан да суга төшкән булып чыкты. Җидесуда аулак урын җайлап, мәгарә корып, азык юнәтеп кыш чыккан… Хәле бик авыр иде… Мин аны яз көне генә килеп таптым, кирәк-яраклар бирдем, ут табарга өйрәттем. Ул чын табигать баласы булып үсте. Җен дә, кеше дә түгел, нәкъ менә табигать баласы. Синең Сайдә аңа гашыйк булды. Ә ул — Сайдәгә… Алар хәзер бергә. Рәзил малайлары мине кыйнап ташлаган көнне Сайдәнең йөрәгенә дә утлы ядрә тиде. Аның гомере хәзер шул егет кулында. Әйдә, алар хакына изге догаларыбызны теләп торыйк… И туганкай, барысы да бер җайланыр әле, җайланыр…

Рәхилә нишләргә дә белмәде. Аның зиһене тәмам буталды, күңеле ярсып җилкенде. Күз алдына әле Низамның үчле йөзе килеп баса, әле тегермәнчеләрнең кайгылы, дөресрәге, ачулы карашлары бәгырен телгәли, әле Түләк исемле табигать баласының сәер, әмма үтә дә ихлас елмаюы пәйда була…

Кайтышлый Рәхилә, уңгарак тайпылып, янәшәдәге агачлыкка юнәлде, аннары, авыл зурайган саен, уртадарак кала барган зиратка килеп чыкты. Ул хәтта кыенсынып куйды — Низамның кабере каралмаган булып чыкты; ә менә, сихер ияләре дип зираттан читтәрәк күмелгән тегермәнчеләрнең каберендә зәңгәр-күк төсендәге тере чәчәкләр балкып утыра иде!

## 8

> Вә Ул — Аллаһ — кешене бер тамчы судан халык кылды, вә аларны ир вә хатын итеп, нәсел-нәсәбен үрчетте; Раббың һәр эшкә кадир булды.
>
> *«Коръән тәфсире», «Аеручы» сүрәсеннән 54 нче аять*

Сайдә, якты дөньяга, тормышка ничек тә ябышып калырга тырышып, саташып ята. Тормышка ай-һай ерак әле. Шуңа күрә ул иң элек әкият, риваять каһарманнарына эндәшә, ярдәм сорый, алардан әкият белән тормыш арасында эленеп торучы күпер булуларын үтенә…

*«Түләк, үлем хастасы булуын сизенеп, төрле уен кораллары ясарга булды. Илаһтан үтенде: «Илаһым, хаҗәтемне син кабул ит. Бу төндә миңа уен сәләте бир. Бу уен коралларына җан бир. Шушы җирдә синең хөкемең белән дучар булдым, уйнап җибәрсәм, күңелем күтәрелер иде», — диде.*

*Ходай Тәгалә аның яклы булды. Аның уйнаганын тыңларга барча халык җыелган иде, һәркем кичен-көндезен Түләк катыннан китмәс булдылар; аның моңлы уены җыелган халыкның күңелен әсир итте.*

*Көннәрдән бер көн Түләк үз күңеленнән зарилык кылды: «Әй кәриме рәхим, мин монда пәриләр, кошлар, киекләр, хайван-хәшәрәтләр белән шат булып торам, җил кубып, аның тузаны басып, сурәтең бозылса, мин җеннәр, пәриләр сурәтенә керермен»,— дип зар-зар елады.*

*Ул кичне Түләк Сусылу катында ята иде; ул кызга әйтте: «Ни аяныч! Синең зифа сурәтеңә алданып, адәмнәрдән аерылып, нәсәпсез булдым, үләр булдым. Атам-анам кайда? Минем ыру башым Адәм бит!»*

*Кыз әйтте: «Әй егет, акылың киттеме әллә? Бу байлык, бу дәүләт кадерен белмисеңме әллә? Бу дәүләтне барлыкка китергән Ходай Тәгаләне оныттыңмы әллә? Аерылганнарны кушу аңа берни тормый…*

*Бу сүз белән ул егетнең күңелен юатты. Яттылар. Иртән намазга торгач, күрделәр, алтын тәхетле сарай янында җирдәге кебек тау калыккан, аның тирәсенә урман үскән, киекләр барлыкка килгән…*

*Җыелган халыклар сорадылар: «Бу кемнең тавы булыр? Бу нигә болай торыр?» — диделәр.*

*Түләк әйтте:*

Минем тавым — Балкан тау,
Башы һавага чыккан тау!

*Ишеткән киек, елан-хәшәрәтләр, җыелып килеп, башларын түбән салып тыңлар иделәр.*

*Бу хакта кызның атасы Чачдар ханга ишетелде. Ул кызы торган сарайдан җиде көнлек һәм җиде төнлек юлда иде. Шушы ераклыктан да хан Түләкнең уеннарына гашыйк булды: эчүдән, ашаудан биздe — диюләрен, пәриләрен алырга җибәрде. Түләкне пәриләр алып китәр булдылар…»*

Сайдә, үзалдына саташып, уянып ята. Ул инде уянган, күзләрен генә ача алмый. Әле ярый күзләрен ачмый, керфекләрен күтәрсә, караңгы, шыксыз мәгарәдә ятуын күреп, аның болай да җәрәхәтләнеп беткән йөрәге, бөтенләй теткәләнеп, өзгәләнеп, тәмам өзлегер иде…

Бөтен тәне сызлый, хәтта җаны сызлый. Ул нәрсә булганын исенә төшерә алмый, йөрәгендәге авырту аның аңын, зиһенен томалап куйган. Сайдә берәрсен чакырырга уйлый. Тик кемне чакырырга белми генә. Кеме бар соң аның? Түләк белән Сусылу хакында сөйләгән әткәсе бар… Бар иде… Әнкәсе бар. Су егете бар… Түләк… Юк, бу Түләк әкияттән түгел. Җирдән. Юк, судан… Судан! Ул бит Сайдәне су төбенә алып төшеп киткән иде! Ничек исән соң әле ул, әллә су астында тагын берәр җир, тормыш бармы? Теге дастандагы кебек…

— Ыһ!..

— Сай-дә!..

Бу таныш тавышны Сайдәнең ишеткәне бар. Кемнеке икәнен генә хәтерләми… Менә ул тавыш, җилпенеп очып килде дә аның маңгаена кунды, чәченнән сыйпап назлый башлады…

— Сай-дә…

Сайдә күзләрен ачты. Аның каршында Түләк утыра иде.

— Син?..

— Мин… Түләк…

— Түләк… Мин кайда? Мин үлдемме?

— Үл-мә-дең… — Түләк елмаеп куйды.

— Бу… нинди җир? — Сайдә, башын кузгатмыйча гына, тирә-ягына карана башлады.

Бу юлы Түләк җавап бирмәде. Каядыр өскә үрелеп, ут кабызды. Юк, лампа түгел иде бу, көн яктысы иде. Тирә-як ачылып, балкып китте. Сайдә, хәлсез карашларына соңгы көчен туплап, бу яңа дөньяны өйрәнә башлады. Иң элек су исен, юеш балчык исен тойды ул. Һәр якта текә яр, хәтта өстә дә яр. Яр? Өстә яр буламыни?! Бу бит тау куышы, мәгарә!

— Түләк, мин кайда? Бу нинди җир?

— Бу — мин-нем җир.

Сайдә тормакчы булды, башын калкытты. Түләк шундук аягүрә басты. Кулы белән ишарәләп, ятарга кушты. Һәм каяндыр агачтан уеп ясалган касә алып, эчәргә кушты. Сайдәнең бик эчәсе килгән иде, шундук йотлыгып эчәргә кереште. Бу чәй дә, су да түгел, ачы да, татлы да түгел иде. Күбрәк үлән катнашмасын хәтерләткән җылы сыеклык Сайдәгә хәл кертеп җибәрде, аның тын-сулышын ачты. Күкрәге турысындагы авырту гына бетмәде.

Ул, Түләккә таба борылып:

— Авырта…— диде. Аннары: — Мин үлмимме? — дип сорады.

Түләк дәшмәде, елмаеп кына куйды. Үрелеп, Сайдә өстендәге япманы ачты. Үзенең шәрә тәнен күреп, Сайдә каушап китте, ләкин, бу караңгы дөньяга каяндыр табып китерелгән ап-ак япманы яңадан өстенә капларлык хәле юк иде аның…

Шунда гына Сайдә бөтен җир асты дөньясына ачылып яткан күкрәкләре өстендә берничә үги ана яфрагы шәйләп алды. Алар ниндидер ак, үзле балчык белән аның ап-ак түшенә ябыштырып куелганнар иде.

Сайдә әллә шушы сәер хәлләрдән, әллә җир салкыныннан чирканып, калтыранып куйды. Моны һаман әле янында елмаеп утырган Түләк тә сизде. Егет, сак кына кагылып, Сайдәнең хәлсез гәүдәсен чүпрәк-чапракка төреп куйды, коры печән тутырып эшләнгән киң, калын түшәген рәтләде. Аннары, бер читкә тайпылып, кызарып, мәлҗерәп яткан әзер күмер өстендә учак тергезеп җибәрде. Черт-черт килеп яна башлаган учак яктысында бу сәер дөнья тагын да ачылып, балкып китте, баллы-ачылы эчемлектән соң айнып, терелеп барган Сайдә үзенең яткан урынын тагын да җентекләбрәк өйрәнергә керește.

Иркен генә җир өй иде бу. Һәр якта балчык стена. Ишеге булмавы бик сәер. Бер як дивар такта белән тышланган, аңа пөхтә, тигез итеп шүрлекләр эшләп куелган, бу шүрлекләрдә тормыш кирәк-яраклары, табак-савыт, чиләк-чүлмәк әйберләре; янәшәдәге чөйләрдә кием-салым, тире-сары…

Иdәннең Сайдә яткан яртысына такта түшәлгән, күтәртеп эшләнгән сәке, тәбәнәк кенә өстәл тора, бер-ике бүкән күренә. Җир өлешендә учак казаны, аның ике ягына чатлы тәкәләр кадалган, шунда ук әрдәнәләп утын, чыбык-чабык өелгән. Шәүлә булып кына кипкән мүк, печән өемнәре утыра… Өстәге почмакларда камыш, үлән бәйләмнәре, кипкән җиләк-җимеш, гөмбә баулары… Шулай да иң күбе — ысланган балык, кош түшкәләре…

Әрем катыш тире, ит исе, аннары су, ләм, балык исе бөтен дөньяга тулган. Су! Әйе, кайдадыр якында гына су булырга тиеш! Сайдә тагын бер мәртәбә җир өйне карап, барлап чыкты. Кайдадыр су чылтырый, кайдадыр тамчы тама…

Әнә ул! Таш бусага янында караеп тора! Кое! Бәке! Нәрсә булса да, су…

Сайдә тирә-ягына каранып, уйланып арды, күзләрен йомды. Үзе генә түгел, күзе генә түгел, җаны арды аның бу көтелмәгән хәлләрдән…

Оеп йоклап китте. Төш күреп ята, имеш. Әнисе тәмле әйберләр пешереп йөри. Сөтле ашларны бигрәк тә тәмле пешерә ул; елга бер мәртәбә сөтле умач пешерә. Басуда игеннәр җыелып беткәч, яңа ашлыктан тартылган оннан умач пешергәннәр борынгылар. Әнисе дә шул йоланы онытмый. Ул бит чын татар түгел. Әнисенең әнисен — Сайдәнең дәү әнисен — Хаммат бабасы сугыштан — Болгария җиреннән алып кайткан. Безнең бабалар да болгар булган, син дә болгар бит, дигән дә алып кайткан. Анастасия, Камышлыга кайткач, Әнисә булып киткән. Әнисә дәү әнисе татарчаны бераз ватыбрак сөйләшкән булса, Сайдәнең үз әнисе инде шәп белә, хәтта кайбер ачы телле татар апаларына караганда да матуррак сөйләшә. Менә шул: яңа уңыш оныннан сөтле умач пешерү йоласы Әнисәгә ияреп Болгариядән килгән булган. Әлеге йоланы, мондагы татарлар да үз иткәннәр, аның матур һәм мәгънәле булуын таныганнар…

Әнисе сөтле умач пешереп йөри, имеш. Сайдәнең борын эчләре кытыклана, кытыкланып кына калмый, ул инде аның тәмен тоя, шифасын авыру тәненә, өзлеккән җанына ала…

Умач — җан ашы бит ул, Умай-аштан кыскартып әйтелгән. Ә борынгыларда Умай — җан өләшүче, җан савыктыручы алиһә, Тәңренең сөйгән җариясе… Умай-аш кешенең җанын тәрбияли, аны яшәүгә дәртләндерә, тормышка өнди. Ул аңа көч, егәрлек бирә, рухи ныклык бирә.

«Кызым, тәмлеме?» — дип сорый ана үзенең кызыннан. Сайдә җавап бирә алмый. «Әнием, ашың тәмле булган, мин Умайны тоям, аның көчен үземә алам», — дип әйтергә тели, әмма дәшә алмый, телсез калып тик тора… Менә хикмәт, ул әнисе биргән ашны кабып-кабып карый, ләкин аның чын тәмен тоймый, тагын каба, барыбер тоймый…

— Сай-дә, ач авы-зың-ны… Аш кап… Те-ре-лер-сең… Си-ңа а-шар-га ки-рәк…

Юк, бу аның әнисе түгел. Тавышы да, йөзе дә бүтән кешенеке. Түләкнеке!..

— А-ша, Сай-дә, а-ша…

Сайдә Түләк кулындагы агач кашыктан җылы аш каба. Әнисенең сөтле умачын ашый… Менә хәзер ул ашның тәмен аермачык тоя… Үзе ашый, үзе уйлый Сайдә: «Каян килгән монда сөтле умач? Бу җен өенә, тәмуг базына каян килгән? Нинди җир бу? Кем ул — Түләк?

…Берничә мизгелдән Сайдәгә тагын яшәү тоемы, тормыш гаме кайтты. Ул әле керфекләрен ачып карый алмый, әмма инде ишетә, тоя иде.

Түләкнең тавышын да беркемнеке белән бутамаячак ул. Тик бу юлы аның тавышы нигәдер калтыранып, хәтта шомланып, куркынып чыга. Кемгәдер эндәшкән кебек…

— Терелергә тиеш ул, ничек тә терелергә тиеш!

Ниндидер гөрелдәвек тавыш, үлем төпкеленнән яңгырап чыккан кебек, сузып җавап бирде:

— Үлек тә түгел, терек тә түге-е-ел… Үлекне терелтеп була-а-а… Терекне яшәтеп була-а-а… Бу адәм баласы ни үлек түгел, ни терек түге-е-ел…

Түләк тавышы:

— Син бит бөтен сулар өстеннән хаким! Су — тереклекнең нигезе, асылы һәм мәгънәсе! Су — җирнең каны! Ә кан ул — җан! Су — җирнең җаны, хәтере! Су — барысы да! Су — иң тере нәрсә! Аннан да тере әйбер юк! Ә син… Син, булдыра алмыйм, дисең… Терелт Сайдәне, үтенеп сорыйм, терелт!

Теге гайре табигый гөрелдәвек тагын телгә килде:

— Мин барысын да эшләде-е-ем… Бу үлем каршында су көчсез-е-ез…

— Ничек көчсез? Бөтен нәрсә судан яралган бит! Изгелек чорыннан ук Тәңре судан халыкларны яратты, диелгән. Тәңренең теләге, ихтыяры яратты, дип язылган. Дәрте һәм өмете! Ышанычы һәм үгете! Нәфрәте һәм мәхәббәте! Ана карынында да кеше суда ята, үлгәч тә суда коендыралар… Син — Җирдә иң көчлесе! Син генә терелтә аласың Сайдәне… Әй, Су рухы! Ялварып сорыйм!..

— Үҗәт, үзсүзле син, Адәм баласы-ы-ы… Җир үҗәтлеге бар синдә-ә-ә.. Шуңа күрә, Җирдән сорап кара, бәлки, ул ярдәм итәр?..

Түләк тавышы:

— Әй син, Җир рухы! Терелергә ярдәм ит бу Адәм баласына. Мин аны синең кулга тапшырам.

Каяндыр өстән, кара җир куеныннан, яңгыравык өн-аваз ишетелде:

— Син аны үзең белән чагыштырма-а-а… Син безгә якын, без — сиңа… Бу авыру йөрәктә инсаниятнең меңьеллык гөнаһы җыелган, аны бер мизгелдә кире кайтару мөмкин түгел… Күпме үлем ачысы, рәнҗеш, каргыш җыелган! Син миннән ярдәм көтмә, адәм баласы, Җир кадәр Җир булып, мин дә күтәреп, җиңеләйтеп бетерә алмыйм кеше йөрәгенә төшкән авырлыкны…

— Син бит Җир — безнең туган нигезебез, ә үлгәннән соң — барыр җиребез. Син кодрәтле, уңдырышлы һәм игелекле… Ярдәм ит, зинһар!

— Мин сиңа соңгы сүземне әйттем, Адәм баласы… Вакытыңны әрәмгә уткәрмә, Илаһи Күккә гыйбадәт кыл, ул ярдәм итсен…

Түләк тавышы:

— Күк ерак бит. Арада син бар. Минем карашым да, тавышым да синең аша үтеп чыга алмаячак…

— Бер мизгелгә генә ачылып, мин сиңа Күкне күрсәтәм. Сорап кал, Күккә җиде елга бер генә ачылам мин…

Шул вакытта җир тетрәп, калтыранып куйгандай булды. Салкын җил йөгереп узды. Каяндыр өстән сыек томан төшеп җәелде. Салкын, тәннәргә генә түгел, җаннарга үтеп керде…

Түләкнең тавышы да калтыранып чыкты:

— Күк-Тәңре!.. Ярдәм ит миңа! Сайдәне терелтә алмасаң, миңа ярдәм ит — аны, минем өчен терелт, тормышыма кайтар!

— Әй Адәм баласы! Нәрсә бәрабәренә сорыйсың син аңа тормышны?

— Мәхәббәтебез хакына! Мин сиңа берни дә бирә алмыйм.

— Гомерең бар… Шуны бир!

— Гомерем миңа Сайдә белән бәхетле яшәү өчен кирәк!

— Гомереңне бир!

— Бирә алмыйм! Минсез нишләр ул?

— Минем белән булыр.

— Син көчле, син кодрәтле, әмма ул мине ярата. Сине үз итә, ә мине ярата! Ярдәм ит!

— Миңа ышану гына җитми, миңа инану кирәк. Ә синдә инану… бар. Мин сиңа ярдәм итәм, Адәм баласы. Иң шифалы һавамны Сайдәгә тормыш сулышы итеп өрәм… Җирне, Суны бәхиллә; Күктә яшәсәм дә, минем көчем иң элек аларда…

…Сайдә күзләрен ачканда, Түләк, ике кулын өскә сузып, йомык күзләрен җир түшәмгә төбәп, үзе генә белгән телдә гыйбадәт кылып тора иде.

— Түләк, син нишлисең?

— Ә? Терелдеңме, Сайдә?

— Син кемнәр белән сөйләштең, Түләк?

— Мин Тәңре белән сөйләштем, Җир белән, Су белән сөйләштем, алардан шәфкать сорадым.

— Җир, Су белән сөйләшеп буламыни, Түләк? Күк белән дә сөйләшеп буламы? Алар теремени?

— И Сайдә, син бу хакта сорашма. Шуны гына бел: Дөньяда, Галәмдә һәрнәрсә тере, һәрнәрсәнең җаны, рухы, иясе бар. Тик Тәңре генә бердәнбер һәм мәңгелек…

— Син аларны күрәсеңме, тоясыңмы?

— Күрәм, тоям, ишетәм.

— Ә нигә мин күрмим?

— Син бит кеше, синең күзең сукыр, син чукрак.

— Ә син кеше түгелмени?

— Түгел.

— Кем соң син? Җенме?

— Мин — Түләк.

— Түләк, мин хәзер үлмимме?

— Юк, үлмисең. Син Тәңре бәхиллегенә ирештең. Җир белән Су да сиңа мәрхәмәтле булдылар.

— Түләк, әйдә мин синең хатының булам. Безнең балаларыбыз туар...

Түләк дәшмәде. Учак тирәсендә булашты.

— Түләк, син әйбәт…— Сайдәнең бик тә сөйләшәсе килә иде.

— Син дә әйбәт, Сайдә.

— Мин ошыйммы сиңа?

— Син әйбәт.

— Яратасыңмы мине?

— Син әйбәт!

— Ә мин сине бик тә, бик тә яратам!

Түләк, торып, Сайдәнең түшәге янына ук килде, елмаеп-сөеп карап торды, аннары, уң кулын учак корымына буялып беткән шәрә күкрәгенә куеп:

— Мин... Әйбәт! — диде дә, йөгереп барып, өй почмагында ялтырап яткан сулы коега сикерде...

## 9

Дәхи Аллаһ юлларны белергә галәмәтләр —маяклар бар итте, вә адәм балалары кораблар белән диңгездә йөргәндә барачак тарафларын йолдызларга карап табарлар.

*«Коръән тәфсире»,*
*«Нәкел» сүрәсеннән 16 нчы аять*

Сайдә бик авыр терелде. Тормышка да озак кайтты. Түләк аның яныннан бер минутка китмәде. Соңрак, көнгә бер мәртәбә, үзенең кое юлы буйлап, тышка, Җидесу буена чыгып керә башлады. Бу җир өй читендәге бәке елга өстенә алып чыга торган су юлының авызы икән. Түләк кирәк-яракларны шул су юлы белән алып керә яисә алып чыгып китә... Баштарак порхылдап өскә килеп чыккан Түләктән сискәнеп, куркып, җаннары суырыла иде Сайдәнең. Аннары күнекте. Су тавышына, су исенә, су гаменә күнекте.

Бу сәер торагына да күнегә башлады Сайдә. Түшәмдәге яктылык бер дә лампа түгел икән, җир өстенә кадәр менә торган уентык тишек икән. Шуңа карап вакыт исәбен дә беләләр: ул ачык торса — көн, томаланса — төн җиткән була.

Иң кызыгы бу да түгел әле. Түрдәге почмакта бер уентык ярык булып, аның аша эчкәреге бүлмәләргә кереп йөреп була. Ул бүлмәләрнең берсе келәт вазифасын башкара, иң ары торганы — мал абзары. Анда берничә кәҗә яши. Аларны беренче мәртәбә күргәч, Сайдә акылдан шаша язды.

Ул көнне үзе генә калган иде. Түләк, бер кыр үрдәген ботарлап, учак күмере өстенә элеп куйды да, Сайдә өчен җиләк чәе әзерләде, аннары, гадәтенчә, берни әйтми-нитми, үз коесына төшеп китте. Якты дөньяга, кояшка ишарәләп торган түбә тишегеннән башка берни дә калмады.Ә, калган икән әле! Печән өеме арасында сайрап өзгәләнүче чикерткә бар әле! Ул да үзенең кырын, яланын сагына микән?

Тагын кемдер бар. Түр почмакның караңгы аралыгыннан ниндидер тавышлар ишетелгән кебек булды. Сайдә сагайды, терсәгенә таянып, башын калкытты. Җир өй эчен түшәмдәге ачык тишек белән учакның тонык уты гына яктыртып бетерә алмый, шуңа да һәр шәүлә, һәр кыштырдау җен-пәри булып күренә. Бу юлы стена эченнән чыннан да бер җен килеп чыкты. Ике мөгезле, кәҗә сакаллы, озын йонлы, үзе ап-ак... Нишләп ак? Җеннәр кара була ди бит... Аһ! Аһ...

Сайдә бая гына Түләк төшеп киткән коега үзе дә чумарга әзер иде инде, аннан пылт итеп Түләк үзе килеп чыкты. Сайдәнең, ах-ух килеп, шөбһәләнеп ятуын күреп, ул шундук зәхмәтле почмакка таш ыргытты. Җен сыңары, кәҗә кебек кычкыра-кычкыра, кабат стена ярыгына кереп китте, ә Түләк, Сайдә каршына тезләнеп, кызның калтыранган кулларыннан тотты.

— Җен... җен анда... — Сайдә һаман тынычлана алмый иде әле.

— Җен түгел, кәҗә ул, кәҗә!

— Кәҗә! Каян килсен ул монда?

— Күптән инде. Көнне күргәне юк аның, шуңа да күзләре күрми. Аның әле бәтиләре дә бар...

Сайдә шунда гына Түләк пешергән сөтле ашны, көн дә берничә мәртәбә эчә торган парлы күбекле сөтне исенә төшерде.

Тагын берничә атнадан Сайдә аякка басты, өй, хуҗалык эшләрендә Түләккә булыша башлады, учак бөтенләе белән аның карамагына күчте. Түләк күбрәк балык тотып, ау эшләре белән мәшгуль булды, кышка утын әзерләде, печән, орлык, бәрәңге китерде, он, тоз юнәтте. Сайдә аларның каян алынганын белмәде. Түләктән сорарга да кыймады. Бер генә нәрсәгә аптырады ул: ниндидер сихер белән, Түләк алып кайткан әйберләр юешләнмәгән була, югыйсә тар коедан бүтән тышка чыгу юлы да юк бит...

Сайдә беркөнне кыен хәлдә калды, аннары шул көн өчен Түләктән кыенсынып йөрде. Шушы көн аларны кавыштырды да. Ул, учак янында булашканда, һаман янып бетә алмый азапланган утын кисәвен, кая куярга белмичә, үзе сизмәстән, Түләк чумып йөри торган коега илтеп тыкты. Чыжылдап пар болыты күтәрелде, бөтен бүлмәгә көек исе тулды... Түрдә бүген генә каяндыр алып кайткан такта кисәкләрен урнаштырып йөргән Түләк, кай арада килеп җитеп, кискен хәрәкәтләр белән кисәү агачын тартып алды, Сайдәнең үзен түшәккә таба этеп җибәрде. Аннары, тезләнеп, һаман әле сүнеп бетмәгән кисәүне ипләп кенә бер читкә куйды да, иелеп, маңгаен суга терәде. Күзләрен йомды. Шулай шактый вакыт торды.

Сайдә Түләкнең мондый чагын беренче мәртәбә күрә иде. Бу кыргый адәмнең кан тамырлары бүртеп чыккан, йөзенә карау да куркыныч иде. Менә ул, башын күтәрмичә генә, Сайдә ягына боры-

лып карады, аннары, кашларын җыерып, сынап торды да… Сайдәнең җан-бәгыре өзелдем дигәндә генә, элеккечә матур, ачык итеп елмаеп җибәрде.

Сайдә исән калды. Башын артка ташлап йомшак түшәгенә ятты да күзләрен йомды. Түләккә шул гына кирәк булган, — ул мәче җитезлеге белән Сайдә янына килеп җитте, битен кызның куркудан алсулана башлаган йөзенә куйды…

— Алай эшләмә, Сайдә… Су ачулана… Рәнҗи…

— Ничек ачулансын, ничек рәнҗесен, су гына бит ул?!

— Шуңа да рәнҗи ул, су бит ул, су! Кеше генә түгел… Ул кешегә караганда тererәк; аның да тәне авырта, җаны сызлана…

— Мин берни дә аңламыйм, Түләк. Син әллә нинди дөньяда яшисең. Миңа кыен монда…

— Бер дә кыен түгел. Суга тияргә ярамый, аңа пычак, сөңге белән кадарга ярамый, түкерергә, ярамый, аны нәҗесләргә ярамый! Аннары… Аңа карап сүгенергә, ялганларга ярамый… Шул гына!

— Кызык бу. Тик куркыныч…

— Кешеләрне рәнҗетергә ярамый. Моны бер дә куркыныч димисез бит. Суны да рәнҗетергә ярамый, аның хәтере әйбәт. Усал кешене бер килеп тота ул, барыбер аның соңгы сулышын суырып ала…

— Мине алмады, тотмады, әйеме. Мин әйбәтмени?

— Юк, ул синең нинди икәнеңне белми иде әле.

— Ни өчен мине тотмады соң ул?

— Минем хакка. Син бит минеке. Ә мине су белә: аның туганы икәнне белә…

— Мин синекемени, Түләк?

— Әйе… Су безгә бергә булырга куша. Җир дә, Күк тә бергә булырга куша… Мин моны тоям… Син тоясыңмы?

Түләк үбешә белми иде. Ул уттай кызу яңагы белән Сайдәнең йөзен, маңгаен, иякләрен иркәләде, күкрәкләрен назлады, үзе дә онытылып назланды. Аннары ул дәрткә тулыша барган тәнендә кызның йомшак кулларын тойды; ул куллар аны сөю-мәхәббәт иленә, бәхетнең җиденче катына чакыралар иде…

Сайдә барысын да үзе эшләде. Аның мәхәббәткә тоемы көчлерәк, сөю хәрәкәтләре төгәлрәк булып чыкты. Иреннәр иренгә тиюгә, иң элек икесе дә, пар еланнар кебек бер-берсенә сарылып, дәртләрен сынадылар. Иң ахырда ниндидер илаһи көч тәннәреннән соңгы тамчы тирне, дәртләреннән соңгы тамчы майны сыгып чыгарганда, җаннарын алмаштылар…

Шулай алар су ярдәме белән ирле-хатынлы булдылар, язмыш, тормыш белән генә түгел, тән белән дә, кан белән дә, хәтта җан белән мәңгелеккә туганлаштылар.

Бу көннәрдә Түләк сирәгрәк чыгып йөри башлады. Табигать асылы белән дәртле бит ул. Табигать улы буларак Түләк тә Сайдә яныннан китмәде, кыз үзе дә аны еракка җибәрмәскә тырышты. Көннәр буе, ашау-эчүләрен онытып, назланышып яткан чаклары күп булды аларның. Бу көннәрдә Түләк сөйгәненә тәмле ризыклар әзерләп бирә, хәтта, келәт ягына чыгып, берничә кәнфит тә алып керде. Сайдә мондагы ризыкларга күнекте инде, үзе дә кипкән, ысланган иттән, балыктан күп нәрсәләр әзерләргә өйрәнде.

Бер иртәдә Түләк аңа күлмәк бүләк итте. Сайдә куанычыннан сикергәләп куйды. Таман гына икән. Әлбәттә инде, ул Түләктән бу күлмәкне каян алуын сорады. Әнисенеке булуын әйткәч, Сайдә аны кочаклап үпте. Түләккә шул җитә калды, ул хатынын, кулларына күтәреп, бүлмә уртасында зыр-зыр әйләндереп йөртә башлады.

Аның каравы Сайдә моңсуланды.

— Нәрсә булды? — дип кат-кат сорады Түләк.

Башта дәшмичәрәк торган Сайдә, пышылдап кына:

— Әнием искә төште… — диде.

Түләк, барысын да аңлыйм дигән кебек, башын аска иеп, сәке читенә утырды. Бераз тын калып тордылар.

Аннары Сайдә үзе сикереп торды.

Бармагындагы йөзеген алып Түләккә тоттырды да:

— Минем исән икәнне белдер, — диде.

Түләк шундук коега төшеп юк булды. Сайдә ялгызы гына хәтсез моңаеп, уйланып утырды әле. Бик күп һәм төрледән-төрле уйлар уйлады ул бу утыруында. Әмма ялгыш кына да, китәм мин бу җир дөньясыннан, авылга, әнием янына кайтам дип уйламады.

Табигатьнең серләре күп. Сайдәнең шушы караңгы гүр почмагыннан кабат якты дөньяга, туган нигезенә, газиз анасы янына кайту турында борчылып уйламавы Табигать белән Ходай Тәгалә өчен дә, изге рухлар өчен дә олы сер булып калды.

Түләк кайтып кергәндә, Сайдә түшәгендә оеп ята иде. Кулына әнисе әзерләп биргән төенчек килеп кергәч, ул сискәнеп, хәтта куркып китте. Өй исләре аңкытып торган түшәк җаймаларен, зәңгәрсу күлмәген, кашемир яулыгын күкрәгенә кысып, елап алды.

Түләк аны ничек тә юатырга белмәде. Ахырда уйлап тапты.

Хатыны каршына килеп тезләнде дә, яшькә чылана башлаган чүпрәк-чапракка күрсәтеп:

— Миндә болар күп, — диде.

— Ә? Кайда?

Хатын-кыз өчен күп кирәкмени? Сайдә борчуларын бик тиз онытты, Түләккә ияреп, келәт ягына кереп китте. Ул бит бу якка бик кереп йөрми, теге юлы кәҗә белән булган хәлләрдән соң, төрле хәшәрәтләр, җеннәр бар кебек тоела аңа бу җир куышында.

Түләк җыйнак кына ике сандык сөйрәп чыгарды. Аларны, әти-әнисе үлгәч, тегермән чормасыннан алып кайтуын әйтте.

Сайдәгә шул җитә калды. Сандыктан чыккан пәрдә-чаршауларны, чигүле сөлгеләрне ул шундук өй диварларына элде. Түшәген өр-яңадан көйләп җәйде, өстәлдәге ашъяулыкны, шүрлекләргә эленгән чыбылдыкны алыштырды, түр якка көзге элеп куйды.

Шыксыз, ямьсез җир куышы шул минутта чып-чын авыл өенә охшады да калды.

Балага узган көнне Сайдә тагын әнисен исенә төшерде, елап алды. Түләкне хәл белергә җибәрде. Ә ул бик озак торып кайтты. Әллә нәрсәләр уйлап бетерде Сайдә. «Авылга кайткач, Рәзилләр кулына эләктеме әллә?» дигән уй да тынгылык бирми йөдәтте. Көтеп-көтеп тә ала алмагач, Сайдә су юлына төшеп карарга булды. Бу серле урын күптәннән үзенә тартып, кызыктырып тора иде аны.

Кое төпсез булып чыкты. Су салкын түгел, Сайдә, берничә мәртәбә чумып, астагы юлларны барлады. Ә юл берәү генә иде. Очында көн яктылыгы җем-җем килеп тора. Димәк, бу мәгарәнең авызы Җидесу өстенә чыга.

Сайдә тәвәккәлләп карарга булды. Әтисенә ияреп елгага йөргәндә, ул су астында да, су өстендә дә бик әйбәтләп йөзәргә өйрәнгән иде. Хәзер шул күнекмәләрне искә төшерергә туры киләчәк…

Ләкин Сайдә җемелдәп торган яктылыкка тиз генә барып җитә алмады. Хәтта… барган саен ерагайган кебек тоелды аңа бу яктылык… «Әллә кире борылыргамы?» — дип уйлады ул. Юк, ниндидер ымсындыргыч көч Сайдәне һаман алга — теге сәер җемелдәвеккә өндәде.

Тыны бетеп, зиһене томалана башлагач та өметен сүндермәде ул. Ләкин өмете дә өметсез иде аның: «Кайда соң бу Су рухы, Җир рухы? Күк рухы кайда? Алар ярдәм итәргә тиеш иде бит… Су! Су! Нигә шулкадәр күп син?! Нигә мин су түгел?! Нигә мин кеше?!»

Шул вакыт суга җан кергән кебек булды. Каяндыр су төбеннән бер бәйләм дулкын йөгереп килеп чыкты да, хәлсезләнгән, тынсыз, буынсыз булып калган Сайдәне күтәреп өскә алып менеп китте. Кинәт өстәге җир селкенеп-калтыранып куйды да як-якка тайпылып, аерылып китте, һәм кеше башы сыярлык кына бушлык, ярык барлыкка килде. Сайдә йотлыгып-йотлыгып һава сулады. Үзен коткарган су белән җиргә, шулай ук татлыдан татлы һавага рәхмәтләр укыды. Ләкин ул сулышын тигезләп, һушын җыеп өлгермәде, су агымы тагын аска тартып алды, озак та үтми Сайдә Җидесу өстендә пәйда булды!

Ул Түләк белән йөзгә йөз очрашты. Шундук елый-елый иренең киң түшенә барып сарылды.

— Түләк, мин батып үлә яздым… Су гына коткарды мине, Җир белән Һава коткарды.

Түләк хатынын күкрәгенә кысты. Баш түбәсеннән үбеп алды.

— Беләм, миңа бу хакта хәбәр иттеләр инде. Бүтән үзең генә йөрмә, яме.

— Минем дә чыгасым килә, якты дөньяны күрәсем килә!.. Түләк, аңлыйсыңмы, мин бит кояш астында туган кеше… Өйрәт мине дә, үзең кебек йөзәргә өйрәт!

— Өйрәтермен, хәзер сиңа да, балага да бик күп һава, якты һава кирәк булачак… Бу дөньяга туганчы ук тояргa тиеш ул шушы киңлекне, Күкне, Кояшны. Ул бит кеше булып туачак, шулаймы, Сайдә?

— Безнең кебек үк…

— Юк, минем кебек булуын теләмим. Минем кебек кыргый булмасын, ятим булмасын ул, аннары…

— Нәрсә — «аннары», Түләк?

— Аннары… кешеләр арасында үссен. Чын кеше булу өчен кешеләр арасында үсәргә тиеш ул!

— И Түләк, уйларга да куркыныч бу хакта…

— Әйдә керәбез… Син арыгансың инде… Иртәгә чыгарбыз. Мин сиңа ничек тын алмыйча йөзәргә өйрәтермен. Бик җиңел ул… Хәлең, тының бетсә, ана карынындагы кебек, бер мәлгә бөгәрләнеп торырга гына кирәк. Шундук хәл керә, тын-сулыш иркенәя…

Дөреслектә, сиңа җәннәттә ачлык вә ялангачлык юктыр. Дәхи син анда сусыз булмассың һәм кояш кыздыруына пешмәссең.

*«Коръән тәфсире»,*
*«Та һа» сүрәсеннән 119—120 аятьләр*

Көзге салкыннар башланганчы Түләк белән Сайдә Җидесуга чыгып йөрделәр. Алар булмаган бер яр да, бер күл дә калмагандыр. Ябалак тавына да менделәр. Түләк Ябалак тавының иң биек кыясыннан кош кебек очып төшкәндә, Сайдәнең йөрәге кысылып, сулышы тараеп куя иде… Аннары алар Җидесуның җиде суы кушылган урында йөзеп куыштылар… Шулай да ике нәрсә аларны үз өннәренә бик тиз куып кертте: дөньяга кыш җитеп килә иде. Сайдә карынында яткан бала да җылы сорап тибенә башлады.

Кышка кергәч, алар кеше кыяфәте алдылар. Сайдә Түләкнең чәчләрен кисте, сакал-мыегын рәтләде, булган байлыкны актарып, аны өр-яңадан киендерде. Үзе дә киенеп алды, ясанып-төзәнеп йөри башлады.

Чыра яктысында көннәр-төннәр буе сөйләшеп утырган чаклары күп булды, Түләк үзенекен сөйли, Сайдә — үзенекен… Түләккә үзе хакындагы дастан ошады. Ул аны берничә мәртәбә сөйләтте.

Һәр тыңлаганда аның күзләреннән мөлдерәмә яшь ага, ул бигрәк тә Түләк белән Сусылуның, җир өстенә чыгып, бәхетле гомер итүләре хакындагы җыруны бөтен күңеле белән ихлас кичереп тыңлый иде.

*«Чачдар хан, Түләк уйнаганын ишетеп, гашыйк булды.*

*Кырык көн эчеп-ашап, бергә булдылар. Аннан соң Түләк еракта калган Сусылуны, Балкан тауны сагынды. Чачдар ханга җырлап:*

Балкан тавым монда юк,
Ак киегем монда юк,
Утырып уен уйнарга
Алтын тәхетем монда юк!
Җөмлә буе җофары,
Зифа ярым монда юк… —

*диган иде, Чачдар хан диюләргә, пәриләргә боерды: «Барыгыз, Түләкнең тавын китерегез!» — диде. Диюләр, пәриләр бардылар. Ләкин Хак Тәгалә Балкан тавын аларга күрсәтмәде, бу сарай янындагы икенче бер тауны бер пәри өстенә салып алып килделәр. Түләк, пәриләрнең нииндидер тау китергәнен күреп:*

Минем тавым ул түгел,
Алтын тәхетем ул түгел!
Тауны тауга охшатып,
Тимер белән коршатып,
Алып килә торырлар! —

*диде. Аңа Чачдар хан җавап итеп әйтте:*

Тауны тауга охшатып,
Тимер белән коршатып,
Торыр монда Түләгем,
Балкан тауга охшатып.

*Ләкин Түләк, Чачдар хан әйткәннәргә риза булмыйча, үз тавына кайтаруны сорады.*

*Чачдар хан пәриләренә әмер кылды: «Барыгыз, ул әйткәнчә эшләгез», — диде. Падишаһ Түләк белән Сусылуны җир өстенә чыгарып куйдыртты. Алар үзләренең Балкан тауларында күп еллар матур гомер иттеләр…»*

Үз исеме дә шул дастаннан алынганлыгын белгәч, Түләкнең тагын күңеле нечкәрде, күз төпләре дымланды. Ул Сайдәдән тагын, тагын укуын сорады. Кайсыдыр сандык төбендә берничә китап яткан икән, аларны да берничә мәртәбә укып чыктылар. Түләк бик тырыш укучы булып чыкты: һәр тыңлаганын, йөрәгенә якын алып, исендә калдырырга тырыша, күңеленә хуш килсә, очынып-очынып мактый, ошамаса — сабый балалар кебек үпкәли, бәхәсләшә, тиргәшә башлый…

Бервакыт Сайдә аңа хәреф өйрәтергә булды. Түләк өйрәнеп кенә калмады, белгән хәрефләрен янәшә куеп, иҗекләп укый да башлады. Аннары санарга, кушарга, алырга өйрәнде. Үзе моңа шатланып бетә алмады, ашаудан, эчүдән калды, дөнья гамен онытты; Сайдә әзерләп биргән «парта» артында көннәр буе китап тотып утырды. Үзе, кирәккә-кирәкмәгәнгә дә Сайдәгә бихисап күп сораулар биреп, Дөнья, Галәм, Җир, Яшәеш, кешелек хакында кызыксынды, шул рәвешле көннән-көн тормышка якыная барды…

Аны бигрәк тә Җирнең түгәрәк булуы аптыратты.

Ул, Сайдәне бүлә-бүлә:

— Ә нигә су агып бетми алайса? — дип сорашырга керешә.

Йоп-йомры Җир шарыннан елга-күлләрнең, дәрьяларның агып, коелып, чәчелеп бетмәвен Сайдә үзе дә аңлатып бирә алмый иде, шуңа күрә ул Түләкнең үз «телендә» җавап бирде:

— Чөнки Җир белән Су — бертуганнар; алар береккәннәр, бер-берсеннән аерыла алмыйлар... Аерыла башласалар, Күк-Аналары аларны шундук татулаштыра, дуслаштыра...

Түләк моңа ышана, караңгы җир түшәмгә карап, уйланып, Сайдә сөйләгәннәрне күзаллап утыра.

Шулай хыялланып утыра-утыра да, үзе дә сизмәстән, җир стенага үрелеп, бер чеметем балчык каба. Бераздан тагын каба, тагын... Су коенган вакытта Сайдәнең искә алганы бар иде инде: Түләк, тамагы ача башласа, кыя төбеннән ак ком учлап ала да иреннәренә куя...

Бу юлы Сайдә сорамый кала алмады:

— Түләк, нишлисең син? Әллә балчык ашыйсың инде?

Түләк кыенсынгандай итте, аннары, иреннәрендә калган балчык тузанын сыпырып куйды да сөйли башлады:

— Мин шушы балчыкны ашап исән калдым. Хәзер дә ашыйм, тамагым тук, барыбер ашыйм. Миңа ул кирәк, мин хәзер балчык ашамыйча тора алмыйм...

— Ничек булды ул, сөйләле, Түләк...

Түләк, бермәл уйга калып торганнан соң, Сайдә хакында бөтенләй оныткан кебек, акрын, салмак кына сөйләп китте:

— Мин барысын да хәтерлим... Әтиемне, әниемне хәтерлим... Аларга килеп йөргән авыл кешеләрен дә хәтерлим... Мәннән картны... Күзләрен, йөзләрен хәтерлим... Тавышларын... Исемнәрен... Ләкин әнием белән әтиемне үтерткән кешене генә хәтерләмим. Оныттым. Үзен дә, йөзен дә, исемен дә оныттым... Шул кеше янап киткән көнне, юк-юк, төнне әллә нинди кешеләр килеп, әтием белән әниемне тегермән ташы астына салып, аның күчәрен кистеләр... Мин боларның барысын да хәтерлим... Әтиемнең, миңа карап: «Кач, кач, тауга кач!» — дип кычкырганын да хәтерлим...

Ә мин качмадым. Чормада үзем генә белгән тар бүлмәләр бар иде. Шунда качып калдым. Әтием белән әниемне алып чыгып киткәч, куркып, дер калтырап, ике көн яттым. Аннары, өйдәге вак-төяк әйберләрне төйнәп, ашарга юнәтеп, Ябалак тавына киттем. Өч көн, өч төн качып йөргәннән соң, Җидесуга төштем. Төшеп җитә алмадым, бер ярыкка эләгеп, җирдәге куышлыкка убылып төшеп киттем. Әнә ул тишек... Аннан шуып төшсәң, нәкъ шушы коега эләгәсең... Шуңа күрә дә исән калдым. Үле дә түгел, тере дә түгел — шулай яшәдем. Ашарга ризыгым беткәч, җир кимердем, шушы ләмле суны эчтем. Эчке бүлмәләрне соңыннан казыдым мин, андагы туклыклы чишмәләрне дә соңрак ачтым.

Балчык ашап, су үләннәре чәйнәп, вак төяк белән, елан, балык тотып, кышны кышладым... Шушы коедан төшеп, елгага алып чыга торган юлны эзләп таптым...

Аннары Мәннән карт килеп чыкты. Ул мине күп нәрсәгә өйрәтте. Ут кабызып бирде. Табак-савыт, тоз, сабын китереп торды... Ул — әтиемнең дусты, әйбәт кеше. Әниең белән дә ул сөйләште, аңа синең хакта хәбәр итте. Мин беләм — әниең сине ярата, сагына, көтә. Ул хәзер тыныч, ул... ул терелде инде.

— Түләк, әнием авырдымыни?

— Бераз гына авырды, сине сагынып авырды. Хәзер ул үз аңында, үз күңелендә...

Түләкнең тарихы Сайдәгә бик авыр тәэсир итте. Аны хәтта тулгак тота язды. Түләк үзенең сихере белән, «су догасы» белән генә тынычландыра алды хатынын.

Ләкин Сайдә барыбер тынычланып бетә алмады, гадәти тормышында торып-торып сорап куя иде ул Түләктән:

— Ничек яши алдың соң ничәмә-ничә еллар? Үзеңә генә кыен, ямансу булгандыр бит?

— Баштарак әтиемне, әниемне бик сагына идем, бик елый идем. Тегермән тирәсендә күп йөрдем. Берсендә авыл кешеләре «җен!» «җен!» дип кудылар. Эттән талаттылар. Ул эт белән канга батып сугыштым. Тешләрем белән бугазын өзгәләдем. Аннары, өнемә алып кайтып, бер атна буе учакта итен кыздырдым, тиресен астыма җәйдем...

Шунда минем күңелемә беренче мәртәбә ау хисе керде. Кыргый киекләр ауларга чыккан төннәрдә буш кайтканым булмады. Тамагым тук, өстем бөтен иде.

— Ә менә... мине күргәч... мине күргәч нәрсә уйладың? — Сайдә, түземсезләнеп, үзен кызыксындырган иң мөһим сорауны бирде.

— Сине күптән белә идем. Мин бит авылны яхшы беләм; еш кына, тегермән чормасына менеп, күзәтеп утыра идем. Син гел су буенда үстең. Әтиең белән балыкка йөрдең. Син су коенганда астан карап торган чакларым да булды. Ачуланма, миңа ул вакытта барысы да кызык иде... Хәзер дә кызык... Син бит матур... Хәтта бик матур!..

— Аннары мине коткардың, шулаймы?

— Коткара алмадым шул. Мин сине ярга алып чыкканда син үлгән идең инде. Мин салкын тәнеңә сулышымны өреп карадым, сихерләп, йөзеңә су да сиптем, әмма терелтә алмадым... Аннары җир

тырнап, үкереп еладым. Су, Җир, Күк ишетте минем бу әрнүле тавышымны. Шундук килеп тә җиттеләр, терелттеләр. Ә миңа сине, күтәреп, авылга кадәр илтеп куясы гына калды. Теге явыз бәндәләрне, өчесен бергә бәйләп, агач башына элеп киттем...

...Кайчакта Сайдә белән Түләк бөтен кичләрен туачак балалары белән уйнап үткәрәләр. Сайдәнең карынында тибенеп яткан җан-бәгырь кисәге бу ике табигать баласын көннән-көн бер-беренә якынайта бара. Уртак бала, уртак язмышка әверелеп, аларга киләчәкләре хакында уйларга мәҗбүр итә иде.

Бәхәсне Түләк кузгатып җибәрә:

— Ул кешеләр арасында, авылда туарга тиеш, — ди.

Сайдә шундук каршы төшә:

— Җен баласы дип, таш бәреп китәрләр иде бугай. Юк, үтерсәләр дә авылга кайтмыйм.

— Аңла син, Сайдә. Без монда кешеләр арасында туганга гына кеше булып калдык... Ә бу җан кисәге шушы караңгы җир тишегендә туса, үзенең кеше икәнен ничек тояр соң? Тәне кешенеке булса да, җаны баканыкы яисә... җен-пәринеке булачак аның...

Шунда бәхәс тәмамлана. Чөнки Түләк хаклы. Сайдә моны аңлый һәм, йөрәген учына кысып булса да, үзенең авылга кайтачагы, баласын әнисе янында табачагы белән килешә. Бөтен күңеле белән, рухы белән шуңа әзерләнә...

## 11

Фиргавен, үзенең гаскәрен алып, Мусаны тотарга артларыннан куа чыкты; атлы гаскәре белән Муса артыннан коры юл белән диңгезгә керделәр, алар керүгә, диңгез кушылып, һәммәсе һәлак булдылар.

*«Коръән тәфсире»,*
*«Та һа» сүрәсеннән 78 нче аять*

Түләк Җидесуга май аенда чыгып йөри башлады. Иң элек ул Җидесуның ике ярын тоташтырып торган асылмалы күперне рәтләп, төзәтеп кайтты. Бу вакытта Сайдә нык кына тазарып, калынаеп өлгергән иде. Малай булырга охшаган — карынындагы бала, бертуктаусыз бимазалап, әнисенең тәмам тынычлыгын, йокысын алды. Йөгерә дә йөгерә... Кая йөгерәдер ул, кая ашыгадыр?.. Ашыккан җире бер дә аһ итәрлек түгел бит аның — табигатьнең караңгы бер базы, аның хәшәрәтләр, җеннәр яши торган зәхмәтле чокыры... Нишләп йөгерсен ул?! Йөзәдер... Карындагы суны дәрья итеп йөзәдер, әтисе кебек, әнисе кебек, су кошы, юк ла, су кешесе булырга әзерләнәдер...

Ниһаять, ул сәгать сукты. Авылга җыена башладылар. Дөресен генә әйткәндә, Сайдә өйгә кайтырга күптән җыена башлаган иде инде. Кирәк-яракларны инде әллә кайчан барлап куйган иде, стенадагы көзге өстенә чүпрәк каплап, учакны сүндерәсе генә калды. Нишләптер Түләк кәҗәләрне суймый... Берәр хикмәте бардыр — Сайдә бу хакта башын ватып тормады, аның үз хәле хәл иде...

Китәсе көнне Түләк суга төшеп менде. Ул шулай рухлар белән саубуллашты, аларның бәхиллекләрен алды. Бер чеметем балчык кабып, су йотып, үзенең йоласын башкарды, тезләнгән килеш кулларын күккә сузып, авыз эченнән нидер укынды...

Ләкин, Сайдәне гаҗәпкә калдырып, Түләк аны су юлына төшермәде, кире якка — эчкәрегә мәгарәгә алып кереп китте. Чишмә бәреп-агып торган җир куышы да, кәҗәләр яшәгән җир абзар да, келәт тә артта калды, ниндидер олы, йомры ташны янтайтып, Түләк тар гына җир ярыгы буйлап тагын да арырак кереп китте. Өске яктан нурлы яктылык сирпелә, шуңа күрә һәр таш кисәге, һәр тузан бөртеге аермачык булып күренеп тора. Сулыш алуы да иркенәйде, димәк, озакламый алар тышкы якка барып чыгачаклар...

Шулай булды да, Сайдә тирә-ягына каранып, бу сәер юлга күнегеп өлгергәнче, алар, пылт итеп, куе әрәмәлек авызына килеп тә чыктылар.

— Түләк? — Бу сорауда барысы да бар иде: «Мондый юл да бар идемени? Нигә судан йөртеп интектердең мине? Нигә элегрәк әйтмәдең?» — дип сорамакчы иде Сайдә. Сорамады. Ә Түләк җавап бирмәде. Ул бүген бик борчулы иде. Бу борчу аның йөзенә чыккан, күз-карашларына иңгән, хәтта авыр адымнарына, салмак хәрәкәтләренә күчкән. Нидер сизенеп борчыламы, әллә ничәмә-ничә еллар яшәгән чокырыннан аерыласы килмиме? Аңа бит Сайдәгә караганда да кыенрак,— авыл бу табигать баласын, «су җенен» бик озак үзенә кабул итмәячәк әле. Бу көн кебек ачык. Ләкин бала язмышы, бала хакы дигән нәрсә бөтенесен дә хәл иткән, шуңа күрә дә авылда туып, табигатькә сыгынып яшәгән ике адәм баласы җитәкләшеп үз язмышларына каршы китеп баралар иде.

Бу юлы алар качып йөрмәделәр, туп-туры юлга чыктылар. Беркем дә очрамады. Очраса да, кешечә киенгән бу яшь парга әллә ни игътибар да итмичә узып китәрләр иде, мөгаен. Әле сөенеп уйланырлар иде: «Карале, туар алдыннан балаларын су буена алып чыкканнар. Су — сагышка һәм изгелеккә. Һичшиксез, бу бала да матур, батыр, таза һәм... моңлы булып үсәчәк»,— диярләр иде.

Менә алар иске тегермән белән тигезләштеләр. Сөйләшмәделәр. Һәрберсенең үз уе. Әмма нәрсә генә уйласалар да, уйлары бер үк төенгә килеп бәйләнә иде. Бу мәлдә алар бер-берсенә карашып

алалар: «Ул ireккә һәм мәхәббәткә лаек!» Бераз баралар да тагын уйлыйлар: «Ул кешеләр арасында яшәргә лаек!» Тагын уйлыйлар: «Ул бәхеткә лаек!» Тагын: «Ул яшәүгә лаек!» Тагын, тагын, тагын... Нәрсә уйласалар да, икесе бер үк уйны уйлыйлар. Балалары якты дөньяга килер алдыннан ата белән ана бер-берсенә аеруча якынаялар, бер-берсен ныграк тоялар, аңлыйлар, диләр. Дөрес икән...

Дөрес микән? Менә хәзер алар төрлечә уйлыйлар. Сайдә: «Кайтам! Әнием янына, кешеләр янына кайтам!» — дип сөенә, ә Түләк: «Кайтмыйм. Кире китәм. Ят миңа бу дөнья... Үземнекеләрне читтән генә күзәтеп яшәрмен, рухыбыз белән аерылышмыйбыз бит без», — дип карыша.

Шулай алар уйларында бер-берсен таба алмыйча аптырыйлар. Аптырап кына калмыйча, тегермән белән авыл уртасында туктап калалар...

Сайдә Түләк белән нидер булганын шундук аңлап алды.

— Түләк, ник туктап калдың?

— Сайдә...

— Түләк, әйт инде, ник туктадың? — Сайдә борчылып тынгысызлана башлады.

— Сайдә... — Түләк, тутый кош кебек, һаман бер сүзне тукып тора иде.

— Нәрсә инде?

— Мин калам... Син бар. Минем белән булсагыз, сезгә тынгылык бирмәячәкләр. Сезне беләләр, мине белмиләр...

— Түләк, ни сөйлисең син?

— Сайдә, мине кешеләр кабул итмәячәк. Мин бит алар өчен «җен», белдеңме — «җен»! «Су җене»! Минем аркада сезгә дә эләгәчәк. Мин анда үләчәкмен, үлмәсәм дә... үтерәчәкләр... Ә син... Әниең янына кайт, бала тап, шуннан соң күрешербез, безгә нишләргә икәнен әйтерләр.

— Кемнәр?

— Су, Җир, Күк...

Бу юлы Сайдә каршы дәшмәде. Башын Түләкнең түшенә куйды да елап җибәрде.

Бераз тын тордылар. Аннары, якындагы чишмәдән су учлап, Түләк Сайдәне ырымлап өшкереп алды, аның шактый зураеп, бүртеп киткән корсагын сыйпаштырды.

Ул арада авыл ягында ниндидер тавышлар ишетелә башлады. Алар, якынайганнан-якыная барып, менә-менә үр артыннан килеп чыгарлар кебек иде.

— Бар, Сайдә, син кайт.

— Түләк!..

— Бар, Сайдә, бар... Туп-туры өеңә кайт. Беркемнең дә күзенә карама. Шулай кирәк. Әлегә шулай кирәк...

— Түләк!

— Сайдә!

— Без әле бергә яшәячәкбез, Сайдә!

— Түләк!..

Шулай аерылыштылар. Сайдә кайтыр юлга төште, Түләк тә, үзенә генә хас җитезлек белән, ә бәлки сихер беләндер, баскан урынында ук юк булды.

Сайдәгә моңсу булып китте. Ул як-ягына каранып бара бара да бер урында таптанып тора, аннары тагын кузгала. Күңелендәге шомны, куркуны күңелендә йөргән җырлар белән алмакчы, оныттырмакчы була...

Җидесуга төшим микән,
Төшеп су алыйм микән;
Су алганчы, су төбенә
Төшеп югалыйм микән?

Җидесуга төшәр идем,
Ярлары сөзәк булса;
Кайгысына түзәр идем,
Сагнуга түзеп булса...

Бер бәхетсез урын гел бәхетсез була, диләр бит. Бу юлы да шулай булып чыкты. Сайдә ире Түләк белән аерылышкан чишмә яныннан ерак китә алмады, Рәзил һәм аның әзмәвердәй өч иярчене каршына килеп чыкты. Алар юл буендагы бер аланлыкта кәеф-сафа корып утыралар иде. Сайдәне күргә, телсез, аңсыз калып, тораташ кебек карап каттылар, аннары, корт чаккандай, дәррәү сикереп тордылар. Кайберләре бер-ике адым арткарак та чүгеп куйды әле. Аракы үзенекен итте, исерек бәндәләр, хәмер томанын аралап, бу гайре табигый хәлне күңелләренә якын алып бетерә алмадылар, күзләрен акайтып, Сайдәгә таба килә башладылар.

Сайдә бу минутта нишләргә кирәген белми иде. Шуңа күрә юлын дәвам итте. Ләкин ул, адымын күпме генә кызулатса да, исерекләр төркемен узып китә алмады, тегеләр, яланны кистереп чыгып, аның каршына тезелешеп бастылар.

— Син кем? — дип сорады аягында чак-чак басып торганы.
— Сайдә.
— Сайдә? — Иптәшләрен як-якка этә-төртә, Рәзил алгарак чыкты,— син Сайдәме?
— Сайдә, Рәхилә кызы! Рәзил, танымыйсыңмыни?
— Белмим, белмим… Сайдә юк бит инде… Ул үлде… Суга батты…
Рәзилне хуплап, теге лаякыл исерәге тагы алга чәчрәп чыкты:
— Без бит сине… теге ни… атып үтердек! Өрәктер син, җендер, албастыдыр… Тфү-тфү!..
Рәзил маңгаена берне тондырганчы теге тынмады. Ләкин Рәзилнең күңеленә корт булып керәчәк сүз әйтелгән иде инде.
— Син… чыннан да өрәкме әллә?
— Рәзил, юк нәрсә белән булашма, җибәр мине, кайтыйм, әнием көтәдер…
— Әйт, син Сайдәнең өрәгеме?
— Теләсә нәрсә уйла, җибәр генә. Менә бала табарга торам, рәнҗетмә мине, зинһар… Шушы бала хакына булса да җибәр…
— Сайдә булгач, кайда яттың соң моңа кадәр? — Рәзил тынычланган кебек күренде; Сайдә, алдын-артын уйламыйча, болай да шик-шөбһәгә төшкән исерекләрне сагайтырлык шомлы сүзләр ычкындырды:
— Җир астында.
— Җир астында? — Рәзил, йөзен чытып, баш чайкап куйды.— Алайса син чынлап та өрәк инде. Былтыр көз үлгән Сайдәнең өрәге…
— Әрвах булып чыга бу… — Арттан кемдер болай да дөрләп киткән утка май сипте…
Барыбер соңгы сүзне Рәзил әйтте:
— Юк, җибәрмибез. Без сине хәзер авылдан араларга тиеш. Без сине хәзер…
Аны хуплап кычкырдылар:
— Утта яндырабыз…
— Күкрәгенә усак чөй кагабыз…
— Корсагын ярабыз…
— Җенен чыгарабыз…
— Аңынчы әле кети-кети уйнап алабыз…
Сайдә Рәзилнең мәрхәмәтлелегенә ышана иде әле.
— Шушы якты дөнья хакына, туачак балам хакына тимәгез миңа!.. Рәзил, син бит мине ярата идең, җибәр мине, зинһар, әнием янына җибәр!..
— Әниеңә инде син кирәк түгел. Ул иң элек акылдан язды, акылы кайткач, дингә бирелде. Нәрсәгә аңа тере өрәк? Ул хәзер фәрештәләр белән генә сөйләшеп утыра…
— Сез бит мөселманнар, нигә болай кыланасыз, Рәзил?..
— Юк, без — җен, шайтан, шулаймы, егетләр?
— Ихахайлап көлеп торган Рәзилгә карап, Сайдә барысын да аңлады: бу имансыз, шәфкатьсез бәндәдән мәрхәмәт көтеп булмаячак. Шулай да Мәннән карт бар бит әле. Сабантуйларда авыл җыеннарында иң түрдә утыручы бу карт авыл малайлары өчен Хозыр Ильяс белән бер иде.
— Рәзил, Мәннән бабайдан сора, ул минем ничек югалуымны, ничек табылуымны белә… Рәзил, ышанмасаң, бар, чакырт үзен. Телисеңме, әйдә бергә кайтабыз, сорыйбыз…
— Теге җенле Мәннәннәнме? Без аның бер кирәген биргән идек инде. Хәзер дә күп сорамабыз. Кара син аны, җеннәр белән сөйләшә икән, диләр иде, дөрес икән… Беркөн әйтеп торган була бит әле — янәсе минем исем ошамый аңа, «Рәзил» дигән сүз Коръән телендә «шайтан» дигәнне белдерә, имеш… Исемеңә җисемең туры килгән, дигән була, тере үләксә!..
— Рәзил, син шаштыңмы әллә? Нәрсә булды сиңа, ник тотасың мине?
— Барыбер бер кулга эләгәсең, дигән идем бит… Менә эләктең дә… Үзең эләкмәсәң, рухың эләкте, өрәгең, әрвахың… Ну-ка, егетләр!
Рәзилнең ияге белән Сайдәгә күрсәтеп ым кагуы булды, өч яктан өч ир килеп, авырлы хатынның кулларын каера да башладылар. Аннары, шул кулларыннан, чабуларыннан, чәчләреннән сөйрәп диярлек якындагы имән агачына алып киттеләр; аркасы белән терәп, шул имәнгә бәйләп куйдылар.
— Рәзил, гөнаһ эш эшлисең… Тумаган баланы үтергән кеше явыз рухлар үлеме белән үләчәк, ди… Акылыңа кил, Рәзил!..
Сайдәнең иң соңгы сүзләре шул булды. Алары да бала хакына гына, Ходай Тәгаләдән мәрхәмәт өмет итеп кенә әйтелде.
Ул арада кайсыдыр айный башлады, ахры, әллә, чынлап та, анысының күңеленә Ходай сулышының җиле килеп җиттеме, Сайдә каршында җенләнеп йөрүче Рәзил алдына килеп басты.
— Рәзил, ә бу хатын дөрестән дә чын булса, тере булса? Бәласеннән башаяк, әллә җибәрәбезме?

— Юк, җибәрмибез! Кем булса да, хәзер барыбер инде. Сайдәне үлгән дип беләләр… Так что… Борчылма юк өчен, гөнаһысы үземә булыр, мин барыбер шайтан бит… Ә, егетләр?

Аңа кушылып, калганнар көлде.

Сайдәнең үкереп-үрсәләнеп елыйсы килде. Елый алмады. Аның, хәл-егәре киткән, эче авырта башлаган иде инде.

— Сапый карчыкны чакыртырга кирәк, ул өрәкләрне таный белә…

Рәзил кырт кисте:

— Нәрсәгә безгә ул тиле-миле карчык? Аны гына мин үзем дә беләм: җен-пәриләрнең кендекләре булмый. Аннары… култык асларындагы тишектән бөтен эчләре күренеп тора…

Рәзил, бер ныклы карарга килеп, бөтен гәүдәсе белән алга сыгылып төшкән Сайдә янына килде дә, үзенең егетләрен генә түгел, бөтен аланны, андагы имәннәрне, шомырт куакларын, язгы чәчәкләрне таң калдырып, бичара хатынның күлмәк изүен аерып төшерде.

Сайдә аһылдап, ыңгырашып куйды. Башын күтәргәндәй итте. Аның агарган чыраенда бер генә теләк, үтенеч бар иде: «Тизрәк бетсен бу мәхшәр, Рәзил, озак җәфалама мине, интектермә, зинһар!..»

Бераздан тагын ыңгырашып куйды. Юк, бу юлы ул агач артына каерылып бәйләнгән куллары авыртудан да, сөйрәп китергәндә тартылып, өзгәләнеп беткән чәч төпләре әрнүдән дә түгел, бәлки, сөт төшеп тулыша башлаган күкрәкләре сызлавына түзә алмыйча ыңгыраша иде.

Сайдәнең авырлы килеш тә зифалыгын югалтмаган тәненә ябышкан күлмәгеннән ирекка чыккан сөттәй ак, йомры күкрәкләре һаман әле аракы сөременнән иләс-миләс йөргән егетләрне айнытып җибәргәндәй булды. Алар, өерелеп, Сайдә белән Рәзил торган агач янына җыелдылар. Кемдер, якынрак барып, Сайдәнең изүен, сырма чабуларын киңрәк ачып җибәрде һәм шакшы куллары белән хатынның күкрәк алмаларына барып тотынды…

— Әй син, мавыкма, иң элек кендеген кара… Бармы? — Рәзилнең җикеренеп эндәшүе булды, тегесе кулларын аскарак шуыштырды.

— Бар, кендеге урынында. Тагын астанрак карыргамы?

Теленә салына башлаган егетне бер як читкә этәреп, Рәзил үзе дә Сайдәнең ак, саф тәнен капшап чыкты, тагын бер мәртәбә кендеген карады, култык асларын тикшерде… Аннары башын тотып, җиргә утырды.

— Мин берни дә аңламыйм, аңламыйм, аңламыйм!.. Үлде бит ул, үлде, су төбенә китте! Аңламыйм!.. — Җир төеп, башын як-якка чайкап утырган Рәзил, сикереп торып, Сайдәнең бугазыннан барып тотты. — Җен бит син, өрәк бит, шулаймы? Өрәк бит? Өрәк бит?.. — Шундук егетләренә борылып: — Хәзер үк усак чөй әзерләгез, чыбык-чабык җыеп китерегез! — дип кычкырды.

Бөтенесе дә аңлап алдылар: Рәзил Сайдәне, йөрәгенә усак чөй кагып, утта яндырмакчы була!

Егетләрнең берсе, айныграгы, Рәзилгә каршы килеп булашты:

— Рәзил, кирәкмәс монысы… Теге юлы да милициягә чакыртып тинтерәттеләр. Әйдә, бераз сыйпаштырабыз да… китсен үз юлына.

— Юк! Җен тек җен! Убыр тек убыр! Без юк итмәсәк, хәзер ул үзе безне харап итәчәк!..

— Рәзил, кешеләрдән качып эшләмик без моны… Качып эшләмик… Авыл рөхсәте кирәк. Мокруха бит бу…

— Җитте!.. Җебеп утырма син дә, бар, үзем җавап бирәм дидем бит инде, усёк?

— Усёк… Миңа барыбер… Тик авырлы ул, беләсеңме? Бала хакын кая куясың? Бала гаепле түгел бит, Рәзил…

— Гаепле! Җеннең баласы да җен! Димәк, гаепле! Өрәк өрәкне чакыра, ди, тизрәк эшен бетерергә кирәк, югыйсә, аның зарын ишетеп, тирә-яктагы бөтен алама рухлар җыела башлар. Ягез, тотыгыз!

Сайдәне җиргә егып салдылар, ботын ботка, кулын кулга аерып куйдылар. Алан читендә, йөкле корсагын өскә күпертеп, чалкан төшеп яткан шәрә хатынны күреп, кояш тоныкланды, җил исүдән туктады, чәчәкләр башларын иделәр, язгы кошлар сайраудан яздылар… «Нәрсә бу? Нинди кыямәт? Нинди мәхшәр? Дөнья бетәме әллә? Табигать ияләре, дөнья ияләре ник дәшми? Бу фаҗигане туктатыр өчен күк нигә берни дә кылмый? Карынында бала йөрткән ананы үтергән бәндәләрне ничек җир тота, ничек су тота?» — дип борчылып уйланалар кебек алар…

Тукта, Җидесу аланындагы бу җен туен Табигать күрдеме, ишеттеме әллә? Әллә Күк күрдеме, ишеттеме? Җир, Су ишеттеме? Кинәт су ягыннан, күпереп үсеп утырган гөлҗимеш куаклары ягыннан, кайтаваз кебек кенә, ниндидер сәер авазлар ишетелә башлады: «У-лу-лу-лу-лу!.. У-лу-лу-лулу!..»

Кулына усак казык тотып, Сәйдәнең хәрәкәтсез гәүдәсе өстенә иелгән Рәзил үзен-үзе белештермичә сикереп торды, як-ягына каранды, аннары елга буена текәлеп катып калды. Табигать, аның кан тамырларыннан агып ятучы су үз шаукымы белән бу явыз бәндәне буынсыз итте, аны хәтәр җинаятьтән йолып калырга теләде…

Теге сәер тавыш тагын кабатланды. Тагын, тагын... Кабатланып кына калмады, һаман көчәя барды, якыная барды...

Менә ул тавыш, мәһабәт гәүдәле, шәрә тәнле алып ир кыяфәтенә кереп, яр читендә пәйда булды, аннары, чәчләрендәге су тамчыларын як-якка чәчрәтеп башын чайкады да, күккә карап, тагын бер мәртәбә кычкырып куйды: «У-лу-лу-лу-лу!..»

Бу шәрә тәнле кыргый затның Камышлы халкы телендә йөргән «су җене» булуы шушы язгы, кояшлы көн кебек ачык иде. Әмма, ачык дип кенә, аландагылар баскан урыннарыннан кузгалып китә алмадылар әле. Риваятьләрдәге каһарманнар кебек, судан калыккан Түләкнең кан төшкән, дөньяга чәчрәп чыгардай булып ачылган шардай күзләренә карап ялгыштылар алар. Шул сихри күзләр бу явызларның бөтен егәрлекләрен, аң-зиһеннәрен, хәтта җаннарын суырып алган кебек булды.

Ул арада Түләк, ике-өч сикерүдә, үлән арасында яткан хатыны янына килеп җитте, килгән уңайга ук, аны беләкләренә күтәреп, тегермән юлына кереп юк булды...

Иң элек Рәзилгә җан керде. Ул, кулындагы казык белән суккалап, башкаларны «уята» башлады. Аннары, шул казыгын баш очында болгый-болгый, Түләк белән Сайдә киткән якка йөгерде. Аның артыннан ава-түнә калганнар кузгалды...

...Рәзилнең усак казык белән Җидесу ярына кадап куелган гәүдәсен икенче көнне генә табып алдылар. Калган егетләрнең эзләре аермачык булып елга эченә кереп китә. «Су җене»нең кара эше бу», — дигән карарга килде Камышлы халкы. Моннан соң бу якларга бик якын килмәскә тырыштылар. Юл ялгышып, адашып килеп чыккан адәмнәр генә, су буенда бала җитәкләп йөргән «су җене» белән «су анасын» күреп, тизрәк авылга кайтып китү ягын карыйлар иде. Мәннән карт белән Рәхилә Җидесуга курыкмыйча баралар, шунда көннәр буе югалып йөриләр дә кичкә таба гына авылга кайтып керәләр.

Аларның бу сәер гадәтен авыл кешеләре үзләренчә фараз кылды. Әлбәттә инде, һәрвакыттагыча, начарга юрадылар, алар хакында төрле имеш-мимешләр таратып, мир каршында рисвай иттеләр: әле капкаларына дегет буядылар, әле тәрәзәләренә кара мәче мәете ташлап өркеттеләр.

Кешеләрне шул кимсетте: Мәннән карт белән Рәхиләнең йөзләре тыныч, күңелләре көр иде. Чөнки бу Ходай бәндәләре төгәл белә: тереклек — кешелек кенә түгел әле ул. Кешелек үзе дә авыл дөньясы белән генә чикләнми; дөнья — киң һәм мәрхәмәтле, юмарт һәм бай, бөтен һәм матур ул...

Су кешене тынычландыра, шуңа да: «Сагышың булса, суга сал»,— диләр.

Мәннән карт белән Рәхилә дә бөтен сагышларын суга салдылар, үзләре Ходай Тәгаләгә сыендылар, шуңа күрә алардан да бәхетлерәк кеше юк хәзер Камышлыда. Рәхилә теле белән җырланган җырларда гына ана күңеленең ерак төпкелләрендә яшеренеп яткан тирән сагышка серле ишарә бар кебек:

Җидесуга төшәр идем,  
Ярлары сөзәк булса;  
Кайгысына түзәр идем,  
Сагнуга түзеп булса...

*2005*

## ***ЭТ ЕЛЫ***

*(Бәян)*

**1**

Вахит, подъезддан чыгып барганда, ниндидер кара, йомшак төргәккә абынды. Тыштагы зәһәр суыктан качып, җылыга кергән урам эте булып чыкты ул. Бөгәрләнеп ишек төбендә яткан тере йомгак чыелдап сикереп торды да, бәрелә-сугыла, салкын пар бөркеп торган ярым ачык ишектән җан көченә тышка атылды...

Кәефе юк иде Вахитның. Яңа елны каршы алганнан соң беренче көнне эшкә бару — тән һәм җан газабы гына булмыйча, тәмуг газаплары белән бердер. Мең-миллион мәртәбә сыналган фал бу.

Шундук Вахитның хәтерендә кичәге мәҗлес яңарды. «Син өйләнмәгән, шуңа күрә синдә «хатын синдромы» юк»,— дип, Рәдиф дусты бөтен таныш-белешен аңа җыйган иде. Ике тәүлек буе ишеге ябылып тормады, өстәлдән аракы, закуска өзелмәде, кочактагы кызларның йөз-сурәтләре, альбом битләре ачылып ябылган кебек, туктаусыз алышынып торды... Барысы да бертөрле, бер йөзле... Шулар арасында берсе генә аерылып тора иде. Ул кыз кич буе Рәдифнең кочагында утырды. Нык кына төшереп алган Рәдиф аны күршесендәге егеткә димли башлагач, кискен генә торып, җилләнеп-тузынып чыгып китте. Шуннан соң бүтән күренмәде...

Тагын нәрсәләр булды соң? Рәдифнең тосты хәтерендә калган. «Маймыл елын маймыл кыяфәтендә каршы алырга кушалар, белеп торыгыз! Маймыл булгач, маймыл булсын, маймыл елы өчен!» — дип кычкырган иде ул. «Маймыл тосты»ннан соң чынлап та Вахитка әллә нәрсә булды: дөнья тирәүләре каядыр авыша башлады, аяк астында җир убылып китте, вакыт төшенчәсе үзенең мәгънәсен югалтты...

Уянып, көчкә-көчкә күз кабакларын ачканда, Вахитның тирә-ягында беркем дә калмаган иде инде. Ул, өйдәге тәртипсезлекне күреп, йөзен чытып куйды да, торып, эшкә барырга җыена башлады. Төне буе җырлап, телевизордагы җырчының тавышы беткән, авызын ачкалап, мыскыллап тора кебек анысы да...

Баш төзәтергә бер йотым аракы тапмаган Вахитка, үртәлеп: «Маймыл елы түгел, эт елы булды бу!» — дип, бөтен зәһәрен чыгарып сүгенәсе генә калды...

Урамда кеше күп түгел. Әллә суыктан, әллә кичәге авыр тәэсирдән качарга тырышып, башларын якалары эченә яшергән шәүләләргә карап, Вахитның көләсе килде. Ләкин көлмәде, хәтта елмаймады да. Үзенең дә шундый кыяфәттә булуын уйлап, йөзен тагын да эчкәрәк яшерде...

Урам аша чыгып, якындагы паркка барып кергәч, Вахитның күңелендә үткән бәйрәм тойгысы кабат яңарды. Телисеңме–теләмисеңме, күзгә бәреп кереп тора бу тойгы. Кая карама шартлаткыч калдыклары, ылыс ботаклары, ялтыравык кәгазьләре белән күзләрне камаштырып ятучы шешәләр... Вахит, аларга игътибар итмәскә тырышып, кистереп кенә паркның аргы ягына ашыкты. Кистереп дигәч тә, үзләре генә белгән ис һәм хис буенча йөрүче этләр сукмагына кереп китте ул.

Юкка керде. Вахит моны ун адымлап ара үткәч кенә аңлады. Белә иде бит ул урманда — бүре, урамда эт сукмагына керергә ярамаганлыгын!

Вахитның күңеленә килеп кергән шом артыннан ук курку пәйда булды, курку исә этләрнең үзләрен чакырып китерде.

Сукмакның ике як очында пәйда булып, үз биләмәләренә сораусыз кергән адәм затына ярсып өрә-өрә, томырылып чабып килүче бу бозау кадәрле этләрдән котылып, исән калып булмавы көн кебек ачык иде. Вахитның аң-зиһене томаланып китте, ләкин аңа кадәр: «Этләрдән таланып, шушында җан тәслим кылырмын микәнни?» — дип уйлап өлгерде әле ул.

Аң-зиһене артыннан ук йөрәге тибүдән туктады, йөрәгеннән соң аяк буыннары көч-егәрлеген югалтты. Вахит, бу ике зәһәр ерткычка каршы тора алмаячагын сизенеп, терсәкләре белән йөзен каплады да эт йоннары белән укмашып каткан сукмак карына сузылып ятты...

Ис-акылыннан язса да, йөрәге тибүдән туктаса да, Вахит үзе белән булачак фаҗигане күз алдына китерерлек хәлдә иде. Менә этләрнең берсе, алданрак килеп җиткәне, аның җилкәсенә тешләрен батырачак, як-якка тарткалый башлаячак. Икенчесе ботларына, җан җиренә ябышачак...

«Их, өйләнеп, башлы-күзле булырга өлгермәдең, ичмасам,— дип, үзен-үзе битәрләде Вахит.— Кешечә яши дә алмадың. Авылда әнкәң ялгызы калды. Кайтып, хәлен дә белмәдең. «Яңа елга кайта алмассыңмы, балам, газга түләргә чыгарлык та хәлем юк», — дип язган иде бит ул соңгы хатында... Күзгә генә зыян килмәсен. Җан тамыры гына шартлап өзелмәсен. Бугазга да якын җибәрергә ярамый. Калганы төзәлер... Хотя... Җәл... Пальто яңа иде; икенчесен алу өчен тагын ярты ел ипи белән суда утырырга туры киләчәк...

Нишләп бер җире дә авыртмый соң әле аның? Нишләп беркем дә йолкымый, тешләми? Әллә?.. Әллә бер тешләүдә өзделәрме аның бугазын, җанын? Әһ тә итми, ахирәткә үк китеп бардымы? Көт тә тор! Ахирәтне әзерләп куйганнар ди сиңа? Кичә генә өч-дүрт кыз белән түшәк уртаклаш та... Алар үзләре теләп кергәннәр бит дип кенә акланып булмый анда... Үз башың, үз күтең кайда? Кешенекен тикшергән буласың... Аннары... ишек төбендәге мескен этне тибеп очырдың... Әллә ул рәнҗемәгән, каргамаган дисеңме? Бәлки әле, бу әзмәвердәй этләр шул кечкенә җан иясенең каргышы булып чабып килгәннәрдер?»

Вахитның җаны урыныннан купкан, ә ул үзе барысына, хәтта үлемгә дә әзерләнеп беткән иде. Вакыт туктаган урында мәңгелек башлана, диләр бит. Вахит өчен вакыт туктады. Ләкин үлем килмәде дә килмәде. Вахит инде өч мәртәбә үлеп терелде, дөньяның һәр аһәңен Әҗәл тавышына охшатып, тетрәнеп ятты. Үлем генә түгел, этләр үзләре дә юкка чыктылар. Тирә-якны үлем тынлыгы басты... Тынлыгы бар, үлеме генә юк...

Вахит тагын бераз капланып түзеп ятты да, терсәкләрен, учларын бушатып, дөньяга колакларын ачты.

Исән... Галәм тавышларын ишетә икән, димәк исән... Кайдадыр кар шыгырдый, кайдадыр кош очып үтте, куак ботаклары шыбырдашты... Якын-тирәдә этләрнең барлыгы-юклыгы да сизелми. Тукта, нәрсә бу? Дөнья тавышларына охшамаган авазлар ишетә түгелме? Кайтаваз кебек кенә, бакча һавасында ниндидер ягымлы, серле тавышлар тибрәнеп тора...

— Мин сине югалттым... Мин сине сагындым...

— Мин дә югалттым... Мин дә сагындым...

— Син кайда йөрдең соң?

— Шәһәрнең аргы башына барган идем, ошамады, безнең бакча әйбәтрәк…

— Моннан соң бервакытта да алай эшләмә, яме, ташлама мине… Кичә төнлә куркып үлә яздым. Таңга кадәр шарт та шорт атып чыктылар. Төтен исенә буылып үлә яздым, җитмәсә, шешә атып, янбашымны авырттырдылар…

— Әйдә бүтән бер дә аерылышмыйбыз…

— Әйдә…

Вахитка кызык булып китте. Шундук башын калкытты. Гаҗәеп хәл: тирә-якта беркем дә юк иде. Урамга барып тоташа торган сукмак башында гына ике эт бер-берсен иснәшеп, назлашып уйныйлар. Койрыкларын тырпайтып, алгы аякларын күтәреп, карда ава-түнә уйнап йөргән бу этләрне Вахит шундук танып алды. Менә нәрсәдә икән хикмәт — алар бит бер-берсен сагынышып шулай томырылып чапканнар. Туктале, алайса кем сөйләшә соң монда?

Вахит сикереп торып утырганын сизми дә калды, шул утырган килеш, тагын бер мәртәбә бакчаны сөзеп карап чыкты. Аннары, башын як-якка чайкап, шушы берничә минут эчендә башына ишелеп төшкән авыр шаукымнан котылырга теләде… Котыла алмады. Баягы сәер тавышлар аның зиһенен һаман иләсләндереп тора иде.

— Әйдә минем белән, кичә мин тәмле калҗа таптым; синең өчен яшереп куйдым.

— Рәхмәт… Минем инде ике көн тамагыма бер сынык сөяк капканым юк…

— Кешеләр — чыршыга гыйбадәт кылып, олы туй үткәрүчеләр бит, сиңа бәйрәм өстәленнән берни дә эләкмәдемени?

— Юк шул. Мин йөргән урамда кешеләр өелеп сугыштылар. Чыршы туе түгел, кан туе булды анда. Шуңа да кире кайттым…

Шул исәнгерәгән килеш эшенә барып җиткән Вахитны кәкре-бөкре хәрефләр белән язылган белдерү көтә иде. Анда бәйрәмнәргә тагын ике көн өстәлүе, дөресрәге, бу көннәрнең ял көннәренә күчүе хакында хәбәр ителгән иде.

Вахит сүгенә-сүгенә кире кайтып китте. Ләкин бу юлы бакчаны урап узарга, ул шаукымлы җирдән ераграк йөрергә булды. Яшәгән йорты ике-өч урам аша гына булса да, аякларын көчкә сөйрәп, автобус тукталышына килеп басты.

Сәер көн бүген — урамда беркем дә юк. Дөресрәге, кеше заты юк. Ниндидер хәрәкәткә күзе ияреп китсә, карашлары шундук урамда иснәнеп йөрүче этләргә барып төртелә. «Карале, Яңа елдан соң урамнарга иң элек этләр чыга икән… Иртәннән башлап этләр белән үтте гомере… Нәрсә инде бу? Чынлап та, «этләр елы»на берәр ишарәме әллә? Быел да юньле тормыш булмас микәнни?..»

Вахит, чабу астыннан суык үтеп керә башлавын сизенеп, сикергәләргә, кулларын болгарга кереште. Үзе ара-тирә, башын якасыннан чыгармыйча гына бер якка янтаеп, күккә карап ала. Ә бит көн кояшлы! Яз кояшы түгел түгелен. Әмма кояш бар. Аяз яктысы, хәтта күзләрне чагылдырырлык нурлары бар. «Эт кояшы» диләр андый кояшны халыкта. Тфү! Теленә тагын этләр килеп керде, нинди галәмәт инде бу!

— Юкка көтәсең, әле яңарак кына китте.

— Шулаймы? — Вахит, тавыш иясенә җавап бирү өчен артына борылды. Нәрсә бу? Тукталышта бүтән бер кеше мазар да күренмәде. Колагына гына ишетеләме? Бәйрәм махмыры күңелне буташтырамы? Шулайдыр… Яңа ел мәҗлесләренең исерек томаны чыгып бетмәгән, күрәсең…

— Кайта торсаң да була, шактый көтәргә туры киләчәк.

Шул ук тавыш. Тавыш бар, кешесе юк. Акылга җиңеләюнең башы шушыдыр инде…

Вахит ары бәрелде, бире сугылды, тукталыш будкасын җентекләп карап чыкты, әмма эскәмия астында посып утырган йөнтәс, кара эттән башка беркемне дә күрмәде.

— Син сөйләшмисеңдер бит?

— Мин сөйләшәм…

Вахит артына егылып китә язды. Әллә суыктан, әллә куркудан калтыранып утырган шушы кечкенә урам эте кеше теле белән сөйләшсен әле! Үзе, кыенсынган кебек, башын аска игән дә, күз каралары гына өскә тәгәрәтеп, адәм карашлары белән карап тора!

Изгелеккә дәлил кирәкми. Әллә бер илаһи ым, ишарәме бу? Изге ишарә… Ходай үз ихтыярын балалар аша, хәтта җәнлекләр аша белдерә, ди бит… Юктыр, бер дә изге фалга охшамаган бу җан иясе. Үзе котсыз, үзе… кара! Ә менә шайтан коткысы булырга мөмкин…

Тәмам акылдан язганчы, Вахит сөйләшүне кулайрак күрде. Сөйләшү, аңлашу аша гына күңелне исән-имин саклап калып булачак. Ул моңа төшенеп өлгергән иде инде.

— Син кем?

— Кем булсын, эт…

Карале, бу чынлап та сөйләшә бит! Тик… кешеләр кебек авызын ачып сөйләшми, күңеле, җан-рухы белән генә сөйләшә, аралаша… Әллә?.. Күңеле белән генә түгел, күз карашлары белән сөйләшә-

ме? Авылда әйтәләр иде бит: рухлар авыз ачып сөйләшмиләр, күзләре белән генә сөйләшәләр, диләр иде. Рухларның кара этләр кыяфәтенә кереп йөргәнен дә белә Вахит, бик белә…

— Эт икәнеңне күреп торам. Каян килдең, дим?

— Без таныш инде. Иртән очрашкан идек, хәтерлисеңме?

— Хәтерлим… Син идеңмени ул?.. Кичер, брат, кәеф юк чак иде. Аннары… мин сине күрмәдем бит… Кичә ныграк бәйрәм ителгән…

— Мин сиңа ачуланмыйм…

— Ачулансаң да була… Матур килеп чыкмады…. — Вахитка иртәнге хәлләр өчен бик кыен иде. Ул гомерендә беренче мәртәбә үзеннән-үзе оялып куйды…

— Аңлыйм мин сине. Син бит кеше, ә мин — эт кенә…

— Шулай да син кем? Эт кенә түгел, монысы хак. Безнең телне каян беләсең? Хикмәт кемдә — синдәме, миндәме?

— Серме? Үзеңдә… Ул серне син үзең төшенергә тиеш. Бүтән берни дә әйтә алмыйм.

— Ну бит син сөйләшәсең!

— Юк, син ишетәсең!

— Мин берни дә аңламыйм.

— Нәрсәсен аңламыйсың инде? Әйттем бит: хикмәт үзеңдә, этләрне ишетә, аңлый белүеңдә…

— Сез дә кешеләр кебек уйлыйсызмыни?

— Һәр тереклек иясендә уй бар.

— Димәк, аң бар. Зиһен бар.

— Аң бар, әйе, Тик сез моны танырга теләмисез.

— Ну бит… Павлов нәрсә ди…

— Әйе, рефлекс, ди… Терекленең асылын рефлекска сылтап аңлатасыз… Ә Дөнья белән идарә итүче, аны оештырып, тәртипкә салып торучы Аңны кая куясың? Дөньяның үз җанвары бар, беләсең килсә…

— Ә? Үз җанвары?

— Әйе. Бөтен тереклек шул җанвардан туган. Кешеләр дә…

— Кешеләр дә?

— Әгәр алай булмаса, сез җанварларга табынып яшәмәс идегез. Алар белән ант итмәс идегез…

— Син безнең ак барсны әйтәсеңме?

— Ак барсны да әйтәм.

— Ул бит эт түгел!

— Эт. Ул да эт. Борынгы төркиләр аңа кыргый эт буларак табынганнар. Фарсыларда аны әле дә кыргый эт дип йөртәләр. Алар хәтта үз исемнәрен дә шушы барстан алганнар…

— Алайса, Аллаһы Тәгаләне кая куясың? Дөнья җанвары белән ничек килешә ул?

— Алла — биектә, аң һәм зиһен җитмәслек урында. Ә Дөнья җанвары безнең янда. Ул Аллаһының эте кебек. Аллаһы нәрсә кушса — шуны эшли.

— Димәк, ул — Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры?

— Әйе. Ихтыяры, куллары, күзләре…

— Син боларның барысын да каян беләсең? Син бит эт кенә, урам эте…

Вахит үзенең тагын кешелегенә кайтырга, кешеләргә хас булганча, тәкәбберләнә баруына төшенеп, кинәт туктап калды. Этнең күзләренә тутырып, хәтта үтенеп, ялварып карады.

— Гафу… теләп әйтмәдем…

Ә эт аның тәкәбберлегенә игътибар да итмәгән булып чыкты.

— Каянмы? И сез, кешеләр… Күңелегез тар сезнең, карашыгыз тар. Дөньягыз тар. Тар булмаса, уйлап карар идегез: җир йөзендәге бөтен тереклек сездән алдарак барлыкка килгән. Димәк, ул сезгә караганда күбрәк күргән…

— Акыллырак димәкче буласыңмы?

— Акыллырак та. Ә син… урам эте, дисең…

— Әйттем бит инде, гафу, дидем. Тагын бер тапкыр гафу… Бөтен кешеләр өчен, кешелек өчен гафу…

— Ярый, гафу иттем дип уйла…

— Рәхмәт…

Вахит, ниндидер шау-шу ишетеп, айнып киткәндәй булды, тирә-ягына күз салды. Автобус килергә вакыт җиткәндер — тукталышка шактый кеше җыелып өлгергән. Урам эте белән сөйләшеп торучы ир кеше бик сәер тоелгандыр шул — тукталышның Вахит басып торган өлеше бөтенләй буш иде.

— Синең торыр урының юкмы?

— Минем өем — урам.

— Әйдә минем белән яшә.

— Юк, син минем белән аралашырга әзер түгел әле.

— Гафу үтендем бит инде. Тагын ни кирәк?!

— Әйттем бит, әзер түгел дип... Вакыты җиткәч сөйләшербез... Ә хәзер бар, үз юлыңда бул, автобусың килә...

Вахит өенә чак-чак кайтып егылды, бер тәүлеккә якын баш калкытмыйча йоклады.

Торып, өен җыештырырга кереште. Кичә булган хәлләр белән бәйле уйлары зиһен капкачын төртеп торса да, Вахит бирешмәде, вак-төяк уйларын күңеленә якын алмыйча гына, фатирын тәртипкә китерде, аннары, уттан качкандай кабаланып, Рәдиф янына чыгып китте. Аңа Яңа ел бәйрәменнән соң күргән, кичергән сәер хәлләр хакында берсен дә калдырмыйча, бөртекләп сөйләп бирде.

Тегесе аптырамады.

— Ныграк җибәргәнсең, малай. Маймыл елы дигәч тә... Чистый эт булганчы эчкәнбез түлке... Этләр белән сөйләшеп йөрүең дә шуннан гына...— дип, уен сүз белән җавап кайтарды.

**2**

Яңа ел бәйрәменә өстәлгән ике көн бик тиз үтеп китте. Вахит та элеккеге тормышының эзенә бик тиз төште. Телефоннан дуслары белән сөйләшеп чыкты.

Бәйрәм алдыннан гына үпкәләшкән Зөлфиясе сүз озайтып тормады, турысын әйтте дә салды:

— Мин Яңа елны икенче кеше белән каршыладым,— диде.

— Мин дә...— дип, чак-чак әйтеп өлгерде Вахит.

Шуның белән ике яшь йөрәк арасында төенләнә башлаган язмыш җебе өзелде. Арада олы мәхәббәт булмагач, аерылышу да йөрәккә әллә ни авырлык китерми икән. Кыен, әлбәттә. Әмма чарасызлык, бәхетсезлек үзе юк, аның тойгысы гына бар...

Эшкә чыгып китәр алдыннан Вахит озак кына көзгегә карап торды. Кыл кебек кара чәчләр, күксел-зәңгәр күзләр, озынча яңаклар һәм киң, итләч борын — боларның барысы да үзенеке түгел кебек... Шулчак: «Үткән тормышымда әллә чынлап та эт булдым микән? — дигән уй сызып үтте Вахитның Яңа елдан соң тернәкләнә башлаган зиһенен. — Кешенең җаны үлми, бары тик бүтән тереклек ияләренә генә күчә, ди бит...»

Тагын теге сәер, хәтта күңелләрне өшетерлек шомлы хәлләр исенә килеп төште. Иң мөһиме, боларның төш кенә булмаганлыгын төгәл белә Вахит. Димәк, белая горячка. Алай дисәң, бакчадагы этләрне күргәнче берни дә юк иде. Сукмак буенда коты ботына төшеп, үләргә җыенып ятканда, әллә нәрсә булды аңа...

Вахит, тагын нindидер шаукымга бирелә башлавын сизенеп, тизрәк чыгып китәргә ашыкты. Бу юлы ул подъезд төбеннән сакланып, каранып үтте. Тагын теге кара эт килеп чыгып, аяк астында буталып калмасын... Юк, таныш эт күренмәде. Вахитка бераз ямансу булып китте. Күңелендә яралып килүче яңа хис-тойгылардан ул хәтта сискәнеп куйды. Аның бу серле, серле генә түгел, сихерле кара этне бик тә, бик тә күрәсе килә иде!

Бүген урамда кеше күп. Вахитның юлы күрше подъездда торучы малай белән янәшә туры килде. Гадел исемле бу малай, әнисенә ияреп, мәктәпкә барырга чыккан. Үзе чаклы сумкасы шулкадәр авыр, күрәсең, ул алга табан түгел, артка табан бөкрәеп бара... Ләкин һич зарланмый, үзалдына нидер сөйләнеп, көйләп бара-бара да кинәт туктап уйланып тора, аннары тагын әнисе артыннан йөгерә.

Вахит тукталыш ягына борылды, Гаделләр исә, башкаларга кушылып, мәктәпкә кереп киттеләр. Әмма ерак китә алмады Вахит, зәһәр тиргәш, каргыш тавышлары ишетеп, артына борылып карады.

— Эттән туган нәрсә! Нишләдең син? Кичә генә юып кидерттем бит! Күрсәтермен мин сиңа күрмәгәнеңне, кайт кына әле, эт җан!..

Мәктәп юлында тау кадәр портфеле-ние белән сузылып яткан малаен торгызып булашучы хатын Вахитның күзенә иң усал, иң явыз җен-пәриләрнең берсе булып күренде. Үз-үзенә аптырап бетә алмады: мондый әйберләргә һич игътибар итми иде ләса, нишләп күңеле шулкадәр нечкәреп китте соң әле аның?..

Тукталышта кеше күп. Йөзләрдә бәйрәм чалымнары калмаган, һәркем җитди, хәтта борчулы, гамьле. Вахит, үз күңелендәге тойгыдан котыла алмыйча, җаен табып, тукталыш будкасын урап-әйләнеп чыкты. Кем белә, бәлки, аның таныш эте шушы тирәдә йөридер?..

Юк, күренмәде... Нишләп күренмәсен, әнә бит ул җылылык трассасы буендагы тимер капкач өстендә йомарланып ята, башын алгы аяклары өстенә куйган килеш, күзләрен йөгертеп, Вахитны күзәтә...

Бу юлы беренче булып Вахит үзе эндәште. Чөнки ул белә: бәйрәмнән соң булган ялгышулар, саташулар күптән инде үтеп киттеләр, кешеләр — үз урыннарын, этләр үз урыннарын алып, элеккечә

яши башладылар. Табигатьнең кануннары, Ходай Тәгаләнең язганнары шундый. Беркем дә үпкәләргә тиеш түгел…

— Сәлам, дускай… Син ачтыр инде, ә? Менә сиңа бераз ипи, колбаса калдырам. Кич кайтканда тагын карарбыз…

Вахит, сумкасын ачып, көндезге чәйгә дип салынган икмәк, колбаса, сыр телемнәрен алып, эт яткан җылымса таба читенә куйды. Бүтән сөйләшеп торырга вакыты юк иде, ул үзен-үзе белештермичә, куктән төшкән кебек кенә килеп туктаган автобуска табан укталды.

— Рәхмәт…

Стартта алгарак омтылып, үрә катып торучы спортчылар кебек йөгерергә әзерләнгән хәлендә тораташ кебек катып калган Вахит бу мәлдә бер шашып көләрлек, бер акырып еларлык хәлдә иде.

«Нәрсә-ә-ә? Тагын сөйләшә бит бу эт кисәге? Рәхмәт әйтә… Тилерүем чын булды микәнни?..»

Вахит, кырт борылып, кабат эт янына килде.

— Әле генә син дәштеңме? Син рәхмәт әйттеңме?

— Мин…

— Бәй, син һаман сөйләшәсеңмени?

— Автобусың китә.

— Китсен лә! Җәһәннәмгә олакмыймы шунда!

— Каргышлы сүз сөйләмә! Үзеңә кире кайтыр…

— Туктале, син каян шундый акыллы соң әле, каян шулай сөйләшәсең? Син кем? Ник мине саташтырасың? Ник юлыма чыгасың?

— Мин сине чакырмадым. Кызгансаң, ризыгыңны кире ал…

Эт башын икенче якка борып ятты, күзләрен йомды. Вахитка кинәт әллә нәрсә булды. Шул күзләр белән бергә, әле ачыла гына башлаган олы, серле, хәтта изге бер дөнья ябылган, йомылган кебек тоелды. Һәм ул, үзен-үзе белештермичә, этнең каршына ук килеп тезләнде.

— Йә инде, ачуланма. Мине дә аңла. Мин бит кеше. Кеше! Табигатьнең иң акыллы заты! Һәм менә син… Бу минем акылыма сыешалмый, күңелемне тиле-миле итә…

— Сезнең, кешеләрнең, зиһен офыклары да, күңел дөньялары да томаланып беткән; сез табигать тоемыннан мәхрүм калгансыз, шуңа шулай ул…

Этнең күзләре генә сөйләшә иде. Бу күпмедер тынычландыра. Чөнки күңел тоемы, күңел бәйләнышлары — илаһи, изге нәрсә; ул адәм балаларына нинди генә халәттә дә акылларын җуярга ирек бирми…

…Кичке якта алар кайтыр юл чатындагы таныш тукталышта тагын очраштылар. Бу юлы җәяү генә кайттылар. Вахит хәзер ул чаклы шикләнми, адәми затлар белән аралашкан кебек, тыныч кына сөйләшеп бара.

— Син нинди җан иясе? Каян килдең? Кайсы дөньядан?

— Шәһәр читендәге авылдан мин. Минем дә хуҗам бар иде. Урамдаш этләрем бар иде. Балаларым бар иде…

— Балаларың? Син әни этмени? Кайда соң алар?

— Хуҗам аларны, күзләре ачылмаган килеш, дуңгызларга ашатты… Шуңа киттем дә инде мин аңардан…

— Кызганыч… Хәзер хуҗаң юкмы?

— Урам минем хуҗам. Алырга теләүчеләр бар иде. Мин бит начар эт түгел, кешеләр моны сизәләр… Үзем иярмәдем. Сезгә этләрне рәнҗетү берни тормый. Ышанып бетмим мин адәм балаларына… Элекке хуҗам да әйбәт кеше иде, әнә ничек килеп чыкты…

— Аңлыйм мин сине… Мин үзем дә кайчакта кешеләрне күрә алмаслык хәлгә киләм. Хәтта үзүземне күрә алмаган чаклар да була…

Ниһаять, Вахит күптән күңелен борчып-бимазалап торган сорауны бирергә булды. Чөнки бу этнең изге бер фал, Ходай Тәгалә ишарәсе булуына тәмам ышанып җиткән иде ул.

— Ә нигә мин сине ишетәм? Шуны әйтә аласыңмы? Бу бит юкка түгел, шулаймы?

— Юкка түгел. Әмма баш җитмәслек хәл дә түгел бу. Табигатьнең саф, ихлас, вакытында бөтен тереклек, җан ияләре дә үзара аралашып, бер-берсенә ияләшеп, ярдәм итешеп яшәгәннәр. Ул вакытта «тереклек теле» дигән тел булган. Тора-бара бу тел онытыла башлаган, табигать ияләре арасында дошманлык арткан, ә кеше үзен бөтен тереклектән, бөтен җанварлардан өстен куя башлаган… Ә бит җанвар сүзе үк, «җан бар» дип искәртеп тора; кеше шул хакта уйланырга да вакыт таба алмый хәтта… Менә сиңа шул тел кайтты. Күп дәверләрдән соң кайтты… Бу —табигать бүләге, илаһи затлар бүләге. Шул ук вакытта искәртү, сынау да. Мин шулай аңлыйм…

— Ни өчен — сынау?

— Бу тел җан очып чыгам, очып чыгам дип торганда гына кайта ала. Димәк, син шушы чиктән үтә язып калгансың…

— Аңлашылды... Димәк, бакчадагы теге этләр дә сөйләшеп уйнап йөргәннәр, ә мин аларны ишеткәнмен? Алайса... мин сине генә түгел, бөтен этләрне дә ишетә алам?

— Этләрне генә түгел, бөтен тереклек дөньясы сиңа ачык.

— Алай булгач, мин ник моңа кадәр синнән башка беркемне дә ишетмәдем соң?

— Ишетергә теләмәгәнгә ишетмәгәнсең, теләсәң — ишетер идең...

Вахит зиһен борылмаларына килеп өелгән уйлардан тагын кызыша башлады, уй чоңгылларының тагын да тирәнрәгенә таеп төшеп китмәс өчен, ул гадәти тормышка кайтырга булды...

— Әйдә минем белән яшә. Мин дә ялгыз, син дә... Тамагың тук, яткан урының йомшак, җылы булыр...

— Юк, без бергә яши алмаячакбыз.

— Нигә? Ни өчен?

— Без бергә яшәсәк, син акылдан шашачаксың.

— Нигә алай дисең?

— Син тереклек гаменә, дөнья фәлсәфәсенә әзер түгел. Беркөнне килеп, зиһенең дә, күңелең дә дөнья авырлыгын кабул итүдән баш тартачак. Һәм син акылыңнан язачаксың...

Алар шулай аерылыштылар, бергә яшәмәсәләр дә, көн саен диярлек очрашып, сүз алышып, аралашып йөрделәр. Бөтен нәрсәгә дә бер күнегәсең икән. Бер нәрсәгә генә күнегеп бетә алмады Вахит: бу таныш этнең күзләрендә адәм карашлары бар кебек. Шул карашлар аның күңелен шомландырып, өшетеп торалар, ә уй-ниятләренә, хыялларына моңарчы таныш булмаган мәгънәләр бирәләр иде.

**3**

Вахитның тормышы тагын көйләнеп китте. Фәнни-тикшеренү институтында эш авыр түгел. Вакытында барып, вакытында кайтып китсәң, шул җитә. Статистика фәненә мохтаҗлык күбәйгән саен, Вахитларга да заказлар ешрак килә. Читтән дә эш эләгә. Анысы өстәмә табыш дигән сүз. Вахит үз эшендә иң алдынгылардан санала, шуңа күрә аны бик еш студентлар, укучылар алдында, хәтта гади халык каршында чыгыш ясарга чакыралар. Бөтенесе дә Рәдиф аша эшләнә. Рәдиф эш урыны таба, Вахит лекцияләр укып кайта, акчасын урталай бүләләр. Заманча һәм кулай, иң мөһиме, икесенә дә файдага...

Туры килүен әйт: беркөнне Вахитны «Эт асраучылар җәмгыяте»нә лекция укырга чакырдылар.

Рәдиф:

— Малай, мин сиңа төшемле эш таптым, әйдә, ике сәгать чатнатып укып кайт та айлык эш хакыңны кесәңә салып куй! Әзерләнергә бер тәүлек! — дип килеп әйткәч, Вахит керфек тә какмыйча риза булды; бер көн, бер төн этләр хакындагы саннар белән танышып утырды. Бигрәк тә бер нәрсәгә исе-акылы китте аның. Тикшеренүләргә караганда, җир йөзендә бер кешегә бер эт туры килә икән! Күп тә түгел, аз да түгел: һәр кешегә бер эт. Һәр эткә бер кеше. Сәер бу... Дөрес, әмма сәер... Әллә?.. Кешеләрнең җаны этләр булып яши микән? Бу кадәр тәңгәл килмәсләр иде... Шулайдыр...

Вахит инде үзенең этен тапты. Һәр кеше үзенең этен тапсын иде дә... Дөньяда гуманлылык мәсьәләсе шундук хәл ителер иде. Кешеләр янәшәсендә, аларның җан дусты, намусы булып, тугрылыкка ишарә булып, бәлки... гыйбрәт булып яшәсеннәр иде бу тереклек ияләре. Ә бит элеккеге йолалар шулкадәр акыллы булганнар, безгә аларга кадәр ай-һай ерак әле... Әле кайчан гына бәхете ишелеп килгән кешегә: «Бүресе улый» яисә... «Эте улый», — дигәннәр. Эт улаганда сәфәргә чыккан кешенең юлын әйбәткә юраганнар... Ә хәзер ничек? «Этләнеп яшибез», — дип зарланабыз. «Эттән туган!» — дип сүгәбез. «Ак эт бәласе кара эткә», — дигән фәлсәфә белән үз-үзебезне тынычландырабыз...

Вахит, һичшиксез, боларның барысы хакында да үзенең тыңлаучыларына сөйләячәк.

Гыйбрәтле саннар, җанга төшә торган фактлар күп икән... Һәр туган көчекнең икенчесе үлә, әйеәйе, тууына ук үлә; кеше асрамасындагы һәр ике этнең берсе югала яисә куып чыгарыла; һәр өч этнең икесе үз үлеме белән үлми; җәй көннәрендә дачаларда кулга ияләштерелгән ун этнең тугызы урман, юл, елга буйларында ташлап калдырыла...

Дүрт тал агач төбендә
Кәкре кое сиртмәсе,—

дип, табышмаклар әйткән халык кая киткән соң? Асрау этләр күбәя барган саен, аларның кадерләре азайган заманда яшибез икән бит...

«Эт асраучылар җәмгыяте»нә барганчы, Вахит этен Җанбар дип, Җанвар түгел, нәкъ менә Җанбар дип йөртә башлаган иде. Алар инде күптән бергә, иртән дә, кич тә очрашып торалар,үзара сөйләшеп, гәпләшеп йөриләр. Урамда көн күрсә дә, Җанвар Вахитта еш кунак була, озаграк күрешми торса, Вахит аны каян эзләргә икәнен белә...

Ләкин бу юлы тиз генә таба алмады ул үзенең дустын. Юлда очраган этләрдән дә сорап карады.

— Юк, күрмәдек. Ул хәзер Акколак белән йөри, — диделәр.

Хәзер шул гадәтенә керде: берәр эт, мәче яисә кош-мазар күрсә, Вахит сөйләшеп калырга тырыша. Беренчедән, бу кызык. Моңа кадәр беркем кагылмаган табигать серенә, яшәеш серенә кагыла ала бит ул. Ул бит, бөтен кешелектән бер вәкил булып, киек җаннар белән сөйләшә ала! Һичшиксез, бу иҗади миссияне әйбәт итеп, җиренә җиткереп үтәп чыгарга тырышачак ул.

Әнә миләш куагында бер песнәк утыра. Нигә сөйләшеп карамаска?

— Исәнме, песнәк?

— Исәнме… — Кошның чырылдык тавышында борчу бар иде.

— Нигә борчылдың? Ни булды?

— Борчылырсың да, ике айдан урманга бала чыгарырга китәбез, ә минем парымны суык бәрде.

— Икенче бер песнәк юкмыни?

— Без елга бер генә парлашабыз шул.

— Аңлыйм. Шундый ук, парын югалткан берәр кош очрар әле, борчылма.

— Рәхмәт, адәм баласы, әйбәт сүзеңә рәхмәт.

— Ә ни өчен урманга китәсез? Калыгыз. Сез бит кыш буе кешеләр янында яшисез.

— Әйе, без март аенда урманга бала чыгарырга китәбез. Салкын көздә генә кайтабыз. Без бит элек-электән урманда яшәгәнбез. Аннары кешеләр янына ияләшкәнбез. Хәзер, электәгечә, безне урман ныграк тарта. Кешеләрдә игелек, миһербанлылык азайды. Күп песнәкләр кышка да урманда калалар хәзер.

…Ә менә бу мәче шат. Подъезд төбенә чыгып утырган да һәр үткән кешегә елмаеп, аны сәламләп кала. Кешеләр ишетми, ә Вахит ишетә!

— Минем хуҗам бар, беләсезме, хуҗам бар!

— Ник ул кадәр шатланасың, элек юк идемени!

— Элек мин идән астында, балчык базда яшәдем. Хәзер минем өем — җылы фатир.

— Котлыйм, дускай. Ә син бу тирәдә чем-кара эт белән ак колаклы этнең парлашып киткәнен күрмәдеңме?

— Күрдем. Алар бик бәхетле иделәр. Ә-ә-әнә теге өйләр артында булырга тиешләр.

— Рәхмәт, моннан соң хуҗаңны югалтма, фатирыңны да ташлама, яме…

…Эт кояшында иркәләнеп утыручы ул ике этне Вахит шундук күреп алды. «Эт кояшы» дидеме? Үзе кояшлы, аяз, үзе салкын көнне кешеләр шулай диләр. Нигә икән? Дөреслек бармы монда?

Бер кояшка, бер этләргә карый Вахит. Алар разый, алар бәхетле! Димәк, «эт кояшы» дигән сүз дөрес!

Җанбар шундук Вахит янына йөгереп килде, Акколак, горурлыгын саклап, озын, ак колакларын кояшка тырпайтып, урынында калды.

— Сәлам, дускай!

— Исәнме… Каян килеп чыктың монда, син бит бу якларда йөрмисең?

— Сине эзләп килдем.

— Мине? Ә нигә?

— Болай гына, күрәсем килде. Сине бәхетле диделәр, дөресме?

— Дөрес, язга минем балаларым булачак. Алар Акколакка охшаячак.

— Матур булачаклар икән. Дускай, әйдә болай итәбез, син балаларыңны миндә тап, алар аякка басканчы, кеше булганчы миндә яшә, ә?

— Рәхмәт. Тик бу миннән генә тормый. Акколак нәрсә әйтә бит әле. Шулай да, нигә эзләдең мине?

— Болай гына… Болай гына эзләргә ярамыймыни? Сагынырга, юксынырга ярамыймы?

— Миңа моны аңлау кыен. Барыбер рәхмәт.

— Әле безгә бик күп нәрсәне аңлау кыен булачак, бик күп нәрсәгә өр-яңадан өйрәнергә туры киләчәк, Җанбар дус…

…Вахитның лекциясе уңыш казанды. Бигрәк тә бер сорау зур кызыксыну уятты. Ике сәгать буе тыныч кына тыңлап утырган бер егет, кулын күтәреп:

— Сез этләр белән аңлаша белгән кебек сөйлисез, алар белән сөйләшә беләсезме әллә? — дип сорады.

Вахит, ике дә уйлап тормыйча:

— Беләм, мин этләр телен аңлыйм, — дип җавап кайтарды.

Зал гөжләп куйды.

Вахитның сүзе бетмәгән иде әле.

— Ә сез үзегез сөйләшәсезме соң?

Теге егет як-ягына каранып алды, аннары, йөзенә тыйнак, оялчан кыяфәт чыгарып:

— Сөйләшәм… — диде.

Вахитка бер рәхәт, бер кыен булып китте. Рәхәт, чөнки үзе кебек кешеләрнең тагын булуы җанына ниндидер җиңеллек бирә, аны юата, тынычландыра. Кыен, чөнки ул бу егетнең шушы хәлгә, дөресрәге, халәткә нинди авыр тетрәнүләр, драмалар аша ирешүен чамалап, тоеп белә, ә бу аның күңеленә шулай ук авыр тойгылар сала иде.

Һәм Вахит, ишек ягына тайпылып, тизрәк чыгып китү ягын карады…

**4**

Җанбар белән күбрәк аралашкан саен, Вахит үз күңеленең игелек, изгелек ягына табан үзгәрә баруын ныграк тойды. Ихласлыкка, сафлыкка бик тә сусаган чагы, серлелеккә, илаһилыкка ымсынган мәле иде шул аның…

Бу үзгәрешләрдән Рәдиф кенә канәгать түгел иде. Вахит, этләр белән сөйләшеп йөри башлагач, дустының халтура лекцияләреннән баш тартты, Рәдиф күңел ачар өчен алып килгән чәчбикәләрне ике дә уйламыйча куып чыгарды...

Шулай була бит: сафлыкка, бәхеткә ымсынган кайсыдыр бер минутында Ходай Тәгалә үзенең бәндәсен сыный башлый. Әйе, язмыш булган җирдә сынау да күп була. Бу очракта да көн тәртибенә язмыш мәсьәләсе куелып өлгергән иде.

Эштән кайтып, иртәнге ашын җылытып йөргән чагы иде Вахитның. Кемдер тәрәзә шакыды. Кухнядан йөгереп чыккан уңайга, ишеккә бәрелә язып, туктап калды ул. Кем шакысын?! Ул бит өченче катта яши! Их, авыл гадилеге! Һаман котыла алмый шул авылчанлыгыннан… Имеш, җиргә, кешеләргә якынрак буласы килә…

Шулай да Вахит тәрәзәгә якынрак барды. Үрелеп карады. Кош… Песнәк… Таныш песнәк бит бу! Миләштәге песнәк!

Вахит кошлар телен белә, шуңа да белеп, аңлап, әмма бераз шикләнебрәк, күңелендәге беренче, юньле сорауны бирде:

— Сиңа нәрсә кирәк? Өшедеңмени?

— Юк-юк, өшемәдем. Мин сиңа бик начар хәбәр алып килдем. Күрше подъездда яшәүче малай коега, базга төште…

— Кем, кем? Гаделме?

— Әйе, тизрәк ашык — ул инде өши башлады…

Песнәк, мөһим хәбәрен ишеттерде дә үз юлына китеп барды, Вахит күңел бакчасына төшкән таш белән берьялгызы торып калды. Нишләргә? Кая барырга? Әлбәттә инде, иң элек Гаделләргә керергә кирәк. Бәлки, ул өендә утырадыр? Песнәк хаталанадыр?

Вахит барып кергәндә, Гаделнең анасы керләр үтүкләп тора иде.

Ул аналарга гына хас күңел тоемы белән шундук малае хакында сораша башлады:

— Гадел? Нәрсә булган? Нишләткәннәр?

— Юк, юк, борчылмагыз. Берни дә булмады. Әлегә булмады…— Вахит, нәрсә әйтергә белмәгәч, үзеннән-үзе ялганларга кереште. Ләкин шундук ис-акылын җыеп ала алды. — Гадел… ниндидер коега, чокырга төшкән.

— Нинди кое ул? Кайда? Ничек?

— Белмим, бер кош килеп әйтте. Гадел бәлагә тарды, ди.

— Кем? Кошмы? Сез мине тиле дип беләсезме әллә? Кош ничек әйтсен? Аның бит теле юк. Каян белә ул Гадел хакында?

— Анисы инде караңгы, тик Гаделнең югалуы дөрес. Эзләргә, табарга туры киләчәк. Әйдәгез, киенегез!

Үзара аңлашканчы тагын күпмедер вакыт үтте. Ана кеше яланөс чыгып йөгерергә дә әзер иде. Вахит аңа киенергә булышты, калтыранган кулларыннан ачкычын алып, ишеген бикләде…

Урамда аларны Җанбар каршы алды. Ул Гадел белән килеп чыккан кайгылы хәл хакында күптән белә икән.

— Мин инде якын-тирәдәге этләрдән барысын да белештем. Акколакны гына күрмәдем, ул бу вакытта хуҗабикәсе белән була…

— Әйдә, тизрәк Гаделне эзләп табарга кирәк безгә! Иртәнгә калдырсак, туңып үләчәк, ашыгыйк!

Шул җитә калды, Җанбар, иснәнә-иснәнә, үзе генә белгән эз буенча торып чапты, Вахит, Гаделнең анасы белән бергә, якын-тирәдә пар бөркеп торган җылылык коеларын тикшерергә кереште. Юк, Гадел шундук табылмады. Кышкы кич аны еракка, тирәнгә яшергән иде…

Бераздан ана кеше үз сукмагы белән китеп барды — улын якын-тирәдәге туганнарыннан, таныш-белешләреннән эзләп карарга булды.

Вахит шомлы хәбәр алып килгән песнәкне, аннары каядыр китеп югалган Җанбарны сүгеп, ике урам чатында япа-ялгызы басып калды…

Ул арада караңгы төште, тәрәзәләргә ут кунды, урамнардагы фонарьлар да гөлт-гөлт кабына башладылар.

Вахит, армый-талмый, якын-тирәдәге ишегалларын карап чыкты, аулак ярларны, караңгы почмакларны тикшерде, әмма күрше малаеның эзенә төшә алмады.

Кинәт кайсыдыр йорт артында тонык кына эт өргән тавыш ишетелде. Вахит, тукталып, бераз тыңлап торды да, шул тавыш килгән якка йөгерде. Юк, тиккә өрми бу эт. Әнә бит ничек ярсынып өзгәләнә. Бер-бер хәл бар анда…

Бераздан бу ят эт өрүенә тагын бер эт тавышы кушылды. Монысын Вахит әллә каян таный — Җанбарның моңлы тавышы бу. Ул гына шулай, җырлаган кебек, моңга ташып, җан ярсуы белән өрә белә… Бүген бу тавышта шом да бар. Әллә… Гаделне тапканнармы?

Вахит барып җиткәндә, Җанбар белән Акколак, янәшә басып, бер-берсенә карашып өреп торалар иде. Яннарында тагын кемдер бар… Юк, Гаделнең анасы түгел бу… Кыска ак тун кигән, башына шундый ук ак, җыйнак шәл ябынган бу кыз Акколакның башыннан сыйпап тора. «Акколакның хуҗасы шушы була икән»,— дип уйлап алды Вахит. Шундук Җанбарның әйткәне исенә төште. «Һәр җан иясе парлы булырга тиеш. Әйдә мин сине Акколакның хуҗасы белән таныштырам», — дигән иде ул бервакыт…

Туктале, нәрсә бар соң монда? Нигә бу кадәр өзгәләнеп өрәләр соң бу этләр? Әһә, менә кайда икән хикмәт!

Вахит ул кое тишеген ерактан ук күреп килде. Кичке эңгердә таудай көрт уртасында караеп, ыржаеп торган бу афәт авызы күңелләрне ярыйсы ук шомландырса да, Вахитка күптән таныш иде. Бу урында Гаделнең тау шуып йөргәнен берничә мәртәбә күргәне бар аның. Шуңа гына төшенә алмый — нигә башта ук шушы урынга килергә уйламады икән?..

Килеп җитүгә үк, Вахит, Акколакның мактаулы хуҗасы белән исәнләшеп тә тормыйча тирән базга төшеп китте. Ул Гаделнең хәлсез гәүдәсен күтәреп менгәндә, кыз һаман шул урында басып тора иде. Ай-айлап, ул шундук Вахитка булышырга кереште. Вахит, кирәкми дигән кебек, башын гына як-якка чайкады да, шул күтәргән килеш, Гаделне өйләренә алып кайтып китте…

Аның бөтен уйлары Гадел хакында иде. Исәнме ул? Кай җире авырта, кайсы саны имгәнгән? Нәрсә булган?

Ара-тирә генә, аҗаган кебек балкып, күңелен ят бер уй сызып үтә: «Нинди кыз ул? Аңлашыла — Акколакның хуҗасы… Шундый якты, мөлаем… Әллә күргәне дә бар инде? Таныш йөз… Таныш караш… Тик кайда күрде соң? Кайда?.. Кем ул? Каян?»

Аннары уйлары белән тагын Гаделгә әйләнеп кайта. Аның ара-тирә ыңгырашып куюы үзәкләрне өзә, хәлне ала, күңелне төшерә… Тизрәк кайтып җитәргә кирәк, коткарырга кирәк… Ашыгырга, ашыгырга!..

«Исән-сау ул, имгәнмәгән дә… Күбрәк курыккан, шул гына…»

Вахитка шундук җиңел булып китте: бу бит Җанбар тавышы. Әнә ул янәшә бара — әле бер якка чыга, әле икенче якка, ярдәм итмәкче була, ярдәм генә итә алмый…

Малай өч көннән аякка басты, урамга чыгып йөри башлады. Сынган-имгәнгән җире юк, Җанбар дөрес әйткән. Егылып төшкәндә, башы бәрелеп, миңгерәүләнгән булган.

Вахит аны этләр белән еш күрә. Гадел хәзер алар белән кача-поса уйнамый. Чөнки белә: әнисе бүтән тиргәмәячәк. Теге борчулы көндә улын этләр коткарганын ишеткәч, ул бөтен кеше алдында сүз биргән: «Моннан соң этләрне изге җаннар кебек күрәчәкмен», — дигән, имеш.

Ә беркөнне урамда сәер күренешкә очрап, Вахитның йөрәге тагын урыныннан куба язды.

Эштән кайтып килгән чагы иде. Урам чатындагы аулакта ниндидер этләр өерен күреп, Җанбар да юкмы дип, Вахит шул якка китте. Килсә, теге Гадел исемле малай бер чуар эт белән рәхәтләнеп сөйләшеп утыра.

— Синең исемең ничек?

— Ничек? Чуарборын?

— Каян килдең?

— Ерактан? Ташладылармыни?

— Миңа дус буласың киләме?

— Ышанмыйсыңмы?

— Син миңа ошыйсың. Мин дә ошыйм?

— Алайса бир кулыңны. Дуслар бер-берсенә кул бирешә бит…

Карале, бу малай чын-чынлап сөйләшеп утыра ласа! Ул да этләр телен беләме, аңлыймы әллә? Теге көнге егылу галәмәтеме? Барыбер ниндидер сер бар монда…

Вахит, якынрак килеп, Гаделнең кылларын тарткалап карарга булды.

— Нихәл!

— Әйбәт.

— Сөйләшәсезме?
— Сөйләшәбез.
— Нәрсә ди соң?
— Кем?
— Менә бу чуаркай.
— Чуарборын...
— Матур исем.
— Үзенә дә ошый.
— Шулаймы? Үзе әйттеме?
— Үзе әйтте...
— Этләр сөйләшә беләмени?
— Чуарборын сөйләшә...
— Ничек сөйләшә?
— Күзләре белән... Ник сорашасың, үзең дә беләсең бит?..
— Мин дә беләм? Каян? — Вахит малайны юри сөйләштерә иде.
— Каян булсын, бала чагыңнан. Бала чакта бөтен кеше дә этләр белән сөйләшә, беләсең килсә...
— Боларны кем әйтте, Гадел?
— Әнием әйтте. Аның да эте булган. Алар да сөйләшкәннәр. Үлгән ул. Әнием суга батканда коткарып калган, ә үзе... үзе чыга алмаган, батып үлгән...
— Ничек инде, үзе коткарган, үзе батып үлгән?..
— Яз көне булган ул; ярга чыгам дигәндә генә боз алып киткән аның Акбаен... Әнием, ул этен сагынып, бик озак елады... Мин дә еладым... беләсеңме, ул да чуар булган. Чуарборын кебек...
— Алай икән... Сез хәзер ташлашмагыз инде. Бер-берегезне саклагыз. Бер-берегезнең кадерен белегез. Дус булыгыз. Беләсеңме, Гадел, һәр кешенең үз эте булырга тиеш. Өйдә бергә яшәү мәҗбүри дә түгел. Татарларда элек-электән өйдә эт асрау гадәте булмаган. Ләкин һәр кеше эт тоткан. Һәр кеше үзенең эте, дусты барлыгын җаны, күңеле белән тоеп торырга тиеш булган...
Вахит өенә ашыкты. Артыннан, кайтаваз булып: «Рәхмәт, адәм баласы!» — дигән йомшак, сихри аһәң озытып калды. Бу авыр шәһәр тормышында үзенә дус, юлдаш табып сөенгән Чуарборынның назлы тавышы иде.
Соңгы очрашу Вахитның күңелен кузгатты. Ул авылын, авылда ялгызы яшәп яткан әнкәсен исенә төшерде. Ләкин авылны бөтенләе белән күңеленә алу өчен, ике араны бәйләп кую өчен аңа ниндидер серле җеп, кыл җитми иде. Вахит аны авырлык белән эзләп тапты. Әмма тапты! Бу серле, сихри җеп, кыл аның сабый җанына беренче рухи тетрәнүләр алып килгән бер хатирәдән гыйбарәт иде...

**5**

Вахит, авылга кайтканчы, юл буе шул гыйбрәтле вакыйганы күңеленнән яңартып, кабат кичереп кайтты.
Бу вакыйганың төп геройлары — күршедә торучы Ак бабай, Вахитның әнкәсе, Вахит үзе. Ә! Ак бабайның Бүрек исемле эте бар бит әле! Бүрек — ул хәлләрнең иң төп герое.
Ак бабай зур бакча тота иде. Ул алмалар, чияләр үстереп сата, кыяр-помидорлары да уңа. Авылның күп балаларын кызыктырып тора бу бакча. Ак бабай үзе саран түгел, әмма урлап алган алма тәмлерәк тоелгандыр инде, малайлар Ак бабай бакчасындагы җиләк-җимешләрне урлап ашарга яраталар. Югыйсә, әйбәтләп сорасаң, үзе үстергән байлыкны күпме кирәк шулкадәр төяп чыгара бу изге карт...
Алмагач ботакларын имгәтеп, түтәл таптап җәфалаган малайларны куркыту өчен, Ак бабай беркөнне эт алып кайтып бәйләде. Бүрек кадәр генә кара эт. Исеме дә Бүрек икән. Кечкенә булса да, бик усал булып чыкты ул. Бакчага керәм дип, коймага гына менәсең, шундук ярсып өрә башлый. Вахит үзе күрмәде күрүен, әмма берничә малайның ыштан балагын да аерып төшергән, диделәр.
Ләкин Вахитка андый бәла янамый иде. Чөнки ул Бүрек белән беренче көннәрдән үк дуслашып алды. Баштарак алар койма ярыгыннан карашып торалар иде. Аннары сөйләшә башладылар. Нәрсә хакында сөйләшкәннәрен хәзер хәтерләми иде Вахит. Шуны гына әйтә ала: койма артындагы Бүрек аңа бик серле әйберләр хакында сөйли иде. Бу сөйләшүләрдән Вахит бер нәрсәне аңлап алган иде. Бакчага төшкән малайларга Бүрек куркытам, тешлим, кабып йотам дип өрми икән. Тизрәк керегез, минем уйныйсым килә, дию икән аның...
Бервакыт Ак бабай капка башына язулы такта кагып куйды. Вахит әлегә укый белми иде, Бүрек тә укый белми. Шуңа күрә алар бу язуның нәрсә белдергәнен аңлый алмадылар. Ул вакытта ук «Бу йортта усал эт яши» дигән язуны таный алсалар, кем белә, язмышлары нинди булыр иде аларның.

Ярый әле укый белмәгәннәр. Югыйсә, мин усал икән дип, Бүрек чынлап та усал этккә әверелер иде, ә Вахит аның янына бүтән бер дә кермәс иде…

Әйе, Вахит, кадагыннан купкан бер койма тактасын читкә этеп куеп, Бүрек янына кереп йөри башлаган иде. Ул этнең йонын тарый, аны исәнләшергә өйрәтә, ә Бүрек, рәхмәт әйтеп, кытыршы телләре белән Вахитның бөтен җирен ялап чыга…

Беркөнне әнкәсе улының Бүрек белән назланышып утырганын күреп калды. Күреп калды да, юан таяк күтәреп, атылып килеп тә керде. Менә ул, кергән уңайга, эт кочагыннан Вахитны җилтерәтеп тартып алды да җан көченә Бүрекне кыйнарга кереште. Әлбәттә инде, бу хәлгә Бүрек түзмәде, бер җаен китереп, тәпәч тоткан беләкнең иң йомшак җирен тешләп тә алды…

Шуннан соң нәрсә булганын исенә төшерәсе дә килми Вахитның. Әнкәсе кайтып әйткәч, әткәсе, мылтык алып килеп, ямьсез сүгенә-сүгенә атып үтергән иде аның дустын. Ак бабай белән икесе этнең үле гәүдәсе янында моңаеп басып торуларын хәтерли Вахит. Пуля Бүрекнең күзенә тигән. Ә бит ул нәкъ менә шушы матур күзләр белән сөйләшә иде…

Бүрекне урман буена илтеп күмгәндә дә бергә булдылар. Ак бабай ул вакытта Вахитка ныклап әйткән иде.

— Озакламый мин булмам. Бу ялгыз кабер дә караучысыз калыр. Кайда гына булсаң да, кайтып, караштырып, җыештырып тор, балам, — дигән иде. — Этләр — изге җаннар. Алар безгә рәнҗемәсләр. Әмма дөнья, галәм, илаһи затлар рәнҗер, онытма,— дип тә өстәгән иде.

Вахит авылда озак тормады. Өй тирәләрен, ишегалларын, капка төпләрен кар көртләреннән чистартты, почтага чыгып, газга, утка түләп кайтты, язга кадәр яшәрлек он-шикәр юнәтте, утыннарны барлап, мунча-абзарларны караштырды… Аннары бер көнен урман буенда йөреп үткәрде. Барышлый, зиратка — әткәсе янына кереп чыкты. Ул, Бүрек үлгәч, озак яшәмәде. Икенче кышта ук, урман кисkәндә, агачка басылып үлде… Вахит әткәсе янында күп юанмады, тездән кар ярып, якындагы урманга юнәлде.

Ак бабай белән икесе утырткан куш каенны бик тиз эзләп тапты ул. Бүрек шушы ике каен арасына күмелгән дә инде. Чардуган кебек корылмасы да бар иде. Анысы юк, тузып, коелып төшкән, күрәсең. Җәй кайткач, яңасын корып куярга кирәк…

— Исәнме, Бүрек… — дип пышылдады Вахит, каен төпләренә төбәлеп.

Җавап бирүче булмады.

— Кайтмыйча йөрүем өчен ачуланма, яме. Беләм, мин синең алда да, Ак бабай каршында да нык гаепле. Моннан соң кайтып торырмын, хәлеңне белермен…

…Авыл үзгәрмәгән, малайлар да шул ук. Этләр дә… Әнә бәләкәй генә Вахитлар үзләренең Бүрекләре белән йөгерешеп уйнап йөриләр, ап-ак кар өстендә әүмәкләшәләр…

Авылда этләр бар әле. Димәк, иминлек бар, изгелек, игелек бар әле. Бәхет бар… Бу — бик мөһим. Хәзер… китәргә дә була.

**6**

Вахит Акколакның ак тунлы хуҗасы хакында оныта язган иде инде. Бердән бер көнне ул кыз аның каршына үзе килеп чыкты. Бу юлы ул үзе генә иде.

— Исәнмесез… — Кызның беренче булып исәнләшүе Вахитны тәмам каушатып җибәрде.

— Сәлам… Сез ачуланмагыз, зинһар… Теге көнне юньләп исәнләшә дә, саубуллаша да алмадым…

— Нишләп ачуланыйм ди… Ул көнне бала кайгысы иде бит… Этләр килеп тапмаса, нишләр иде икән ул малай? Шуны уйласам, әле дә йөрәгем жу итеп китә. Үзегезгә рәхмәт…

Җәмилә исемле икән. Якындагы бер мәктәптә инглиз теле укыта. Торган җире дә күршедә генә — Вахит аны өенә кадәр озатып куйды. Ләкин кемнәр белән яшәве хакында сорарга кыенсынды. - Ә сорыйсы килә… Кияүдәме ул? Түгелдер. Әнә бит ничек иркен сөйләшә, хәтта: «Чәй эчәргә керегез», — дип чакырып калды… Йөргән егете бармы? Юктыр, әнә бит ул ничек матур итеп карады… Егете булган кызлар болай өметләнеп һәм өмет биреп, ымсынып һәм ымсындырып, яратып һәм яраттырып, иң мөһиме, киләчәктә сөйгән яр булырга мөмкин кешегә караган кебек, җылы итеп карамыйлар…

Бәлки, бу чынлык та түгелдер, тоем гынадыр? Бу кадәр чибәр, мөлаем, ачык кызның егете булмый димени?!

Тагын бер тойгы: кайдадыр күргәне бар шикелле аны. Кызның күзләре дә мин бит сине беләм дип карыйлар.

Тик кайда, ничек күрештеләр соң алар? Кемдер язган бит: «Үзеңә язган кешене, язмышыңа тигән ярыңны шундук танныйсың, күптән күргән, белгән кебек хис итәсең», — дигән… Шундый очрактыр бу, башкача булмас…

Вахит өенә кайтып кергәнче үз-үзен ышандырырга тырышты. Юк, бәхет болай җай гына, җиңел генә килә алмый. Бу очраклы бер күрешү генәдер, кеше бәхетенә сокланып, хәтта көнләшеп карау

гынадыр… Их, бәхетнең, дөресрәге, киләчәкнең чиген-чамасын төгәл генә белеп булса икән! Ул чикне белгән очракта бәхет өчен, киләчәк өчен көрәшү җиңелрәк булыр иде…

Аннары… Вахит әзерме соң ул бәхет дигәннәренә? Бәхеткә үк булмаса да, олы, матур мәхәббәткә әзерме? Ымсыну бәхет түгел бит әле. Бу яңа тойгы ымсыну гына булып калмас дип кем әйтә ала? Ныклап уйлап карасаң, үткән гомереннән сәер төш булып калган сөйгән кызлары әле дә булса аның күңеленнән юылып бетмәгәннәр… Әнә соңгысы — Зөлфиясе дә ерак күңел төпкелендә бармак янап тора: «Кара аны, малай актыгы, әлегә син беркемгә дә карарга тиеш түгел, берәрсенә карасаң — хыянәт булачак», — ди.

Шулай да рәхәт бүген Вахитка. Күңелендә ниндидер яңа, матур хисләр кайнаша. Йөрәк түрендә басылып, онытылып яшәүче өмет баш калкыткан кебек булды…

Өметтән — хыялга, хыялдан бәхеткә ара ерак түгел… Әллә, чынлап та, аны бәхет үзе сынамакчы буламы?

Әһә! Менә кайда икән хикмәт! Сынауда! Дөресрәге, сыналуда! Вахитның тормыш юлына Җәмиләнең чыгуы, һәм моның Ходай ишарәсе булып җирдә яшәүче этләр булышлыгы белән эшләнүе — әнә шул сынау-сыналу була да инде! Дөресен әйтергә кирәк, үткәндәге сөйгән ярлары белән ул мәхәббәт телендә аңлашырга өйрәнә алмады, ә Җәмилә белән аңлаша алырмы?

Башында яшен уты кебек уйнаклаган уйлардан тәмам арып-алҗып, Вахит, ниһаять, үз йортына кайтып җитте. Өенә кереп киткәнче, уйланып алды: артык ваклана башлады бугай ул, фәлсәфәгә бирелә башлады…

— Бер дә фәлсәфә түгел, сиңа күптән шулай бер уйланып алырга кирәк иде.

Кем бу? Нинди тавыш? Кем укып бара аның күңелен? Ә, Җанбар икән. Күптән күзгә чалынганы юк иде. Акколак белән дуслашып алгач, бөтенләй онытты Вахитны…

Вахит сер бирмәде.

— Беләм дә соң… Әлегә безнең арада беркем дә юк. Ә мин инде әллә нәрсәләр уйлап бетердем…

— Бар, нишләп булмасын. Сез инде табыштыгыз. Ә бу — иң мөһиме. Аннары… син аны беләсең, ул да сине белә, яхшы белә…

— Белә? Каян белә? Үзем дә сизәм аны…

— Каян булса да барыбер түгелмени? Үткән белән яшәмә, бүгенге белән яшә.

— Киләчәк белән яшә димәкче буласыңмы?

— Юк, киләчәкнең кайчаннан башланганын беркем дә әйтә алмый. Бүген белән яшәргә кирәк, киләчәк ул бүген…

Күренеп тора, подъезд төбендә тәкәббер кыяфәт чыгарып утырган Җанбарның бик тә сөйләшәсе килә иде. Вахит моны шундук сизеп алды һәм, һич авырсынмыйча, якындагы эскәмияләрнең берсенә барып утырды.

— Йә, ни әйтмәкче буласың инде? Нинди киләчәк? Нинди бүген? Ул кыз миңа ошый, беләсеңме, ошый, бары тик шул гына!

— Ошый гына, имеш. Иң мөһиме шул бит инде! Иң кирәге шул!

Этнең бөтен дөнья гамен җыйган шомырт күзләрендә нур балкып китте… Чын нур! Дөнья нуры!

«Карале син моны!.. Эт кенә диген инде син аны, ә! Әнә нәрсәләр уйлап йөри икән бит! Әллә?.. Берәр изге рух шушы җан иясе кыяфәтендә каршыга чыктымы? Этләр өчен артык акыллы бу сөйләшү! Кеше белмәгәнне белә, адәм уйламаганны уйлый, сөбханалла!.. Сөбханалламы, әллә гөнаһ шомлыгымы?» Вахит, күңеленә йомылып, тагын үз фәлсәфәсенә кереште… Ләкин Җанбар бу юлы да аны бик тиз гөнаһлы җиргә кайтарды.

— Андый авыр сүзне әйтмә. Уйлама да. Күңелеңә авырлык аласың… Сагынырсың әле… Минем белән аралашкан чакларыңны юксынырсың… Шуңа күрә рәнҗетмә…

— Нишләп? Без гомер буе шулай сөйләшеп, аралашып яшәмәбезмени?

— Юк, әлбәттә. Тиздән безнең тормышларыбыз элекке хәленә кайтачак; ике арадагы шаукымны олы хис, гүзәл гамь алыштырачак…

— Нинди шаукым? Нинди хис, нинди гамь? Мин берни дә аңламыйм.

— Мәхәббәт хисе. Сөю хисе. Сөю хисе бөтен хистән дә, бөтен сихер-шаукымнан да өстен!

— Нинди мәхәббәт? Ни сөйлисең син? Акылыңа кил!..

— Бөтен дөнья, бөтен тереклек белә бу хакта, озакламый үзең дә белячәксең: син Акколакның хуҗасы Җәмиләгә гашыйк булдың…

— Бөтен дөнья белә, мин генә белмим, имеш… Кызык…

— Син дә беләсең, аңлап-төшенеп кенә җиткермисең әле. Үлеп гашыйк булган кеше үзенең күңел халәтен аңламыйчарак тора, моңа нигә аптырарга?.. Бөтен дөньяга фаш булгач кына төшенә башлый…

Үзенең күңел халәте хакында Вахит бик яхшы белә, әлбәттә! Юри генә сөйләгән була. Менә шундый матур уен. Шушы уен белән тагын берничә көн, аннары берничә атна узды. Вахит Җәмилә бе-

лән һәркөн диярлек күрешеп, очрашып торды. Бәхетләренә, эш сәгатьләре бер тирәдәрәк бетә, юллары да бер үк юл… Хәтта уйлары, хыяллары да охшаш… Язмышлары гына ничектер — анысы караңгы, анысын илаһи ишарә булып яшәүче Җанбар белән Акколак та белеп бетермидер әле…

Вахит үзенең этләр, мәчеләр белән сөйләшеп йөрүе хакында Җәмиләгә әйтмәде. Кызның дөньяга шаулап ачылган чәчәк кебек күңеленә шом кертүдән курыкты ул. Юкка курыккан икән. Бер вакыйгадан соң ул Җәмиләгә күңелен тәмам чишеп ташлады. Һәм ул моны теләп, яратып эшләде…

Беркөнне Вахит эшеннән соңга калыбрак чыкты. Җәмилә аны калдырып китмәгән, көткән. Әнә ул, юл читенә чүгәләп, каршы алырга килгән Акколак белән сөйләшеп тора. Әйе-әйе, чын кешеләр кебек, тукталыштагы халыкка да исе китмичә, рәхәтләнеп сөйләшеп тора! Юк анысы, Вахит Җәмиләнең сөйләшүенә аптырамады. Хикмәт башкада: Акколак та кешеләр телендә сөйләшеп тора!

Вахитның яннарына килеп басканын күрмичәрәк калдылар, онытылып гәпләшүләрендә булдылар.

— Беләсеңме, Акколак, ул миңа бик якын хәзер; шулкадәр якын күрәм, шушы баскан урынымнан кузгалып та китә алмыйм…

— Бу нәрсә дигән сүз инде?

— Бу, Акколак, мәхәббәт була… Бу — ярату дигән сүз…

— Мәхәббәт? Ярату? Бу хис кешеләргә дә хасмыни? Сез дә безнең кебек ярата беләсезме?

— Нишләп алай дисең, Акколак? Нигә болай мине рәнҗетәсең?

— Һич рәнҗетергә уйламыйм. Мәхәббәт — тереклеккә, җан ияләренә генә хас. Ә менә кешеләргә хасмы ул? Минем бераз шигем бар. Якты, изге хис ымсындыра бит ул. Кешеләр дә тартыла аңа, мәхәббәткә ирешеп, күңелләрен сафландырырга, яхшыртырга телиләр… Тик…

— Нәрсә — тик? Акколак, нәрсә?

— Тик алар бу хиснең кадерен белмиләр.

— Тагын рәнҗетмәкче буласыңмы, Акколак?

— Һич юк. Уйлап кара: мәхәббәтнең асылы — тугрылык. Ә кешеләрдә тугрылык юк. Алар тугры була белмиләр. Мәхәббәттә тугрылык мәҗбүри түгел дип саныйлар алар. Үзләре мәхәббәт уены уйныйлар, хәтта чын-чынлап яраталар да, ә үзләре… Ялган, хыянәт белән яшиләр…

— Акколак, җитте! Дәшмә бүтән! Син хаклы түгел. Һәрхәлдә, миңа карата, Вахитка карата хаклы түгел!

— Ярый, шулай булсын. Мин бит синең яклы. Шуңа күрә язмышыңны әйбәткә юрыйм.

Моңа кадәр тыныч кына яннарында торган Вахит Җәмилә белән Акколак арасындагы киеренкелекне бушатып җибәрмәкче булды:

— Кем анда минем исемне кушып сөйләшә? Ә? Ну-ка, ну-ка…

Кыз, сискәнеп, аягүрә торып басты. Акколак та, гаебен таныгандай, койрыкларын җыеп, башын аска иде…

Вахит һаман шаяруында булды, бу көтелмәгән хәлдән тизрәк котылырга ашыкты:

— Көтеп тормаска иде, Җәмилә. Әллә?.. Әллә бүтән берәрсен көтәсеңме? Әгәр шулай икән, мин хәзер китәм, күзләреңә бер тутырып карыйм да…

Шаяру уңышсыз чыкты. Вахит кызны тагын да кыенрак хәлгә куйды. Аның Җәмилә белән бу кадәр туарылып сөйләшкәне юк иде әле.

Аны кичерделәр. Әнә Җәмилә ничек елмаеп, яратып карап тора… Акколакның карашларында да шик-шөбһә юк…

Кайтырга чыктылар. Вахит, күңелен ачып, иркенләп сөйләшеп китә алмады. Чөнки аның мәхәббәт хисләреннән нечкәреп, иләсләнеп калган күңелен ят бер тойгы кимерергә керешкән иде: «Әллә Җәмилә дә, минем кебек, тереклек ияләре белән, этләр белән аңлаша аламы? Ул да, Вахит язмышына дучар булып, татлы да, аянычлы да хисләр кичереп яшиме?»

Ничек кенә теләмәсә дә, Вахит бу хакта дәшмичә кала алмады. Инде кайтып җитәргә дә күп калмаган иде, ул, мәктәптәге бер шаян, тыңлаусыз бала хакында сөйләп барган Җәмиләне бүлеп, кинәт сорап куйды:

— Бая Акколак белән нәрсә хакында сөйләшеп тора идең, Җәмилә? Әллә этләр телен беләсең инде?

— И Вахит, минем Акколак, кеше кебек сөйләшә белмәсә дә, мин әйткәннәрнең барысын да аңлый. Үзе сөйләшә белмәсә дә, мин барыбер аның әйтәсен күңелем белән тоям, шуңа да без бик еш сөйләшеп утырабыз…

— Шулаймыни? Әйбәт бу. Тереклек ияләре бер-берсе белән аралашып, аңлашып яшәргә тиешләр, әйеме? — Вахит үзенең урынсыз бирелгән соравына җиңелрәк, гадирәк мәгънә салмакчы булган иде дә, ләкин сүз җитдиләнеп өлгергән иде инде.

— Авылга кайткан саен мин әби белән бабай арасындагы бәхәскә тап булам, — дип, карашларын юл сукмагыннан аермыйча гына сөйләп китте Җәмилә. — Минем бабакай этләрне бик ярата, ә әбекәй аларны күралмый.
— Ни өчен? — Вахит, алгарак чыгып, Җәмиләнең каршына ук килеп басты.
— Хикмәт тә шунда шул. Әбекәй әйтә: «Коръән буенча, этләр, дуңгызлардан кала, иң пычрак җан ияләре,— ди.— Алар кеше йортында яшәп тә, аның белән бер савыттан ашарга тиеш түгелләр,— ди.— Этнең сулышы да кеше тынына керергә тиеш түгел»,—ди…
— Шуннан, шуннан? Бабаң моңа нәрсә ди?
— Нәрсә дисен, ул әбекәйгә Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре белән җавап кайтара.
— Нинди сүз ул, Җәмилә, әйт инде тизрәк!
Җәмилә бераз уйланып торды, аннары, чүгәләп, Акколакны сыйпарга, назларга кереште.
— Имеш, этләрне күралмаган бер хатын булган. Менә шул хатын бер этнең өстенә табак каплап киткән. Теге мескен эткәй күп көннәр буе, шул табак астыннан чыга алмыйча, газапланып иза чиккән, бераз вакыттан соң, ачтан интегеп, тәмам хәлсезләнеп, кибеп үлгән. Ходай Тәгалә әйткән: «Эткә шундый мөгамәләдә булганы өчен мин бу хатынны тәмуг газапларына дучар иттем»,— дигән. Аннары өстәп әйткән: «Урамда сусап йөргән эткә бер йотым су эчергән кешегә мин оҗмахтан урын бирәчәкмен»,— дигән. Менә шундый хәлләр булды бездә. Ләкин бабакай ничек кенә ышандырып сөйләсә дә, әбекәй өйгә эт кертмәде, безне этләр белән уйнатмады…
— Кызык бу. Карале, Җәмилә, изгелек белән явызлыкның чиге этләр белән янәшә уза микән әллә?
— Шулай булып чыга. Бер яктан, алар — усаллык символы, икенче яктан, тугрылык, гаделлек һәм көч билгесе…
Яннарында барган Акколак, бу фәлсәфәгә риза булмыйча, ырылдап куйды, төчкеренергә кереште, аннары, читкә тайпылып, бөтенләй чабып китте… Ләкин ул читтә озак юанмады, ярар, сөйләсәгез сөйләгез инде, түзәм дигән кебек, кабат килеп, башын аска игән кыяфәттә, адәм балалары белән янәшә атлап бара башлады.

**7**

Беркөнне әлеге таныш тукталыш янында барган бер вакыйга Вахитны тирән борчуга салды, хәтта сагаерга мәҗбүр итте.
Алдан килешеп куелганча, Җәмилә бу көнне дә Вахитны бераз көтеп торырга тиеш иде. Белгән булса… Вахит сөйгәненнән бер сәгать алдан чыгып басар иде…
Нинди хикмәт булгандыр, бу хәлне Вахит ерактан ук тоеп, хәтта күреп килде. Төптән таза бер бәндә Җәмиләнең тун җиңеннән эләктереп алган да тарткалапмы-тарткалый, каядыр сөйрәп алып китмәкче була. Шунда гына кызыл машинасы тора. Ишекләре ачык. Тукталыштагы кешеләр, читкәрәк китеп, бер төркемгә укмашып торалар. Һәрвакыттагыча, беркемнең дә бу тарткалашка катнашасы килмидер, күрәсең…
Вахитның җан түрендә бер кыл чиертеп алды — кайсы җире беләндер таныш кебек бу кеше. Хәтта бик тә таныш… Ераграк шул, йөзен күреп булмый… Ышанасы килми… Вахитның танышлары арасында мондый яман затлар юк…
Вахит үзе, тыны кысылып, үпкәсе шартлар дәрәҗәгә җитеп чаба, үзе бертуктаусыз тукталыш ягына карап кычкыра:
— Җәмилә-ә-ә! Җәмилә-ә-ә!
Теге адәм актыгы аны беренче булып ишетте. Җәмиләнең изү якасыннан бөтереп тоткан кулларын бушатып, тавыш килгән якка бераз карап торды, аннары тиз генә машинасына кереп чумды, төтен болыты пошкытып, яңа яуган карда салулый-салулый китеп тә барды…
Вахит хәле бетеп килеп җиткәндә, Җәмилә, күз яшьләренә төелеп, еламсырап тора иде.
— Нәрсә булды, Җәмилә? Кем ул? Нәрсә кирәк аңа?
Җәмилә җавап бирерлек хәлдә түгел иде. Ул, башын Вахитның күкрәгенә салып, озак кына тынычланды, елап та алды. Кайту юлына төшкәч, сулкылдап сулыш ала-ала, барысын да җентекләп сөйләп бирде.
Авылдашы, алай гына да түгел, яшь чакта озатышып, сөешеп йөргән егете икән. Кайчандыр, яратам-сөям, дип йөргән-йөргән дә, бер сәбәпсез-нисез, шәһәргә китеп барган, суга төшкән кебек юкка чыккан. Менә хәзер шул егет ун елдан соң күктән төшкән кебек пәйда булган. Беренче тапкыр ул Җәмиләне Яңа ел бәйрәменә кадәр үк күргән.
Гафу юк, ни юк дигәндәй, урамнан китеп барган Җәмилә янында машинасын туктаткан да:
— Әйдә Яңа елны бергә каршылыйбыз. Минем шәп компания бар — үкенмәссең,— дигән.
Җәмиләнең күңеле йомшап киткән, йөрәгендә авылдаш егетенә булган элеккеге матур хисләре баш калкытып куйган. Ул бәйрәмгә баруын барган, әмма бәйрәм вакытында «сөйгәне» аны дуслары

кочагына тәкъдим итә башлагач, мәҗлесне ташлап чыгып киткән. Теге бәндә хәзер дә күргән саен бәйләнеп, Җәмиләне үзенә чакырып җәфалый икән…

Вахит күпме генә белергә тырышса да, Җәмилә бәйләнчек авылдашының исемен әйтмәде. «Сине дә катнаштырырга теләмим», — дип котылды.

Вахитка:

— Берни дә булмас, егетем бар дип әйт, бәйләнеп интектерсәң, егетемә әйтәчәкмен дип әйт, — дип акыл сатудан башка чара калмады.

Җәмилә аны бөтенләй башкача аңлады.

— Вахит, нигә алай дисең? Син минем егетеммени?

— Менә сиңа мә! Ничек егетең булмасын. Бер ай йөрибез бит инде, уйлап кара — бер ай бергә!

— Син шулай дисең, Вахит. Ә бит безнең бер мәртәбә дә үбешкәнебез юк…

— Һи, нәрсә карап торабыз соң. Әйдә үбешәбез! Әйдә аңлашабыз…

— Вахит! Сиңа көлке, ә минем елыйсым килә…

— Минем дә елыйсым килә, Җәмилә. — Вахит бу юлы бик җитди иде. — Мин үз гомеремдә беренче мәртәбә үлеп гашыйк булдым, яраттым. Менә сине яраттым. Шуңа күрә дә шатлыктан бер көләсем, бер елыйсым килә! Их син, елагым минем, бәхетем, язмышым минем! Кил әле, бер кысып кочаклыйм үзеңне, бер суырып үбим…

Бу көнне алар озаклап урамда йөрделәр, күңелләре булганчы сөйләштеләр, сөештеләр, үбештеләр. Әллә каян гына яннарында Җанбар белән Акколак пәйда булды. Җәмилә шундук үз этен тиргәп алды: «Кирәк чакта кайда йөрисең соң син? Хәзер берегез дә кирәкми инде. Барыгыз, кайтыгыз, үбешәсебез бар безнең, шулай бит, сөйгәнем?» — Үзе һаман Вахитның кочагына керә барды.

Вахит сүз катып дәшәрлек хәлдә түгел иде. Телсез, аңсыз бер бәндә кебек, ул, күзләрен зур ачып, үбешер өчен генә яратылган дәртле, калын иреннәрен турсайтыбрак, ризалыгын биреп башын гына какты.

Ләкин шул мәлдә үк Җанбарның әйткәннәре Вахитның йөзендә балкыган нурлы елмаюны сыпырып алгандай булды.

— Син бит аны беләсең… — диде Җанбар, койрыгын тырпайтып. — Әйтимме кем ул?

— Әйт, әйт, кем ул? Тукта, әйтмә, мин аны үзем табачакмын! Үзем сөйләшәчәкмен!

— Ярый, синеңчә булсын. Ләкин озакка сузма, аның күңеленә явыз уй керде…

Әллә каян гына килеп чыкты бу шайтан коткысы! Үзем табам, үзем сөйләшәм, имеш! Каян тапсын, каян сөйләшсен ул, булмаганны! Ичмасам, Җәмиләдән ул егетнең исемен дә әйттерә алмады. Шикләнер, әллә нәрсәләр уйлар дип уйлады… Ник ныклап сорашмады, ник әйттермәде икән аның кем икәнен? Нигә кирәк булды бу тәккәбберлек?

Шул көннәрдә янына килеп чыккан Рәдиф дусты да юньле-башлы киңәш бирә алмады. Көзге каршында торган килеш, сул як каш читендәге тырналган урынга кәгазь ябыштыра-ябыштыра, фәлсәфә куертудан узмады ул.

— Хатын-кыз — эт кебек ул. Хатын-кыз ир кешенең дусты булырга тиеш. Тыштан фәрештә кыяфәтендә йөрсә дә, эчке асылы белән ул — хайван зат, үзенә көч кулланганны, көчләгәнне ярата. Шуны көтә дә. Синең урында булсам, мин ул кешене эзләмәс идем. Кстати, Җәмилә сиңа ул кешенең исемен әйттеме?

— Нишләптер ныклап сорамадым.

— Сорама да. Үзләре аңлашып, килешеп бетсеннәр. Синең эшең түгел ул…

— Шулай дисеңме? Рәдиф, син ни әйтсәң дә, күңелем барыбер тыныч түгел минем, беләсеңме шуны?

— Белмим дә, беләсем дә килми. Бүтән берни дә әйтмим, соңгы сүзем шул: йөргән кызыңның элеккеге гөнаһлары өчен баш катырып йөрмә, болай да дөнья тыныч түгел…

Әллә шушы сүздән, әллә Җәмиләнең: «Начар белән начар булма»,— дип әйтеп торуыннан Вахит бер күндәм кешегә әверелде, күңеле тәмам тынычланып, сөюнең бөтен ләззәтен татып яши башлады.

Ләкин Рәдиф ялгышкан булып чыкты. Аңа карап Вахит ялгышты. Вахитка карап — язмыш…

Бәла аларны февральнең кояшлы бер көнендә килеп тапты. Җәмиләне урладылар.

Тукталышта очрашырга сүз куешканнар иде, аяк буыннары муртаеп катканчы торса да, Вахит үзенең сөйгәнен көтеп ала алмады. Кайтышлый сугылган иде, кызның өе дә бикле булып чыкты, күршеләре, таныш-белешләре дә күрмәгән…

Тагын бер шомлы хәбәр: иясе белән бергә Акколак та югалган, хәтта Җанбар да кинәт юкка чыккан, имеш. Бер кичтә Вахит япа-ялгызы торды да калды. Шулай аптырап, гаҗәпләнеп, йортлары каршындагы эскәмиядә моңайганда, аның янына күршедәге Гадел килеп утырды. Бераз ябыгып, үсеп киткәнме? Соңгы вакытларда бу малайның өй тирәсендә күренгәне юк иде шул.

— Нихәлләр, Гадел? Күренмәдең, әллә тагын берәр чокырга төштеңме?

Юмор барып чыкмады — моны Вахит үзе дә белә. Ләкин бит… бер кәлимә сүз дәшми утырганчы, нидер сөйләшеп алу әйбәтрәк…

— Авырдым мин… Бүген беренче көн генә чыктым әле. Урамнарны урап кайттым. Җәмилә апаны кызыл «Жигули»га утыртып алып киттеләр…

— Ә? Нәрсә дидең? Тагын бер кабатла әле!

— Җәмилә апаны алып киттеләр.

— Син күрдеңме? Үзең күрдеңме?

— Үзем күрдем.

— Кем алып китте? Үзе утырдымы?

— Утырырга теләмәгән иде, кулыннан тотып, төрткәләп утырттылар.

— Кемнәр? Кемнәр дим!..

— Кемнәр түгел, кем. Беләсең син аны. Сиңа килгәне бар…

Нәрсә була инде бу? Һич кенә дә башка сыя торган әйбер түгел. Аның бит әле Җәмилә белән бер дустын да таныштырганы булмады… Кызыл «Жигули» диме? Кызыл «Жигули» бер Рәдифтә генә… Ул исключается… Тагын кем? Кем?

Вахит тагын Гаделне җилтерәтергә тотынды:

— Исеме ничек иде? Исеме?

— Белмим, үзең беләсең…

— Кыяфәте нинди иде соң? Гәүдәсе, йөзе, киеме? Ә?

— Белмим лә… Мин аны ныклап карап кала алмадым. Тизрәк табыгыз сез аны…

Вахитның зиһене бөтенләй таралды. Ул, ах-ух килеп, башын тотып ук утырды.

Нинди серле кеше ул? Нинди дус, таныш? Каян белә ул Җәмиләне? Әллә җенме, пәриме? Нигә көчләп алып киткән ул аның яңа гына күңеленә кереп баручы бәгырь кисәген? Җанбар да күренми, ичмасам, аның белән бергә ни дә уйлап табарлар иде…

Вахит, шулай дип уйлап кына бетерде, койрыгын болгый-болгый, авызыннан пар-бу бөркеп, әллә каян гына Җанбар килеп чыкты. Килеп чыкты да, телләрен салындырып, иясенең каршына ук барып утырды. Вахит аның алдына тезләнде.

— Нәрсә булды соң, Җанбар? Нинди хәбәр алып килдең? Нәрсә беләсең?

— Ә син нәрсә беләсең? — Этнең сорауга сорау белән җавап бирүе Вахитны тәмам чыгарыннан чыгарды.

— Мин бит синнән сорыйм — нәрсә булды дим! Ярдәм ит миңа, табарга булыш Җәмиләне!

Үз тавышыннан үзе куркып китте Вахит. Эт тә койрыгын бот арасына кысты… Ул бүтәнчә сүз куертып тормады.

— Мин Акколакка ияреп барган идем. Барысын да күреп тордым. Машина артыннан чабып бардык. Шәһәр читендәге бистәдә тукталдылар. Акколак шунда калды, мин сине алырга кайттым. Әйдә, җыен тизрәк, каккан казык кебек җебеп утырма…

Гадел һаман шунда икән әле.

Ул да торып басты:

— Ул дөрес әйтә, тизрәк барырга кирәк.

Вахит ничек сикереп торганын сизми дә калды. Аннары шап итеп кире утырды. Туктале, тукта… Җанбарның нәрсә әйткәнен каян белә соң бу малай актыгы?

Вахит үзенең борчулы күңелендә баш калкыткан сорауга җавап табып өлгерә алмый калды, тәмам акылдан шаштыра язып, артында Гаделнең сихри тавышы ишетелде:

— Вахит абый, мине дә үзегез белән алыгыз әле. Мин бит… этләр телен беләм!..

— Нәрсә? Этләр телен? Беләсең? Каян беләсең?

— Нишләп белмәскә… Бөтен балалар да белә… Хәтерләмисеңмени?

Җитмәсә, елмаеп-көлеп торган Җанбар да:

— Белә, белә, безнең телне белә, — дип үртәгән була…

Бүтән сорашып, аңлашып торырга вакыт юк иде, Вахит, ияге белән ымлап, малайга үз артыннан иярергә кушты. Һәм алар, өчәүләп, акка чорналган ишегаллары, бакча-аллеялар аша Җәмилә исемле язмышларын эзләп чыгып киттеләр.

Юлда барганда Вахит Җәмилә хакында уйламаска тырышты. Исән генә булсын, калганында Ходай Тәгалә булышачак, билләһи булышачак… Ә менә Гаделнең сүзен ул күңеленә якын алды, югалтмаслык, онытылмаслык итеп йөрәгенә беркетеп куйды. Ул аптырап уйланды, хәтта үз-үзе белән бәхәсләшә-бәхәсләшә уйланды. «Ничек була инде бу? Җәмилә Акколак белән сөйләшеп йөри. Гадел дә этләр телен аңлый… Бар дөнья этләр белән аңлашып яшәгән бер вакытта Вахит үзен нindидер бер изге кеше, пәйгамбәри зат итеп тоеп, шуның белән горурланып, кәпрәеп йөрсен инде, ә?! Адәм көлкесе!»

Җанбар аларны шактый еракка алып китте. Эт артыннан йөгерә-атлый барганда сөйләшмәделәр. Шәһәр өстенә эңгер-меңгер төшкән саен, Вахитның күңелендә шомлы, хәсрәтле тойгылар көчәя, арта барды.

Менә ул йорт. Биш катлы «хрущевка». Подъездда кемдер бар. Эт бит бу! Акколак! Акколак утсыз подъездның төпсез караңгылыгыннан йөгереп чыкты да Җанбар янына чабып килде; койрыгын болгап, аны сәламләргә дә онытмады — баштанаяк иснәп, назлап чыкты…

Вахитка кинәт әллә нәрсә булды. Ул көч-хәл белән ис-акылын җыеп ала алды. Әмма шундук буыннарыннан язды, баскан урынында торараташ кебек катып калды. Алар Рәдиф дусты яшәгән йорт каршында басып торалар иде! Әнә аның кызыл машинасы да тора. Бүлмәсендә ут бар. Пәрдә артында хәрәкәт сиземләнә. Өй эчендә кемнәрдер йөри сыман…

Рәдиф... Менә кем икән ул — Җәмиләне чарасызлап интектерүче, урлап алып китүче хәерсез бәндә! Менә кем ул аның яшьлек мәхәббәте…

Тәрәзә артындагы киеренкелекне Вахит шундук сизеп алды. Керергәме, юкмы? Дусты бит ул аның. Күп еллар бергә яшәгән, ачысын-төчесен бергә татыган дусты… Дусты? Нинди дус булсын ул?! Вахитка күңелен багышлаган Җәмилә аның дусты! Җанбар, Акколак аның дусты! Гадел дә дусты! Ә Рәдиф… Дус микән соң ул? Кәсеп, табыш буенча, дөнья мәшәкатьләре буенча танышы, бары тик шул гына. Вахитның лекцияләре, эше, белеме исәбенә яшәүче бер паразит бәндә… Юк, мондый кеше аңа дус була алмый…

Үзенең ачышыннан нишләргә дә белмәде Вахит. Ары сугылды, бире сугылды, ничек тә Рәдифнең фатирына кермәс өчен сәбәп табарга тырышты. Андый сәбәп табылмады. Хакыйкать чынлыктан күп мәртәбәләр ачы була. Бу инде сыналган фал.

Рәдиф ишекне озаклап, теләмичә генә ачты. Үз-үзенә охшамаган иде ул бүген. Ачылып китмичә генә күреште, түргә — эчке бүлмәгә дә чакырмады. Йөзендәге, тавышындагы, хәрәкәтләрендәге каушау чалымнарын, ничек кенә тырышса да, яшереп бетерә алмый үзе…

— Нәрсә кирәк, Вахит?

— Иң элек кешечә исәнләш, Рәдиф!

— Нәрсә? Ә, сәлам…

— Рәдиф, Җәмилә кайда? Күрмәдеңме?

— Кем? Җәмилә?

— Ишеттең бит инде, ник сорыйсың?

— Гафу… Ну, күрсәм нәрсә диярсең?

— Нишләттең син аны?

— Сиңа барыбер түгелмени? Яхшы чакта чыгып кит, Вахит. Җәмилә — минем забота.

— Юк! Синеке генә түгел инде хәзер!

— Ә? Нәрсә дисең? Җәмилә синеке дә? У-һу-һу…— Рәдиф ямьсез итеп көлеп, шыңшып куйды…— Ә син беләсеңме, иптәш статист, беренче булып ул миңа бирелде. Ике ел буе минеке булды… Атнасына өч тапкыр күрешә идек… Ун елдан соң тагын очраштык. Санап барасыңмы, статист?

— Рәдиф, җитте сиңа!

— Юк, җитмәде әле. Яңа елны хәтерлисеңме? Бу елны «эт елы» дип игълан иткән идек. Аннары эт булганчы эчкән идек… Хәтерлисеңме? Анда да бар иде ул…

Рәдиф теләгәнә иреште: Вахитның зиһене ә дигәнче буталып куйды, уйлары чуалды… Ләкин акылыннан да язмады.

Ул үзенең кайда икәнлеген, ни өчен килгәнлеген төгәл белә иде.

— Рәдиф, миңа болар кирәкми. Мин боларны беләм инде. Кайчандыр ул сине яраткандыр да. Хәзер дә, бәлки, онытып бетерә алмыйдыр… Ләкин бүген мин аны яратам, ә ул мине ярата, белдеңме?! Ишетәсеңме, яратам!

— Миннән калган булса дамы?

— Их, Рәдиф, син бөтенләй кешелек гаменнән ваз кичкәнсең икән. Мәхәббәттә бер генә кеше була — яраткан кеше генә! Калганнары мөһим түгел, аңлыйсыңмы, мөһим түгел!

— Баш катырмале шул фәлсәфәң белән! Телеңә салынып, күңелеңне тынычландырасың килсә, башка урын эзлә. Бар, кит моннан!

— Рәдиф, соңгы мәртәбә сорыйм: Җәмилә кайда? Мин аны алырга килдем.

— Әнә ул эчке бүлмәдә. Алып кит тизрәк. Юкса бер-бер хәл кылып куюым бар… Төрмәгә утырасы килеп тормый әле…

Вахит атылып-бәрелеп түр бүлмәгә барып кергәндә, Җәмилә бөрешеп диванда утыра иде. Үксеп, шешенеп беткән. Киемнәренең рәте-чираты юк. Бер кулы белән изүеннән бөтереп тоткан да икенче учы белән күзләрен каплаган…

— Җәмилә!

Җәмилә кузгалмыйча утыра бирде. Ә үзенең йөзе буйлап, бармак араларыннан саркып, яшь ага…

— Җәмилә! Син ничек? Ник дәшмисең? Җәмилә!

— Вахит…

— Җәмилә… Әйдә, тор, китик моннан тизрәк! Кайтыйк…

— Юк, якын килмә миңа, Вахит!

— Нигә, Җәмилә?

— Мин… Мин сиңа лаек түгел. Рәдиф минем иң саф чагымны алды. Кайчандыр мин аны яраткан идем…

— Җәмилә!.. Син минем өчен иң саф кеше, иң саф җан! Син — саф җан гына түгел, сафлыкның үзе, белдеңме?!

Җәмилә, яшь аралаш, олы, матур күзләре белән елмаеп җибәрде. Ул бу минутта бик мөлаем һәм мәхәббәтле иде! Бөтен куркуларын, борчуларын онытып, Вахит та аңа ихлас сөеп карады. Ул беренче мәртәбә үз язмышының Җәмилә язмышына мәңгелеккә береккәнлеген тойды.

Шайтан коткысы булды, ахры, Вахит, Рәдиф кереп киткән бүлмә ягына ымлап, сорап куйды:

— Рәнҗеттеме?

— Юк. Ул да бит мине ярата, үзенчә ярата. Ләкин көчләп яраттырып булмаганын белми… Шул гына…

…Урамда буран купкан. Аларны кар сарган Акколак белән Җанбар каршы алды. Гадел дә шунда гына икән… Бераз туңган. Бераз курыккан… Адәм баласы бит — хәлне тиз аңлап алды. Елмаеп җибәрде.

Аннары, этләргә карап, олыларча әйтеп куйды:

— Ә сез курыккан идегез…

Акколак белән Җанбарның койрыкларын болгап, шатланып, сөенеп йөрүләрен үзенчә юрады Вахит: бик тә сөйләшәселәре килә боларның. Әнә күз карашлары ук әйтеп тора, нәрсә булды? Хәлләрегез ничек? Сез хәзер бергәме инде? Бүтән аерылышмассызмы? ди. Тукта, ә нигә аларны ишетми соң Вахит? Нигә элеккечә сөйләшә, аралаша алмый? Тоя алмый… Күңелен аларның нәзберек, изге җаннарына көйли алмый…

Вахит, тезләнеп, Җанбарның хискә, моңга мөлдерәмә тулы, әмма сүзсез күзләренә баккан килеш, дулкынланып сөйләп китте:

— Менә шундый хәлләр, дускай. Миндә бит хәзер бүтән хис, бүтән тойгы… Тик шуны бел: мин сине бервакытта да ташламаячакмын! Акколакны да ташламаячакбыз. Сезнең балаларыгыз туар, без аларны карашырбыз, кеше итәрбез. Җәмилә белән безнең дә бәбиләребез булыр. Сезнең балалар белән безнең балалар бергә уйнарлар, сөйләшеп, аралашып яшәрләр… Балалар этләр телен аңлый бит. Мин инде синең белән бүтән сөйләшә алмам. Балаларым сөйләшер. Балаларым аша мин дә сөйләшермен… Шунда тагын аңлашырбыз, яме.

Барысын да аңлаган, төшенгән кебек, Җанбар мөлдерәмә күзләре белән Вахитка карап тора. Гүя әйтә: «Мин сезгә бәхет телим, кешеләр! Мәхәббәт телим. Минем белән сөйләшмәсәгез сөйләшмәгез, тик бер-берегезне генә яратыгыз, бер-берегезнең кадерен белегез, якыннарыгызны ташламагыз, югалтмагыз, рәнҗетмәгез… Онытмагыз: сезнең җаныгызда безнең шәүлә дә бар…»

*2005*

## *СОҢГЫ СУГЫШ*

*(Бәян)*

Ходай Тәгалә әйтте: «Мин бер халыкның да хәлен үзгәртмәм, әгәр ул үзенең хәлен үзе үзгәртмәсә»,— диде.

*Хәдис*

### Пролог

*Зәкәрия карт үләргә җыенды. Шомландырса да, үлем куркытмый аны. Ул озын, бәхетле гомер кичерде. Бәхетне ничек аңлыйсың бит... Аны тигез гаиләдә туу, үсү дип тә, яшьлек бүләк иткән матур мәхәббәт дип тә, бөтен гаилә яисә балалар исәнлеге дип тә, хәтәр сугыш сынавы үтеп, җиңү яулау яисә шул җиңүләрдән соң туган җиреңә тугры хезмәт итү дип тә аңларга мөмкин. Зәкәрия күпне күрде, күпне кичерде, кешедән калмады — партиясенә дә керде, соңгы гомерендә мәчет карты да булып йөрде. Иң мөһиме, хәләле Өммегөлсем белән ике ул, бер кыз үстереп, ил каршында да, табигать каршында да төп бурычын үтәде. Дөрес анысы, ата-баба гадәтенчә, башка чыгарып, улларын үз*

*янында, җирдә калдыра алмады. Авылда хәзер эш юк, колхоз таралды, тирә-як басуларны шәһәр байларының икешәр, өчәр катлы йортлары тутырды. Шуңа да малайлар якындагы Яр-Чынлы шәһәренә китеп урнаштылар, кызлары аталарын, аналарын карап калды. Анисының үз язмышы, үз гыйбрәте — байлар йортында җыештыручы булып йөргәндә, кияүгә чыкмыйча гына бала тапты. Кай арада үсеп җиткән диген — оныгы Камиләгә дә унҗиде яшь инде. Ул да, мәктәпне тәмамлауга, шәһәргә китәргә чамалап тора.*

*Зәкәрия карт үләргә җыенды. Карчыгы китеп барганга да ярты ел узган икән. Әле дә хәтерендә: Өммегөлсемнән соң яшәүнең кызыгы беткән кебек булды. Кинәт кенә күктә кояш сүнде, күңелдә дәрт бетте, тәннән дәрман китте... Янында кызы Наилә белән оныгы булмаса, нишләр иде икән ул; бу кадәр озак яшәмәс тә иде, мөгаен... Зәкәрия аларны үзе дә бик ярата. Шәһәргә китеп, бизнес дигән җиргә кереп, елга бер-ике мәртәбә генә кайтып киткәләгән улларына караганда да ныграк ярата. Әллә шул ярату үлемгә бирми тора микән аны? Мәхәббәт үлемгә караганда зуррак бит...*

*Зәкәрия карт үләргә җыенды. Аның якын кордашлары күптән Аллаһ катына китеп бетте инде. Элек, урам тутырып, орден-медальләрен зыңгылдатып, мәктәпкә очрашуга баралар иде. Авылның бердәнбер ветераны ул хәзер. Соңгы елларда Җиңү көнендә кәнсәләр алдында торган таш һәйкәл янына ул япа-ялгызы чыга, чүп үләне сарган сукмакта таптанып тора-тора да тын гына кайтып китә...*

*Нишләп ялгызы булсын?! Бу вакытта аны бала-чагалар сырып ала. Янәшәсендә каяндыр кояшта уңган, кыршылып беткән пилотка табып кигән Гадел булыр. Бу күрше малае белә-белгәннән бирле аның тирәсендә бөтерелә. Зәкәрия карт аның анасын да, атасын да хәтерләп, күзаллап бетерә алмый. Ниндидер үтә дә акыллы, иманлы малай ул. Олыларча акыллы, җитди. Көлми дә, хәтта елмаймый да, ахры. Әллә Ходай Тәгалә ишарәсе булып яшәүче бер изге зат ул? Гаделлек, изгелек булып яшәүче... Исеме дә Гадел бит аның...*

*Зәкәрия карт үләргә җыенды. Юк, ул үлемнән курыкмый. Үткән сугышта күп мәртәбәләр әҗәл белән күзгә-күз очрашкан өчен генә түгел. Ул үзенең бик карт күңеле белән тоя, хәтта аңлый: һәр туу — хакыйкатьне раслау ул, һәр үлем дә шулай ук хакыйкатьне раслау гына. Яшәү — үлемгә әзерләнү генә, башка берни дә түгел. Аннары... үлем котылгысыз бит. Шуңа күрә аннан куркырга һич ярамый. Курку үзе канны киптерә, гомерне өзә... Нигә куркырга? Үлү дә — яшәүнең бер мизгеле бит!*

*Үлем көтеп яткан Зәкәрия картның бу дөньяга үпкәсе юк. Ничек яшәлгән — шулай яшәлгән. Кыен чаклар булган икән — барысына да үзе сәбәпче, әйбәт чаклар булган икән — аның рәхәтен дә үзе күрә. Үпкәләргә ярамый, кем әйтмешли, үлгәч, үпкәле кешенең җаны күчеп китә алмый җәфалана, ди...*

*Зәкәрия картның бу дөньяга үпкәсе юк. Ләкин аның бу дөнья өчен бирәсе йөрәге, җаны бар... Зәкәрия карт үләргә җыенды. Баштарак акрын-акрын гына йөрештерсә дә, хәзер бөтенләй түшәк иясенә әверелде. Көненә берәр мәртәбә ишек катына барып килә дә дога китаплары белән юанып тик ята. Ара-тирә генә, ишек башына кыстырылган кайракка күзе төшеп: «Быел печән дә әзерләнми калды, яланнарым көтә-көтә зар-интизар булып беткәннәрдер инде», — дип уфтанып куя.*

*Кайчакта күршедәге карт-карчык кереп чыга яисә мәчет хәзрәтләре хәл белергә килеп җитә... Барысы да бер үк сорауны бирәләр, бер үк сүзне сөйлиләр... Аларның һәр сүзе Зәкәрия картка: «Кайчан китәсең инде, кайчан үләсең?» дигән кебек ишетелә, шуңа да ул кеше керүен бик өнәп бетерми. Кемдер әйткән бит: «Мәңгелек юлы ялгызлыкны ярата», — диген.*

*Наилә әйбәт. Камилә дә «дәү әтием» дип өзелеп-өзгәләнеп тора. Ләкин ул өйдә сирәк була. Яшьлек бит, күңелнең иләсләнгән чагы, аның үз юлы, үз язмышы дигәндәй...*

*Зәкәрия үләргә җыенды. Ул, мөгаен, шулай тыныч кына, үз җае белән мәңгелек юлына китеп тә барган булыр иде. Күптән түгел генә аның күңеленә һәм тормышына яңа гамь, борчу килеп ияләште. Әллә шул борчу аңа бу якты дөньядан кубарылып китәргә ирек бирми торамы?*

*Соңгы вакытларда күршедәге ялан-басуларда барлыкка килгән «Поле чудес» яшьләре Акбүре авылының тынычлыгын алдылар. Әле берсен кыйнап китәләр, әле икенчесенә ябышалар... Түбән очтагы ике кызны бозганнар дигән хәбәрләр дә чыкты.*

*Зәкәрия картны үлем шикләндерми. Ул инде үләргә әзерләнеп бетте. Кызы Наилә, оныгы Камилә өчен, күршедәге Гадел өчен, тагын бик күпләр өчен өтәләнә ул...*

*Милиция дә чакыртып карадылар. Якын-тирәдәге ун авылга берүзе күз-колак булып йөрүче участковый: «Нишләп тә булмый, начальник балалары!» — дип, җилкә сикертүдән узмады. Сиксән йорттан торган, тузып-таралып бетә язган Акбүре авылы балаларының язмышы көне-төне исереп, азынып-тузынып йөрүче шәһәр малайлары кулында калган бер мәлдә, Зәкәрия карт юлга җыенып бетте. Ләкин күңеле нидер сизенеп, һаман әле торып, кузгалып китәргә кыймыйча, үткәннәрен уйлап, тормышының ачысын-төчесен хәтереннән уздырып, җылы, йомшак түшәгендә ята бирде.*

### 1. Хәтәр

Зәкәрия сугышның авызында булды. Разведчик-диверсант иде ул. Ярты сугышны дошман тылында йөреп үткәрде. Күп мәртәбәләр үлем белән күзгә-күз очрашты, әмма ниндидер тылсым аны бәла-казалардан саклап килде.

Кырык өченче елда аңа Герой бирә яздылар. Ике айлык «сәяхәт»тән кайтып керүләре булды, берничә разведчикны алгы сызыкка — һөҗүм оештырырга килеп чыккан Жуков янына чакыртып алдылар. Жуковның үзен туры китерә алмаса да, фронт штабында Зәкәрияне Герой исеменә тәкъдим иттеләр. Хәтта, сорашып, әллә күпме документ тутырдылар. Ләкин барыбер бирмәделәр. Сугышчан Кызыл Байрак ордены килде. Дөрес анысы, аның белән рейдта йөргән Себер урысы Иван Соколик Алтын Йолдызын тагып йөри башлагач, кыенсынып, хәтта кимсенеп куйгалый иде Зәкәрия. Соколик дустын тынычландырмакчы була: «Син, Захар, миңа караганда геройрак, просто татарларга хәзер бирмиләр икән, шул хакта яшерен күрсәтмә килгән...» — ди.

Соколик аңа тагын бер серне ачты. Ул элгәрерәк тә: «Диверсант кешеләр күзенә күренергә тиеш түгел. Бер адәм затына гына күренсә дә, ул инде диверсанттан разведчикка әверелә», — ди торган иде. Кайсыдыр рейдтан соң ул бик борчылып йөрде. Зәкәрия сораша башлагач, барысын сөйләп бирде.

«Беләсеңме, — диде ул, утлы күзләрен Зәкәриянең җанына кадәр батырып, — без ничә кешенең җанын кыйдык бу юлы?»

Зәкәриядә исәп-хисап төгәл иде. Ничә фашист дөмеккәнлеге, ничә эшелон сафтан чыкканлыгы, күпме күпер җимерелгәнлеге хакында ул шундук әйтеп бирде.

«Ә-ә, юк шул, — диде Иван... бармагын өскә күтәреп, — корбаннар моның белән генә бетми әле. Безне күреп, белеп, танып калган, хәтта безне каршы алган кешеләрнең дә юк ителгәнен беләсеңме соң син?»

Зәкәрия аңламыйчарак торды. «Ничек инде? Безне кундырып чыгарган Степан дәдәй белән Марфа апаны да, озатып җибәреп, каршы алган сержант Самойловны да, башкаларны да үзебезнекеләр үк юк иткәнме?»

«Әйе. Законы шундый».

Зәкәрия нишләргә дә белмәде. Ары бәрелде, бире сугылды, ниһаять, үзен-үзе күралмас хәлгә килде. Сугышның никадәр хәтәр икәнен белә иде ул. Әмма бу чаклы канечкеч һәм кешелексез булыр дип башына да китерә алмаган иде.

Зәкәриянең фронт капчыгында һәрвакыт көмеш көпшәле трофей револьвер йөрде. Иван Соколик белән сөйләшкәннән соң, шул револьверын алып, ничә мәртәбәләр генә аның салкын көпшәсе белән чигәсен капшап карамагандыр… Барыбер курокка баса алмады. Авызын ыржайтып торган сугышка тагын бер корбан бүләк итәргә теләмәде ул. Хәзер дә шул револьвер, киндер чүпрәккә төрелгән килеш, чормадагы яшерен шүрлектә ята...

Күрше малае килеп кергәндә, Зәкәрия картның күз карашларыннан сугыш шәүләсе китеп тә өлгермәгән иде әле.

— Бабакай, беләсеңме, бүген сугыш булачак. Әнә җыелалар инде. Авыл малайлары «Поле чудес» бандасы белән бәрелешәчәк... Вот кызык, ә?

Зәкәрия карт берни дә аңламады. Әмма авылның ниндидер бәлагә, хәтәргә юлыкканын күңеленең иң нечкә, нәзберек кыллары белән шундук сизенеп алды.

Терсәкләренә таянып, торып утырмакчы булды. Хәле җитмәде. Тыны кысылып, тау кебек ястык өстенә шуып төште. Гадел килеп булыша башлагач, тагын бер мәртәбә көчәнеп карады, барыбер сөялеп утырудан ары уза алмады.

— Нинди сугыш? Кайда? Кем белән?

Гадел, һәр сүзгә басым ясап, һич иренмичә кабат сөйләп бирде.

— Һай-ай-ай... Нинди нәмәрсә бу? Нинди кыямәт? Туктатырга кирәк моны! Кая, бир әле миңа чөйдәге сырманы, тизрәк чыгып, акылларына күндерик үзләрен!.. Яле, бир, әнә, әнә... Шунсын!

Зәкәрия картның сырмасын китергәндә Гадел ялваргандай әйтеп куйды:

— Сиңа ярамый, бабакай, син авырыйсың... Ярамый...

— Ярамаса ярамый, ярамыйга карамый, ди идек без бәләкәй чакларда. Чыкмый булмый, балам. Башкалар да чыгарга тиеш. Чик куелырга тиеш бу хәтәргә...

— Бабакай, «Поле чудес»ларның кораллары да бар, ди. Атып үтерсәләр?.. Алар уйлап тормый, ата да куя... Беркөнне Илдарларның мунча бурасына атып уйнаганнар. Бозауларының аягына тигән... Суярга туры килгән...

Зәкәрия карт тагын да ныграк сагайды, хәтта, башын артка ташлап, берара тынсыз калып торды.

Аннары кискен генә башын калкытты:

— Алайса... бигрәк тә чыгарга кирәк!..

Ләкин ул урамга чыга алмады. Бүген тән көче, аңа ияреп җан егәрлеге дә, үч иткәндәй, әллә кая гына китеп югалган иде.

Кичке якта Гадел тагын ишек катында пәйда булды.

Бу юлы ул шатлыгын кая куярга белмичә, авызын колагына кадәр ерып килеп керде.

— Бабакай, безнекеләр җиңде! Тегеләр чак качып котылдылар. Мылтыклары да бар иде. Барыбер курыктылар...

Зәкәрия карт Гадел алып килгән шатлыклы хәбәргә куанмады. Хәтта җавап та бирмәде. Бөтен җан-йөрәге белән ыңгырашып кына куйды. Чөнки ул белә иде: җиңелгән явызлык тагын да хәтәррәк. Чын сугыш, хәтәр сугыш әле алда. Ул башлана гына...

Сугыш... Һаман сугыш... Кайчан бетә инде бу сугышлар... Мылтыклары да бар диме? Юк, бу сугыш тегесенә караганда күп мәртәбә хәтәррәк. Бу сугышны синнән соң яшәргә тиешле яңа буын үзе башлый. Димәк, киләчәк белән сугышырга туры киләчәк... Мондый сугышның мәгънәсе юк, мәгънәсе генә түгел, чиге юк, фронты юк. Әмма аның кануны шул ук: явызлык белән акыл көрәшен бары тик рух кына хәл итә ала. Әйе, явызлыкны акыл гына каплап куя алмый. Әмма сугышта рух җиңә. Шуңа күрә дә сугышта рух — язмышка тиң. Ходай Тәгалә дисезме? Рух ул — Ходай Тәгаләнең ихтыяры, әмма Үзе түгел! Чөнки Ходай Тәгалә җәза бирми, бары тик искәртә генә, кисәтә, куркыта гына...

Зәкәрия карт тыштан сөтле чиләк күтәреп килеп кергән Наиләне үз янына чакырып алды.

— Кызым, якынрак кил әле... Камилә кайда?

— Кайда булсын, урамдадыр... Үзишләре беләндер... Айрат янындадыр...

— Нинди Айрат? Кем ул?

— Кем булсын, классташы. Икенче ел инде дус булып йөриләр. Әйбәт егет.

Сүзгә шунда мыштым гына утырган Гадел кушылды:

— Беләсеңме, бабакай, Айрат абый булмаса, безенекеләр җиңә дә алмас иде. Ул берүзе өч малайны чүмәләгә өеп куйды...

Зәкәрия карт сүзен бетермәгән икән әле.

— Камиләгә әйт, еракка чыгып йөрмәсен. Айрат та сак йөрсен. Хәтәр көннәр килә, сак булсыннар... Сакланганны гына саклармын, дигән бит...

— Ярый, әткәй, әйтермен. Соңгы вакытта бигрәк соңга калып кайта әле ул. Үзем дә нык кына тиргәрмен дип тора идем, син дә әйткәч, үзәгенә үтәрлек итеп сөйләшермен. Бер-бер хәл кылып куймасыннар тагы. Әллә нинди хәтәр хәлләр башланды бит авылда. Тиле чаклары, һич кенә дә алларын-артларын карап йөри белмиләр...

Зәкәрия картның сизгер йөрәге ялгышмаган булып чыкты. Ике-өч көн яра-җәрәхәтләрен ялап, йөрәкләрен ярсытып ятканнан соң, «Поле чудес»ның бандит егетләре кабат Акбүре авылына ябырылдылар. Иң элек авыл читендәге ташландык өй янды. Аннары авыл кешеләренең абзар-куралары, мунча-келәтләре төтен булып күккә оча башлады. Ниһаять, беренче кан да коелды — сагалап торып, Айратны имгәткәнче кыйнадылар, кешелектән чыгарып ташладылар. Аның хәлсез, буынсыз тәнен машинага салып, шәһәр хастаханәсенә алып киттеләр.

Ул көнне Камилә елап-шешенеп кайтып керде. Керде дә тоташ бер тәүлек түшәгендә капланып ятты. Зәкәрия карт бу юлы оныгын юатмады, хәтта керфеген дә күтәреп карамады. Камиләнең үзе сүз башлаячагын белә иде ул.

Шулай булды да. Бераз тынычланган, күңел ярсуларын җинеп, гамьле дөньяга кайткан кыз килеп эндәшкәндә, карт оебрак ята иде.

— Дәү әтием, ә, дәү әтием!.. Син йокламыйсыңмы? Юкмы?

— Юк, йокламыйм.

— Күзләрең йомык бит...

— Күзләрем йомык булса да, күңелем ачык минем... Барыгызны да күреп, тоеп торам...

— Дәү әтием...

— Кызым... мин барысын да беләм. Сиңа бу араларда өйдә генә утырырга туры киләчәк...

— Нигә алай дисең, дәү әтием? Ә Айратның үчен кем кайтара? Без малайлар белән уйлаштык инде...

— Кызым, бүтән болай сөйләшмә, ташла бу ниятеңне. Үчнең күзләре юк. Ул — дөм сукыр. Шуңа күрә, ялгыш кына кагылса да, ул шундук харап итәчәк.

— Нишләргә соң миңа? Безгә нишләргә? Ә, дәү әтием? — Кыз тынычланырга уйламады да. Аның әрнүле, рәнҗүле карашларында чарасызлык чаткылары беленә башлаган иде инде.

— Түзәргә. Сабыр итәргә. Көтәргә. Бу хәл барыбер бер бетәргә тиеш. Дөнья тынычланырга тиеш...

— Дәү әтием! Син кайсы гасырда яшисең? Нинди дөньяда яшисең? Нинди сабырлык хакында сөйлисең син?! Авылда йортлар яна, малайлар имгәнә, кызлар урамга чыгарга курка... Ә син, түзәргә

кирәк, дисең... Болай тик утырсак, бу җирдә берни дә калмаячак. Нидер эшләргә кирәк, нидер кылырга кирәк, беләсеңме, болай ярамый!

Бу юлы да оныгының йөрәк ярсулары картның күңелен кузгата алмады.

— Милиция берни эшли алмаганны, без нишли алабыз соң, кызым? Мин нишли алам? Менә бит кыймылдарга да хәлем юк...

— Авыл малайлары барыбер сугышачак, дәү әтием. Айратның булмавы гына тотып тора. Ул булмагач, көчебез нык кимеде хәзер... — Бераз тын калып, моңсуланып торганнан соң, Камилә тагын башын күтәрде. Аның күзләрендә ике бөртек яшь һәм... көчле рух чаткысы бар иде. — Менә син, дәү әтием, илебезне яклап сугышып йөргәнсең. Бер дә, түзәргә кирәк, дип уйламагансың. Бу шундый ук сугыш. Шундый ук хәтәр сугыш. Акбүре — безнең ил. Шуңа да без аны сакларга, якларга тиеш... Бу бит бик борынгы авыл, беренче татарлар шушыннан чыккан. Мәктәптә шулай сөйләделәр...

— Әйе, без бүре нәселеннән. Ләкин барыбер дөрес түгел бу. Сугышу дөрес түгел. Өйләр яндырып, мылтыктан атып, кеше имгәтеп йөрү дөрес түгел. Монда фронт юк бит. Фашистлар да юк. Кем өчен, нәрсә өчен соң бу сугыш? Менә син, ил өчен, авыл өчен, дисең... Кайда ул син әйткән ил? Колхозны бетереп, басуларны ташландык хәлгә китергән ил — илме инде? Ярты халкы читтә, калган яртысы эчеп ята. Мәктәбен бетерделәр, балалар бакчасын кибеткә әйләндерделәр... Нинди ил бу, нинди ватан? Нәрсә өчен сугышырга? Әйт, нәрсә өчен? Кем өчен?

— Нәрсә өчен булсын? Аңлашыла бит инде...

— Нәрсә аңлашыла?

— Нәрсә дип... Белмим... Мин белмим, дәү әтием!.. Бу сугышның нинди сугыш булуын белмим!..

Бу юлы авыл малайлары җиңелде. «Поле чудес»тан төшкән утызлап малай Акбүре авылында бер кич, бер төн буе пәри туе ясап йөрделәр. Күп өйләрнең капкалары каерылды, тәрәзәләре ватылды, качып котыла алмаган унлап малай түшәк иясе булды, түбән очта торучы кызны, төне буе мәсхәрәләп, иртән генә кайтарып җибәргәннәр...

Аннары, болытларын куертып, хәтәр яңгыр килде.

Авыл өстен генә түгел, акбүрелеләрнең күңел күген дә кара хәсрәт басты... Бала-чагасыннан башлап карт-корысына кадәр кайсы кая качып беттеләр — кем, капкасына аркылы такта кагып, шәһәргә улларына китеп барды, кем күрше авылларга — туган-тумачасына сыенды... Болай да сирәкләнеп калган көтү бөтенләй чыгудан туктады, ярым җимерек ферма абзарлары бикләп куелды, ике-өч скотник, эчкә ябылып, арык малларын карап, начар көмешкәдән миңгерәүләнеп, көне-төне шунда яттылар...

Теге каһәрле төн белән генә чикләнмичә, Акбүре нәселеннән булган халыкны эзәрлекләүче әтрәк-әләмнәр һәр кичтә, авылга төшеп, әвәрә килеп йөри башладылар, меңнәрчә ел буе табигый дөнья белән дә, илаһи дөнья белән дә тату яшәгән татар авылына бер атна эчендә хуҗа булып өлгерделәр.

Зәкәрия картта бүтән кайгы — үлем кайгысы иде. Ул бу көннәрдә әҗәл белән якалашып ятты. Әҗәл аңа үткән сугыштагы фашист-мәлгуньнәр булып та, полицайлар, сатлыкҗаннар яисә үз солдатларын күрәләтә үлемгә җибәрүче генераллар булып та төшенә керә иде. Ә бер төшендә Әҗәл аңа авыл читендәге «Поле чудес» ягыннан үрмәләп килде. Елгыр, җитез хәрәкәтләр белән кача-поса килүче бу илаһи хәшәрәт аеруча нык гайрәтен чигәрде Зәкәриянең.

Кем генә килсә дә, барыбер картны чит-ят дөньяга китәргә күндерә алмады. Бер кулына печәнгә йөртә торган кайрагын, икенчесенә трофей револьверын тоткан килеш, ишек яңагына терсәген терәп, карышты да карышты ул...

Шулай да бу дөньядан бөтенләй аерылып җитмәгән әле аның күңеле. Зиһене ачылыбрак киткән мәлләрдә, шундук Наиләне яисә Камиләне чакырып ала, сораша башлый, ишеткән борчулы хәлләрне эченнән кичереп, йөзен чытып куя, ләкин, ләммим сүз дәшмичә, башын артка ташлап, көннән-көн тоныклана барган күзләрен йома... Дөнья карты булса да, үлемгә, димәк, хакыйкатькә бүтәннәргә караганда якынрак торса да, Зәкәрия карт әлегә нишләргә, ни кылырга икәнен белми. Шулай да ниндидер рухи ныклык һәм тәвәккәллек аның авыру тәнендә изаланып, үрсәләнеп яшәгән җанына көннән-көн күбрәк иңә бара иде. Мондый көч-егәрлек һәм тәвәккәллек, хәтта үҗәтлек, моңа кадәр булса да, бары тик соңгы Ватан сугышында, немец илбасарларына каршы сугышып йөргәндә генә шулай аермачык һәм максатлы булгандыр.

Дөресен генә әйткәндә, Зәкәрия карт үткән сугыштан ераклашкан саен аңа ныграк якыная бара иде...

### 2. Көчләү

«Поле чудес» малайларының һөҗүме һаман ешайды, алай гына да түгел, көннән-көн миһербансызрак, хәтәррәк була барды. Яклаучысыз калган йортларны эзәрлекләү, талау белән генә чикләнмичә, алар ялгызак хатын-кызларга, хәтта үсмер балаларга ябыша башладылар.

Бердән бер көнне Наилә ачы күз яшьләре белән елап, шешенеп кайтып керде. Башта, берни дәшми-нитми, мунча ягарга чыгып китте, аннары ниндидер үлән суы кайнатып эчте. Кичкә табан, бераз тынычлангач, барысын да сөйләп бирде. Ул өй караучы булып эшләгән йорттагы бай малае, тагын ике дустын да котыртып, аны көчләп, мәсхәрәләп җибәргән. Наилә бу хәшәрәтләр астына ятмаган да булыр иде, тегеләр аның колагына: «Югыйсә кызыңны чиратка салабыз», — дип тукып торганнар.

Зәкәрия карт Наиләнең хәбәрен авыр кабул итте. Ләкин барыбер ике дөнья чигендә яшәгән килеш калды. Үлмәде дә, терелмәде дә. Ходайдан сабырлык, түземлек һәм шәфкатьлелек сорап, догаларын укып ятты.

Кызына:

— Аллаһы Тәгалә барысын да күреп тора, кызым. Ничек тә түзәргә тырыш. Камилә хакына булса да түзәргә туры килә...

Наилә Ходай Тәгалә хакында ишетергә дә теләмәде:

— Күргәч, ни өчен бу хәтәр хәлләргә тыныч кына карап тора алайса? Чынлап та бармы соң ул? Әллә юкмы? Булса, хет аз гына булса да мәрхәмәтен күрсәтер иде!..

— Алай димә, кызым. Гөнаһысына кермә. Боларның барысын да сынау итеп кенә кабул ит. Илаһи Ходаебыз үзе яраткан, сөйгән адәмнәрне генә сыный ул...

Наиләнең хәлләрен Камиләгә сиздермәделәр. Элеккечә тыныч кына, кеше күзенә бәрелмичә, кеше теленә кермичә яшәүләрендә булдылар. Наилә, башын тотып, өч көн, өч төн түшәктә ятты да, «Поле чудес»тагы эшеннән чыгып, шәһәргә китә торган юл буена сөт, бәрәңге, алма сатарга чыгып утырды.

Кеше тәнен җәрәхәтләү, мәсхәрәләү белән генә чикләнмичә, «Поле чудес» бандитлары утлы корал белән шаяра башладылар. Баштарак каз, үрдәк ише йорт кош-кортлары күпләп кырылды, аннары көтүдәге ике мәхлук сыер кан коеп егылды, ниһаять, бердән бер көнне Чатан Шәмсиләр йортына «адашкан пуля» килеп керде, өй хуҗасының янбашын яралады. Җәйге кыска төннәрдә авыл артындагы имәнлектә мылтыктан атышкан тавышлар гадәти хәлгә әверелде, бу тавышлардан аптырап, авыл тавыклары күкәй салудан туктадылар, сыерлар кысыр калдылар...

Зәкәрия картның өйдә кадере бетте. Кызы да, оныгы да үлем көтеп яткан карт янында сирәк булалар, булганда да, эшләрен тиз-тиз генә бетереп, үз борчуларына төелеп китеп баралар. Бигрәк тә Наиләсе үз эченә йомылды, ул көннәр буе урамнан кайтып кермәде. Бәрәңге сата алмаган көннәрендә дә борчылмады, бер уч акча тотып кергән чакларда да әллә ни аһ итмәде... Яшәсәм дә яшим, яшәмәсәм дә яшим дигән кебек, тормышның ямен югалтып, дулкын өстендәге йомычкадай, салмак һәм хәсрәтле язмыш белән яшәвендә булды.

Зәкәрия карт кызы белән берничә мәртәбә сөйләшергә тырышып карады. Ләкин Наиләнең күңелен дә, тәнен дә, телен дә җан сызланулары ныклап ябып-томалап куйган иде. Кызы белән берни дә барып чыкмагач, Зәкәрия карт оныгына күчте, дога сүзе белән дә, әфсен-төфсен белән дә аны бәла-казадан, бәхетсезлектән аралап, саклап калырга теләде.

— Куль әгузе бираббил-фәләк. Миң шәрри мә халәк. Уә мин шәрри гасикыйн изә уәкаб. Уә мин шәррин-нәфәсәти фил-гөкадө...

Камилә көлә генә:

— Дәү әтием, бу догада нәрсә хакында сүз барганын беләсеңме соң?

Дәү әти булган кеше бу догада нәрсә хакында сүз барганын төгәл генә белми иде. Алай ук укымышлы түгел шул ул. Бу дога сүзенең яман күз тиюдән укыла торган дога икәнен генә белә Зәкәрия карт...

— Уә мин шәрри хәсидин изә хәсәдә. Көль әгузе бираббин-нәс. Мәликин-нәс. Иләһин-нәс. Мин шәррил-уәсуәсил-ханнәс. Әлләзи йүуасвису фи судурин-нәс. Минәл-җиннәти уән-нәс.

Камиләгә тутырып карарга да курка Зәкәрия карт. Күздә ниләр булмас. Нәрсә генә күрмәгән бит алар шушы су кебек гомердә...

Бигрәк чибәр шул кызый. Өммегөлсемгә — дәү әнисенә тартымрак. Ул да авылда бер кыз иде. Барыбер каратты аны Зәкәрия. Болынга печән чабарга төшкәч каратты. Авылның беренче чалгычы егете бул да каратма, имеш... Үзе еландай елышып килде, минсиңайтим... Ходай Тәгалә бар ул, бар. Әнә бит оныгы Камилә сурәтендә булса да күз алдында йөртә хәләлен...

Бәхете генә булсын инде. Айратны кыйнап ташлагач, бераз басынкыланып калды, ямансулап йөри башлады ул. Әллә... Әллә берәр юньсезлекне, бәла-казаны алдан сизеп борчыламы?

Зәкәрия карт авыр уйларын тизрәк төйнәп куярга ашыкты.

Менә ул, йоласына туры китереп, «яман күз» догасыннан соң өч тапкыр укылырга тиешле «Фәләк» һәм «Ән-Нәс» сүрәләрен күңеленнән үткәрде дә көзге каршында боргаланып торган Камиләгә эндәште:

— Балакай, берәр кая җыендыңмы әллә? Соң бит инде, кара аны...

— Әле без бу вакытта яши генә башлыйбыз, дәү әтием. Борчылма, яме. Синең укыган догаларың мине бөтен-бөтен әшәкелекләрдән саклар, менә күрерсең дә торырсың... — Чыгып китәм дигәндә генә, ишек катына җиткән Камилә тагын бер мәртәбә дәү әтисен ирештереп алды. — Бүген иске клуб каршында дискотека була, әйдә, минем белән чыгасыңмы?

Камилә, гомердә булмаганча, көлә-шаяра чыгып китте, аның артында ишек ябылырга өлгермәде, Гадел килеп керде. Керде дә, исәнләшеп тә тормыйча, Зәкәрия картның аяк очына килеп - утырды.

— Нәрсә, бию буламыни бүген?

Малайның җавабы баш кагудан узмады.

— Ыһы.

— «Дискәтик» дигәне нинди нәрсә соң аның?

— Әй... Селкенеп торалар шунда...

— Сиңа ошамыймыни?

— Юк, ошамый.

— Алай икән... Авылда ниләр бар соң?

— Һаман шул инде. «Поле чудес»лардан куркып яталар.

— Һаман атышалармы?

— Атышалар... Кичә үр буеннан мәчет аена атып уйнаганнар. Пуля тиеп, манара башындагы ай кыйбла яктан читкә борылган, ди... Бер дә әйбәт нәрсә түгел, ди, бу... Хаммас абый менеп төзәтмәкче булган, егылып төшеп билен кузгаткан... Бүтән менүче булмаган... Хәзер картлар мәчеткә барырга да куркалар икән. Кичә җомга намазы да булмый калган. Ае кыйблага карамагач, дөрес булмый, ди...

— Мәхшәр көн шушы була микәнни?

— Минем әби дә шулай ди. Бабакай, нәрсә соң ул — мәхшәр? Ә кыямәт, ахырзаман нәрсә? Шул вакытта бөтен кеше җирдән кубарыла, ди, дөресме шул? Әби әйтә, гөнаһлар күп булганга шулай була, ди... Барыбыз да кубарылып китсәк, җир нишләр? Ә, бабакай?

Зәкәрия карт күрше малаена җавап кайтарганчы, иң элек эченнән ихлас сөенеп куйды. Аның кебек борчылып яшәүче тагын бер җан иясе бар икән әле. Юк-юк, гади малай-шалай гына түгел, бәлки, ниндидер акыл иясенә, пәйгамбәри затка тиң адәм баласыдыр бу... Ходай Тәгалә сабыйлар теле белән сөйләшә, диләр иде, шушылай була икән...

— Һи, мәхшәрне күрергә язмасын, балам. Изге китап сүзе булса да, тормыш мантыйгына бер дә сыешып бетми ул. Күңел теләгән нәрсә түгел, диюем. Ходаебызның куркытып кукы кебек кенә... Ә бит ул бик акыллы; мин сезгә кысылмыйм, үз хәлегезне үзегез күрегез, ди. Мин бары тик сезнең күңелләрегезне иман нуры белән яктыртам, сез шул иман яктысында үз язмышыгызны үзегез хәл итегез, ди... Белмим шул, мәчет аена мылтыктан ата башлагач, адәм баласын иман нуры гына коткара алыр микән? Ходай үзе төшсә дә авырга туры киләчәк әле монда... Төшмәс шул, аның үзенең дә гайрәте чигеп барадыр инде бу адәм балаларыннан...

Гаделгә Зәкәрия картны аңлау кыенрак иде бугай.

Шулай да ул, бөтен дөньяны сискәндереп, дөрес сорау бирде:

— Алла әйбәт булгач, нигә соң Ул «Поле чудес» малайларын тыймый? Нигә күрми ул аларның нәрсә эшләгәнен?

— Шулай сыный ул үзенең адәми затларын. Җирдә үк Сират күпере аша үткәреп карый…

— Кемне? Безнеме? Әллә «Поле чудес»тагыларнымы?

Бу юлы Зәкәрия карт аптырабрак калды. Шулай шул, кемне күбрәк сыный соң Ходай Тәгалә? Акбүрелеләрнеме, әллә теге килмешәк әтрәк-әләмнәрнеме?

Бу сорауны җавапсыз калдыруың хәерлерәктер. Зәкәрия карт бик яхшы аңлый: илаһи сынау кешенең канын кою, җанын кыю аша эшләнергә тиеш түгел. Һәр кыелган җан — ул инде үзе үк җәза, йә гыйбрәт, йә… искәртү!

Зәкәрия картның хәле авыраеп китте. Ул борчулы уйлардан, борчулы тормыштан тәмам арыган иде.

Шулай да, хәлсез сулышын җыеп, соңгы сорауны бирә алды:

— Нинди йомышың бар иде соң, балам?

— Камилә апа хакында әйтергә кергән идем.

— Нәрсә булган Камилә апаңа? — Карт дөньяның үзе кебек авыр керфекләрен күтәрде.

— Аңа «кара кәрт» чыккан, дип сөйләнделәр. «Поле чудес»тагылар авылга хәбәр җибәргәннәр. Шуны әйтергә кергән идем...

«Кара кәрт»нең нәрсә икәнлеген аңлап бетермәсә дә, Зәкәрия карт үзенең догалы, Аллаһлы күңеленә ниндидер билгесез, үтә дә шомлы, хәтәр бер шаукымның ургылып керә баруын тойды. Ул, тагын нидер сорамакчы булып, чыгып киткән Гадел артыннан кузгалып, торып утырмакчы булган

иде дә, буынсыз, тынсыз калып, тагын түшәгенә авып төште. Үзенең уйларында булса да нидер кылырга, каядыр барырга, кемгәдер зарланырга, кемнәндер ярдәм сорарга теләде. Авылларына, гаиләсенә төшкән афәт гүя аның кадакланган кебек үлем түшәгендә ятуыннан тора кебек иде.

Зәкәрия карт бу юлы да төне буе саташып чыкты. Ләкин ул бүген чын разведчик кебек тавыштын чыгармыйча, эчтән генә кичереп, борчылып, үрсәләнеп ятты, шуңа күрә дә аның күңел ярсуларын чоланда урын әмәлләгән Наилә дә, мәчет бакчасында исерек байбәтчәләрнең җирәнгеч тәннәре астында бәргәләнгән Камилә дә ишетми калды...

Зәкәрия төне буе, үзенең фронтташ дусты Иван Соколик белән бергә, бөтен ялан-кырны тутырып килүче немец-фашистларга каршы атышып чыкты. Ябырылып килүче дошманның иге-чиге юк, шуңа да карамастан Зәкәрия белән Иван үз траншеяларыннан чигенмиләр, окоп каршында калыккан һәр фашистны берәмләп чүпли торалар...

Шул вакыт Зәкәрияләр янына каяндыр Камилә килеп чыкмасынмы?! Өс-башы, йөз-битләре канга, пычракка буялып беткән. Үзе хәлсез тавыш белән: «Әйдә инде, дәү әтием, кайтыйк, мин шундый арыдым, авырдым, кайтыйк инде!» — ди. Зәкәрия әйтә, имеш: «Әнә бит, әле күпме дошманны дөмектерәсе бар, ничек кайтыйм инде?» — ди. Камилә берни дә әйтми, окоп читенә чүгәләп, яшьле керфекләрен йома...

...Кызның мәсхәрәләнгән, көчләнгән гәүдәсен иртә белән мәчет артыннан табып алдылар. Җаны чыгам-чыгам дип торган сылу тәнне шундук, машинага төяп, Яр-Чынлыга озаттылар, аңа ияреп, Наилә дә хастаханәгә китеп барды. Зәкәрия карт, мәңгелек белән күзгә-күз карашып, япа-ялгызы торды да калды. Аның үлемгә бу кадәр якын килгәне юк иде әле. Соңгы сәгате сугар алдыннан адәм баласына илаһи көч кереп ала, диләр, дөрес икән, Зәкәрия карт та, оныгы хакында ишетү белән, шундук сикереп торып утырды, бушап, котсызланып калган өй эчен бер мәртәбә сөзеп, күздән кичереп чыкты да, җәһәт кенә кузгалып, киенә башлады...

## 3. Фронт

Зәкәрия карт, яшьрәк чагында, Җиңү көне җитү белән, сугыштан киеп кайткан, күп юудан агарып-уңып беткән гимнастеркасын киеп чыга иде. Бүген ул шул гимнастеркасын эзләп тапты. Түрдә эленеп торган яңа костюмыннан орден-медальләрен салдырып, шул гимнастеркасына күчереп такты. Биленә солдат каешын буып, чал башына тараебрак калган пилоткасын киеп куйгач, чып-чын фронтовикка охшады да куйды Зәкәрия карт. Ул бу минутта көчләнеп ташланган оныгы хакында да, җәберләнгән, бәхетсезлеккә дучар ителгән кызы, мәсхәрәләнгән, түбәнлеккә төшерелгән авылы, бүре нәселеннән килеп тә, эт типкесендә яшәүче татары, шул татарның иң борынгы бишеге булган туган җире хакында да уйларга тырышмады. Зәкәрия картның нәфрәт тулы йөрәгендә үч гаме генә калган иде. Иң мөһиме, ул бу минутта нәрсә эшләргә кирәген төгәл белә иде. Дошманының кем икәнен белә. Чын сугыштагы кебек!

Менә ул түшәк читенә утырып бераз хәл алды, сулышын тигезләгәндәй итте, аннары, тиз-тиз генә чоланга чыгып, чормага менеп китте, сугыштан алып кайткан револьверын эзләп тапты, аны сөрткәли-сөрткәли тагын өйгә керде. Стенада эленеп торган сурәтләр каршына килеп басты. Үрелеп, кытыршы, авыр эштән чатланып, гарипләнеп беткән бармаклары белән Өммегөлсемнең фотосын сыйпап куйды, аннары бишесе бергә төшкән «бәхетле фото»га озаклап карап торды. Буыннары йомшап, тагын түшәгенә чүкте, тәне белән түгел, күбрәк җаны, күңеле белән хәл җыйды...

Зәкәрия карт бу минутта дога укырга кирәклеген белә иде, ләкин ул бүген Аллаһы белән араларга теләмәде, дөресен генә әйткәндә, ул Аңа үпкәле, хәтта ачулы иде. Аныңча, шулкадәр догада утыруына, Ходай Тәгалә аңа һәм аның гаиләсенә мәрхәмәтлерәк, шәфкатьлерәк булырга тиеш иде, бәхетле үк итмәсә дә, аларны бөтенлектә һәм иминлектә яшәтергә тиеш иде... Картның сугыш гаме томалаган күңелендә илаһи хисләргә урын юк иде, ләкин бу әле аның күңелен иман ташлап киткән дигән сүз түгел; ул илаһи тойгы бары тик авыр үч, бетмәс-төкәнмәс нәфрәт хисе белән томаланып, бастырып куелган хәлдә иде.

Бил каешына револьверын кыстырып, аркасына юл капчыгы асып урамга чыгып баручы Зәкәрия картка әлеге дә баягы Гадел очрады.

Ул үлем түшәгендә ятучы картны хәрби киемнәрдә күреп, тәмам каушап калды, хәтта, бер як читкә тайпылып, аны үткәреп җибәрде, шуннан соң гына, ис-акылына килеп:

— Бабакай, син кая? — дип сорый алды.

Картның тавышы көр, карары нык иде:

— Фронтка, балам, фронтка!

Гадел инде иркенәеп сөйләшерлек хәлгә килгән.

— Сугыш күптән беткән бит инде, бабакай, шуны да белмисеңмени? Фашистлар юк хәзер...

— Фашистлар беткән, менә сугыш бетмәгән...

— Бабакай, шундый кызык! Мине дә иярт әле,ә?

— Синə ярамый. Син яшь əле. Бар, өеңə кайт, сөйлəндереп вакытымны алма...
Һəркемнең үз юлы шул, үз язмышы. Аны адəми зат кына билгели алмый.
Зəкəрия карт нык адымнар белəн фронтка чыгып китте, бераз арткарак калып, аңа Гадел иярде. Алар, бер-берсенə бəйлəнгəн кебек, Акбүре авылының үрге ягына чыктылар, язгы су төшкəндə убылып, яргаланып калган ерганак-ярлар янына килеп чыктылар. Авылның чиге нəкъ шушыннан үтə. Окоп-траншеяларны хəтерлəткəн бу кара чокырлар үзлəре үк сугышка чакырып торган кебек, гүя алар сугышның нəрсə икəнен белəлəр, ул гына да түгел, аны сагынып көтəлəр...
Бер елны Казаннан археологлар килеп, җəй буе казынып ятканнар иде. Нəкъ шушы чокырларда əллə күпме чүлмəк ватыклары, ук очлары, пычак, хəнҗəр ише əйберлəр таптылар. Бүре башы, аның артыннан ук бүре тешлəреннəн тезелгəн дисбе килеп чыккач, үзлəренчə нəтиҗə ясадылар. «Акбүре нəселе шушында сугышкан, димəк, бу авыл — татарның иң борынгы иле», — дидfestival.
Зəкəрия карт үзе артыннан ияреп килүче малайга күзлəрен кысып, болай да сырланып беткəн йөзен тагын да ныграк җыерып карап-карап алса да, аны кире борып җибəрергə кыймады. Аннары ул белə иде: сугышта иптəш кирəк, дөресрəге, япьтəш кирəк. Үткəн сугышта Зəкəриянең Ваня дусты — Иван Соколигы бар иде. Гадел аның белəн тиңлəшə алмый, əлбəттə. Əмма батырлыкта, зирəклектə аңардан ким дə түгел...
Фронтовик, чын окопны хəтерлəткəн, чирəмлекне кеше буе чокып кергəн бер уйсу ярны сайлап алды да урнашу ягын кайгырта башлады: үрелеп күзəтү өчен аяк астына кəслəр түшəде, «окоп» алдына да берничə кəс куйды. Анысы бруствер була инде. Күзəтү пунктларында шулай була иде — шушы ике кəс арасындагы ачыклыктан көннəр буе дошман позициялəрен күзəтеп ятасың, минсиңайтим, күзлəр чəчрəп чыгардай була, биллəһи!
Позиция мəсьəлəсен хəл итеп бетергəч кенə Зəкəрия карт билендəге каешын салды, көмеш көпшəле трофей револьверын яр читендəге чирəмлеккə куйды, кулъяулыкка төрелгəн бер уч патронын да шунда ук урнаштырды.
Янəшəдəге яр читендə утырган Гадел барысын да аңлап-төшенеп алган, күрəсең, бераз мыштым гына карап-күзəтеп торгач, Зəкəрия картның каршына ук килеп, олыларча əйтеп куйды:
— Əле алар йоклыйлар. Кичке якта гына торып чыгалар...
Карт гүя ишетмəде дə. Ул үзенең сугышчан позициясен камиллəштерү белəн мəшгуль иде.
Малай аның дəшмəвен аңлашу билгесе итеп кабул итте, ахры, тəмам үз булып, Зəкəрия картка фронтташ, көрəштəш булып сөйлəп китте.
— Бездə ау мылтыгы бар. Əйткəйдəн калган. Аның унике патроны да бар. «Финка» да бар, анысын үзем таптым, көтү көткəндə. «Поле чудес» малайларыннан төшеп калган. Апкилимме? — Инде сүзе беткəч, тагын җанланып, картның револьверына ишарəлəп əйтеп куйды. — Моның белəн генə каршы торып булмаячак. Аларда корал — менə моннан! — Гадел нəни учларын баш түбəсенə кадəр күтəрде. — Кирəк икəн, үзем дə ата белəм мин...
Карт бу юлы да дəшмəде. Ул үз тирəсендə бөтерелеп йөргəн бу күрше малаен ишетми дə кебек. Аның бөтен күңеле, күз карашлары авыл читеннəн үк башланып киткəн «Поле Чудес» бистəсендə. Биек коймалар артыннан берсен-берсе узып калыккан бу ике-өч катлы йортларда нииндидер котсыз, яман затлар яши кебек. Алар кинəт кенə килеп чыгарлар да бистə белəн авыл арасындагы барлы-юклы бер чакрымны чабып үтеп, мең ел торган Акбүре иленə ябырылырлар сыман... Юк, бу юлы тиз генə ала алмаслар. Наилəне дə, Камилəне дə, башкаларны да бүтəн бирмəячəк аларга Зəкəрия! Ул бүгеннəн явызлыкка, вəхшилеккə, кешелексезлеккə каршы сугыш ачты. Явызлык белəн иминлек арасында, үлем белəн яшəү арасында фронт бар хəзер. Утлы позиция бар... Бу фронт белəн гвардия сержанты, биш сугышчан орден, җиде медаль кавалеры, разведчик, «смертник» Зəкəрия Вəлиəхмəтов командалык итə. Аның командасында кеше күп түгел. Дөресрəге, ул үзе генə. Аннары Гадел исемле малай бар. Ул фронт командующиена əйбəт ярдəмче була ала. Их, Иван Соколик булса! Ыһ та итмəс иде Зəкəрия, дошманына туры карап яуга күтəрелер иде. Исəн микəн ул? Бер күрешеп, сөйлəшеп тə булмады, ичмасам. Сугыштан соң бергə кайтканнар иде югыйсə. Казанда юллары аерылды, Ваня Төмəн ягына китеп барды, Зəкəрия — үз авылына. Адреслар да алмашканнар иде, язмыштыр инде,— ул язулы кəгазьне Казан вокзалында очраган иң беренче патруль алып калды. Шикле адрес, янəсе. Төмəнгə барып, нинди диверсия корырга йөрисең, янəсе. «Дустымның адресы ул»,— дип тə карады. Ышанмадылар. Бер көн каталажкада тоттылар да, частеннан уңай хəбəр алгач, чыгарып җибəрделəр. Тик барыбер адреслы кəгазьне бирмəделəр. Хəтта укытмадылар да. Бер күз төшерү белəн исендə калдырыр иде югыйсə…
Зəкəрия карт уйларын уйлап бетерə алмый калды, каяндыр Гаделнең йомшак, əмма олыларча җитди тавышы ишетелде:
— Бабакай, мин авылга кайтып килдем. Синең хакта Ибраһим абзый белəн Исмəгыйль абыйга да əйттем. Аларның малайларына да «кара кəрт» чыккан…

— Син боларны каян беләсең соң, малай актыгы?! — Гаделнең белдекле булып кылануы, ниндидер сәер мавыгу белән «үлем уены»на керә баруы Зәкәрия картны шактый ук үрти башлаган иде.

— Каян булсын, бөтен кеше сөйли… Менә әткәйнең мылтыгын да алып килдем, «финка»ны да… Кирәге чыгар әле…

Бу юлы «фронт командующие» малайны ачуланмады, авыр мылтыкны алып, затворын тартып карады, көпшәләрен тикшерде, курокка басып алды, аннары бруствер өстенә — револьверы белән янәшә куйды, Гадел сузып торган патроннар янчыгын да, дәшми-нитми генә алып, мылтык белән револьвер арасына урнаштырды. «Финка»ны алмады, кире малайның үзенә бирде. Эшнең аңа кадәр үк барып җитмәячәген белә иде ул.

Тагын бер мәртәбә үзенең сугышчан позициясен күзаллап, өйрәнеп чыкканнан соң, Зәкәрия карт, окоп читенә чүгеп, аркасын үлем салкынлыгы бөркеп торган кызыл балчыкка терәде…

Соңгы ун-унбиш елда беренче мәртәбә аның үтереп ашыйсы килде. Ул кесәсенә тыгылды, юл капчыгын капшап чыкты, әмма ирен читенә куярлык та ризык таба алмады…

— Гадел балам, ашарга юнәтәсе иде безгә.

— Ә мин юнәттем инде. — Гадел шунда ук аркасындагы мәктәп сумкасын салып чирәм өстенә куйды, тезләнеп, актарынырга кереште, сөт тутырылган шешә, берничә пешкән йомырка, кабыклы бәрәңге һәм кыяр-помидорлар чыгарып куйды. Иң ахырдан кып-кызыл ике алма алды. Окоп эченә тәмле, хәтта татлы табигать исе, яшәү исе таралды…

Зәкәрия карт бәхетле иде. Аның иреннәренә ризык тәме кайтты. Ул бу минутта яланга җил алып килгән бөтен хуш исләрне дә сизә, яшәүнең ямен, дөньяның гамен тоя башлаган иде…

Көч-егәрлеге, дәрт-дәрманы, яшьлеге шулай кабат кайттымы әллә? Әллә рәнҗетелгән якыннары арасындагы җан һәм кан бәйләнешләре шулай аның гомерен озайттымы? Әллә... Әллә күңелен томалап алган чиксез, чамасыз нәфрәт, дошманнарыннан үч алу тойгысы аны көчле, бәхетле итәме?

Зәкәрия картның күңел ярларында бу тойгыларның барысы да бар, ә менә илаһи догалар аша иңә торган изгелек әлеге давыллы, шаукымлы күңел дәрьясының иң ерак чоңгылларына төшеп яткан иде...

Кеше тормышында шундый минутлар була: бервакыт ул төштәге кебек кенә яши башлый. Зәкәрия карт белән дә шулай булды, ахры. Корал тотып «фронтка» чыкканнан бирле ул гүя үз тормышы белән яшәми, икенче бер адәм баласының язмыш юлына төшеп, бөтенләй чит-ят гомер яшәп ята... Шуңа күрәдерме, Наилә белән Камилә дә бик борчымый кебек аны, бары тик авылга каныккан бандитлар өере белән канлы, хәлиткеч сугыш гаме, көрәшкә генә түгел, җиңүгә ымсыну хисе яшәтә, ахры.

Гадел сакта торган арада, Зәкәрия карт, «окоп» читенә чүгәләп, черем итеп алды.

Ләкин «фронт командующие»на озак юанырга туры килмәде, «часовой» аны сак кына төрткәли башлады:

— Бабакай... Киләләр...

Зәкәрия шушы хәбәрне көтеп кенә торган диярсең, яшьләрчә җәһәт кенә сикереп торып, гимнастерка чабуларын тарткалый башлады, изү төймәләрен эләктерде, пилоткасын рәтләде. Аннары «окоп» алдында яткан коралларын сыйпаштырып алды, шуннан соң гына карашларын «Поле чудес» ягына күчерде.

Баштарак ул беркемне дә күрмәде. «Поле чудес»ның мәһабәт йортлары бөтен офыкны шыплап тутырып, томалап куйганнар иде. Шул мәлдә Зәкәрия картның зиһенен бер сукбай уй сызып үтте: «Бүгенге байлар йортларын ни өчен тау кадәр итеп салалар икән дисәм, әйе шул, күп бүлмәле, иркен, якты булсын өчен түгелдер, бүтәннәр алар янында үзләрен кечкенә итеп, мескен итеп, түбәнсетеп тойсыннар өчендер...»

Әнә алар... Унлап егет, кулларындагы шешәләрдән сыра чөмерә-чөмерә, йөз кешелек шау-шу, ыгы-зыгы куптарып, авылга алып керә торган бердәнбер юл буенча киләләр иде.

Бу гайре табигый күренештән Зәкәрия карт йөзен чытып куйды. Аннары яр читенә таянып калкынды да «фронт сызыгы»н күзәтә башлады.

Карап торышка шундый ук адәм балалары — авыл малайларыннан берни белән дә аерылмыйлар. Ә кыланмышлары... Кыланмышларында адәми затларның әсәре дә юк. Барыбер алар да инсан нәселеннән, аларның да өйләрендә өзелеп көтеп торучы аналары бардыр, зур, җаваплы эшләрдә эшләүче аталары бардыр, сөйгән ярлары, дус-ишләре, яраткан шөгыльләре, укый торган китаплары, җырлый торган җырлары, хыяллары бардыр...

Ә бәлки... болар өчен бер генә изге әйбер дә калмагандыр?..

Шул вакыт каяндыр җир төпкеленнән, әллә күк катыннанмы, онытгы Камиләнең кайтаваз кебек кенә тавышы ишетелгәндәй булды. «Кызганма син аларны, — ди иде бу тавыш. — Алар мине төне буе интектереп, газаплап чыктылар, сафтин-саф тәнемне, ихластин-ихлас җанымны мәсхәрәләде-

ләр... Алар яшәргә тиеш түгел, дәү әтием... Ходай эшли алмаганны үзең эшлә — дөмектер шуларны. Минем хакка дөмектер. Ялварып, ялынып сорыйм...»

Зәкәрия, үзен-үзе белештермичә, җәһәт кенә револьверын алып, дошман ягына төбәп тә куйды. Ләкин шундук, кулы пешкәндәй, кире тартып алды, утлы коралын чирәмгә ташлады. Аннары, окоп төбенә тезләнеп, якында гына яткан чыбык сыныгын алды да очына ак кулъяулыгын бәйли башлады. Менә ул бәйләп бетерде, торып басты, кабат револьверын алды, аны баш очына күтәреп, һавага атып җибәрде. Шуннан соң гына, ак кулъяулык бәйләнгән чыбыкны болгап, окоп читенә менәргә талпына башлады. Бу кадәресенә түзеп торган Гадел аның янына йөгереп килеп тә җитте.

— Китер, бабакай, үзем сөйләшергә барам. Сиңа ярамый...

— Нишләп ярамасын?! Менә сиңа ярамый. Син бала гына әле. Бәласеннән баш-аяк...

— Сиңа ярамый! — Малай олыларча үҗәт иде. — Син китсәң, «фронт» буш кала. Аннары... командирлар парламентер була алмый. Кинода күргәнем бар — дошман белән сөйләшергә гел аларның ярдәмчеләре йөри.

— Анысы шулай... Курыкмыйсыңмы соң?

— Ник куркыйм ди... Мин аларны болай да көн саен күреп торам. Нәрсә дип әйтергә соң?

— Нәрсәме? — Зәкәрия карт кешелекләрен югалткан бу яшьләр өеренә ни-нәрсә әйтергә икәнен әлегә белеп бетерми иде. Мылтык аткан тавышка сискәнеп, юл очында туктап калган дошманга төбәлгән килеш, ниһаять, нәрсә әйтергә кирәклеген уйлап тапты.— Акбүрене фронтовик Зәкәрия Вәлиәхмәтов саклый, әйбәтлек белән кире үзләренең «Чудес»ларына кайтып китсеннәр. И бүтән монда күренмәсеннәр. Шулай дип әйт, Зәкәрия Вәлиәхмәтов тора, диген. Гвардия сержанты, диген... Аңладыңмы? Нәрсә сөйләргә онытмассыңмы? Яле, әйтеп кара!

— Аңладым инде, бабакай, нәрсәсен кабатлап торырга аның... Вакыт та юк, әнә тегеләр бу таба килә башладылар... Тизрәк бир ак флагны, киттем...

— Гадел балам, сак кылан, яме. Синең белән минем җаным да китә. — Җиргә тезләнеп, Зәкәрия карт малайның күзләренә тутырып карады. — Теге сугышта булса, мин сине үз отрядыма алыр идем, ей-богу, боец... Гадел...

— Рядовой Гадел Исламов!

— Рядовой Гадел Исламов...

— Разрешите идти?

— Разрешаю...

— Есть!

«Поле чудес» егетләре очына ак чүпрәк бәйләнгән таяк күтәреп килүче малайны сәерсенеп каршы алдылар. Шулай да килгән уңайга куып та җибәрмәделәр. Күренеп тора: Гадел сүзне сөйләшә белә. Ләкин килмешәк егетләрнең түземлеге чиксез-чамасыз түгел иде, ахры, алар берәм-берәм дә, парлап та малайга уктала башладылар. Кайсыдыр, кесәсеннән пистолет чыгарып, янап та куйды. Ниһаять, сүз алып барганы, атаманнарыдыр инде, Гаделне төрткәли башлады, бер-ике мәртәбә суккалап та алды. Гадел аңа игътибар да итмәгән кебек, авылга төбәп күрсәтә-күрсәтә, үз сүзен сөйләвендә булды.

Ниһаять, ул кайту ягына борылды. Аның артыннан кемдер шаркылдап көлеп, кемдер сүгенеп, янап калды. Ә берсе, Гадел бераз китү белән, пистолетын алып, малай артыннан ата башлады. Гадел «Зәкәрия фронты»на таба йөгерергә тотынды.

Бу хәлгә «фронт» битараф кала алмый иде инде. Зәкәрия карт револьверын төбәп атып җибәрде. Гадел артыннан атып калган егет, сул кулы белән уң янбашын тотып, сыгылып төште. Аның янына башкалар йөгереп килде. Яралы дусларын килгән юллары буенча «Поле чудес»ка таба алып та киттеләр. Үзләре, авыл ягына карап, йодрык күрсәтә-күрсәтә кычкырырга, янарга да онытмадылар...

Бераздан авыл белән бистә арасында үлем тынлыгы урнашты.

— Кайтып киттеләр... — Шунда Гадел үзенең исән икәнлеген сиздереп куйды.

Карт, сискәнеп, малайга табан борылды, җәһәт кенә кузгалып, аның сипкелле йөзен күкрәгенә кысты, аркасыннан сөеп тәкрарлый башлады:

— Сугыш әле башлана гына... Башлана гына... Башлана гына...

Зәкәрия карт белә: яралы ерткыч хәтәррәк. Сугышның башы гына әле бу, фаҗигаләрнең башы гына...

Чынлап та, ярты сәгатьләп вакыт үтәр-үтмәс, әллә кайлардан гына берәмтекләп тә, төркем-төркем дә «Поле чудес» капкасы янына ир-егетләр җыела башлады. Күбесенең кулында мылтык, обрез ише кораллар, тимер кисәкләре, күсәк тотканнар да бар...

Менә алар, өч төркемгә бүленеп, иелә-бөгелә Зәкәрия белән Гадел тоткан «фронт сызыгы»на табан килә башладылар. Егермеләп булыр...

— Егерме өч. — Гадел санап та өлгергән икән.

Зәкәрия хәлнең мөшкел булуын аңлап алган иде инде. Аның ул кадәр патроны да юк. Ул чаклы патронны атасы да килми аның. Әнә берсен яралады да инде. Исән калса гына ярар иде. Акылга утырса, шул җитә. Юк, болар акылга утырырга охшамаганнар. Әнә бит ничек киләләр. Сугышта «СС» дивизиясе солдатлары гына шулай акырып-бакырып киләләр иде.

Урталыктагы төркемне башы кырып алынган, киң җилкәле бер егет алып килә. Аның кычкырып команда бирүе аермачык ишетелеп тора.

— Уратып алыгыз, уратып!.. Исән калдырмагыз, үзе казыган окобына терелəй күмегез!

Зәкәрия карт, озаклап төбәп торды да курокка басты. Теге атаманга охшаганы, чалгы белән чапкандай, җиргә кыелып төште... Чәчрәп барып төшкән башлыкларын күреп, калганнар бермәлгә каушап, тукталып калдылар, әмма шундук, кем ятып, кем тезләнеп, тәртипсез рәвештә атарга керештеләр.

Берничә пуля Зәкәрия картның колак очыннан гына сызгырып үтте. Ул моңа әллә ни игътибар итмәде. Ләкин, кызыксынуын баса алмыйча, үрелеп ялан ягына карарга маташкан Гаделне ярның төбенә үк төртеп төшерде.

Атыш кызганнан-кыза барды. Зәкәрия карт, бөтен шартын китереп, позициясен алыштырды. Ике атып, тагын бер дошманны җиргә чүгәргә мәҗбүр итте. «Их, бер патрон әрәм китте»,— дип баш чайкап куйды.

Сугышта һәрвакыт шулай: рух җиңә, кеше җиңелә. Егермеләп дошманга берүзе каршы тора алмаячагын белә Зәкәрия карт. Бу сугышның соңгы сугыш булуын аңлый. Шуңа да ул үзен тыныч тотты. Түшәктә ыңгыраша-ыңгыраша җан биргәнче, дошман белән көрәшеп башны салу — мең мәртәбә әйбәтрәк!..

Кинәт кайдадыр якында гына — авылның уң як очында — мылтык аткан тавыш ишетелде. Зәкәрия карт шундук чамалап алды — авыл ягыннан аталар. Димәк, Акбүрене якларга тагын кемдер чыккан...

— Ибраһим абзый бу, әйттем бит, ул да кушылачак, дип... Хәзер барып киләм.

Гадел, тирән ярга ышыкланып, уң як күршедәге «фронт»ка китеп барды, Зәкәрия исә, атып, тагын бер әзмәверне җиргә кадалдырды.

Ул арада сул якта да кемдер ата башлады. «Монысы Исмәгыйль булырга тиеш,— дип уйлап алды карт.— Аларның йортҗире шул якта... Молодец Гадел! Тыңлата алган бит, ышандыра алган!»

Шул вакыт Зәкәрия картның култык астын нидер чәнчеп алды. Карт ыһ итеп куйды да тагын фронт гаменә бирелде, инде шактый якынаеп өлгергән дошманга соңгы патроннарын атты. Аннары кулына Гадел күтәреп килгән ау мылтыгын алды. Әмма берничә мәртәбә атуга, аяк астында җир убыла башлады; менә ул хәлсезләнеп «окоп» читенә чүгәләде, карашларын кызыл кабер балчыгына төбәп тынып калды.

Юкка чыгып торган Гадел килеп җитмәсә, нишләр иде икән ул? Шулай япа-ялгызы чокыр төбендә җан очырган булыр иде, мөгаен. Янында Гаделнең кабат пәйда булуы Зәкәрия картка хәл кертеп җибәрде. Ул тырыша-тырмаша кабат торып басты, мылтыгына үрелде...

Сулышын тигезли алмый торган Гадел «рапорт» бирергә ашыкты:

— Бабакай... Иптәш... сержант... Рөхсәт... итегез...

— Ниләр бар анда, балам? «Фронт» нишли, нык торамы? — Зәкәрия картның тавышы хәлсез иде.

— «Фронт» үз урынында... иптәш сержант... Ибраһим... абзый белән Исмәгыйль абыйлар үз «окоп»ларында геройларча сугышалар. Бөтен авыл белә бу хакта. Озакламый халык сугышка кузгалачак. Хәзер ду килеп корал җыялар...

— Менә монысы кирәкмәс иде. Күрәләтә ут эченә керү кирәкмәс. Безгә ярый — без фронтовиклар... Бар, кайтып әйт үзләренә, бу якта ялгыш та күренмәсеннәр...

— Бабакай, ни сөйлисең син?! Патронсыз-нисез сугышып була димени? Менә Исмәгыйль абый ике патрон бирде, бүтән бирә алмыйм, диде...

Гадел тагын каядыр китеп барды. Зәкәрия карт кабат үз урынына басты, ун-унбиш адым читтәрәк кенә мылтыгын төзәп булашкан таза гәүдәле, тулы битле, кысык күзле егеткә атып җибәрде. Атуын атты, әмма үзе дә, буынсыз булып, «окоп» төбенә шуып төшеп китте... Шулай һәр аткан саен аның хәләл каны, каны белән бергә яшәү көче дә кабат кайтмаслык булып чыгып бара иде...

Гомердә булмаганча, Зәкәрия картның бик тә, бик тә яшисе килде. Бу соңгы сугыш аның карт, авыру тәнендә, арыган, талчыккан, гаҗизләнгән күңелендә шулкадәр көчле яшәү дәрте уяткан иде, дымлы,салкын чокыр төбендә канга батып утырган килеш, кызы Наилә, оныгы Камилә, шәһәрдә уллары белән узачак бәхетле гомерен күз алдына китерергә тырышты...

Шул мәлдә вакыт тукталып калды һәм серле, сихри мәңгелек башланды... Ә мәңгелектә кеше гел бәхетле. Үлеп барган фронтовик карт бу минутта үзенең никадәр бәхетле булуын белми дә, тоймый да иде. Ул көрәштәшләре Ибраһим белән Исмәгыйльнең «Поле чудес» бандитлары тарафыннан

атылып үтерелүләре хакында белмәве белән бәхетле иде. Авыл тыкрыкларының берсендә күзенә пуля кереп, канга батып яткан, соңрак дөм сукыр калачак Гадел хакында белмәве белән дә бәхетле иде ул. Шулай ук оныгы Камиләнең аңына килә алмыйча җан тәслим кылуын, кызы Наиләнең, акылыннан язып, тилеләр йортына җибәрелүен, анда санитарлар тарафыннан кочләнеп, өченче каттан ыргытылуын белмәве белән дә бик бәхетле иде. Меңьеллык Акбүренең, перспективасыз авыл дип, җир йөзеннән мәңгелеккә юк ителүен, халкының көчләп Яр-Чынлыдагы иске тулай торакларга күчерелүен, авыл урынына затлы коттеджлар төзелүен дә күрми, белми калды Зәкәрия карт. Ул шуның белән дә бәхетле иде...

**Эпилог**

*Кайчандыр Акбүре авылы торган үр куенында бүген дә ике истәлекле урын бар. Икесе дә авылның чит-ят куллар кагыла алмый торган бердәнбер җирендә — иске зират эченә урнашкан. Аларның берсе — каберстандагы мәһабәт мәрмәр таш. Аның төн кебек кара йөзлегенә, чокып: «Татарның иң борынгы авылы» дип язылган. Шунда ук тагын язу: «Татар яугирләренең Явыз Иванга каршы соңгы сугышлары булган урын».*

*Икенче истәлек ташы фронтовик, гвардия сержанты Зәкәрия Вәлиәхмәтов истәлегенә, аның кабере өстенә куелган. Җыйнак кына ак таш. Язуы да бар: «Дошман белән алышта һәлак булган соңгы ветеран Вәлиәхмәтов Зәкәрия Мөхәммәтгали улы» диелгән.*

*Бу кабергә еш кына өч ир кеше кайта. Аларның икесе — гүр иясенең үзенә бик охшаганнары — аңлашыладыр, мәрхүмнең үз уллары. Өченчесе — кара күзлек киеп, кулына озын таяк тоткан — кайчандыр шушы авылны яклап сугышка чыккан Гадел исемле малай булыр. Хәзер кем ул? Кайда? Ничек? Янына барып сорашасы килә. Әмма үтә дә җитди ул, хәтта усал да кебек... Бу начар түгел. Түгел! Әле усал булырга туры киләчәк. Әле күпме сугышлар булачак, күпме соңгы сугышлар!.. Батырлык, тәвәккәллек, үҗәтлек бик тә кирәк булачак татарга.*

*Күзләр дисезме? Татарның маңгай күзе күптән сукыр инде. Ләкин аның күңел күзе маңгай күзләреннән дә әйбәтрәк күрә, әйбәтрәк тоя... Аның моңлы, гамьле булуы да шуннан килә, күрәсең...*

*Бердәнбер көнне бу өч кешегә дүртенче берәү — ап-ак чәчле, шундый ук ак, куе мыеклы, зирәк, әмма моңсу карашлы карт килеп кушылды. Фронтовик. Ветеран. Герой. Түшендәге орден-медальләрнең исәбе-хисабы юк. Инде аңлашылгандыр, Зәкәрия Вәлиәхмәтовның фронтташ дусты Иван Соколик бу. Соңгы юлга чыгып китәр алдыннан, җан дусты белән саубуллашу өчен, кайчандыр күңел дәфтәренә язып куйган адресын табып, мең чакрым ара үтеп килгән. Килгән дә монда булган хәлләрне ишетеп таң калган. Аның күзләреннән туктаусыз яшь ага. Бу яшьтә күз яше буламыни, дисезме? Яшь түгел ул, җан ул, җан! Күз яше булып җаны суырылып ага аның, гомере ага...*

*Менә ул, тирә-яктагыларны сискәндереп, кызу-кызу чишенә башлады. Плащын салды, шарфын чишеп элде... Ботак-чатаклы бармаклары белән нәкъ күкрәк өстендә балкып торган Алтын Йолдызны эзләп тапты, аны җәһәт кенә ычкындырып, Зәкәрия Вәлиәхмәтовны үз куенына алган чирәм җир йөзлегенә куйды. Һәм җан тавышы белән иң кирәкле сүзләрне әйтте:*

*— Прости меня, друг! Я хочу к тебе!*

*2005*

## *БӨКРЕ*

*(Бәян)*

* * *

Тын гына, беркемгә начарлык кылмыйча, япа-ялгызы яшәп ятучы Бөкре хакында бу әсәр. Аның беркеме дә, хәтта атасы белән анасы да юк. Дуслары да, сөйгән яры да…

Бөкре бит ул. Бөкрегә кем туган булсын да, кем дус булсын?! Бөкреләрнең никахлашкан кешеләре дә, гаиләләре дә булмый. Алар яшәгән җирдә көзге-мазар да таба алмассың. Шайтан төкреге белән йөгертелгән пыяладагы килбәтсез чагылышыңа карап, йөрәгеңне әрнетүдән ни мәгънә?! Көзге булмагач, Бөкренең гарип, иләмсез кыяфәте дә юк сыман. Җайлы, шулаймы? Калганы ул кадәр мөһим түгел. Күренми, шуның белән вәссәлам!

Ә менә исеме бар микән? Бардыр, Бөкре булса да, кеше, Адәм баласы ласа ул! Инсани зат! Аннары… исемгә көзге кирәк түгел бит. Исемнең йөзе, кыяфәте, бөкресе дә юк…

Шулай да исеме ничек икән аның? Бөкре… Бөкре? Нишләп Бөкре булсын?! Әйттем бит, андый исем булмый, дидем. Берәр пәйгамбәр исемедер әле…

Исемгә көзге кирәк түгел, аңа күңел кирәк. Кеше исеменең чагылышы — аның күңелендә. Кеше булуның иң югары дәрәҗәсе дә шунда —исемен аның күңеленнән табып, укырга, танырга өйрәнүдә…

Үзе бөкре, килбәтсез, ямьсез булса да, исеме матурдыр аның. Ә нигә ул килбәтсез, ямьсез булырга тиеш әле? Юктыр, бөкрелек ямьсезлек билгесе түгелдер. Күнекмәгәнгә генә шулай килбәтсез, сансыз булып күренәдер ул. Ә бәлки, ул иң гүзәл кешедер. Башкалар гариптер, ямьсездер? Сез аның ашыгып китеп барган чагында артыннан карап калыгыз. Очып, очынып барган кебек ул, гүя иңнәрендә пар канатлар бар! Шундук уйлап куясың: бөкрелек  изгелек билгесе түгелме? Борынгы китапларда язылган бит: кеше бөкресендә Ходай Тәгалә яши, диелгән…

Бөкре ул. Канатлы. Изге. Тик… ялгыз. Бәхетсез түгел — ялгыз. Изгелек ялгызлык белән бергә йөри. Ул моны тоеп белә. Шуңа күрә аның беркемгә дә ачуы юк. Үпкәсе юк. Зарланмыйча, сыкранмыйча, рәнҗемичә, кинәт күктән төшкән кебек кенә үзенең тар бүлмәсендә берүзе яшәп ята…

Бөтенләй үк япа-ялгыз түгел икән әле ул. Аның белән өмет яши. Хыял дип әйтмәс идем. Хыял ул — зуррак, мөһимрәк, татлырак. Хыял ул ерактарак. Бөкре белән тыйнак кына, басынкы гына өмет яши. Бөкре аны әлегә күрми дә, ишетми дә, бары тик тоя гына. Якында икәнен тоя. Өметнең мәрхәмәтле, игелекле һәм мәхәббәтле булуын тоя…

Бу сүз юктан гына тел очына килеп кермәде, әлбәттә. Әйе, Бөкре үзенең өметен генә түгел, мәхәббәтен дә тоя, бу мәхәббәт хисенең үз яшәешен, язмышын төбе-тамыры белән үзгәртәчәген белеп тоя…

* * *

Ул бүген иртәрәк чыкты. Тукталышка халык җыелып өлгергәнче, берәр иркенрәк автобуска утырырга иде нияте. Шыплап, дыңгычлап тутырылган машина эчендә кысылып, бәрелеп-сугылып барудан да хәтәррәк газап бар микән? Бәлки, башкаларга алай ук тоелмыйдыр да, ә менә аркасында өркәче тырпаеп торган Муса өчен андый газап — үлемгә тиң. Эшенә барып керүгә үк сизә ул бу юл галәмәтен — иңнәре, янбашлары сызлауга түзә алмыйча, башын ташка бәрердәй була…

Ә аның эшендә башны бәрердәй генә ташлар бар. Ташчы булып эшли бит ул. Йортлар сала. Шәһәр төзи. Начар эш түгел. Көне буе һавада. Кеше күзеннән читтә. Раствор, кирпеч биреп торган Зәрия ападан башка кеше белән юньләп сөйләшкәне дә юк аның. Менә ул, ичмасам, барысын да аңлый…

Муса тукталышка җитеп килә иде инде. Янәшәдәге йорт тәрәзәсеннән үзенә төбәлеп карап торучы мөлаем йөзгә тап булды, нәрсәгәдер килеп төртелгән кебек, сөртенеп туктап калды… Нинди йөз бу? Кем йөзе? Ник карый? Нигә аңа карый? Бөкре күргәне юкмы әллә? Юктыр шул, шуңа карыйдыр. Каравы бер хәл. Ничек карый бит: көлеп карыймы, әллә хәленә керепме?

Муса моны шундук аерып бетерә алмады. Моңсу карый… Шулай да, көлеп, кызык табып яисә мыскыллап карамый. Урамдагы һәр ике кешенең көлеп китүенә күнеккән инде ул. Төртеп-төртеп күрсәтүчеләр дә аз түгел. Ә бу кыз моңсуланып, сагышланып, хәтта бераз гына үз итеп карый…

Шулай алар озак кына карашып тордылар. Бер-берсеннән кыенсынмыйча, оялмыйча, үзләре генә белгән серле уйларга, татлы хисләргә бирелеп, ниндидер билгесез гомер, хәтта язмыш кичереп тордылар…

Муса соңга кала иде. Тукталышка да әнә бер көтү халык җыелып өлгергән. Бүген дә көне буе аркасы, бөкресе сызлап интектерәчәк икән…

* * *

Икенче көнне дә кыз шул урында иде. Муса ерактан ук икенче каттагы таныш тәрәзәгә карап килде. Күңеле җилкенеп, йөрәге ялкынсынып, дулкынланып килде. Сөенеп килде. Бәхетле иде ул. Чынлап та, әллә бәхет шушындый була микән — әнә бит, үз итеп, көтеп тора…

Менә аларның карашлары тагын очрашты. Кыз елмаеп куйды. Ләкин бу елмаю гына аның ак йөзендәге моңсулыкны юып ала алмады.

Муса да елмайды. Тагын елмайды. Тагын… Кыз исә моңсу карашлары белән карап торды да торды. Ниһаять, бу карашлар, бу моңсу йөз Мусаның күңеленә барып ирешге. Ул үз хисләреннән сискәнеп уянып киткәндәй булды. «Нигә елмайсын ди, нигә көлсен?! Бөкрегә карап елмаеп, көлеп була диме? Шуңа да моңсу ул. Бөкрегә карап моңсу гына булып буладыр шул…»

Муса, үзен-үзе белештермичә, сынын турайтмакчы булды, ияген чөеп, башын күтәрде… Тик… барыбер тураеп баса алмады, аркасындагы дөнья кебек авыр йөк һаман әле башын идермәкче, буйсындырмакчы булып тарткалаша иде…

Бу юлы да бөкре үзенең иясен җиңде. Муса, тән авыртуына чыдый алмыйча, сынын, иңбашларын, кулларын үз иркенә җибәрде, аннары бөтенләй алга сыгылып төште һәм, аркасында калкып чыккан «тауга» ышыкланып, алпан-тилпән тукталышка йөгерде…

* * *

Бу хәлләрдән соң Муса автобус тукталышына урау сукмактан йөри башлады. Аркасындагы сызлаулар бетеп, күңел тетрәнүләре басылган кебек тоелды. Ләкин һәр иртәдә тәрәзәсеннән карап калучы кызны ул һич оныта алмады. Онытырга теләмәде дә. Бары тик хәтеренең ерак почмагына салып куйды да, бик кирәк чакта гына табып алып, күңелен юата торган булды…

Ә беркөнне үзе дә аңлап бетерә алмый торган эш эшләде Муса. Әллә нинди урау юллар белән теге таныш йорт каршына килеп, мул ябалдашлы юкә агачы артына барып басты. Бөтен булган күз нурларын төбәп, юк-юк, күз карашларын гына түгел, күңел күзләрен төбәп, таныш, кадерле һәм газиз тәрәзәгә күтәрелеп карады…

Кыз һаман шул урында иде. Тик ул элеккечә моңсу гына түгел, борчулы, хәтта кайгылы кыяфәттә иде. Үзе бертуктаусыз як-ягына карана, тынгысызланып, борчылып, Муса йөри торган юлны күзәтә…

Мусага бик тә, бик тә кызганыч тоелды ул. Үзе дә сизмәстән, алгарак омтылды, кызның каршына ук чыгып басмакчы булды. Ләкин иң соңгы мәлдә нindидер көч аның чабуыннан тотып алып калды, җиргә «кадаклап куйды». Дөресрәге, нindидер уй. «Ә бәлки, ул Мусаны көтмидер, башка берәүне карыйдыр» дигән уй иде ул.

Муса хәйләгә кереште. Урабрак килеп, үзенең гомер буе таптаган сукмагына төште. Теге таныш кыз басып торган тәрәзә турына якынлашты. Менә ул аның белән тигезләште, адымын кызулатып, тизрәк узып китмәкче булды… Ләкин… сихри бер шаукымга буйсынып, өскә күтәрелеп карады! Карады да ах итте. Тәрәзәдән менә инде күпме гомер таныш мөлаем йөз тутырып карап тора иде. Бу карашта әллә нинди серле ишарәләр бар иде…

Кызның бәхетле елмаюына Муса шундый ук шат елмаю белән җавап бирде, аның тыйнак кына кул болгавына җавап итеп, учларын күкрәгенә куеп, башын иде…

* * *

Мусадагы үзгәрешне эшендә бик тиз сизеп, күреп алдылар. Бигрәк тә Зәрия апасы бер минут та тынгылык бирмәде.

— Нәрсә булды, Муса? Син бүген бөтенләй башка кеше. Атлап түгел, очып йөрисең димме?..

Муса дәшми. Елмаеп тик тора. Нәрсә дисең? Бер кыз белән таныштым, ул миңа ошый, дисенме? Көләчәкләр генә… Аннары, сөйләрлек берни дә юк бит әле. Тәрәзә бар, ул тәрәзәдән карап торучы якты, күркәм йөз бар, елмаю бар… Дөресен генә әйткәндә, Муса үзе дә аңлап-аңышып бетерә алмый — чынмы соң бу, әллә берәр хыялый шаукым галәмәтеме? Кешене үзенең бөкресе саташтырып йөртә, диләр бит…

Муса, ямьсез, шомлы уйларын читкә куып, тагын тәрәзәдәге кыз хакында уйлый башлады. Үзе уйлый, үзе кирпеч тезә. Бүген аның эше гөрләп бара. Зәрия апасы измә ташып өлгерә алмый.

Битәрләпме битәрли:

— Тукта инде, кая болай ашыгасың? Тын алырга, артны төртергә дә вакыт бирмисең… Юк, малай актыгы, синең белән нидер булган, әнә бит бөтен җаның, җаның гынамы соң, җенең кузгалган…

Мусаны барыбер сөйләндерә алмады ул. Ләкин бу кирәк тә түгел иде.

Зәрия үзе үк аның күңелен ачып салды:

— Серле-тылсымлы бер хәлгә юлыккансың син, акыллым. Күңелеңә кагылганнар синең. Кайчан, ничек — сорап та тормыйм. Тылсымның сәбәбе юк аның, изгелекнең, яратуның да сәбәбе юк. Күреп торам: җаның дулкынлана синең, ай-һай дулкынлана… Ә беләсеңме, үз җаныңны тоя башлыйсың икән инде, димәк, син гашыйк булгансың…

Мусага бөтен күңел җылысын биреп, йөз нурларын балкытып елмаюдан башка чара калмады.

* * *

Мусаның тормышы үзгәрде. Ул бүтән дөньяда, бүтән үлчәмдә яши башлады. Аның тормышы гына түгел, уйлары, максатлары, яшәвенең мәгънәсе үзгәрде. Күпне күргән Зәрия апасы белеп әйтте: мәхәббәт ул — җанның иң югары үлчәнеше… Аның бу сүзләре яңа, моңа кадәр беркем дә искәрмәгән мәгънә белән әйтелде: изгелек матурлыктан матуррак!

Муса иң элек кеше буе көзге алып кайтып куйды. Үзен баштанаяк карап, өйрәнеп чыкты. Өр-яңадан киенде, төзәтенде, тәрбияләнде.

Ләкин иң элек күңелен тәртипкә китерәсе бар иде аңа. Ничек яши ул? Ни өчен, нинди уйлар, максатлар белән яши? Әти-әнисен хәтерләми. Алар аның балачагында ук торып калганнар. Кайсыдыр бабасында үскән ул. Бабасы үлгәч, балалар йортына тапшырганнар. Баштарак бөкресе дә булмаган. Әллә егылганнан соң, әллә кыйналганнан соң кинәт үсә башлаган. Ишеткәне дә бар — андый бөкре, ничек чыккан булса, шулай кинәт кенә бетәргә дә мөмкин, ди… Әллә аның бөкресе хәзер дә

юкка чыгып тора микән? Әнә бит ничек карый ул кыз! Елмаеп, балкып карый. Бөкре, гарип кешегә болай карамыйлар… Әллә, өстән караганда, аның бөкресе күренмиме?

Муса гомерендә меңенче мәртәбә үзенең гариплеге хакында уйланды. Әмма бу уйларында бер бөртек курку, шом да юк иде. Чөнки аның күңелендә яралган олы, якты, кешелекле хис бу шомнан зуррак, көчлерәк иде. Һәм ул яшәргә булды, яратырга, яратып, үз өлешенә тигән бәхетенә ирешергә булды…

Беренче мәртәбә аның күңел кешесе, тормыш пары барлыкка килде. Алар хәзер көн дә очрашалар, баш кагып, елмаеп исәнләшәләр, озаклап карашып торалар, аннары кулларын болгап аерылышалар. Кичке якта тагын күрешәләр, бераз карашып торганнан соң, иртәнгә кадәр саубуллашалар…

Икенче каттагы тәрәзәдән карап торган ул таныш йөзнең һәр чалымын, һәр нур бөртеген, яшәү күзәнәген белә, таный хәзер Муса. Татар кызыдыр ул… Алар гына толымнарын калын итеп үрәләр. Алар гына кашларын шулай «айлатып» сызалар; күзләрендәге сафлыкны, ихласлыкны да түкмичәчми бердәнбер кешеләре өчен саклыйлар…

Читтән карашып, яратышып торуларга гына риза булмыйча, беркөнне Мусаның йөрәге үзенең пары белән күрешүне таләп итә башлады. Ләкин йөрәге дәртенә тулышып ярсыган саен, аның күңеле тынгысызлана гына барды; үз янына чакыра калса, кызның баш чайкап кире кагуыннан курыкты ул.

* * *

Күңелендәге шик-шөбһәләр хакында ул Зәрия апасына сөйләде.

Анысы бер сөенде, бер көенде, ләкин тынычландыра алмады, Муса күңелендәге шөбһәләргә яңаларын гына өстәде:

— Бәй, ничек була инде бу? Берәр нәрсә эшләргә кирәк алайса… Әйдә, әзерлән, мин сине Зәмзәмбану карчыкка алып барам. Өшкертеп карарга кирәк бу бөкреңне. Гомер буе аркаңа капчык асып йөрмәссең бит инде… Белеп калсалар, кызлар да аһ итеп тормас…

Икенче көнне үк Муса филле чәй белән исле сабын кисәге юнәтте дә, Зәриягә ияреп, тирә-якта даны чыккан имче карчыкны эзләп китте.

Ләкин Зәмзәмбану карчыкның им-томы Мусага ошамады. Нәрсә инде бу? Учларын алдына җәеп, бер-ике тапкыр Мусаның баш түбәсеннән сыпыргандай итте дә, кесәсеннән кырык бер ногыт борчагы санап алып, аркасына сипте. Аннары, иреннәрен медер-медер китереп, идәнгә чәчелгән борчакларны берәмтекләп җыя башлады. Монысына да түзәргә булыр иде, карчыкның әйткән сүзләре сискәндерде аны.

— Балам, синең өркәчегең сихердән түгел, Ходайдан, — диде ул, төкеренә-төкеренә, соңгы борчакны кесәсенә салып куйгач.— Аңа минем көчем генә җитми. Ходай Тәгалә өлеше бу. Аның ихтыяры. Мин кысылмыйм… Шуны гына әйтәм: бөкре дә түгел ул. Синең канатларың алар. Фәрештәләрдә генә була андый канатлар, бик сирәк кенә адәм балаларында да ярала… Юк-юк, бөкре түгел, җыеп, төреп куелган канатлар синдә…

— Хәзер нәрсә эшләргә инде безгә? — Зәрия, «безгә» дип, бу хәлнең бөтен кеше өчен дә олы борчу булуын искәртеп әйтте.

— Нишләргә икәнен бер Ходай Тәгалә үзе белә. Әйттем бит: Аның ихтыяры бу. Ләкин шул да мәгълүм булсын: мондый канатларның иясе очарга яратылган. Очып карарга тиеш ул. Ә моның өчен иң элек күңелдә, җан түрендә канатлар яралырга тиеш…Тагын шуны да онытмагыз: канатлар очканда гына ачыла… Бүтән берни дә әйтә алмыйм…

Зәмзәмбану карчыктан яңа җан тынгысызлыгы, күңел борчулары алып чыктылар. Шул булды.

Зәрия дә, хәлнең никадәр катлауланып киткәнлеген аңлап, Мусаны тынычландырырга ашыкты:

— Нәрсә белә соң ул сихер карчыгы?! Канатлар дигән була бит… Хәлләреннән килмәсә, шулай юк-бар сөйләнеп котылалар алар…

* * *

Муса төнен тәмам миңгерәүләнгәнче уйлап чыкты. Иртә белән генә йокыга китте. Эшенә соңга кала язды. Ләкин, ничек кенә ашыкса да, үзенең юл буендагы мөлаем танышын күрмичә китә алмады.

Әнә ул көлеп-елмаеп көтеп тора. Гүя кичә кич аерылышканнан бирле шунда торган...

Беренче мәртәбә Мусаның күңелендә көчле тойгы уянды. Җанында тулып чайпалган кайнар дулкыннар йөрәген иркәләде... Кызны күрәсе килү, аның кулларына, йөз-битенә кагылып, сыйпап назлыйсы килү теләге иде бу. Назлап кына калмыйча, бу кызны кысып кочаклап, шашып-тилереп үбәсе килде Мусаның...

Учлары белән тәрәзә өлгесенә таянып, сузылып-сузылып Мусага карап торучы кызны куллары белән үрелеп, тын-сулышы белән суырып алыр иде ул. Яисә аның янына үзе очып менәр иде. Әнә бит имче карчык нәрсә ди: канатларың бар, ди. Димәк, ул оча ала?

Үзе дә сизмәстән, Муса, аяклары белән этенеп, басып торган урынында сикергәләп куйды. Кулларын кыз ягына сузып, тагын бер өскә омтылды. Тагын, тагын... Ләкин канатларын як-якка ничек кенә җәяргә, шул канатларын җилпеп очып китәргә тырышса да, җирдән аерыла алмады...

Егетнең сәер гамәлләре кызга мәзәк тоелды, ахры. Ул, учлары белән авызын каплап, пырхылдап көлеп җибәрде. Муса сизеп, белеп тора: мыскыллап түгел, яратып, үз итеп көлә ул…

Очып менә алмагач, Муса кызның үзен аска, урамга чакыра башлады. Кыз, аңламаган кебек, елмаеп торуында булды. «Әйдә, төш монда, хәзер үк төш!» — дип кычкырып та карады Муса...

Ниһаять, кыз аның ишарәсен аңлады. Аңлады да, шундук көлүеннән туктап калды, йөзенә элеккеге моңсулык йөгерде. Менә ул, елап җибәрергә җыенган сабый кебек, чыкмыйм дип баш чайкады да нәни учлары белән йөзен каплады...

* * *

Бүген Мусаның эше эш булмады. Тәрәзәдән карап торучы кызның чыкмыйм дип баш чайкап торуы күз алдыннан китмәде. Шулай үзалдына уйланып, кәефсезләнеп йөргәндә, ялгыш басып, әллә ничә мәртәбә аска егылып төшеп китә язды.

Аларның бригадасы хәзер өченче катны бетереп килә. Бу йортны аеруча тырышып салалар, чөнки аны үз трестларында эшләүчеләр өчен төзиләр. Өйләнгәннәргә фатир бирәләр, ди.

Зәрия апасы, әллә көлеп, әллә шаяртып, Мусага гел әйтеп тора:

— Әйдә, акыллым, бу йортны өеп бетергәнче өйләнеп куй, ичмасам, түбәле булып калырсың, — ди.

Каян килеп өйләнсен ул?! Бөкрегә кем чыксын?! Аның аркасына «канатлар» дип язылмаган бит. Ул канатларны әнә теге кыз да күрмәде әле. Аның янына төшеп, сөйләшеп торудан да кимсенде, түбәнсенде хәтта.

Их, ул канатларны як-якка җәеп җибәреп булсын иде! Менә шулай, менә шулай!..

Муса, сикереп торып, кулларын як-якка сузып җибәрде, аяк очларына күтәрелде, сынын турайтты һәм, менә хикмәт, бөкресенең бетә баруын тойды. Әллә шулай тоела гынамы? Хыяллар, уйлар шулай канат булып үсеп чыкканмы? Әгәр чынлап та канатлар үссә? Бәлки инде алар бардыр да? Шуларны җилпеп-җилпеп, менә хәзер аска очып төшеп китсәң иде!..

Бу уй бик татлы булып тоелды Мусага. Ымсындыргыч булып тоелды. Менә ул, ике кулын якягына сузып торкан килеш, яңа гына салынган, измәсе дә катып өлгермәгән таш стена читенә килеп басты. Күзләрен йомды... Соңгы уен уйлады... Ул уй бик моңсу, хәтта шомлы иде: «Канатларым булса — очармын, булмаса да үкенечле түгел; ул кыз барыбер минем янга төшмәячәк... Мин бит бөкре, бөкре, бөкре!..»

Уйлап та бетерде, хәл итеп тә куйды.

Мусаның йөзенә җиләс җил килеп бәрелде. Җилне тоя бит ул! Тоя... Димәк, канатлары бар аның, бар! Канатлары булмаса, ничек очар иде ул?! Оча ул, оча! Бер дә бөкре, гарип түгел, канатлы ул, канатлы! Ка-нат-лы! Ы-ы-ы!..

* * *

Муса ике ай хастаханәдә ятып чыкты.

Аны үзе сала торган кирпеч стена буендагы ком өеме өстеннән табып алганнар. Аркасы белән төшеп, умырткасына зыян килгән. Шулай да, аягына басачак, кеше булачак, ди. Бу хакта Зәрия бөтен дөньяга әйтеп чыкты, үзе исә көн саен Муса янына килеп, хәлен белеп йөрде, аның тамагын тавык шулпасыннан, сөт-каймактан өзмәде...

Мусаның хәле шәптән түгел иде. Көннәр буе түшәмгә карап, сызланып, сыкрап ята. Килеп йөрүчеләргә дә әллә ни игътибар итми. Шулай да, Зәрия килеп керүгә, тырышып елмаеп куя, аннары тагын күзләрен йома. Шулай күзләрен йомып, хәтәр сызланулардан котылып калырга тели ул. Их, тән сызлауларына ничек тә түзәр иде әле, күңел сызлавына, җан әрнүенә ничек түзәргә соң? Әнә бит ничек килеп чыкты: канатлары да үсмәде, бөкрелегеннән дә котыла алмады. Түшәк иясе булып ята, шул булды...

Ләкин Мусаның газапланып борчылулары юкка булган икән. Тагын бер атнадан иртәнге обход ясаганда, врачлар үзара пышан-пышан сөйләшеп, йөгерешеп йөри башладылар. Сәгать саен кереп хәл белешеп торучы өлкән шәфкать туташы шундук серне ачып чыгып китте: имеш, Мусаның бөкресе кими башлаган. Моны врачлар үзләре дә аңлата алмыйлар, ди. Әгәр болай барса, ул, бөкре дигәннәре, имеш, бөтенләй дә бетәчәк икән...

Әлбәттә, Муса бу сүзгә ышанып җитмәде. Әнә бит ул, бар, бар! Аркасын телеп-телеп сызлый... Бетәргә дә, кимергә дә уйламый... Бу кадәр сызлауга ничек бетсен соң ул?!

Теге ай кашлы кыз турында уйламаска тырышты Муса. Бер уйны гына куып җибәрә алмады: «Хәзер дә шул урынында тәрәзәсеннән карап тора микән? Һаман көтә микән Мусаны? Юл очыннан күзләрен алмыйча үрелеп-үрелеп карый микән? Берәр бәндә белән бутап, аңа да елмая микән, артыннан кул болгап кала микән?.. Бу кешенең Муса түгеллеген белгәч, йөзләрен чытып борчыла микән? Аннары, исенә төшереп, теге вакытта урамга чыкмавы өчен үкенә микән?..»

Ул иртәдә Муса яткан палатада авыруларга караганда врачлар күбрәк булгандыр. Алар төркем-төркем дә, берәмләп тә Муса янына керәләр, аның хәлсез гәүдәсен әйләндереп-әйләндереп карыйлар, торып утырырга, басарга кушалар, тагын яткызалар...

— Нишләтәләр мине алар? — Муса бу галәмәт хакында үз янына хәл белергә килгән Зәрия апасыннан сорамый булдыра алмады.

— Бөкрең беткән, ахры, синең, балам. Шуңа чабышалар. Каяле, кая, кеше-кара күргәнче, үзем дә тотып карап калыйм. Сөбханалла-машалла!..

Аркасындагы җиңеллекне Муса тагын ике атнадан — аягына басып, таякка таянып йөри башлагач кына сизде. Җиңеллекне сизде, әмма иңбашындагы «йөк»тән арына алмады. Әллә шуңамы, ул сөенергә ашыкмады, бөкресе шул килеш калган кебек тоелды аңа. Башкалар нишләптер аны күрмиләр, әллә күрергә теләмиләрме? Сызлавы да басылмый... Әллә басылганмы? Бәлки, хәзер аның бөкресе сызламыйдыр да, күңеле, җаны сызлыйдыр... Канатлары сызлыйдыр...

Муса үзенең яңа тәненә озак күнекте. Врачлар, һаман бөкрәеп йөрүен күреп, тиргәп китәләр, хәтта үзләре үк аның сынын турайтып, башын күтәреп куялар. Ләкин Мусаның гәүдәсе элеккеге торышын «сагына», врачлар күздән югалу белән алга бөгелеп үз иркендә яши башлый...

* * *

Хастаханәдән чыккан сәгатьтә үк Муса тукталыш каршындагы таныш йортка төбәп китте. Ул инде үзенең яңа халәтенә күнегеп килә; бу юлы да, менә күрегез, мин хәзер бөкре түгел, нәкъ сезнең кебек үк дигәндәй, башын югары тотып, очраган һәр кешенең күзенә туры карап, җилкенеп, очып диярлек барды. Гүя аның аркасындагы канатлары ниндидер тылсым белән, сихер белән юкка чыккан да кабаттан күңелендә яралган...

Кыз үз урынында иде. Бер тамчы үзгәрмәгән. Шул ук толымнар, шул ук кашлар, карашлар, күзләр... Юк, күзләре үзгәргән... Аларда сагыш, моң күбәйгән. Гадәти сагыш кына түгел бу, югалту сагышы, өметсезлек, чарасызлык сагышы...

Мусаны күреп алуга, бу сагыш тамчылары аның матур күзләреннән яшь булып атылып чыктылар. Чыктылар да ап-ак йөзен, алсу, сусыл иреннәрен чылатып бетерделәр.

Муса, кулын болгап, сәлам бирде. Елмаеп, баш какты. Кыз исә кайнар күз яшьләре булып аккан сагышын тиз генә басып куя алмады, шулай аптырап, тәэсирләнеп торган килеш, кулы белән ишарәләп, Мусаны үз янына менәргә чакырды.

Муса баштарак һич аңлый алмады, шулай да подъезд ягына төртеп күрсәтте. Кыз башын кагып җөпләгәч кенә, дәррәү кузгалып, ярым ачык ишеккә юнәлде, ике-өч сикерүдә икенче катка менеп җитте һәм сөйгәне, бәхете яшәгән ишеккә барып төртелде. Бермәлгә тын калып, ярсу йөрәгенең дәртле тибешен тыңлап торды, аннары нык адымнар белән эчкә кереп китте...

Ниндидер нурлы, әкияти бер дөньяда пәйда булды ул. Киң, иркен бүлмә түрендә олы, якты тәрәзә. Аның нәкъ урта турына куелган тимер кыршаулы биек урындыкта, йомгактай йомарланып, бала йөзле гарип кыз утыра. Куркынган күзләрендәге салкын карашы бәгырьләрне өтеп-өтеп ала: «Менә инде мин... Нигә кердең, нигә боздың безнең мәхәббәтле, бәхетле тормышыбызны?»

Мусаның күкрәк турында — нәкъ йөрәк янында нидер чәнчеп куйды. Әллә бу хәлләрнең барысын да күтәреп бетерә алмыйча йөрәге сызлады, әллә инде бу мәлдә аның иңбашында өр-яңа канатлар яралып килә иде...

*2005*

## *ӘТКӘЙНЕҢ СУГЫШ КӨНДӘЛЕГЕ*

*(Повесть-хатирә)*

* * *

Минем әткәй — сугыш баласы. Яшьтән ятим калып, сугыш авылының бөтен кыенлыкларын җилкәсендә татыган кеше. Сугыш чорында күргән авырлыклар хакында сөйләргә

яратмый ул, ара-тирә генә, бигрәк тә үткәннәр хакында уйланып, моңаеп утырганда, кинәт ачылып китә, малайларын үз тирәсенә җыеп, күңелен түгә башлый…

Бу хатирәләр әнә шул моңсу, әмма үтә дә изге минутлардан җыелып калганнар.

*Автор*

## 1. Кара акчарлак буламы?

Безнең авыл сугыш башланачагын белә иде. Борын-борынгыдан шул мәгълүм: хәтәр яу алдыннан төрле хикмәтле хәлләр башлана икән. Кандай кызарып кояш баеган чакта, аулак юлларда, кешеләр каршына ак кием кигән чибәр затлар очрый башлый. Үлем, Әҗәл шулай чыга, имеш. Еш кына ул матур кыз кыяфәтендә була, ди. Кырык беренче елның җәй башында күрше авылдагы Мәмәт картка шундый бер чибәркәй очрап, сугыш булачагын әйтеп киткәч, халык берара гөжләп алды. Кешеләр күңеленә «Халыклар атасы иптәш Сталин да туктата алмас микәнни бу сугышны?» дигән шик керә башлады…

Миңа — унике яшьлек малайга да килеп күренде ул «сугыш хәбәрчесе». Яманкул чокырындагы күлгә балык тотарга барган идем. Агыйдел ягыннан акчарлаклар кергәли ул күлгә. Бу юлы да берничәсе очкалап үтте; балык күзлиләр инде, беләм. Ләкин суга тигән кош күренми. Бик сәер тоталар бүген үзләрен. Ниндидер сер бар монда…

Ул серне мин бик тиз шәйләп алдым. Чем-кара акчарлак иде ул. Дөресе — «карачарлак». Бөтен кош шуның тирәсендә бөтерелә. Ниндидер шаукымы, сихере бар кебек аның. Тавышы да икенчерәк, шомлырак димме — ничектер карлыгып, ярсынып чыга…

Акчарлакларда балык кайгысы юк иде. Алар ниндидер уен уйнаган кебек кыланалар, гүя серле бер йола башкаралар… Үч иткәндәй, бүген балыгы да эләкми… Әллә анысына да шушы сәер кош сәбәпчеме?

Өйгә кайткач, бу хакта әнкәйгә сөйләдем. Әнкәй бер сүз дәшмәде. Әткәйгә әйткән икән.

Әткәй, кичен бергә җыелгач, үзалдына сөйләнгән кебек кенә әйтеп куйды:

— Фәүзия, әзерләнә башларга кирәк, бүген-иртәгә сугыш башланачак…

Нәкъ бер атнадан сугыш башланды. Тагын бер атнадан әткәйне алып киттеләр. Теге кара акчарлак бүтән күренмәде. Кесәмә таш та алып йөри башлаган идем югыйсә… Сугыш хакында хәбәр итәр өчен күрше-тирә авылларга китеп барды, ахры…

## 2. Әткәйнең җиз камчысы

Әткәй авылда бригадир булып эшли иде. Ул минем хәтердә кара туры аты белән, аннары җиз саплы камчысы белән калган…

Китәргә җыенып беткәч, әткәй әнкәй белән икебезне үз янына чакырып алды. Нишләптер иң элек миңа эндәште ул.

— Улым, Хәмитҗан, син хәзер өйдә минем урынга каласың. Өйне кара, әнкәңне сакла. Кысыбрак тотсагыз, берәр елга җитәрлек ризык бар, калганын эшләп юнәтерсез…

Әткәй бик күп нәрсәләр хакында сөйләде. Ничек хуҗа булырга, мал карарга, авыр чакта кемгә барырга… Сугышның авыр, озак буласын да әйтте...

Үзем тыңлаган булам, ә күзләрем әткәйнең итек кунычында. Аннан теге затлы камчының җиз сабы күренеп тора!.. Калдырмас микәнни? Үзе белән фронтка алып китәр микәнни? Ә үлеп калса? Бу камчы әрәм була бит!..

Гөнаһлы уйларның иге-чиге юк. Ә әткәй сөйли дә сөйли. Әнкәйгә мине карарга куша, миңа әнкәйне карарга куша…

Ниһаять, кузгалырга вакыт җитте. Утырып дога кылдылар. Мине урталарына утырттылар… Әнкәй елый башлады. Әткәй әнкәйнең елаганын яратмый, ә бу юлы бер сүз дә әйтмәде…

Әткәй сугышка китте, күзләрне камаштырып торган җиз саплы камчысын да үзе белән алып китте. Ул камчы беренче төнне үк төшемә керде. Имеш, әткәй миңа шул камчыны сузып тора. Мин алмыйм. «Үзеңә булсын, дошманнарны камчыларга кирәк булыр»,— дим…

Иртән торуга, басуга эшкә киттем. Без ул көнне борчак басуында пакус әйләндерергә тиеш идек. Үзем эшлим, үзем кичә генә әткәйләр киткән басу капкасы ягына карап алам. Әткәй бөтенләй дә сугышка китмәгәндер, һаман әле шул басу капкасы төбендә басып торадыр кебек…

Шул вакыт капка баганасында ниндидер нур балкып китте. Бу нур балкышы, күз карашларым аша суырылып килеп, җаным янына ук төшеп ятты! Нинди нур бу, нинди балкыш? Ике җәпле таягымны бер читкә аттым да, җаныма килеп иңгән серле балкыш янына киттем. Тыным-сулышым бетеп барып җиткәнче югалмады, сүрелмәде ул нур. Менә ун, биш адым калды… Инде үрелеп аласы гына, шул нурны алып, өметле, бәхетле буласы гына калды!

Юк, шундук үрелеп ала алмадым әле. Баскан урынымда туктап, катып калдым. Басу капкасының уң баганасында әткәемнең нурлы җиз камчысы эленеп тора иде!

## 3. «Җан» җанны саклый

Сугыш башланып, берничә атна үтүгә үк, авылга «кара кәгазь»ләр килә башлады. Түбән очтан киткән Зиннәтулланың җаны иң беренче булып кыелды. Ул чик буенда хезмәт итә иде. Бөтен авыл җыелып кайгырды. Аннары Ислам, Гомәр абыйлар һәлак булдылар. Аларга да еладык. Кайгыга күнегәсең икән. Үлем хәбәрләре күбрәк килгән саен, азрак елыйбыз. Бераздан яшь түкмичә, үз эчләребезгә бикләнеп, борчылып, шомланып яши башладык…

Сугыш афәте кергәнгә ярты ел үтте. Авыл унсигез кешесен югалтты. Әлегә эткәйдән хәбәр юк. Баштарак кош теледәй генә ике хаты килгән иде, аннары килмәс булды. Күңелебезне төшермибез. «Кара кәгазь» юк бит — шуңа да җан сөенә.

Ә беркөнне тагын да куанычлырак хәлгә тап булдык. Без әнкәй белән фермада ат җигеп эшли идек. Шулай төшке ашка кайтып киләбез. Астурам чатындагы кое тирәсендә җыелып торган хатын-кызлар янына тукталдык. Әнкәй сүзгә кушылып китте, мин пар бөркеп торган атымның аркалыгын бушатырга керештем.

Күршедәге Хәтирә карчыкның сүзе мине сикәндереп җибәрде.

— Ирләрегезгә «җан» кушып сөйләшегез, «җан» җанны саклый, ди ул…

— Ничек инде? Ничек? — диештеләр хатыннар.

— Ничек булсын, ирләрегезнең исемнәрен әйткәндә «җан» дип өстәп куегыз. Менә синең ирең ни исемле? Фәхриме? Хәзер Фәхриҗан дип сөйләш. Синеке Сабирҗан булыр, ә синеке — Мөхәммәтҗан…

— Ә минеке, минеке ничек була инде? Бер дә телгә килешә алмый бит?..

— Вилме?

Әйтсәм әйтим, Вил абыйның исемен Ленин бабай исем-фамилиясенең беренче хәрефләреннән алып куйган булганнар.

— Вил… Вилҗан булыр.

— Андый исем буламыни?

— Булыр, булмый кая китсен. «Җан» барлык исемгә дә килешә ул…

Шунда әнкәй сүзгә кушылды:

— Хәтирә апа, минем Рәхимҗаныма «җан» кушарга кирәкме?

— Юк, аның үзенең «җан»ы бар бит.

Чынлап та, бу «җан» дигәннәре кешене саклый икән. Минем эткәйдә дә «җан» бар — шуңа да ул исән! Безнең авылда сугышка киткән Сәлимҗан, Галимҗан, Тимерҗаннар да исән… «Җан» кергән бер генә кеше дә үлмәгән булып чыкты. Шул көннән башлап, фронттагы бөтен ир-атлар да «җан»лы булдылар, хикмәти Хода, «кара кәгазь»ләр килү дә тукталды.

Урамдагы сөйләшүләрдән көләсе килгән чаклар да була иде.

— Хәят апа, синең Сөләйманҗаннан хәбәр юкмы әле? — дип сорый Мәймүнә дигән хатын.

— Юк шул әле, синең Фуатҗаның ни яза соң? Безнекеләрне күрмәгәнме?

— Сезнекеләрне күрмәгән. Ә менә күрше авылдагы Сәярҗан белән райондагы Билалҗанны күргән…

Юк, «җан» дип әйтү генә сугыштагыларны саклап бетерә алмады. Язгы чәчүгә әзерләнеп йөргән көннәрдә Хәят апаның ире Сөләйман хакында кайгылы хәбәр килде. Бу юлы инде Сөләйманҗан дип тормадылар, ничек бар шулай— Сөләйман дип кенә сөйләштеләр…

Беренче май бәйрәменә авыл тагын өч кешесен югалтты. Ләкин моңа карап кына халык «җан» кушып сөйләшүдән туктамады. Барыбер өметле иде бу сүз.Ә сугыш вакытында өмет бик кирәк, шунсыз исән калам димә…

Минем эткәйдән «кара кәгазъ» килмәде. Әнә шул «җан»ы саклагандыр инде… Тик… ул әйләнеп тә кайтмады… «Хәбәрсез югалды» дигән хәбәре генә килде. Хәбәрсез югалу үлү дигән сүз түгел бит әле. Бәлки, исәндер, бәлки, исәндер дип, сугыш беткәнче өметләнеп яшәдек. Әнкәй, эткәйне телгә алганда еш кына «Рәхимҗан-җан» дип тә әйткәли иде. Бик яшәтәсе килгәндер шул.

Ике «җан» да кайтара алмады эткәебезне. Ул шул ике җан арасында, дөресрәге, ике дөнья чатында, авылга кайту юлында япа-ялгызы торып калды, ахры…

## 4. Атны кайсы яктан җигәләр?

Сугыш елларында ун яшьләре тулган малайлар атта эшләделәр. Җәйге, көзге басу алар карамагында булды.

Безнең якта атлар күп. Сугыш беткәнче аларның төп өлешен саклап кала алдык. Ун-унбиш яшьлек малайлар ул гайрәтле атларны тыңлата алгандырмы, юкмы — хәтерләмим, анысы хәзер мөһим

дә түгел. Иң мөһиме, авылда атны яхшы белгән абзыйлар булган. Шакир карт әнә шундый «ат җене кагылган» бер кеше иде.

Сәерлеге дә бар. Атта эшләр өчен җибәрелгән малайлардан сынау алырга ярата ул.

— Атны кайсы яктан җигә башлыйлар соң? — дип сорый ул, мышык-мышык борынын тартып, каршысында басып торучы малайдан. Тегесе ык-мык килеп тора башласа, ике дә уйламыйча: — Бар, белеп кил, — дип өенә кайтарып җибәрә.

Икенче берәүдән:

— Яхшы атны ничек беләләр? — дип сорый.

Моны күп малай белми. Ә мин беләм. Кайсы яктан җигә башларга икәнен дә беләм. Әткәйдән беләм. Сул яктан. Яхшы атны исә суга кертеп сыныйлар. Затлы ат бервакытта да үзе эчә торган суга йомышламый, түзә, ярга чыккач кына бушана. Суга сигән атның кадере дә юк, андый ат бозылган ат була.

Беренче мәртәбә фермаларга ат алырга килгәч, Шакир карт миннән берни дә сорамады. Мин аның сынавына әзер идем, ә ул сорамады. Якындагы алмачуар янында күпме генә булашсам да, сорамады. Күңелем төште — әллә бирмәскә уйлыймы?

— Ошыймы? — дип сорады ул, алмачуар ягына ымлап.

— Ошый...— дип суздым мин, янымдагы атның яңагыннан сыйпап.

— Шуны җигәрсең, килешәсез дә бугай... Бар, лапастан әйберләрен кереп ал...

Шулай эшләп киттем. Атларны яратам мин. Алар кешеләрне аңлыйлар. Сөйләшә генә белмиләр. Дуслыкны аңлыйлар. Кадерлиләр...

Сугыш тәмамланыр елны авылдагы атларга Шакир карт белән икәү хуҗа булып калдык. Бу Хода бәндәсе мине үзенә ярдәмче итеп алды.

Шунда, бер җаен туры китереп, сораша башладым:

— Әйт әле, Ак бабай, нигә теге вакытта миннән берни дә сорамадың? — дидем.

Ә ул тиз генә җавап бирмәде. Тәмәкесен төреп, кабызып җибәрде. Утарда тибенеп йөргән яшь тайларны барлап алды...

Шуннан соң гына, беренче герман сугышыннан ук телгәләнеп кайткан ямьсез иреннәре белән матур елмаеп әйтеп куйды:

— Син, Хәмитҗан балам, сынауны үткән идең инде. Хәтерлисеңме, капкадан керүгә, иң элек Алмачуар янына бардың... Аны тыныч кына узып китә алмадың... Шунда аңлап алдым: син атларны яратасың. Сорап-нитеп торуның кирәге дә юк иде...

Сугыш вакытында безнең авыл сыер җикмәде. Шакир картның атлары барысын да җиренә җиткезеп эшләде. Безне, сугыш чоры малайларын кеше итүдә дә Ак бабайның өлеше зур булды. Ул һәр терлек иясенә, бигрәк тә атларга кеше белән тигез карарга өйрәтте...

Җиңүне генә күрә алмады. Кырык бишенче елның апрелендә, басу карап йөргәндә, минем Алмачуар өстендә җан очырды бу изге карт.

### 5. Фронттан хатлар

Сугыш авылы өчен иң якты, кадерле минутлар фронттан килгән хатлар белән бәйләнгән. Безнең авылда кич утырып хат уку гадәте бар иде. Кайбер апалар өй борынча йөреп укыйлар. Кайчакта авыл буйлап өчпочмаклы хат үзе генә китә. Иясенә урап кайтканчы ул таушалып, теткәләнеп беткән була иде.

Фронт хатларын укуның үз йоласы бар. Аны тиз генә укый башламыйлар. Иң элек дога кылалар, укыгач та тиз генә таралышмыйлар, хатны язган кеше хакында сөйләшеп утыралар. Кем хакындадыр начар дип әйткәннәрен ишеткәнем булмады, фронттагыларны әйбәт яктан гына искә алалар иде.

Аннары ничек җавап язу хакында киңәшәләр. Кемнәрдән сәлам әйтергә, кемнәрдән әйтмәскә... Хат ахырында җыр булырга тиеш. Монысы мәҗбүри. Анысын да киңәшеп язалар. Кабатланган булырга тиеш түгел. Яңа җыр сорап Өммегөлсем карчыкка яисә шул ук Шакир картка баралар.

Мин әнкәйләрнең кемгә нәрсә язганнарын инде хәтерләп бетерә алмыйм, әмма фронттан килгән хатлардагы юллар йөрәгемә мәңгегә уелып калдылар. Хәзер шул хакта еш уйланам: ул хатларның ияләре үзләренең хисләре, уйлары, мәхәббәтләре һәм нәфрәтләре белән чын әдипләрдән бер дә ким булмаганнар; алардагы ихлас, бөек хисләр талантлы язучыларның талантлы әсәрләрендә дә сирәк очрыйдыр...

Түбән очта яшәп, гомере буе басудан кайтып кермәгән Чыпчык Мөхәммәтенең язганнары әле дә күңелемне дулкынландырып тора...

«Монда хәлләр мөшкел. Куркыныч, — дип язган иде ул хатында. — Куркып чигенүчеләр күп. Чигенү — хыянәт белән бер. Мин сугыштан, үлемнән курыкмыйм, хыянәттән куркам. Хыянәт итеп иманымны сатсам, кешелегемне югалтсам, Агыйдел елгасы дулкынланганда, үрелеп яңагыма сугар

кебек… Кайтып кергәндә, бакчабыз түрендәге шомырт куагы йөземә чабып җибәрер кебек… Әнкәй, минем өчен оялып, кешегә туры карый алмас, шул оялуы белән күңелемне, җанымны яңаклар кебек…»

Мин тагын шуңа игътибар иттем. Гади генә авыл кешеләре дә туган ил, туган җир хакында матур итеп, тәэсирләнеп яза беләләр иде. Әткәйнең икенче, соңгы хатындагы юлларны мәңге онытасым юк. Безне сагынуы хакында әйткәч, ул туган ил хакында болай дип язып куйган: «Туган ил дөньяның кайсыдыр тарафында түгел, ул йөрәк янында, җан түрендә яши икән», — дигән.

Шулай да нык истә калганы язылып бетмәгән хат булгандыр. Ул хат пожар урамында яшәүче Гайфулла абыйдан килгән иде. Бөтен авыл белән укыдык. Хикмәт шунда ки, бу хатның ахыры юк, ярты сүздә өзелеп калган… Ничек алай килеп чыккандыр — бу хакта кем генә әйтә алыр икән. Сугышның бер сере булып калды ул хат. Ә Гайфулла агай үзе әйләнеп кайтмады, үле хәбәре дә килмәде…

### 6. Туганлык

Фронттан беренче кеше кырык беренче елның октябрендә кайтты. Ике аяксыз, бер кулсыз Галләм абзый иде ул. Авылга аны бер хәрби кеше китереп куйды. Кечкенә агач йорт алдына бөтен авыл җыелды. Ләкин безгә — малайларга чират тигәнче бер атналап вакыт узды. Шулай да, ничек кирәк алай хатыны Сания апаны килештереп, Галләм абзый янына керә алдык.

Без дәррәү килеп кергәндә, ул түшәктә йокымсырап ята иде. Сискәнеп уянды да, сыңар беләгенә таянып, торып утырмакчы булды. Ләкин теләгенә ирешә алмады, шуып, кабат элекке урынына төшеп ятты.

Килеп күрешкән булдык. Рәтен белеп бетермәсәк тә, фронт хәлләрен сорашырга керештек. Галләм абзыйның нәрсә сөйләгәннәре хәзер хәтердә калмаган инде. Бер кош хакындагы гыйбрәтле хикәяте генә истә.

Яраланып сугыш кырында калган Галләм абзый бомба чокырында бер тәүлек аңсыз ята. Якынтирәдә теленә салырлык үлән дә булмый. Шул вакыт аның янына бер урман күгәрчене ияләшә. Баштарак ул бу үлеп барган адәм баласын карап, күзәтеп кенә тора. Аннары юкка чыга, тагын очып килә. Килә дә Галләмнең кибеп-яргаланып беткән иреннәренә томшыгын тидерә. Ул бер тамчы суның тәмен яралы солдат шундук тоеп ала, башын калкыта, күкрәгендә басып торган кошка рәхмәт әйтмәкче була… Кош көне буе томшыгында су ташый, ара-тирә суалчан, бөҗәк яисә җимеш бөртеге алып килә… Галләм берсен дә кире какмый, шулай аңа хәл керә башлый.

Урман күгәрчене икенче көнне дә яралы яныннан китми. Өченче көнне дә армый-талмый су, ризык ташый…

Һөҗүмгә баручы солдатлар килеп тапканда, Галләм янында таныш кош булмый инде. Ходай Тәгалә изге ният итеп җибәргән бу җан иясе үзенең газиз балаларын туендырырга китеп баргандыр шул…

Галләм абзый протез белән йөрергә бик тиз өйрәнде, басу-кырларга су илтте, төшке аш ташыды…

Күпме беләм, шул гомерендә ул гел кошлар белән сөйләшеп йөрде. Кулында бер телем ипи булса, яртысын, сындырып, шул канатлы дусларына бирә иде…

Галләм карт тарихыннан мин шуны аңладым. Сугыш кешеләр гаме генә түгел икән. Бөтен тереклек тоя икән аны, бөтен тереклек аңа каршы көрәшкә күтәрелә икән… Сугыш вакытында табигатьтәге һәр җан бөртеге, тереклек иясе берләшә, туганлаша, шуңа да тормыш, игелек, изгелек һәрчак үлемнән өстен булып кала…

### 7. Күңел күзе

Кырык икенче елга чыккач, югары очта торучы Оркыя апалар «кара кәгазь» алдылар. Гадәттәгечә, тол хатынны юатырга туганнары җыелды. Безгә чыбык очы туры килгәнгә, әнкәй дә, әнкәйгә ияреп мин дә, кар ера-ера югары очка киттек. Күршеләрендә торучы Ак бабай да шунда булып чыкты. Тагын берничә хатын-кыз, бала-чага бар иде.

Без барып кергәндә тыныч кына сөйләшеп утыралар иде. Мине бигрәк тә Оркыя апа аптыратты. Аптырарсың да, ире сугышта үлгән, ә ул, исе дә китмичә, елмаеп сөйләшеп утыра!

Кулында — Вәлиәхмәтенең сурәте. Фронтка баргач төшеп җибәргән булган. Хәрби киемнән. Елмаеп карап тора. Оркыя апаның сүзләре дә шул хакта.

— Әнә ничек көлеп тора бит ул җанкисәккәем!.. Җиңеп чыккан диярсең! Мондый кеше үлә димени?! Ялгышканнар гына ул, күңелем сизә, күңел күзем күрә… Үлмәгән ул, үлмәгән!

Аңа башкалар кушыла.

Ахырдан Ак бабай төгәлләп куя:

— Исән булса кайтыр, балам, кайтыр, кая китсен ул. Рәхмәт үзеңә, ышанып көтә беләсең, көтсәң, кайта ди ул… Көт, синең Вәлиәхмәтең дә кайтыр…

Кайтканда, юллар Ак бабай белән бергә туры килде. Ул вакытта аның әйткән сүзләре әле дә истә. «Үлгән кеше сурәтенә болай карамыйлар… Чынлап та исән микән әллә?» — дигән иде ул.

Ходай шаһит, Вәлиәхмәт абый исән булып чыкты. Үлде дип яу кырында калдырып киткәннәр, ә ул госпитальгә эләккән. Башта хаты килде, аннары, Берлинны алып, елмаеп үзе кайтып төште…

Бу вакыйгадан соң авыл халкы «кара кәгазь»ләргә бөтенләй башкача карый башлады. Ирләре сугышта үлеп калган кайбер хатыннарның Оркыя апа янына юратырга йөрүләре хакында да имеш-мимешләр ишетелгәләп калды.

## 8. Җирдән аерылган — җиңелгән

Кырык икенче елның сабан туен шомланып көтеп алдык.

Чәчүләр әйбәт кенә узды, уңышлар шытып чыкты, авыл печәнгә төшәргә әзерләнә башлады. Кышын нык кына арыкланган маллар көрәйде, тартылып, үсеп киткән малайларның бит очларына ит кунды.

Безнең авылда яшьтән үк даннары чыккан ике көрәшче егет бар. Наил белән Равилне бөтен тирә-як белә. Быел аларның бигрәк тә җаваплы еллары. Көзгә аларга повестка киләчәк. Димәк, соңгы сабантуйлары. Җиңүгә кадәр соңгысы.

Язгы чәчү бетәр-бетмәс, Наил эшкә чыкмый башлады. Авырыйм дигән булып, өендә әнисенең майлы коймагын ашап ятты. Көзен сугышка китәсе булгач, беркем бер сүз әйтә алмады. Наилнең, эштән качып, сабан туена әзерләнүен бөтен авыл белә иде. Моны Наил үзе дә яшермәде. «Сугышка китсәм дә, әнкәйгә тәкә калдырып китәм», — дип мактанып йөрде.

Равил әнисе белән генә тора. Тормышны җигелеп тартучы егет ул. Әнисә апа соңгы вакытта авырыбрак йөри, шуңа да Равилгә икеләтә тырышырга туры килә. Аның ябык чандыр гәүдәсенә карап, бер дә көрәшче дип уйламассың. Ләкин бөтен кеше белә: Равилнең көче тәнендә түгел, йөрәгендә!

Сабантуйдагы ямансулык җанны өшетерлек иде. «Сугыш ни, Сабантуй ни…» дип йөрүчеләр күп булды. Мәйданда күбрәк хатын-кызлар, яшүсмерләр, бала-чагалар. Карт-корылар күренгәли. «Кара кәгазь» килгән йортлардан бөтенләй чыкмаганнар.

Колхоз рәисе Чулак Солтан мәйданны Сталинга рәхмәт әйтеп, фронттагыларга җиңү теләп ачып җибәрде. Чәчүдәге алдынгыларны котлады, кемгә сабын, кемгә чүпрәк-чапрак өләште.

Чабыш-мазар булмады. Атларны болынга төшәргә саклыйлар. Уен-көлке дә бер читтә җыелып торган кыз-кыркынның чыркылдашуыннан узмады. Һәркем көрәшне көтә иде. Ул бөтен уеннар уйналып беткәч кенә башлана.

Менә мәйдан уртасында Наил белән Равил генә торып калды. Алар сөлгеләрен беләкләренә урап, бер-берсенә текәлеп, түгәрәк буенча әйләнеп чыктылар, шулай «соңгы алыш» йоласын башкардылар.

Баштарак Наил көчлерәк кебек иде. Раилне күтәрә дә куя, күтәрә дә куя. Әмма, янтаеп, тәгәрәтеп җибәрә алмый. Равил, чәчрәп барып төштем дигәндә генә, мәче җитезлеге белән ике аягына тора да баса, тора да баса… Ул үзе әлегә көчәнеп булашмый, нindидер җай көтеп йөри…

Наил арый башлады. Өйдә ятып, түгәрәкләнеп, бүртеп киткән гәүдәдә егәрлек озак тормый шул. Ә ябык, чандыр Равил һаман шул килеш — җитез, өлгер, елгыр… Менә ул бер ике мәртәбә Наилнең билен тотып, аны күтәрергә тырышып карады. Тегесе, тезләрен як-якка аерып, бөтен гәүдәсе белән җир өстенә сузылды. Ләкин җир аңа ярдәм итә алмады. Равил Наилнең биленнән шундый итеп кысып тотты, тегe хәтта кычкырып куйды. Ул арада Равил, каерылып, Наилне җирдән куптарып алды, аннары, уң якка янтаеп, баш аша чөеп җибәрде. Наил авыр гәүдәсе белән чирәм өстенә чәчрәп барып төште. Мәйдан халкы, аягүрә басып, аһ итеп куйды.

Янымда басып торган Шакир картның фәлсәфәсе мине сискәндереп җибәрде.

— Җирдән аерылган кешенең көче китә шул,— диде ул.

## 9. Икмәк исе

Кырык икенче елның кышында ачлыкның нәрсә икәнен танып белдек. Авылда шешенеп берничә кеше үлде.

Колхозда уңыш та ярыйсы гына булган иде югыйсә. Ләкин бөтен ашлыкны фронтка алдылар. Келәтләрдә вак-төяк фураж белән орлык ашлыгы гына торып калды. Анысын да агулап куялар. Агулы орлык ашап, сугыш елларында күп кеше эчен бозды, сәламәтлеген бетерде.

Ачлык безне дә урап узмады. Өйдә икмәк, он бетте. Бәрәңге суына алабута ипиен җебетеп ашыйбыз. Җитмәсә, авырып киттем. Юньле-рәтле киеме дә юк бит аның, салкын җил, кыска сырмадан кереп, тәнне генә түгел, йөрәкне, җанны өшетә…

Әткәйдән хат килми, әнкәй елый да елый, ә мин авырып, саташып ятам… Дарулар юк, үлән суы эчәм, җимеш кайнатмасы кабам, әнкәй каяндыр бер кашык бал табып кайткан. Аны кабып чәй эчкәч, тәнем кызыша башлады, манма тиргә баттым. Әнкәй өстемне алыштырды. Ничә көнгә беренче мәртәбә басылып йоклап киттем.Төш күрдем. Әткәй белән әнкәй өстәл артында утыралар, имеш. Мин дә шунда. Әткәй ипи кисә. Бер кисәген миңа бирә. Мин бу икмәк телемен олы итеп кабам да аш чөмерәм. Шунда берничә ипи валчыгы кулымдагы сыныгымнан кубарылып өстәл өстенә төшеп китә, аннары идәнгә тәгәри… Әткәй, кулындагы икмәген сак кына өстәлгә куеп, идәндә яткан ипи валчыкларын учына җыеп ала да стена бурасындагы ярыкка кыстырып чыга. Әткәйме, әнкәйме — кайсыдыр әйтә кебек: «Идәнгә төшкән ипи валчыгын җыеп алып, стена ярыгына кыстырсаң, ачлык килми!» — ди.

Ул икмәкнең тәмен аермачык тоям. Үзем йоклыйм, үзем тоям… Әнкәйнең:«Аша, балам, аша, икмәк хәл кертә ул»,— дигән ягымлы тавышын ишетәм.

Бу ягымлы тавышка ияреп, үземнең ач дөньяма кайтам. Янымда әнкәй утыра, кулында агач кашык.

— Әнкәй?

— Әйдәле, кап, балам, икмәк хәл кертә ул…

Шунда гына агач кашыктагы икмәк измәсен күреп алам, дөресрәге, сизеп, тоеп алам! Юк, юк, сугыш чоры икмәге түгел бу! Сугышка кадәрге икмәктән генә шундый татлы, хуш ис килә иде!..

Шушы ике-өч кашык ипи, чынлап та, миңа хәл кертеп җибәрде. Башымны калкытып торып утырдым.

Бер җаен туры китереп, әнкәйдән сораша башладым:

— Әнкәй, әйт әле… Каян бу ипи?

— Каян дип… Бура ярыгыннан, балам… Идәнгә төшкән ипи валчыкларын кыстырып бара идек бит!.. Шуннан…

Минем елыйсым килде, һәм мин, каһәрле сугыш башлангач, беренче мәртәбә рәхәтләнеп, үксеп еладым.

**10. «Әмрикә паегы»**

Бу сүзем, ирен сугышка озатып, берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала белән ялгызы торып калган Зөләйха апа хакында.

Әйттем бит инде, ачлык безнең авылга сугышның икенче кышында ук килеп җитте. Өй борынча йөри-йөри, беркөнне ул Зөләйха апаларга да барып кергән. Әнкәй бервакыт эштән кайткач: «Зөләйха апаң шешенгән», — диде. Бу миңа «Зөләйха апаң үлгән» дигән хәбәр булып ишетелде, йөрәгемне авырттырды. Чөнки авылда шешенеп үлүчеләр бар иде инде. Үзара сөйләшеп, бер-ике уч борчак оны илтергә булдык. Ләкин әнкәйнең, күңелсез генә: «Барыбер балаларына бирәчәк инде, үзе авызына да алмаячак»,— дип әйтеп куюы минем яшь йөрәгемне тагын да ныграк тетрәндерде. Шуны аңладым: Зөләйха апа бөтен тапкан ризыгын, үзе ашамыйча, балаларына биреп барган. Хәзер аның ашыйсы да килмидер инде. Чөнки ачтан шешенгән кеше бервакыт ризык тәмен, ризык исен сизми башлый, тамагы тук кебек хис итә… Андыйларның тәннәренә басып-басып карыйлар. Бармак очы белән баскалаган тән тиресе, үз урынына кайтмыйча, чокырланып кала икән, димәк, бу кеше үлем ачлыгына дучар.

Боларын соңыннан гына белдем: Зөләйха апаны кәнсәләргә чакырып алганнар. Нык кына ачуланганнар.

— Син нәрсә, фронтовик хатыны?! — дигәннәр. — Безне хур итмәкче буласыңмы? Ирең фронтта батырларча һәлак булып калды, хәзер үзең, балалар дип, бер тәгам ризык капмыйча җан тәслим кылмакчы буласыңмы? Фронтовик хатынын ачтан үтергән өчен беләсеңме безгә нәрсә булачак? Син бит үзеңне түгел, безне кабергә кертәсең, бөтен илгә, Сталин партиясенә, җиңүгә тап төшерәсең! — дип, сугышның иң зур авырлыгын үз җилкәсендә күтәргән юлбашчыбызның исемен әйтүгә кадәр барып җиткәннәр.

Зөләйха апа нәрсә әйтсен. Күз яшьләрен мелт-мелт тамызып, тик басып торган. Аннары, хәлсезләнеп, мич алдына өеп куелган утын өстенә егылган…

Зөләйха апаларга «Әмрикә паегы» билгеләделәр. Төсле пакетларда бирелә торган бу тары боткасы аның үзен дә, дүрт баласын да үлемнән коткарып калды. Ул паек безгә дә эләккәләде әле. Шул «Әмрикә» дигән сүз тартып китергәндер инде. Аларның ботка пешергән вакытларын чамалап килеп керсәк, Зөләйха апа безгә берәр кашык чит ил күчтәнәче каптырып чыгара иде. Тәмле иде ул ботка! Майлы иде! Хәтта баллы иде! Аның тәме хәзер дә тел очында. Ләкин теге бал тәме генә онытылган… Сугыш ачысы «Әмрикә паегы»ның татлы тәмен тәмам оныттырган иде.

Ә Зөләйха апаның балалары үсеп кеше булдылар. Хәзер бер малае Америкада тора. Анда яшәү рәхәт икән. Ләкин авылын, туган җирен бик сагына, ди…

## 11. Көч — йөрәктә!

1944 елның ахырында авылда тагын ике фронтовик пәйда булды. Берсенең кайтканын сизмәдек тә. Пожар урамындагы Кәрлә Гарәфи иде ул.

Әнкәйнең эшкә китешли генә:

— Гарәфи абыең кайткан, диләр, сорашып аласы иде, әтиеңне күрмәгәнме? — дигән сүзенә баштарак игътибар да итмәдем.

Чөнки мин бу кешене бөтенләй дә белмим. Ул сугышка кадәр үк шахтага күмер чабарга чыгып киткән булган. Авылдан озатылмагач, аның кайтуына әллә ни аһ итмәделәр. Хәтта: «Фронтта булды микән?» — дип шикләнүчеләр дә табылды. Сәбәбен эзләп торасы да юк — гимнастеркадан аны беркем дә күрмәгән.

Ул вакытта фронттан кайткан һәр кеше хәрби киемнән йөри иде. Берничә көн орден-медальләрен дә салмый. Өй борынча йөреп, хәл-әхвәл белешеп чыкканнан соң, кәнсәләрдән эш-«нәрәт» алгач кына сандыкка салып куела ул орденнар, погоннар.

Аннары... Буе да бик кечкенә иде шул Гарәфи абыйның. «Кәрлә Гарәфи» дип юкка гына атамаганнардыр. Юри янына басып караганым булды — миннән чак кына калкурак... Буена да түзәр идең, холкы белән бик юаш иде ул. Аның, «ур-ра» кычкырып, баш очына беләк буе граната күтәреп, немецларның «тигр»ларына каршы һөҗүмгә баруын берничек тә күз алдына китерә алмый идек.

Үзеннән дә фронт хакында бер авыз сүз чыкмады. Гүя сугышта бөтенләй булмаган да... Бу хәл безне — фронтовик малайларын — нык кына үртәде; сугышта үлеп калган әтиләр өчен ялганчы Кәрләдән үч аласы килә башлады.

Кечкенә буена, юаш холкына карамыйча, Гарәфи абыйны тегермәнгә куйдылар. Әйбәт тегермәнче иде ул. Тегермәннең туктап, ватылып торганын хәтерләмим. «Гарәфи тегермәненең оны әйбәт, тәмле, туклыклы», — дигән сүз дә чыкты бервакыт. Үзе кадәр капчыкларны «эһ» тә итми күтәреп алып кереп китә иде. Карт-корыга бик булыша иде, ятим балаларга качырып кына бирәр уч он өләшкәне дә булгалады.

Без аның тырыш, игелекле, гадел булуы хакында бик уйланмый идек шул. Ачлыктан, авыр эштән нык кына миңгерәүләнгән башларыбызда бер генә сорау бөтерелә иде: «Фронтта булганмы, юкмы? Булса — ярый, булмаса — әләгәчәк үзенә...»

Һәм әләкте дә.

Кырык бишнең апрель ахырлары. Кәрлә Гарәфинең атта эшләп йөргән чагы иде. Чәчүгә ашлык ташыйбыз. Егетләр «алдакчы Кәрлә» атының аркалык һәм тәртә бауларын кискәннәр. Тау менгәндә өзелерлек итеп кенә калдырганнар. Чынлап та, үр тавын менгәндә орлык тулы арба, аттан аерылып, кирегә — аска таба төшә башлый. Гарәфи күп уйлап тормый, артка йөгереп чыга да тәгәрмәч астына ята, шулай итеп, егерме биш пот ашлыкны Яман Күл чокыры сазлыгына батудан саклап кала...

Кешеләр килеп тапканда, арба тәгәрмәченең тимер кыршавы, Кәрлә Гарәфинең сул беләген имгәтеп, кабыргалары арасына кереп кысылган була.

Җиңү көнендә ул авырткан кулын кара чүпрәккә асып чыкты. Чып-чын фронтовик кебек. Шушы көнне без аны беренче мәртәбә гимнастеркадан күрдек. Күрдек тә... телсез калдык. Аңсыз, җансыз кала яздык хәтта. Гарәфи солдат түшендәге орден-медальләрнең исәбе-хисабы юк иде. Минем бу чаклы орденны аңа кадәр дә, аннан соң да бер кеше түшендә дә күргәнем булмады.

Без ул көнне Гарәфи абыйдан ерактарак йөрергә тырыштык. Оят иде безгә, бик тә оят иде. Ул көнне генә түгел, бөтен гомеребез буе оялып, кыенсынып яшәдек бу «кәрлә герой»дан. Безнең өчен олы бер гыйбрәт булып калды ул. Шул вакыттан мин гомерлеккә аңлап калдым: көч — беләктә түгел, көч йөрәктә икән! Исемен генә хәтерләмим, кайсыдыр шагыйрьнең шигыре бик тә туры килә Кәрлә Гарәфи тарихына:

Йөрәк бит ул,
Йөрәк бит ул, —
Йодрык кадәрле генә.
Ләкин аны тоя ала
Олы бәгырьле генә.
Бәгырьдән үсә йодрык —
Шуңа кадерле бит ул.
Йодрык кына булса да,
Йөрәк кадәрле бит ул!

## 12. «Тәртипсез» малай

Ничек кенә авыр булмасын, мәктәптә дәресләр тукталмады. Уку көннәре кыскарды, сәгатьләр кыскарды, әмма мәктәп ябылмады. Суык та, ачлык та үзәкләрне өзә, әмма ел әйләнәсендә колхоз эшен җигелеп тартучы авыл малайлары киләчәктә укуның никадәр кирәклеген аңлыйлар иде.

Безнең мәктәптә дә әйбәт укучылар, шулай ук начар укучылар, тәртипле балалар, шулай ук тәртип бозучылар бар иде. Бигрәк тә Зөфәр исемле малай нык җәфалады укытучыларны. Йә урамда җен булып каршыларына чыга, урындыкларына су түгеп куя, аркаларына ямьсез сүзләр язып элә, алар кебек кыланып, кәмит күрсәтеп йөри…

Безнең класста укыган Зөфәрне мин дә яхшы беләм. Тәртипсез булса да, гадел малай ул. Уйнаганда да, эштә дә хәрәмләшми. Дус та була белә. Ә менә мәктәпне атлап керүгә «җене кузгала», билләһи!

Бер вакыйгадан соң мәктәптә аңа мөнәсәбәт үзгәрде. Хәтта ул үзе дә үзгәрде. Шул хакта бөртекләп сөйләмәкче булам.

Ботаника дәресе иде. Зәмзәмия апа керә. Исеме матур булса да, үзе бик усал апа. Сүзне сүзгә сорап җанны ала. Бигрәк тә Зөфәргә каныга. Зөфәр китап сүзләрен яратмый, үләннәр хакында үз сүзләре белән, үзенчә сөйли.

Беркөнне Зәмзәмия апа Зөфәрне «тотты». Иң арткы партада астан гына нидер эшләп утыра иде ул.

Укытучы аның иелгән башын күреп калды да:

— Сәфәргалиев! — дип кычкырды.

Зөфәр шундук башын күтәрде, сикереп торып, үрә катты. Ул арада идәнгә нәрсәдер шапылдап төшеп китте.

Зөфәр төшкән әйберен иелеп алмакчы булган иде, Зәмзәмия апаның чәрелдәвек тавышы аны кабат үрә бастырды:

— Сәфәргалиев! Такта янына чык!

Зөфәр болай да артык озын, алга сузылып йөрүче гәүдәсен тагын да бөкрәйтебрәк такта янына узды, класс ягына борылып, теләсәгез нишләтегез дигән кебек, башын иде.

Зәмзәмия апа, дәрес хакында тәмам онытып, бөтен усал сүзләр белән Зөфәрне тиргәргә кереште.

— Син нәрсә, малай актыгы! Управа табылмас дип уйлыйсыңмы әллә? Мәктәптән кудырып, колхозның тирес базында башыңны черетәм бит, каһәр суккыры нәрсә!

Без, әлбәттә, аңлыйбыз, аңларга тырышабыз. Зәмзәмия апаның ире сугышта үлгән. Сугышта үлгән кешенең хатыны кычкыра да аладыр. Әмма Зөфәрнең әтисе дә сугышта һәлак булган бит. Менә монысын аңлап бетерә алмыйбыз.

Ул арада класс ишегендә мәктәп директоры Нәзиров агай күренде. Коридорда барганда ишетеп калган, күрәсең…

— Нинди тавыш монда? Нәрсә булды?

— Нәрсә булсын, әнә, һаман шул Сәфәргалиев инде…

— Тагын нәрсә?

— Дәрес вакытында астан гына кирәкмәгән эшләр эшләп утыра…

Нәзиров агай Зөфәргә табан борылды.

— Нинди эш ул?

Зөфәр дәшмәде.

— Нинди эш дим, малай актыгы!

Зөфәр һаман дәшмәде.

Бу юлы Нәзиров агай үзе барып тикшерергә булды. Зөфәрнең партасы астыннан калын гына китап тартып чыгарды.

Озак кына ул китапның тышына карап торды, актаргалап чыкты, аннары, такта ягына борылып:

— Зөфәр бит әле? — дип сорады.

— Әйе… — Бу юлы Зөфәргә җан керде.

— Менә шул, Зөфәр туган, сиңа бик мөһим задание бирелә. Тиз арада шушы китабыңны укып чык та класс белән әңгәмә үткәр. Аңладыңмы?

Нәзиров агай, Зөфәрнең җавабын да көтеп тормыйча, кызу-кызу атлап чыгып китте, ә без, дәррәү килеп, теге серле китап өстенә ябырылдык. Зөфәрнең биш чатлы йолдыз тырналган партасында «Дошманны ничек җиңәргә?» дигән китап ята иде.

### 13. Мәхәббәтнең күзләре ачык

Кырык өченче елның язында фронттан Маннур абый кайтып төште. Бөтен җире дә таза, сау, тик күзләре генә күрми.

Аның Зәйтүнә исемле сөйгән кызы бар иде. Маннур абыйның авылга кайтуы хакында ишетүгә, иң элек шул Зәйтүнә йөгереп килеп җиткән. Маннур абый аны кире каккан. «Минем кебек имгәк сиңа нигә кирәк?» — дигән.

Зәйтүнә апа елап чыгып киткән. Бераз вакыттан соң тагын килгән. «Әйдә өйләнешик, матур дөнья корыйк, балалар табыйк. Шулар синең күзләрең булыр», — дигән.

Маннур аны тагын куып чыгарган.

Зәйтүнә тагын килгән, тагын, тагын…

Бик яраткан ди ул Маннур абыйны. Маннур үзе дә яраткан. Түзмәгән, ризалыгын биргән.

Боларын мин ишетеп кенә беләм. Ә менә туйда үзем булдым. Кияү егетләренә ияреп, уйнапҗырлап йөрдем, Маннур абый белән Зәйтүнә апаны «кияү келәте»нә дә үзем кертеп җибәрдем.

Туйдан соң әнкәйләр, пышан-пышан, серле сүзләр сөйләшә башладылар.

— Зәйтүнәнең назы килешкән…

— Маннурның күзләре яктырган…

— Нинди кошы, шундый чәчәге…

Соңрак барысы да ачыкланды: туй төненнән соң Маннур абыйның күзе ачыла башлаган икән. Беренче балалары туганда, ул урамда таяксыз-нисез йөри ала иде инде.

Иманым камил, Маннур абый белән Зәйтүнә апаның бу бәхетле тарихы сугыш афәтенә дучар булган бала чагымның иң матур хатирәседер.

### 14. Изгелеккә биш адым

Кырык өченче елның җәендә авылда Гайфи-пожарник пәйда булды. Фронттан түгел, төрмәдән кайтты ул. Сугышка кадәр үк, колхоз амбарына ут төрткән өчен, ун елга хөкем ителгән булган. «Пожарник» кушаматы да шуннан калган.

Эшкә минем янга билгеләделәр. Икебез ике атта, бер олау булып, кырдан ашлык ташыйбыз. Мин аңа төяргә булышам. Бер кулында өч бармагы юк, шуңа да капчык авызын бөтереп тота алмый ул. Гайфи минем әле генә ияләштерә башлаган атымны тыярга булыша. Турайгыр миңа баласытып карый, чыгымчылап интектерә, ә Гайфидән шүрли, ул күренү белән, шундук шым була.

Гайфи-пожарник күп сөйләшми, төрмә хакында бөтенләй дә ләм–мим. Рәхәт булмагандыр шул — аның бер колагы китек, ә йөз-бите тоташ җөйдән тора. Басынкы холыклы бу кешене һич кенә дә җинаятьче дип уйламассың. Игелеклелек, итагатьлелек аның холкында гына түгел, бөтен эш-гамәлләрендә, әйткән сүзендә, күз карашында бар иде.

Ике-өч ай янәшә эшләп, мин аның белән бер мәртәбә генә ныклап сөйләшеп алдым. Бу сөйләшүдән шуны аңладым: ул, чынлап та, колхоз амбарына ут төрткән булган. Кулак дип, келәтеннән соңгы икмәген алып чыгып киткәч, кызган баштан барган да төрткән…

— Дөрес эшләмәдем, ике капчык бодайга үч итеп, бөтен авыл игенен яндырырга тиеш түгел идем, — дип сөйләнде Гайфи.

Үзенчә философ иде ул. Тәүбә итүнең асыл мәгънәсен мин аңардан аңлап-төшенеп калдым.

— Явызлыктан изгелеккә биш кенә адым, — ди иде Гайфи-пожарник. — Беренчесе — үз гаебеңне тану; икенчесе — үз алдыңда тәүбә итү; өченчесе — якыннарың алдында тәүбә итү; дүртенчесе — Ходай каршында тәүбә итү; бишенчесе — шул ук урында кабат пәйда булсаң, бөтенләй башка төрле гамәл кылу…

Ходай Тәгалә сынавымы, әллә язмыш шаяруы булдымы — игенне ышыгына кертеп бетергәч кенә колхоз амбарларында янгын чыкты. Без, Гайфи белән икәү, якындагы басудан, колхоз кетәклегенә дип, кибәк җыеп йөри идек. Шундук торып чаптык. Ут ерак китә алмаган әле. Гайфи, ике дә уйлап тормыйча, төтенләнеп яткан амбарның такталарын каерырга кереште, мин ут дөрләгән почмакка туфрак ата башладым. Ул арада Гайфи эчкә кереп китте, бераздан, башын тыгып: «Авылга йөгер, мин монда утның юлын бүлә торам», — дип кычкырды.

Без җыелып килеп җиткәндә, амбардагы янгын басылган иде инде, Гайфи генә исән чыга алмады. Аның үле гәүдәсен җимерелеп, ишелеп төшкән стена бүрәнәләре арасыннан көчкә генә табып алдылар…

Күңелем ничек кенә әрнесә дә, андагы бер якты уйга һич кенә дә каршы килә алмадым: «Гайфипожарник изгелеккә табан ясаган соңгы — бишенче адымын да чын кешеләрчә үти алды…»

### 15. Ятимлек

Авылда ятимнәр күбәйгәннән-күбәя барды. Баштарак берәм-берәм генә булып, аларны җай чыккан саен жәлләп, сөеп, үсендереп китә торган булсалар, соңрак, һәр ике баланың берсе әтисез калгач, исләренә дә алмый башладылар…

Ятимлек белән бергә авылда начар гадәтләр дә пәйда булды. Әтиләре исән балалар белән ятимнәр арасында «сугыш чыкты». Берәм-берәм дә, күмәкләп тә бәргәләшмичә, төрткәләшмичә узып китә алмыйлар иде.

Иң кыены минем кебек малайларга төште. Безне ятим дип тә әйтеп булмый, әтиләребезнең исән булуы да шикле — «хәбәрсез югалганнар». Шулай да, без еш кына әтиләләр янына елыша идек. Ятим буласы килмәгәнгәдер инде.

Баштарак ятимнәргә күбрәк, ныграк эләкте. Ятимнәрнең саны арткан саен, әтиләләргә төшем күбрәк төшә башлады. Күзләрем шешенеп, йөз-битләрем кара янып, кешедән качып өйдә яткан чакларым күп булды. Әмма түзә идем, әтиле булу барыбер рәхәтрәк иде.

Бервакыт мин ятим булмавыма бик нык үкендем. Югары оч ятимнәре — Сәлим белән Вилдан — мине бер өемгә өеп, тукмап киттеләр.

Суккан саен, типкән саен: «Монысы әткәй өчен, әткәй өчен, әткәй өчен!» — дип тәкрарлыйлар, җитмәсә. Ак бабай күреп аермаса, бу ике әзмәвер егет минем күзне чыгаралар яисә кулсыз-аяксыз итәләр иде. Кәмит карагандай, уратып алып, егермеләп бала карап тора. Күбесе ятимнәр. Минем дә ятим буласым килде. Азчылык булып яшәү бик авыр бит, күпчелек булу җиңелрәк, җайлырак. Кайгы, хәсрәт, ятимлек, күз яше, каргыш күбрәк иде шул безнең авылда… Әле бит кырык өченче ел гына… Сугыш бетәргә тагын ике ел бар!..

Ятимнәрдән коткарып калган Ак бабай минем өчен Хозыр Ильяснының үзе белән бер иде. Аның бу көнне әйткәннәрен авыл малайлары бик озакка исләрендә калдырганнардыр.

— Нәрсә бүлешәсез? — дип сорады Ак бабай, өчебезне өч якка тарткалап.

— Аның әтисе исән… — дип мыгырданды Сәлим. Үзе һаман миңа уктала…

— Шуннан? Әтисе исән булу гаепмени? Синең әтиең юк инде. Аның әтисе дә үлсә, кем азат итәр илебезне? Кем җиңәр дошманны? Ә? Кем?

— Ятим мин, ятим!.. — Сәлимнең ярсып акланырга тырышуы Ак бабайны тәмам чыгырыннан чыгарды.

— Тукта, адәм баласы! Алма үзеңә авырлык! Гөнаһлар алма! Юк ул ятимлек! Юк! Башын яуда салган аталарның урынын Ходай Тәгалә үзе ала. Синең атаң — Ходай үзе, белдеңме? Син бу балага караганда өстенрәк, көчлерәк! Акланма! Кешегә бүтән кул күтәрмә! Ходайны, атаңны рәнҗетәсең килмәсә, күтәрмә!

## 16. Ясмин чәчәге

Күршедәге Мәрьям апаның өч улы да фронтта. Әлегә өчесе дә исән. Кырык өченче елның салкын кышында беренче шомлы хәбәр килде. Почта аша түгел, төш аша… Мәрьям апа олы малае Сабитны төшендә күргән икән. Начар күргән. Бура бурап йөри ди… Бура — үлемгә. Анысын бөтен кеше дә белә.

Бу хәбәр бөтен авылны тетрәндерде. Әле дә истә — 13 гыйнвар көн иде. Кешеләр Мәрьям апаларга җыела башладылар. Әнкәйгә ияреп, мин дә кердем. Кем кушылып елый, кем юата, кем, дәшмичә, үз күңеленә бикләнеп, бер читтә тора…

Хәтирә карчык та шунда. Ул күп сөйләшми, еламый да. Дога укып тик утыра. Менә ул догаларын укып бетерде дә, битен сыпырып, Мәрьям апа янына килде.

Аннары, балалар сөйгән кебек, аркасыннан кагып куйды:

— Бик бетеренмәле, бик елама… Болай елап утырсаң, Сабитыңның җанын өркетерсең… Өч көннән кайтачак ул… Тәрәзәңә киләчәк, көт, көт, — диде.

Күңелгә кереп калды бит бу сүзләр.

Икенче көнне иртән күзне ачуга ук әнкәйдән сорыйм:

— Сабит абыйның җаны кайтмаганмы әле?

Әнкәй аңламый. Үз мәшәкатьләре, үз кайгысы белән башы каткан.

— Нигә, кичә Хәтирә әби әйтте бит, тәрәзәгә җаны киләчәк, диде…

— Ә-ә, аны әйтәсеңме? Төш кенә бит ул, балам. Өзелеп көткән кеше бөтен нәрсәне дә күңеленә якын кабул итә башлый, шул гына…

— Алайса, нигә чынлап еладылар соң?

— Күзләрдәге ачы яшьне күпме саклап йөртеп була инде. Бер елап, бушанып алу ярый ул, балам…

— Син дә шуңа гына елыйсыңмы?

— Минме? Карәле, ачы таң белән сорау алып булаша, малай актыгы! Бар, тор тизрәк, мәктәбеңә соңга каласың!..

Әнкәй минем сорауга җавап бирмәде. Ә мин болай да беләм. Авыл апалары бушаныр өчен генә еламыйлар, чын-чынлап елыйлар. Сугышта бөтенесе дә чын.

Әнкәй миннән качып кына Мәрьям апаларга кереп чыкты. Дәшмәде. Димәк, Сабит абыйның җаны килмәгән әле. Килсә, әйтми калмас иде. Иртәрәктер шул. Хәтирә әби: «Өч көннән киләчәк», — диде бит.

Ишеткәнем бар. Үлгән кешеләрнең җаны күбәләк йә кош булып кайта. Мондый салкын кышта нинди күбәләк инде ул?! Нинди кош?! Сирәк-мирәк кенә күзгә чалына торган ала каргалар, йә булмаса күк күгәрченнәр булуы бар… Ә менә чыпчык халкы җитәрлек… Ләкин… алар бит мондагылар, алар күз алдында, аларда бернинди сер дә юк… Ә җан белән бәйле бөтен нәрсә дә серле, хәтта сихерле булырга тиешләр ул.

Икенче көнне дә кайтмады Сабит абыйның җаны. Өченче көнне дә… Кеше кызык бит ул. Аны сер тарта. Шушы сер авыл кешеләрен кабат Мәрьям апаларга җыя башлады. Без дә кердек.

Мәрьям апа бүген тыныч. Хәтта күңелчәнрәк тә әле. Көлеп, елмаеп сөйләшә. Тәрәзәсенә бернинди җан әсәре дә килмәгән, шуңа тыныч ул. Сабиты үлмәгән аның, Сабиты исән!

Шунда күзем тәрәз төбендәге ясмин гөленә төште. Бу матур гөл бүген бик сәер, хәтта серле димме?.. Аның куе яшел яфраклары арасында җете ак төстәге бер чәчәк балкып тора. Сер шунда икән. Кыш көнендә ясмин чәчәк атмый, дигән булалар тагы…

Мин әнкәйнең сырма чабуыннан тартам:

— Әнкәй, карале, ясмин чәчәк аткан…

— Тс-с, дәшмә… Мин дә күрдем аны… Хәтирә карчык та, башкалар да күрде…

— Ә Мәрьям апа?..

— Ул… Ул күрмәде әле…

Шул килеш таралыштык. Ике атнадан Сабит абыйның «кара кәгазе» килде. Тагын җыелдык. Акка кара белән чатнатып язып куйганнар: «Сезнең улыгыз Имамов Сабит 13 гыйнвар көнне дошманга каршы алып барылган каты сугышларда батырларча һәлак булды», — дигәннәр…

## 17. Бүре фәлсәфәсе

Быел кыш зәһәр дә салкын килде. Карлы-буранлы, давыллы булды. Шулай да, күңелләр күтәренке иде. Сталинград янындагы җиңү җан түренә җылы булып ятты. 22 дивизиясе белән камалышта калган Паулюска Гитлер да ярдәм итә алмады. Ак бабайның әйткәннәре һәрвакыттагыча образлы иде. «Капкынга эләккән бүре үз аягын чәйнәп өзде», — диде ул.

Без аның бу сүзен тагын бер вакыйгадан соң искә төшердек.

Бүреләр күп булды ул кышны. Күп малның башына җиттеләр бу явызлар. Баш бүрене тота алмыйча кыш үтә язды. Яшьрәкләре эләгә, әмма өер башы һаман исән кала. Шунсын тотмыйча, бу афәттән котылып булмаячак.

Февраль ахырларында анысы да эләкте. Гыйбрәт өчен, тиресен тунап, кәнсәләр алдындагы койма башына элеп куйдылар.

Тик нишләптер малларга һөҗүм тукталмады. Әле түбән, әле югары очтан, әле фермадан сарыклар һаман югала торды, ә явыз буран дошман бүреләрнең эзен кырып-себереп яисә күмеп куя иде. «Тагын берәр бүре ияләште микәнни?» — дип, аптырап бетте халык. Сак та, каравыл да куеп карадылар. Капкыннарның да иң шәбен юнәттеләр, бүрене кулга төшерә алмадылар.

Йомгак җепнең барыбер бер очы чыга, диләр бит. Бу юлы да шулай булды. Сарык фермасына куелган иң хәтәр капкыннарның берсенә килеп эләкте теге дошман. Эләгеп бетмәде бетүен, әмма кеше дә булмас инде — аягын чәйнәп качкан. Соры тәре!

Ак бабайның: «Капкынга эләксә, бүре аягын чәйнәп өзә», — дигән сүзләре шул вакытта искә төште дә.

Ләкин яралы бүре беркайда да табылмады. Бүресе түгел, эзе дә күренмәде хәтта! Тамып барган кан авыл башында гына торган Бүре Хәтмиләрдән уза алмаган.

Хәтми дигәннән, аны районга алып киттеләр. Аягы шешенеп бозыла башлаган, ди. Ә «Бүре» кушаматы шуннан калган — кирәкмәгән җиргә борын тыгып, җайсызрак яткан әйберләрне сорамыйча ала торган гадәте бар аның. Бу юлы да тиешсез җиргә тыгылгандыр, аяксыз кала язган бит әнә…

Ә? Бүре дигәннәре шул үзе булса? Бүре Хәтми!

Бу уй миңа берничә көн тынгылык бирми йөдәтте. Ләкин кемгә дә булса ачылырга җөрьәт итмәдем, хәтта әнкәйгә дә әйтмәдем.

Күңелемне бүреләр тырнап йөргән бервакытта, Хәтмиләр йортына тентү белән керделәр, бик күп сарык ите алдылар. Үзен авылга кайтарып тормадылар, ун елга ябып та куйдылар. Ә бозык аягын кискәннәр, бүтән урлашып йөрмәсен, дигәннәрдер инде.

## 18. Тимерҗан һәм аның командасы

Аркадий Гайдарның мәгълүм повестен җитәкчебез Фәһимә апа бөтен класс алдында кычкырып укыды. Безгә ул бик ошады. Үзебез дә шундый ярдәм командалары төзергә булдык.

Безнең мәктәптә берничә команда бар иде инде. Шул командалар белән яшелләргә һәм кызылларга бүленеп, кыш буе «сугышып» йөрдек. Теләп түгел, күбрәк өстән, районнан кушканга. Ләкин барыбер кызык иде, агач мылтык күтәреп, «ура» кычкырып басуларда йөргәндә фронттагы әткәй-

ләрне күз алдына китерә идек; бу мәлдә без аларга ничектер якыная идек, аларның күңелен, гамен, сагышын тоя идек, аларны ныграк аңлый идек... Нәкъ алар кебек, җиңгәндә — шатланып бүрекләрне чөябез, җиңелгәндә — качып кына елыйбыз. Бер генә өстенлегебез булгандыр — «үтерсәләр» дә, кабат терелеп, өйгә — әнкәйләрнең җылы өйрәсен чөмерергә кайтып китә идек...

Ә менә ярдәм командалары белән эш башкача тора. Уллары, ирләре сугышта үлеп калган ялгыз аналарга, карт-корыларга үзләре сизмәгәндә генә ярдәм итәргә тиеш идек без. Класс командасының башлыгы итеп Тимерҗанны куйдык. Исеме туры килгәнгә куйдык, югыйсә аннан да лаеклырак малайлар бар иде. Башта ук шундый карарга килдек: командада малайлар гына булырга тиеш. Кызларга ышаныч юк. Алар караңгыдан куркалар, этләрдән, ата казлардан, ябалак тавышыннан, капка шыгырдавыннан, тагын әллә нәрсәләрдән куркалар... Көчләре дә чамалырак, озакка чыгып та йөри алмыйлар — өйдә эләгәчәк...

Кызлар ялынып-ялварып сорап карасалар да, алмадык. Бигрәк тә Нәсимә җанга тиде. Бу кыз миңа ошый. Ул үзе дә матур итеп, яратып карый. Шуңа да: «Нәсимәне генә алыйк инде»,— дигән идем, Тимерҗан кырт кисте: «Юк, дигәч, юк! Аяк астында буталып йөрмәсен! Фррнттагы кебек булырга тиеш. Ә фронтта кызларга урын юк! Сугыштагы кебек — игелек һәм көч!»

Тимерҗанның соңгы сүзе команданың девизына әверелде. Шундук план төзедек, кемнәргә нинди ярдәм күрсәтү хакында киңәшләштек. Иң элек сугышка өч малаен җибәргән Миңниса апага барырга булдык. Аның кары көрәлмәгән, көчле буран абзар түбәсендәге саламны очырып алып киткән, утыны беткән...

Хәтирә карчыкка, Мәймүнә әбигә, Зәйнәп апага, Кирам бабайларга ярдәм кирәк. Кемнең капкасы ауган, кемнең саламы беткән, кемнең бәрәңгесе туңган, утыны ярылмаган... Барысын да исәпкә алып чыктык. Бер кич җыелып, катыргыдан йолдызлар кистек, аларны кызылга буядык, икенче төнне бу йолдызларны солдаткаларның, уллары фронтта һәлак булган әби-бабайларның капкаларына кагып чыктык.

Миңниса апада эшне бик тиз бетердек. Беркем дә сизми калды. Хәтта утынын да юнәттек. Һәр кеше үз өеннән икешәр утын агачы алып килеп, Миңниса апаның ишеге төбенә әйбәтләп өеп куйдык.

Зәйнәп апаларда да озак маташмадык. Төнге уникедә, эшне тәмамлап, өйгә кайтып ауган идек инде. Ә менә Мәймүнә әбиләрдә галәмәт хәлгә очрадык: без кача-поса барып кергәндә, әбекәйнең ишегалдында кар көрәлгән, күтәрмә баскычы төбенә су китереп куелган, утыны өелгән иде. Без шунда ук аңлап алдык: авылда тагын бер ярдәм командасы барлыкка килгән.

Бу хакта күп уйлап тормадык, эшләребезне дәвам иттек. Ләкин теге серле команда гел генә безнең юлга аркылы төшә, без барасы йортны әллә каян гына белеп, андагы эшне бетереп куя, безгә, кулларыбызны селтәп, кайтып китәргә генә кала.

Тимерҗан берничә малайдан разведчиклар группасы оештырып җибәрде. Ләкин файдасы булмады. Күз уңыннан югалып торган берничә сәгать эчендә без барасы картларның эшләре ниндидер җен шаукымы белән эшләнә дә куя.

Малайларга әйтмичә генә үзем разведкага чыгарга булдым. Берничә төн йокламасам йокламадым, әмма эзләренә төштем тегеләрнең. Көн төнгә авышкан чак иде. Миннән ике өй аша торган Нәсимәләрдән бер малай чыкты да, кача-поса, түбән очка таба китте. Кем бу? Нинди шайтан ияләшкән Нәсимәләргә? Ну тотсам! Мин — аның артыннан. Ул ашыга, мин ашыгам, ул йөгерә, мин йөгерәм, шулай йөгерә-йөгерә, авыл башындагы тәбәнәк кенә өйгә барып җитүебезне сизми дә калдык. Теге малай мәче кебек мыштым гына эчкә кереп китте, мин якындагы көрт артына постым. Каяндыр тагын ике малай килеп чыкты, тагын, тагын...

Мин барып кергәндә, малайлар киемен киенгән унлап кыз-кыркын Мәймүнә әбинең ишегалдын көрәп бетерәләр иде инде.

Нәсимәне шундук танып алдым. Ул да мине күреп алды. Бик чибәр иде бу көнне Нәсимә. Аның алсу йөзләреннән тотып, сыйпап карыйсы килә хәтта...

— Хәми-ит? Нишләп йөрисең монда?

— Менә... килдем әле... булышырга...— Каушавымны ничек кенә сиздермәскә тырышсам да, барып чыкмады. Шундук мине сырып алдылар, оялтырга керештеләр.

— Качып кызлар карап йөрү әйбәт эшме инде?

— Кайсыбыз артыннан килде-е-ең?

— Нәсимә, карале, малакаем, сиңа ничек карап тора!

Нәсимә исә шаярырга уйламады да.

Очлы күзләре белән җаныма үтәрдәй булып, үзенекен тукыды:

— Нишләп йөрисең монда?

— Разведкага килдем. Ник бездән яшереп команда оештырдыгыз?

Нәсимә сорауга сорау белән җавап бирде:

— Ә нигә үзегезгә алмадыгыз?
— Дөрес эшләдек.
— Без дә дөрес эшләдек.
— Дөресме, түгелме — иртәгә карарбыз…
Шунда Нәсимәгә нидер булды.
Ул кинәт йомшап китте, елардай булып, миңа ялына башлады:
— Хәмит, ярар инде, әйтмә инде… Сүз бирәбез — моннан соң сез барасы йортларга кермибез. Әйтмисеңме?
Нишлим соң? Ошый ул миңа! Шуңа да каршы килә алмадым. Ык-мык итеп булса да, Нәсимәләрнең серен ачмаска сүз бирдем.
…Җиңү көнендә мин аны беренче мәртәбә озата бардым. Ике өй аша гына торган Нәсимәләргә бик тиз барып җиттек. Нәрсә хакында сөйләштекме? Әнә шул кырык өченче елның кышында ярдәм командалары төзеп йөрүебез хакында, нәрсә хакында булсын…

## 19. Чулак Сафыйның үлеме

Кырык дүртенче елның җәе Сафый исемле кешенең үлеме белән истә алган. Аның тарихы болай.
Сугыш башлануга, авылыбызга читтән бер гаилә кайтып төште. Гаилә башлыгы — сугышка ярамаган Чулак Сафый дигән Украина татары. Хатыны исә, холкы беләнме, безнеңчә аңламагангамы, аз сүзле, салмак кына йөрүчән украинка. Үзләре белән берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала ияртканнәр.
Ташландык бер өйгә урнашып яши башладылар болар. Сафый бик тә уңган кеше булып чыкты. Хәленнән килгән, көче җиткән барлык эшне дә эшләде — фермада мал карады, көтү көтте, ашлык сукты. Өенә кайтса да, йокларга гына. Яисә үзләре үстереп җибәргән яшелчә бакчасында казынырга.
Килүләренә бер-ике ай үтмәгәндер, Сафыйлар хакында тирә-юньдә белмәгән кеше юк иде инде. Әйе, бик саран кешеләр иде алар. Ике ел яшәп, ике ел буе байлык җыйдылар. Эш көненә тигән аз гына ашлыкларын да сатып җибәргәннәр, дип сөйләнде халык. Бар булган киемнәрен, өй җиһазларын да талчукка илтеп бетерделәр. Бакчаларында күкрәп уңган кыяр-помидорларны да авыз итмәделәр бугай алар. Һаман шул базарга чыгардылар…
Авыл кешеләре, очраган саен, Сафыйның сөяккә калган балаларын кызганып, аларга бирәр кыерчык булса да икмәк биргәлиләр иде. Колхоз, мәктәп җитәкчеләре Сафыйны берничә мәртәбә идарәгә чакыртып та сөйләшкәннәр, ди…
Бердән бер көнне Сафый авырып китте. Ферма юлында хәлсезләнеп егылып яткан килеш тапканнар. Әмма ул түшәктә озак юанмады, берничә көннән тагын эшкә чыкты.
Инде бөтенләй эшкә ярамый башлагач, Сафый чүпрәк-чапрак, тимер-томыр, сөяк, көл җыю эшенә кереште. Шулай ул өч ел буе акча туплады.
Сугыш уты дөрләгән яклардан кайткан бу гаиләне баштарак авыл халкы ачык йөз белән каршы алса да, соңыннан алардан тәмам бизде. Кешеләрне Сафыйның комсызлыгы, саранлыгы читләштереп бетерде. Сафый берара юкка чыгып торгач, «әллә бу хатынын, балаларын ташлап, акчасы-ние белән читкә качтымы» диючеләр дә табылды. Кабат авылда пәйда булган Сафыйны кешеләр таный да алмадылар: беренче тапкыр ул елмаеп йөри башлады.
Кырык дүртенче елның җәй уртасында Сафый дөнья куйды. «Ач яшәде, үзен-үзе харап итте», — дип сөйләнде халык. Бер-ике авыл картыннан башка аның каберенә баручы да булмады. Кызык итеп кенә без берничә авыл малае барып карап тордык.
Сафый үлгәч, украин хатыны озак тормады — балаларын ияртеп, үз туган якларына кайтып китте.
…Инде сугыш тәмамланган иде, авылга каяндыр пөхтә киенгән хәрби кеше килеп төште. Күкрәге орден-медаль белән тулы бу гвардия капитаны Чулак Сафыйны эзли иде.
Халык сагаеп калды. Шулай да, кунакны зиратка алып барырга булдылар.
Кич зур җыелыш җыелды. Хәрби кеше сөйләячәген ишетеп, бөтен авыл клубка кереп тулды. Комсыз Сафыйның язмышы кемне генә кызыксындырмагандыр ул чакта.
Бар халыкны гаҗәпләндереп, хәрби кеше сүзен Сафыйга рәхмәт әйтүдән башлады. Баксаң, комсызлыгы белән даны чыккан Сафый, акча җыеп, бер танк сатып алган да фронтка җибәргән - икән. Дөресрәге, ул танкны әлеге капитанның кулына тапшырган. Ике ел буе танк дошманнарны кырган, Берлинга барып җиткән…
Хәрби кеше сөйләде дә сөйләде. Ә зал үкседе дә үкседе. Шулай төнге уникегә кадәр…
Ул көнне авылда төне буе ут янып чыкты. Җеназасында яткан Сафыйның ябык чыраена беленер-беленмәс кенә төшеп калган елмаю һәркемнең күңелен сыкрата, елата иде…

## 20. Дивана Даян

Даян абый авылга акылын җуеп кайтты. Контузияләнеп дошман кулына төшкәч, берничә ел фашист концлагерьларында булган, диләр. Шунда акылыннан мәхрүм калып исәрләнгән дә инде.

Кайчакларда зиһене ачылып китә иде мескенкәйнең. Дошман тылында күргәннәрен шунда сорашып кала идек.

Мин аны аеруча якын иттем. «Хәбәрсез югалганнар»ның фашист тоткынлыгында булырга мөмкинлеге хакында ишетеп белә идем инде. Бәлки, Даян абзый минем әткәйне күргәндер? Шул хакта сорашасым килде. Ләкин «Дивана Даян» белән сөйләшү бик кыен булып чыкты. Чак кына зиһененә кайтса да, ул шундук елый башлый, калтыранып, тетрәнеп үкси дә үкси… Бигрәк тә бала елаган тавыш ишетсә нишләргә белми, бәрелеп-сугылып йөри, җиргә ятып ауный яисә, ике колагын учлары белән каплап, җан-фәрманга читкә чаба… Соңыннан чамалап белдек — аларның бараклары яшь балалар тутырылган үлем бараклары белән янәшә булган икән…

Әткәйнең исемен ишетү белән, ул сискәнеп, айнып киткәндәй була, күзләрен шар ачып, офыкка төбәлә… Аннары тагын елый башлый, кулларын селти-селти нидер әйтмәкче була, шулай кемнеңдер каядыр китүен белдерә. Соңрак мин аны аңлый башладым. Дивана Даян минем әткәйнең качуы хакында сөйләмәкче була бит.

Аның балалар теле белән:

— Яхимҗан… Тачты, тачты!.. — дип тәкрарлавы миңа еш кына: «Рәхимҗан исән, исән!» — дип ишетелә иде…

Әнкәйгә дә әйттем. Әнкәй дә сорашып карады. Шул ук «тачты, тачты». Акылын җуйган бу Хода бәндәсе безгә хәбәрсез югалган әткәебез белән ниндидер серле-сихерле күпер кебек тоелды. Шуңа да без аны үз иттек, булдыра алган кадәр карадык, тәрбияләдек. Бервакытта да ач-ялангач булмады ул.

Әткәйне бик сагынган вакытларда мин аның янына бара идем дә шул ук сорауны бирә идем:

— Рәхимҗанны күрмәдеңме?

Ә ул безнең өчен дога сүзләре булып, илаһи аять булып әверелгән шул ук сүзләрне кабатлый:

— Яхимҗан… Тачты, тачты…

Миңа рәхәт булып китә. Димәк, качкан минем әткәй, дошман тикле дошман кулыннан качкан! Димәк, ул юлда, ул кайтачак, һичшиксез кайтачак!

## 21. Китап «җене» кагылган Герой

Кәрлә Гарәфи белән бер чордарак кайткан икенче кеше — югары урамда торучы Мирсалих абый. Менә ул чын фронтовик ичмасам! Фронтка да авылдан китте. Әле дә хәтеремдә: аның әнисе — безнең чыбык очы Сания апа — улының сугышка китүе уңае белән, бөтен туган-тумачаны, күрше күләнне җыйган иде. Әнигә ияреп мин дә мендем. Шундагы бер кызык күренеш хәтердә калган. Кемдер ишектән килеп керде дә түр сәке өстенә берничә йомырка тәгәрәтеп җибәрде.

Үзе имләп өшкергән кебек:

— Шушы йомырка кебек бөтен кайтсын, сау кайтсын,— дип теләк тели башлады.

Өйдә мин бу йоланы бик еш кабатлый идем. Әнием күкәй пешереп биргән саен, аны иң элек түшәктә тәгәрәтәм. «Әтием шушы күкәй кебек бөтен кайтсын, исән-имин кайтсын»,— дим, теләкләр телим.

Бу йоланы җиренә җиткереп башкара алмадыммы, әтием кайтмады, ә менә Мирсалих абый кайтты. Без моңа да сөендек, чөнки хәләл туганыбыз кайтты бит, авылыбызны тотардай кеше кайтты…

Герой булып кайтты. Дөрес анысы, безнең авылыбыздан Алтын Йолдызлы геройлар чыкмады. Бер Мирсалих абый гына чын геройларга тиңләнә ала иде. Чөнки аның өч Дан ордены бар. Закон буенча, Дан орденының тулы кавалерлары Геройларга тиңләштереләләр. Без моны әлегә белми идек. Әмма, күңелебез, йөрәгебез белән тоеп, Мирсалих абыйның бәясен, абруен бик югары тота идек.

Ә бәлки, сәбәп бөтенләй башка нәрсәдә булгандыр? Әйтик…

Мирсалих абый шәп балта остасы иде. Шуңа күрә дә аны агач эшенә куйдылар. Сугыш ахырына колхоз хуҗалыгы, амбарлар, фермалар нык кына туздды, шуларны рәткә китерәсе бар иде. Мирсалих абый агачны яхшы таный. Мин гомеремдә урман белән, агач белән аңлаша белгән андый кешене бүтән күрмәдем. Ул безне дә «агач теле»нә өйрәтте.

Әле дә хәтеремдә, Мирсалих абый утын агачларын берничә төркемгә бүлә иде: мунча миченә кара чыршы әйбәт икән. Аның күмере күп, ялкыны аз, мунча миченә күмер кирәк бит! Ә өй миченә имән, каен шәп. Мунчага имән, каен яксаң, ис тиячәк, көт тә тор.

Имәннән балта саплап утыручы малайларны орыша иде Мирсалих абый.

— Кулыгыз яңгырый бит, картлык көнегездә кулсыз-беләксез каласыз! — ди иде.

Балта сабына иң әйбәте — өрәңге. Ә менә элмә агачы дуга бөгәргә, тәгәрмәч тугымына, чана табанына әйбәт!

Аш-су өчен дә агачларның рәте бар икән. Бу хакта да Мирсалих абыйдан ишетеп белдек. Безнең авылда әле дә кабартмаларны — ак чыршы утыны, коймакны тал чыбыгы, сөян, зирек утыны ягып пешерәләр.

Шулай да, Мирсалих абыйның авыл балалары алдындагы абруе аның данлыклы китапханәсе белән бәйләнгәндер дип уйлыйм. Әйе, аңа китап «җене» кагылган иде. Сугыш афәте дә өркетеп чыгара алмаган аның бу «җенен».

Улы кайткач, Сания апа сөйләнгән, имеш:

— Сугышка китап төяп китте, сугыштан да китап төяп кайтты,— дигән.

Аның фронттан кайтып төшүен әле хәтерлим. Районнан бер «полуторка»га төялеп кайтты ул. Биш-алты әрҗә бушаттылар. Шул көнне үк халык арасында: «Саниянең олы улы неместән трофей алып кайткан, гел алтын-көмеш икән»,— дигән сүз таралды. «Трофей» дигән сүзне белә идек инде, ә менә биш-алты капчык алтынны күз алдына китерү кыен иде.

Китап булып чыкты ул алтын дигәннәре. Беренче баруда ук исем-акылым китеп кайттым. Сания апаларның бөтен стеналары китап белән тулган. Ниндие генә юк! Гарәпнеке дә, яңалифтәгесе дә, урыс хәрефе белән дә. Урысның үз китаплары да күп, хәтта немец телендәгеләр дә бар. Шиллер, Һейне дигән язучыларны мин беренче мәртәбә Мирсалих абыйдан ишеттем.

Олы-олы география атласлары да шунда ук сөяп куелган. Бер кечкенә шүрлектә шырпы кабы кадәр генә китапчыклар. Кәгазь, катыргы тышлылары янында күн, чүпрәк, хәтта агач, фанера белән тышланганнары да бар. Ә берсен… Калай кап эчендәгесен тотып карыйсы килде. Мирсалих абый читкә борылган арада, бармак очы белән генә кагылып алдым. Урта бер җирендә тишек бар икән… Һава керсен өчендер инде…

— Ә-ә, кызыкмы? Мине ул үлемнән саклап калды… Түш кесәмдә йөртә идем…

Сискәнеп киттем. Мирсалих абый үлем хакында сөйли бит. Ул сөйли, мин калай савытны әйләндереп-әйләндереп карыйм. Пуля тишеге шушы микәнни? Китабы да тишек. Үтәли чыккан икән. Үтәли чыккач, ничек исән калган соң ул?

Мирсалих абый каяндыр минем уйларымны белгән.

— Ничек исән калган дип уйлыйсыңмы? Менә шушы калай савыт фашист пулясының хәлен алган да инде. Йөрәккә кадәр керергә көче калмаган явызның. Бер атна госпитальдә китап укып яттым, шул булды.

Авыл клубындагы китапханәдә китаплар күп түгел. Бөтен авыл китапка Мирсалих абыйларга йөри. Мирсалих абыйга бу ошый. Үзе кебек үк китап белән җенләнүчеләргә ул хәбәр җибәрергә дә онытмый: яңа китап бар, янәсе… Һәр биргән китабын язып бара, укып кире китергәч, тагын билгеләп куя.

Миңа, минем тирәдә йөргән тагын бер-ике малайга, китап укып торасы да юк. Китапларның эчтәлеген Мирсалих абый бер иренмичә сөйләп бирә. Юк, анысын… үзебез дә ала идек. Өйгә бер генә китап алырга ярый. «Укып бетергәч, тагын килерсең, китап килеп алганны ярата», — ди иде ул.

Кайчакта «китапханәче» өйдә булмый. «Уфасында тагын китап эзләп йөридер», — дип каршы ала Сания апа. Бер-ике тапкыр Казанга барганын да хәтерлим. Без инде беләбез, чын күңелебездән ымсынып көтәбез, Мирсалих абый каядыр барып кайтса, авылыбыз тагын берничә айга китапка бөтенәячәк, китап сүзе белән рухын, ышанычын ныгытачак, өметен озынайтачак, күңелен тынычландырачак…

Кызганыч, Мирсалих абыйдан үз батырлыклары хакында сорашып калмаганмын. Үзе дә бик тыйнак булган, ахры. Хәйләкәр булган… Китап геройларының батырлыклары турында сөйләп, ул үз күргәннәре, үз кичергәннәре хакында бер авыз сүз дә әйтми киткән.

## 22. Соңгы кыш

Кырык бишенче елның февраль кышы бик авыр килде. Әткәй һаман кайтмады. Күпләрнең әтиләре кайтмады. Авыл тәмам бөлгенлеккә төште.

Дүрт еллык сугыш адәм балаларының иң соңгы ризык-тәгамнәрен тартып алды, соңгы бәрәңге тимер мич калаена куеп кыздырылды. Соңгы уч оннан боламык уып ашалды… Ягарга утын бетте, өй-тирә, абзар-кура яраксыз хәлгә килде. Кешеләр соңгы мал-туарларын суя башладылар.

Әмма атларга тимәделәр. Колхозда сыер малларының рәте-чираты юк иде, ә менә атларның саны кимемәде. Сугыш бетәсен беләбез инде. Сугыштан соң колхозларны күтәрергә кирәк булачак алар.

Авылда атларга хөрмәт болай да зурдан иде. Бер вакыйгадан соң бахбайларга илаһи җан ияләренә караган кебек карый башладык.

Февральнең гарасатлы-давыллы бер иртәсендә авылга шомлы хәбәр таралды. Астурам Хәлимә апаның Ильяс исемле кече малае югалган! Кичә кич түбән очтагы әбиләренә чыгып киткән булган. Иртә белән Хәлимә апа күңеле сизенеп барып керсә, Ильяс юк ди! Менә шуннан соң кыямәт купкан да инде. Хәлимә апаның йөрәге тоткан, күрше-күлән, урамдагы хәтәр буранга карамыйча, эзләргә чыгып киткән. Кәнсәләрдән килеп, безне дә эзләүче төркемнәргә куштылар.

Кемнеңдер башына җиткән: атларга атланып, кырга чыгып карарга булганнар. Адашып, авылдан ук чыгып китмәгәнме?

Шунда тагын бер күңелсез хәбәр мәгълүм булды. Пожарка лапасыннан иң яхшы биш атны урлаганнар. Бүрәнә киртәләрне, такта стенаны җимереп кергәннәр… Чәчүгә төшәргә вакыт җитәрәк кенә иң таза биш атның югалуы колхоз өчен әйтеп-аңлатып бетереп булмый торган афәт иде. Бу бәла хакында ишетеп, Ильясны эзләргә чыккан төркемнәр, бер-бер артлы, саманнан эшләнгән пожар ихатасына җыела башладылар.

Кайгырып ни кыласың? Адәм баласының җаны барыбер кыйммәтрәк. Ильясны табарга кирәк, атлар моннан хәтәррәк буранны да күтәрә, ә менә адәм баласы өчен бу карлы давыл үлем белән бер.

Буран басылмый да басылмый. Шулай да кузгалырга кирәк. Эчтә дә буран котыра. Иртәннән бирле бер тәгам ризык капкан юк. Ничек тә тизрәк теге малай актыгын табарга да җылы өйгә кайтып егылырга…

Шул вакыт күзем пожар утарының бер почмагына өелгән салам чүмәләсенә төште. Ул урында буран аеруча нык котыра. Әнә никадәр өйгән инде ул кар тавын! Туктале! Нишләп монда ике тау соң? Анда бер генә чүмәлә иде бит! Мин моны төгәл беләм. Шакир бабайга булышырга килгәндә ул якта мең тапкыр булганым бар…

Бер өемнән төтен чыккан кебек. Берәр нәрсә янамы әллә? Кар янамы? Бәй, кар янамыни? Кар өеменең тап урта бер җиреннән дулкын-дулкын пар күтәрелә. Сәер, хәтта серле күренеш…

Бу хакта янымда басып торган абзыйларга әйттем. Миннән аермалы буларак, алар шундук аңлап алдылар. Йөгерешеп барып, пар-бу бөркеп торган кар өемен көрәргә керештеләр.

Беренче ат күренүгә үк мин төшенә башладым. Башларын иеп, түгәрәкләнеп баскан биш ат уртасында, салам өстендә йөз-битен алсуландырып яткан Ильясны күргәч, тәмам аңлап җиттем: атлар, сабый баланың бәлагә таруын сизенеп, утарларын җимереп чыкканнар да, аңа туңарга, өшергә ирек бирмичә, төне буе, кайнар тыннары белән җылы өреп торганнар…

Аңын җуйган, әмма тормыштан ваз кичмәгән Ильясны күтәреп алып кайтып киттеләр, ә бөтен тәннәрен бозлы бәс сарган атларны иң кара көннәргә дип калдырылган затлы солы белән туйганчы сыйладылар.

Сугышның соңгы кышы авыр килде. Әмма, алдагы кышлардан аермалы буларак, бу кышта авыл бер генә кешесен дә югалтмады. Мин моның сәбәбен беләм: җиңүнең якынлыгын тоеп, тәгаен яшәүгә, язга омтыла иде халык.

### 23. Ак бабай

Бу сүзем Ак бабай хакында.

Әйе, һәр татар авылында шундый бер Ак бабай була. Авылның старостасы, мулласы, кирәк икән, пәйгамбәре, иң акыллы кешесе. Безнең авылда шундый кешеләрнең берсе — Хәтмулла карт. Ике улын сугышка озатып, икесен дә «хәбәрсез югалткан» бу карт үзенең Рәхимә абыстае белән бергә сугыш чоры татар авылын бөтен килеш, саф, иманлы килеш саклап калуда төп эшне башкарды, дисәм дә хакыйкатькә хилафлык килмәс.

Безнең Ак бабай чын Ак бабай иде. Ул үзенең күңелен, акылын беркемгә дә көчләп такмый, кеше күзенә кереп, яшәргә өйрәтеп тә йөрми, бары тик якын кеше булып, туган булып янәшәдә яши. Аның бу яшәве үзе үк авыл тормышына мәгънә, ямь бирә, күңелгә рухи көч, өмет, дәрт өсти.

Гадәттә Ак бабай иң кыен чакларда пәйда була.

Кырык икенче елга чыкканда кышның авыр килүе хакында әйткән идем инде. Бер бөртек икмәк валчыгына зар-интизар булып яшәгән вакыт бу. Дошман һаман илнең эченәрәк керә, үлем хәбәрләре ешая, күбәя, авылда ачтан, суыктан үлүчеләр арта… Менә шул мәлдә ягылмаган клубта колхозның җыелышы бара. Партия күрсәтмәләре укыла. Шул күрсәтмәләр буенча акыллы карарлар кабул ителә…

Дөресен генә әйткәндә, бу күрсәтмә-карарларга халыкның исе дә китми. Аның инде күңеле төшкән, рухы сына башлаган, киләчәккә өмете сүрелгән…

Менә шул минутта залдан Хәтмулла карт, ягъни безнең Ак бабай торып баса. Һәм үзенең йомшак, бәрхет тавышы белән бөтен дөньяны җылытып, акыллы сүзен башлый.

— Җәмәгать, мине дә тыңлагыз әле… Авыр, бик авыр. Афәт бөтен яклап та урмәләп керергә тора… Тәннәр генә түгел, җаннар өши… Кеше җаны кыела, адәм җаны кыела торган вакыт… Бу кадәр

авыр сынауның кеше башына төшкәне юк әле. Сүзем дә әнә шул турыда. Ходай Тәгалә җибәргән сынау дип кабул итик без бу кыенлыкларны. Һәм шуны онытмыйк: Ходай Тәгалә адәм баласына җиңә алырлык сынаулар гына җибәрә. Ходай язган булса, бу сынауны да үтәрбез, ничек тә үтәрбез, күңелебезне төшермик, йөрәгебезне юкка ярсытмыйк, газиз туганнарым минем!..

Бөтен авыл өчен әйтә алам: Ак бабайның бу сүзләре безне ары табан яшәтеп алып китте. Яшәүгә дәрт, киләчәккә өмет уятты. Иң мөһиме, һәр кеше Ходай Тәгалә тарафыннан үз күңелләренә иңдерелгән иманның көчен тойды, шул тоем аша рухын ныгытты.

Икенче бер вакытта мәктәпкә чакырдылар Ак бабайны. Шундый авыр вакытта да укуның кирәклеге хакында сөйләгәч, ул барыбызны да сискәндерерлек бер сүз ычкындырды. Ул сүзне башка берәр кеше әйтсә, елмаеп-көлеп кенә үткәреп җибәрер идек, Ак бабай әйткәч, күңелебезгә алып, мәңгелеккә җан түренә салып куйдык.

— Балалар, — диде ул, җанны иркәли торган ягымлы тавышы белән, — уку ул — Ходай Тәгалә ихтыяры. Коръән Кәрим дә: «Укырга, укырга һәм укырга!» — дип, өч мәртәбә тәкрарлап әйткән…

Сугыш чорында төшнең кадере күбәйде, мәгънәсе артты. Кешеләр бөтен өметләре сүнгәндә дә фал, юрау, төш кебек сихер хасиятләренә ябышып, чарасызлыктан котылып калырга теләделәр. Ләкин ни хикмәттер гел киресе килеп чыга иде: төшләргә һаман кайгы-хәсрәт керә, фалчылар, китапчылар сагыш, күз яше ача; юраучы-ырымчыларда да куандырырлык нәрсә юк — югалту, югалту, югалту…

Ак бабай боларның барсына түзеп яшәде-яшәде дә, бер җаен туры китереп, халыкка үз сүзен игълан итте:

— Җәмәгать, — диде ул, — дога теле белән сөйләшер урында юк нәрсә белән баш катырмагыз… Төшнең муены нечкә аның, кая таба барып юрасаң, шул булачак. Шуңа күрә нәрсә генә күрсәгез дә әйбәткә юрагыз!..

Ак бабай безне түземлеккә өйрәтте, сабырлыкка күндерде. «Сабырлык тар сукмак кебек: аның бер ягында — бәхет, икенче ягында — сагыш», — ди торган иде ул.

Ул безнең күңелдә тормышка, киләчәккә ышаныч, хәтта инану уятты. Аның: «Ышаныч — инануга, инану иманга нигез», — дигән сүзләре соңыннан да күпләр өчен яшәү шарты булып калгандыр.

Ак бабай, безнең кебек, мыек төрткән егетләрне, кешеләрне аңларга гына түгел, аларның ялгышларын, хаталарын кичерә белергә дә күндерде. Бүген миңа яшәү җиңел, чөнки ул кырык биш енче елның апрель кичендә үк, иренмичә, әллә нинди иләс-миләс уйлар, һавалы хисләр, тәшвишле идеяләр белән шыплап тулган яшь башыма кешенең асылы, рухи хасияте кеше булуның асылы хакында аңлатып, төшендереп куйды.

— Балакай, Рух дигәннәре иң элек авыр йөк тартучы ат кебек була, — дип, салмак кына сүз башлады ул, кайбер таныш-белешләрем хакындагы зарларымны тыңлагач, — аннары үз юлында бөтен нәрсәне юк итеп, чистартып йөрүче арысланга әверелә, соңыннан гына саф, керсез, гөнаһсыз бала рәвешенә керә, яши, үсә, камилләшә. Син, балакай, боларның барысын да үтәргә тиеш, шуларны үткәндә генә син теләгәнеңә ирешә алачаксың, чын кеше булачаксың…

Тагын бер айдан, Җиңү көненә ун көн калгач, Ак бабай җан тәслим кылды. Бөтен авыл белән кадерләп озаттык. Еламадык, яшь түкмәдек, тынычлап озаттык, чөнки Ак бабабызның ахирәт иясе буласын без төгәл белә идек. Аның изгелеген мәңгелеккә күңелләребезгә салып куйдык, хәтеребездән, догабыздан өзмәскә сүз бирдек.

Хәтмулла картның урынын Шакир бабай алды. Аны без элек тә Ак бабай дип әйткәли идек. Бераз борчылыбрак киткән күңелебез тагын тынычланды: бу изге бәндә дә ат кебек нык рухлы, арыслан кебек батыр, сабый бала кебек саф, гөнаһсыз зат иде.

### 24. Җиңү байрагы нинди төстә?

Авылга Җиңү көтмәгәндә килде. Күңелдән көтсәк тә, аның нинди икәнен белмәгәч, бик ышанып бетми идек әле. Сугышка нык кына күнегелгән иде шул.

Мин малайлар белән көтүдә идем. Шул ук Вилдан, Сәлим, Әсхәт, Зөфәр… Авылның көтүе зур түгел, әмма сыерларның холыксыз чагы бу. Кышкы ачлыктан соң кинәт кенә яшел чирәмгә баскан сыер халкы шулай бер-ике атна тиленәнеп ала. Олырак малайларны, чәчүдән аерып, көтүгә куялар. Минем көтүче булып китүемнең тарихы әнә шундый.

Бу көнне көтүне саклап калып булмады. Ничек кенә тырышсак та, төшке якта ук ярты малдан колак кактык, көн кичке якка авышканда, ике-өч сыер белән торып калдык. Шул үшән сыерларны куып авылга кайтып китүдән башка чара юк иде.

Нык кына эләгер дип уйлаган идек, киресенчә, безне шатланып каршы алдылар. Урамда очраган һәр апа: «Чукынып китсен сыерлары, Җиңү бит, Җиңү!» — дип, аркадан кагып, сөеп китә иде. Капка төпләрендә мөгрәп торган сыерлар да: «Җиңү! Җиңү!» — диләр кебек. Гүя алар Бөек Җиңүне тоеп,

белеп алданрак кайтканнар, бөтен дөнья бәйрәм иткәндә нишләп йөрисез яланда дип үпкәләрен дә белдерәләр әле…

Халык кәнсәләр алдына җыела башлаган. Колхоз рәисе Чулак Солтан белән ата коммунист Әхмәтгалиләр бер-бер артлы речь тоталар.

Мин әчкәрәк үттем. Шатланасы килә, әмма күңелдәге төер якты хисләрнең ташып чыгуына юл бирми тора. Их, әткәй дә кайтса!.. Кайтмады шул, кайтмады…

Шул вакыт кәнсәләр түбәсендәге озын колгага күзем төште. Белә-белгәннән бирле анда кызыл флаг эленеп тора иде. Хәзер ул юк. Кышкы буран алып киткән аны. Күпме эзләп тә таба алмадык. Ә флаг кирәк. Җиңү көнендә флаг булырга тиеш!

Мин ымлап кына малайларны җыеп алдым. Бер читкә китеп киңәшләшә башладык. Каян кызыл ситсы табарга? Кемдә бар?

Шунда Сәлим әйтеп куйды:

— Миндә былтыр Сабан туенда көрәшеп алган сөлге бар барын, аңа кызыл чигү дә төшкән, ярармы?

— Юк, бармый. Барыбер ак ул. Без бит аклар түгел, без — кызыллар. Ничек тә кызыл чүпрәк табарга кирәк.

— Нигә бармасын, бара! — Минем башта бик сәер, әмма үтә дә дөрес уй туды. — Канга буйыйбыз да эләбез! Безнең әтиләр сугышта әнә күпме кан түккәннәр әле, бер уч каннан гына үлмәбез, шулаймы, егетләр?

Башта аптырап, каушап калсалар да, бу фикерне малайлар шундук күтәреп алдылар. Сәлим өенә йөгерде, башкалар кызып-кызып ничек кан чыгару хакында гәпләшә башладылар. Йөзләре алсуланган, күзләрендә нур уйный. Һәркем нindидер таныш түгел халәт кичерә. Кан белән бәйле һәрнәрсә изге бит — моны малайлар да сизенәләр, шуңа да йөзләре җитди, күңелләре күтәренке.

Үткен пәкегә кытлык юк: сугыш чоры малайларының һәрберсендә кечкенә пәке йөри. Шунсыз булмый. Сугыш бара бит — кирәге чыгып куюы мөмкин.

Уч төбенә төртеп, һәркем үзенең хәләл канын тамыза башлады. Ул арада Сәлим килеп җитте.

Җиңү флагы кызарганнан кызара барды. Бу комач кисәген сөлге дип уйламыйсың да хәзер. Аңа авыл малайларының җылы каны сеңгән. Алар өчен фронт кебек бу. Кан коела икән, димәк, көрәш, димәк, фронт!

Байрак әзер булды. Кинодагыча, һәр малай аны, учларына алып, үбеп чыкты, аның алдында тезләнеп башын иде. Шуннан соң гына эләргә киттек.

Халык һаман да урамда әле. Кемдер гармун уйный. Кемдер җырлый, кемдер елый… Җиңү көне шушындый була икән… Җиңү шулай була икән…

Шобага тоттык. Сәлим белән Зөфәргә чыкты. Дөрес чыкты, Сәлимнең көрәшеп алган үз сөлгесе бит ул. Ә Зөфәр — мәктәптә малайлардан оештырылган хәрби отрядның командиры. Ул соңгы ике елда безне хәрби күнегүләргә өйрәтте, политинформация сәгатен алып барды…

Егетләр Җиңү флагын бөтен кеше карап торганда, көчле алкышлар астында элделәр. Кул чабып, алкышлап торган апалар арасында күзләрен сөрткәләп алучылар күп иде. Хәтта кайчандыр фронтта булып, имгәнеп кайткан ир-атлар да йөзләрен сыпыргалап алалар…

Нәсимә дә елый… Янына барып, башыннан сыйпыйсым, юатасым килде. Ул да мине күрде. Күз яшьләре аша елмаеп куйды. Без, оялышып, икебез ике якка китеп бардык.

Мин әнкәй янына килеп бастым. Кулбашына башымны салдым.

Аннары, үзалдыма әйткән кебек кенә әйтеп куйдым:

— Сугыш бетте, әнкәй, иң авыры артта калды, әйеме?

Әнкәй, яшьле күзләрен миннән бер тамчы да яшермичә, Җиңү флагына төбәлгән килеш, битараф кына әйтеп куйды:

— Иң авыры башлана гына әле, балам…

*2005*

### ***ЭЧТӘЛЕК***


Оча торган кешеләр, яки Иясез язмышлар хакында бәян *(Роман)*
Шартлау *(Повесть)*
Табылдык хатлар *(Повесть)*
Тимерче *(Кыйсса)*
Аллалар кайда яши? *(Бәян)*
Бала хакы *(Бәян)*
Сагышың булса, суга сал *(Повесть)*
Эт елы *(Бәян)*
Соңгы сугыш *(Бәян)*

Бөкре *(Бәян)*
Әткәйнең сугыш көндәлеге *(Повесть-хатирә)*

Литературно-художественное издание

***Гильманов*** *Галимьян Хамитьянович*

ЛЕТАЮЩИЕ ЛЮДИ

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Гыйльманов*** *Галимҗан Хәмитҗан улы*

ОЧА ТОРГАН КЕШЕЛӘР

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Л.П.Петрова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 6.03.2007. Форматы $84\times108^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Times New Roman» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 24,36 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 26,46. Нәшер-хисап табагы 26,47 + форз. 0,36. Тиражы 3000 д. Заказ С-101.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga. ru   e-mail: tki@tatkniga.ru.**

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.